АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
**Институт языка, литературы и искусства
имени Г. Ибрагимова**

# ТАТАРСКАЯ ГРАММАТИКА

Издание 2-е, дополненное

В трех томах

**Том II**

Казань
2016

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
**Г. Ибраһимов исемендәге**
**Тел, әдәбият һәм сәнгать институты**

# ТАТАР ГРАММАТИКАСЫ

Тулыландырылган 2 нче басма

Өч томда

**II том**

Казан
2016

**УДК 811.512.145'36**
**ББК 81.2Тат-2**
**Т 12**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карары нигезендә нәшер ителә*

«2014–2020 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен
һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү»
дәүләт программасы кысаларында басыла

**Проект җитәкчесе** – филол. фән. докт., проф. **М.З. Зәкиев**

**Фәнни редактор –** филол. фән. докт., проф. **Ф.М. Хисамова**

**Җаваплы редактор –** филол. фән. канд., доц. **Г.Ф. Гайнуллина**

**Рецензентлар:**
филол. фән. докт., проф. **Г.Р. Галиуллина,**
филол. фән. докт., проф. **К.Р. Галиуллин**

**Т 12** **Татар грамматикасы:** өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев. – Тулыландырылган 2 нче басма. – Казан: ТӘһСИ, 2016. – Т. II. – 432 б.
ISBN 978-5-93091-212-8

«Татар грамматикасы» татар теленең фонетик һәм грамматик системасын тасвирлап, аңлатып бирүне үз эченә ала. Бу хезмәт татар әдәби теленең төрле стильләреннән алынган бай фактик материалны хәзерге грамматик казанышларга таянып анализлау җирлегендә язылды. Икенче томда морфологиянең югары уку йортларында укытыла торган барлык бүлекчәләре дә урын алган.

Хезмәт тел белгечләренә, аспирантларга, студентларга һәм татар әдәби теле белән кызыксынган киң катлам укучыларга тәкъдим ителә.

**ISBN 978-5-93091-212-8**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият
һәм сәнгать институты, 2016

# КЕРЕШ

Морфология (грек теленнән *morphe* – ‘форма’, *logos*– ‘сүз, өйрәтмә’) – грамматиканың бер өлеше. Ул ике мәгънәдә кулланыла: беренчедән, телдәге сүзләрнең төркемнәре һәм шул төркемнәрдәге сүзләрнең грамматик категорияләре, ягъни сүз формалары – телнең морфологик төзелеше, дип атала, икенчедән, шул морфологик төзелешне өйрәнә торган фәнне дә морфология дип атыйлар.

*Морфология* сүзе, иң элек, биология фәнендә кулланылган, анда ул терлекләрнең һәм үсемлекләрнең формасын, төзелешен өйрәнә торган фән исеме буларак ныгып урнашкан. XIX йөздә исә бу термин тел гыйлеменә килеп керә һәм сүз төзелешен өйрәнә торган фәнне атый башлый. Сүз төзелешен җентекләп өйрәнү барышында аларны морфологик төркемнәргә һәм лексик-семантик төркемчәләргә аерып карау ихтыяҗы туа.

Морфология, грамматиканың бер бүлеге буларак, төрле телләрдә төрле юнәлештә үсеш ала. Төрки телләрдә дә ул сүзләрне төркемләү, сүз төркемнәрендә морфологик категорияләрне танып белү, сүзнең составын – морфларын, морфемалардагы аваз үзгәрешләрен өйрәнү кебек өлкәләрне үз эченә ала. Өйрәнү объекты шактый киңәйгәч, морфология эчендә **морфемика, морфонология** дигән бүлекләр оеша. Бу уңайдан морфологиянең өйрәнү объекты да конкретлаша. Аның төп бурычы – телдәге сүз төркемнәре системасын һәм аларга хас грамматик категорияләрне, ул сүзләрне төркемләүне һәм һәр төркемдәге морфологик категорияләрне өйрәнү.

Морфология фәнендә төп проблемаларның берсе – сүзләрне төркемнәргә аеру. Сүзләрне грамматик яктан, ягъни аларның лексик-грамматик табигатен өйрәнү, беренче чиратта, билгеле бер җирлектә аларны төркемләүдән башлана.

Хәзерге тел белемендә аерым сүзләр классына берләшкән сүзләр җыелмасы, ягъни сүз төркемнәре, тел төзешенә караган структур

берәмлекләр буларак кына түгел, ә телнең кулланылышына бәйле рәвештә, чынбарлык күренешләре турындагы төшенчәләрне аеруга хезмәт итә торган сүзләр җыелмасы, сүзләр классы булу ягыннан да өйрәнелә [Хисамова Ф., 2015, б. 52].

Грамматикада сүзләрне төркемләү билгеле бер принципларга нигезләнә. Төрле телләрдә сүз төркемнәре җыелмасында типологик уртаклыклар булган кебек, сүзләрне төркемләүдә дә уртаклыклар бар. Әмма галимнәр, сүзләрне төркемләгәндә һәр телнең үз үзенчәлекләрен исәпкә алырга кирәк, дип саныйлар. Төрки тел белемендә сүзләрне төркемләүнең теоретик ягы башлап И. Батманов, Э. Севортян кебек галимнәр тарафыннан яктыртылды. Татар тел белемендә исә бу юнәлештә Д. Сәлимованың төрле типтагы телләрдә сүз төркемнәрен чагыштырмача планда өйрәнүгә багышланган хезмәте аерым фәнни әһәмияткә ия [Салимова Д., 2001].

Татар телендә сүзләрне төркемләү лексик-семантик, морфологик һәм синтаксик принципларга нигезләнә. Аларны сүз төркемнәренең **классификация билгеләре** дип тә атыйлар.

Лексик-семантик яктан сүзләрне төркемләгәндә, аларның гомуми лексик мәгънәләре исәпкә алына. Гомумлексик мәгънә дип сүзләрнең конкрет лексик мәгънәләренә бәйсез, билгеле бер үзенчәлек буенча гомумиләштерелгән мәгънәләрне атыйлар. Телдәге аерым төркем сүзләр (мәсәлән, һәртөрле предмет, күренеш, вакыйгалар) киң мәгънәдә предметлык төшенчәсен, ә кайберләре исә эш-хәл, предметлык билгесе һ.б. кебек гомумиләштерелгән мәгънәләрне белдерәләр. Бу үзенчәлек – сүз төркемнәренең семантик ягы, дип атала.

Морфологик принцип буенча сүзләрне төркемләгәндә, аларның төрләнү мөмкинлеге, ягъни аларга хас грамматик категорияләр исәпкә алына. Телдә сүз төркемнәренең төрләнү мөмкинлеге төрлечә, ягъни һәр сүз төркеменең үзенә хас грамматик категорияләре бар. Әйтик, исемнәр килеш, тартым, сан белән төрләнәләр, фигыль заман, зат-сан, юнәлеш белән төрләнә, ә кайбер сүз төркемнәре үзләренең төрләнмәве белән башка сүз төркемнәреннән аерылып тора (мәсәлән, рәвеш). Сүз төркемнәренә хас бу үзенчәлек – аларның морфологик яки грамматик ягы, дип атала.

Синтаксик принцип дигәндә, сүзләрнең җөмләдәге типик функцияләре һәм сөйләм эчендә сүзләрнең үзара бәйләнешкә керү мөм-

кинлекләре исәпкә алына. Исем, мәсәлән, җөмләдә күбрәк ия һәм тәмамлык булып килә; сыйфат – аергыч, фигыль хәбәр функциясен башкара һ.б. Әмма татар телендә бер үк сүз төркеменә кергән сүз теләсә нинди җөмлә кисәге булып та килергә мөмкин. Шуңа күрә бу очракта теге яки бу сүз төркеменең иң еш кулланыла торган, ягъни типик функциясе нигез итеп алына.

Шунысын да онытмаска кирәк: сүзләрне кайсы гына яктан һәм нинди максат белән өйрәнсәк тә, аларның бары сөйләмдә генә реаль яшәвен онытмаска кирәк. Сүз бары сөйләмдә кулланылып кына төрле формаларны алган, шомара барган. Морфология фәнендә дә сүзләрнең төркемнәре аларның сөйләм оештыруда тоткан әһәмиятеннән чыгып билгеләнә.

Теге яки бу телдә сөйли белүче ул телнең һәрбер конкрет җөмләсен хәтерендә йөртми, бәлки ул сүзләрне, бәйләүче чараларны һәм җөмләнең шул телгә хас калыпларын гына үзләштергән була. Нәрсә турында булса да хәбәр итәргә кирәк булганда, сөйләүче кеше җөмләнең билгеле калыпларына сүзләрне бер-берсенә бәйләп салып бара, һәм шулай итеп сөйләм барлыкка килә.

**Татар телендә сүз төркемнәре.** Татар теле буенча язылган грамматик хезмәтләрдә сүз төркемнәре традицион тәртиптә өч төркемгә бүлеп карала:

– мөстәкыйль сүзләр: исем, сыйфат, сан, алмашлык, фигыль, рәвеш;

– ярдәмлек сүзләр: бәйлек, теркәгеч, кисәкчә;

– ымлыклар, аваз ияртемнәре һәм модаль сүзләр.

Әлеге бүленешнең нигезен алдагы бүлекчәдә әйтелгән сүз төркемнәренең һәр өч принцибына таянып билгеләү тәшкил итә.

**Мөстәкыйль сүз төркемнәре** лексик-семантик яктан реаль лексик мәгънәгә ия, ягъни алар чынбарлык күренешләрен атыйлар, предмет, күренеш, билге, эш-хәлләрне белдерәләр, яки аларга гомуми рәвештә ишарә итәләр. Морфологик яктан мөстәкыйль сүзләр төрләнәләр, аларга һәм сүз ясагыч, һәм форма ясагыч кушымчалар ялгана ала. Синтаксик яктан алар җөмлә кисәге булып киләләр.

Мөстәкыйль сүз төркемнәре арасында сан ягыннан иң күбесе – исемнәр һәм фигыльләр. Башкорт грамматикасын язучылар сүз төркемнәренә керә торган сүзләрне санап караганнар. Нәтиҗәдә сүзнең

лексик байлыгының яртысын диярлек исемнәр алып тора икән, фигыль нигезләре – 15 мең, калганын – 35 мең сүзне исем һәм фигыльдән калган сүз төркемнәре тәшкил итүе ачыкланган. Бу санау, дөрес үткәрелгән булса, татар телендәге лексик байлыкның бүленешен дә чагылдыра дип уйларга кирәк [Татар грамматикасы, 2002, б. 13].

**Ярдәмлек сүз төркемнәре** семантик яктан предметларны, билгене һ.б.ны турыдан-туры атамыйлар, ә чынбарлык күренешләре арасындагы мөнәсәбәтләрне, ягъни грамматик мәгънә (бәйлекләр, теркәгечләр), яки төрле мәгънә төсмерләрен (кисәкчәләр) белдерәләр. Бәйлекләр, теркәгечләр, кисәкчәләр төрләнмиләр, аларга сүз ясагыч һәм форма ясагыч кушымчалар ялганмый (морфологик яктан), алар, шулай ук, үзләре генә җөмлә кисәге булып та йөри алмыйлар (синтаксик яктан). Бәйлекләр һәм теркәгечләр телдәге функцияләре буенча форма ясагыч кушымчаларга якын торалар, чөнки алар сүзләрне һәм җөмләләрне бәйләүгә хезмәт итәләр, шулай ук төрле мөнәсәбәтләрне белдерәләр.

«Татар грамматикасы» хезмәтенең икенче басмасында сүз төркемнәре таблицасы түбәндәгечә бирелә:



Схемадан күренгәнчә, сүз төркемнәренең бүленешендә беркадәр аермалар бар. Анда сүз төркемнәре шулай ук өчкә бүлеп карала: 1) мөстәкыйль сүз төркемнәре; 2) бәйләгеч сүз төркемнәре; 3) модаль сүз төркемнәре. Мөстәкыйль сүз төркемнәренә исем, сыйфат, сан, алмашлык, фигыль, рәвештән тыш, рәвешкә өстәмә булып, тагын ияртемнәр һәм хәбәрлек сүзләр (барысы сигез мөстәкыйль сүз төркеме) карый; бәйләгеч сүз төркемнәренә – бәйлекләр һәм теркәгечләр; модаль сүзләргә ымлыклар, кисәкчәләр һәм модаль сүзләр керә [Татар грамматикасы, 2002, б. 11–12 ].

Модаль сүзләр составындагы *бар, юк, кирәк, тиеш* кебек сүзләрне аерып алып, аерым мөстәкыйль сүз төркеме – хәбәрлек сүзләр рәвешендә бәяләү өчен, объектив нигез юк. Грамматик хезмәтләрдә хәбәрлек сүзләр мәгънә төсмерләре һәм синтаксик функцияләре буенча ике төркемгә аерып карала: 1) хәбәр составында йөреп, сөйләмнең чынбарлыкка мөнәсәбәтен объектив рәвештә белдерә торган модаль сүзләр: *бар, юк, тиеш, кирәк* һ.б.; 2) сөйләмнең чынбарлыкка мөнәсәбәтен сөйләүченең субъектив бәяләве аша белдерә торган модаль сүзләр: *ахры, имеш, бугай, бәлки, әлбәттә* һ.б. [Тумашева Д., 1964, б. 279].

Д. Тумашеваның «Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе» (Казан, 1964) китабында сүз төркемнәре таблицасы түбәндәгечә бирелә:

Сүз төркемнәре таблицасы

| | Сүз төркеме | | Гомуми лексик мәгънәсе | Морфологик билгеләре | Синтаксик функциясе |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | | 3 | 4 | 5 |
| 1 | мөстәкыйль сүз төркемнәре | исем | предметлык | килеш, тартым, сан, хәбәрлек | ия, тәмамлык һ.б. |
| 2 | | сыйфат | предмет билгесе | төрләнми (дәрәҗә – асыл сыйфатларда) | аергыч, хәбәр |
| 3 | | рәвеш | эш-хәл яки билгенең билгесе | төрләнми | хәл, хәбәр |
| 4 | | сан | предметлар саны, тәртибе | исем урынына килсә, исем кебек төрләнә, калган очракларда төрләнми | бәйсез (исем ролендә), бәйле кулланыла |
| 5 | | алмашлык | югарыда күрсәтелгән мәгънәләргә гомуми рәвештә күрсәтү | алмаштырган сүз төркеме кебек төрләнә | алмаштырган сүз төркеме функциясен үти |
| 6 | | фигыль | эш яки хәл | наклонение, юнәлеш, барлык-юклык, заман, зат-сан, дәрәҗә | хәбәр һ.б. |

| 1 | 2 | | 3 | 4 | 5 |
|---|---|---|---|---|---|
| 7 | ярдәмлек сүз төркемнәре | бәйлек | сәбәп, максат, бергәлек, корал мөнәсәбәтләрен һ.б.ны белдерә | | үзе бәйләнгән сүз белән бергә җөмлә кисәге була |
| 8 | | теркәгеч | мөнәсәбәт белдерә, ияртү яки тезү бәйләнешләрен тәгъбир итә | | җөмлә кисәге була алмый |
| 9 | | кисәкчә | мәгънә төсмерләрен (модаль, чикләү, көчәйтү) белдерә | | |
| 10 | ымлык | | иң кыска юл белән эчке хис, тойгы, ихтыярны белдерә | | үзе җөмлә хасил итә, җөмләдәге сүзләргә бәйләнми |
| 11 | аваз ияртеме | | төрле тавышларга охшатып ясалган сүзләр | фигыль һәм исем ясагыч кушымчалар ала | җөмлә кисәге (хәл) булып килә ала |
| 12 | модаль сүз | | сөйләмгә мөнәсәбәт (модаль мәгънә) белдерүче сүзләр | уртак грамматик категорияләре юк | хәбәр, кереш сүз |

Димәк, өченче төркемгә ымлыклар, аваз ияртемнәре һәм модаль сүзләр кертелә. Алар үзләренең семантикасы һәм грамматик табигате ягыннан беренче ике төркемгә кергән сүз төркемнәреннән беркадәр аерылалар. Семантик яктан ымлыклар һәм аваз ияртемнәре, мәсәлән, шулай ук чынбарлык күренешләрен белдерәләр, әмма, мөстәкыйль сүзләрдән аермалы буларак, алар күренешләрне атап күрсәтмиләр, ә кыска юл белән, ягъни хис-тойгы яки охшату аша белдерәләр. Аларның атау (номинатив) функцияләре юк. Бу сүз төркемнәренең грамматик ягы да үзенчәлекле: ымлыклар һәм аваз ияртемнәре төрләнмиләр; ымлыклар җөмлә кисәге булып килә алмыйлар; аваз ияртемнәре исә үзләре генә дә җөмлә кисәге булып килергә мөмкин [Хисамова Ф, 2015, б. 56–57].

Ф. Хисамова «Татар теле морфологиясе» хезмәтендә (2015), татар теле белемендәге сүзләрне төркемләү буенча соңгы вакытта әйтелгән фикерләрне күздән кичереп, сүз төркемнәренең схемасын түбәндәгечә бирү уңышлырак дип саный:




Шул рәвешле хәзерге татар телендә җиде мөстәкыйль сүз төркеме (исем, сыйфат, сан, алмашлык, фигыль, рәвеш, аваз ияртемнәре), ике ярдәмлек сүз төркеме (бәйлек, теркәгеч) һәм өч модаль сүз төркеме (ымлык, кисәкчә, модаль сүзләр) исәпләнә.

Сүзләрне төркемнәргә бүлеп өйрәнүнең күп гасырлык тарихы булуга карамастан, бу өлкәдә бүгенге көндә дә бәхәсле һәм хәл ителмәгән мәсьәләләр бар.

Сүзләрне төркемләүгә караган җитди бәхәсләрнең объектив сәбәпләре Ф. Хисамованың «Татар теле морфологиясе» хезмәтендә тәфсилле аңлатыла:

1) флектив телләрдән аермалы буларак, татар телендә сүзләр тышкы яктан, ягъни формаль күрсәткечләр белән бер-берсеннән аерылмыйлар. Икенче төрле әйтсәк, татар телендә, мәсәлән, рус телендәге кебек, сүз төркемнәрен генә ясый торган махсус суффикслар юк. Тышкы яктан нәкъ бер төрле яңгырый торган сүзләр татар телендә төрле сүз төркемнәренә карарга мөмкин *(мендәр, зәңгәр);*

2) икенче объектив кыенлык – грамматик (морфологик һәм синтаксик) яктан охшаш сүз төркемнәре булу. Шуңа бәйле рәвештә

хәзерге татар тел белемендә сыйфат һәм рәвеш сүз төркемнәрен бер-берсеннән аеру иң бәхәсле мәсьәләләрнең берсе булып тора. Сыйфат та, рәвеш тә морфологик яктан төрләнми, аларга, өлешчә, дәрәҗә категориясе генә хас. Синтаксик яктан сыйфатның җөмләдәге типик функциясе – аергыч һәм хәбәр булып килү; сыйфат сүз төркеменә кергән бер төркем сүзләр (*матур, яхшы, начар* һ.б.) җөмләдә хәл булып та килә алалар: ***матур** җырлый, **яхшы** эшли, **начар** күрә* һ.б. Рәвеш, башлыча, җөмләдә хәл функциясендә килә, аерым очракларда ул, сыйфат кебек, аергыч булырга мөмкин: ***күп** халык, **аз** сүз, **әкрен** кеше* һ.б. Сыйфат һәм рәвешне аеру өчен иң әһәмиятле критерий итеп, аларның лексик-семантик ягы алына, ягъни сыйфатлар тел кулланылышында күбрәк – предмет билгесен, ә рәвешләр эш-хәл билгесен белдерәләр;

3) сүзләрне төркемләүдәге өченче объектив кыенлык итеп татар телендә контекстта исемләшү (субстантивация) күренешен һәм сүз төркемнәренең бер-берсенә күчеше – конверсия ысулы белән сүз ясалышын билгеләргә мөмкин. Чыннан да, мәсәлән, килеш, килешләр белән төрләнү морфологик аспектта исем сүз төркеме өчен хас грамматик билге булып саналса да, татар теленең үзенчәлеге нигезендә, башлыча исемләшү күренешенә бәйле рәвештә, теләсә кайсы сүз төркеме диярлек килешләр белән төрләнә. Әмма һәр килеш белән төрләнгән сүз исем була алмый билгеле [Хисамова Ф., 2015, б. 59].

Хәзерге тел белемендә сүз төркемнәрен аеру, сүзләрне төркемләүдәге төп бәхәсле моментлар да, асылда, исем һәм сыйфат, сыйфат һәм рәвеш сүз төркемнәренең үзара мөнәсәбәтен ачыклауга кайтып кала.

Исем һәм сыйфат сүз төркемнәренең үзара мөнәсәбәтенә килгәндә, татар теленең грамматик үзенчәлекләренә бәйле рәвештә (ачыклаучы сүз алдан килә), бер исем бернинди кушымча алмаган хәлдә икенче исемне ачыклап килә ала (I төр изафә). Төрки изафәдә алдан килгән исем ахырдан килгән исемне ачыклый: ***таш** йорт, **агач** күпер, **салам** эшләпә, **йон** кофта* һ.б. Мондый очракта беренче исем икенчесен материалы буенча ачыклый; ***укытучы** апа, **инженер** егет, **укучы** малай* – беренче исем икенчесен билгеле бер шөгыль, профессия буенча ачыклый һ.б. Рус телендә исә мондый сүзтезмәләрдә исемнән махсус суффикслар ярдәмендә ясалган сыйфатлар килә: *каменный, деревянный* һ.б. Төрки тел белемендә аерым очракларда бу рәвешле кулланылган исемнәрне сыйфат сүз төркеменә кертеп карау бар. Шуңа

бәйле рәвештә «Татар грамматикасы»ның I томында һәм Ф. Ганиевнең сүз ясалышы буенча хезмәтләрендә күп кенә исемнәр сыйфат сүз төркеменә күчкән сүзләр дип (конверсия) бәяләнә. Икенче төрле әйткәндә, татар телендә *таш, йон, агач* һ.б.ш. исемнәр һәм шундый ук сыйфатлар бар булып чыга.

Күпчелек галимнәр исә, аерым алганда татар тел белемендә, бу мәсьәләгә башкачарак караштa торалар.

Д. Тумашева, мәсәлән, ***таш*** *йорт,* ***агач*** *өй,* ***алтын*** *сәгать,* ***күн*** *итек* кебек мисалларда *таш, агач, алтын, күн* кебек сүзләрне турыдан-туры сыйфат дип санауга каршы чыга, болай карау бу сүзләрнең татар телендәге мәгънәсенә туры килми, дип саный [Тумашева Д., 1964, б. 83], һәм аны түбәндәгечә дәлилли: «...чөнки алар билге төшенчәсен түгел, предметлык мәгънәсен белдерәләр һәм, аергыч булуларына карамастан, исем булып калалар. Исемнәр икенче исемгә тартым аша бәйләнәләр: ***таш*** *өеме,* ***агач*** *үзәге,* ***алтын*** *эшләре остасы,* ***күн*** *заводы* һ.б.».

М. Зәкиев шундый ук карашны фәнни нигезләп, синтаксик яктан дәлилли. Ул бер исемнең икенче исемне бернинди кушымчасыз ачыклап килә алуын урал-алтай телләренең үзенчәлеге, һинд-европа телләре төзелешеннән аермасы дип саный: «...татар телендә исемнәр, исем белән бирелгән төшенчәләрне конкретлаштырганда, ягъни аергыч булып килгәндә, исемнәр дә, фигыльләр дә, саннар да, хәбәрлек сүзләр дә сыйфатка әйләнмиләр, шул ук сүз төркеме булып калалар. Мәсәлән, *агач күпер, укыган кеше, икенче төркем, юк сүз* кебек тезмәләрдә синтаксик планда *агач, укыган, икенче, юк* сүзләре аергыч булып киләләр, ә морфологик яктан *агач* – исем булып, *укыган* – фигыль булып, *икенче* – сан булып, *юк* – хәбәрлек сүз булып кала» [Татар грамматикасы, II т. , 2002, б. 13].

Төрки тел белемендәге бу бәхәсле мәсьәләне, ягъни исем – сыйфат, сыйфат – рәвеш мөнәсәбәтен ачыклауга Д. Сәлимова хезмәтендә дә шактый зур урын бирелә. Аерым алганда, галимә икенче бер исемне ачыклап килгән исемнәрне сыйфатка күчү (конверсия) дип карауга каршы чыга һәм үз фикерен фәнни юнәлештә төрле яктан дәлилли. Ул, беренчедән, исемне ачыклаган теләсә нинди исемне «Татар грамматикасы»ның I томында сыйфат буларак бәяләү белән килешми, лексик-семантик ысул белән (полисемия) ясалган кайбер сыйфатларның

яки троплар рәвешендә кулланылган сүзләрнең дә конверсия күренеше буларак билгеләнүен хаклы рәвештә тәнкыйтьли: ***баш** врач,* ***арыслан** егет,* ***елан** хатын* һ.б. [Сәлимова Д., 2001, б. 168–169].

Бу хезмәттә шулай ук сүз төркемнәрен аеруда сүзләрнең лексик-семантик ягы (семантик принцип) хәлиткеч роль уйнавына басым ясала, *агач, тимер, алтын* кебек сүзләрнең аергыч ролендә килгәндә дә билге мәгънәсен түгел, предметлыкны белдерүе ассызыклана. Мондый сүзләрнең сыйфатка (нисби сыйфатларга) күчмәвенә өстәмә дәлил итеп Д. Сәлимова, беренчедән, нисби сыйфатларның татар телендә дә, рус телендәге кебек үк *(весенний, зимний),* бары тик махсус кушымчалар белән ясалуын *(язгы, кышкы, шигъри, педагогик),* икенчедән, сыйфатларның ачыкланган исем алдындагы позицияләре иректә булуын, ягъни сыйфат һәм сыйфатланмышларның аралары ерагаю мөмкинлеген күрсәтә [шунда ук]. Чыннан да, мәсәлән, *кышкы юл, кышкы озын юл; кышкы озын, авыр юл* дип әйтелә, әмма *зур таш йорт* тезмәсен *таш зур йорт* яки *матур агач кашык* тезмәсен *агач матур кашык* дип әйтеп булмый.

Изафә бәйләнешенә кереп, икенче бер исемне ачыклаган исемнәрне сыйфат дип билгеләү телебездә сыйфатларның (исемнәр исәбенә) табигый булмаганча артуына китерәчәген дә галимнәр дөрес билгеләр: «...аергычлар рус телендә, башлыча, сыйфатлар белән, ә татар телендә исемнәр белән биреләләр, шуның өчен сыйфат сүз төркеменә керә торган сүзләр сан ягыннан рус телендә күбрәк, татар телендә азрак, һәм, аергыч булып исемнәр дә килә алганлыктан, татар теле өчен (һәм гомумән, урал-алтай телләре өчен) сыйфатның күп булуы кирәк түгел. Бу – закончалык» [Татар грамматикасы, II т., 2002, б. 14]. Шул ук вакытта типология дөньядагы теләсә кайсы телдә исемнәрнең сыйфатларга караганда берничә тапкыр артык булуын да билгели.

Төрле телләр арасындагы мондый типологик аермалыклар морфология буенча булган гомумтеоретик хезмәтләрдә дә искә алына. Мәсәлән, «Общая морфология» дигән хезмәттә сыйфатларның, яки билге белдерүче сүзләрнең кулланылышы буенча телләр өч төргә бүлеп карала:

1) адъектив телләр, ягъни сыйфат сүз төркеменә бай телләр;

2) фигыль телләр («глагольные»), бу телләрдә исемне ачыклау өчен күбрәк сыйфат фигыльләр («причастие») кулланыла;

3) исем телләр («именные»), ягъни исемнәр икенче бер исем белән ачыклана торган телләр. Мондый телләр сыйфатларга ярлы телләр дип билгеләнә, һәм аларда нисби сыйфатлар ролендә күбрәк иялек килешендәге яки башкача бәйләнештәге исемнәр килә: «Так называемые относительные прилагательные в адъективно бедных языках будут иметь не адъективную, а иную, главным образом субстантивную реализацию.<...> Семантическими эквивалентами относительных прилагательных в таких языках являются существительные в генитиве или другие конструкции с участием существительных» [Плунгян В., 2000, с. 245].

Татар тел белемендә сүз төркемнәре турындагы бәхәсле карашларга шулай ук сыйфат һәм рәвеш сүз төркемнәренең үзара мөнәсәбәтен ачыклау да керә. Семантик яктан һәр икесе б и л г е төшенчәсе белән бәйле һәм грамматик яктан төрләнми торган бу сүз төркемнәрен аеруда, чыннан да, билгеле бер кыенлыклар бар. Классификация билгеләре буенча карасак:

– лексик-семантик яктан сыйфатлар – предмет билгесен, рәвешләр эш-хәл билгесен белдерәләр: ***матур*** *җыр,* ***язгы*** *көн* – сыйфатлар; ***тиз*** *эшли,* ***күп*** *укый,* ***геройларча*** *көрәште* – рәвешләр;

– морфологик яктан сыйфат та, рәвеш тә төрләнми торган сүз төркеме. Сыйфатка бары тик дәрәҗә категориясе хас: *яхшы – яхшырак – иң яхшы;* рәвешләр дә еш кына дәрәҗә күрсәткечләрен алалар: *тиз – тизрәк – иң тиз;*

– синтаксик яктан исә сыйфатлар күбрәк исем сүз төркеме белән бәйләнешкә керәләр һәм җөмләдә аергыч функциясен башкаралар; бер төркем сыйфатлар исә (*яхшы, матур, пөхтә, начар* һ.б.) фигыльләр белән бәйләнешкә кереп, хәл функциясендә дә килә алалар: ***яхшы*** *эшли,* ***матур*** *яза,* ***пөхтә*** *киенә* һ.б. Рәвешләр күпчелек очракта эш-хәлне ачыклыйлар һәм, фигыль белән бәйләнешкә кереп, җөмләдә хәл булып киләләр, сирәгрәк аергыч булып та кулланылырга мөмкиннәр: ***шәп*** *кеше,* ***аз*** *сүз,* ***татарча*** *китап* һ.б.

Шул рәвешле, семантик яктан һәр икесе билге төшенчәсен белдерә торган һәм грамматик яктан (аеруча синтаксик функцияләре белән) үзара охшаш бу сүз төркемнәрен бер-берсеннән аеру мәсьәләсенә галимнәр төрлечә якын киләләр. Д. Тумашева, мәсәлән, грамматик билгеләре белән охшаш булган бу сүз төркемнәрен аеруда лексик-

семантик якка өстенлек бирергә кирәк, дип саный, ягъни телнең гомуми кулланылышында теге яки бу сүз күбрәк предмет белдерәме, әллә эш-хәлне төрле яклап характерлыймы, шуннан чыгып, аларның сүз төркеме буларак статусын билгеләү ягында тора. Бер үк сүзне, синтаксик функциясенә карап, бер очракта сыйфат дип, икенче очракта рәвеш дип билгеләүгә галимә каршы чыга: «Әгәр дә сүзнең семантикасында билге төсмере көчле булса, аларны, аергыч яки хәл булып килүләренә карамастан, сыйфат дип карарга кирәк: ***сөйкемле*** *кыз* – ***сөйкемле*** *сөйләшә,* ***авыр*** *мәсьәлә* – ***авыр*** *чишелә,* ***җиңел*** *кием* – ***җиңел*** *карау,* ***матур*** *җыр* – ***матур*** *җырлау* һ.б. Мондый очракларны сыйфатларның рәвеш ролендә килүе һәм, киресенчә, (***күп*** *кеше,* ***татарча*** *китап* һ.б.) рәвешнең сыйфат ролендә йөрүе дип бәяләү мәсьәләне хәл итүдән ерак тора...» [Тумашева Д., 1964, б. 83].

Бу мәсьәләгә үз чорында В. Хангилдин да игътибар иткән, һәм аның фикерләре шактый оригиналь һәм кызыклы. Ул татар телендә сыйфатларны семантик һәм грамматик билгеләре буенча ике төркемгә бүлеп карый. Беренче төркемгә ул бары тик предмет билгеләрен генә белдерә торган сыйфатларны кертә: *кышкы, язгы, кичке, авылдагы, җирдәге, тозлы, тозсыз, күтәренке, кызыл, сары* һ.б. Икенче төркемне ул, предмет һәм эш-хәл билгеләрен белдерә ала торган сыйфатлар, дип атый, һәм аларга *яхшы, матур, тыныч, күңелле, вак, киң, тыгыз, начар* һ.б. сүзләрне кертә. Шундый ук мәгънәдәге сүзләргә ул *аз, күп, якын, ерак* рәвешләрен дә китерә. Галим фикеренчә, мондый сүзләрнең статусын билгеләү «аларның сыйфатлык яки рәвешлекләре шул ике сүз төркеменә хас төп грамматик билгеләрнең кайсы аларда көчлерәк булуын, күбрәк табылуын чамалау аша» хәл ителергә тиеш була [Хангильдин В., 1954, б. 84–85].

Телебездәге чыннан да катлаулы бу күренешне аңлатуда башка төрле карашлар да бар. Татар телендә сүз ясалышын өйрәнүгә багышланган хезмәтләрендә, мәсәлән, Ф. Ганиев мәсьәләне башка фәнни юнәлештә чишүгә омтылыш ясый. Рәвеш һәм сыйфатның охшаш кулланылышын галим конверсия ысулы белән сүз ясалышы буларак билгели [Татарская грамматика, I т.]. Бу караш шулай ук «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндәге (3 томлы) искәрмәләрдә дә чагылыш тапкан. Әмма бу очракта типологиядә сүзләрне төркемләүгә карата куелган төп таләп бозыла, чөнки бер үк сүз, бер үк вакытта һәм бернинди

тышкы билгеләрсез, төрле сүз төркемнәренә карый алмый: *матур* – сыйфат, *матур* – рәвеш; *яхшы* – сыйфат, *яхшы* – рәвеш дип билгеләү сүзләрне төркемнәргә бүлү зарурлыгын да юкка чыгара. Бу очракта, башка галимнәр белән беррәттән, Д. Сәлимованың да: «Возникает резонный вопрос: как вообще производить классификацию частей речи (морфологических единиц) татарского языка, если одно минимальное условие – окружение слова – способно изменить частеречную принадлежность слов?» – дип сорау куюы бик урынлы.

**Грамматик категория турында төшенчә.** Грамматик категория – телнең морфологиясен өйрәнүдә төп төшенчәләрнең берсе. **Грамматик категория** дип грамматик мәгънә һәм грамматик форма берлегенә әйтәләр. Грамматик мәгънә җөмлә эчендә сүзләр үзара мөнәсәбәткә кергәндә барлыкка килә, башкача әйткәндә, грамматик мәгънә – нинди дә булса мөнәсәбәт белдерү; грамматик форма исә грамматик мәгънәләрне белдерә торган морфологик чара ярдәмендә ясалган сүз формасы (сүзформа).

Хәзерге тел белемендә грамматик категорияне уртак грамматик мәгънәгә ия булган формалар рәте – парадигма дип билгеләү киң таралган. **Парадигма** дип бер үк сүз нигезенең күп төрле грамматик формаларда килүенә әйтәләр. Парадигмалар гадәттә баганалап яки таблица рәвешендә бирелә (килеш парадигмасы, тартым парадигмасы һ.б.).

Грамматик категорияләр синтагматик һәм модаль төрләргә бүленәләр. Синтагматик грамматик категорияләр сүзләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләрен белдерәләр һәм шул юл белән сүзләрне үзара бәйлиләр. Мәсәлән, килеш формалары, хәл фигыль, сыйфат фигыль, шарт фигыль формалары сөйләмдә сүзләрне бер-берсенә бәйләү хезмәтен үтиләр, ягъни синтагматик төргә керәләр: *укучының китабы; урманга бару; укыган кеше; укып сөйләде; белешкәч, әйтте; белсә, сөйләр* һ.б. Бу мисаллардагы сүзләрне бәйләүче *-ның, -га, -ган, -п, -кәч, -сә* кушымчаларының һәрберсенең үз морфологик мәгънәләре бар, алар сүзләр арасындагы мәгънә мөнәсәбәтенә дә туры киләләр.

Модаль грамматик категорияләр сүзләрне түгел, ә сөйләүче белән чынбарлык арасындагы мөнәсәбәтне белдерәләр, шуңа күрә алар сүзләрне үзара бәйләүдә катнашмыйлар. Аларга сан (тартым һәм хәбәрлек кушымчалары булмаганда), фигыльләрдә, сыйфат һәм рәвешләрдә дәрәҗә, юнәлеш, заман, наклонение категорияләре керә: *юл – юллар,*

*зур – зуррак, кара – кап-кара – карарак, укый – укыды – укыган иде – укый иде – укыячак – укыячак иде* һ.б.

**Кушымчаларны төркемләү.** Морфология фәне элек-электән сүзләрне төркемләү белән генә түгел, сүзнең төзелеше белән дә җентекле шөгыльләнә. Соңгы елларда сүз төзелешен җентекләп өйрәнүне морфемика исеме белән аерым бүлеп чыгардылар. Ләкин бу, морфология сүз төзелешенә бөтенләй игътибар итми дигән сүз түгел. Морфология грамматик категорияләр белән эш итә, димәк, ул категорияләрнең формаларын – кушымчаларны да читтә калдыра алмый. Шуңа күрә, морфемиканы бераз кабатлау булса да, биредә кушымчаларны төркемләү мәсьәләсенә дә гомуми генә тукталу сорала.

Кушымчалар, иң элек, ике зур төркемгә аерыла: **ясагычлар** һәм **мөнәсәбәт белдерүчеләр.** Соңгысын традицион рәвештә төрләндергечләр дип тә атыйлар.

**Ясагыч кушымчалар** сүздән сүз ясау өчен кулланылалар. Мәсәлән*, эш – эш-лә, утын – утын-лык, тимер – тимер-че, илә – илә-к* һ.б. Тарихи яктан ясагычлар да төшенчәләр һәм күренешләр арасында төрле мөнәсәбәтләрне белдерү кирәк булганлыктан килеп туганнар, һәм хәзер дә аларның ул мәгънәләре югалып бетмәгән. Мәсәлән, син һәм эш төшенчәләрен бәйләп фикер әйтергә кирәк булганда, сөйләүче икенче затны хәрәкәткә өнди икән, *син эшлә* дигән җөмлә төзи, һәм монда *-лә* ясагычы *син* һәм *эш* сүзләре арасында билгеле бер мөнәсәбәт тә урнаштыра.

*-че* кушымчасы да башта исем белән исем арасында мөнәсәбәт белдергән: *тимерче кеше.* Ләкин мондый очракта икенче исем, башлыча, *кеше* сүзе белән бирелгәнлектән, үзеннән-үзе аңлашыла торган сүз булып киткән һәм кыскарган. Шуңа күрә *тимерче кеше, язучы кеше* дип әйтеп торуның кирәге калмаган, чөнки *тимерче, язучы* дисәң дә, аларның кеше икәнлекләре аңлашылып тора.

Димәк, ясагычлар да мөнәсәбәт белдерүдән азат түгел, тик алар, сүзнең лексик мәгънәсен үзгәртеп, башка сүз ясау өчен кулланылалар. Алар түбәндәге үзенчәлекләр белән характерланалар. Ясагычлар, алда әйтелгәнчә, сүзнең лексик мәгънәсен үзгәртәләр, аңа яңа мәгънә бирәләр, яңа лексик берәмлек ясыйлар. Нәкъ менә шуңа күрә ясагычлар ярдәмендә ясалган сүзләр, аерым лексик берәмлек буларак, төрле сүзлекләргә кертеләләр. Кешенең аңында алар, аерым сүз була-

рак, әзер килеш яшиләр, сөйләмгә дә әзер килеш кертеләләр, сөйләм барышында бер сүзне икенчесенә ялгарга кирәк булганда гына кулланылмыйлар. Ясагычлар, билгеле бер сүзләрдән яңа сүз ясап, шул сүз составында мәгълүм дәрәҗәдә катып калганнар, шуңа күрә алар, гадәттә, кайсы да булса бер категориягә керә торган сүзләрнең барысына да ялганып йөри алмыйлар, бәлки сүзләрне сайлап кына ялганалар.

Төрки телләрдә ясагычларга исемнәр һәм фигыльләр ясый торган кушымчалар керәләр. Сыйфат һәм рәвеш ясаучы кушымчалар дип йөртелгәннәрен ясагыч дип тану хәзер дә әле бәхәсле булып кала. Чөнки аларда ясагычларга хас үзенчәлекләр азрак, бәйләүчеләр үзенчәлеге күбрәк. Шуңа күрә алар «ясаучы һәм бәйләүче ролен үтәүчеләр» дип аерым алыналар.

**Мөнәсәбәт белдерүче кушымчалар.** Боларны икенче төрле төрләндергеч кушымчалар дип тә атыйлар. Алар сөйләмдә чагылдырыла торган төшенчәләр арасында төрле мөнәсәбәтләрне белдерәләр. Бу мөнәсәбәтләр ике төргә бүленәләр: **объектив мөнәсәбәтләр** һәм **субъектив мөнәсәбәтләр.**

Объектив мөнәсәбәтләр сөйләмдә чагылдырыла торган төшенчәләр арасында булалар һәм, төшенчәләр мөстәкыйль сүзләр белән бирелгәнлектән, бу мөнәсәбәтләрне белдерүче кушымчалар бер үк вакытта шул мөстәкыйль сүзләрне үзара бәйләү хезмәтен дә үтиләр. Шуннан чыгып объектив мөнәсәбәт белдерүче кушымчаларны **бәйләгечләр** дип тә йөртәләр.

Субъектив мөнәсәбәтләр сөйләүче белән чынбарлык арасында була. Алда әйтелгәнчә, сөйләм шундый мөнәсәбәтне белдерүдән (ягъни модаль мөнәсәбәттән) башка була алмый. Сөйләүче, гадәттә, сөйләмдә аерым сүз белән бирелми, шуңа күрә субъектив (модаль) мөнәсәбәтне белдерүче кушымчалар, гадәттә, сүзләрне үзара бәйләү хезмәтен үти алмыйлар, бәйләгечләр дип тә аталмыйлар. Аларны **модальлекләр** дип атарга мөмкин. Димәк, **мөнәсәбәт белдерүчеләр бәйләгечләргә** (объектив мөнәсәбәт белдерүчеләргә) һәм **модальлекләргә** (субъектив мөнәсәбәт белдерүчеләргә) бүленәләр.

Мөнәсәбәт белдерүче кушымчаларның ясагычлардан төп аермалары түбәндәгеләрдән гыйбарәт. Алар, сүзләргә ялганып, яңа лексик мәгънәле сүз ясамыйлар, сүзнең лексик мәгънәсен үзгәртмиләр, шуңа күрә мондый кушымчалы сүзләр сүзлекләргә дә аерым лексик

берәмлек буларак кертелмиләр. Мәсәлән, *урман* сүзе сүзлеккә кертелә, ә *урманда, урмандагы, урманлы, урмансыз* кебек сүзләр сүзлектә аерым бирелмиләр. Соңгылары кеше аңында аерым сүзләр буларак урын алмыйлар, бары *урман* сүзе генә аңда яши. *Урманда, урманның, урмандагы, урманлы, урмансыз* кебек сүзләр сөйләм барышында гына, *урман* сүзен башкаларга бәйләү процессында гына барлыкка киләләр.

Мөнәсәбәт белдерүче кушымчалар, гадәттә, теге яки бу категория сүзләрнең барысына да, яисә күбесенә ялганалар.

Объектив мөнәсәбәт белдерүчеләргә, ягъни бәйләгечләргә исемнәрдәге килеш кушымчалары, тартым кушымчалары, фигыльләрдәге рәвеш фигыль кушымчалары керәләр. Сыйфат фигыль кушымчалары да фигыльне исемгә бәйләү өчен кулланыла, тик аның белән янәшә башка чаралар да киләләр. Объектив мөнәсәбәт һәм субъектив мөнәсәбәт белдерүчеләр арасында хәбәрлек кушымчалары урын алалар. Бер яктан, алар ия белән хәбәрне бәйлиләр, икенче яктан, субъектив мөнәсәбәтне (сөйләүче белән тыңлаучы һәм өченче зат арасындагы мөнәсәбәтне) дә белдерәләр.

Субъектив мөнәсәбәт белдерүче кушымчаларга исемнәрдәге иркәләү-кечерәйтү кушымчалары *(әти-әткәй, сеңел-сеңелкәем, кош-кошчык),* фигыльләрдәге наклонение (мөнәсәбәтлек) кушымчалары турыдан-туры карыйлар.

Сыйфатлардагы һәм фигыльләрдәге дәрәҗә кушымчалары (*кызыл – кызылрак, кызгылт, ошый – ошанкырый, бара – баргала* һ.б.), фигыльләрдәге заман (наклонение белән бергә), юнәлеш кушымчалары да сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерәләр.

Кушымча төрләренең схематик бирелеше



Тәкъдим ителгән «Татар грамматикасы» 1998, 1999, 2002 елларда татар телендә дөнья күргән «Грамматика»ның тулыландырылган икенче басмасы булып тора. 2003 елда басылган «Татар грамматикасы»нда «Сан» бүлеге – Н. Борһанова, «Исем» – З. Вәлиуллина, «Инфинитив», «Дәрәҗә категориясе» һәм «Исем фигыль» – Ф. Ганиев, «Фигыльләрдә дәрәҗә-ысул категориясе» – М. Зәкиев, «Сыйфат», «Алмашлык», «Фигыль юнәлешләре», «Хәл фигыль», «Рәвеш» бүлекләре – К. Зиннәтуллина, «Теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр», «Бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр», «Мөнәсәбәтле сүзләр» бүлекләре – С. Ибраһимов, «Хәбәрлек сүзләр», «Модаль сүзләр», «Кисәкчә», «Ымлык», «Ияртемнәр» – М. Сәгыйтов, «Фигыльнең лексик мәгънәсе», «Татар теле фигыленең темпоральлек, модальлек һәм персональлеккә караган функциональ-семантик категорияләре» бүлекләре – Д. Тумашева, «Сыйфат фигыль» – Ф. Хисамова тарафыннан язылган иде. Әлеге басма, исемнәре аталган галимнәрнең хезмәтләренә таянып һәм хәзерге тел белемендәге карашларны искә алып, Г. Гайнуллина тарафыннан эшкәрелде, яңартылды, «Кереш» өлеше яңадан язылды. «Библиография» өлеше, Р. Фәттахова төзегән вариантка таянып, Г. Гайнуллина тарафыннан яңартылды.

# 1. ИСЕМ

Исем – предметлыкны белдерә торган сүз төркеме. Бу – аның лексик-грамматик мәгънәсе. Исем сүз төркеменә *тарак, өстәл, пыяла, дәфтәр* кебек әйбер атамалары*, кеше, бала, сандугач, төлке, черки* кебек тереклек ияләрен атый торган сүзләр*, яңгыр, җил, давыл, буран* кебек табигать күренешләрен белдерә торган атамалар, *өлгереш, агым, яшәеш, тирәнлек, яхшылык, тизлек* кебек предметлаштырылган эш-хәл, билге атамалары, *көн, атна, ел, сәгать, минут* кебек вакыт берәмлекләрен атый торган сүзләр дә керә. Кыскасы, исем сүз төркемендә предметлаштырылып бирелгән теләсә нинди төшенчәне очратырга була.

Морфологик үзенчәлекләрдән исемгә түбәндәге грамматик категорияләр хас:

1. Сан: *йолдыз – йолдызлар, шәһәр – шәһәрләр, урман – урманнар, келәм – келәмнәр.*

2. Тартым: *китабым – китабыбыз; китабың – китабыгыз; китабы – китаплары (китабы).*

3. Килеш: *Бик матур бер айлы кичтә бу авылның бер егет Киткән урманга утынга ялгызы бер ат җигеп* (Г. Тукай).

4. Хәбәрлек: *тәрбиячемен – тәрбиячебез, тәрбиячесең – тәрбиячесез* һ.б.

Синтаксик яктан предметлык төшенчәсенә ия булган исем башка сүз төркемнәреннән, еш кына, фигыль белән бәйләнешкә керә һәм алар арасында хәбәрлекле (предикатив) яки ачыклаулы (төгәлләүле) мөнәсәбәт урнаша: *Ашлыклар өлгереп килә.*

*Тормышлар яхшыра* (хәбәрлекле мөнәсәбәт); *авылга китү, эштән кайту, дуслар белән очрашу, китапны укып чыгу* (ачыклаулы мөнәсәбәт).

Исем башка бер исем белән дә бәйләнешкә керә һәм алар арасында шулай ук ачыклаулы мөнәсәбәт барлыкка килә. Тюркологиядә бу

төр тезмәләрне «изафә» дип йөртәләр: 1) *калай түбә, эшче кеше, агач көрәк;* 2) *бала киеме, укытучы хезмәте, йорт түбәсе;* 3) *кешенең сәламәтлеге, кулның көче, күкнең зәңгәрлеге.*

Исемнең үзен сыйфат, сыйфат фигыль, алмашлык, сан сүз төркемнәре ачыклый, алар арасында да ачыклаулы (төгәлләүле) мөнәсәбәт урнаша: *намуслы кеше, ялгыз каен, өлгергән җиләк, шушы авыл, бишенче сыйныф* һ.б.

Җөмләдә исем теләсә нинди җөмлә кисәге булып килә ала. Әмма алар арасында ия, тәмамлык, аергыч – исемнең төп функцияләре. Мәсәлән: *Кеше иксез-чиксез В а т а н ы н тоташтан күз алдына китерә алмый. Аның күңелендә үзе туып үскән бер т и р ә л е к, ул т и р ә л е к н е ң дә аерым бер у р м а н ы, я л а н ы, ч и ш м ә с е, я булмаса тар гына бер а в ы л и н е ш е яши* (Г. Сабитов).

Димәк, исем предметлыкны белдерә, аңа сан, тартым, килеш, хәбәрлек категорияләре хас, җөмләдә, күбесенчә, фигыль белән бәйләнешкә кереп, ия, тәмамлык, икенче бер исемне ачыклап, аергыч та булып килә. Гомумән алганда, исем җөмләнең һәр кисәге вазифаларын үти ала.

## 1.1. ИСЕМНЕҢ СЕМАНТИК ТӨРКЕМЧӘЛӘРЕ

Исемдә предметлык мәгънәсе үз эченә күп төрле төшенчәләрне туплый: конкрет һәм абстракт исемнәр, җыйма исемнәр, матдә исемнәре, ялгызлык һәм уртаклык (күмәклек) исемнәр була.

**Конкрет исемнәргә** затларны, гомумән тереклек ияләрен, предметларны атый торган сүзләр (*бала, ат, куян, йорт, урындык, кәгазь* һ.б.), төрле вакыйга, табигать күренешләренең *(яңгыр, буран, кыш, җир тетрәү* һ.б.), вакыт һәм үлчәү берәмлекләренең (*ай, ел, көн, чакрым, метр, минут* һ.б) атамалары керә.

**Абстракт исемнәргә** эш-хәл, билге һәм башка төрле төшенчәләрне атый торган сүзләр керә: *үсеш, үзгәреш, бүленеш, язмыш, агым, азатлык, яктылык, эшчәнлек, тизлек, түбәнлек, фикер, хис, хакыйкать* һ.б. Аларның күбесе ясалма, араларында алынмалары (*фикер, хис, хакыйкать*) да бар. *Үсеш, үзгәреш, бүленеш, язмыш, агым* – фигыльдән, *азатлык, яктылык, эшчәнлек* – сыйфаттан, *тизлек, түбәнлек* – рәвештән ясалганнар. Абстракт мәгънәле исемнәр үзләре ясалган

фигыльдән, сыйфаттан, рәвештән түбәндәгечә аерыла: фигыль белән белдерелгән эш-хәлнең үтәүчесе була, үтәлеше дә билгеле бер заман кысаларында бара, ә шул фигыльдән ясалган исемдәге эш-хәлнең үтәүчесе булмый, заман төшенчәсенә карата да ул битарафлык күрсәтә: *(агач) үсә* – үсеш, *(һава) үзгәрер* – үзгәреш һ.б.; сыйфат белән белдерелгән билге нинди дә булса предметка карый, ә шул сыйфаттан ясалган абстракт исем, билгене предметтан аерып, мөстәкыйль бер төшенчә буларак белдерелә: *якты (бүлмә) – яктылык, эшчән (кеше) – эшчәнлек* һ.б.; рәвеш, гадәттә, эш-хәлнең билгесен белдерсә, рәвештән ясалган исем билгене эш-хәлдән аерып, мөстәкыйль бер төшенчә итеп белдерә: *тиз (йөри) – тизлек, әкрен (оча) – әкренлек, еш (килеп йөри) – ешлык* һ.б.

Җыеп кына әйткәндә, бу төр исемнәрдә эш-хәл, билге предметлаштырылып бирелә һәм, исем буларак, шул сүз төркеменә хас барлык морфологик билгеләргә, ягъни исемгә хас сан, тартым, килеш категорияләренә ия була*: корылыктан җәфа чигү, игеннәрнең үсешен күзәтеп тору, шатлыктан елмаю, тизлеккә күнегү* һ.б.

Конкрет исемнәрне берлектә дә, күплектә дә кулланып булса, абстракт исемнәр, гадәттә, берлек формасында гына кулланылалар. Бу – аларның морфологик үзенчәлеге.

**Җыйма исемнәргә** бер төрдән булган предметларның җыелмасын атый торган сүзләр керә: *ташлык, каенлык, җиләклек* һ.б. Аларның да гадәти формасы – берлек сан. *Савыт-саба, хатын-кыз, мал-туар* кебек исемнәргә дә җыелмалылык мәгънәсе хас. Җыелмалылык төсмере *чия, алма, карлыган* кебек җиләк-җимеш исемнәрендә дә бар.

**Матдә исемнәренә** азык-төлек, төзү материаллары, химик матдә атамалары керә: *май, он, тоз, кислота, ташкүмер, сөт, балчык, терекөмеш, калай, такта, ташкүмер* һ.б. Болар – аерым берәмлекләргә бүленми торган предмет исемнәре, әмма аларны үлчәп була: *бер кашык тоз, ике литр сөт, бер капчык он, өч тонна ташкүмер* һ.б.

Исемнәр **ялгызлык** һәм **уртаклык** (күмәклек) дигән ике төркемгә бүленәләр: *Казан – шәһәр, Дим – елга, Чаян – журнал, Урал – тау, Хәмит – кеше* һ.б. Бер төрдән булган предметларның берсен икенчесеннән аеру өчен бирелгән исем – ялгызлык, ә бер төрдән булган предметларның барысы өчен дә уртак булганы – уртаклык исем дип атала.

Мәсәлән: *бала, язучы, газета, дәүләт, елга, бәйрәм, мәче* һ.б. шундый сүзләр уртаклык исем, аларның телдә ялгызлык парлары бар: *бала – Айсылу, язучы – Г. Ахунов, гәзит – «Татарстан яшьләре», елга – Идел, бәйрәм – Җиңү бәйрәме, дәүләт – Татарстан, мәче – Шаян; халкыбызның бөек шагыйре – Тукай.* Ялгызлык исемнәргә географик-астрономик атамалар, кеше исемнәре, хайван кушаматлары һәм шулай ук газета-журнал, әдәби әсәр, завод-фабрика, төрле оешма исемнәре керә: *Идел, Урал, Испания, Кояш, Ай, Марс, Сәйдәш, Тукай, Ибраһимов, Зәйтүнә, Гөлсинә, Лилия, Шаян, Актырнак, «Шәһри Казан» (газетасы), «Ташкыннар» (драмасы), «Тан» (фабрикасы)* һ.б.

Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр үзара тыгыз бәйләнештә: ялгызлык исемнәрнең күбесе уртаклык исемнәрдән яки башка сүз төркемнәреннән барлыкка килә: *Йолдыз, Тимербулат, Чулпан, Аккош күле, Буа (районы), «Шүрәле» (балеты), «Эшкә өндәү» (шигыре)* һ.б. Мәсәлән: *Тыкрык рәсми рәвештә Я ш ь л ә р урамы дип атала* (А. Расих). *Я ш е л Ү з ә н шәһәре Казаннан ерак түгел.*

### 1.2. ИСЕМНӘРНЕҢ ӨЙРӘНЕЛҮ ТАРИХЫ

XIX йөздә һәм XX йөз башларында язылган грамматикаларда татар теленең морфологик төзелеше (сүз төркемнәре) турында шактый мәгълүмат бирелгән. Дөрес, сүз төркемнәре, аларның саны, составы, сүз төркемнәрен билгеләү принциплары төрле авторлар тарафыннан төрлечәрәк хәл ителә. Татар теленең беренче грамматикаларында ук шактый җентекләп өйрәнелгәне – фигыль.

**И. Гиганов** (Грамматика татарского языка. СПб, АН, 1801), **И. Хәлфин** (Азбука и грамматика татарского языка. Казань, тип. Казанского университета, 1809), **А. Троянский** (Краткая татарская грамматика. Казань, Изд-во дух. учебн. упр., 1860), **М. Иванов** (Татарская грамматика. Казань, тип. Казанского университета, 1842) грамматикаларында исем аерым сүз төркеме буларак түгел, ә бәлки «Имя» дигән атама белән исем, сыйфат, сан бергә карала, аларның барысы өчен дә уртак морфологик билгеләр күрсәтелә. Кыскасы, бер билгеләмәдә исем, сыйфат, сан берләштерелеп бирелгән [Гиганов И., 1801; Троянский А., 1860, с. 14].

Әйтергә кирәк, бу авторлар үз грамматикаларын рус теле, конкрет алганда М. Ломоносовның «Российская грамматика»сы [Ломоносов М., 1755] үрнәгендә язганнар. Татар теленең морфологик төзелеше рус теле күзлегеннән чыгып каралганга күрә (татар телен тикшерүнең беренче тәҗрибәләре булгангадыр), татар телендә рус теленә хас грамматик үзенчәлекләр табарга тырышылган, ә татар теленең үзенә хас үзенчәлекләре кирәкле дәрәҗәдә исәпкә алынмаган. Мәсәлән, татар теленә карата род категориясе турында фикер йөртү, «Татары имеют один только род как для прилагательных, так и для существительных имен» [Троянский А., 1860, с. 14], килешләргә звательный, творительный, предложныйларны кертү [Хальфин И., 1809, с. 10], исемнәрдә килеш белән төрләнешнең берничә төрен күрсәтү һ.б. югарыда әйтелгән фикерне раслыйлар.

Татар теленең бу чорда язылган грамматикаларында сүз төркемнәренә, шул исәптән исемгә дә, билгеләмә биргәндә, семантик принципка нигезләнәләр, аларның морфологик билгеләренә игътибар җитәрлек түгел, телгә алынганнары да сүз төркемнәреннән аерым карала. Тик И. Гиганов кына үз грамматикасында, рус теле белән чагыштырып, татар теленең байтак үзенчәлекләрен дөрес билгели алган: татар телендә «сүзләргә кушымчалар ялгана» [Гиганов И., 1801, с. 23] дигән искәрмәсе белән әһәмиятле бер үзенчәлеккә – татар теленең ялганмалы табигатенә игътибар итә. Ул исемгә «лицо, число, падеж, склонение» кебек морфологик билгеләр хас дип, килеш, сан белән беррәттән, беренче булып, татар телендә исемнең тартым белән төрләнүенә дә туктала: «К именам существительным прикладываются окончания, которые показывают принадлежность». Бу күренешне ул «О лице имен» дип атый [шунда ук, б. 21]. Кызганычка каршы, И. Гигановның тартымга исемнең бер билгесе итеп каравы озак вакытлар игътибарсыз кала, ә тартым кушымчалары башка грамматикаларда алмашлыкның бер төре итеп кенә билгеләнә.

М. Иванов [Иванов М., 1842] һәм М. Мәхмүдев [Махмудов М., 1857] хезмәтләрендә дә сүз төркемнәренә, шул исәптән исемгә дә, бөтенләй билгеләмә бирелми. Аларда татар теленең морфологик төзелеше практик планда гына өйрәнелә. А. Казимбәкнең да хезмәте [Казембек А., 1839] татар телен практик яктан өйрәнүне күздә тота, сүз төркемнәренең исеме атала һәм аның кайбер морфологик билгеләре

карала: «Об имени. Турки не имеют рода. Чисел два: единственное и множественное» [шунда ук, б. 49]. Бу авторның грамматикасы шул чорда язылган башкаларыннан бер үзенчәлеге белән аерылып тора: анда төрек теле белән татар теле чагыштырма рәвештә тасвирлана, кайбер урында чагыштыруга чуваш һәм монгол телләре дә җәлеп ителә.

Әйтеп үтелгәнчә, бу чордагы (XIX йөз һәм XX йөз башы) татар теленең рус телендә язылган грамматикаларына рус теле грамматикаларының йогынтысы зур. Ә шулай да һәр автор татар теленең грамматик үзенчәлекләрен дөрес билгеләргә омтылган. Әмма ул төрлесендә төрле дәрәҗәдә тормышка ашкан, күбесе рус телендәге морфологик күренешләрне татар телендә дә табарга тырышудан котыла алмаган.

Татар теленең татарча язылган грамматикалары XIX йөзнең икенче яртысында күренә башлый.

Г. Фәезханов [Фәезханов Г., 1887] исем сүз төркемендә, аның бер төркемчәсе итеп, санны (исме гадәд) күрсәтә. Исемнең морфологик категорияләреннән килеш һәм санга туктала. Килешкә кертелгән III зат тартым кушымчасын искә алмаганда, тартым исемнең морфологик билгесе итеп каралмый.

К. Насыйриның [Насыйри К., 1895] хезмәте авторның күп еллар татар һәм рус телләрен укыту тәҗрибәсенә нигезләнеп язылган һәм ул хәзерге татар теле белеме өлкәсендә дә үзенең лаеклы урынын саклый. Анда гарәп теле грамматикалары үрнәгендә өч кенә сүз төркеме: исем, фигыль, хәреф. Сыйфат, сан, алмашлык кебек хәзерге татар әдәби телендәге мөстәкыйль сүз төркемнәре исемнең төркемчәләре (исме сыйфат, исме гадәд, исме замир), дөресрәге, барысы да исем сүз төркемнәре (именные части речи) итеп карала. Морфологик яктан да аларга нигездә бер үк төрле характеристика бирелә. Мәсәлән, исемгә хас килеш (игъраб) турында сүз барганда, исме зат игъраблары, исме сыйфат игъраблары, исме замир игъраблары дип санап кителә [шунда ук, б. 46–50].

Гомумән, Г. Фәезханов һәм К. Насыйри хезмәтләрендә гарәп теле грамматикасының йогынтысы нык сизелә: 1) терминнарның күбесе гарәпчә (кәлимә, сарыф, игъраб, замир һ.б.); 2) сүз төркемнәренең саны бик чикле (3–5); 3) сүз төркемнәре эчендәге бүленеш тә гарәп телендәгечә (исме сыйфат, исме гадәд, исме замир).

К. Насыйри «Исем дип шундаен кәлимәне әйтерләр ки, үзендәге бер мөстәкыйль мәгънәгә дәлаләт кылыр, әмма заман фәһемләнмәс» дип, исемне фигыльдән аера торган төп билге итеп заман категориясен күрсәтә [Насыйри К., 1895, 7]. Ул исемнәрнең килеш белән төрләнүләренә, берлектә һәм күплектә кулланылуларына туктала. Тик исемнең тартымы гына, башка күп кенә грамматикалардагыча, алмашлыкның бер төре (тоташ алмаш) итеп карала.

Х. Кәбутари да [Кәбутари Х., 1910] исем сүз төркеменең фәкать килеш һәм сан категориясенә генә туктала. Тартым кушымчаларын ул да алмашлыкта карый. Алмашлыкка, тартым кушымчаларыннан башка, хәбәрлек һәм фигыльнең зат (сан) кушымчаларын да кертә [шунда ук, б. 19–22].

Һ. Максуди [Максуди Һ., 1910] сүз төркемнәренә шактый киң туктала. Мәсәлән, исемне ул үзенә бер аерым сүз төркеме итеп карый һәм аның барлык грамматик категорияләрен, шул исәптән тартымны да тикшерә. Исемнең тартым белән төрләнешен, тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнү үрнәкләрен дә бирә [шунда ук, б. 12–13].

Сүз төркемнәрен, шул исәптән исемне өйрәнүдә дә Г. Нугайбәкнең «Төрлек» (Казан, 1911) исемле хезмәте игътибарга лаеклы.

Бу грамматикада исемгә шактый тирән морфологик характеристика бирелә, аның килеш, сан кебек грамматик категорияләре дә үз урыннарында, алар, нигездә, дөрес тасвирлана. Тик тартым гына алмашлык сүз төркемендә карала.

Г. Нугайбәкнең бу хезмәтендә бер үзенчәлек күзгә ташлана: анда алынма терминнарның (атамаларның) барысы да диярлек татар теленең үз сүзләре белән алыштырылган; *әйбер аты* (исем), *билге аты* (сыйфат), *кылым* (фигыль) һ.б. Шунлыктан булса кирәк, бу грамматика, шактый тирән эчтәлекле булуына карамастан, киң кулланылышка кереп китә алмый.

Г. Ибраһимов моңа карата: «Татар теленә сарыф язгач, аны баштанаяк гарәп һәм фарсы атамалары белән тутыру һичбер ярый торган эш булмаган кебек, һичбер фәндә тик үз телеңнән атамалар җиткерү, шул дәрәҗәдә сафлыкны гамәлгә куя алу да – мөмкин булмаслык бер эш. Тарих һәм тормыш көче белән һәр телгә бераз чит сүз керә. Тәмам халыклашкан яки аңлашылуы җиңел булган кайбер чит сүзләрне кертү

эшнең гамәлгә ашуын уйлаучылар өчен мәҗбүри бер хәлдер», – дип язды [Ибраһимов Г., 1927, б. 104].

Татар теленең морфологик төзелешен тикшерүгә шактый өлеш керткән кеше – Г. Ибраһимов. Аның «Татар сарфы» (1911, 1915) озак вакытлар дәвамында татар телен өйрәнүдә дәреслек хезмәтен үти.

Исемне Г. Ибраһимов «бер нәрсәнең атын белдерә торган сүзләр» дип билгели һәм грамматик категорияләреннән санга гына туктала. Исемнең морфологик билгеләрен тиешле дәрәҗәдә исәпкә алып бетермәгәнгә булса кирәк, *бүген, кичә, былтыр, быел* кебек рәвешләрне дә исем сүз төркеменә кертә [Ибраһимов Г., 1911, б. 14]. Исемнең, башка грамматик категорияләренә килгәндә, «татар теленә килеш хас түгел» ди [Ибраһимов Г., 1911, б. 96–114], ә тартым кушымчаларын «тоташ алмашлыклар» дип, алмашлыкның бер төркемчәсе итеп билгели [шунда ук, б. 58].

Г. Ибраһимовның терминология өлкәсендә башкарган эшен билгеләп үтәргә кирәк. Ул кулланган грамматик терминнарның күбесе хәзерге көндә дә гамәлдә.

Җ. Вәлиди килеш һәм тартым мәсьәләсендә Г. Ибраһимов фикеренә кушыла [Вәлиди Җ., 1915; 1919]. Икенче хезмәтендә ул, К. Насыйри кебек, сүз төркемнәрен өчкә генә бүлә (исем, фигыль, элемтәләр). Исем, сыйфат, сан бер сүз төркеме итеп карала.

Шулай итеп, XX йөзнең 40 нчы елларына кадәр язылган грамматикаларда да сүз төркемнәренә, аларның морфологик билгеләренә карата фикер бердәмлеге юк: кайберләрендә 3, ә кайберләрендә 8–9 сүз төркеме, сыйфат, сан күбесендә исемнең мәгънәви төркемчәләре итеп кенә карала, морфологик билгеләреннән килеш һәм санга урын бирелә. Г. Ибраһимов белән Җ. Вәлиди исә сан категориясен генә исемнең морфологик билгесе итеп карыйлар. Бу чор грамматикаларында рәвеш аерым сүз төркеме итеп саналмый, кайбер рәвешләрне исемгә китерелгән мисаллар арасында, ә кайберләрең сыйфатта күрергә була.

Татар теленең морфологик төзелешен, сүз төркемнәрен өйрәнүдә Г. Алпаровның «Шәкли нигездә татар грамматикасы» [Алпаров Г., 1945, б. 21–147] аерым урын алып тора. Г. Алпаров тел белемендә шул чорларда өстенлек иткән формаль, ягъни шәкли якны нигез итеп ала һәм шул юнәлешне үз хезмәтендә тормышка ашырырга тырыша. Шуннан чыгып, ул, сүз төркемнәренә билгеләмә биргәндә, аларның

тик морфологик билгеләренә генә таянып эш итә: сүз төркемнәрен төрләнүче һәм төрләнмәүчеләргә бүлеп, беренчеләренә фигыль һәм исемне, икенчеләренә рәвеш, ымлык һәм ярдәмлекләрне кертә. Исем дигән сүзне киң мәгънәдә куллана: аны зат исеме, сыйфат исеме, сан исеме, урын-вакыт исемнәренә бүлә. Г. Алпаров исемнең килеш, сан һәм озак вакытлар бу сүз төркеменең морфологик билгесе итеп каралмаган тартым (япсару) категориясен дә җентекләп тикшерә.

Алмашлык, сыйфат һәм санга карата «аларның үзләренә махсус төрлекләр белән төрләнешләре юк. Ләкин җөмлә эчендә, исемнәр үзләре әйтелми калган чагында, сыйфат, сан һәм аларның алмашлары, ул исемнәрнең урынына килеп, исем төрлекләре белән төрләнәләр» [Алпаров Г., 1945, б. 107] дигән искәрмә белән татар телендә киң таралган бер күренешкә – исемләшүгә туктала.

Г. Алпаровның «Шәкли нигездә татар грамматикасы»нда сүз төркемнәренә морфологик яктан шактый тулы характеристика бирелә. Шунлыктан да, моннан 50 еллар элек язылган булса да, бу грамматика татар теленең морфологик төзелешен фәнни яктан өйрәнүгә зур өлеш керткән хезмәт булып кала.

Татар теленең грамматик төзелешен өйрәнеп, тирән эчтәлекле хезмәтләр калдырган кеше – В. Хангилдин. Ул 12 сүз төркеме эчендә исемгә шактый киң туктала. Аңа ул, лексик-грамматик яктан чыгып, тулы билгеләмә бирә. Исемнең сан, тартым һәм килеш категорияләре җентекләп тикшерелә. Бу сүз төркемен аның ясалышын караудан башлый [Хангилдин В., 1954, 1959].

Д. Тумашева шулай ук 12 сүз төркемен бүлеп чыгара [Тумашева Д., 1964, б. 32–46; 1978, б. 23–32]. Ул исемне мәгънәсе, морфологик билгеләре, синтаксик функцияләре ягыннан чыгып яктырта. Исемнең синтаксик билгеләре итеп, беренче чиратта исемнең нинди сүз төркемнәре белән мөнәсәбәткә (бәйләнешкә) керүе исәпкә алына.

Д. Тумашева үзенең хезмәтләрендә хәзерге көндә дә бәхәсле булган бер мәсьәләгә туктала. Ул изафәнең беренче төрендә кулланыла торган *таш, тимер, агай, алтын* кебек сүзләрне исемнәрдә калдыру ягында тора: «...сүзнең кайсы сүз төркеменә керүен билгеләгәндә, аның гомумән телдә кулланылышын һәм бөтен тел системасындагы урынын исәпкә алырга кирәк»,– ди һәм бу мәсьәләгә карашын түбәндәге сүзләр белән тәмамлый: «Синтаксик функциясенә таянып,

исемнәрне, гәрчә рус теленә сыйфат белән тәрҗемә ителсәләр дә, татар телендә ул сүзләрне сыйфат дип карап булмый» [Тумашева Д., 1964, б. 83].

М. Зәкиевнең морфология мәсьәләләренә багышланган хезмәтләрендә сүз төркемнәре хакында, шул исәптән исемгә карата да, әйтелгән фикерләре зур әһәмияткә ия. Мәсәлән, ул, сөйләмдә үтәгән рольләреннән чыгып, сүз төркемнәрен өч зур төркемгә бүләргә тәкъдим итә: 1) мөстәкыйль мәгънәле сүзләр (исем, сыйфат, рәвеш, сан, алмашлык, фигыль, хәбәрлек сүзләр, аваз ияртемнәре); 2) модаль мәгънәле сүзләр (модаль сүзләр, ымлыклар һәм кисәкчәләр); 3) бәйләгечләр (бәйлек һәм теркәгечләр). М. Зәкиев татар тел белемендә бәхәсле бер мәсьәләне чишүгә дә үз өлешен кертә. Бу очракта *агач, тимер, таш* кебек исемнәр*, матур, яхшы* кебек сыйфатлар турында сүз бара: *агач күпер, матур яза* тезмәләрендәге *агач* сүзе икенче бер исемне ачыклап килгән исем (сыйфат түгел), *матур* сүзе фигыльне ачыклап килгән сыйфат (рәвеш түгел) [Вәлиуллина З. һ.б., 1972, б. 5–10; Татарская грамматика, 1997, II т., б. 5–18].

Хәзерге татар әдәби телендә лексик-грамматик мәгънәләре һәм морфологик-синтаксик билгеләре нигезендә 13 сүз төркеме билгеләнә: исем, сыйфат, рәвеш, сан, алмашлык, фигыль, хәбәрлек сүз, аваз ияртемнәре, бәйлек, теркәгеч, ымлык, кисәкчә, модаль сүзләр.

Шуларның сигезе (исем, сыйфат, рәвеш, сан, алмашлык, фигыль, хәбәрлек сүз, аваз ияртемнәре) мөстәкыйль мәгънәле сүзләр төркеменә берләшә. Алар – чынбарлыктагы предмет, күренеш, билге төшенчәләрен белдерә торган сүзләр. Икесе (бәйлек, теркәгеч) – сүзләрне һәм җөмләләрне үзара бәйләп, алар арасында төрле синтаксик мөнәсәбәт урнаштыра торган сүзләр. Калган өчесе (ымлык, кисәкчә, модаль сүзләр) – сөйләүченең (сөйләмнең) чынбарлыкка мөнәсәбәтен, ягъни модальлекне белдерә торган сүзләр.

## 1.3. ИСЕМНӘРНЕҢ ГРАММАТИК КАТЕГОРИЯЛӘРЕ

### 1.3.1. Сан категориясе

Грамматик категория буларак, сан исемдә предметның бер яки бердән артыклыгын, ягъни билгесез күплеген белдерә. Бу – санның төп мәгънәсе. Шуңа бәйле рәвештә сан категориясе ике формадан –

берлек һәм күплектән тора*: кош – кошлар, өстәл – өстәлләр, урман – урманнар, келәм – келәмнәр* һ.б.

Әмма барлык исемнәрне дә сан категориясенең бу ике формасына да куеп булмый, ягъни татар телендә исем сүз төркеменә караган һәр сүзнең берлек формасы булса да, байтак кына исемнәрнең күплек формасы булмый яки күплек кушымчасы андый сүзләрнең мәгънәләренә үзгәреш кертә. Берлектә дә, күплектә дә куллану мөмкинлеге исемнәрнең семантик (мәгънәви) төркемчәләренә бәйле. Берлек һәм күплекне чын мәгънәдә бер-берсенә каршы куеп куллану – санала торган конкрет предмет, күренеш исемнәренә генә хас, ягъни шундый төр исемнәр генә иркен рәвештә санның бу ике формасында да кулланыла һәм сан категориясенең төп мәгънәсен (берлек сан предметның берлеген, күплек – бердән артыклыгын) белдерә: *шәһәр – шәһәрләр, йолдыз – йолдызлар, китап – китаплар* һ.б. Мәсәлән: *Лобачевский һәйкәле каршына трамвай килеп туктаган (ул елларда трамвайлар, Кремль турысыннан борылып, вокзалга төшеп китәләр иде)* (И. Гази).

Саналу сыйфатына ия булмаган абстракт исемнәр (*үсеш, тигезлек, шатлык, түземсезлек, яшәеш, авырлык, сәламәтлек, михнәт* һ.б.), матдә исемнәре (*он, тоз, су, терекөмеш, ярма, корыч, такта* һ.б.), җыйма исемнәр (*каенлык, камышлык, җиләклек, җәмгыять, халык* һ.б.) берлектә кулланыла, Ялгызлык исемнәрнең дә гадәти формасы – берлек (*Казан, Идел, Уфа, Урал, Гөлнара, Хәлим, Бәләбәй* һ.б.).

**Берлек сан.** Берлек санның аерым күрсәткече юк, ул исемнең нигез формасына туры килә. Грамматик мәгънәсе – предметның берлеген белдерү. Бу мәгънә санала, ягъни сан белән ачыкланып килә ала торган конкрет исемнәрнең берлек формасына хас: *кеше, авыл, күл, кое, кыш, ел, атна, чакрым* һ.б. Мәсәлән: *Ул шәһәр читенә килеп чыкты да, тар гына бер сукмакка ияреп, алдагы урманчыкка карап атлады да атлады* (И. Гази). *Хафиз картның әтисе дә кулыннан балтаны төшермәде, һөнәрен улына биреп калдырды* (Н. Акмал).

Башка семантик төркемчәләргә килгәндә, абстракт, матдә, җыйма исемнәрнең берлек формасы конкрет исемнәрнең берлек мәгънәсенә туры килми, ягъни исемнәрдә предметның берлеге турында сүз бармый. *Яшәеш, дуслык, өлгереш* һ.б. шундый абстракт мәгънәле

исемнәр; *ташлык, җиләклек, наратлык* кебек җыйма исемнәр; *май, ярма, балчык, терекөмеш* кебек матдә исемнәренең берлек формасы предмет һәм төшенчәләрне аерым данәләргә бүленми торган (тик кайберләре генә үлчәнә) бербөтен икәнлеген белдерә (бербөтен итеп күзалларга ярдәм итә). Мәсәлән: *Сандугачлар т а б и г а т ь тудырган иң нечкә сулыш музыкасы аркылы м а т у р л ы к н ы, шатлыклы т о р м ы ш н ы һәм я ш ь л е к н е мактыйлар, б а т ы р л ы к к а, н а м у с л ы л ы к к а, э ш ч ә н л е к к ә чакыралар* (Ш. Камал). *Урман белән ике арада бер с а з л ы к бар. Анда чишмәле елга ага, таллар, камышлар үсә. Кара болыт белән давыл килгән вакытларда к а м ы ш л ы к арасыннан ыңгырашкан тавышлар ишетелә, ди* (М. Мәһдиев). *Европа көньяк һәм төньяк диңгез юлларыннан чит илгә и к м ә к, м а й, б а л, б а л а в ы з озата* (М. Мәһдиев). *Иң элек күзем өйләргә төште. Барысы да диярлек яңа, барысы да к а л а й белән ябылган* (Ә. Еники). *С у шаулап забойга тула. Инде тездән була* (И. Гази).

Ялгызлык исемнәр берлектә генә кулланыла. Мәсәлән: *Алар җыелыштан кайталар. Араларында М и ң л е г ө л дә бар* (Ш. Камал). *Озак та үтмәде, әни К а з а н н а н кырык чакрымнар чамасы арадагы Шәле авылының башлангыч мәктәбенә укытучы итеп билгеләнде* (А. Расих). *И д е л – илебездәге иң зур елгаларның берсе.*

Парлы предметларны атый торган исемнәр дә (*итек, оек, биләй* һ.б.) берлектә кулланыла. Мәсәлән: *Минем алдан бер кыз бара. Аның аягында к и е з и т е к* (И. Гази).

Тереклек ияләренең парлы әгъза исемнәре дә, күбесенчә, берлек формада була. Мәсәлән: *К о л а г ы м сүз ишетми, к ү з алдым караңгылана бара иде* (Г. Ибраһимов). *Берәр сәгатьтән авыру к ү з е н ачты* (Г. Бәширов). *Аның а я г ы н д а киез итек* (И. Гази).

Сан белән ачыкланып килгән исем дә берлектә була. Мәсәлән: *Кечкенә самавыр, д ү р т ч ы н а я к, и к е т ә л и н к ә, а л т ы чаган к а ш ы к... тагын әлләниләр...* (Г. Ибраһимов). *Берничә минут эчендә разведчиклар к ы р ы к л а п а в т о м а ш и н а, у н а л т ы т у п һәм башка к ү п кенә к о р а л кулга төшерделәр* (Г. Әпсәләмов).

Конкрет исемнәрнең берлеге (предметның берлеге), үзенең төп мәгънәсеннән тыш, санга, саналуга битараф булган предметлар исеме буларак та кулланыла. Мәсәлән: *К и т а п – белем чишмәсе. Б ө р е л е*

*куян үрчетүдә зур тәҗрибә туплаган* (Ә. Еники). *Җәй буе, күз буе урманнан кайтмый авыл баласы: чикләвеген җыя, миләшен, баланын* (А. Гыйләҗев). *Әнә теге егетләр Шушма буенда балык каптыралар (Г. Шәрәфетдинов).*

**Күплек сан.** Санала торган предмет һәм күренеш исемнәрендә күплек сан билгесез күплекне белдерә[1]. Бу форманың кушымчалары: *-лар/-ләр, -нар/-нәр (яфрак-лар, чиләк-ләр, урам-нар, көн-нәр).* Мәсәлән: *Урман үзенең серле ерткычлары, җәнлекләре, кошлары белән үзе бер дөнья иде* (М. Мәһдиев). *Куяннар урман эчендәге калкулыкта, җирдән күтәреп эшләнгән челтәр төпле читлекләрдә яшиләр* (Ә. Еники). *Җыйнак итеп җыештырылган бүлмәдә шкаф тора. Анда – китаплар* (Г. Бакир). *Әрҗәләрдә коелган яшел алмалар гына иде* (И. Гази).

Гадәттә берлектә генә кулланыла торган исемнәрнең дә кайберләрен күплектә очратырга була. Әмма күплек сан кушымчасы андый исемнәрнең мәгънәләренә билгеле бер дәрәҗәдә үзгәреш кертә:

1. Абстракт мәгънәле исемнәргә конкретлылык төсмере өсти. Мәсәлән: *Урман хәзер гади бер йорт җылытучы, тамак туйдыручыга әйләнде. Ләкин бу яхшылыкларны ул бик зур газаплар аркылы гына җиткерә алды* (М. Мәһдиев). *Кичәге матурлыклар беткән, күңел бераз ялыккан, ничектер бераз пошынулы ару җанны биләп алган* (Г. Ибраһимов). *Әнә шул ерактагы гөлдерәү аны тагын балачак истәлекләренә алып китте* (Г. Ахунов). *Мәҗит илебезнең йөзләгән-меңләгән авыл-шәһәрләреннән килгән егетләрнең туган ил хакына эшләгән батырлыкларын күрә* (Л. Ихсанова). *Бер җәй эчендә әллә никадәр үзгәрешләр булган. Иң кызыгы – әтисе Әркәшәне шәһәргә алып барган да колак докторына күрсәткән. Ул аңа колак машинасы җайлаган* (М. Мәһдиев).

2. Матдә исемнәрендә күплек сан формасы шул матдәнең төрле сортларын, төрләрен, мул булуын, төрле урында җыелып торуын белдерә. Мәсәлән: *Ул арада чәй хәзерләнеп, әллә ничә айлар сагынып*

---

[1] Конкрет күплекне белдерү тик санга гына хас: *бер китап, биш, ун, егерме китап* һ.б. Мәсәлән: *Бу ике кыз, кечкенә вакыттан бергә уйнап үскәнгә күрә, бер-берсенә бик ияләшкәннәр иде* (Ф. Әмирхан) – *ике кыз* тезмәсендә *ике* саны, күплек сан *(кызлар)* формасыннан аермалы буларак, предметның конкрет исәбен белдергән.

*йөргән с ы й л а р берәм-берәм өстәлгә тезелде* (Г. Ибраһимов). *Кичәге яңгырдан соң җыелып калган с у л а р д а кояш нуры күзләрне чагылдырырлык булып балкый* (И. Гази).

3. Җыйма исемнәрдә күплек бер үк предметлардан торган җыелманың төрле урыннарга таралганлыгын белдерә *(камыш – камышлык – камышлыклар, нарат – наратлык – наратлыклар).* Мәсәлән: *Елганың аръягында, с а з л ы к л а р д а , бакалар кычкыра* (И. Гази). *Шактый озак йөргәннән соң җ и л ә к л е к л ә р очрый башлады.*

Ялгызлык исемнәргә ялганган күплек кушымчасы туганлык, кардәшлек, фикердәшлек, замандашлык, якташлык һ.б. шундый уртаклык нигезендә берләшкән затлар төркемен белдерә. Мәсәлән: *Х ә л и м н ә р н е ң авылы нинди матур! Ике тау итәгенә сыенып, ямь-яшел бакчаларга күмелеп утыра* (И. Гази). *Тарих белән ясалып килгән тормыш көчләре Г а й ш ә л ә р н е иске нигездә яңа ояга кертеп утырттылар* (Г. Ибраһимов). *Бу кырда окоплар күмелгән, Чәчәкле түтәлләр тезелгән. Безнең уй бара, җыр бара Җ ә л и л л ә р , К ә р и м н ә р эзеннән* (Г. Афзал).

*Эзли торгач, ә н и л ә р Яңа бистә белән Иске бистә арасындагы кыска бер тыкрыкта бүлмә таптылар* (А. Расих). Бу мисалдагы күплектә килгән *әниләр* сүзе ата-ана мәгънәсендә кулланылган.

Парлы предметларны атый торган исемнәрнең күплеге предметның берничә пар булуын белдерә. Мәсәлән: *Ул заманнан бирле минем аякта нинди генә б о т и н к а л а р булмагандыр, барысы да онытылган, ә өсте яшел постау ботинкам һаман күз алдымда* (И. Гази). *Әбием безгә о е к б а ш л а р бәйләп китерде.*

Сан белән ачыкланып килгән исем дә күплектә булырга мөмкин. Бу очракта сан һәм исем тезмәсенә чамалап әйтү төсмере өстәлә. Мәсәлән: *Ул к ы р ы к б и ш я ш ь л ә р д ә , шактый озын буйлы, ныкгәүдәле бер кеше иде* (Ш. Камал). *Мең е л л а р элек, хәтта соңрак та әле, китап басу станоклары да булмаган. Ул чорда китаплар кульязма хәлендә йөргән* (Г. Бәширов).

Татар телендә күплек санда гына кулланыла торган исемнәр юк. *Яшьләр, олылар, аклар, кызыллар* кебек исемнәргә килгәндә, аларның тамыр өлеше *(яшь-, олы-, ак-, кызыл-)* исем түгел. Бу очракта*-лар/-ләр* кушымчасы җыйма күплекне белдерә торган исемнәр ясаган, дөресрәге, бу очракны исемләшү нәтиҗәсе дип карарга кирәк *(яшь*

*кешеләр – яшьләр).* Мәсәлән: *Аңа бик иртә о л ы л а р арасына килеп керергә, о л ы л а р күтәргән йөкне нәни җилкәсенә күтәрергә туры килде* (Г. Ахунов).

*Т а у л а р авылында өч җил тегермәне бар* (И. Гази). Бу мисалдагы *Таулар* сүзе авыл исеме, ялгызлык исем буларак кулланылган.

Сан төшенчәсе (берлеге дә, күплеге дә) аналитик юл, ягъни аерым сүзләр белән дә белдерелә: *бер кеше, бер телем* (икмәк), *бер кочак* (утын), *бер көтү* (мал) һ.б. Мәсәлән: *Столяров өстәл тартмасын ачты да б е р т ө р г ә к г а з е т а чыгарды. Хәлим тагын б е р к о ч а к я ң а л ы к алып кайтты* (И. Гази). *Минә тәрбияче апалары, т е л е м - т е л е м и к м ә к тезелгән тактаны күтәреп, кухня ягына килеп чыкты* (И. Гази).

Шулай итеп, сан категориясенең берлек һәм күплек формасы, һәр форманың үзенә хас грамматик мәгънәсе була.

Эзлекле рәвештә, берлеген һәм күплеген каршы куеп, санның шушы ике формасында да кулланыла, шуларның төп мәгънәләрен (берлек яки гомуми күплекне) белдерә торган исемнәр белән беррәтттән, татар телендә берлеге дә, күплеге дә сан категориясенең төп мәгънәләренә туры килми торган, ягъни саналу төшенчәсенә битараф булган исемнәр дә байтак. Шундыйларга абстракт исемнәр, матдә исемнәре, җыйма һәм ялгызлык исемнәр керә. Аларның төп кулланылу формасы – берлек. Күплектә куллану (күплек кушымчасы) бу төр исемнәрнең мәгънәләренә төрле дәрәҗәдә үзгәреш кертә.

### 1.3.2. Тартым категориясе

Тартым категориясе предметның нинди дә булса затка (яки икенче бер предметка) караганлыгын белдерә. Аның махсус кушымчалары бар: *бакча-м – бакча-быз; бакча-ң – бакча-гыз; бакча-сы – бакча-лары.* Мәсәлән: *Безнең элекке а в ы л ы б ы з Акташ дип атала* (Г. Ибраһимов).

**Өйрәнелү тарихы.** Грамматикалар тарихында исемнең бу категориясенә карашлар төрле була. Озак вакытлар тартым исемгә хас морфологик билге итеп каралмый. Дөрес, татар теле грамматикаларының беренче авторларыннан И. Гиганов хезмәтендә [Гиганов И., 1801] татар телендә исемнәрнең тартым кушымчаларын кабул итүләренә, ягъни тартым белән төрләнүләренә игътибар бирелә. Бу күренешне

И. Гиганов «О лице имен» дип атый [Гиганов И., 1801, б. 23]. Әмма шуннан соңрак язылган грамматикаларда тартым кушымчалары алмашлыкның бер төре итеп, «тоташ алмашлар» дип йөртелә. Тартымның III зат формасы гына кайбер грамматикаларда [Фәезханов Г., 1887; Кәбутари Х., 1910] килеш системасына кертелә. Һ. Максуди [Максуди Һ., 1910] бер гасыр буена алмашлыкның бер төре итеп кенә каралган тартым кушымчаларын исемгә кайтара, *«...аның киеме, синен киемең, минем киемем»* дип, исемнең тартым белән төрләнү үрнәгенә, кушымчаларның төрләренә, ялгану кагыйдәләренә, тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнүләренә туктала [шунда ук, б. 12–13]. Әмма Һ. Максудиның тартымга карата булган фикере дә озак вакытлар игътибарга алынмый килә. Г. Ибраһимов та [Ибраһимов Г., 1911; 1915, б. 58], Җ. Вәлиди дә [Вәлиди Җ., 1915; 1919, б. 53] тартым кушымчаларын алмашлыкка кертәләр. Тик инде Г. Алпаровның хезмәтендә генә [Алпаров Г., 1945] тартымга карата булган караш төрлелегенә чик куела: анда һәм аннан соң язылган грамматикаларда исем сүз төркеменең сан, килеш категорияләре белән рәттән тартым да исемгә хас морфологик билге итеп карала.

Шул рәвешчә, тартымга карата татар теле грамматикаларында озак вакытлар төрле фикер яшәп килде: күбесендә тартым кушымчалары «тоташ алмашлар» дигән исем белән алмашлыкка кертелде, кайберләрендә генә исемнең морфологик билгесе итеп каралды, III зат формасын килешкә кертү очраклары да булды. Фәкать XX йөзнең икенче яртысы һәм аннан соң язылган грамматикаларда тартым исемнең башка категорияләре рәтендә үз урынын алды.

Тартым предметның, беренче чиратта, затка караганлыгын, нинди дә булса затныкы икәнлеген белдергәнгә күрә, аның өч зат һәм берлек/күплек формалары була:

| | Берлек | Күплек |
|---|---|---|
| I | *кул-ым* | *кул-ыбыз;* |
| II | *кул-ың* | *кул-ыгыз;* |
| III | *кул-ы* | *кул-(лар) ы* |

| Тартым формалары | Сузыкка беткән исемнәргә ялгана | | Тартым һәм *у–ү* гә беткән исемнәргә ялгана | |
|---|---|---|---|---|
| | Берлек | Күплек | Берлек | Күплек |
| I зат | *-м* | *-быз/-без* | *-ым/-ем* | *-ыбыз/-ебез* |
| II зат | *-ң* | *-гыз/-гез* | *-ың/-ең* | *-ыгыз/-егез* |
| III зат | *-сы/-се* | *-сы/-се (-лары/-ләре)* | *-ы/-е* | *-(лар)ы/-(ляр)е -(нар)ы/-(нәр)е* |

Тартым килеш категориясе белән тыгыз бәйләнештә: тартым белән төрләнгән исем, еш кына, билгеле бер килештәге зат алмашлыгы яки исем белән ачыкланып килә. Зат алмашлыклары иялек килешендә, тартымлы исемне ачыклап килгән икенче бер исем исә иялек килешендә дә, баш килештә дә кулланыла: *минем киемем, синең киемең, аның киеме; баланың киеме – бала киеме, өстәлнең тартмасы – өстәл тартмасы.* Мәсәлән: *Күптән түгел безнең тәрәзә капкачын оя итте минем сөйгән карлыгачым* (Г. Тукай). *Яшь алмагачның ботаклары үзләренә сарылган эре-эре яшел алмаларны көчкә күтәреп торалар* (И. Гази). *Абый бүлмәсендә ничә көн яшәгәнбездер, бераздан аерым фатир алып, шунда күчтек* (А. Расих).

Тартымлы исемнәр үзләре төрле килештә булалар. Мәсәлән: *Төштә миңа нәни кызым килде, чәчләремне сыйпап тарады. Айһай, әти, озак йөрдең, – диеп, күзләремә сөеп карады* (М. Җәлил). *Әнкәсе берничә тапкыр аның яныннан үтеп китте, хәтта үләндәге чык тамчылары аның битенә сибелеп калды* (И. Гази).

Предметның I һәм II затка караганлыгы түбәндәгечә тәгъбир ителә:

1) тартым кушымчалары ярдәмендә генә (синтетик ысул): *дәфтәрем, дәфтәр-ең, дәфтәр-ебез, дәфтәр-егез.* Мәсәлән: *Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм, Шуңар күрә сөям җаным, тәнем белән* (Г. Тукай). *Без документларыбызны тапшыргач, яңа һөнәрләребезне аныклау өчен тагын килербез, дип урамга чыктык* (А. Расих). *Әниең – дөнья бәясе кеше, – диде Балкыш, – тормышның терәге шундыйлар* (М. Маликова).

2) иялек килешендәге зат алмашлыгы һәм тартым кушымчалы исем белән (аналитик-синтетик ысул); *минем дәфтәр-ем, синең дәфтәр-ең; безнең дәфтәр-ебез, сезнең дәфтәр-егез.* Мәсәлән: *Шул көннән алып Алмачуар минем тормышымның үзәге була*

(Г. Ибраһимов). *Мин Сезнең м ә к а л ә г е з н е элек тә укыган идем, кичә тагын бер кат укып чыктым* (Г. Әпсәләмов). *Менә мин тагын авыл у р а м ы н д а йөрим. Бу – минем туган авылым* (И. Гази).

Бу ике ысулның беренчесе *(хезмәтем)* сөйләм телендә дә, язма телдә дә якынча бер дәрәҗәдә кулланылса, икенчесе *(минем хезмәтем)* күбрәк язма телгә карый. Моннан башка икенче ысулга эмоциональлек (хис-тойгы) төсмере хас. Мәсәлән: – *М и н е м М а й ш ә к ә р е м – трактористка. Менә м и н е м к ы з ы м к е м, – дип мактанып җавап бирде Җиһанша абый* (Г. Кутуй). *Сездә м и н е м бөтен т о й г ы л а р ы м, Сездә м и н е м керсез я ш ь л ә р е м. Сез үлсәгез, мин дә онытылырмын, Яшәсәгез мин дә яшәрмен* (М. Җәлил). Тартымлы тезмәдәге сүзләрнең урыннарын алыштыру эмоциональлек төсмерен көчәйтә генә. Мәсәлән: *К ү ң е л е м өйдә инде м и н е м хәзер, Гөлшаһидә Бәдриевна, – диде Галина Петровна сөенеп* (Г. Әпсәләмов).

Иялек килешендәге зат алмашлыгы һәм тартымсыз исем сүзтезмәсе дә тартым төшенчәсен белдерә: *минем дәфтәр – синең дәфтәр, безнең дәфтәр – сезнең дәфтәр.* Мәсәлән: *Миңнулла абзый, с и н е ң ф и к е р ? – дип сорады Якуп. – М и н е м ф и к е р м е ? Синеке ничек, минеке шулай* (И. Гази). *Тимеркәй – м и н е м и п т ә ш, мин аны яхшы беләм* (И. Гази). *Тау башына салынгандыр б е з н е ң а в ы л, Бер чишмә бар, якын б е з н е ң а в ы л г а ул* (Г. Тукай).

Тартым категориясенең III зат формасы мәгънәләре һәм кулланылышы белән I һәм II затлардан шактый аерыла. Предметның III затка (яки затларга) караганлыгы: 1) иялек килешендәге III зат алмашлыгы һәм тартым кушымчалы исем белән белдерелә (аналитик-сннтетик ысул): *аның дәфтәре – аларның дәфтәре (дәфтәрләре).* Мәсәлән: *Хәбир юл буе күзәтеп карап кайтты. Аста, самолет канатларыннан бик күпкә түбәндәрәк, а н ы ң туган я г ы, туган җ и р е җәйрәп ята иде* (Н. Акмал). Бу төр тезмәдәге сүзләрнең урыннарын алыштыру (инверсия) сөйләмгә эмоциональлек төсмере өсти. Мәсәлән: *А д ы м н а р ы җитез, к ү ң е л е күтәренке, у й л а р ы якты иде а н ы ң* (И. Гази).

2) III зат тартымлы исем белән генә дә белдерелә ала (синтетик ысул): *дәфтәре, баласы, куллары.* Бу очракта предметның кемгә (яки нәрсәгә) караганлыгы сөйләмдә ачыклана. Мәсәлән: *Бу вакыт Якуп күптән юлда иде инде. Анасын, күрше авылдагы к а р д ә ш л ә р е н ә*

*озатып куюны Шәрифҗанга тапшырып, үзе бүген иртә белән Казанга барырга чыккан иде* (И. Гази). *Егетләр, ахрысы, шуның өчен генә килгәннәр иде: эшләрен бетерделәр дә, килгән якларына кире борылып китеп бардылар* (Г. Ибраһимов). *Яннарында тугыз-ун яшьлек бер кызчык та бар. Балалары булса кирәк* (Г. Әпсәләмов).

III зат тартымлы исем, тартымның I һәм II зат формаларыннан аермалы буларак, иялек килешеңдәге яки баш килештәге икенче бер исем белән дә ачыкланып килә ала. Бу тезмәләрдә предметлар арасында иялек мөнәсәбәте дә, башка төр мөнәсәбәтләр дә белдерелә. Иялек мөнәсәбәте белдерелгәндә, ачыклаучы исем, гадәттә, иялек килешендә була: *абыйның бүлмәсе, баланың киеме, аюның баласы, карганың оясы* һ.б. Мәсәлән: *Сентябрь урталарында Дияровның улы кайтты* (Г. Ахунов). *Профессорның китапханәсе бөтен Казанга атаклы иде* (Г. Әпсәләмов). *Сугыш башланыр алдыннан гына, Төхфәт күн заводында эшләүче бер картның кызына өйләнде* (Ш. Камал).

Ачыклаучы исем баш килештә килсә, предметлар арасында урынга, вакытка, материалга, өлешкә, милләткә, ни өчен кирәклеккә һ.б. төшенчәләргә карата булган мөнәсәбәтләр белдерелә: *бала киеме, кыр чәчәге, урман чикләвеге, кыш бураннары, җәй яңгырлары, алма бәлеше, яшелчә ашы, өй түбәсе, татар егете, сөт савыты, савыт-саба шкафы* һ.б. Мәсәлән: *Җыелыштан соң Миңнулла Казан кунагын үзенә чәй эчәргә алып китте* (И. Гази). *Тиздән урман кошлары уяна. Әкрен генә таң җиле исеп куя* (Г. Бакир). *Якын гына урнашкан бер татар авылына Әлтафи морҗачы һәм сәгатьче буларак килеп төште* (М. Мәһдиев). *Чишмәле авылның тагын бер ягы бар: чишмә тавышын ишетеп үскән бала моңлы була* (М. Мәһдиев). *Ат караучының ат абзары ишеген авыр шыгырдатып ачканы ишетелә* (М. Мәһдиев).

Бу төр III зат тартымлы исем тезмәләрнең кайберләре, лексик берәмлеккә әйләнеп, татар теленең сүзлек байлыгын арттырганнар: *сөт өсте, эш хакы, печән өсте. куна тактасы, җир җиләге* һ.б.

*-ныкы/-неке* кушымчасы да, исемгә ялганып, тартымга якын мәгънәне белдерә. Тартым категориясеннән аермалы буларак, бу форма белән, беренче чиратта, нинди дә булса әйбернең (предметның) иясе (хуҗасы) белдерелә. Аңа караган предмет (исем) җөмләдә *-ныкы/-неке* кушымчалы исемнән алда килә яки ул сүз сөрешеннән аңлашыла.

Мәсәлән: *Менә ялтыравыклы дерматин белән капланган тагын бер ишек. Бу ишек – директорныкы* (М. Хәсәнов). *Өстәге киштәдә абый китаплары. Менә бу катта – апаныкы* (Г. Бакир). *Хәзер инде: «Бусы – Харис абзыйныкы», – дип, гәзитне алдан ук сумкасына салып куя* (Г. Гомәр).

*-ныкы/-неке* кушымчалы исемнәрнең килеш белән төрләнүе дә III зат тартымлы исемнәрнеке кебек: *укучыныкы, укучыныкы-на, укучыныкы-нда* һ.б. Мәсәлән: *Йорты авылдашларыныкыннан әллә ни аерылып тормый. Тик нигезен биегрәк итеп салган, шунлыктан калкурак күренә* (Ш.Хөсәенов).

Кайбер очракларда тартымлы исем үзе дә башка бер (тартымлы) исемне ачыклап, аның белән иялек мөнәсәбәтенә керә. Мәсәлән: *Бу егет – Мәдинә ханымның бертуган сеңлесенең улы иде* (Г. Әпсәләмов) (Мәдинә ханымның сеңлесе, сеңлесенең улы). *Авылыбызның эшчән киленнәре тезелешеп монда кер чайкыйлар* (Г. Ибраһимов) (авылыбызның киленнәре). *Хафиз картның әтисе дә кулыннан балтасын төшермәде, һөнәрен улына биреп калдырды* (Н. Акмал).

II зат (берлек) тартым кушымчасы кайбер очракларда предметның гомумиләштерелгән затка караганлыгын да белдерә ала. Мәсәлән: *Үз телеңне белми торып, халкыңа нинди дә булса ярдәм итү, аңа хезмәт итү һич мөмкин түгел* (А. Расих). *Мәзәкләр арасында шундый акыллылары, шундый тапкырлары бар ки, аларны ишеткәч, эшләгән эшеңә, электән ныгып килгән фикереңә бүтәнчәрәк, ачыграк күз белән, киңрәк мохиттән карый башлыйсың* (Г. Бәширов).

Шул рәвешчә, I–II зат тартымлы исем, зат алмашлыгы белән генә ачыкланып, предметның затка караганлыгын гына белдерсә, III зат тартымлы исем, зат алмашлыгы *(аның, аларның)* белән дә, икенче бер исем белән дә ачыкланып, предметның затка караганлыгыннан, ягъни иялек мөнәсәбәтеннән тыш башка күп төрле мөнәсәбәтләр белдерә.

Тартымлы исемнәр берлектә дә (нуль формада), күплектә дә (*-лар/-ләр* кушымчасы белән) кулланылалар. Сан категориясенә мөнәсәбәттә дә тартымның I–II затлары белән III заты арасында кайбер үзенчәлекле яклар бар. I–II зат тартымлы исем берлек санда килсә – предметның берлеген, күплектә булса – предметның бердән артык булуын белдерә: *бүлмәм – бүлмәләрем, бүлмәң – бүлмәләрең; бүлмәбез – бүлмәләребез,*

*бүлмәгез – бүлмәләрегез.* Мәсәлән: *Еш булмаса да, б а л а л а р ы м белән бергә су керергә барам, урманга чыгам* (Г. Кутуй). *Ә ә н и е ң – дөнья бәясе кеше,– диде Балкыш.– Тормышның терәге шундыйлар* (М. Маликова). *Без сезнең к а з а н ы ш л а р ы г ы з белән горурланабыз.*

III зат тартымлы исем дә берлектә дә, күплектә дә кулланыла. Мәсәлән: *Малайлар б а ш ы н югары күтәреп өреп торган Елгырны күрделәр* (Л. Ихсанова). Бу мисалда предмет та *(башын),* шул предмет иясе дә *(Елгырны)* берлектә килгән.

*Аның с о р а у л а р ы һәм алган җ а в а п л а р ы төрле иде* (Г. Кутуй). Бу мисалда предметның иясе *(аның)* бер, ә аңа караган предметлар (*сораулар-ы, җаваплар-ы)* бердән артык.

*Инде ә т и л ә р е күптән сугышка киткән иптәшләре арасында канәгатьләнү тойгысы иде бу* (М. Әмир). Бу мисалда предметларның иясе дә *(иптәшләр-е),* аларга караган предметлар да *(әтиләр-е)* бердән артык.

Ә кайбер очракларда тартымлы исем, формасы белән күплектә булса да, берлек сан мәгънәсе, ягъни III затка караган предметның бер икәнлеге белдерелә.

Мәсәлән: *Балаларым яшь, ә т и л ә р е турында дөресен сөйләсәм, аңлый алмаслар* (Г. Кутуй). *Әти-ләре* – күплектә, әмма мәгънәсе – берлек сан. *Ике елдан соң к ы з л а р ы үлеп, аңардан Шаһибәк исемле ир бала кала* (Г. Ибраһимов). Бу мисалда да III зат тартымлы исем күплектә *(кыз-лары),* әмма бу исем белән белдерелгән предмет бер *(аларның кызы).* Моны җөмләдәге *аңардан* сүзе раслый. Гомумән, күп очракта, III зат тартымлы исемнәрнең күплек формасы берлекнеме, күплекнеме белдергәнлеге контексттан, җөмлә эчтәлегеннән чыгып билгеләнә.

Эндәш сүзләргә ялганган I зат (берлек) тартым кушымчасы бу төр җөмлә кисәкләренең эмоциональлек төсмерләрен арттыра. Мәсәлән*: Исән-сау әйләнеп кайтыгыз, җ а н к и с ә к л ә р е м ! – дип әйтәсе килә кошларга* (И. Гази). *– Э н е к ә е м , шундый матур музыка, ...ә син тыңламыйсың,– ди Кадрия* (Г. Кутуй). *С а н д у г а ч ы м , әйт үземә, кайсы талга кунасың?* (җыр).

Шул рәвешчә, исемнең морфологик категорияләреннән берсе булган тартымның үзенә хас мәгънәсе һәм шул мәгънәне белдерә торган кушымчалары (формалары) бар. Предметның нинди дә булса затка

караганлыгын (нисбәтен) белдерү – аның төп мәгънәсе. Бу мәгънә тартымның I һәм II зат формаларында бик ачык күзәтелә. III зат тартым предметның III затка яки затларга караганлыгын да, ә күбесенчә, предметлар арасындагы күп төрле башка мөнәсәбәтләрне дә белдерә.

### 1.3.3. Килеш категориясе

Килеш – исемнәрне башка сүзләр белән бәйләп, аларны үзара төрле синтаксик мөнәсәбәткә (объект, субъект, урын, вакыт, сәбәп, максат һ.б.) куя торган грамматик категория: *китапны* (объект) *укып чыгу, мәктәптән* (урын) *кайтып керү, июльдә* (вакыт) *ял итү, җиләккә* (максат) *бару, шатлыктан* (сәбәп) һ.б.

Башка грамматик категорияләр кебек, килеш тә грамматик мәгънә һәм шул мәгънәне тәгъбир итә торган грамматик формадан тора: *баланы тәрбияләү* – бу тезмәдәге исемнең грамматик мәгънәсе – объект, *-ны* (төшем килеше) кушымчасы белән белдерелгән.

**Өйрәнелү тарихы.** Хәзерге татар әдәби телендә 6 килеш бар. Ләкин бу мәсьәләгә карата хәзерге көнгә кадәр бәхәсләр тукталганы юк. Килешкә, исемнең бер грамматик категориясе итеп, татар теленең рус телендә язылган беренче грамматикаларында ук урын бирелә. И. Гиганов [Гиганов И., 1801], И. Хәлфин [Хальфин И., 1809], А. Троянский [Троянский А., 1814], А. Казимбәк [Казембек А., 1839] һ.б. 7 килеш карыйлар: И. *кул;* Р. *кулнең;* Д. *кулгә,* В. *кулне;* Зв. *йә, кул;* Тв. *кул берлә;* Пр. *кул сәбәпле, кул хакында.* Бу авторларның хезмәтләре рус телендә булып, М. Ломоносовның «Российская грамматика»сы үрнәгендә язылганнар [Ломоносов М., 1755]. Шунлыктан татар теленең үз килеш системасы, аның үзенчәлекләре кирәкле дәрәҗәдә исәпкә алынмаган: кайбер килеш атамалары гына түгел, исемнәрнең килеш формалары да нәкъ рус телендәгечә (Зв. *йә, кул;* Тв. *кул берлә;* Пр. *кул сәбәпле, кул хакында*).

Г. Фәезханов үзенең грамматикасында [Фәезханов Г., 1887] 8 килешкә туктала: 1) *китап;* 2) *китабы;* 3) *китапның;* 4) *китапка;* 5) *китапны;* 6) *китап белән;* 7) *китаптан;* 8) *китапта.* Мисаллардан күренгәнчә, Г. Фәезханов килешкә *белән* бәйлеге ярдәмендә формалашкан исемне дә, тартымның III зат формасын да кертә. Беренчесе, аңа кадәр булган грамматикаларның барысында да диярлек, чыгыш килешенең бер варианты итеп яки чыгыш килеше урынына

күрсәтелгән, Г. Фәезханов III зат тартым кушымчасын килешкә кертеп, аның ике исем арасында бәйләнеш булдыруыннан чыгып эш итә: *адәм бала-сы, яз баш-ы* һ.б.

К. Насыйриның «Әнмүзәҗ»ендә 6 килеш. Тик анда да чыгыш килеше *белән, илә* бәйлекләре ярдәмендә бирелгән [Насыйри К., 1895, б. 46].

Г. Ибраһимов [Ибраһимов Г., 1911; 1915] һәм Җ. Вәлиди [Вәлиди Җ., 1919] килеш мәсьәләсенә бөтенләй башка караштa: алар «татар теленә килеш белән төрләнү хас түгел» дигән фикерне күтәреп чыгалар.

Бу фикерен дәлилләү өчен Г. Ибраһимов: «Рус телендә падеж белән үзгәргәндә, сүзнең ахыргы хәрефе ташлана да аның урынына төрле хәрефләр арттырыла... (*вода – вод-ы, вод-е* һ.б.). Татар телендә исә 1) сүзләрнең үзгәрүе вакытында сүз үзе бөтен кала; 2) сүз ахырына тоташкан галәмәтләр (к у ш ы м ч а л а р) исемдә, сыйфатта, санда һәм берлек-күплектә һаман бер төрле йөри. Димәк, безнең телебездә сүзләрнең падеж яки игъраб белән үзгәрүе дигән нәрсә бөтенләй юк» дип, катгый нәтиҗә ясап куя [Ибраһимов Г., 1927, б. 96–114].

Г. Ибраһимов килеш кушымчаларын «кушымта» [Ибраһимов Г., 1927, б. 51–52], ә Җ. Вәлиди «тагылмалар» [Вәлиди Җ., 1919, б. 85–86] дип аерым карарга тәкъдим итәләр.

Г. Ибраһимовның бу карашын Г. Алпаров тәнкыйть итеп чыга. Килеш белән төрләнгәндә, сүзләрнең үзгәрмәве татар теленең ябышмалы (агглютинатив) табигатенә бәйле булуын аңлатып, «...кушымта дигән нәрсәләр, нинди генә яктан караганда да, аерым сүз була алмыйлар. Алар ...безнең телебездә төрле хокукы белән бар булган падеж бетемнәре (к у ш ы м ч а л а р ы) генә, башкача түгел» – дип язды [Алпаров Г., 1925, № 1].

Г. Нугайбәкнең «Төрлек» исемле хезмәтендә [Нугайбәк Г., 1911] килешләрнең саны да, составы (төрләре) да хәзерге татар әдәби телендәгечә. Тик исемнәре (атамалары) генә башкача: 1) атау төшеме (баш килеш); 2) тарту төшеме (иялек килеше); 3) бирү төшеме (юнәлеш килеше); 4) күчү төшеме (төшем килеше); 5) чыгу төшеме (чыгыш килеше); 6) урын төшеме (урын-вакыт килеше)[1].

---

[1] «Килеш» сүзен, грамматик термин буларак, гамәлгә кертеп җибәрүчеләр М. Корбангалиев һәм Х. Бәдигый була (Ана теле сарфы, 1918). Ә аңа кадәр «килеш» урынына «падеж» яки «игъраб» сүзләре кулланылды, килешнең төрләре дә я рус, я гарәп исемнәре белән йөртелде.

Г. Алпаров 1926 елда язылган «Шәкли нигездә татар грамматикасы»нда [Алпаров Г., 1945, 24–145] 8 килеш барлыгын әйтә (баш килеш, иялек килеше, чыгыш килеше, юнәлеш килеше, төшем килеше, вакыт-урын килеше, рәвеш килеше, ошату килеше). Соңгы ике килешкә карата үзе дә искәрмә биреп: «...ча-чә*, дай-дәй* кушымчаларының башка иптәшләреннән аерымлыклары бар, беренче – болар басымны үзләренә үткәрмиләр. Бу яктан алар уртак кушымчаларга ошыйлар. Икенче – кайвакыт үзләреннән соң башка килеш төрлекләрен кабул итәләр. Бу яктан алар сыйфат һәм рәвеш ясаучы кушымчаларга ошый төшәләр», – ди.

Соңгы чорда язылган грамматикаларның (морфологияләрнең) барысында да [Хангилдин В., 1959, б. 82–90; Тумашева Д., 1964, б. 56–67; Хәзерге..., 1965, 194–198; Современный..., 1969, 139–143; Хәзерге..., 1972, 44–52] 6 килеш (баш килеш, иялек килеше, юнәлеш килеше, төшем килеше, чыгыш килеше, урын-вакыт килеше) карала.

1960 еллардан соң килеш мәсьәләсенә карата яңа фикерләр барлыкка килде. М. Зәкиев үзенең мәкаләсендә төрки телләрнең, шул исәптән татар теленең дә, күп килешле тел булулары турында яза. Ул килешләргә *-лы, -сыз, -дагы, -дай, -ча* кушымчалы формаларны өстәп, «татар телендә 11 килеш бар» дигән фикерне күтәрә [Закиев М., 1964, б. 207–219].

М. Зәкиев татар теленең сөйләм төзелешен тирәнтен тикшерү нәтиҗәсендә кайбер ясагыч кушымчаларның да сүзләр арасында бәйләнеш булдыруларына игътибарны юнәлтә. Ул бу мәсьәләгә карата түбәндәгеләрне әйтә: «...сыйфат яки рәвеш ясаучы кушымчалар бер үк вакытта сүзләрне үзара бәйләүче чара булып та торалар, ягъни *-лы/-ле, -сыз/-сез, -ча/чә, -дагы/-дәге, -лык/-лек, -дай/-дәй* кебек кушымчалар исемнәрне исемгә бәйләү процессында ясалма сыйфатлар яки ясалма рәвешләр барлыкка килә...» [Закиев М., 1974, 59].

Ф. Ганиев М. Зәкиевнең килешкә карата әйтелгән фикерләренә кушыла. Алай гына да түгел, 10 синтетик, 8 аналитик форма белән килеш санын 18 гә җиткерә. Аналитик формаларга *аяк белән, Ватан өчен, юлбарыс төсле, алтын хакында, җир астында, Идел өстендә, вагон астына, игътибарсызлык аркасында* кебек бәйлек, бәйлек сүзләр белән кулланылган исемнәрне кертә [Ганиев Ф., 1970, 74–82].

Үзенең кандидатлык диссертациясендә Р. Зарипов башкорт телендә 19 килеш турында сүз алып бара, бишесе кушымчасыз (нуль

формалы), алтысы гамәлдәге килешләр, калганнары башка төр кушымчалы формалар (*-лы, -сыз, -дагы, -дай, -ча, -ныкы, -ый*) [Зарипов Р., 1971, 23].

Килеш хәзерге көндә дә татар тел белемендә бәхәсле мәсьәләләрнең берсе булып кала. XX йөздә русча һәм татарча язылган татар теленең грамматикаларында килешләр *белән* (*берлә, илә*)*, хакында, сәбәпле* кебек бәйлекләр хисабына арттырылган. Аларда килешләр саны 7–8 гә җитә [Гиганов И., 1801; Хальфин И., 1809; Троянский А., 1814; Фәезханов Г., 1887; Насыйри К., 1895]. Бу – турыдан-туры рус теленең килеш системасына ияру, аның творительный, предложный исемле килешләренең мәгънәләрен татар телендә бирергә тырышу нәтиҗәсе. Хәзерге көндә килеш системасына сыйфат һәм рәвеш ясагыч дип йөртелә торган кушымчаларның кайберләрен (*-лы/-ле, -сыз/-сез, -дагы/-дәге, -дай/ -дәй, -ча/-чә*) кертү турында сүз бара һәм килешләр саны 10–11 гә җиткерелә [Закиев М., 1964, 207–219; Ганиев Ф., 1970, с. 74–84; Ганиев Ф., 1980, с. 17–30].

Тел белгечләре татар телендә кушымчаларның саф ясагыч һәм саф төрләндергеч, ягъни, сүзнең лексик мәгънәсен үзгәртеп, яңа лексик берәмлек ясый торган һәм, сүзнең грамматик мәгънәсен үзгәртеп, аның төрле грамматик формаларын үзгәртә торган төрләреннән башка, сүз ясагыч та, сүзнең грамматик формасын үзгәртүче дә, ягъни күп функцияле кушымчалар булуын да әйтеп, андыйларга *-лык(-лек), -ча(чә), -лы(-ле), -сыз(-сез)* кушымчаларын кертәләр [Ганиев Ф., 1980, с. 31–32].

*-лы/-ле, -сыз/-сез, -дагы/-дәге, -дай/-дәй, -ча/-чә* ләрне килеш кушымчаларына охшаш кушымчалар дип йөртергә була. Тик аларның саны югарыда китерелгән 4–5 белән генә чикләнми. Алар телебездә байтак, бигрәк тә сыйфат һәм рәвеш ясагычларның күбесе шундыйлар: *-гы/-ге(-кы/-ке), -чан/-чән, -лык/-лек, -даш/-дәш. -лап/-ләп, -лата/-ләтә* һ.б. Бу кушымчалар да сүзләр арасында бәйләнеш булдыралар: *яз-гы җил, кышкы юл, эш-чән кеше, атна-лык азык, аваз-даш сүзләр, чиләк-ләп ташу, акча-лата түләү* һ.б.

Килеш – махсус кушымчалар ярдәмендә исемне башка сүзләр белән бәйләп, аларны төрле синтаксик мөнәсәбәткә куя торган грамматик категория.

Кушымчалар ярдәмендә формалашып, исемнең үзенә генә хас төрләнеш системасын (Б. *җиләк;* И. *җиләк-нең;* Ю. *җиләк-кә;* Т. *җиләк-не;*

Ч. *җиләк-тән;* У-в. *җиләк-тә*) булдыруы килешне морфологик категорияләр рәтенә кертә.

Шул ук вакытта килеш категориясе грамматиканың икенче бүлеге булган синтаксиска да карый: теге яки бу килештәге исемнең грамматик мәгънәсе һәм аның синтаксик функциясе сүзтезмәдә яки җөмлә эчендә генә ачыклана. Мәсәлән: *Җиләккә су сибәргә кирәк. Балалар җиләккә киттеләр.* Бу мисаллардагы *җиләккә* сүзе икесендә дә юнәлеш килешендә, тик беренчесендә ул исем *(җиләккә)* эш-хәлнең объектын белдерә, җөмләдә тәмамлык, ә икенчесендә эш-хәлнең максатын белдерә, җөмләдә хәл.

Хәзерге татар әдәби телендә килеш системасын баш килеш, иялек, юнәлеш, төшем, чыгыш, урын-вакыт килешләре тәшкил итә. Һәр килешнең үзенә хас кушымчасы була, тик баш килеш кенә кушымчасыз (нуль формалы). Килеш кушымчалары сингармонизм законына бәйле рәвештә ике вариантлы: нечкә һәм калын (*-ның/-нең, -га/-гә, -ны/-не, -дан/-дән, -да/-дә*). Исемнең соңгы авазы нинди (яңгырау-саңгырау һәм борын авазы) булуга бәйле рәвештә килеш кушымчаларының вариантлары тагын да арта төшә (*-га/-гә. -ка/-кә, -дан/-дән, -тан/-тән, -нан/-нән, -да/-дә, -та/-тә*). Шул рәвешчә, кайбер килеш кушымчалары – ике вариантлы, кайберләре – дүрт вариантлы, ә берсе (чыгыш килеше) – алты вариантлы. Моны түбәндәге таблицадан күрергә була:

| Килешләр | Кушымчалар |
|---|---|
| Баш килеш | – |
| Иялек килеше | *-ның -нең* |
| Юнәлеш килеше | *-га -га / -ки -кә* |
| | *(-гача -гәчә) (-кача -кәчә)* |
| Төшем килеше | *-ны / -не* |
| Чыгыш килеше | *-дан -дән / -тан -тән / -нан -нән* |
| Урын-вакыт килеше | *-да -дә /-та -тә* |

Килеш-кушымчалары исемгә иң соңгы булып ялгана: *Урын-нар-ыгыз-да (булыгыз), -нар* – сан, *-ыгыз* – тартым, *-да* – килеш кушымчасы[1].

[1] Килеш кушымчасыннан соң кисәкчәләр генә ялгана ала: *Барыгыз да урын-нарыгыз-да – мы?*

Бу хезмәттә килешкә характеристика биргәндә, өч аспект күздә тотыла: 1) грамматик форма, 2) грамматик мәгънә һәм 3) синтаксик функция. Кирәк булганда, килешләрнең стилистик мөмкинлекләре дә исәпкә алына.

Килеш кушымчасы: 1) исемне башка сүзләргә бәйли; 2) исемнең сүз төркеме (предметлык) мәгънәсен үзгәртми; 3) теләсә нинди исемгә ялгана; 4) бер килеш кушымчасы булган исемгә икенче килеш кушымчасы ялганмый.

**Баш килеш.** Исемнең килеш кушымчасыз формалары баш килешкә карый. Баш килеш – татар телендә күп функцияле. Ул субъект, объект һ.б. мөнәсәбәтләрне белдерә. Аның синтаксик функцияләре дә күп төрле.

Баш килештәге исем, субъектны белдереп, җөмләнең иясе була. Мәсәлән: *Дөнья яшеллеккә күмелгән. Кояш елмаеп карый, агачларда кошлар сайраша* (Г. Ахунов). *Безнең бик борынгы бабаларыбыз чиктән тыш кыен шартларда яшәгәннәр* (Г. Бәширов). Бу мисаллардагы ия хәбәр белән хәбәрлекле мөнәсәбәттә, ия хәбәрне үзенә иярткән: *Дөнья (яшеллеккә) күмелгән. Кояш карый. Кошлар сайраша. Бабаларыбыз яшәгәннәр.*

Баш килештәге исем, туры объектны белдереп, җөмләдә тәмамлык була. Мәсәлән: *Көндезләрен ул күзлеген киеп ала да, алты почмаклы яңа өенең олы ягына чыгып, газит-журналлар караштыра, хатлар, китаплар укый* (Р. Кәрами).

Туры объект (тәмамлык) – төшем килешенә хас мәгънә. Тик баш килештәге тәмамлык үзе бәйләнгән җөмлә кисәге алдында, аның белән янәшә тора. Мәсәлән: *Мин, көне-төне эшләп, бүләкләр хәзерләдем* (А. Шамов). *Без аның матур итеп шигырь сөйләвен тыңларга яратабыз.* Урынын алыштыру тәмамлыкның килеш формасын үзгәртүгә китерә. Мәсәлән: *Әнием бик тәмләп чәй эчә. – Әнием чәйне бик тәмләп эчә.*

Баш килештәге объектка (тәмамлыкка) билгесезлек төсмере хас: *бала тәрбияләү (баланы тәрбияләү), кунаклар озату (кунакларны озату), аш ашау (ашны ашау)* һ.б.

Баш килештәге исем икенче бер исемне ачыклап килә. Алар арасында төрле синтаксик мөнәсәбәт урнаша.

Аерылмыш исем тартымлы да тартымсыз да була. Аерылмыш тартымлы булса, баш килештәге исем (аергыч) аны төрле яктан: милләте,

(ялгызлык) исеме, ни өчен кирәклеге, урыны, вакыты һ.б. яклардан ачыклап килә: *т а т а р кызы, У ф а шәһәре, И д е л елгасы, а ш өстәле, к и т а п шкафы, у р м а н чикләвеге, к о е суы, м а р т ае* һ.б. Мәсәлән: *Шушы вакыйгадан соң Якупка р у с эшчеләре дә, т а т а р эшчеләре дә хөрмәт белән карый башладылар* (И. Гази). *Г а г р а шәһәре шулай минем тормышымда зур борылыш ясады* (М. Мәһдиев). *Ул, ш ә һ ә р урамнарында бераз йөргәннән соң, вокзалга әйләнеп килде* (И. Гази). *Яз көне Төхфәт Шәрәфи карт белән сөйләшми-нитми генә күн заводыннан үзенең элекке эшләгән урыны – к и р п е ч заводына эшләргә күчте* (Ш. Камал).

Аерылмыш тартымсыз булса, баш килештәге исем (аергыч) аны материалы, профессиясе, шөгыле, күләм-чамасы һ.б. яклардан ачыклап килә: *п ы я л а ишек, е ф ә к күлмәк, т ә р б и я ч е хатын, у к ы т у ч ы апа, б е р к а п ч ы к он, т е л е м - т е л е м икмәк* һ.б. Мәсәлән: *Башта аерым җырлар җырланды, шуннан соң сәхнәгә е ф ә к күлмәктән зифа буйлы бер кыз килеп чыкты* (Г. Бакир). *Т и м е р мич астында, шатыр-шотыр килеп, коры-сары яна* (М. Хәсәнов). *Авылда бер карчык бар иде. Балалар аны җ и л ә к ч е әби дип йөртәләр иде* (Г. Ибраһимов). *Журналны алды да, б е р к о ч а к дәфтәр күтәреп, классы кереп китте* (М. Мәһдиев).

Татар тел белемендә *таш йорт, тимер капка, йон күлмәк* кебек тезмәләрдәге беренче исемнәрне сыйфат дип караучылар бар. Дөрес, алар, сыйфатлар кебек, икенче бер тартымсыз исемне ачыклап, аергыч булып киләләр, аерылмыш алдында янәшә торып, формаларын үзгәртмиләр. Әмма формаларын үзгәртмәве бу төр исемнәрнең кулланылышына бәйле. Башка кулланылышта *таш, пыяла, кирпеч, тимер* һ.б. килеш, тартым белән төрләнәләр, берлек яки күплектә киләләр. Мәсәлән: *Урман артыннан бүрек хәтле болыт күренде исә, шунда ук т а ш н ы бастырып, тиз генә тәгәрмәчләрне бәйләргә менеп китә* (Г. Ибраһимов).

Бу күренешкә карата М. Зәкиевнең әйткән сүзләрен китерү урынлы булыр: «Татар телендә исемнәр, исем белән бирелгән төшенчәләрне конкретлаштырганда, сыйфатка әйләнмиләр, исем булып калалар (*а г а ч күпер, а г а ч тотка* һ.б.)» [Хәзерге..., 1972, б. 12].

Баш килештәге исем ия, тәмамлык, аергычтан башка хәбәр дә булып килә. Мәсәлән: *Җиргән – Агыйдел суы буенда, Эстәрлетамак шәһәре белән Оренбург шәһәре арасында урнашкан зур гына а в ы л* (Л. Хәмидуллин). *Бу – безнең бөек елгабыз И д е л* (Г. Ибраһимов).

Эндәш сүз дә баш килештәге исем белән белдерелә. Мәсәлән: – *Ә б и , атны бераз ял иттерик, үзебез дә җылыныйк. Монда берәүгә кереп чыгарбыз, – диде Низами* (Г. Ибраһимов). *Ю л л а р ,  ю л л а р , сез бит барыгыз да Менә шундый аяусыз! Я, әйтегез, кемнәр үтте сездән, Салындыгыз башлап каян сез?* (М. Җәлил).

Баш килештәге исем вакыт, күләм-чама мәгънәләрен белдереп, җөмләдә хәл була: *и к е  е л (хезмәт итү), к ө н  д ә (килеп йөрү), б е р  а й (кунак булу), к ы ш (әйләнеп кайту)* һ.б. Мәсәлән: *Я з кайтмасам, к ө з кайтам дип, үз күңелемне юатам* (җыр). *А й китте, е л китте, артына әйләнеп караса, энә буе җир китте* (әкияттән).

Атау җөмләләрдә баш килештәге исем предмет һәм күренешләрнең чынбарлыкта булу-булмауларын белдерә (хәбәр итә). Мәсәлән: *Җ ә й . Күктән кояш карый, кошлар сайраганы ишетелә* (Г. Ахунов). *Т ө н .  Салкын ж и л . Яңгыр сибәли.*

Баш килештәге исем бәйлекләр белән дә кулланыла. Ул, объект, урын-вакыт һәм башка мөнәсәбәтләрне белдереп, җөмләдә тәмамлык һәм хәл булып килә: *дуслар белән* (очрашу), *көн саен* (хәбәрләшү), *урман шикелле* (куе), *балалар өчен* (борчылу), *урам аркылы* (чыгу) һ.б. Мәсәлән: *Алар җәй көне шулай к ө н  с а е н , безнең а в ы л  б е л ә н ике арадагы тау башына чыгып, караңгы төшкәнче җырлыйлар иде* (Г. Бәширов). *Иделнең түбән ягыннан а к к о ш  к е б е к бер пароход күренде* (Ш. Мөхәммәдев).

Баш килештәге исем лексик берәмлеккә әйләнгән кайбер тезмәләрдә дә очрый: *колак салу, күз ташлау, ут йоту, юл бирү, үрнәк алу, баш күтәрү, сүз бирү* һ.б.

**Иялек килеше.** Бу килеш *-ның/-нең* кушымчасы ярдәмендә формалаша. Иялек килеше предметның (затның) башка бер предметка (затка) ия булуын, гомумән, предметлар арасындагы төрле мөнәсәбәтләрне белдерә: *а н а н ы ң мәхәббәте, б а л а н ы ң көлмәге, й о р т н ы ң тәрәзәсе, җ ә й н е ң матурлыгы, к о я ш н ы ң җылысы, с а н д у г а ч н ы ң тавышы, т ы р ы ш л ы к н ы ң нәтиҗәсе* һ.б. Иялек килешендәге исем гадәттә җөмләнең аергычы була. Мәсәлән: *Агыйделнең киң болыннар, зур таулар арасыннан боргаланып-боргаланып аккан җирендә үзенең зурлыгы, й о р т л а р ы н ы ң төзеклеге белән кечерәк шәһәргә охшашлы бер авыл бар* (Г. Ибраһимов). *Тирән чанага утырып, ниндидер бер озын гына буйлы кеше белән бергә Г а б д у л л а н ы ң*

*әнисе килеп төште* (Ә. Фәйзи). *Иң, алдан Зәңгәр чишмәнең үз сатучылары кайта* (Г. Ибраһимов). *Кара карлыган салган чәйнең тәме дә икенчерәк була* (Ш. Камал). Иялек килешендәге аергычка (баш килештәге аергычтан аермалы буларак) билгелелек төсмере хас: *баланың курчагы (бала курчагы), авылның урамы (авыл урамы), китапның тышы (китап тышы), йортның түбәсе (йорт түбәсе)* һ.б.

Иялек килешендәге исем, икенче бер исемне ачыклап килгәндә, аергыч була. Әмма иялек килешендәге исемнең кайбер фигыль формаларын ачыклап килүләре дә шактый еш очрый: *Әтинең кайтуын (кайтканын) көтәбез. Әтинең кайчан кайтасын белмибез.* Бу очракта иялек килешендәге исем үтәүче затны яки нинди дә булса хәлне кичерә торган предметны белдерә һәм җөмләдә тәмамлык булып килә. Мәсәлән: *Бары тик сугыш бетәр алдыннан гына Солтанның, ниндидер бер елганы кичкәндә, батырларча һәлак булуы турында әти-әниләренә язу килде* (Н. Фәттах). *Бераздан тышкы ишекнең ачылып ябылуы, чолан идәненең шыгырдап китүе ишетелде* (И. Гази). *Мотаһирның бу ихатага инде бик күптәннән аяк басканы юк* (Р. Кәрами).

**Юнәлеш килеше.** Бу килеш *-га/-гә, -ка/-кә*, ә I һәм II зат тартымлы исемнәргә *-а/-ә*, III зат тартымлы исемнәргә *-на/-нә* кушымчалары ялганып формалаша: *бакча-га, бакчам-а, бакчасы-на* һ.б.

Болардан башка юнәлеш килешенең *-гача/-гәчә* кушымчалы төре дә очрый. Бу кушымча урынга-вакытка чикләү төсмере өсти: *урмангача, төшкәчә* һ.б.

Юнәлеш килеше урын-вакыт, максат мәгънәләрен белдереп, җөмләдә хәл була. Мәсәлән: *Мин инде, бакча артындагы елгага төшеп, су да коендым* (А. Шамов). *Киткән урманга утынга ялгызы бер ат җигеп* (Г. Тукай). *Юлчылар, кичкә кайтып җитәргә тырышып, кызу атладылар.*

Юнәлеш килеше объект мәгънәсен белдереп, җөмләдә тәмамлык була. Мәсәлән: *Урам тын. Җил генә агачларга, кое чылбырына, сыерчык оясы кадакланган колгага кагылып выжлап үтә* (Р. Кәрами). *Егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз* (мәкаль).

*Таба, хәтле, каршы* һ.б. шундый бәйлекләр белән кулланылып, урын-ара, объект мөнәсәбәтләрен белдерә. Мәсәлән: *Ул кискен адымнар*

*белән ишеккә таба китте* (А. Расих). *Кайтам, кайтам туган якларыма, Талларыма хәтле сагынган* (С. Хәким). *Болай булгач, без Босфорга кадәр дә барып җитә алмаячакбыз* (Г. Бәширов).

*-гача/-гәчә* кушымчалы юнәлеш килеше дә урын-вакыт мәгънәләрен белдерә һәм *хәтле, чаклы, кадәр* бәйлекләре белән кулланылган формаларга тәңгәл килә. Мәсәлән; *Төшкәчә (төшкә хәтле) өмә шул таллыкка җитәргә тиеш иде* (Г. Ибраһимов).

Юнәлеш килешендәге исемнәрне түбәндәге кушма фигыльләрдә очратырга була: *кулга төшерү, кәкре каенга терәтү, күңелгә сеңдерү, колакка каты булу* һ.б.

**Төшем килеше.** Кушымчасы – *-ны/-не.* III зат тартым кушымчалы исемнәргә *-ын/-ен/-н* кушымчасы ялгана: *кул-ны, сөлге-не; ку-л-ын; сөлге-се-н.*

Төшем килеше туры объектны белдерә. Бу – аның төп мәгънәсе. Җөмләдә төшем килешендәге исем – тәмамлык. Мәсәлән: *Ул йөгерә-йөгерә торакка кайтты, бүлмәләрне, уку залларын әйләнеп чыкты, университетка кагылды* (Г. Ахунов). *Кем белә, ул таныш авазлар, бәлки, иркендә чагындагы рәхәтлекләрне, киң басуларны, урман аланнарын яңадан күз алдына китергәндер* (Г. Бәширов).

Баш килештәге туры объекттан (тәмамлыктан) аермалы буларак, төшем килешендәге объектка билгелелек төсмере хас: *күлмәкне тегү (күлмәк тегү), хатны язу (хат язу)* һ.б.

Шунлыктан, ялгызлык исем белән белдерелгән туры тәмамлык, җөмләдәге урынына карамастан, һәрвакыт төшем килешендә була. Мәсәлән: *Кошчакның үлем хәбәре Сөембикәне аяктан екты* (Р. Батулла). *Урамга чыктым да иптәшләрне эзләргә киттем. Бәлки, Гайнияне дә очрата алмаммы, дигән өмет бар иде* (Г. Ибраһимов).

Төшем килеше, эш-хәлнең вакытын белдереп, җөмләдә хәл дә була ала. Бу очракта төшем килешендәге исем, гадәттә, билгеләү, күрсәтү алмашлыклары яки *бер* саны белән кулланылган була. Мәсәлән: *Ап-ак кар таулары кайнар кояш нуры астында шул көнне үк иңеп төште* (И. Гази). *Айсылу Нәфисәгә һәр көнне яңа газеталар, кечкенә китапчыклар китерә торган иде* (Г. Бәширов). *Ул елны ашлык искиткеч уңган иде* (Ш. Камал). *Бер көнне алар урамда очраштылар.*

**Чыгыш килеше.** Бу килеш *-дан/-дән, -тан/-тән, -нан/-нән* кушымчалары ярдәмендә формалаша. III зат тартымлы исемнең кушымчасы – *-ннан/-ннән: шәһәр-дән, урам-нан, йорты-ннан* һ.б.

Чыгыш килешендәге исем, эш-хәлнең урынын белдереп, җөмләдә урын хәлен аңлата: *мәктәптән (кайту), юлдан (бару), ишектән (чыгу).* Мәсәлән: *Бер бик эссе көнне яшенле яңгыр и н с т и т у т т а н кайтып баручы Кыямны әллә кемнәрнең ишек алдына куып кертте* (И. Гази). *Ш ә һ ә р д ә н килгән яшьләр учак янына җыйналдылар* (Ш. Камал).

Вакыт төшенчәсен белдергән, чыгыш килешендәге исем вакыт хәле була: *бер елдан (очрашу), ике көннән (кайтып җитү), кичтән (ява башлау)* һ.б. Мәсәлән: *Күңелем сизә: мин а л т ы - җ и д е а й - д а н кайтырмын* (Г. Ибраһимов). *Ике амбар арасында к ө з д ә н төшеп калган, иртә шытып чыккан көнбагыш сап-сары чәчәк аткан* (А. Гыйләҗев). Күргәнебезчә, вакыт мәгънәсен белдергәндә, чыгыш килешендәге исем, еш кына, сан белән кулланыла.

Чыгыш килешендәге исем эш-хәлнең сәбәбен белдерә һәм җөмләдә сәбәп хәлен аңлата: *шатлыктан (елмаю), куркудан (калтырау), эсседән (хәлсезләнү)* һ.б. Мәсәлән: *Мин к у а н ы ч ы м н а н тагын да ягымлырак тавыш белән дәшә башладым* (Г. Бәширов). *Шаһи картның үзенең дә э с с е д ә н күзләре агарган* (Г. Ибраһимов).

Эш-хәлнең күләм-чамасын белдереп, күләм хәле була. Мәсәлән: *Су шаулап забойга тула. Инде т е з д ә н булды* (И. Гази). *Б и л д ә н карга батып булса да, бакчадагы йортыбызга килеп җитә алдык.*

Чыгыш килешендәге исем эш-хәлнең объектын да белдерә һәм җөмләдә тәмамлык була: *туганнардан (хәбәр алу), ападан (үрнәк алу), күршедән (сорашу), китаптан (аерылмау)* һ.б. Мәсәлән: *Б и т - л ә р д ә н, м у е н н а р д а н, ч ә ч л ә р д ә н йомшак кына сыйпап, рәхәт, җиләс җил исә* (Г. Әпсәләмов). *Чатнама гыйнвар суыкларында да иске п а л ь т о д а н йөрде* (И. Гази). *Ләкин аны зирәклеге х у р - л ы к т а н коткара барды* (Г. Ибраһимов).

Сирәгрәк булса да, чыгыш килешендәге исем җөмләдә хәбәр булып килә. Мәсәлән: *Кунак йортының стеналары н а р а т т а н* (Г. Ахунов). *Аның эшләре хәзер м у е н н а н булачак* (И. Гази).

Чыгыш килеше бәйлекләр белән дә кулланыла. *Кыштан бирле, җыелыштан соң, илемнән башка* һ.б. Мәсәлән: *Бер я р т ы с ә г а т ь т ә н*

*соң без авыл уртасындагы зур гына клубка барып кердек* (А. Шамов). *Ике җ ы р д а н  с о ң  Мәдинәдән тагын ике җырны җырлаттылар* (Ш. Камал). *К и т а п т а н  б а ш к а  белемле булып булмый.*

Хәлдән таю, эштән чыгу, һуштан язу кебек фигыльләр чыгыш килешендәге исемнәр катнашында ясалганнар.

**Урын-вакыт килеше.** Кушымчасы – *-да/-дә, -та/-тә*, III зат тартымлы исемнәрдә – *-нда/ -ндә: урам-да, шәһәр-дә, йорт-та, йортын-да* һ.б.

Урын-вакыт килешендәге исем, эш-хәлнең урынын яки вакытын белдереп, җөмләдә хәл була. Мәсәлән: *Югары п а л у б а д а  кызлар авыл егетенең аерылышу турындагы җырын сузып җибәрделәр* (С. Сабиров). *Шушы яшенә җитеп, Якупның я з  б а ш ы н д а  у р м а н д а  булганы юк иде* (И. Гази). *Җыелыш билгеләнгән с ә г а т ь т ә  башланды* (Ә. Баян). *Сугышның соңгы е л ы н д а  чигәләрендә ак чәчләр елтырый башлады* (И. Гази). *У р м а н ы н д а  кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк* (Г. Тукай).

Объект мәгънәсен белдереп, урын-вакыт килешендәге исем җөмләдә тәмамлык була. Мәсәлән: *Нәгыйм яшьтән үк балык тотарга ярата һәм бу э ш т ә  беркадәр сәләте дә бар* (Ш. Камал). *Беләм, егет, синең җ ы р ы ң д а  Үз иленә сөю, якынлык* (М. Җәлил).

Урын-вакыт килешендәге исем җөмләдә хәбәр дә була. Мәсәлән: *Шылт иткән тавыш та юк. Һәммәбезнең күзе Х и с а м  а б з ы й д а* (Г. Бәширов). *Миңа унҗиденче яшь бара инде; Күңел – бикле, баян – с а н д ы к т а* (Ә. Баян).

Шул рәвешчә, килеш – исемнең иң әһәмиятле грамматик (морфологик) категорияләреннән берсе.

Килешләрдән иялек килеше, гадәттә, исемне исемгә, тик кайбер очракларда гына фигыльнең кайбер формаларына (исем фигыль һәм сыйфат фигыльгә) бәйли. Исемне исемгә бәйләгәндә, төрки тел белемендә «изафә» дип йөртелгән сүзтезмәләр барлыкка килә: I. *Тәрбияче апа, укытучы кыз, таш йорт* һ.б.; II. *Бала киеме, өстәл аягы, китап шкафы* һ.б.; III. *Кешенең сәламәтлеге, әтинең йорты, агачның яфрагы* һ.б. Төшем килеше исемне тик фигыльгә генә бәйли. Ә калган килешләр (юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешләре), ешрак исемне фигыльгә бәйләсә дә, исемне башка сүз төркемнәре белән дә төрле синтаксик мөнәсәбәткә куя.

| Килешләр | Сузыкка һәм яңгырау тартыкка беткән исемнәр | | Саңгырау тартыкка беткән исемнәр | |
|---|---|---|---|---|
| | Калын | Нечкә | Калын | Нечкә |
| Баш килеш | *җыр* | *тәрәзә* | *агач* | *сөт* |
| Иялек килеше | *җыр-ның* | *тәрәзә-нең* | *агач-ның* | *сөтнең* |
| Юнәлеш килеше | *җыр-га* | *тәрәзә-гә* | *агач-ка* | *сөт-кә* |
| Төшем килеше | *җыр-ны* | *тәрәзә-не* | *агач-ны* | *сөт-не* |
| Чыгыш килеше | *җыр-дан* | *тәрәзә-дән* | *агач-тан* | *сөт-тән* |
| Урын-вакыт килеше | *җыр-да* | *тәрәзә-дә* | *агач-та* | *сөт-тә* |

**Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше.** Хәзерге татар әдәби телендә килеш белән төрләнү төгәл бер система тәшкил итә. Килеш белән төрләнми торган исемнәр юк. Барлык исемнәрнең дә (берлектә дә, күплектә дә) төрләнеше бер төрле үк, тик тартымлы исемнәрнең генә кайбер килеш формаларында үзгәреш була. Ә килеш кушымчаларында булган төрлелек татар теленең фонетик закончалыкларына бәйле (калын һәм нечкә кушымчалар, яңгырау-саңгырау яки борын авазына башланган кушымчалар һ.б.).

| Килешләр | I, II һәм III зат (берлек) тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше | | |
|---|---|---|---|
| | I | II | III |
| Баш килеш | *тәрәзәм* | *тәрәзә* | *тәрәзәсе* |
| Иялек килеше | *тәрәзәмнең* | *тәрәзәңнең* | *тәрәзәсенең* |
| Юнәлеш килеше | *тәрәзәмә* | *тәрәзәңә* | *тәрәзәсенә* |
| Төшем килеше | *тәрәзәмне* | *тәрәзәңне* | *тәрәзәсен* |
| Чыгыш килеше | *тәрәзәмнән* | *тәрәзәңнән* | *тәрәзәсеннән* |
| Урын-вакыт килеш | *тәрәзәмдә* | *тәрәзәңдә* | *тәрәзәсендә* |

III зат тартымлы исемнәрнең юнәлеш, төшем, чыгыш, урын-вакыт килешләрендәге «н», тел белгечләренең әйтүләренә караганда, борынгырак чорда тартым кушымчасы составында, ягъни III зат тартым кушымчасы *-ын, -сын* формасында булып, сүз азагында килгәндә төшеп кала, ә III зат тартымлы исемгә кушымча ялганганда, «н» яңадан урынына кайта торган була [Дмитриев Н., 1956, с. 32–33; Тумашева Д.Г., 1964, б. 66].

Ә тартымның күплек формаларында килеш белән төрләнеш тартымсыз исемнәрдәге кебек: *тәрәзәбезнең, тәрәзәгезнең, тәрәзәләренең, тәрәзәбезгә, тәрәзәгезгә, тәрәзәләрегезгә* һ.б.

### 1.3.4. Хәбәрлек категориясе

Тарихи рәвештә төрки телләрдә шактый киң таралган һәм актив кулланылган исемгә хас бу грамматик категория хәзерге телдә аерым очракларда гына үзенең барлыгын сиздерә, һәм ул җуелып бара торган грамматик күренешләрдән санала.

Хәбәрлек – исемнең җөмләдә хәбәр булып килүен махсус кушымчалар белән белдерү дигән сүз. Мәсәлән: *Мин укытучымын. Син укытучысың. Ул укытучыдыр.*

Кайчандыр ул тулы парадигмада кулланылган:

| | Берлек | Күплек |
|---|---|---|
| I зат | *-мын/-мен* | *-быз/-без* |
| II зат | *-сың/-сең* | *-сыз/-сез* |
| III зат | *-дыр/-дер (-тыр/-тер)* | *-дыр/-дер (-тыр/-тер)* |

Күргәнебезчә, исемнең хәбәрлек кушымчалары, фигыльдәге затсан кушымчалары кебек, бер үк вакытта затның да, санның да күрсәткече булып торалар.

Хәбәрлек кушымчаларыннан I һәм II затка караганнары чыгышлары белән зат алмашлыкларына, ә III затныкы *тор-* дигән фигыльгә кайтып кала.

Мәсәлән: *Бөтенләем белән җирнекемен, Игенчеләр – нәсел-нәсәбем* (С. Хәким). *Балык каптыру минем бәләкәй чактан ук сөйгән эшемдер* (Г. Ибраһимов).

Хәбәрлек кушымчалары хәбәр булып килгән урын-вакыт килешендәге исемнәргә дә ялгана ала. Мәсәлән: *Мин егерме бер яшьтәмен* (Г. Ибраһимов). *Сез өйдәсез икән әле.*

Хәбәрлекнең юклык төре «түгел» сүзе ярдәмендә формалаша, аңа хәбәрлек кушымчалары ялгана. Мәсәлән: *Мин язучы түгелмен. Син язучы түгелсең* һ.б.

Хәбәрлек кушымчалары, гадәттә, профессия, һөнәр исемнәренә ялгана: *укытучы-сың, машина йөртүче-мен, балта остасыдыр* һ.б.

Тик шуны әйтергә кирәк, хәзерге татар әдәби телендә I һәм II зат хәбәрлек кушымчалары сирәк кулланыла. Аларны зат алмашлыклары алыштыра: *Мин – тегүче; Син – тегүче; Без – тегүче(ләр): Сез – тегүче(ләр).*

Ә инде III зат хәбәрлек кушымчаларын куллану бөтенләй юк дияргә була. Аның урынын кайбер очракта гына III зат алмашлыгы ала: *Нәсимә – т е г ү ч е ул.* Гадәттә, хәбәр булып килгән исем зат алмашлыгыннан башка гына кулланыла: *Нәсимә – т е г ү ч е; Нәсимә, Фәридә, Зәйнәп – т е г ү ч е л ә р.*

### 1.3.5. Исемдә билгелелек-билгесезлек мәсьәләсе

Һәр грамматик категориянең эчтәлек (грамматик мәгънә) һәм формадан (грамматик формадан) торганын искә алсак, билгелелек/билгесезлекнең, грамматик (морфологик) категория буларак, татар телендә формалашмаганы күренә, чөнки аның үзенә генә хас грамматик формалары, махсус морфологик күрсәткечләре (кушымчалары) юк. Бу төшенчәләр телдәге төрле (ешрак лексик) чаралар ярдәмендә (мәсәлән, *бер* саны һәм *бу, шул, шушы кебек* күрсәтү алмашлыклары ярдәмендә) белдерелә. Бер саны, предметның исәбе буларак кулланылмаганда, предметка билгесезлек төсмере өсти, *бу* (*шул, шушы*) предметны билгеле бер әйбер итеп күзалларга ярдәм итә. Мәсәлән: *Кара күзле б е р матур к ы з Шәйхетдинов белән янәшә туры килде. Б у к ы з н ы институт коридорларында Кыямның очратканы бар иде инде* (И. Гази). *Куянак исемле станциядән аз гына читтәрәк б е р к а з а р м а д а тора идек* (Ш. Камал). *Авылдан өч чакрым ераклыкта булган б у зур к ү л г ә миңа балачактан ук бик еш йөрергә туры килә иде* (Г. Ибраһимов). *Минем б е р ш и г е м бар иде. Өч көн үтте, өч төн үтте. Шул шик йөрәгемне кимерүдән туктамады* (Г. Ибраһимов). *Безгә ш у ш ы ю л д а н күп йөрергә туры килде.*

Билгесезлек алмашлыклары да исемнәргә билгесезлек төсмере өсти. Мәсәлән: *Н и н д и д е р кечкенә м а л а й тегеләргә капка ачты. Ат урам буйлап чаба башлады* (И. Гази).

## 1.4. ИСЕМЛӘШҮ

Исемне ачыклап килә торган сүз төркемнәре (сыйфат, сыйфат фигыль, сыйфат алмашлыклары, сан), исемнән башка үзләре исем функциясендә кулланылып, исемгә хас морфологик һәм синтаксик

билгеләрне кабул итәләр. Бу күренеш тел белемендә сүз төркемнәренең контекстуаль исемләшүе дип йөртелә. Моңа үз вакытында Г. Алпаров та игътибар итә: «Җөмлә эчендә исемнәр үзләре әйтелми калган чагында, сыйфат, сан һәм аларның алмашлары ул исемнәрнең урынына килеп, исем төрлекләре белән төрләнәләр» [Алпаров Г., 1945, б. 107].

Исемләшкән сүз җөмләдә исем кебек килеш, тартым белән төрләнә, берлек яки күплектә килә, күбесенчә фигыль белән бәйләнешкә кереп, ия, тәмамлык була. Исемләшүнең төп шарты – сыйфат, сыйфат фигыль, сыйфат алмашлыгы һәм санның исемнән башка кулланылуы. Гадәттә исемләшү төп игътибарны предметның үзенә түгел, аның билгесенә юнәлтү кирәк булганда барлыкка килә. Мәсәлән: *Бикмүш бабай зәңгәр фонарьны алды да, аның урынына к ы з ы л н ы куйды* (Г. Гобәй). *Юл күрсәтә а д а ш к а н г а Имән кышкы бураннарда, Җәен татлы дымын эчерә Кырда урак у р г а н н а р г а* (М. Җәлил). *Трамвайдан т ө ш ү ч е л ә р, ботинкаларын, туфлиләрен кулларына тотып, туп-туры суга сикерәләр иде* (И. Гази). *Чокырның уң як ярында, саргылт комда, тирән аяк эзе бар. Ш у н ы үлчәп алдылар* (Г. Ибраһимов). *Шәяхмәткә алдагы көндә у н т у г ы з тулып, е г е р м е г ә китә* (Г. Ибраһимов). *Борылышка җитәрәк, урман шикелле үсеп утырган киндер арасыннан ике кеше килеп чыкты. Б е р с е атның тезгененнән тотты, и к е н ч е с е читкәрәк басып карап тора башлады* (И. Гази). Бу мисаллардагы *кызылны* (сыйфат), *адашканга, урганнарга, төшүчеләр* (сыйфат фигыльләр), *шуны* (сыйфат алмашлыгы), *унтугыз, егермегә, берсе, икенчесе* (сан) – исемләшкән сүзләр. Алар – төрле килештә, кайберсе тартым кушымчалы, берлектә яки күплектә. Бу сүзләр – фигыль белән бәйләнештә һәм төрле җөмлә кисәге: *кызылны* (куйды), *адашканга* (юл күрсәтә), *урганнарга* (эчерә), *шуны* (үлчәп алдылар) – тәмамлык, *төшүчеләр, берсе, икенчесе* – ия, *унтугыз, егермегә* – хәбәр составында. Исемгә күчкән сүз төркемнәреннән (*күрше, яралы, язучы, буяу, язу* һ.б.) аермалы буларак, исемләшкән сүзләрнең исемгә хас билгеләре җөмлә эчендә кулланылышларына гына бәйле. Җөмләдән тыш, ул сүзләрнең исемгә хас билгеләре юкка чыга (*кызыл, адашкан, урган, төшүче, шул, унтугыз, егерме, бер, икенче*).

Исемләшү – телебездә еш очрый торган күренеш. Ул сөйләмне җыйнакландыра, кирәкмәгән кабатлаулардан коткара. Шунлыктан бу күренешне халык авыз иҗатының бер төре булган мәкальләрдә еш куллану очраклы түгел: *Һ ө н ә р л е үлмәс, һ ө н ә р с е з көн күрмәс.*

*Тырышкан табар, ташка кадак кагар* (мәкаль) һ.б. Исемләшүнең төп шарты – исемне ачыклый торган сүз төркеменең исемнән башка кулланылуы. Моннан башка, аергыч булып килгән исемнең аерылмышы белән урыннарын алыштыру да исемләшүгә китерә. Мәсәлән: *Чишмәләрнең дә бит төрлесе була: ташлар ярып чыкканы, шаулап, чәчрәп акканы, куе үләннәр арасыннан тавышсыз, ашыкмыйкабаланмый гына юл ярганы* (Л. Ихсанова). *Кызыл чәчәкләр яратам. Чәчәкләрнең кызылын яратам. Сеңелемә өч китап алдым. Китапның өчесе дә – сеңлемә.*

## 1.5. ИСЕМДӘ ИРКӘЛӘҮ-КЕЧЕРӘЙТҮ КУШЫМЧАЛАРЫ

*-чык/-чек, -кай/-кәй, -кәш* кушымчалары хәзерге татар әдәби телендә исемнәрнең мәгънәләренә иркәләү-кечерәйтү төсмере өстиләр: *кош-чык, бала-кай, эне-кәш* һ.б.

Бу кушымчалар, нигездә, тереклек ияләрен белдерә торган исемнәргә ялганалар. Мәсәлән: *Яннарында тугыз-ун яшьлек бер кызчык та бар иде* (Г. Әпсәләмов). *Мескен кошчык бәрелде, харап булды, дип торганда гына, тургай канатларын җәеп җибәрде дә солы арасына әкрен генә килеп төште* (И. Гази). Бу мисаллардагы *кыз-чык, кош-чык* сүзләренә ялганган кушымчалар аларның мәгънәләренә кечерәйтү төсмере өсти.

Түбәндәге мисалларда *-кай, -кәй* кушымчалары исемнәргә иркәләү төсмере бирә: *Әнкәй усал кайнана булмас, ул, киленкәем, дип аркасыннан кагып кына торыр* (Г. Ибраһимов). *Бер генә түгел, бик күп тапкырлар очраштык әле без ул кара кашлы кызыкай белән* (И. Гази). *Көн-төн көлтә ташу белән, бераз өшәнгәннәр ахрысы, малкайлар* (Г. Ибраһимов).

Исемнәргә шундый ук мәгънә төсмере бирә торган *-кәш* кушымчасы да бар: *Сеңелкәше бик уңган, бик чибәр кыз икән.*

Эндәш сүз булып килгән I зат (берлек сан) тартым кушымчалы исемнәрдә (исемләшкән сүз төркемнәрендә) дә иркәләп эндәшү төсмере бар. Мәсәлән: *Күбәләгем, түгәрәгем, асыл кошым, сандугачым, хатлар көтәмен синнән* (Ф. Кәрим). *Әнием, күз нурым, көт мине, кайтырмын* (Ә. Даутов). *Карга әйтте: «Аппагым!» Куян әйтте: «Батырым!» Бака әйтте: «Матурым!» Керпе әйтте: «Йомшагым!» Ә кешегә ни кала? «Шәфкатьле бул син, балам!»* (Ш. Галиев).

## 2. СЫЙФАТ

Сыйфат инде беренче грамматикаларда ук бүленеп чыгарыла. И. Гиганов, М. Иванов, М. Мәхмүдев, К. Насыйри һ.б.ның грамматикаларында сыйфатларның мәгънәсе, кулланылышы, ясалышы һәм типологик үзенчәлекләре турында мәгълүмат бар.

Октябрь инкыйлабыннан соңгы чорда грамматика мәсьәләләрен планлы рәвештә өйрәнү башлана. М. Корбангалиев, Җ. Вәлиди, Г. Алпаров, Х. Бәдигый хезмәтләрендә сүз төркемнәренең, шул исәптән сыйфатның да төрләнешенә һәм ясалышына зур игътибар бирелә.

В. Хангилдин, Д. Тумашеваның гомуми грамматик хезмәтләрендә, СССР Фәннәр Академиясе һәм Казан дәүләт педагогия институты авторлар коллективлары тарафыннан төзелгән грамматикаларда сыйфатларның лексик-семантик, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләре бик җентекләп өйрәнелгән. Сыйфатларның ясалышы Ф. Ганиев хезмәтләрендә тирән яктыртылган.

Сыйфат предметның киң мәгънәсендә процессуаль булмаган, статик билгесен белдерә. Монда объектив чынбарлыктагы предметларны, затларны, төрле мөнәсәбәтләрне характерлаучы үзенчәлекләр, сыйфатлар, аерым алганда, зат һәм предметларның тышкы сыйфатлары *(матур, сипкелле, кытыршы),* кешенең эчке үзенчәлекләре *(оялчан, рәхимсез, тыйнак),* пространство белән бәйле төрле мөнәсәбәтләр *(очсыз-кырыйсыз, кыска, озын),* вакыт мөнәсәбәтләре *(җәйге, еллык, көндәлек),* предметларның төсе *(ак, кара, күгелҗем)*, тәме *(ачы, төче, тозлы),* физик халәте *(сыек, ватык, үле),* формасы *(түгәрәк, шакмаклы, өчпочмаклы)* һ.б. билгеләр керә.

Предметның конкрет нинди билгесен белдерүләренә карап, сыйфатлар түбәндәге лексик-семантик төркемнәргә бүленәләр:

1) төс ягыннан билге белдерүчеләр: *яшел кызыл, сары;*

2) тәм ягынан билге белдерүчеләр: *тәмле, ачы, татлы;*

3) ис ягыннан билге белдерүчеләр: *хуш исле, сасы, иссез;*

4) пространствога бәйле билге белдерүчеләр: *иксез-чиксез, озын, кыска;*

5) вакыт ягыннан билге белдерүчеләр: *атналык, язгы, кичке;*

6) тышкы сыйфатны белдерүчеләр: *гүзәл, ямьсез, матур;*

7) характерны, психик үзенчәлекләрне белдерүчеләр: *юаш, усал, тәрбиясез;*

8) форма белдерүчеләр: *яссы, очлы, тулы;*

9) физик халәтне белдерүчеләр: *каты, йомшак, сыек;*

10) күләм, чама ягыннан билге белдерүчеләр: *зур, кечкенә, түгәрәк;*

11) акыл ягыннан билге белдерүчеләр: *акыллы, надан, тинтәк* һ.б.ш.

Морфологик планда караганда, сыйфат татар телендә грамматик яктан формалашмаган: сыйфатның аны башка сүз төркемнәреннән аера торган формаль күрсәткечләре юк. Чагыштырып карагыз: *тары* (исем), *бары* (кисәкчә), *сары* (сыйфат); *шушы* (алмашлык), *чыршы* (исем), *кытыршы* (сыйфат). Составларында шушы сүз төркеменә хас сүз ясагыч кушымчалары булган сыйфатлар гына чыгарма тәшкил итәләр: *итагатьле, тәрбияле, тәрбиясез, котсыз, эшчән, хәрәкәтчән, тышкы, эчке* һ.б.ш.

Сыйфат – төрләнми торган сүз төркеме. Асыл сыйфатлар гына дәрәҗә белдерәләр: *яшел, яшелрәк, ямь-яшел, яшькелт; сары, сарырак, сап-сары, саргылт; кызыл, кызылрак, кып-кызыл, кызгылт.*

Синтаксик планда сыйфат исемгә янәшәлек ярдәмендә бәйләнә һәм, нигездә, аергыч функциясен үти: *Җиңгәчәйнең өстендә киң итәкле, озын, кәшимир зәңгәр күлмәк, яшел камзул, башында көмеш тәңкәле тар гына калфак, калфак өстеннән чәчәкле яулык ябынган, юка шәлен иңенә салган, аягында сары читек белән кара галош* (Ә. Еники). *Безне котлап, җылы яңгырлар Шатлык сибәр Идел буенда, Безне котлап, иркен болында Назлы аккош моңы яңгырар* (Ф. Кәрим). *Озын яллы сары ат җиз кыңгыраулы кара дуга һәм эшлияле камыт белән читән тарантаска җигелгән* (Ә. Еники).

Сыйфат хәбәр функциясендә дә киң кулланыла. Мәсәлән: *Идән черек, стеналар юеш, почмакларда гөмбәләр үсә* (К. Нәҗми). *Бу кешенең чиксез күп газаплардан тирән-тирән җыерчыклар белән капланган йөзе тыныч, кырыс, хәтта тантаналы иде*

(Г. Әпсәләмов). *Өйләр барысы да яңалар, тазалар һәм бер яклап кына утырганнар* (Ә. Еники). *Ә ай юк, айның соңгы көннәре, тиз генә чыкмаячак, шуңа күрә төне дә дөм-караңгы* (Ә. Еники).

Сыйфат хәл функциясен дә үти: *Ул елларда... Һади Такташның көчле тавышы тагын да дәртлерәк яңгырый башлады* (Г. Бәширов). *Кара паровоз еракtан, чабыш айгыры шикелле, бик сылу, дәртле, кыю булып күренә һәм, пошкырган саен, һавага бер-бер артлы тезелешеп киткән кечкенә ак болытлар тарата* (Ә. Еники). *Йосыф үзендә моңарчы булмаган ныклык белән һәрбер сүзен үткен итеп, утлы итеп әйтте...* (К. Нәҗми).

Субстантизацияләнгәндә, сыйфат исем үзенчәлекләрен ала: килеш, тартым белән төрләнә, берлектә һәм күплектә килә, исемнең синтаксик функцияләрен үти: *Әйбернең яңасы яхшы, дусның искесе яхшы* (мәкаль). *Сүзе хакның йөзе ак* (мәкаль). *Олыларга хөрмәт кыл, кечеләргә шәфкать кыл* (әйтем). Беренче җөмләдә исемләшкән сыйфатлар – ияләр, икенчесендә – хәбәрләр, өченчесендә – тәмамлыклар функциясендә килгәннәр.

### 2.1. СЫЙФАТНЫҢ ЛЕКСИК-ГРАММАТИК ТӨРКЕМЧӘЛӘРЕ

Лексик-грамматик үзенчәлекләреннән чыгып, сыйфатларны асыл сыйфатлар һәм нисби сыйфатлар дип аталган ике төркемгә бүлеп өйрәнәләр. Асыл сыйфатлар предметның саф билгеләрен – төсен *(яшел, зәңгәр, ал),* күләмен, формасын *(киң, тар, түгәрәк),* физик сыйфатларын *(яшь, карт, көчле),* эчке сыйфатларын *(тыйнак, юаш, усал)* һ.б.ны, ягъни аның башка предметка, күренешкә мөнәсәбәтеннән килеп чыкмаган билгеләрен белдерәләр.

Нисби сыйфатлар предметның башка предметлар белән төрле мөнәсәбәтләреннән килеп чыккан билгеләрен белдерәләр: *язгы җил, көзге яңгыр, кышкы юл* (вакытка бәйле билге), *атлы кеше, күзлекле кыз* (башка предметка иялек мөнәсәбәтендә булудан килеп чыккан билге), *өске кат, аскы бүлмә* (предметның урынына бәйле билге) һ.б.

Асыл сыйфатларга дәрәҗә категориясе хас: *ак – аграк – ап-ак – аксыл; сары – сарырак – сап-сары – саргылт* һ.б. Асыл сыйфатлар нигездә тамыр сүзләр: *саф, яшь, карт, аяз, сай.* Ләкин асыл һәм нисби

сыйфатлар арасында аерма бик аз. Асыл сыйфатлар, исемнән ясалган нисби сыйфатлар бәрабәренә, даими рәвештә тулыланып торалар: *башлы, төпле, көчле, ихтыярсыз* һ.б.ш.

Асыл сыйфатлар җөмләдә аергыч, хәбәр һәм хәл функцияләрендә киләләр. Мәсәлән: *Мин үзем, нигәдер, менә шушындый иркен, матур табигатьтә утырган кечкенә, җыйнак авылларны күбрәк яратам* (Ә. Еники). *Дөнья матур, дөнья киң...* (Г. Афзал). *Һаваларда очкан кошкайларның Күңелле икән шаулап үтүе...* (халык җыры). *Кояш чыга әйләнеп, Ак болытка бәйләнеп, Җиңү белән, саусәламәт Кайтсак иде әйләнеп* (халык җыры).

Әйтергә кирәк, татар телендә бер очракта – предмет билгесен, икенчесендә – эш-хәл билгесен белдереп, асыл сыйфат функциясен дә, рәвеш функциясен дә үти ала торган шактый күп сүзләр бар: *яхшы кеше – яхшы эшләү, югары кат – югары карау, матур үрнәк – матур чигү.*

Нисби сыйфатларның синтаксик функцияләре асыл сыйфатларныкына караганда, таррак: алар, нигездә, аергыч булып кына йөриләр. *Безнең халыкның бөтен рухи дөньясы урман белән бәйле* (М. Мәһдиев). *Ахияр белән гармун кинәт кенә икесе ниндидер бер сихри музыкаль инструментка әйләнә дә куя* (М. Мәһдиев).

## 2.2. СЫЙФАТ ДӘРӘҖӘЛӘРЕ

Асыл сыйфат белән белдерелгән билге төрле дәрәҗәдә булырга мөмкин: бер предметтагы билге, икенче бер предметтагы шундый ук билге белән чагыштырганда, аннан бераз артык, яки иң югары дәрәҗәдә яисә гадәттәгедән ким булырга мөмкин. Сыйфат белдергән шушы билге дәрәҗәләре татар телендә махсус грамматик һәм лексик чаралар ярдәмендә бирелә.

Төп дәрәҗә – сыйфатның чыганак формасы – билгене башка предмет һәм затлар белдергән билге белән чагыштырмыйча бирә. Бу дәрәҗәнең махсус күрсәткече юк: *ак (күлмәк), нечкә (җеп), кечкенә (авыл).*

Чагыштыру дәрәҗәсе бер предметтагы билгенең башка предметлардагы шундый ук билгедән артыграк булуын белдерә. Аның үз күрсәткече бар, ул – *-рак/-рәк* кушымчасы: *ак – аграк, нечкә – нечкәрәк,*

*кечкенә – кечкенәрәк.* Мәсәлән: *Бүген кичәгедән салкынрак... Каракошның киләчәге, үткәненә караганда, һичшиксез матуррак булырга тиеш* (Ә. Еники).

Чагыштыру дәрәҗәсенең мәгънәсен белдерү күп кенә очракта синтаксик яктан ныгытыла: чагыштыру предметы баш килештәге исем белән, чагыштыру объекты – *караганда* һәм *чагыштырганда* бәйлек сүзләре белән бирелә: *Бу авыл тегесенә караганда* (тегесе белән чагыштырганда) *кечкенәрәк*. Мондый конструкцияләрдә *-рак/-рәк* кушымчасын ул белдергән мәгънәгә зыян китермичә, төшереп калдырырга да мөмкин. Чагыштырыла торган билгенең интенсивлыгы бу очракта кимеми генә түгел, киресенчә, арта: *Бу авыл тегесеннән кечкенә. Бу авыл тегесенә караганда* (тегесе белән чагыштырганда) *кечкенә.*

Чагыштыру дәрәҗәсе кушымчасы кайвакытта билгенең түбәнрәк интенсивлыгын да белдерә: *күңелсезрәк хәл, сәеррәк кеше, йомшаграк укучы*. Шушындый ук мәгънәне, билгенең түбәнрәк интенсивлыгы мәгънәсен, бу кушымча башка сүз төркемнәренә дә бирә. Мәсәлән: *азрак ашап алу, соңрак килү, озаккарак сузылу* (рәвешләргә); *тегендәрәк тору, мондарак килү, болайрак эшләү* (алмашлыкларга); *эшли торганрак кеше, тыңлый торганрак бала; китебрәк утыру, уйлабрак сөйләү* (сыйфат фигыльләргә, хәл фигыльләргә).

Чагыштыру дәрәҗәсе асыл сыйфатларга гына хас. Ләкин алар арасында да билге интенсивлыгын үзгәртми торган семантик төркемнәр бар: *үле, тере, шәрә, чулак* һ.б.ш.

Артыклык дәрәҗәсе гомумән билгенең яисә башка предметларның, шундый ук билгеләре белән чагыштырганда, иң югары интенсивлыгын белдерә. Бу дәрәҗәнең ясалуы, чагыштыру дәрәҗәсендәге кебек, эзлекле түгел, аның күрсәткечләре дә төрле.

Артыклык дәрәҗәсе сыйфаттан алда урнаша торган универсаль *иң* кисәкчәсе һәм индивидуаль, бары тик бер сыйфатка гына яки фонетик яктан үзара охшаш берничә сыйфатка гына ялгана торган препозитив кисәкчәләр ярдәмендә ясала. Мондый кисәкчәләр татар телендә шактый күп: *чем- (чем-кара), чеп- (чеп-чи), шыр (шыр надан, шыр ялангач, шыр тиле), дөм (дөм сукыр, дөм караңгы), чалт (чалт аяз, чалт якты), тома (тома сукыр, тома надан), ап- (ап-ак), кап- (кап-кара,*

*кап-караңгы), зәп- (зәп-зәңгәр), кып- (кып-кызыл), чып- (чып-чын), яп-/ япа- (яп-ялгыз), ямь (ямь-яшел), түп- (түп-түгәрәк), түм- (түм-түгәрәк), күм- (күм-күк), җете (җете зәңгәр), сап- (сап-сары), өр- (өр-яңа)* һ.б. Индивидуаль көчәйткеч кисәкчәләр күпчелек очракта сүзнең беренче иҗегенә *п* яки *м* авазлары өстәп кабатлау юлы белән ясалалар: *ап-ак, кап-кара, зәп-зәңгәр, ямь-яшел, күм-күк* һ.б.ш. Мәсәлән: *Болын тип-тигез, чуп-чуар чәчәк кенә* (Ә. Еники). *Япа-ялгызым идем. Шунда гына аңладым: үзем ыңгырашканмын икән бит* (Г. Бәширов). *Алдымда шау чәчәктән торган тип-тигез болын җәйрәп ята* (Ә. Еники). *Пароходлар Казанга җиткәндә, пристань элеккечә буп-буш иде* (К. Нәҗми).

Артыклык дәрәҗәсенең үзенчәлекле формасын сыйфатларның кабатланып килүе тәшкил итә: *чибәр-чибәр (кызлар), зур-зур (ташлар), озын-озын (юллар).* Бу форманың үзенчәлеге шунда: ул күп предметлар һәм затларның, сирәгрәк, эш-хәлләрнең билгеләрен генә белдерә: *Кайчак исә ул юлларга озын-озын эшелоннар килеп туктый* (Ә. Еники). *Өстендә эре-эре кара тәңкә төшкән ак кофта* (М. Мәһдиев). *Яшел чирәм өстеннән вак-вак атлап, муеннарын текә тотып йөрүләре!* (Р. Мөхәммәдиев).

**Кимлек дәрәҗәсе.** Бу дәрәҗәдәге сыйфат белән белдерелгән билге гадәттәгедән ким, азрак итеп бирелә: *яшькелт, саргылт, аксыл, алсу* һ.б.ш. Кимлек дәрәҗәсе *-кылт/-келт, -чылт/-челт (яшькелт, саргылт), -келтем (әчкелтем, төчкелтем), -сыл/-сел (аксыл, күксел), -су (алсу), -елҗем (күгелҗем)* кушымчалары ярдәмендә ясала.

Кимлек дәрәҗәсенең телдә кулланылуы шактый чикле. Ул, нигездә, предметларның төсен, тәмен, физик халәтен белдерүче сыйфатларда гына күзәтелә. Мәсәлән: *Өстендә саргылт толстовка, башында аксыл уңган фетр эшләпә* (М. Мәһдиев). *Шушы биеклек өстеннән кайсы якка гына карасаң да, җәелеп яткан аксыл иген кырлары, яшел үзәннәр, күгелҗем урманнар... күренә* (Ә. Еники). *Авыл бакчаларында кызгылт бакыр төсле иң гади күбәләкләр була* (М. Мәһдиев).

# 3. САН

## 3.1. САННАРНЫ ӨЙРӘНҮ ТАРИХЫ

Сан исемнәре беренче татар грамматикаларында ук аерым сүз төркеме итеп танылганнар. Ләкин аларда әле сан сүз төркемен фәнни анализлау җитәрлек дәрәҗәдә түгел. Терминнарны куллануда булсын, саннарның лексик-семантик, морфологик билгеләрен тикшергәндә булсын, әле бердәм караш юк.

Татар телендә язылган беренче грамматикаларда түбәндәге терминнар кулланыла: исме гадәд (Г. Фәезханов, К. Насыйри), сан атлары (Г. Нугайбәк), сан, сан исеме (Җ. Вәлиди), сан, саннар (Г. Ибраһимов, Г. Алпаров). Соңгы авторлар кулланган атамалар хәзерге әдәби тел терминологиясендә норма булып урнаша.

Беренче грамматикаларда санның лексик-семантик, морфологик билгеләрен тикшергәндә дә бердәмлек булмый. Рус телендә язылган хезмәтләрдә, мәсәлән, санның өч төркемчәсе күрсәтелә: 1) микъдар саны, 2) тәртип саны (И. Гиганов) яки тәртипле сан (И. Хәлфин, А. Троянский, А. Казимбәк), 3) бүлем саны.

М. Иванов исә үзенең грамматикасында санның түбәндәге төркемчәләрен билгели: 1) микъдар саны, 2) тәртип саны, 3) бүлем саны, 4) вакланма сан, 5) җыю саны. Бу хезмәттә автор җыю санын тагын өч төркемчәгә аера:

а) *-ау/-әү* кушымчалы саннар: *дүртәү, бишәү, алтау;*

б) *-лап/-ләп* кушымчалы саннар: *дүртләп, бишләп, алтылап;*

в) *-аулашып/-әүләшеп* кушымчалы саннар: *дүртәүләшеп, бишәүләшеп, алтаулашып.*

Күренә ки, М. Иванов хезмәтендә татар телендәге сан төркемчәләре тулы күрсәтелсә дә, аларның семантик ягы әле ачыкланып җитми.

Шулай ук татар телендә язылган беренче грамматикаларда да әле саннарны төркемләү мәсьәләсендә бердәм караш юк. Мәсәлән,

Г. Фәезханов сан исемнәрен башта асыл сан һәм тәртипле сан төркемнәренә аера. Асыл санны үз эчендә тагын ике төркемчәгә бүлә: а) билгеле асыл сан *(бер, ике. өч...)* һәм б) билгесез сан *(аз, күп, бераз, берничә...)*.

Г. Фәезханов схемасы буенча билгеле асыл сан нигезеннән тагын өч төркемчә ясала: 1) арттыру саны *(мең дә өч йөз дүртенче ел),* 2) бүлү саны *(өчәр, дүртәр),* 3) йыйу (җыю) саны *(берәү, икәү, өчәү...)*.

Шулай итеп, Г. Фәезханов грамматикасында *аз, күп...* тибындагы сүзләр (рәвешләр) дә, һәм төп санның сүз ясалыш кушымчалары алган формалары да саннарның аерым төркемнәре итеп карала.

К. Насыйри «Әнмүзәҗ» дигән хезмәтендә саннарны түбәндәге алты төркемгә бүлә: 1) гадәти исме гадәд, 2) исме гадәд микъдари *(өчәү, бишәү),* 3) исме гадәд тәртиби *(өченче, бишенче),* 4) исме гадәд тәкъсими *(өчәр, бишәр),* 5) исме гадәд зати *(өчлек, бишлек...),* 6) исме гадәд васфи *(өчле, бишле...)*.

Күренә ки, К. Насыйри төп сан нигезеннән ясалган исемнәрне дә *(өчлек, бишлек),* сыйфатларны да *(өчле, бишле)* аерым сан төркемчәләре итеп карый.

Шулай ук, хезмәттә автор *-ау/-әү* кушымчалы саннарны да аерым төркемчә итеп түгел, бәлки төп санның практик максатларда (ягъни предметларны санаганда ялгышмас өчен) кулланыла торган бер төре итеп аңлата.

XX йөз башларында язылган грамматикаларда (Г. Нугайбәк, Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди) татар теленең грамматик төзелешен өйрәнү шактый уңай якка үстерелә. Аерым мәсьәләләр буенча кайбер иске (традицион) карашлар сакланса да, татар теле фактлары киңрәк анализлана һәм нигезле аңлату таба.

Г. Нугайбәк үзенең хезмәтендә саннарны, аларның морфологик-семантик билгеләренә нигезләнеп, дүрт төркемгә бүлә; 1) санау аты *(бер, ике...),* 2) җыю аты *(берәү, икәү),* 3) тарату аты *(берәр, икешәр...),* 4) тезү аты *(беренче, икенче...)*. Бу схемада фәкать чама саны *(берләп, икеләп...)* формасы гына исәпкә алынмаган.

Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди хезмәтләрендә исә саннар өчен үзенчәлекле булган формаль билгеләр (*-ау/-әү, -нчы/-нче, -ар/-әр/-шар/-шәр, -лап/-ләп* кушымчалары) барысы да искә алына. Ләкин бу хезмәтләрдә дә *-ау/-әү* күрсәткече алган сан аерым төркем итеп танылмый, бәлки

(К. Насыйридагыча) төп (микъдар) санның бер төре итеп карала. Шулай итеп бу авторларда да саннарның дүрт төркеме генә күрсәтелә: 1) төп сан *(бер, ике...),* 2) дәрәҗә саны *(беренче, икенче...),* 3) бүлем саны *(берәр, икешәр...),* 4) чама саны *(икеләп, өчләп...).*

Г. Алпаров хезмәтендә саннар шулай ук аерым сүз төркеме итеп таныла. Ләкин автор санның үзенчәлекле морфологик билгесе итеп фәкать *-нчы/-нче* кушымчасын гына исәпли. Икенче бер урында *-ар/-әр/-шар/-шәр* күрсәткечләре белән беррәттән, *-нчы/-нче* кушымчасын да сыйфатларның сүз ясалыш системасына кертә.

Татар әдәби теленең морфологиясен өйрәнүгә багышланган соңгы хезмәтләрдә телдә объектив яши торган фактлар киңрәк исәпкә алына, сүз төркемнәре мәсьәләсе фәнни яктан тирәнрәк анализлана. Шулай ук терминнар мәсьәләсе дә аныклана һәм бердәм системага салына. Бу үсешкә, һичшиксез, гомумтел белеме һәм төрки телләр өлкәсендә ирешелгән уңышлар уңай йогынты ясады. Аерым төрки телләрнең грамматик төзелешен фәнни өйрәнүдә бигрәк тә проф. Н. Дмитриевның роле зур булды. Аның «Грамматика башкирского языка» (М.-Л., 1948) хезмәтендә саннарга, аларның семантик-морфологик билгеләренә тирән фәнни анализ ясала һәм ул алдагы фәнни өйрәнүләр өчен үрнәк булып торды.

В. Хангилдинның «Татар теле грамматикасы» (Казан, 1954) китабында саннарның, аларны мөстәкыйль сүз төркеме итеп карарга мөмкинлек бирә торган, берничә билгесе күрсәтелә: 1) мәгънәсе (предметның данә исәбен белдерү), 2) синтаксик билгесе (саналмышын берлек төрендә үзенә ияртү), 3) үзенә хас төркемчә ясагыч күрсәткечләре *(-нчы/-нче, -ар/-әр/-шар/-шәр, -лап/-ләп).*

Соңгы елларда язылган хезмәтләрдә саннарга, сүз төркеме буларак, тагын да киңрәк характеристика бирелә. Санның сүз составы һәм сүз ясалышындагы үзенчәлекләренә тирәнрәк анализ ясала. Сан өчен генә үзенчәлекле булган ачыклагыч (нумератив) сүзләр турында да мәгълүмат тулырак бирелә.

### 3.2. САН СҮЗ ТӨРКЕМЕНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ БИЛГЕЛӘРЕ

Сан, сүз төркеме буларак, микъдар төшенчәсен, предметларның сан, данә исәбен белдерә.

Телдә фәкать саннарга гына ялгана торган морфологик күрсәткечләр бар. Алар – *-нчы/-нче, -ау/-әү, -ар/-әр, -шар/-шәр, -лап/-ләп*

кушымчалары, шулар ярдәмендә сан сүз төркеме үз эчендә аерым төркемчәләргә формалаша:

1) микъдар саны яки төп сан: *ике, өч, алты, ун...*

2) тәртип саны: *икенче, өченче, алтынчы, унынчы...*

3) җыю саны: *икәү, өчәү, алтау, унау...*

4) бүлем саны: *икешәр, өчәр, алтышар, унар...*

5) чама саны: *икеләп, өчләп, алтылап, унлап...*

Сан, предметның микъдар, исәп билгесе буларак, исем белән аергыч һәм аерылмыш (саналмыш) мөнәсәбәтендә бәйләнә.

Саналмыш исем, кагыйдә буларак, фәкать берлек санда гына әйтелә. Мәсәлән: *бер китап, ике китап, ун китап* h.б. Сан ачыклап килгән исемнәргә *-лар/-ләр* күплек кушымчалары өстәү татар теле өчен хас түгел.

Санның кайбер семантик-морфологик төркемчәләре фигыльләрне дә ачыклап килә. *-ау/-әү* кушымчасы алган сан, нигездә, фигыль белән бәйләнә. Мәсәлән: *бишәү булды, унау бардык* h.б. Сөйләү телендә (микъдар) төп сан да фигыльне ачыкларга мөмкин. Мәсәлән: *бер әйттем, ике әйттем.* Ләкин татар әдәби телендә мондый бәйләнеш ешрак санау берәмлеген аңлата торган махсус (нумеративлар) ачыклагыч сүзләргә карый: *тапкыр, мәртәбә, кат, кабат...* ярдәмендә башкарыла. Мисал: *Җиде кат үлчә, бер кат кис* (мәкаль). *Өч мәртәбә килде.*

Санның башка сүзләргә бәйләнмәгән, мөстәкыйль кулланылышы ике очракта була;

а) абстракт төшенчәне белдергәндә: *ике икең дүрт була. Ике сигезең – уналты, тагы сигез, тагы алты – ничә була?* (санамыш). *Алты җирдә ун алтмыш була;*

ә) исемләшеп килгәндә. Бу очракта саннар, исемнәр кебек үк, килеш, тартым категорияләре белән төрләнә. Мисал: *Юк шул, бишегезне биш урынга җибәрергә туры килә.* (Г. Әпсәләмов). Ләкин санның тартым белән төрләнүендә дә кайбер үзенчәлекләре бар.

Санның, аерым сүз төркеме буларак, сүз составы, сүз ясалышы ягыннан да үзенә генә хас үзенчәлекләре бар. Сан исемнәре фәкать үз нигезләреннән генә ясала. Башка сүз төркемнәре алар өчен сүз ясалу базасы була алмый. Мәгънәләре белән саннарга якын *аз, күп, игез, берничә* сүзләре дә бу рольне башкармый.

Санның төп сүзлек фонды зур түгел. Алынма *миллион, миллиард* (аннан да зуррак) сүзләрен кертеп санамаганда, ул барлыгы 20 сүздән тора. Алар түбәндәгеләр:

1) берлек саннар: *бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз;*

2) унлылар (түгәрәк уннар): *ун, егерме, утыз, кырык, илле, алтмыш, җитмеш, сиксән, туксан;*

3) *йөз, мең* сүзләре.

Шул сүзләр нигезендә санның кушма һәм тезмә формалары ясала.

Борынгы татар әдәби телендә «10 мең» мәгънәсендә *төмән* сүзе дә кулланылган. Мәсәлән: *бернең бәласе – меңгә, меңнең бәласе – төмәнгә* (әйтем). Әмма хәзерге телдә бу сүз конкрет сан төшенчәсен белдерә торган лексик берәмлек буларак кулланылыштан төшкән.

### 3.3. САН ТӨРКЕМЧӘЛӘРЕ

Микъдар саны – махсус кушымчалары булмаган, микъдар төшенчәсен, предметның санын, исәбен белдерә һәм *ничә?* соравына җавап бирә торган төркемчә. Ул саннарның башка төркемчәләре ясалуда төп нигез булып тора*: биш – бишенче, бишәү, бишәр, бишләп.*

Татар телендә микъдар санының ике төрле кулланылышы бар:

1) микъдар (сан, исәп) төшенчәсен, предметның билгесен белдерә. Бу очракта саннар аерылмыш сүзнең (исемнең) аергычы булып киләләр һәм бернинди дә төрләнеш кушымчалары алмыйлар. Мәсәлән: *алты кеше, унбиш бала, утыз көн, йөз ел* һ.б.;

2) абстракт микъдар төшенчәсен белдерә. Бу очракта микъдар саны мөстәкыйль кулланыла, җөмләдә башка сүзләргә бәйләнмәгән була һәм, исемнәр кебек үк, килеш, тартым белән төрләнә: *биш бишең – егерме биш. Алтыны бишкә тапкырла. ... дүрт ай бар шул... Дүрт ай, ә... ике утызың алтмыш, алтмыш та алтмыш – йөз егерме...* (Ф. Бурнаш).

Сүз ясалышы ягыннан микъдар (төп) саннары өч төркемгә – гади (тамыр), кушма һәм тезмә саннарга аерыла:

а) **Гади саннар:** *бер, ике, өч, дүрт, биш, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, утыз, кырык, илле, йөз, мең.*

Шулай ук түгәрәк дистәләрне белдерә торган *егерме, алтмыш, җитмеш, сиксән, туксан* сүзләре дә хәзерге телдә гади атамалар итеп карала. Ләкин тарихи яктан аларның кушма сүзләр булуы ачык, ягъ-

ни алар составында беренче дистәгә кергән (ике, алты, җиде, сигез, тугыз) сүзләр һәм *-ме, -мыш/ -меш; -ан/-ән* морфологик элементлар ачык беленә. Сиксән, туксан сүзләрендәге *-ан/-ән* күрсәткече хәзерге телдәге ун сүзеннән үзгәргән булуы бәхәссез.

Әдәбиятта шулай ук *-мыш/-меш, -ме (алтмыш, җитмеш, егерме)* күрсәткечләрен дә дистә атамасы итеп караган фикерләр бар.

Искәрмә. *-мыш/-меш* кушымчаларын «ун» мәгънәсендә куллану татар телендә дә очрый. Мәсәлән, халык авыз иҗаты әсәрләрендә: *бермеш* ‘ун’, *икемеш* ‘егерме’, *өчмеш* ‘утыз’, *дүртмеш* ‘кырык’, *бишмеш* ‘илле’, *алтымыш* ‘алтмыш’, *җидемеш* ‘җитмеш’, *сиксән, туксан, йөз* [Бурнаш Ф., I, б. 57; Исәнбәт Н., б. 112].

Бу санамышта (бармак санаш) тел тарихы өчен әһәмиятле булган икенче бер фактка да әһәмият итәргә кирәк: *-мыш/-меш* кушымчалары *алты, җиде* тамырларына гына ялгана.

ә) **Кушма саннар** *биш йөз, биш мең, тугыз йөз, тугыз мең* кебек түгәрәк йөзлек һәм меңлек атамаларын эченә ала. Сүз ясалыш схемасында кечерәк саннар алда, *йөз, мең* сүзләре алардан соң әйтелә: *10000–90000 (ун мең – туксан мең), 100 000–900 000 (йөз мең – тугыз йөз мең).*

*10000–90000, 100 000–900 000* саннары һәм алар арасындагы түгәрәк дистәне, йөзлекләрне белдергән кушма сан атамалары да шушы ук схемада ясала: *ун мең, алтмыш мең, туксан мең, йөз мең, алты йөз мең, тугыз йөз мең* һ.б.

Орфографик яктан алар аерым сүз итеп язылалар, ләкин семантик яктан бер төшенчәне белдерергә береккән булалар.

б) **Тезмә (катнаш) саннар** түгәрәк дистәләр, йөзлек, меңлекләр (һәм тагын да зур) арасында ясала торган сүзләрне эченә ала. Тезмә саннарның сүз ясалыш схемасы өчен югарыдан түбәнгә, ягъни зур саннар алда һәм аларга кечерәк берәмлекләр ялгана бару үзенчәлекле. Мисаллар: *уналты*[1]*, илле биш, ике йөз илле, ике мең дүрт йөз егерме*.

Тезмә сан атамаларындагы аерым компонентлар арасында бәйләгеч сүзләр (морфологик элементлар) килми. Мәсәлән: *илле биш, бер йөз илле биш, бер мең бер йөз илле биш* һ.б.

Ләкин сөйләү телендә кагыйдәдән беркадәр чыгарма булу да күзәтелә: *йөз* һәм *мең* сүзләренә ялганган сан исемнәре арасында еш кына *дә* теркәгече әйтелә: *йөз дә биш, мең дә биш йөз* һ.б.

[1] Орфографик норма буенча 11 дән 19 га кадар сан исемнәре кушылып языла.

Бу үзенчәлек әдәби әсәрләрдә дә чагылыш таба. Мисаллар: *Ул алдынгыларның алдынгысын йөз дә унике кешене сайлап алды* (А. Алиш). *Урылганы ике йөз дә җиде, эскертләгәне илле тугыз* (Г. Бәширов).

Язма истәлекләргә караганда, *-да/-дә* теркәгечен куллану татар теленә борынгы чорлардан ук үзенчәлекле була. Мәсәлән, XVI–XVII гасыр ташъязмаларында: *...Тарих тукуз йүз дә кырык алтыда...* (Г. Йосыпов). *Тарих мең дә йөз дә йетидә ирде...* (Г. Йосыпов).

Татар телендә 20 дән 90 га кадәр түгәрәк дистәләрнең (*егерме, утыз, кырык, илле, алтмыш, җитмеш, сиксән, туксан* сүзләренең) *ун* һәм *дистә* (рус. *десяток*) сүзләре белән ясалган синонимнары да кулланыла. Мисаллар: *Кызның яше унҗидедә, кияү яше җиде унда* (Н. Исәнбәт). *Ильясның шул вакыттагы милке 7 баш бия, 2 сыер һәм ике дистә куйдан гыйбарәт иде. Җәй буена җыйган кавырсынnarым бар. Өч дистәдән арттылар инде* (Г. Ибраһимов).

Кайбер микъдар саннары, үзләренең төп мәгънәләреннән (абстракт сан төшенчәсен, предметның микъдар билгесен белдерүдән) тыш, башка мәгънәләрдә дә кулланылалар. Бу яктан бигрәк тә *бер* сүзенең семантикасы һәм функциясе киң.

Тотрыклы сүз тезмәләре, тәгъбирләрдә әйтелә торган биш, җиде, кырык саннары да, үзләренең төп мәгънәләреннән тыш, билгесез күпчелекне белдерәләр: *биш былтыр, бишектәге бишкә төрләнә* (мәкаль), *җиде ят, кырык ата баласы* һ.б.

**Өлеш саннары** (вакланма саннар) шулай ук микъдар саннары төркеменә карыйлар. Алар үзара чыгыш килеше формасы белән бәйләнгән ике микъдар саны тезмәсеннән торалар. Чыгыш килеш күрсәткече алган сан беренче урында, баш килештәгесе аннан соң әйтелә: *өчтән ике (2/3), уннан биш (5/10), йөздән бер (1/100)* һ.б.

Семантик яктан чыгыш килеш формасы алган сан бер бөтеннең ничәгә (тигез өлешләргә) бүленүн, ә баш килештәге сан шул тигез өлешләрнең ничәсе алынганлыгын аңлата. *Биш бөтен уннан ике (5 2/10), ике бөтен дүрттән өч (2 3/4)* һ.б. тибындагы катнаш өлеш саннар да шул ук төркемчәгә карый.

Ләкин, аермалы буларак, алдан килгән сан соңгы өлеш саннарга *бөтен* сүзе ярдәмендә бәйләнә.

Татар телендә микъдарның өлешләрен белдерү өчен *ярым* сүзе дә кулланыла: *ике ярым, биш ярым, мең ярым* һ.б.

Сан исеме янында ачыклагыч булганда, *ярым* сүзе алардан соң әйтелә: *ике ел ярым, ун чакырым ярым, биш пот ярым* һ.б.

*Икедән бер (1/2), дүрттән бер (1/4), сигездән бер (1/8)* өлеш саннарының кайчандыр халык телендә актив йөргән синонимнары да бар: *ярты, чирек, әчмуха* (рус. осьмух, осьмушка), алар авырлык һәм озынлык үлчәү берәмлекләре буларак кулланылганнар. Мәсәлән: *чирек кадак май, әчмуха чәй, ярты чакрым юл* һ.б.

Вакыт санау берәмлекләрен (сәгать, минут) белдерә торган сүзләр дә шулай ук өлеш саннарына карый. Ләкин татар телендә вакытны сәгать, минутларда белдерүнең үзенә хас кайбер үзенчәлеге дә бар: *-нчы/-нче* (тәртип саны) күрсәткече алган сан башта әйтелә, аңа өлеш саны өстәлә: Мисаллар: *(сәгать) икенче унбиш минут, алтынчы ярты* яки *алтынчы утыз минут* һ.б.

Тәртип саны микъдар саны нигезенә *-нчы/-нче/-ынчы/-енче* аффиксы кушылып ясала һәм *ничәнче?* соравына җавап бирә: *икенче кеше, унынчы көн* һ.б.

Кушма һәм тезмә формалы микъдар саннарыннан ясалганда, тәртип саны күрсәткече *-нчы/-нче/-ынчы/-енче* соңгы компонентка гына ялгана: *егерме бишенче, ике мең биш йөз илленче.*

*-нчы/-нче* кушымчасы фәкать саннарга гына ялгана. Ул башка сүз төркемнәре өчен хас түгел. *Уртанчы* сүзе генә бу кагыйдәдән чыгарма булып тора: *уртанчы кыз, уртанчы малай, уртанчы бала.*

Семантик яктан *-нчы/-нче* кушымчалы сан табигый санау тәртибендә урнашкан предметларның эзлеклелеген күрсәтә, һәм бу эзлеклелек предметларның төп билгесе булып аңлашыла. Мисаллар: *Дүртенчесен узып китәсең, ә бишенче йорт әбиләрнеке* (А. Алиш). *Беренче сентябрь иде, беренче лекциягә соңга калмас өчен, мин ашыга-ашыга университетка киләм, ...йөгерә-йөгерә икенче катка менәм* (Г. Кутуй).

Тәртип саны, нигездә, предметны ачыклый, җөмләдә аергыч ролен үти: *Беренче көнне үк шәһәрнең икенче читеннән отставкадагы полковник улы белән килене дә аны күрергә килеп җиттеләр* (Ә. Еники).

Сөйләү телендә тәртип санының эш-хәлне, процессны ачыклаган очраклары да күзәтелә: *Минем бирегә өченче килүем инде.*

Тәртип саны да исемләшкәндә (ягъни саналмыштан башка әйтелгәндә) тартым һәм килешләр белән төрләнә: *Ул кулындагы сумканы, нишләтергә белмичә, әле б е р кулына, әле и к е н ч е с е н ә күчерде* (Г. Бәширов). *Ө ч - д ү р т бүре, б е р с е соңра кача б е р с е, Ө ч е н ч е с е, аннан соңра д ү р т е н ч е с е* (Г. Тукай). *Пароход ө ч е н ч е н е кычкыртты да кузгалып китеп тә барды* (И. Гази).

Җыю саны микъдар саны нигезенә *-ау/-әү* кушымчасы кушылып ясала һәм *ничәү?* соравына җавап бирә: *икәү, бишәү, унау* һ.б.

Татар телендә *-ау/-әү* кушымчалары, норма буларак, беренче дистә (1 дән алып 10 га кадәр) саннарга гына ялгана. Уннан соңгы саннарда җыю төшенчәсе микъдар саны формасы белән белдерелә. Мәсәлән: *у н а у идек, инде хәзер у н б и ш булдык.*

Җыю саннарының төп мәгънәсе микъдар төшенчәсен җыеп, җыелма итеп күрсәтүдән гыйбарәт. Мисаллар:

*Җ и д ә ү барып а л т а у кайттык, беребезне калдырдык* (Җиде кыз бәете). *Мин ике кызым белән килдем: Разия, Мәрьям – ө ч ә ү килдек* (Ф. Әмирхан). *Бу өйдә без апам, җизни, мин – ө ч ә ү генә идек* (М. Гафури). *Менә инде хәзер у н а у булдык. – диде солдат, – безнең артельгә артыгы кирәкмәс тә инде* (Ш. Камал).

*-ау/-әү* кушымчасы алган сан микъдар саны мәгънәсендә дә кулланыла. Бу бигрәк тә предметларны абстракт санаганда яки арифметик гамәлләр белән эш иткәндә күзәтелә. Мисаллар: *...б е р ә ү, и к ә ү, ө ч ә ү, д ү р т ә ү, б и ш ә ү... тәрәзәләрнең очына чыга алмассың* (А. Алиш); *унбиштән сигезне алсаң җ и д ә ү кала.*

Беренче грамматикаларда (К. Насыйри, Җ. Вәлиди, Г. Ибраһимов) *-ау/-әү* кушымчалы саннарны, күрәсең, шушы үзенчәлегенә карап микъдар саны төркемчәсенә керткәннәр.

Татар телендә *-ау/-әү* күрсәткече булган саннарга өстәмә *-лап/-ләп, -лашып/-ләшеп* кушымчалары да ялганырга мөмкин. Бу очракта алар да җыю, туплану, бергәлек мәгънәсен көчәйтә. Мисаллар: *Бу читәнне дә, кайчандыр, алар и к ә ү л ә п үргәннәр иде* (И. Гази). *Мохтар, Фәйзи, Гыйльмулла ө ч ә ү л ә п театрга барырга чыктылар* (Ш. Камал). *Кичләрен без и к ә ү л ә ш е п җырлыйбыз* (Г. Кутуй). *Әнә алар д ү р т ә ү л ә ш е п әкрен генә ярга менеп баралар* (Ә. Еники).

Татар телендә җыю саны мәгънәсендә башка формалар да килә. Бу мәгънәдә бигрәк тә тартым категориясенең күплек кушымчаларын

алган микъдар саннары еш кулланыла. Мисаллар: *Барыгыз, бишегез дә хәзер үк юлга чыгып китегез* (А. Алиш). *Ун кеше эшен дүртебезгә башкарырга туры килде* (К. Тинчурин). *Нәрсәгәдер синең белән икебезне Губкомга чакырганнар* (Ш. Камал).

Халык авыз иҗаты әсәрләренә, шулай ук язма чыганакларга караганда, татар телендә *-м/-н* кушымчалы сан төркемчәсе дә булган. Телдә сакланган фактлар бу кушымчаның *-ам/-әм; -ан/-ән; -ым/-ем; -ум/-үм; -ны/-не* вариантлары һәм катлаулы семантикасы булуын билгеләргә мөмкинлек бирә:

а) Болгар чоры ташъязмаларында бу кушымча тәртип саны мәгънәсен белдерә: *...рәҗәп айхы оным көн эти* (Ф. Хәкимҗанов, текст 3), *...җерме үчүм җыл ...* (текст 8);

ә) биш таш уенында (балалар фольклоры) бу аффикс тәртип – җыю төшенчәсен белдерә: *икәм* – ике ташны бергә алу, *өчәм* – өч ташны бергә алу, *дүртәм* – дүрт ташны бергә алу;

б) *бишәм* (бер өемгә куелган биш көлтә), *бишәмләү* (биш көлтәне бер өемгә салу) сүзләрендә бу кушымча җыю мәгънәсен белдерә;

в) санамышларда *-м/-н* кушымчасы абстракт санауны белдерә: *Берән, икән, өчән, дүртән, бишән, алтан кайры балтаң* (Н. Исәнбәт).

г) *-ң* кушымчалы сан кабатлап әйтелгәндә җыю-бүлү (бүленү) төсмерләрен белдерә: *Җөмләгез бер капудан кермиясез, Ике-икең һәр капудан керең имди* (Кыйса-и Йосыф, XIII й.)

*Түтәрәм* (< *түтәр* < *түрт+әм* – бер бөтенне дүрт өлешкә бүлү) сүзендәге *-әм* кушымчасында да шул ук бүлем, бүлү мәгънәсе саклана.

**Бүлем саны** микъдар саны нигезенә *-ар/-әр/-шар/-шәр/-ышар/-ешәр* кушымчасы ялганып ясала һәм *ничәшәр?* соравына җавап бирә: *дүрт+әр, биш+әр, җиде+шәр, сиксән+ешәр, туксан+ ышар* һ.б.

Мисаллардан күренә ки, кушымчаның *-ар/-әр* варианты – тартыклардан соң, *-шар/-шәр* варианты – сузыклардан соң ялгана, *-ышар/-ешәр* варианты исә *сиксәнешәр, туксанышар* сүзләрендә генә әйтелә.

Кушма саннарда бүлем саны күрсәткече соңгы компонентка гына ялгана: *кырык бишәр, йөз илле бишәр, йөз туксанышар* һ.б.

Түгәрәк йөзлек һәм меңлекләрне белдергән саннарда бу кушымча беренче компонентка ялгана: *өчәр йөз, җидешәр мең, туксанышар мең* һ.б.

Семантик яктан бүлем саны предметларның бертигез төркемнәргә бүленүен белдерә. Мисаллар: *Әби кулына и к е ш ә р алма тоткач та өстәлдә б и ш алма калды* (А. Алиш). *Быел безнең һәркайсыбызга кимендә ө ч й ө з у т ы з а р хезмәт көне эшләргә туры киләчәк* (Г. Бәширов). *Кара урман... Б и ш ә р гасыр үскән великаннар, барсы калын, барсы мәһабәт* (Ш. Мөдәрис).

Бүлем саны предметны ачыклый, күбесенчә исемнәргә иярә һәм җөмләдә аергыч ролен үти. Татар телендә *-әр/-ар, -шәр/-шар* кушымчалы сан фигыльләргә дә ияреpгә мөмкин. Бу очракта бүлем саны белән фигыль арасында *кат, мәртәбә, тапкыр* кебек арадаш (ачыклагыч) сүзләр әйтелә: *Аңа бер эшне и к е ш ә р, ө ч ә р к а т эшләргә туры килә* (К. Тинчурин).

Сөйләү телендә *-ар/-шар* кушымчалы сан фигыльгә турыдан-туры да ияреpгә мөмкин: *Чәйне без ө ч ә р эчәбез. Ферма малларына су ташыйм: көненә б и ш ә р барам.*

*-әр/-ар, -шәр/-шар* кушымчалы саннар парлы (кабатланган) формада да кулланыла. Татар телендә мондый формадагы бүлем саннары ике төрле типта ясала:

а) бер үк санның кабатлануы: *икешәр-икешәр, бишәр-бишәр, унар-унар* һ.б.;

ә) янәшә торган сүзләрдән яки төрле зурлыктагы саннарны белдергән сүзләрне тезү юлы белән*: өчәр-дүртәр, алтышар-җидешәр, бишәр-унар* һ.б.

Бу ике тип форма (тезмә) арасында мәгънә аерымлыгы да бар. Әгәр *икешәр-икешәр* тибында бер үк сан кабатланса, предметларның тигез төркемнәргә бүленүе, ә *икешәр-өчәр, бишәр-унар* кебек тезмәләрдә (кушмаларда) якынчалык, төркемнәргә бүленгән предметларның тигез булмаулары белдерелә. Мисаллар: *Доктор тышкы ягыннан б и ш ә р й ө з л е к акча белән төргән кәгазьләрне и к е ш ә р - и к е ш ә р ике кулына тотып ... Сираҗетдин артына килә* (Г. Камал*). Барысының да күкрәгендә б и ш ә р - а л т ы ш а р йолдыз* (Ә. Исхаки).

Барлык форма бүлем саннарына өстәмә *-лап/-ләп* кушымчасы да ялганырга мөмкин: *икешәрләп, өчәрләп-дуртәрләп, бишәрләп-унарлап.* Бу очракта бүлем саны семантикасына рәвешлек төшенчәсе өстәлә. *Шахтага төшә торган эшчеләр д ү р т ә р л ә п - б и ш ә р л ә п клеткада шахтага төшәләр* (Ш. Камал).

Чама саны предметларның санын якынча, чама белән белдерә һәм *ничәләп?* соравына җавап бирә. Татар телендә чама саннары ясалуның берничә юлы бар:

1) *-лап/-ләп* кушымчасы ярдәмендә: *Бишләп китап калган. Унлап кеше* һ.б.

Ачыклагыч (нумератив) сүз булганда *-лап/-ләп* кушымчасы гадәттә аңа ялгана: *Барачак җирем алты чакырымлап булыр* (Г. Ибраһимов). *Унбиш еллап вакыт үткән бу хәлләргә* (Г. Әпсәләмов). *Алтмыш-җитмеш чүмәләләп булыр* (М. Фәйзи).

2) *Ике-өч, биш-ун* тибында ике микъдар санын тезү юлы белән: *Өч-дүрт бүре утырганнар каршы утка* (Г. Тукай). *Юлда аларга тагын алты-җиде малай иярде* (Г. Гобәй). *Картның унсигез-унтугыз яшьлек бик матур, мөләем бер кызы бар икән* (К. Тинчурин).

Бу тип чама саннарына *-лап/-ләп* кушымчасы да өстәлергә мөмкин. Гадәттә ул санның икенче компонентына гына ялгана: *Аларның биш-алты баш сыерлары, илле-алтмышлап сарыклары бар* (М. Гали). *Артыкбикә белән бергә алты-җиде башкорт кызы һәм биш-алтылап мәктәп малайлары килгән иде* (М. Әмир).

3) *-лар/-ләр/-нар/-нәр* күплек кушымчасы ярдәмендә: *Сәгать уннарда алар Ослан перевозына килеп җиттеләр* (М. Гали). *Мифтах бабай яше алтмышларга җиткән, сакалы ап-ак бер карт* (М. Гафури). *Сәгать икеләр булгандыр. Йосыф ... сискәнеп уянды* (К. Нәҗми).

Ачыклагыч (нумератив) сүз булганда *-лар/-ләр* кушымчасы аңа ялгана: *Халиктан ул ун яшьләр кече* (Ш. Камал). *Казанга җитәргә утыз чакрымнар калды* (сөйл.).

4) *-ларча/-ләрчә* катлаулы кушымча ярдәмендә *ун, йөз, мең, ун мең, йөз мең, миллион* һәм *дистә* сүзләреннән билгесез күплек төшенчәсен аңлата торган чама саннары ясала: *Йөзләрчә язучылар, ун меңнәрчә эшчеләр безне каршыладылар* (Һ. Такташ). *Аның кара күзләре ...уннарча хатын кызлар арасыннан Миңнурыйны эзләде* (Г. Әпсәләмов). *Казанга көн саен йөзләрчә кешеләр килә, йөзләрчә кешеләр китә тора* (Г. Әпсәләмов).

5) *-лаган/-ләгән* кушымчасы ярдәмендә шул ук *ун, йөз, мең, ун мең, йөз мең, миллион* һәм *дистә* сүзләреннән билгесез күплек мәгънәсен аңлата торган чама саннары ясала: *Унлаган мәктүпләремә*

*каршы бер җавабыңны кызганмассың дип өмет итәм* (Г. Ибраһимов). *Бу вакытта университет каршына йөзләгән халык җыелган иде* (Г. Әпсәләмов). *Дистәләгән күзләр биюче егетнең җитез йөргән аякларына текәлделәр* (М. Гафури). *Һәр көн юлдан дистәләгән юлчы уза, тузан туза* (М. Җәлил).

Татар телендә предметларның санын якынча, чама белән белдерү өчен аерым лексик берәмлекләр дә кулланыла. Шулар арасында *бер* сүзе үзенчәлекле. Ул үзе бәйләнгән санның алдында килеп, аның мәгънәсенә якынчалык төсмерен өсти: *Мин бер егерме ел эшләдем тракторда* (сөйл.). *Бер илле кеше килер туйга* (сөйл.).

*Чамасы, тирәсе, якын, ары, артык, ким* һ.б.ш. ярдәмлек сүзләр шулай ук предметны ачыклый торган сан семантикасына чама, якынчалык төсмерен өстиләр: *Гаскәрләрнең саны ике йөз кеше чамасы* (К. Тинчурин). *Ул Хөсәен яшьләрендә, егерме биш-егерме алтылар тирәсендә генә күренә* (А. Расих). *Сәйфулла карт ... Яше җитмешләр тирәсендә бер кеше иде* (Ш. Камал).

**Саннарның морфологик категорияләре.** Сан исемнәре, предметларның микъдар билгесен белдерүче буларак, җөмләдә аергыч ролен үтиләр, һәм бу очракта алар тартым, килеш категорияләре белән төрләнмиләр, үзләре ачыклап килгән сүзгә янәшәлек юлы белән бәйләнәләр: *өч кеше, өченче кеше, өчләп кеше, өчәр кеше.*

Җыю саны формасы гына бу кагыйдәгә буйсынмый, ягъни татар телендә *өчәү кеше, бишәү бала, унау китап* һ.б.ш. типта аергычлы-аерылмышлы сүз тезмәсе ясау әдәби норма түгел.

Җыю саннары җөмләдә, кагыйдә буларак, хәбәр төркемендә киләләр һәм фигыльне ачыклыйлар: *Дүртәү сөйләшеп торалар* (сөйл.). *Менә инде хәзер унау булдык, – диде солдат, – безнең артельгә артыгы кирәкмәс тә инде* (Ш. Камал).

Искәрмә. Сөйләү телендә, бигрәк тә реликтив сөйләшләрдә, җыю санын исемне ачыклаучы (аергыч) ролендә куллану да күзәтелә: *өчәү оланнарым бар* (глз.). *Икәү кызы бар, берәү малае бар* (перм.). *Сигезәү сеңелләрем минем* (т.я.-тарх.).

### 3.4. САННАРНЫҢ ИСЕМЛӘШҮЕ

Саннар башка сүзләргә бәйләнмичә, мөстәкыйль кулланганда, исемнәр шикелле үк, морфологик категория (тартым, килеш, хәбәрлек)

күрсәткечләре белән төрләнәләр һәм төрле җөмлә кисәге ролен башкара алалар. Ләкин исемләшкән саннарның морфологик категорияләр белән төрләнүендә исемнәрдән аерым булган кайбер үзенчәлекләре дә бар.

**Тартым категориясе.** Саннарның барлык төркемчәләре өчен дә тартым белән төрләнү үзенчәлекле түгел. Тартымның тулы схемасы нигездә тәртип саннарында гына табыла. Мәсәлән, *өченче* сүзенең генә парадигмасын карыйк:

берлектә: *өченчем, өченчең, өченчесе;*

күплектә: *өченчебез, өченчегез, өченчеләре.*

Мисаллар: *Өч-дүрт бүре, берсе соңра кача б е р с е, ө ч е н ч е с е, аннан соңра д ү р т е н ч е с е* (Г. Тукай). *Алар и к е с е дә бер яшьтәләр* (Ш. Камал). *Балаларым икәү, берсе сигезенчедә, и к е н ч е м алтынчыда* (сөйл.).

Микъдар һәм җыю саннары тартымның нигездә күплек формасын гына ала:

безнең *өчебез, өчәвебез*

сезнең *өчегез, өчәвегез*

аларның *өчесе, өчәве (өчәвесе).*

Бу төркемчә саннарны тартымның I һәм II зат берлек күрсәткечләре белән төрләндерү әдәби тел өчен норма түгел. Кайбер әдәби әсәрләрдә күзәтелә торган фактлар сөйләшү теленең яки җирле сөйләш үзенчәлекләренең чагылышы булса кирәк. Мисаллар: *– Ходай сакласын! – диде Газизә, – Б е р е ң дә үлмәсен, илдә аналарыгыз зарыгып көтә торгандыр...* (Ш. Камал). *Өч оланым бар, б е р е м җидене бетерде быел* (лмбр.). *Ө ч е ң дәме бер авылныкы?* (тмн.).

Сөйләү телендә тартым күрсәткечләре алган микъдар һәм җыю саннары синоним буларак, ягъни бер үк мәгънәдә кулланылалар, икенче төрле әйткәндә, һәр ике санда да предметларны җыю, төркемләү төшенчәләре белдерелә: *Менә хәзер и к е б е з дә картайдык, чәчләребез агарды* (Ш. Камал). *Кызлар и к ә в е с е дә, сүзләрен әйтә алмыйча, күзләргә керештеләр* (М. Гали). *Бу арада инде чыгып киткән кешеләр дә акрын-акрын урыннарына кайтып утыра башладылар: әүвәл Суфия залга кайтты. Аның артыннан егетләрдән дә и к ә в е с е кайттылар* (Ф. Әмирхан).

Сөйләү телендә чама саннарының да кайберләренә тартым күрсәткечләре ялганырга мөмкин: *Бер ө ч л ә б е генә калды, унау иде*

*шундый кашыкларым* (сөйл.). *Өмә көнне бер бишләбегез мастерскойда эшләр, калганнарыгыз фермага барыр* (сөйл.). *Майның унбишләре* (сөйл.).

Бүлем саннарына тартымның фәкать III зат күрсәткече генә ялганырга мөмкин. Мәсәлән: *өчәре бергә, өчәре-өчәре* һ.б.

Шулай итеп, санның барлык төркемчәләре дә тартым белән бер төсле төрләнә алмый. Микъдар саннарында исә тартымның күплек кушымчалары тартым (иялек) нисбәтен белдерми, бәлки җыю санының синонимы буларак кулланыла.

**Килеш категориясе.** Саннарның килеш белән төрләнүләрендә дә характерлы үзенчәлекләр бар. Килеш кушымчаларының тулы системасын нигездә микъдар һәм тәртип саннары гына ала.

1. Микъдар саннарын төрләндерүгә мисаллар: *Бу икенең фәкать үзләре генә белә торган ниндидер серле, яшерен дөньялары бар кебек* (Г. Бәширов). *Миңа инде алтмышны бирүчеләр бар* (Г. Фәйзи). *Уникегә борып куйдым Куен сәгатьләремне* (хал. җыры). *Алар бөтен авылда да уннан артмыйлар* (Ф. Бурнаш). *Уналтыда, унҗидедә Кызның матур чаклары* (хал. җыры).

2. Тәртип саннарын төрләндерүгә мисаллар: *Шулай итеп бер авылдан икенчегә, өченчегә, бишенчегә, унынчыга рәттән китә бара* (Ш. Камал). *Икенче көнне ниндидер илаһи бер көч мине сәгать бишенчедән ук паркка барырга кыстый башлады* (Ф. Әмирхан). *Тукта икенчене бирәм кашыкны* (сөйл.). *Берсе сигезенчедә, икенчесе алтынчыда, өченче кыз дүртенчедә укый* (сөйл.).

Җыю санының тартым күрсәткечле формалары гына килешләр белән төрләнә. Мисаллар: *Юкса я сез, я мин – икәвебезнең берсе хәзер үк моннан китәргә тиеш* (Г. Тукай). *Мин сезнең киявегез Хәлил кебекләрнең унавын бер бармакта биетәмен, беләсезме?* (М. Фәйзи). *Газизә ... аларның бишәвесенә дә күз төшереп үтте* (Ш. Камал).

Әдәби телдә тартым күрсәткече алмаган җыю санын килеш белән төрләндерү сирәк күренеш, нигездә, ул кыек килеш формаларында гына әйтелә: *икәүдән икәү. Икәүдән өчәү, өчәүдән – дүртәү булырсыз әле, боерган булса* (Ә. Еники).

Сөйләү телендә сирәк кенә булса да *өчләбе, бишләбе...* тибындагы чама саннарына да килеш кушымчалары ялгана ала. Мәсәлән: *Бер*

*тавыгым урлап басты, сигезләп чеби чыгарды, бишләбе йөреп тора* (сөйл.). *Ун чеби чыгарган иде, бер бишләбен генә үстерә.*

Исемләшкән бүлем саннары да, нигездә, төшем, юнәлеш һәм чыгыш килешләре формаларында гына күзәтелә: *Өчәрне ал; өчәргә бүл; берәрдән генә түгел, күбесенчә икешәр, өчәрдән эләгә* (Ш. Камал). *Арышны саттым кырыгардан* (сөйл.). *Йөзәрне-йөз утызарны алып эшлиләр фермада* (сөйл.).

**Хәбәрлек категориясе.** Хәзергә татар телендә хәбәр функциясендә гадәттә җыю, тәртип һәм микъдар саннары кулланыла. Бу функциядә аларга хәбәрлек кушымчалары ялганмый. Мисаллар: *Әткәй, әнкәй, мин, апай, әби, бабай һәм бер песи, Безнең өйдә без җидәү, безнең песи – җиденчесе* (Г. Тукай). *Кызның анасы – кырык, кырык беренчесе – чыбык* (мәкаль). *Без биш бала, мин – бишенчесе*(сөйл.).

Сан белән белдерелгән хәбәргә өченче зат хәбәрлек *-дыр/-дер* кушымчасы да ялганырга мөмкин. Бу үзенчәлек бигрәк тә халык авыз иҗаты әсәрләрендә һәм кайбер урыннарда сөйләү теленең үзенчәлеге буларак сакланып килә: *Ундыр җаный бармагы, уникедер балдагы* (хал. җыры). К*азларым уникедер, калдырдым өчне ыруга, тукызны суйдым* (тмн.).

Сан белән белдерелгән хәбәргә *-дыр/-дер* кушымчасы ялгану борынгы татар әдәби әсәрләрендә күзәтелә: *Ушбу «Төхфә» тарихын гәр сорсайлар, Тукыз йөз кырык алтыдыр белсәйләр* (М. Мөхәммәдьяр).

**Сан категориясе** сан сүз төркеме өчен үзенчәлекле түгел. *-лар/-ләр/-нар/-нәр* күплек күрсәткече кайбер сан төркемчәләренә генә (микъдар һәм тәртип саннарына гына) ялганырга мөмкин. Ләкин бу очракта ул бернинди дә күплек мәгънәсен белдерми, бәлки үзе ялганган сүзгә төрле семантик төсмерләр өсти:

1) еш кына чама (якынчалык) төсмерен белдерә: *ун чакрымнар, айның егермеләре, сәгать уникеләр* һ.б.;

2) гомумиләштерү төсмере булган яңа сүзләр (исемнәр) ясала: *берәүләр, икенчеләр.* Мәсәлән: *Берәүләр шагыйрьне тиргәргә тотындылар, икенчеләр, киресенчә, ... сүзне уенга борырга тырыштылар* (Ә. Еники).

Сөйләшү телендә *-лар/-ләр...* кушымчасы җыю саны нигезенә дә ялгана һәм бу очракта ул:

а) берләшү, җыелу төшенчәсен көчәйтә: *Өчәүләрмени үзегез?*

ә) ия белән хәбәр арасында бәйләгеч ролен үти: *Балалар минеке икәүләр.*

**3.5. НУМЕРАТИВ СҮЗЛӘР (САН АЧЫКЛАГЫЧЛАРЫ)**

Аергыч ролендә килгән саннарга махсус ачыклагыч сүзләр иярә. Алар гадәттә аергыч белән аерылмыш (сан белән исем) арасында әйтеләләр. Бу сүзләр саналмыш предметның сыйфаты белән ярашкан булалар һәм, нәтиҗәдә, алар телдә аерым категория сүзләргә генә хас булган нумератив билге булып урнашканнар (Н. Дмитриев). Күзәтүләргә караганда, татар телендә мондый ачыклагыч сүзләрнең фонды шактый зур. Иң еш очрый торганнарын күрсәтеп үтик.

*Баш.* Терлек малын, кайбер үсемлек – яшелчәләрне санаганда әйтелә: *биш баш ат, ике баш сарык, ун баш умарта, ике баш кәбестә, өч баш суган.*

*Оя.* Кошларны гомумиләштереп санаганда кулланыла: *Ике оя каз. Бер оя үрдәк.*

*Төп.* Җиләк-җимеш агачлары: *ике төп алмагач, биш төп карлыган.*

Яшелчәләргә карата *түтәл, бураэна* ачыклагыч сүзләре кулланыла: *бер түтәл кишер, ике түтәл шалкан, ун буразна бәрәңге.*

*Кием, куш, пар* (< рус. *пара*) сүзләре ике бертөрле предметны берләштерә: *ике кием итек, өч куш себерке бәйләдем, ике пар башмак* һ.б.

*Тиен, тәңкә, сум* сүзләре акча санауда кулланыла: *биш сум, бер тиен, ун тиен* яки *биш тәңкә.*

*Яшьлек, яшәр, еллык* сүзләре яшьне белдергәндә кулланыла: *алты яшьлек баласыннан алтмыш яшәр картларынача сабан туе дәрте белән җилкенә* (Г. Ибраһимов).

Әдәби телдә *яшьлек* һәм *еллык* сүзләре арасында стилистик аерма бар: *яшьлек* гадәттә җанлы предметларны ачыклый*: ике яшьлек бала, кырык яшьлек кеше, өч яшьлек тай* һ.б.

*Еллык* сүзе исә җансыз предметларны ачыклый: *биш еллык алмагач, йөз еллык имән, ун еллык тәҗрибә* һ.б.

Татар телендә озынлык, авырлык, җир үлчәмен һ.б.ны белдерә торган бер төркем ачыклагыч сүзләр бар. Аларның кайберләре инде искергән, архаизмга әйләнгәннәр яки диалектларда гына сакланганнар. Тарихи күзлектән караганда аларның кулланылыш сферасын һәм

семантикасын ачыклауның әһәмияте зур. Чөнки алар арасында борынгы чорларда ук барлыкка килгән лексик берәмлекләр дә әле сакланып килә:

а) озынлык үлчәүдә: *метр, аршын* (=0,711 м.), *сөям* (1/4 аршын), *карыш* (1/4 аршын); *адым, сажин* (3 аршын), *таяк* (3 аршын); *чакрым; колач, кара* (бер метрга якын), *каре* (терсәк алып бармак очларына кадәр булган озынлык);

ә) авырлык үлчәүдә: *грамм, кило, центнер, тонна* сүзләре белән беррәттән, *кадак* (400 гр.), *гөрәңкә, герамәңкә* (< рус. *гривенка*), *пот* (< рус.), *подаука* (< рус.), *почык//бычык* (ике пот һәм 2 пот сыешлы савыт);

б) күләм берәмлеге буларак: *бер чеметем тоз, бер кабым ипи, бер йотым су; ике телем ипи; бер уч тоз, ике кушуч он; өч тотам сүс; бер саплам җеп; ике басма җеп; бер киләп җеп;*

в) сыек әйберләрне үлчәүдә, *литр, ярты литр, чирек литр* сүзләре белән беррәттән, *аяк, чынаяк, дустаган/тустаган, кашык* сүзләре сан ачыклагычы булып кулланылганнар;

г) җир үлчәү берәмлеге буларак, хәзерге телдә рус теленнән алынган *гектар, сутый* сүзләре кулланыла. Элек *дисәтинә* (< рус. *десятина,* 1,09 га).

Татар телендә тагын аерым төркем нумератив сүзләр бар: *кабат, кат, тапкыр, мәртәбә, тона, тынап* (диал.), *сира* (диал.). Алар санны фигыльгә бәйләү өчен кулланылалар, ягъни эш-процессның санын ачыклыйлар: *ике кабат килде, җиде кат үлчә, бер кат кис* (әйтем). *Казанда быел ике тона булдым. Мәскәүгә быел дүрт сира бардым* һ.б.

Санга ияреп әйтелә торган ачыклагыч сүзләр морфологик категорияләр белән төрләнми, шулай ук күплек күрсәткечен дә алмый. Әдәби телдә, мәсәлән, *биш башлар сарык, ун тиеннәр акча, өч киемнәр итек* һ.б. дип сөйләү һич тә дөрес түгел.

Саналмыш исем төшерелгәндә нумератив сүзләр морфологик категорияләр белән дә төрләнә: *ун чакрым юл. Ун чакрымны үттек. Ун кадак май. Ун кадакка тулмас.*

*Сәгать, ай, ел, атна, көн, минут, чакрым* ачыклагыч сүзләре *-лап/-ләп* һәм *-лар/-ләр* күрсәткечле чама саннарына ияргәндә, бу кушымчалар нумератив сүзләргә ялгана: *ун чакрымлап юл. Ике сәгатьләп (сәгатьләр) көттем.*

# 4. ФИГЫЛЬ

## 4.1. ФИГЫЛЬНЕҢ ЛЕКСИК-ГРАММАТИК МӘГЪНӘСЕ

**Фигыльнең лексик мәгънәсе.** Фигыльнең сүз буларак мәгънәсен өйрәнү ике яклап әһәмиятле. Беренчедән, грамматик категорияләр никадәр генә абстракт һәм сүзнең конкрет лексик мәгънәсенә бәйсез булмасыннар, җентекләбрәк өйрәнгәндә, аларның гомумиләшкән лексик мәгънәгә бөтенләй үк битараф түгеллеге ачыла. Лексик мәгънәгә бәйле рәвештә кайбер сүзләр грамматик мәгънәгә дә яңа төсмерләр өсти, аны үзгәртә алалар, кайбер грамматик категорияләрне алар бөтенләй кабул итми яки аларның төрләнеше чикләнгән була. Мәсәлән, исемдә I төр изафә – исемнәр белән белдерелгән аергыч һәм аерылмышның үзара бернинди кушымчасыз, янәшә торып бәйләнешкә керүе – беренче исем «материал» мәгънәсен белдергәндә генә мөмкин: *мех тун, пыяла ишек, салам эшләпә, агач йорт.* II төр изафәдә исем белән белдерелгән предметлар арасында иялек мөнәсәбәте яки икенчесенең беренчесенә караганлыгы белдерелә: *мәктәп бакчасы, шәһәр урамы, тау итәге, агач яфрагы.* Әмма сүзнең лексик мәгънәсенә карап, беренче сүз (аергыч) икенче сүз (аерылмыш) белән белдерелгән предметны хәрәкәт иттерүче корал мәгънәсен дә белдерә ала: *аяк машинасы, кул пычкысы, җил тегермәне.*

Телдәге лексик һәм грамматик мәгънәләрнең үзара тәэсир итешүләре тел күренешләрен функциональ-семантик ысул белән өйрәнгәндә ачык күренә, чөнки бу вакытта бер мәгънә белдерүдә катнаша торган барлык тел чаралары – лексик, грамматик, интонацион һәм башка чаралар – бер ноктага туплап тикшерелә. Күп вакытта теге яки бу форманың грамматик мәгънәсен контекст билгели. Контекст төшенчәсе исә сүзнең лексик мәгънәсен дә үз эченә ала.

Әйтелгәннәрдән чыгып, алга таба фигыльнең төрле нигездә гомумиләштерелгән лексик мәгънә төркемчәләре каралачак.

Икенчедән, фигыль үзенең семантик табигате белән предметны һәм предметлыкны белдергән исемнәрдән бик нык аерыла, чөнки ул чынбарлыктагы предметларның (объектларның) үзләрен түгел, бәлки алар арасындагы мөнәсәбәтләрне белдерә. *Университет мәктәп өчен укытучылар әзерли* җөмләсендә *әзерли* фигыле *университет* сүзе белән субъект, *укытучылар* һәм *мәктәп өчен* сүзләре белән объект мөнәсәбәтендә тора (кем, кемне, кем өчен әзерли). Фигыльнең мәгънәсе дә шул сүзләр белән бәйләнештә генә ачыла.

Ләкин теге яки бу фигыль кулланылган контекстлар һәм ул белдергән мөнәсәбәтләр гаять күптөрле була, шуңа күрә фигыльнең мәгънәсе дә исемнекеннән үтә киң булуы белән аерылып тора. Фигыль мәгънәсенең гаҗәеп киң булуына, бик күпне сыйдыра алу дәрәҗәсенә галимнәр күптән игътибар иткәннәр.

Фигыльнең объектлар арасындагы төрле мөнәсәбәтләрне үз эченә алган мәгънәсе аның телдәге күптөрле кулланышыннан, контекстлардан чыгып билгеләнә. «Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә *әзерләү* фигыленең мәгънәсе һәм мәгънә төсмерләренә түбәндәге аңлатма бирелә (кыскартып алына): 1. Нәрсәне дә булса файдалануга яраклы хәлгә китерү: *кайберләре салам җыештыра, кайберләре сәнәкләр, көрәкләр әзерли.* 2. Кемне дә булса... укыту, аңа кирәкле белем бирү: *укытучылар әзерләү.* 3. Нәрсәне булса да үтәү, тормышка ашыру өстендә эшләү: *опера репертуарын әзерләү.* 4. Ашау әйберләре, азык турында: пешерү, кыздыру һ.б.: *иртәнге аш әзерләү.* 5. Нәрсәне булса да күпләп алып кую: *утын әзерләү, бәйрәмгә бүләкләр әзерләү* һ.б. Күрсәтелгән мисалларда фигыльнең эш башкаручы субъекты (кем?), туры объекты (кемне? нәрсәне?) һәм кыек объекты (кемгә? нәрсәгә?) бар. Китерелгәннәрдән *әзерләү* фигыленең күптөрле мәгънә төсмерләренә ия булуы, төрле объектлар белән килгәндә эш процессларының шактый төрле икәнлеге күренә. Шулай да *әзерләү* фигыленең барлык очракларда сиземләнә торган уртак мәгънәсе бар: нәрсәне дә булса файдалануга яраклы хәлгә китерү.

Күп мәгънәле *алу* фигыленең кайбер мәгънәләре «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә (ТТАС) бирелгәнчә күрсәтелә.

*Алу* 1) кул белән тоту: *паспортларны алды;* 2) ияртү: *ал мине үзең белән;* 3) башкару өчен эш, йомыш алу: *тема, ризалык, рөхсәт алу;* 4) кире кайтару: *бирелгән документларны алу;* 5) бүләкләнү: *дан,*

*грамота, исем алу;* 6) акча түләп сатып алу: *күлмәк алу, билет алу;* 7) берәр нәрсә өчен түләтү: *штраф, салым алу;* 8) каплау, биләү: *бөтен битен ут алды;* 9) йомыш белән эшне бүлү: *вакытыгызны гына алдык;* 10) эштән чыгару: *эштән алганнар;* 11) эшкә алу: *Дүшәмбе көн үк аның урынына кеше алганнар;* 12) өйләнү: *кыз алу;* 13) кисү, кыскарту, киметү, тарайту: *Пальтоның уң ягыннан бераз алырга кирәк;* 14) һәлак итү, бозу: *карабодайны кырау алды;* 15) берәр оешмага кертү, кабул итү: *консерваториягә алу, армиягә алу;* 16) тоткын итү: *кулга алу* һ.б.

Китерелгәннәрдән күренгәнчә: *алу* фигыле кемне? нәрсәне? кемнән? нәрсәдән? кемгә? нәрсәгә? сорауларына җавап бирә торган объектлар белән бәйләнешкә керә. Күпчелек очракта *алу* фигыле кемгә? нәрсәгә? сорауларын таләп итми, чөнки *алу* процессы һәрвакыт субъектның «үзенә алу»ын белдерә, ягъни эш башкаручыга юнәлгән була: *алам, аласың, ала: паспорт алу, ризалык алу, документларны* (кире) *алу, тәрбия алу, билет алу, салым алу* һ.б.

*Ал мине үзең белән* (башкаручы – II зат) яки – *Аны консерваториягә алдылар* (башкаручы III зат). Мисалларның һәркайсында, процесслар шактый аерылсалар да, төп мәгънә бер үк: кемнедер үзеңә (*үзең белән*) һәм үзләренә (*консерваториягә*) алу, кабул итү турында әйтелә. Фигыль белдергән мәгънәләр арасында капма-каршылары да бар (энантиосемия күренеше): *алу* – эшкә кабул итү һәм *эштән алу* – эштән чыгару һ.б.

Исем белән фигыльдә референция мәсьәләсенә тукталыйк. Референция – исемнәрнең чынбарлыктагы объектларга караганлыгы, дип билгеләнә. Чыннан да бөтен галәм, дөнья, табигать, безнең мохит төрле җисем, җанлы һәм җансыз предмет, ягъни объектлардан тора, һәм алар телдә исем белән белдерелә: *ай, күк, җир, агач, яфрак, шәһәр, өй, юл, йорт, койма, кеше, бала* һ.б. Бу объектлар – исемнең чынбарлыктагы референтлары (вәкилләре). Ләкин чынбарлыктагы объектлар хәрәкәтсез яшәмиләр, һәм аларның хәрәкәтен, эш-гамәлен, ягъни үзара мөнәсәбәткә керүләрен телдә фигыль белдерә.

*Кояш б а т а да кич була,*
*Күңелем шатлык белән т у л а ,*
*Нурлар у й н ы й тирә-ягымда...* (Г. Насрый).

Димәк, исемне чынбарлык белән үзе белдергән объектлар тоташтырса, фигыльнең **референтлары** – араларындагы мөнәсәбәтләрен белдергән объектлар була.

**Фигыльнең лексик-грамматик үзенчәлекләре.** Югарыда фигыльнең лексик мәгънәсе объектлар арасындагы мөнәсәбәтләрне белдерүдән гыйбарәт булуы күрсәтелде. Мөнәсәбәткә кергән бу объектлар телдә төрле сүзләр, төрле җөмлә кисәкләре белән белдерелә. Фигыльнең әнә шул сүзләр белән синтаксик бәйләнешкә керә алу сәләте аның **валентлыгы** дип атала, фигыль белән бәйләнешкә кергән сүзләр аның **актантлары** була. Алар процессның субъектын, туры һәм кыек объектын һәм **субстантив** сүзләр белән белдерелгән төрле хәлләрен: урынын, вакытын, максатын, коралын һ.б.ны белдерәләр.

1. Ничә актант алу мөмкинлегенә карап, фигыльләр – валентлыгы булмаган, ягъни нуль валентлы / нуль актантлы, бер валентлы / бер актантлы, ике, өч, дүрт актантлы фигыльләргә бүленәләр.

**Нуль актантлы фигыльләр:** б*уранлый, яктыра, караңгыланды, суыта* һ.б.

**Бер актантлы фигыльләр:** *йөрәгем* (нәрсә?) *с ы з л ы й , кояш б а й ы й , бала й о к л а д ы , кар я у г а н , мине* (кемне?) *т у ң д ы р а , кулы а в ы р т а , ул а в ы р ы й , башы ә й л ә н ә* һ.б.

**Ике актантлы фигыльләр:** *ул* (кем?) *сине* (кемне?) *я р а т а ; ана кеше* (кем?) *баласы өчен* (кем өчен?) *б о р ч ы л а ; язучы* (кем?) *әсәрен* (нәрсәсен?) *т ә м а м л а д ы ; кибеткә* (кая?) *яңа товар* (нәрсә?) *к а й т к а н* ; *китапка* (нәрсәгә?) *бәяләр* (нәрсә?) *к ү т ә р е л д е* һ.б.

**Өч актантлы фигыльләр:** *Сез балага матур исем к у ш к а н с ы з* (кем? кемгә? нәрсә?). *Ул кулын сабын белән ю д ы* (кем? нәрсәне? нәрсә белән?). *Без утынны электр пычкысы белән к и с т е к* (кем? нәрсәне? нәрсә белән?).

Кайбер фигыльләр бер очракта бер актантлы, икенче очракта күп актантлы була: *Ул матур җырлый* (бер актантлы фигыль: җырлау аның сыйфаты, сәләте итеп бирелгән), ләкин *Ул концертта Рөстәм Яхин романсларын җырлады* җөмләсендә *җырлады* фигыле – өч актантлы (кем? кайда? нәрсә?).

Актантларның теге яки бу фигыль өчен мәҗбүри һәм факультатив (ирекле) булулары мөмкин. Мәсәлән, *Кичә җыелышта укытучылар балаларга яңа дәреслекләр бирделәр* җөмләсендә фигыльнең биш

актанты бар, шуларның өчесе – субъектны (кем?), объектларны (кемгә? нәрсә?) белдерүче актантлар – мәҗбүри, әмма вакытны (кайчан?) һәм урынны (кайда?) белдерә торган актантлар *бирү* фигыле өчен мәҗбүри түгел. Әмма нәкъ урын һәм вакыт мәгънәләре актуаль була икән, актантлар фигыль алдыннан куела. Ләкин кайбер фигыльләрнең мәгънәсе үк урынны һәм вакытны белдерүче актантлар таләп итә, һәм алар мәҗбүри була. Бу, күбрәк, яшәеш, хәл-торышны белдерүче фигыльләргә карый: *Без ун ел Казанда яшибез* җөмләсендә фигыльнең өч актанты да мәҗбүри.

Фигыльнең валентлыгын, актантлар санын юнәлеш кушымчалары үзгәртә ала.

2. Фигыльнең актантларга бәйле тагын бер лексик-грамматик үзенчәлеге бар: алар туры тәмамлык таләп итү-итмәүләренә карап, күчемле һәм күчемсезләргә бүленәләр. Күчемле фигыльләрдә процесс объектка күчә, аңа юнәлгән була, күчемсез фигыльләрдә эш-хәл субъект белән генә чикләнә, һәм бу күренеш тә фигыльнең лексик мәгънәсе белән бәйле. Эшне, гамәлне белдерүче фигыльләр күчемле була: *эшләү, төзү, үрү, казу, бәйләү, сүтү, салу, алу, бирү, кую, кору, очлау, киртәләү, озату, уку, сату, каршылау, юу, тезү* һ.б.

Хәрәкәт фигыльләре, физик һәм психик халәтне, эмоциональ кичерешне, билгенең үсешен һ.б.ш. мәгънә белдерүче фигыльләр күчемсез була: *бару, йөрү, китү, кайту, төшү, авыру, хәлсезләнү, күбү, сүнү, куану, гаҗәпләнү, курку, оялу, эч пошу, кот очу, юану, сөенү* һ.б.

Фигыльгә юнәлеш кушымчалары ялгау аның күчемлелеген яки күчемсезлеген үзгәртә ала.

3. Фигыльнең төрле категорияләргә тәэсир итә торган тагын бер гомумиләшкән лексик мәгънәсе бар: алар **чикле** һәм **чиксез** була. Бу күренеш фигыльләрдә эш ысулы, эшнең үтәлү дәрәҗәсн (способы действия) мәсьәләсен өйрәнү уңае белән Ф. Ганиев тарафыннан тикшерелгән иде (1963).

Чикле-чиксез фигыльләргә тел белемендә төрлечә билгеләмә бирелә. Алар һәммәсе дә дөрес, ләкин берсе берсен тутыра, төгәллек өсти. Ф. Ганиев **чикле** фигыльләр дип, үзләренең семантикасында чиккә ишарә итүче яки аңа омтылучы фигыльләрне атый: *чыгарга, җитәргә, табарга, капларга, үләргә, батарга, төшәргә, җимерелергә.* **Чиксез** фигыльләрнең мәгънәсендә чиккә ишарә итү юк: *йөрергә,*

*сайрарга, уйланырга, эзләргә, түзәргә, ялынырга, яратырга, уйларга, сөенергә.* Өченче төркем фигыльләр, контекстка карап, я **чикле**, я **чиксез** була алалар: *утырырга, торырга, ятарга, сайларга.* Ф. Ганиев бу күренешнең лексик категория икәнен ассызыклап үтә [Ганиев Ф., 1963, с. 95–98).

Фигыльләр өчен уртак бу күренешнең башка телләрдә өйрәнелүе нигезендә билгеләмәне киңәйтергә мөмкин: чиккә омтылучы фигыльләрдә эш чиккә җитү белән туктала, һәм башкаручы яңа халәткә күчә. Мәсәлән, *китап идәнгә т ө ш т е* (һәм идәндә ята); *без өченче катка м е н д е к* (һәм өченче катта басып торабыз яки йөрибез) – чикле фигыльләр. Нәкъ шуның өчен бу фигыльләр үз мәгънәләрен эшнең тәмамлануын белдергән заманнарда тулырак ача.

Татар телендә **чикле** фигыльләр исемлеген арттырып була: *туу, керү, алу, биру, калдыру, ишетү, күрү, хәбәр итү, кот очу, бәрү, сугу, төртү, чакыру, раслау, инкяр итү, вәгъдә итү, алдау, эндәшү, тыю, боеру, кушу, салу* һ.б. **Чиксез** фигыльләр исә үзләренең үтәлешендә чиккә омтылмыйлар һәм эш үсә, дәвам итә ала: *яшәү, сөю, хөрмәт итү, йөрү, эшләү, сөйләшү, җырлау, тырышу, уку, карау, тәрбияләү, авыру, борчылу, шатлану, тыңлау* һ.б.

Фигыльнең чикле яки чиксез булуы фигыль категорияләренең мәгънәсендә, кулланылышында чагылыш таба. Мәсәлән, ул тәмамланмаган үткән заман чиксез фигыльләр өчен аеруча кулай: бу фигыльләрдә заманның мәгънәсе тулысынча реальләшә: *тыңлый иде, чайкала иде, хыяллана идек, диңгез дулкынлана иде, бала йоклый иде, уйламый идең, кайгыра идек.* Чикле фигыльләр исә бу заманда эшнең кабатлануын белдерә, һәм бу вакытта заманның мәгънәсе кабатлаулы үткән заман белән кисешә. Мәсәлән, *су к и т е р е п к у я и д е, аны к ү р ә и д е м, ул безгә к и л ә и д е, искә т ө ш е р ә и д е ң, ут к а б ы з а и д е* (кабатланган процесслар белдерелгән).

Чикле фигыль мәгънәсенең реальләшүе өчен катгый үткән заман аерата уңай (мисаллар Р. Төхфәтуллин әсәренең бер битеннән язып алынды): *кунак киләсен ә й т т е, кухня ягына ч ы г ы п к и т т е, казларын к у ы п к е р т т е, Роберт бусагадан ук шаулап к и л е п к е р д е, көчтәнәчләрен ө е п к у й д ы; ...кычкырып җибәрде, алга ыргылды, туктап калды, җиргә чүкте, ачып җибәрде* һ.б. Чиксез фигыльләр исә бу заманда эшнең беркадәр дәвам итүен белдерәләр (мисаллар

Г. Ахунов әсәреннән китерелә): *ашыкмады, кул чаптылар, халык таралa башлады ... Тамашадан алган хисләрен уртаклаштылар, театрга матур киләчәк юрадылар, һәркем, үзе җырлардай булып, ярсынып-дәртләнеп утырды;гөрләтеп кул чаптылар.*

4. Фигыльләрне лексик мәгънәсе ягыннан тагын **динамик** һәм **статик** төрләргә аералар. **Динамик** фигыльләр эшнең үзен яки хәрәкәтне белдерәләр: *эшләү, ясау, язу, уку, юу, туку, төзү, үрү, вату, алу, бирү, бару, кайту, йөрү, килү* һ.б. **Статик** фигыльләр төрле халәтне, мөнәсәбәтне, теге яки бу сыйфатның барлыкка килүен һ.б.ш. мәгънәләрне белдерә: *тору, яту, яшәү, утыру, хыяллану, үсү, туңу, курку; борчылу, матурлану, картаю* һ.б.

Бу бүленеш фигыльләрне **актив** һәм **пассив**ларга бүлү белән кисешә, фигыльләрнең мондый төрләргә бүленеше субъектның активлыгына бәйләнештә карала. Мәсәлән, *сөйләү, тыңлау, карау, эшләү, ясау, хәл итү, булышу, ярдәм итү, чәчү, тарату, җыю, ачу, кую, эзләү, күтәрү* кебек фигыльләр актив; *ишетү, күрү, утыру, тору, яшәү, ял итү, йоклау, кызару, агару, хәл керү, арту* һ.б. пассив фигыльләр.

Актив фигыльләр арасында субъектның активлыгы ягыннан каузатив (эшкә кушу, эшкә сәбәпче булу мәгънәсендә) фигыльләрне аералар. Бу фигыльләргә: *күрү* (пассив) – *күрсәтү* (каузатив), *китү – җибәрү, егылу – егу, борчылу – борчу, чыгу – чыгару, тору – тоту (яшь бозаулар башта мич артында тора – аларны мич артында тотабыз), килү – алып килү, китерү; үлү – үтерү, төшү – төшерү, барлыкка килү – барлыкка китерү*. Каузатив фигыльләр үзләренең парларыннан бер актантлары артык булу белән аерыла: *ул килә – ул аны китерә, ул борчыла – син аны борчыйсың.*

Китерелгән мисалларда каузатив фигыльләрнең күбесе йөкләтү юнәлешендә килгән *(килү – ки(л)терү, күрү – күрсәтү),* яки пассив фигыль кайтым юнәлешендә булып, каузатив фигыль төп юнәлештә тора *(борчылу – борчу),* кайбер каузатив һәм пассив фигыльләр исә аерым лексема белән бирелә: *китү – җибәрү, (чәч) алу – китәрү, китү – алып китү, бару – алып бару* һ.б.

**Мөстәкыйль фигыльләрнең ярдәмче рольдә кулланылуы.** Бер төркем фигыльләр, аерым лексик мәгънә белдереп, мөстәкыйль сүз буларак кулланылулары белән бергә, фигыль һәм аның формалары белән мөнәсәбәткә кереп, ярдәмче фигыль хезмәтен үтиләр.

I. Бер төркем мөстәкыйль фигыльләр грамматик функция үти, ягъни төрле грамматик формалар ясауда катнаша: *бул-, тор-, ал-, кил-.*

***Бул-*** фигыле:

1) тасвирлама (перифрастик) формалар ясый: *алган була, язган булырмын, яза торган булды, әйтер булсаң, бара торган булсагыз* һ.б.;

2) аналитик модаль формалар ясауда катнаша – мөмкинлек: *эшләп була, уйларга булыр; ниятләнү: эшләргә булдым, бармаска булды;*

3) фигыльнең *булган* формасы хикәя фигыльнең билгесез үткән заманнарын ясауда катнаша:

Күптән үткән заман
- билгеле: *эшләгән иде*
- билгесез: *эшләгән булган*

Кабатлаулы үткән заман
- билгеле: *эшли торган иде*
- билгесез: *эшли торган улган*

4) хикәя фигыльнең үткән заманнарына синонимик формалар барлыкка китерә: *күргәнем булмады (күрмәдем), ишеткәне булмаган (ишетмәгән), әйткәнем булды (әйттем)* һ.б. *Бу турыда Халисәнең сораганы булмады* (Р. Төхфәтуллин);

5) кушма фигыль ясауда катнаша.

***Тор-*** фигыле:

1) хәзерге заман сыйфат фигыльнең аналитик формасын ясый: *без укый торган мәктәп, авылга бара торган юл.* Аның нигезендә төрле формалар ясала: кабатлаулы үткән заман: *укый торган идек, ул килә торган иде;* фаразый хәзерге-киләчәк заман: *мин бара торганмындыр, сез эшли торгансыздыр, ул уйлый торгандыр;* шарт фигыль формалары: *әйтми торган булса, эшли торган булсагыз* һ.б.;

2) инфинитив формасы белән килеп, аспектуаль һәм модаль мәгънә – ниятләүне белдерә: *очарга тора, барырга тора, сөйләшергә дип тора идек.*

***Ал-*** фигыле:

татар телендә бу фигыль мөмкинлек һәм мөмкин түгеллекне белдерүче төп чара булып йөри: *килә алам, йоклый алмадык, кайта алмассыз, аңлый алырлар* һ.б.

***Кил-*** фигыле:

1) татар телендә *-асы* формасы + *кил-* фигыленнән ясалган конструкция теләкне белдерүче күп чаралар арасыннан универсальлеге (төрле формалар ясавы, чикләнүсез кулланылуы) белән аерылып тора: *күккә очасы килә, өйгә кайтасы киләчәк, анда барасың килмәс, укыйсыбыз килде* һ.б.;

2) *кил-* фигыле тезмә фигыль ясауда да актив. Бу фигыль ярдәмендә аваз ияртемнәреннән тезмә фигыльләр ясала: *шау-гөр килү, ду килү, пыран-заран килү, чыр-чу килү;*

3) *кил-* фигыле ярдәмендә предикатив һәм комплетив бәйләнеш нигезендә ясалган тезмә фигыльләр күп: *йокы килү, ачу килү, акылга килү, дөньяга килү, ис килү, телгә килү, аңга килү, кулдан килү* һ.б.;

4) максат-ниятне белдерә торган *-макчы/-мәкче* формасының мәгънәсе тасвирый юл белән дә белдерелә ала: *Эшкә өйрәтим диген идем = өйрәтмәкче идем. Ул калага күчәргә йөри = күчмәкче була.*

Искәрмә. Ярдәмче рольдә килгән хәрәкәт фигыльләре субъект-объектның урын ягыннан ориентациясен белдерәләр. Бу төркемгә *кил-, кит-, кер-, чык-, мен-, төш-. бар-, кайт-, җит-, үт-, уз-* кебек фигыльләр керә. Мәсәлән: *кайтып китә, менеп бара, карап чык, куныт китте, кайтып килә иде* һ.б. (Субъект-объект ориентациясе турындагы битне кара).

**Фигыльнең семантик төркемчәләре.** Фигыль лексикасын мәгънәсе буенча төркемләү шактый катлаулы эш, чөнки фигыльнең мәгънәсе үтә гомуми, үтә киң, һәм аның нигезендә объектлар арасындагы мөнәсәбәт ята. Шулай булуга карамастан, фигыльләр сүз буларак өйрәнелергә тиеш, чөнки шунсыз фигыльдәге категорияләрнең мәгънәсен һәм функциясен бөтен тулылыгы һәм тирәнлеге белән аңлап булмый. Бу бүлекчәдә фигыльнең семантик төркемнәре һәм төркемчәләре карала.

Фигыльгә бирелгән билгеләмәдә үк аның эш яки хәлне белдерүенә ишарә ясала. Бу төрләр, чыннан да, фигыль сүз байлыгының нигезен хасил итә.

Тел җәмгыять яшәеше белән тыгыз бәйләнгән. Телдә кеше эшчәнлегенең төрле яклары һәм эш вакытында аның җәмгыять, табигать, әйләнә-тирә белән күп төрле мөнәсәбәтләре чагылыш таба. Кеше, сөйләүче телдәге грамматик категорияләрнең дә үзәгендә тора.

Чагыштырыгыз: зат категориясе эш башкаручының сөйләүчегә мөнәсәбәтен белдерә; наклонениедә эш-хәлнең чынбарлыкка мөнәсәбәте сөйләүче тарафыннан билгеләнә; заман – эш-хәлнең сөйләү моментына (ул да сөйләүчегә бәйле) мөнәсәбәте, дип билгеләнә һ.б.

Күпчелек фигыльләрнең лексик мәгънәсе үзәгендә дә кеше, аның җәмгыятьтәге хезмәте, актив эшчәнлеге тора. Актив эшчәнлекнең башкаручы субъектыннан башка объекты да була. Ул эш процессында я барлыкка килә, я үзгәрә, я юкка чыга.

Эш фигыленең өченче компоненты итеп кайбер галимнәр аның **максатчан** булуын күрсәтәләр [Кильдибекова Т., 1985, 44]. Чыннан да, кешенең бөтен эшчәнлеге нинди дә булса максатка юнәлгән була. Әгәр ул булмаса, эш ихтыярсыз, үзеннән-үзе башкарыла торган процесска әйләнә. Мондый фигыльләрнең күпчелеге исә хәл-торышны белдерә: *бала йоклый, урман шаулый, табигать үзгәрә, син дулкынланасың* һ.б.

Димәк, эш белән хәл-торыш[1] фигыльләренең аермасы шунда: эш фигыльләре белдергән процесслар нәрсәне булса да барлыкка китерә, үзгәртә яки юкка чыгара, шуңа күрә аларның объекты була, һәм эш аңлы рәвештә, ягъни максат белән эшләнә: *(йорт) салу, (икмәк) салу, (мич) чыгару, (иген) игү, (печән) җыю, (утын) кисү, (күлмәк) тегү, (тузан) сөртү, (дәрес) хәзерләү, (тәрәзә) юу, (бала) үстерү* һ.б. Хәл-торыш фигыльләре субъект белән чикләнгән процессларны, субъектка хас халәтне, аның вакыт эчендә агышын белдерәләр: *көн суыта, яфраклар саргая, яңгыр ява, кеше борчыла, без ял итәрбез* һ.б.

Фигыльләрне төркемләүнең күптөрле кыенлыкларыннан берсе – бер үк фигыльнең мәгънә киңлеге аркасында төрле төркем һәм төркемчәгә керә алуы. Мәсәлән, үтә бер конкрет эшне белдергән *карау* фигыле – күз белән карау мәгънәсендә физиологик процессны белдерә: *баласын яхшы к а р ы й* (тәрбияли) дигәндә – эш фигыльләренә; *ул мәсьәләгә уңай к а р ы й* дигәндә – мөнәсәбәт фигыльләренә керә; *тую* (ашап тую) – физиологик процесс фигыле булса, *тую* (күңел кайту) – хис фигыле; *өзү* (бауны өзү) – эш фигыле, (араны) *өзү* – мөнәсәбәт фигыле; *такылдау, пышылдау* – яңгыраш һәм сөйләм фигыльләренә керәләр.

---

[1] «Хәл-торыш фигыльләре» дигән атама «хәл фигыльләре» термины белән буталмасын өчен алынды.

## 4.2. ФИГЫЛЬ ЛЕКСИКАСЫН ӨЙРӘНҮ ҺӘМ ТӨРКЕМЛӘҮ МӘСЬӘЛӘСЕ

Төрки телләрдә фигыльнең мәгънә төркемчәләрен башлап өйрәнүче Н. Дмитриев булды. Ул төрек, татар, башкорт һәм кайбер башка төрки телләрдәге сөйләү, фикерләү, эш һәм хәрәкәт фигыльләренең төп лексик берәмлекләрен тикшереп чыкты. Аның мәкаләләре, күп еллардан соң, шәкертләре тарафыннан тупланып «Строй тюркских языков» китабына кертелде [Дмитриев Н., 1962, с. 570–598].

1967 елда басылып чыккан «Историческое развитие лексики тюркских языков» китабында Ә. Тенишевның «Төрки телләрдә хәрәкәт фигыльләре», Ә. Юлдашевның «Хис белән кабул итүне белдерүче фигыльләр», Н. Гаджиева һәм А. Кокляннованың «Сөйләм фигыльләре» дигән хезмәтләре урын алган. Хәрәкәт фигыльләрен төрек теле материалында В. Вещилова (1962), үзбәк телендә К. Халиков (1967), чуваш телендә Т. Васильева (1980), татар телендә Р. Лизунова (1991) өйрәнделәр; шулай ук кайбер хезмәтләрдә төрки телләрдәге хәрәкәт фигыльләре рус теленеке белән чагыштырып тикшерелде [Лизунова Р., 1991]. Татар телендә фигыльләрне мәгънәләре буенча төркемнәргә аеру мәсьәләсендә беренче тәҗрибә Ф. Ганиев тарафыннан ясалды [Ганиев Ф., 1984, с. 76–78]. Мәкаләдә фигыльләр 11 тематик төркемчәгә аерыла: хәрәкәт, эш, процесс, хәл, мөнәсәбәт, үз-үзеңне тоту, яңгыраш, сөйләм, фикерләү, сиземләү һәм образ ияртемнәренә нигезләнеп ясалган фигыльләр, һәр төркемчәгә мисаллар китерелгән.

Соңгы 15–20 ел эчендә фигыльне өйрәнү рус тел белемендә бик нык үсеш алды. Бу проблема буенча Екатеринбург (Э. Кузнецова) һәм Уфада (Л. Васильев, Т. Килдебәкова, Р. Гайсина) ике үзәк барлыкка килде. Рус һәм татар телендәге фигыльләр мәгънә күләме белән, чынбарлыкның кайбер мөнәсәбәтләрен фигыль белән атау, кайберләрен грамматик форма белән белдерү ягыннан шактый аерылсалар да, рус тел белемендә тупланган тәҗрибәне исәпкә алмыйча мөмкин түгел. Мәсәлән, Л. Васильев фигыльләрне тикшергән һәм төркемләгән вакытта аларның функциональ тәңгәлләрен – фразеологик берәмлекләрне, перифразаларны да исәпкә ала (*втереть очки кому-либо, дать маху, набить оскомину* һ.б.). Аларның һәммәсе дә сүзгә тиң,

дип саный һәм алардан башка анализның тулы булмаячагын искәртә [Васильев Л., 1981, с. 37]. Бездә исә алар читтә кала. Мәсәлән: *кулдан килү, кулга алу, ачу килү, сүзгә килү, аңга килү, карарга килү, истән чыгу, кияүгә чыгу, йокы килү, йокыга киту, ис тию* кебек фигыльләр татарча-русча сүзлекләрдә фигыльгә яки исемгә бирелгән мәкаләдә фразеология рәвешендә карала, русча-татарча сүзлекләрдә кайберсе рус сүзләрен аңлатканда китерелә: *забыть – оныту* һәм *истән чыгару, хәтердән чыгару.* Ләкин аларның күбесе татар телендә бер фигыль белән бирелми, һәм мондый сүзләрнең шактый өлеше сүзлеккә керми кала. Уңай яктан Ф. Ганиев редакциясендә 1984 елда Мәскәүдә басылып чыккан «Русча-татарча сүзлек» аерылып тора.

Фигыльнең сүз буларак мәгънә төзелеше һәм кайбер семантик төркемчәләре өйрәнелгәннән соң, төрле телләр материалы нигезендә эшләнгән классификацияләр каралды. Алар бик күп төрле булып чыкты. Бу төрлелек фигыль төркемчәләренең үзара мөнәсәбәтен билгеләүгә карый. Мәсәлән, Ф. Ганиев 11 төркемчә аерып чыгара: фикерләү фигыльләрен, сөйләм фигыльләрен эш, хәл-торыш, сиземләү һ.б. фигыльләр белән беррәттән карый, Л. Васильев исә фикерләү фигыльләрен, Г. Кулиев сөйләм фигыльләрен – психик эшчәнлекне белдерүчеләр төркеменә кертәләр. Шунысын да әйтергә кирәк: фигыльнең семантик төркемчәләре үзара кисешәләр, һәм галимнәр моңа игътибар да иткәннәр [Классы слов..., 1980].

Классификациягә якын килүдә, аны нигезләү мәсьәләсендә, шулай ук, күптөрле карашлар бар. Фәнни җәмәгатьчелек тарафыннан иң уңай дип Э. Кузнецова тәкъдим иткән «баскычлап тиңләштерү алымы» («метод ступенчатой идентификации») кабул ителә. Фигыль төркемчәләренең татар телендә аз өйрәнелгән булуы төркемләү мәсьәләсен кыенлаштыра, һәм түбәндә китереләчәк классификация бу мәсьәләдә соңгы сүз булуны дәгъва итми.

Тәкъдим ителгән классификациягә куелган максат – фигыльләрне, төп мәгънәләреннән чыгып, ике зур төркемгә – эш-гамәл һәм хәл-торыш фигыльләренә аеру, алар эчендәге төркемчәләрне билгеләү. Өченче төркем итеп кешенең тормышында, бөтен эшчәнлегендә зур урын тоткан мөнәсәбәтләрне белдерүче фигыльләр аерылды. Бу мәсьәләдә Екатеринбург галимнәренең хезмәтләре ярдәм итте [Гак Г., 1979; Ганиев Ф., 1981; Головин Б., 1969].

**Эшчәнлекне белдерә торган фигыльләр (эш фигыльләре)**

**1. Объектларны барлыкка китерү, үзгәртү һәм юк итүне белдерүче фигыльләр:**

а) объектларны барлыкка китерүне белдерәләр: *эшләү, ясау, төзү, салу, эшләп чыгару, туку, уру, төпләү, тегү, үрү, бәйләү, кисү, басу;*

ә) объектларны сыйфат, күләм, сан ягыннан үзгәртүне, файдалануга яраклы хәлгә китерүне белдерәләр: *әзерләү, көчәйтү, тирәнәйтү, эреләндерү, кечерәйтү, тыгызлау, йомшарту, зурайту, киметү, күбәйтү, кыскарту;* аш-су әзерләү: *киптерү, кыздыру, пешерү, тозлау, кайнату, турау, кисү, чабу, парландыру;* җирне эшкәртү: *казу, сукалау, китмәнләү, тырмалау, ашлау, ашлама кертү, тиресләү;* чистарту: *юу, себерү, утау, иләү, кыру, сөртү, ышку;* объектларны нәрсә беләндер каплау*: асфальтлау, бетонлау, алтынлау, майлау, крахмаллау, буяу, сиптерү* һ.б.;

б) объектларны юкка чыгаруны белдерәләр: *бетерү, вату, бозу, юк итү, җимерү, яндыру, сүтү, түгү, ерту, сындыру, туздыру, челпәрәмә китерү* һ.б.

**2. Акыл эшчәнлеген белдерә торган фигыльләр:**

а) фикерләү фигыльләре: *фикерләү, уйлау, төшенү, аңлау, фикерләшү, фикер йөртү, фикер алышу, акылга килү, аңга килү, акылга утыру, акылга сыймау, башка фикер килү, ... фикердә булу һәм акыл китү, ялгыш фикердә булу, акылдан язу, акылсызлану, аңгыралану;*

ә) фикерләү нәтиҗәсен белдерәләр: *гомумиләштерү, йомгаклау, нәтиҗәгә килү, фикергә килү, карарга килү, уйлап табу, бер сүзгә килү, килешү, карар чыгару, ышану, ышандыру, дәлилләү, хәл итү, раслау, ачыклау, мәсьәләне чишү, исбатлау;*

б) гөман итү: *исәпләү, күз алдында тоту, фараз кылу, ... дип санау, бәяләү, бәя бирү, шөбһәләнү, икеләнү, шик тоту, күзаллау, ниятләү;*

в) төрле өлкәләргә караган акыл эшчәнлеге: *кушу, алу, бүлү, тапкырлау, исәпләп чыгару, санау, тасвирлау, язу, уку, күчерү, хата җибәрү, төзәтү, чагыштыру, тәңгәлләштерү, өйрәнү, тикшерү, конспектлау, йомгаклау, кабатлау, шөгыльләнү, имтихан алу, имтихан бирү, үзләштерү, ялгышу* һ.б.

**3. Иҗтимагый эшчәнлекне белдерә торган фигыльләр:** *тырышу, ялкаулану, омтылу, сайлау, агитацияләү, пропагандалау, тавыш бирү, катнашу, берләшү, штраф салу, үтәү, түләү, көрәшү,*

*буйсыну, каршы төшү, үҗәтләнү, комачаулау, ярдәм итү, ярдәмгә килү, булышу, рөхсәт итү, эш кушу, ялгышу, дошманлашу, сугышу, дуслашу, юл кую, юл куймау, кире кагу, килешү, законлаштыру, идарә итү, оештыру, планлаштыру, җайга салу, бүләкләү, орышу, сугу, мактау, бәхәскә керү, чыгыш ясау, нотык сөйләү, хат алышу* һ.б.

**4. Сөйләм эшчәнлеген белдерә торган фигыльләр:**

а) төп фигыльләр: *дию, әйтү, сөйләү;*

ә) сөйләмнең характеры һәм эчтәлегенә бәйле фигыльләр: *хикәяләү, дәшү, эндәшү, бәян итү, ләчтит сату, исбат итү, сүзгә килү, күпертү, мактану, ялганлау, зарлану, шикаять итү, алдау, турыдан бәрү, үгетләү, җикеренү, сайрау, шаярту, теш кайрау, ярып салу, телләнү, юрау, карышу, сүз кату, сөрән салу, сүз уйнату, сүзгә килү, сүз кыстыру, сүзне кыска тоту, сүзне бору* һ.б.;

б) хәбәр итү фигыльләре: *хәбәр итү, җиткерү, тапшыру, игълан итү, йөрәкне бушату, вәгъдә итү, сүз бирү* һ.б.;

в) сөйләшүне, ягъни сөйләм вакытында контактка керүне белдерүче фигыльләр: *сөйләшү, сорашу, сораштыру, сорау бирү, сорау алу, җавап бирү, җавап кайтару, риза булу, ризалашу, кунү, каршы төшү, инкяр итү, раслау, исәпләшү, серләшү, гайбәт сату, вәгъдәләшү, сүз куешу, хәбәрләшү, бәхәсләшү* һ.б.;

г) сөйләү эчтәлегендә боеру (каузация) мәгънәсе булган фигыльләр: *өндәү, боеру, тыю, рөхсәт итү, кушу, үтенү, ялвару, үгетләү, теләнү, рөхсәт итмәү, күндерү, кыстау, ышандыру, тынычландыру, ашыктыру, таләп итү, киңәш итү, коткы салу, әмер бирү, чакыру* һ.б.;

д) бәяләү фигыльләре: *битәрләү, каһәрләү, яманлау, гаепләү, хурлау, тәнкыйть итү, пыран-заран китерү, каргау, ачулану, сугу, мактау, күккә чөю, рәхмәт уку* һ.б.;

е) эмоциональ мөнәсәбәт белдерүчеләр: *рәхмәт әйту, гафу үтенү, тел тидермәү, битәрләү, хурлау, юмалау, юату* һ.б.;

ж) сөйләмнең төрлечә яңгыравына ишарә итүче фигыльләр: *акыру, кычкырып сөйләшү, пышылдау, мыгырдану, мыңгырдау, лыгырдау, лыкылдау, лыбырдау, такылдау, быдыр-быдыр сөйләү* һ.б.

*Дип* фигыле белән килүче фигыльләр: ... *дип гөрләде, ... дип чыелдады, ... дип сузды, ... дип ысылдады* һ.б.;

з) дәшмәүне белдерүче фигыльләр: *дәшмәү, өнсез калу, ләм-мим әйтмәү, эндәшмәү, тел тешләү, тел-теш кузгатмау, тел(еңне) йоту, телдән язу, авызга су кабу, сүз катмау, сүз кушмау* һ.б.

**5**. **Физиологик эшчәнлекне белдерә торган фигыльләр:** *ашау, эчү, кабу, чәйнәү, кимерү, сөю, косу, тамак туйдыру, йоту, очкылык тоту, күзне ачу, күзне йому, һава сулау, иснәү, йөткерү, төчкерү, төкерү* һ.б.

**6. Хәрәкәт фигыльләре:**

а) төп фигыль: *хәрәкәт итү, йөрү* – юнәлешсез хәрәкәт;

ә) горизонталь юнәлешле хәрәкәт: *бару, юнәлү*.

Ноктадан ераклашу: *китү, ерагаю, чыгу, таралу, чәчелү, сибелү*.

Ноктага якынаю: *килү, җитү, керү, якынлашу, кайту, җыелу.*

Ноктадан кирегә китү: *чигенү, китү, ераклашу.*

Нинди дә булса араны яки каршылыкны узу: *үтү, узу, кичү, чыгу;*

б) вертикаль юнәлешле хәрәкәт: *менү, күтәрелү, үрмәләү, үрләү, төшү;*

в) әйләнү хәрәкәте: *әйләнү, бөтерелү;*

г) хәрәкәт ысулын белдерә торган фигыльләр: *атлау, очу, йөзү, мүкәләү, үрмәләү, шуу, тәгәрәү, сикерү;*

д) хәрәкәтне тасвирлап белдерү: *титаклау, чатанлау, аксау,*

е) хәрәкәтнең тизлеге: *чабу, сөйрәлү;*

ж) хәрәкәтне каузацияләү: *ияртү, китерү, җибәрү, куу, сөйрәү, сөйрәп китерү, эту, тибү, ыргыту, ташлау, төшерү, очыру, юнәлтү, чыгару, тарату, кертү, җыю, үткәрү, әйләндерү.*

**7. Яңгыраш фигыльләре:**

а) кеше тавышларын, сөйләү рәвешен белдерүче фигыльләр: *пышылдау, пыш-пыш килү, бытылдау, тәтелдәү, быдыр- быдыр сөйләү, быдырдау, пыштыр-пыштыр килү;* башка тавышларны белдерүчеләр: *кычкыру, акыру, бакыру, черелдәү, уфылдау, ахылдау, ухылдау, елау, пыскылдау, сулкылдау, пышык-пышык елау, еламсырау, мышнау, мышкылдау; көлү, шаркылдап көлү, кеткелдәү, ыңгырашу, сызгыру, иңрәү, чырылдау, пытырдау, дерелдәү, ихахайлану, тыпырдау;*

ә) табигать, кош-корт, хайван тавышын белдерүчеләр: *шаулау, улау, күкрәү, шыбырдау, пыскаклау, ыжгыру, ору, һауһаулау, ырылдау, шыңшу, чинау, үкерү, мыркылдау, бәәлдәү, мияулау, кытаклау, кешнәү, пошкыру, кыткылдау, чыркылдау, чырылдау, бызылдау, безелдәү, пырхылдау, ысылдау, мыраулау, мыжлау, жулау, жуылдау* һ.б.;

б) предмет тавышын белдерүчеләр: *чытырдау, шытырдау, быгырдау, зыңгылдау, тырылдау, кетердәү, дыңгырдау, пырылдау, дырылдау, даңгылдау, гөрселдәү, пытырдау, тукылдау, шакылдау.*

**8. Образ ияртемнәреннән ясалган фигыльләр:** *җемелдәү, җем-җем итү, ялт-йолт килү, ялтырау, ялт итү, елкылдау, елтырау, балку, челт-мелт итү, ялык-йолык килү, мәш килү; жу итү: йөрәгем жу итеп китте; тыр-пыр килү (пыр тузу), лергелдәү* (селкенә торган әйбер турында) һ.б.

**Хәл-торыш фигыльләре.**

**1. Яшәеш фигыльләре:** *туу, барлыкка килү, тору, яшәү, булу, йөрәк тибү, урнашу, утыру, яту, куну, көтү, үлү, һәлак булу, сүнү, дөньядан китү, вафат булу, югалу, эреп бетү, юкка чыгу* һ.б.

**2. Сыйфат ягыннан хәл-торышны, аның барлыкка килүен белдерә торган фигыльләр:** *яшәрү, яшелләнү, дымлану, агару, саргаю, кызару, сыегаю, суыну, җылыну, алсулану, азаю, кимү, авыраю, матурлану, тазару, зәгыйфьләнү, аксау, ялтырау, төтенләү, тырышу, баю, шатлану, арзанаю, батыраю, бозылу, кимү, шешү, күбәю, көчәю* һ.б.

**3. Социаль хәл-торышка караган фигыльләр:** *мактану, көязләнү, тәртип бозу, гауга чыгару, кылану, башбаштаклану, үҗәтләнү, ялагайлану, ялганлау, ялкаулану, яманлау, гайбәт сату, сүз йөртү, шаяру, юмартлану, урлау, караклану, тәртипсезләнү, кабалану, кызу, оятсызлану, акылсызлану, башка китү, исерү, тыйнак булу, кәҗәләнү* һ.б.

**4. Эмоциональ халәтне, хис-кичерешне белдерә торган фигыльләр:** *борчылу, сагыну, курку, кот очу, тузу, кайгыру, оялу, юану, куану, дулкынлану, соклану, үпкәләү, иркәләнү, рәхәтләнү, ләззәтләнү, хозурлану, күңел кырылу, күңел суыну, хурлану, гарьләнү, рәнҗү, әрнү, мәсхәрәләнү, түбәнсенү, ачу килү, шак кату, ямансулау, юксыну, хафалану, хәсрәт чигү, өмет өзү, өметсезләнү, өзгәләнү, ачыну, ачыргалану, сөю, шашу, каушау, зарыгу, имәнү, сизенү, тою, йөрәк яну, йөрәк әрнү, хәтер калу, эч пошу, үзәккә үтү, кәеф бозылу* һ.б.

**5. Физиологик халәтне белдерә торган фигыльләр:** *җәфа чигү, азаплану, йоклау, уяну, карын ачу, ис тию, ару, тынычлану, сусау, теләү, тазару, ябыгу, сәламәтләнү, суык тию, авыру, туңу, туңдыру, өшү, өшетү, калтырану, дерелдәү, эч кату, тын бетү, сулыш кысылу, эсселәү, кычыттыру, кымырҗып тору, чәнчеп китү, чәнчеп алу,*

*чемердәп тору, аяк ою, баш кату, баш чатнау, колак чыңлау, сулкылдау, әрнү, әчетү, әчеттерү, сызлау, чемету, күңел болгану, хәлсезләнү* һ.б.

**Мөнәсәбәт фигыльләре.** Мөнәсәбәт фигыльләре кем яки нәрсә арасында мөнәсәбәт булуын белдерәләр. Мөнәсәбәт ситуациясе кимендә ике зат яки предмет арасында урнаша. Бу төркемгә караган фигыльләр башка төркемнәргә дә күчә ала.

**1. Мөнәсәбәт белдерүче фигыльнең үзәгендә торучы фигыльләр:** *тәңгәл килү, тәңгәлләштерү, мөнәсәбәткә керү, (яхшы) мөгамәләдә булу, килешү, килештерү, (кемгә яки нәрсәгә булса да) уңай яки кире караштa тору, карау (бу мәсьәлә безгә карамый), туры килү, каршы кую, тигезләү, чагыштыру* һ.б.

**2. Затлар арасындагы мөнәсәбәтне белдерүче фигыльләр:** *хөрмәт итү, якын күрү, ярату, яратмау, аяу булу, кызгану, көнләшү, дошманлашу, дуслашу, ялагайлану, үч тоту, якынаю, туганлашу, очрашу, бәрелешү, гаугалашу, җайлашу, күрешү, танышу, буйсыну, буйсындыру, рәхмәт әйтү, алкышлау, тәбрик итү, читләшү, мактау, ике йөзләнү, шикләнү, мыскыллау, масаю* һ.б.

**3. Социаль мөнәсәбәтне белдерүче фигыльләр:** *җиңү, арадашлык итү, ярдәмләшү, рөхсәт итү, ышану, ышандыру, күндерү, бәхәсләшү, конфликтка керү, сатулашу, фикер уртаклашу, мәҗбүр итү, юлдан яздыру, татулаштыру, идарә итү, тәэмин итү, тапшыру, саклау, канәгатьләндерү, кичектерү, гарантияләү, җайлау, кулга алу, гаепләү, яклау* һ.б.

**Татар тел белемендә фигыль сүз төркеменең өйрәнелү тарихы.** Татар телендә фигыльне өйрәнү И. Гигановның «Грамматика татарского языка» (СПб., 1801) исемле китабыннан башлана. Зур күләмле бу хезмәттә хикәя һәм шартлы теләк (сослагательное) наклонениеләрендә фигыль заманына караган 13 пар гади һәм аналитик форма күрсәтелә. Алар арасында китерелгән диалекталь төрләрне (*булыпмын, булып идим, булдым иди* һ.б.ш.) исәпкә алмаганда, анда хәзерге татар телендә кулланыла торган күпчелек заман формалары китерелгән [Гиганов И., 1801, с. 17–85, 90–96]. Асылда хәзерге татар тел белемендә фигыль заманнарына караган тугыз формадан икесе генә теркәлмәгән: *-ачак* һәм *-ачак иде*. Бу И. Гиганов «Грамматика»сының Себердә язылуы белән дә аңлатыла булса кирәк. Хикәя фигыльдән соң ул боеру һәм билгесез («неопределенное») наклонениеләрне

күрсәткән. Хезмәттә шулай ук сыйфат фигыль, хәл фигыльләр һәм 13 төрле тасвирлама форма бирелгән.

И. Хәлфинның «Азбука и грамматика татарского языка» (Казан, 1809) дигән хезмәтендә алты заман формасы китерелә: *-а* кушымчалы хәзерге заман; *-р* кушымчасы белән ясалган һәм бер тапкыр булачак эшне белдерә торган киләчәк заман; *-ды* кушымчасы алып, бер тапкыр үтәлгән эшне белдергән үткән заман; *-а иде* белән ясалган үткән заман; *-ган* кушымчасы белән ясалган күптән үткән I заман: *-ган иде* (китапча *-мыш иде*) күрсәткечле күптән үткән II заман. Җиденчесенә автор *әйләндерермен* формасын китерә, ләкин бу фигыль *-р* кушымчалы киләчәк заманга карый, *-гала* кушымчасы исә аңа кабатлау, ягъни аспектуаль мәгънә өсти. Шул рәвешчә, хәзерге грамматикаларда кабул ителгән заман формаларыннан өч төре: *-а торган иде, -ачак* һәм *-ачак иде* бирелмәгән әле [Хальфин И., 1809, с. 45–57]; киләчәк заманның *-ачак* формасы сыйфат фигыльнең зат кушымчасы белән төрләнүе, дип каралган.

М. Ивановның «Татарская грамматика»сында (Казан, 1842) түбәндәге формалар бар: *-а* кушымчалы билгеле хәзерге заман; *-а торганмын (дыр)* күрсәткечле фаразый хәзерге заман; *-р* кушымчалы киләчәк заман; *-ды, -ган, -ып* кушымчалы бер тапкыр үтәлгән эшләрне белдерә торган үткән заман формалары; *-а иде(-адыр иде*) күрсәткечле тәмамланмаган үткән заман; *-р иде* һәм *-а торган иде* кушымчалы кабатлаулы үткән заманнар; *-ган иде* һәм *-ып иде* кабатлаулы алдан үткән заман («прошедшее преходящее») формалары. Киләчәк заманга *килеп җитсә кирәк* конструкциясе кертелгән. Беренче буларак, М. Иванов *-ганым бар, -ганым* юк формаларын китерә [Иванов М., 1842, с. 139], әмма шул ук формаларның юклык төре И. Гигановта бирелгән иде инде [Гиганов И., 1801, с. 92].

А. Казимбәкнең «Общая грамматика турецко-татарского языка» (Казань, 1846) хезмәтендә татар теленең фигыль формалары төрек һәм азәрбайҗан телләре белән чагыштырыла. Монда, гомумтатар кушымчалары *-р, -р иде, -ды* һ.б. белән беррәттән, диалекталь формалар да китерелә: *-ды иди, -ыб иди, -малы, -гудаймын*; «китапча» төрләре: *-мыш, -мыш иди, -гай*. Бу формаларның барысы да диярлек *(-малы*'дан башкасы) И. Гиганов китергән исемлеккә бик якын тора [Казем-Бек А., 1846, с. 275–285].

М. Мәхмүтевнең «Практическое руководство к изучению татарского языка» (Казан, 1857) исемле хезмәте башкалардан фигыльнең бик күп формалары теркәлүе белән аерылып тора. Кызганычка каршы, аларның һәммәсен грамматикалашкан төрләргә кертеп булмый [Махмудов М., 1857, с. 147–148]. Бу автор татар телендә өч заман формасын аерып күрсәтә: *-а* кушымчалы хәзерге заман; *-ды* белән ясалган үткән заман; *-р* кушымчалы киләчәк заман. Сыйфат фигыль турындагы бүлекчәдә *-учы, -асы, -а торган, -ган* формаларының зат-сан, килеш белән төрләнеше карала һәм *иде, бул* ярдәмче фигыльләре белән *-гам, -ган, -а турган, -учы, -ар, -асы, -ачак* формаларыннан күптөрле катлаулы төрләрнең ясала алуы искәртелә [Махмудов М., 1857, с. 192–207]. Әйтергә кирәк, бу урында заман формалары гына түгел, бәлки темпораль һәм модаль мәгънәгә ия булган тасвирлама формалар да күрсәтелә. Беренче тапкыр *-ганым бар* / *-ганым юк* формалары карала.

А. Троянский биш заман формасын күрсәтә: хәзерге заман – *укыймын,* дәвамлы («преходящее») заман – *укыр идем,* тәмамланган үткән заман – *күрдем,* күптән үткән заман – *укыган идем,* киләчәк заман – *укырмын.* Шул ук вакытта китерелгән таблица һәм мисалларда ул әйткән, *-а турган иде* кебек заман формалары да китерелә. Шулай ук *-р иде* формасының шартлы теләк белдерә алуы күрсәтелә һ.б. [Троянский А., 1860, с. 192–207].

К. Насыйри «Әнмүзәҗ» исемле хезмәтендә өч төрле заман күрсәтә: үткән заман – *яздым, яздык;* хәзерге заман – *язамын, язамыз;* киләчәк заман – *язармын, язармыз.* Ләкин боеру, шарт, теләк һ.б. кайбер формаларны караганнан соң, катлаулы заман төрләрен дә бирә: *алган иде, -алган идек* (хәзерге термин белән әйткәндә, «күптән үткән заман»); *алганмын, алганмыз* (хәзергечә «нәтиҗәле үткән заман»); *алган булырмын, алган булырмыз* («тасвирлама» ягъни «перифрастик» формалар). Гомумән, К. Насыйри татар теленең заман һәм модаль формаларының мәгънәләренә тулы һәм тирән күзәтүләр ясый алган [Насыйри К., 1895, б. 40–57].

Г. Нугайбәк «Төрлек» дип аталган грамматикасында 19 заман формасын (хәзерге һәм киләчәк заманнарның бишәр, үткән заманның тугыз формасын) китерә. Бу формалар арасында *-ды* һәм *-ган* кушымчалы – үткән заманны; *-а/-и* кушымчалы – хәзерге заманны, дүртесе – *-р, -асы, -ачак, -макчы* кушымчалары белән ясалган төрләр – киләчәк

заманны белдерәләр, дип саный автор. Өстәвенә, бу формаларны *икән, имеш, булган* кебек модаль сүзләре белән дә китерә: *язган, язган иде, язган имеш, язган икән, язган булган икән, язган булган имеш* һ.б. Барысы җиде форма [Нугайбәк Г., 1911, б. 90; II, б. 204, 205]. Бу формаларның һәммәсен җиде заман нигезләреннән ясаганда, 49 форма барлыкка килер иде. Автор аларның барысын да китермәгән, шулай да 19 форманы күрсәткән.

Г. Ибраһимовның 1911 елда Казанда «Татар нәхүе», 1913 елда «Татар сарыфы» басылып чыкты һәм матбугат битләрендә югары бәя алды. Биредә «Сабах» нәшриятендә 1913 елда чыккан басмадан файдаланылды. Хезмәттә хәбәр (= хикәя): боеру, шарт, сыйфат, хәл һәм исем фигыльләр бирелгән. Фигыльнең зат белән төрләнүе нисбәт дип аталган. Автор бу кушымчаларны болай атый: I зат – «сөйләүче», II зат – «тыңлаучы», III зат – «гаиб» (ягъни сөйләмдә катнашмый торган). Хезмәттә биш заман формасы аерылып күрсәтелә: *-а* кушымчалы хәзерге заман (аңа боерык фигыльләр дә кертелгән), *-р* һәм *-ачак* кушымчалы киләчәк заманнар, *-ды* һәм *-ган* кушымчалы үткән заманнар. Димәк, хәзерге тел белемендә заман эчендә карала торган барлык синтетик формалар исәпкә алынган. Аларга өстәп, Г. Ибраһимов тагын хәзерге заманның *-макта* формасын да күрсәтә. Хезмәттә тирән семантик күзәтүләр бар: мәсәлән, боерык фигыльләрнең шарт (дөресрәге – кире шарт) мәгънәсендә кулланылуы, *-асы* кушымчалы төрнең теләкне белдерүе һ.б. [Гухман М., 1968, с. 40–63].

Бу хезмәткә Җ. Вәлидинең «Татар теленең сарыфы» шактый якын тора. Монда фигыль формалары икегә: боерык һәм хикәя фигыльләргә аерылган. Соңгылары эчендә «заманнарның» түбәндәге ике төре билгеләнгән: боеру һәм хикәяләү. Заман исемнәрендә аларның мәгънәләре чагылыш тапкан: күрмә үткән заман һәм ишетмә үткән заман. (Хәзерге грамматикаларда билгеле һәм билгесез үткән заманнар: *-ды* һәм *-ган* кушымчалы төрләре.) Хәзерге заманның киләчәк заман мәгънәсен белдерә алуы искәртелгән, тиешлекне белдерә торган *-асы* формасы бирелгән; шарт фигыль белән хәл фигыль берләштерелгән, чөнки икесе дә мөстәкыйль фигыльдән башка кулланылмый [Вәлиди Җ., 1919, б. 78–87]. Шул рәвешчә, күзәтелгән грамматикаларда кулланылышта йөргән формаларны мөмкин кадәр тулы бирергә омтылыш ясалган.

Бу чорда язылган грамматикаларда хикәя фигыльне кыек наклонениеләр белән, модаль һәм аспектуаль мәгънә белдерә торган формалар белән бутау күренешләре очрый. Мәсәлән, заман формаларын *җитсә кирәк, язайын, язсам иди, язасы иди, булгудай* һ.б.ш. формалар белән тиңләштерү күренешләре очрый. Кайбер мәсьәләләр тел белемендә күп еллар бәхәс тудырып килде: мәсәлән, *-р иде*, *-макчы иде*, *-а торганмын*, *-ачак иде* кебек аналитик формаларның фигыль системасында тоткан урыны шундыйлардан.

Формаларның санын арттыру әлеге грамматикаларда диалекталь, сөйләмә төрләр, грамматикалашып җитмәгән тезмәләр исәбенә дә булды, *-ган* һәм *-ачак* кушымчалары ярдәмендә ясалган заманнар (ягъни затланышлы формалар) озак вакытлар сыйфат фигыльләрнең зат белән төрләнеше итеп каралып йөрде.

Татар теленең грамматик мәсьәләләрен яктырту татар телен мәктәптә укыту бурычы һәм дәреслекләр төзү мәсьәләләренә дә килеп тоташа. Бу өлкәдә Г. Ибраһимов, Җ. Вәлиди, М. Корбангалиев, Ш. Рамазанов, Р. Газизов, Х. Хисмәтуллиннар нәтиҗәле эш алып бардылар. Алар төзегән дәреслекләр 1950 еллар ахырына хәтле чыгып килде.

Фәнни хезмәтләр арасында Г. Алпаровның «Шәкли нигездә татар теле грамматикасы» гомуми тел белеме яссылыгында эшләнүе, башка телләр белән чагыштыру элементларын эченә алуы ягыннан аерылып тора. Галим морфологиянең бурычын, иң элек, сүзнең төзелешен, агглютинация табигатен, кушымчаларның сүзгә кушылу тәртибен өйрәнүдә күрә. Фигыльләргә килгәндә, Г. Алпаров аларны өч төркемчәгә бүлә: 1) хәбәр фигыльләре, 2) хәл фигыльләре һәм 3) исем фигыльләр. Хәбәр фигыльләре үзләре дүрткә бүленеп карала: 1) боерык фигыль, 2) үткән (заман) фигыль, 3) шарт фигыль, 4) хәзерге (заман) фигыль [Алпаров Г., 1945, 88–94]. Хәл фигыльләр икегә аерылган: рәвеш фигыльләре (*алып, ала, ала-ала, алып-алып*) – барлыкта; *-алмыйча, -алмый* – юклыкта [Алпаров Г., 1945, б. 94–95].

Сыйфат фигыльләрне Г. Алпаров исем фигыльләр дип атый: 1) үткән заман исем фигыльләр: *килгән, алган, язган;* 2) киләчәк заман исем фигыльләр: *киләчәк, булачак, күрешәчәк;* 3) җавап исем фигыльләре: *янар, агар, күрсәтер... үтмәс, бетмәс, алмас, ишетелмәс* [Алпаров Г., 1945, б. 96].

Г. Алпаров фикеренчә, исем фигыльләр (хәзерге терминнар күзлегеннән караганда – сыйфат фигыльләр) хәбәрлек кушымчалары алып, зат белән төрләнә һәм өч заман формасында килә [Алпаров Г., 1945, б. 97].

| | | | |
|---|---|---|---|
| *килгәнмен* | *беләчәкмен* | *түзәрмен* | *булмамын* |
| *килгәнсең* | *беләчәксең* | *түзәрсең* | *булмассың* |
| *килгән* | *беләчәк* | *түзәр* | *булмас* |
| ...... | ...... | ...... | ...... |

Хәбәр фигыльләр турында сөйләгәндә, Г. Алпаров әһәмиятьле бер фикер әйтә: II зат берлек сандагы боерык фигыльнең һәм III зат хикәя фигыльнең зат кушымчасы алмауларын телдәге экономия күренеше белән аңлата, чөнки кушымча юклыгы иң еш кулланыла торган формаларда очрый [Алпаров Г., 1945, б. 91–92].

В. Хангилдинның грамматикага багышланган хезмәтләрендә фигыль категорияләре һәм аларның мәгънәләре шактый тулы тикшерелгән. Галим «Татар теле грамматикасы. Морфология буенча очерклар» исемле китабында әһәмиятле бер фикер әйтә: «Заман төркемчәләрендә («наклонение»ләрдә) фигыльлек табигате тулысынча чагылыш таба: сыйфат фигыль, хәл фигыль, исем фигыльләрдә ул кими, ләкин, шуның белән бергә, алар фигыльлек үзенчәлекләрен саклый һәм фигыль төрләре арасында каралырга тиеш» [Хангилдин В., 1954, б. 162–163].

Шулай ук кайбер формаларның мөнәсәбәтле заман белдерүләре, *-ды* һәм *-ган* формаларына билгелелек-билгесезлек хас булуы [Хангилдин В., 1959, б. 196], хәзерге заманның сөйләү моменты белән генә чикләнмичә үткәннең һәм киләчәкнең күпмедер өлешен алып торуы [Хангилдин В., 1959, б. 220], боерык фигыльнең нуль форма белән белдерелүе һ.б.ш. әһәмиятле фикерләр әйтелә.

В. Хангилдин заман категориясен хикәя фигыль белән чикләми: мәсәлән, шарт фигыльнең *-са* кушымчалы формасы заманга битараф *булса, -ган булса* формасының үткән заманны белдерү өчен кулланылуын әйтә. Хикәя фигыль *-ды, -ган, -а иде, -а, -р, -ачак* формалары белән чикләнгән [Хангилдин В.Н., 1959, б. 218–222].

В. Хангилдин, В. Виноградов һәм Н. Дмитриев фикерләрен таныса да, хикәя фигыль заманнарын югарыда күрсәтелгән алты форма белән

чикләгән, мәгънәләре тулысынча ачылмаган, фигыльнең модаль формалары заман төрләре белән бер рәткә куелган. Галим заман формаларының сөйләү моментына мөнәсәбәттә билгеләнүен субъективизм дип карый [Хангилдин В., 1959, б. 190] һәм шуның белән лингвистик һәм объектив сөйләү моменты төшенчәләрен аермый. В. Хангилдинда заман төрләренең бирелеше Х. Курбатов мәкаләсендә тәнкыйди бәяләмә алды [Курбатов Х., 1976, б. 113].

Морфология өлкәсендә алып барылган күп кенә хезмәтләрнең уртак кимчелеге – грамматик формаларның контексттан тыш тикшерелүе һәм шуның нәтиҗәсендә грамматик мәгънәләрнең тулысынча ачыла алмавы. Нәкъ шушы сәбәп аркасында В. Хангилдин грамматик формалар турындагы күзәтүләрен ахырына җиткерә алмаган. Шулай да татар теле грамматикалары тарихында В. Хангилдин хезмәтләре татар грамматикасын тикшерүгә зур өлеш булып санала.

1959 елда А. Нуриеваның заман мәсьәләсенә караган мәкаләсе басылды [Нуриева А., 1959, б. 164–194]. Автор татар телендә биш наклонениене һәм аларны белдерү чараларын күрсәтә. Шарт фигыльнең *-са, -ды исә, -ачак (-р, -асы) булса, -ган булса* формалары бирелә. Теләк фигыльгә *-р иде, -асы иде. -са иде, -ган булса иде* формаларын кертә. Башка чаралардан А. Нуриева *-макчы иде, -макчы була* һәм кайбер диалекталь формаларны күрсәтә. Хикәя фигыльгә караган заманнарга хәзерге грамматикаларда кабул ителгән тугыз заман формасын һәм шулар өстенә ике тасвирлама форманы кертә: *укыган булганмын* һәм *укый торган булганмын* [Нуриева А., 1959, б. 180–194].

Фигыль категорияләре М. Зәкиевнең синтаксисны һәм фигыль белән белдерелгән хәбәрне өйрәнүгә багышланган хезмәтләрендә тикшерелде. Мәсәлән, «Ике составлы җөмләләрдә баш кисәкләрнең белдерелүе һәм аларның мәгънәләре» исемле мәкаләсендә *-а* кушымчалы хәзерге заман, *-р* һәм *-ачак* кушымчалары белән ясалган I һәм II киләчәк заманнар, *-ган* кушымчалы перфект, *-а иде* һәм *-а булганнар* формалы тәмамланмаган үткән заманнар, *-ган иде* һәм *-ган була* – күптән үткән заманнар һәм *-р иде* күрсәткечле тәмамланмаган үткән заман бирелгән [Зәкиев М., 1974, б. 38–44], *-а торган иде* кушымчалы заман эшнең үтәлү характерына караган формаларга кертелгән. Хезмәттә, шулай ук, башка наклонениеләр формалары һәм модальлекләр, эмоциональ-экспрессив мәгънәләр каралган [Зәкиев М.,

1974, б. 47–52, 63]. Бу хезмәтләрдә М. Зәкиев *иде* һәм *бул-* фигыльләре белән ясалган формаларны билгелелек-билгесезлеккә ишарә итү ягыннан аерган. Фәкать *-а торган иде* формасы эшнең үтәлү характерын белдерә торган күренешләр рәтендә китерелгән. Хезмәттә шарт, боеру, мөмкинлек, фараз итү һәм ирония, үкенү кебек эмоциональ-экспрессив мәгънәләр дә тикшерелгән. Заман формаларын билгеләүдә автор Н. Дмитриев, А. Кононов, Э. Севортян хезмәтләренә таяна.

1963 елда Б. Серебренниковның Мәскәүдә «Система времен татарского глагола» хезмәте басыла. Бу хезмәттә заман формаларының составы һәм мәгънәләре махсус өйрәнелә. Заман формаларын контекстта өйрәнү нәтиҗәсендә аларның күпмәгънәлелеге, үзара бәйләнешләре, эмфаза (экспрессия, аеру чарасы) буларак кулланыла алуы ачыклана [Серебренников Б., 1963].

Д. Тумашеваның «Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе»ндә фигыль категорияләре турындагы фикерләр үстерелә, аныклана. Хезмәттә, бер яктан, фигыль формаларының күпмәгънәлелеген күрсәтүгә, икенче яктан, бер үк грамматик мәгънәнең төрле формалар белән белдерелә алуына игътибар ителгән. Мәсәлән, боеру, теләк, шарт һәм кире шарт формалары шул юнәлештә өйрәнелгән [Тумашева Д., 1964, б. 148–157]. Шулай ук *-ыр иде* формасының тәмамланмаган үткән заман (имперфект) һәм шартлы теләк (конъюнктив) мәгънәсендә кулланылуы күрсәтелгән [Тумашева Д., 1964, б. 143–146]; затланышсыз формаларның фигыль һәм исем билгеләре, күпфункциялелеге, сыйфат фигыльнең заман формалары белән хикәя фигыль арасындагы бәйләнеш һ.б. каралган. Шул ук вакытта хәзерге татар әдәби телендә бу формаларның бер-берсеннән мәгънәви һәм формаль яктан тәмам аерылганлыгы күрсәтелгән [Тумашева Д., 1964, б. 196].

СССР Фәннәр академиясе ТӘһТИ хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнеп 1965 елда нәшер ителгән «Хәзерге татар әдәби теле (Лексика. Фонетика. Орфоэпия. Графика һәм орфография. Морфология)» исемле хезмәттә фигыльгә бик аз урын бирелгән [Хәзерге татар..., 1965, б. 225–250]. Элек каралган формалардан заманнар исемлегенә *-а торган иде* күрсәткечле кабатлаулы үткән һәм *-ачак иде* формалы киләчәк үткән заманнар кертелмәгән. Димәк, җиде форма белән чикләнелгән. Наклонениеләрдә ният фигыль һәм аның хәзерге заманы: *-макчы, -макчы була;* юклык формасы: *-асы түгел;* үткән заманы:

*-макчы булды (булган), -рга булды (булган), -макчы иде, -макчы була иде, -асы түгел иде;* киләчәк заманы: *-макчы булачак, -макчы булыр* формалары бирелгән [Хәзерге татар..., 1965, б. 243–246].

Өч төрле заманга караган формаларның кулланылуы бу хезмәттә а) эш-хәлнең төгәл вакытын белдерү кирәклеге, ә) эшнең дәвамлы булу-булмавын, тәмамлану-тәмамланмавын, билгеле-билгесез булуын белдерү; б) контекст тәэсирендә формаларның яңа мәгънә алу мөмкинлеге белән аңлатылган [шунда ук, б. 233–235].

Күзәтелә торган темага фигыль формаларының синонимиясен, тасвирлама формаларын өйрәнүгә караган мәкаләләр [Тумашева Д., 1982; 1965; Мардиева М., 1978; 1982] язылды, түбәндәге кандидатлык диссертацияләре якланды: Л. Гаделшин «Хәзерге татар әдәби телендә фигыльнең инфинитив формасы» (1965), Ф. Хисамова «Хәзерге татар әдәби телендә сыйфат фигыль» (1970), М. Мәрдиева «Татар телендәге тасвирлама формалар (төрек һәм үзбәк формалары белән чагыштыру юнәлешендә)» (1974), М. Ибраһимова «Татар телендә ирреаль модальлек һәм аның бирелеше» (1975), Н. Салехова «Татар телендә фигыльнең заман категориясе һәм темпоральлек» (1975), Д. Шәйхәйдарова «Татар телендә фигыльнең зат категориясе һәм персональлек» (1980), Р. Абдуллина «Татар фигылендә заман мәгънәләренең үсеше һәм стилистик үзенчәлекләре» (1988), Р. Лизунова «Хәрәкәт фигыльләре белән ясалган аналитик төзелмәләрнең мәгънәсе (татар һәм төрки телләр нигезендә)» (1991), Р. Гыйльфанов «Татар һәм француз телләрендә фигыль заманнарының системасы» (1998) һ.б.

«Современный татарский литературный язык» (1969) хезмәтенең фигыль бүлегендә юнәлеш, наклонение категорияләре (хикәя, боеру, теләк һәм шарт фигыль), фигыльнең затланышсыз формалары (сыйфат фигыль, хәл фигыль, исем фигыль һәм инфинитив), *-рга, -макчы, -асы* формаларына нигезләнгән һәм модаль мәгънә белдерә торган формалар, фигыльдә эшнең үтәлү характерын белдерү чаралары һәм фигыль ясалышы каралган [Современный татарский..., 1969, с. 210–294].

Ф. Хисамова сыйфат фигыль формаларын фигыль һәм исем категорияләренең чагылыш дәрәҗәсе күзлегеннән тикшерде: а) заманга, эш субъектына, юнәлеш категориясенә мөнәсәбәте; ә) сыйфат фигыльнең килеш, тартым, сан белән төрләнү үзенчәлеге һ.б.

З. Вәлиуллина, К. Зиннәтуллина, М. Сәгыйтов тарафыннан язылган «Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе» (1972) бу авторларның югары уку йортында курсны күп еллар укыту тәҗрибәсенә таянып эшләнгән, юнәлеш категориясенең бирелешендә фәнни тикшеренү нәтиҗәләре чагылыш тапкан.

## 4.3. ФИГЫЛЬНЕҢ ФУНКЦИОНАЛЬ-СЕМАНТИК ҺӘМ ГРАММАТИК КАТЕГОРИЯЛӘРЕ

**Фигыль турында гомуми төшенчә.** Фигыль – предметның эшен, хәлен процесс рәвешендә белдерә торган һәм барлык-юклык, юнәлеш, дәрәҗә, наклонение, заман, зат-сан белән төрләнә торган сүз төркеме.

Эш-хәл төшенчәсен, предметлаштырып, исем белән дә белдереп була: *утырыш, йокы, аңлатма, сөенеч* һ.б. Бу вакытта эш-хәл мәгънәсе башкаручы предметтан аерылып бирелә. Ләкин эш-хәлнең башкаручысы булса, ул процесс төсен ала һәм фигыль була: *алар утыралар, ул йоклый, без аңлаттык, сез сөенерсез* һ.б.

Димәк, зат-сан белән төрләнү фигыльнең төп билгеләреннән берсе булып исәпләнергә тиеш. Ләкин фигыль формалары арасында, зат-сан белән төрләнә торган «саф» фигыльләрдән башка, зат-сан белән төрләнми торган һәм исем, сыйфат, рәвеш белән чиктәш формалар да бар: исем фигыль, сыйфат фигыль, хәл фигыль.

Зат категориясенә мөнәсәбәте ягыннан барлык фигыльләр **затланышлы** һәм **затланышсыз** төрләргә бүленәләр.

Затланышлы дип зат белән төрләнә торган ягъни зат кушымчалары ала торган фигыль формалары атала. Зат мәгънәсен башка юллар белән белдерү (мәсәлән, *мин баргач, син баргач, ул баргач*) зат белән төрләнү була алмый, һәм андый фигыльләр затланышлыларга керми.

Затланышлы фигыльләргә – хикәя, боерык, шарт һәм теләк фигыль, затланышсыз фигыльләргә сыйфат фигыль, хәл фигыль, исем фигыль һәм инфинитив керә.

Фигыль категорияләре күләме, таралышы ягыннан бердәй түгел. Бер төрле категорияләр барлык фигыльләр өчен хас. Андыйларга барлык-юклык формасы, юнәлеш, дәрәҗә керә. Икенче төрле категорияләр таррак була. Мәсәлән, эшнең чынбарлыкка мөнәсәбәтен (наклонение категориясен) затланышлы фигыльләр генә белдерә, ә заман белән төрләнү наклонениеләрнең берсендә – хикәя фигыльләрдә генә

табыла. Калган фигыльләрдән бары сыйфат фигыльләр генә заман формаларына аерылалар.

**Татар телендә фигыльнең темпоральлек, модальлек һәм персональлеккә караган функциональ-семантик категорияләре.** Бу бүлекчәдә татар телендәге фигыль һәм аның грамматик категорияләрен тикшерү өчен функциональ-семантик алым файдаланды, ягъни фигыльнең грамматик категорияләре ике яссылыкта, парадигматика һәм синтагматикада каралды.

Татар һәм төрки тел белемендә фигыль һәм аның грамматик категорияләренә караган махсус әдәбият шактый күп тупланган. Семантик яктан татар фигыленең заманнар системасын өйрәнүгә, аларның мәгънәсенә һәм стилистик функцияләренә багышланган мәкаләләр татар әдәби телен өйрәнү уңае белән дә, диалектологик хезмәтләрдә дә урын алып килде. Татар грамматикасында семантик яктан зат категориясе, затланышсыз формаларда эш башкаручы затны белдерү, җөмлә синтаксисында зат категориясенең роле һәм башка мәсьәләләр яктыртылган. Ләкин кайбер очракта зат категориясен билгеләгәндә, морфологик һәм морфологиягә карамаган билгеләр аерылмый, бу исә затланышлы һәм затланышсыз формаларны төгәл билгели алмауга китерә. Шуны да әйтеп үтәргә кирәк: югарыда әйтелгән фикер грамматик тикшеренүләрнең билгеле баскычын чагылдыра. Формаларның грамматик мәгънәсен тикшерү бигрәк тә соңгы унъеллыкларда киң колач алды. Шуны да искәртергә кирәктер: элекке грамматик традициядә «морфология – телне формаль яктан тикшерә» дип карала, формаларның мәгънәсен һәм кулланылышын өйрәнү – синтаксис бурычы итеп исәпләнә иде. Ләкин мәсьәләгә мондый берьяклы караш грамматик категорияләрне өйрәнүне чикли иде. Мәсәлән, хәбәрне белдерү өчен бик күп фигыль формалары кулланылса да, аларга синтаксик яктан гына якын килү заман, зат, модаль һәм башка грамматик формаларның махсус өйрәнелүен алыштыра алмый иде. Заман формаларының мәгънә күләме, төп һәм контекстка бәйле мәгънә төсмерләре тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәде, затланышлы формаларның составы, темпоральлекне белдерүче башка фигыль формаларының кулланылуы һ.б. кайбер бәхәсле мәсьәләләр тикшерелмәгән килеш кала килде.

Татар грамматикалары XIX йөз башыннан нәшер ителә башлап, хикәя, боеру, теләк, шарт һәм шартлы теләк фигыль формалары тасвир

ителә, наклонение турында беренче мәгълүмат 1911 елда Г. Нугайбәк тарафыннан бирелә [Нугайбәк Г., 1911, б. 80]; аның фәнни билгеләмәсен 1954 елда В. Виноградовның модальлек турындагы теоретик өйрәтмәсенә нигезләнеп язылган хезмәтендә В. Хангилдин бирде [Хангилдин В., 1954, б. 226–232]: «Наклонение – фигыльдә белдерелгән эш яки хәлнең сөйләүче карашында чынбарлыкка мөнәсәбәтен билгели торган грамматик категория ул» [Хангилдин В., 1959, б. 216].

Безне кызыксындырган юнәлештә татар тел белемендә шактый мәсьәләләр каралды: зат категориясенең төрле юллар белән белдерелүе, затланышсыз формаларда, мәсәлән, сыйфат фигыльдә затны белдерү юллары, зат категориясенең җөмлә синтаксисында тоткан урыны һ.б. Шуның белән бергә, зат категориясен аңлатканда морфологик һәм морфологиягә карамаган чараларны аермау нәтиҗәсендә затланышлы һәм затланышсыз формаларны белдерүдә төгәлсезлекләр җибәрелә, зат категориясенең модальлек белән бәйләнеше һәм кайбер башка мәсьәләләр тиешенчә яктыртылмый кала иде.

Бу хәл рус тел белемендә дә урын алды: «Грамматик традициядә күп телләргә караган морфологик категорияләрнең кулланылуын өйрәнү синтаксиска кертелеп каралды. Ләкин сүз җөмлә синтаксисы турында түгел, бәлки сүз төркемнәре синтаксисы турында бара... Бу исә үзенә аерым бер синтаксис...» [Бондарко А., 1973, с. 28–29].

Грамматик формаларның мәгънә һәм функцияләрен морфологиядә өйрәнүнең кирәклеге турында грамматик теория белгече М. Гухман болай дип язды: «Тел берәмлекләренең билатеральлеге (ике яклы булуы) морфологияне фәкать белдерү чарасы, синтаксисны исә – мәгънә чарасы дип карауга каршы килә… Мондый грамматикалар телнең эчке морфологик төзелешен күрсәтә алмадылар. Грамматик берәмлекләрне функциональ яктан өйрәнү – аның мәгънәсен өйрәнү белән тыгыз бәйләнгән» [Гухман М., 1968, с. 122]. «Морфология һәм синтаксисның һәркайсына хас парадигматика һәм синтагматикалары бар», дип язды Б. Головин [Головин Б., 1969, с. 77].

Төрки телләрнең грамматик категорияләрен функциональ аспектта, ягъни контекст белән бәйләнештә өйрәнү кирәклегенә төрки телләр белгече Э. Севортян игътибар иткән иде [Севортян Э., 1970].

Хәзерге заман тикшеренүләре грамматик категорияләрнең структурасына игътибар итү һәм аны тасвирлау өчен мөмкин кадәр уңай

алымнар эзләүгә юнәлгән. Грамматик формаларның күпмәгънәлелеге эчендә аерым мәгънәләрнең үзара мөнәсәбәтен билгеләү теоретик яктан төрек теле мисалында С. Иванов хезмәтләрендә нигезләнде [Иванов С., 1973].

Хезмәтнең бу бүлегендә фигыльне өйрәнү функциональ-семантик яссылыкта алып барылачак.

Функциональ-семантик тикшеренүнең кайбер принципларына, нигезләренә тукталыйк.

Функциональ-семантик кыр (ФСК) яки функциональ-семантик категория – телнең морфология, синтаксис, сүз ясалышы, лексик системасына караган һәм уртак функция нигезендә билгеле бер семантик категория тирәсендә тупланган гомумилеге ул.

Алга таба фигыльне функциональ-семантик яссылыкта тикшерүнең төп принципларына тукталып үтү урынлы булыр.

1. Функциональ-семантик яктан грамматик форма һәм категорияләрне өйрәнү тел дәрәҗәсендә (парадигматикада) генә түгел, бәлки аларның кулланылышында, ягъни тел күренешләре сөйләм күренешләре белән мөнәсәбәткә кергән вакытта (синтагматикада) да алып барыла. Шул рәвешчә, функциональ-семантик анализ һәм эчтәлекне, һәм аның белдерелү юлларын өйрәнүне күздә тота. Аерым очракта, әгәр эчтәлекне генә өйрәнергә туры килсә, аны белдерү чаралары күздә тотыла.

2. Фигыльне тикшерү грамматик категориянең гомумиләштерелгән эчтәлегенә һәм аны белдергән формалар бердәмлегенә таяна. Бу караш Л. Щерба [Щерба Л., 1974, с. 137], Б. Головин [Головин Б., 1969, с. 75–87], М. Гухман [Гухман М., 1968, с. 117–174], В. Ярцева [Ярцева В., 1968, с. 5–57] һ.б. галимнәрнең хезмәтләренә нигезләнгән.

3. Фигыльнең затланышлы формаларын тикшерү ике яссылыкта алып барыла.

1) Персональлекне (затка караганлык һәм зат категориясен), темпоральлекне (заманга караганлык һәм заманнар системасын), модальлекне (наклонениеләр системасын) өйрәнүдә анализ башта формадан мәгънәгә таба алып барыла. Синтагматик, ягъни контекстка бәйле мәгънәләр ике төргә аерыла:

а) форманың нигез мәгънәсен (билгеле бер темпоральлек, модальлек һәм персональлекне) үзгәртми торган мәгънәләр;

ә) контекст тәэсирендә төп семаларның (мәгънә өлешләренең), нейтральләшүе һәм күчерелмә мәгънәләрнең барлыкка килүе.

2) Анализның икенче төре: мәгънәдән формага таба алып барыла. Анализ өчен нигез итеп ФСК (функциональ-семантик кыр) эчендәге төп грамматик категориянең мәгънәсе алына, һәм бу мәгънәнең башка фигыль формалары белән реальләшүе карала. Әгәр грамматик категория булмаса (мәсәлән, кайбер модаль формаларда), нигез итеп формалар арасыннан тиешле мәгънәне иң төгәл белдергән һәм еш кулланыла торган төр сайлап алына.

Димәк, функциональ-семантик категория, грамматик категорияләрнең мәгънә төзелешен һәм формаларын өйрәнүне тел дәрәҗәсендә (парадигматикада) генә түгел, бәлки аларны сөйләм вакытында, тел күренешләрен сөйләм белән мөнәсәбәттә (синтагматикада) өйрәнүне дә күздә тота.

Функциональ-семантик категория (кыр) шулай ук ике яклы: эчтәлек һәм форма бердәмлеге. Ул, грамматик (морфологик һәм синтаксик) чаралар белән бергә, лексик, лексик-грамматик һәм шул ук семантик өлкәгә караган сүз ясалыш чараларын да үз эченә ала (Бондарко А., 1983, с. 40].

М. Гухман, функциональ-семантик «кыр»ның үзәген грамматик категория хасил итә, ә читтә (периферияда) грамматик категория мәгънәсен белдергән, ләкин формальләшеп җитмәгән структуралар урнаша, дип саный [Гухман М., 1968, с. 172–175].

Функциональ-семантик аспектта тикшерелгән наклонение, заман һәм зат-сан категорияләре фигыльнең нигез грамматик категорияләре булып тора. Алар өчесе дә предикативлыкны белдерүгә юнәлгән. Функциональ-семантик категорияләр (кырлар) дә (темпоральлек, модальлек һәм персональлек) предикативлыкка карый. Алар, әлбәттә, предикативлыкны белдерү белән генә чикләнмиләр, шулай да бу үзенчәлек өйрәнелгән функциональ-семантик «кыр»ларның әһәмиятле ягы булып тора.

Тикшерелә торган функциональ-семантик категорияләр, яки (кырлар), наклонение, заман һәм зат-сан категорияләре тирәсендә тупланган.

I. Беренче баскычта тикшерү формадан мәгънәгә таба парадигматик һәм синтагматик яссылыкта алып барыла. Болай эшләү грамматик формаларның мәгънә төзелешен, семантик мөмкинлекләрен

(потенциалын) ачарга, соңгыларында исә тел яки сөйләм дәрәҗәсенә караган күренешләрне билгеләргә мөмкинлек бирә. Синтагматик мәгънәләр арасында формаларның күчерелмә мәгънәләре дә күрсәтелде. Болар һәммәсе татар фигыленең грамматик яктан стилистик мөмкинлекләргә бай булуын күрсәтә.

II. Анализның икенче төрендә тикшерү мәгънәдән формага таба алып барыла. Анализ өчен нигез итеп ФСК (функциональ семантик кыр) эчендәге төп грамматик категориянең мәгънәсе алына, һәм бу мәгънәнең башка фигыль формалары белән реальләшүе карала. Әгәр грамматик категория булмаса (мәсәлән, кайбер модаль формаларда), нигез итеп формалар арасыннан тиешле мәгънәне иң төгәл белдергән һәм еш кулланыла торган төр сайлап алына.

Мәгънәдән формага таба тикшерү бер үк грамматик мәгънәне белдерә торган төрле фигыль формаларының булуын, грамматикалашкан һәм грамматикалашып җитмәгән, ләкин уртак грамматик мәгънә белдереп, үзара синонимик мөнәсәбәттә торган фигыль сүзтезмәләре булуын ачыкларга ярдәм итә. Мәсәлән, мөмкинлекне белдерә торган *-уы бар, -уы ихтимал*: *югалтуы бар, килмәве мөмкин/ихтимал;* тиешлекне белдерә торган һәм III затта гына кулланыла торган *-ачак булды, -асы булды* һ.б.

Гомумән алганда, бер яктан, грамматик формаларның күпмәгънәлелеге, икенче яктан, бер үк грамматик мәгънәнең күптөрле формалар белән белдерелүе татар теле грамматик чараларының стилистик мөмкинлекләрен ача.

Шуны да әйтеп үтәргә кирәктер: хезмәттә теге яки бу мәгънәнең реальләшүе фигыль формалары белән генә чикләнә; лексик, синтаксик, интонацион һ.б. чараларга формаларның реальләшүе өчен билгеле бер контекст тудырганда гына игътибар бирелә.

Персональлек, темпоральлек һәм модальлекне белдерүче формалар, хезмәттә грамматикалашкан конструкцияләр белән чикләнсә дә, биредә бу семантик зоналар, кабул ителгән анализ төреннән чыгып, грамматик дип түгел, бәлки функциональ-семантик кыр яки функциональ-семантик категория дип аталды.

Эш процессында авторның морфологиягә караган хезмәтләре һәм аның җитәкчелегендә башкарылган диссертацияләрдән Ф. Хисамова, М. Мәрдиева, Н. Салехова, Д. Шәйхәйдарова, Р. Лизунова, Р. Абдуллина хезмәтләре дә файдаланылды.

### 4.3.1. Темпоральлек

**Фигыльдә заман категориясе.** Заман, материянең яшәеш формасы буларак, бер-берсен алыштыра торган күренешләрнең эзлеклелеген белдерә, һәрбер матди процесс бер юнәлештә – үткәннән киләчәккә таба үсә. Хәзерге заман исә үткән белән киләчәкне аера торган бер нокта, һәм ул даимән хәрәкәт итә.

Заман категориясе – объектив заманның телдәге чагылышы ул, һәм аны исәпләү ноктасы итеп сөйләү моменты алына: сөйләү моменты белән туры килә торган эш-хәл – хәзерге заманга, сөйләү моментыннан алда булган эш-хәл – үткән заманга, сөйләү моментыннан соң булачак эш-хәлләр киләчәк заманга карый.

Бу мәгънәләр татар телендә тугыз заман формасы белән белдерелә:

1. Хәзерге заманның бер формасы бар: фигыльнең тартык яки сузыкка тәмамлануына, калын яки нечкә сузыклардан торуына карап, кушымчаның дүрт варианты була: *-а, -ә, -ый, -и*.

2. Үткән заманның биш формасы бар. Аларның күрсәткечләре*: -ды, -ган, -а иде, -ган иде, -а торган иде* һәм фонетик вариантлары.

3. Киләчәк заманның өч формасы бар. Алар: *-р/-мас, -ачак/-әчәк, -ячак/-ячәк*. Үткән-киләчәк заманның кушымчалары: *-ачак иде/-әчәк иде, -ячак иде/-ячәк иде.*

Бер үк заманга караган формалар күплеге алар арасындагы мәгънә аермасын ачыклауны таләп итә. Тел белемендә заманнарга бирелгән билгеләмәләр аларның төрле мәгънә өлешләренә (семаларга) карый. Бу исә заман семаларының төзелешен (структурасын) ачыклау бурычын куя. Мәсәлән, *-ган/-гән, -кан, -кән* формасының мәгънәсен аңа бирелгән атамалардан да өлешчә күреп була: грамматикаларда ул «күрми үткән заман», «билгесез үткән заман», «нәтиҗәле үткән заман», «үткән-хәзерге заман» дип аталып йөртелә. Кайчакта ул контекст ярдәмендә сөйләү моментыннан күп вакыт алда үткән эш-хәлне, ягъни күптән үткән заманны да белдерә ала.

Заман мәгънәләрен өйрәнү өчен биредә функциональ-семантик алым файдаланылды. Ул заманнарны ике яссылыкта – парадигматикада һәм синтагматикада карауга нигезләнгән.

Парадигматика – тел берәмлекләрен система итеп карау, телдәге структур берәмлекләрнең кеше аңында, хәтерендә бер-берсенә каршы

куелу мөнәсәбәтендә торуы. Грамматик форманың парадигматик мәгънәсе дип аның аерым торгандагы яки иң кечкенә контексттан аңлашыла торган мәгънәсе санала.

Синтагматика – тел элементларының бер сызыкта (бер вакытта) урнашуы. Форманың синтагматик мәгънәләре дип аның контекстта кулланылганда, контекст тәэсирендә барлыкка килгән мәгънәләрен атыйлар.

## Хикәя фигыль заманнары

### *Хәзерге заман*

Хәзерге заман хикәя фигыль *-а/-ә, -ый/-и* кушымчалы хәл фигыльгә нигезләнә һәм беренче төр зат кушымчалары белән төрләнә:

| | Берлек сан | Күплек сан |
|---|---|---|
| I зат | *ал-а-м, -мын* | *ал-а-быз* |
| II зат | *ал-а-сың* | *ал-а-сыз* |
| III зат | *ал-а* | *ал-а-лар* |

Хәзерге заман хикәя фигыль формасы татар телендә бер генә, шуңа күрә ул хәзерге заман формалары бердән артык булган төрки телләрдән мәгънә киңлеге белән аерылып тора.

**Хәзерге заманның парадигматик (контекстка бәйсез) мәгънәсе.** Хәзерге заман сөйләү моменты белән бер үк вакытта башкарылган, сөйләү моменты өчен актуаль булган эш-хәлләрне белдерә. *Киек казлар кыйгылдаша. Җырлашалар микәнни? – Туган яклар кала бит, дип, Елашалар микәнни?* (Х. Туфан). *Узды яшьлек. Хафаланмыйм. Масаймыйм. Эреләнмим. Табигать улы булсам да, Язларын бөреләнмим* (И. Юзиев). *Ник бу тикле ярсу син, йөрәгем, Ашкынасың, дөрләп янасың? Сагынасыңмы әллә ерак калган Туып-үскән Казан каласын?* (М. Ногман).

Актуальлек төсмере диалогик сөйләмдә аеруча ачык сизелә. – *Өегезне утын белән ягасызмы? Ташкүмер беләнме? – Икесе белән дә. – Утын күпме китә кышка? – Бер машина.*

Җөмләдә хәзерге заман ситуациясенә контексттагы сүзләр ишарә итә ала: *Җылы. Иллюминаторның пәрдәләре төшерелгән. Диван өстендә бра гына яна. Рәис китап укый* (М. Юныс). *Сагышлы төн. Зәңгәр күктә – төптә Ай яктыра, йолдызлар яна...* (М. Әгъләмов).

**Хәзерге заманның синтагматик мәгънәләре.** Синтагматик, ягъни контекстта барлыкка килә торган мәгънәләр ике төрле була.

1. Заманның төп мәгънәсе, төп семантик үзлеге үзгәрми торган мәгънәләр (А дип билгеләнәчәк).

2. Күчерелмә мәгънәләр. Алар контекст чаралары ярдәмендә хәзерге заман һәм хикәяләү наклонениясе мәгънәләрен үзгәртәләр (Ә).

**А. Беренче төр синтагматик мәгънәгә киңәйтелгән хәзерге заман карый.**

1. Гадәти, типик яки кабатланган эш-хәлләрне белдерә: *Дөньяда иң тыныч урын кайда? Бүре Әскый сәкесендә. К е р ә с е ң, түргә у з а с ы ң. Әскый үзе чабата я с ы й. Сәке тулы юкә... Өйдә тынлык. Сәкегә у т ы р а с ы ң... һәм искиткеч татлы й о к ы г а т а л а с ы ң* (М. Мәһдиев).

2. Җәмгыятьтә йолага, гадәткә кергән эш-хәлләрне белдерә ала: *Крестьян баласы, ир-малай булса, җиде яшьтән атка, тырмага, сабанга й ө р и б а ш л ы й. Сигездә-тугызда – утауга, уракка к у ш а л а р* (Г. Ибраһимов). *Көлтә йөгендә утырып к а й т а с ы ң – бодай башы у ы п а ш ы й с ы ң. Урман буенда күшә, су буенда кыр суганы, җир җиләге о ч р ы й. Амбар тирәсеннән узганда, кесәгә борчак т у т ы р ы п к и т ә с е ң* (М. Мәһдиев).

Бу мәгънә, күпчелек очракта, өченче һәм гомумиләшкән икенче затка карый.

3. Предметны яки затны даими билгесе ягыннан ачыклый: *Т. Миңнуллин үзенә кадәр булган драматурглардан бигрәк тә Кәрим Тинчуринга я к ы н т о р а: һәр ике автор персонажны көтелмәгәнчә итеп б о р ы п к у я б е л ә, аның образ буларак табигый хәрәкәтен б а р л ы к к а к и т е р ә* (А. Әхмәдуллин),

4. Хәзерге заман шулай ук төрле кагыйдәләрдә, объектив хакыйкатьне формалаштырганда, афоризм, табышмак, әйтемнәрдә очрый: *Кошлар о ч а, йолдызлар а т ы л а, елгалар ярыннан т а ш ы н а* (Р. Фәйзуллин). *Кырмыскаларны урман санитарлары д и п й ө р т ә л ә р.*

5. Модаль сүзләр һәм кисәкчәләр белән килеп, хәзерге заман икеләнү, фараз итү, фикер нәтиҗәсен белдерү өчен дә кулланыла: *Зөһрә, син б е л м и с е ң д е р әле, ул мине үлемнән коткарып калды бит!* (Р. Хәмид). *Кешене артык иркәләү дә б о з а икән* (Ф. Хөсни).

*Төшемдә һаман Галимә апа белән саташтым... Үзе шат, үзе е л ы й имеш* (М. Гафури).

**Ә. Икенче төр синтагматик мәгънәгә күчерелмә мәгънәләр карый.**

1. Хәзерге заман киләчәккә карый торган, ягъни сөйләм моментыннан соң башкарыла торган эш-хәлләрне белдерә ала: *Бүген минем әти Казаннан к а й т а . Улмы? Ул миңа саплы калач к и т е р ә . Аннары миңа читек к и т е р ә . Өр-яңа читек* (Г. Исхакый). *Көтегез мине, хәзер к и л е п җ и т ә м* (Ю. Сафиуллин). *Кирәксә, районнан врач к и т е р т ә м* (А. Гыйләҗев). Хәзерге заманның бу мәгънәсе күбрәк хәрәкәт фигыльләрендә чагылыш таба.

2. Хәзерге заман үткәнгә караган эш-хәлләрне белдерү өчен дә кулланыла: *Зөлфәт Хәкимнең өч томлык «Сайланма әсәрләр»е 1997 елда б а с ы л ы п ч ы г а . «Хәйдәр Бегичевнең М. Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрында Н. Җиһановның «Җәлил», Ж. Бизеның «Кармен», М. Мусоргскийның «Борис Годунов» операларында башкарган Җәлил, Хозе һәм Ялган патша партияләре вокал ягыннан да, актерлык осталыгы таләпләреннән чыгып бәяләгәндә дә үзләренең камиллекләре белән а е р ы л ы п т о р а л а р »* (Г. Арсланов, «Казан утлары», 1999, № 6). Алдагы җөмләдә тиешле контекст ярдәмендә хәзерге заман формасының үткәнгә, бүгенгегә һәм киләчәккә каравы белдерелә: *Без яшәгән гасырның башыннан ахырына кадәр (алга таба да бу хәл, һичшиксез, д ә в а м и т ә ч ә к ) халык Тукайны о л ы л ы й , б ө е к л и , илдә әллә ничә буын аңа иман китереп, к ү ң е л е н т ү г ә* (Р. Фәйзуллин).

3. Хәзерге заман хикәя фигыль II зат берлек һәм күплек санда килеп, тиешле интонация һәм контекст ярдәмендә боеру мәгънәсен дә белдерә ала: – *Беркая да к и т м и с е з !.. Квартир сезнеке. Без китәбез* (М. Хәсәнов). Юклыкта килгән сорау формасы йомшак өндәүне белдерә: *Шигырь ә й т е п к ү р с ә т м и с е з м е ? (Г. Бәширов). Бакчага б а р ы п к а й т м ы й с ы ң м ы , кызым?*

III зат күплектә килгән хәзерге заман хикәя фигыль формасы эшне үтәү яки туктату өчен ипле киңәш яки теләк белдерә: *Бүлмәдә б ү р е к к и е п у т ы р м ы й л а р . Олыларны х ө р м ә т и т ә л ә р .*

Хәзерге заман, *икән* модаль сүзе белән килеп, тиешле интонация белән әйтелгәндә, шарт һәм нәтиҗә мәгънәләрен белдерә ала: *Бер-ике*

*уч борчак а п ч ы г а с ы ң и к ә н , Нургаян аны күрми дә, әйбер дә әйтми* (М. Мәһдиев).

### *Үткән заман формалары*

**Билгеле (категорик) үткән заман.** Бу заман фигыль нигезенә *-ды/-де, -ты/-те* кушымчалары ялганып ясала һәм, икенче төр зат кушымчалары алып, төрләнә:

| | Берлек сан | Күплек сан |
|---|---|---|
| I зат | *ал-ды-м* | *ал-ды-к* |
| II зат | *ал-ды-ң* | *ал-ды-гыз* |
| III зат | *ал-ды* | *ал-ды-лар* |

Заманның парадигматик мәгънәсе – сөйләү моментыннан алда, бер тапкыр булган, категорик (= билгеле) үткән заман эш-хәлләрне белдерү. *Җөмләдә эшнең билгеле бер вакытка яки урынга карагандыгы күрсәтелергә мөмкин. Ул кышны мәдрәсәдә укулар бик иртә т у к т а л д ы* (Ә. Еники). *Дөп-дөп итеп мотор кабыну белән, көймәгә җ а н к е р д е , ул салмак кына кузгалып, а л г а ы р г ы л д ы ...* (Г. Афзал).

Бу заман формасы эшнең башлануын, бер тапкыр булуын белдергән аналитик фигыльләр өчен аеруча уңай: *Әмма Лотфулла абзый аның барлык уйларын ике авыз сүз белән т у з д ы р ы п т а ш л а д ы* (Г. Ахунов). *Талип кисәк кенә у р ы н ы н н а н к у п т ы , ишекле-түрле й ө р е п к и т т е* (М. Хәбибуллин). *Акча!.. Акча дип т а ң а т т ы р д ы Хәйдәр, акча дип к и ч е н о з а т ы п җ и б ә р д е* (А. Гыйләҗев).

Эшнең нәтиҗәсен белдергән *-ган* кушымчалы үткән заманнан аермалы буларак, категорик үткән заман вакыйгаларның тиз алышынуын яки эзлекле үсешен белдерә ала: *Сәлахетдин а ң л а т ы п т о р м а д ы , тәмәке төпчеген җиргә б ә р д е дә, палатасына к е р е п к и т т е* (А. Гыйләҗев). *К у з г а л д ы к м ы ? .. Иләмән карт аңа каш астыннан гына к а р а п а л д ы да, трубка көлен учына кагып, урыныннан т о р д ы* (М. Галиев). *Ләкин Нәфисә аяусыз иде. Ул әйткән җиреннән ө з д е д ә с а л д ы : « С ө й л ә ш т е к , б е т т е ! » , – д и д е* (Г. Бәширов). *Арбага килеп курай белән мичкәдән с у э ч т е . Кызу кояш астында янган битен, кулларын, күлгә төшеп, акрынлап ч ы л а т т ы . Төбенәчә якты булып ялтыраган күл суында уйнаган кызыл канат балыкларын к а р а д ы* (Г. Ибраһимов).

Бу заманда килгән фигыльләр, *да, дә* кисәкчесе белән килеп, вакыйгаларның тиз алмашынуын белдерә: *Җиде яшьлек улым, муенымнан кочаклады да, саубуллашып, чыгып йөгерде* (Г. Ахунов).

**Категорик үткән заманның синтагматик мәгънәләре.**

**А.** 1. Фигыльнең лексик мәгънәсе чикле яки чиксез булуына карап *-ды* кушымчалы үткән заман тәмамланган яки дәвам иткән эш-хәлләрне белдерә ала: *Кыр җилләре иркәләде килеп, Тукай моңы ерактан тартты, Әкиятләрең белән ачылды телем, Казан арты, әй Казан арты* (С. Хәким). Бу мисалда *иркәләде, тартты* фигыльләре – чиксез. Алардан ясалган категорик үткән заман эшнең күпмедер вакыт дәвам иткәнлеген белдерә; *ачылды* исә – чикле фигыль, һәм шул ук заман эшнең бер тапкыр булуына һәм тәмамлануына ишарә итә.

2. Контекстта дәвамлылыкка, кабатлануга, эшнең дәвам итүенә ишарә итүче сүзләр булуы мөмкин: *озак, шактый вакыт, һаман, гел, еш, әле* һ.б. Мондый очракта категорик үткән заман аспектуаль мәгънәләр дә белдерә ала: а) дәвамлылык: *Фәрит ауды да кичкә кадәр йоклады* (А. Расих); ә) кабатлану: *Ваил, гаҗәпләнеп, әле әнисенә, әле үзен күзәтеп торган карчыкка карады* (Ш. Рәкыйпов).

3. Кайбер очракта категорик үткән заман *-ган* кушымчалы нәтиҗәле үткән заман мәгънәсен белдерә: *Совет власте елларында 93,3 миллион кеше урта белем алды (= алган).*

4. Категорик үткән заман *булса кирәк, шикелле* кебек модаль чаралар белән кулланылса, фаразый үткән заманны белдерә: *Гаҗәпләнүем йөземә чыкты булса кирәк* (А. Шамов). *Ләкин төп сәбәпне әйтмәделәр шикелле* (Ә. Баян).

**Б.** Күчерелмә мәгънәләр. Алар контекстта үткән заман һәм хикәя фигыль мәгънәләренең нейтральләшүе нәтиҗәсендә барлыкка килә:

1. Киләчәк заман хикәя фигыль мәгънәсендә: *Мич турында киңәшмә була, хәзер туры шунда юнәлдем* (Ф. Кәрим).

2. Тиешле контекстта килеп, *-ды* формасы категорик үткән заман хәзерге заман мәгънәсен белдерә ала: *Сарык ите белән бик тәмле итеп аш пешердем, берәр тәлинкә ашап китәр идең, кая ашыктың шулай, дип кыстап карый Гыйльмениса* (Ф. Хөсни).

3. Хәрәкәт фигыльләре категорик үткән заманның I затында килеп, боерык мәгънәсен белдерәләр: *Бу бит кызыллар!.. Әйдә, йөгердек каршыларына* (Ш. Маннур).

Категорик үткән заманның күпмәгънәлелеге – аның контекстта күптөрле синтагматик, шул исәптән күчерелмә мәгънәләр белдерә алуы – бу форманың бик борынгы булуыннан килә.

**Нәтиҗәле үткән заман.** Нәтиҗәле үткән заман *-ган/-гән, -кан/-кән* кушымчалары белән ясала һәм I төр зат кушымчалары алып төрләнә.

| | Берлек сан | Күплек сан |
|---|---|---|
| I зат | *ал-ган-мын* | *ал-ган-быз* |
| II зат | *ал-ган-сың* | *ал-ган-сыз* |
| III зат | *ал-ган* | *ал-ган-нар* |

Татар телендә бу форма мәгънә киңлеге белән аерылып тора, чөнки кайбер төрки телләрдә аның функциясе өлешчә *-ып* кушымчалы үткән субъектив заманга күчкән: *алыпмын, килепсез, барыпсыз* һ.б. Соңгы форма татар диалектларында очрый.

Форманың парадигматик мәгънәсе: *-ган* кушымчалы форма үткән, әмма нәтиҗәсе хәзерге заман өчен актуаль булган эш-хәлләрне белдерә. Башкача әйткәндә, сөйләү моментына эш тәмамланган, һәм нәтиҗәсе хәзерге заманда дәвам итә: *Ул авылга к а й т к а н* (хәзер ул авылда); *Ул я ш ә р г ә н, м а т у р л а н г а н*. Бу мәгънә *-ды* формасы белән чагыштырганда күренә: *ул авылга к а й т т ы – ул авылга к а й т к а н*.

Н. Дмитриев әйтүенчә, нәтиҗәлелек – форманың төп мәгънәсе. Ягъни үткәндә булган билгеле бер эш яки хәл хәзерге вакыттагы нәтиҗәсе булу-булмавы ягыннан тасвирлана. Сөйләүченең төп игътибары эшнең элек үтәлешенә түгел, бәлки аның хәзерге вакыттагы нәтиҗәсе булу-булмавына юнәлгән [Дмитриев Н., 1948, с. 157–158]. Әгәр сөйләүче өчен, эшнең үтәлүеннән бигрәк, аның нәтиҗәсе әһәмиятле икән, ул эш яки хәл турында үзе күрмәгән килеш, башка кешеләр фикеренә яки сүзенә таянып та фикер йөртергә мөмкин. Бу очракта Б. Серебренниковның: беренчел мәгънә – нәтиҗәлелек, икенче мәгънә – шул нигездә туган билгесезлек [Серебренников Б., 1963, с. 20–21), дигән фикере әһәмиятле. Шул рәвешчә, заманның парадигматик мәгънәсе өч төрле семадан (мәгънә өлешеннән) гыйбарәт: эш-хәлнең сөйләү моментыннан алда булу, нәтиҗәлелек (сөйләү моменты белән контактта булу) һәм модаль сема – билгесезлек. Төп мәгънә – эш-хәлнең сөйләү моментыннан алда булуы; нәтиҗәлелек һәм билгесезлек берьюлы яки аерым-аерым белдерелә алалар.

1. Нәтиҗәлек мәгънәсе билгесезлек семасыннан башка да белдерелә ала: *Уйлап карасак, адәм баласы да – табигатьнең бик нәзберек, бик сизгер бер үсентесе ләбаса!.. Үсемлек сыман ул да билгеле бер төрдәге туфракка, суга, һавага к ү н е к к ә н* (М. Вәлиев). *Әле иртә, Әле караңгы, Әле буран шыңшый, т ы н м а г а н ... Бер сыңар кул ялгыз урам көри, Таң атканын к ө т е п т о р м а г а н . . .* (Р. Фәйзуллин).

2. Нәтиҗәлелек-билгесезлек, сөйләүченең эш-хәлне үзе күрмәгәнлеге, кешедән ишетеп сөйләве кебек семалар белән бергә килә ала: *Уфа нефть институтына имтихан б и р ә а л м а г а н да, авылына кайтып тормастан, Себер ягына с ы п ы р т к а н* (Ә. Еники). *Брянск юнәлешендәге әлеге мин сөйләгән сугышларда Галимҗан да б у л г а н и к ә н . Күршеләр генә булганбыз, очрашу бәхете генә э л ә к м ә г ә н* (Р. Төхфәтуллин).

Бу форма үткәндә булган вакыйгалар, берәр кешенең биографиясе турында сөйләгәндә кулланыла.

**Форманың синтагматик мәгънәләре.**

А. 1. *-ган* кушымчалы форма күптән үткән, билгесез заманны да белдерә ала. Бу мәгънә фольклор әсәрләрендә еш очрый: *«Борын заманда бер әби белән бабай б у л г а н , ди. Шуннан бер вакыт әби бер кыз к и т е р г ә н . Исемен Зөһрә дип к у ш к а н н а р ».*

2. Бу форма күптән үткән заман мәгънәсендә дә очрый: *Азат Гөлчирәгә карады: Гөлчирәнең йөзе с у л г а н* (Г. Әпсәләмов).

3. Үткән эш-хәлләрне киләчәктәге белән бәйләп белдерә ала: *...кайда гына булсак та, ни генә эшләсәк тә, үзебезне шулай тотарга тиешбез ки, киләчәк буын кешеләре безнең турыда – алар гасыр биеклегендә б у л г а н н а р , бүгенге көн хисләре белән генә э ш и т м ә г ә н н ә р , дошман өнендә дә дөньяга киң к а р а г а н н а р , киләчәкне к ү р г ә н н ә р , безнең турыда к а й г ы р т к а н н а р , дисеннәр* (Г. Әпсәләмов).

Ә. *-ган* кушымчалы форма күчерелмә мәгънәдә дә кулланыла ала һәм киңәйтелгән хәзерге заман мәгънәсен белдерә: *Тиле – тиле дигән саен тигәнәк буе с и к е р г ә н (= сикерә, сикерер). Өрә белмәгән эт өенә кунак ч а к ы р г а н .*

**Тәмамланмаган үткән заман (имперфект).** Бу заман *-а/-ә, -ый/-и + иде* формасы белән белдерелә һәм II төр зат кушымчалары алып төрләнә.

| | Берлек сан | Күплек сан |
|---|---|---|
| I зат | *ал-а иде-м* | *ал-а идек* |
| II зат | *ал-а иде-ң* | *ал-а-идегез* |
| III зат | *ал-а иде* | *а-ла иделәр / ал-а-лар иде* |

Мәгънәсенә килгәндә, карашлар шактый төрле. Н. Дмитриев бу заманның мәгънәсен, үткәннең билгеле бер вакытына караган, тәмамланмаган эш-хәлләрне белдерүдән гыйбарәт, дип саный [Дмитриев Н., 1948, с. 47], Ә. Юлдашев заманның төп мәгънәсе дип эшнең тәмамланмаган, билгеле, типик һәм тасвирлы булуын күрсәтә [Юлдашев А., 1965, с. 147], Б. Серебренников бу заманның үткәндә даими булып тора торган эш-хәлләрне белдерүен, вакыйгаларга күрсәтмәлелек, экспрессивлык төсмере бирүен күрсәтә [Серебренников Б., 1963, с. 47–56]. «Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе»ндә бу формага хас мәгънәләр дип, эш-хәлнең тәмамланмавы, дәвамлы булу яки кабатлануы һәм үткәннең билгеле бер вакытка караганлыгы күрсәтелә. *-ганда, -ды* кебек формалар яки сүзләр вакытка ишарәлиләр [Тумашева Д., 1965, б. 134–136]. Н. Салехова форманың мәгънәсен контекстка һәм фигыльнең лексик мәгънәсенә бәйләп өйрәнде. Форманың төп мәгънәләре дип, ул эш-хәлнең сөйләү моментыннан алда булуын һәм процесслык (эшнең агышы) мәгънәләрен күрсәтә; вариант мәгънәләре дип кабатлану һәм үткәндәге даими эшләрне гомумиләштерү, дип саный [Салехова Н., 1978, с. 76].

Парадигматик мәгънәсе: *-а иде* формасы сөйләү моментыннан алда булган эш яки хәлнең агышын һәм үткәннең билгеле бер вакытына беркетелгәнлеген белдерә: *Балачак. Кыш. Сугыш. Тәрәзәне Бодай башаклары к ү м ә  и д е . Шул башаклар арасында йөргән Әти күз алдына к и л ә  и д е* (Я. Игәнәй).

Чиксез фигыльләрдә бу заман эшнең дәвамлы булуына яки тәмамланмавына ишарә итә, чикле фигыльләр бу формада килгәндә, эшнең кабатлануы белдерелә: *Камәр түти исә олы табакка зур казаннан шулпа б у ш а т а , Шәйдулла ипи к и с ә  и д е* (М. Мәһдиев).

Эш-хәлнең агышын белдерә торган бу форма чиксез фигыльләр өчен аеруча уңай, һәм алар бу формада ешрак очрый: *елмая иде, ярата иде, хыяллана иде, сизә иде, уйлый иде, сизелеп тора иде, үсеп килә иде, көчәя бара иде* һ.б. *Һич оныта алмыйм, зур ачылган күзләре*

*тамарга торган шатлыктан б а л к ы й и д е аның, шул ук вакытта нindiдер шүрләүме, әллә шөбһәме ч а г ы л а и д е карашында* (Р. Төхфәтуллин). *Ахияр да, Кәшфи дә күккә текәлделәр. Өч җирдән өч почмак булып, коньякка таба торналар о ч а и д е* (М. Мәһдиев). *Анда такталарны шомарту станогы куелган, ике столяр стеналарга пыялалы буш стендлар к у е п м а т а ш а л а р и д е* (Г. Ахунов).

*Иде* ярдәмче фигыле тиңдәш хәбәрләр составында килгәндә, соңгысына гына кушыла ала: *Ул юк-барга тыкшынмый, завод директорының с ү з е н н ә н ч ы к м ы й , һәрвакыт килешеп эшләргә т ы р ы ш а и д е* (Э. Касыймов).

Тәмамланмаган үткән заманның борынгырак формасы да очрый: *Өйгә кайткач, әни мәрхүмә канаган тез башларын җылый-җылый каз мае белән м а й л а р и д е* (Г. Бәширов). Әдәби әсәрләрдә форманың диалектлар өчен хас варианты очрый: *Яшь чагында мин дә шулай җ ы р л ы й д ы р и д е м бит* (Ш. Камал). Шулай да *-р/-мас иде* кушымчалы форма *-а иде* белән ясалган формадан борынгырак, чөнки ул хәзерге заманның *-р/-мас* кушымчалы борынгырак формасына кайтып кала.

**Форманың синтагматик мәгънәләре.**

А. 1. Бу заман үткәндә булган даими яки гадәти эш-хәлләрне белдерә. Бу очракта *-а иде* формасы хәзерге заман белән мөнәсәбәттәш; әйтерсең, хәзерге заман үткәнгә күчерелгән: *Җәйгә кергәч, аны бөтенләй танып булмый, ү з г ә р ә и д е Бибинур, һәр тәрәзәне киң ачып куеп, өйне хуш ис белән т у т ы р а и д е . Сабан туйлары җитә башласа, йокысы, ялы о н ы т ы л а и д е* (А. Гыйләҗев). *Ул, малай булса да, кызлар арасында үскәнгә, курчак у й н ы й б е л ә и д е* (Г. Исхакый).

2. Эшнең субъектына хас даими билгесе, сыйфаты үткәнгә күчерелеп тасвирлана: *Атлаганда аяклары җиргә дә т и м и и д е* (М. Җәлил). *Язгы чәчү җиттеме, имтиханнарын алданрак т а п ш ы р а и д е дә туры «Игенче»гә к а й т ы п к и т ә , җәй айлары да эштә ү т ә и д е* (Р. Төхфәтуллин).

Ә. Форманың күчерелмә мәгънәләре.

1. *-а иде* формасы сөйләү моменты белән бер үк вакытта булган, нәкъ сөйләү моменты белән туры килгән эш-хәлләрне белдерә, ягъни хәзерге заман мәгънәсенә туры килә. *Әйдә, түрдән уз, туганкай,*

*менә мин эштән к а й т ы п  к ы н а  т о р а  и д е м әле, бу йонлы тәпиләрне салып куярга да өлгермәдем* (Г. Ахунов). *– Санияне телефонга чакырып булмасмы? – А в ы р ы п  т о р а  и д е шул* (сөйләм теленнән). *– Бәй, карт, нишләп болай кайтасы иттең? Яныңа барырга гына т о р а  и д е м , – диде Миңниса, мөмкин кадәр ягымлы тавыш белән* (А. Гыйләҗев).

2. Шарт фигыльле җөмләнең нәтиҗә өлешендә кулланыла: *Килеп тотмасам, егылып, бер-бер җирен б ә р м и - и м г ә т м и  к а л м ы й  и д е* (Х. Сарьян). *Күңелем  б у л м ы й  и д е , өй түреннән Тальян уйнап, җырлап үтмәсәм. Йөрәгемне борчу  б а с а  и д е , Син сөялеп мине көтмәсәң* (С. Хәким).

3. Кабатланган гадәти эш-хәлләрне белдерә: *Аэровокзал, гадәттәгечә колхоз базарыдай г ү л ә п  т о р а  и д е , «фәлән самолетның очуы фәлән вакытка кичектерелә» дип, х ә б ә р  с а л ы п  т о р а л а р  и д е* (Р. Төхфәтуллин).

**Күптән үткән заман.** Күптән үткән заман *-ган/-гән, -кан/-кән* формасына иде ярдәмче фигыле кушылып ясала һәм, II төр зат кушымчалары алып, төрләнә:

| | Берлек сан | Күплек сан |
|---|---|---|
| I зат | *ал-ган идем* | *ал-ган идек* |
| II зат | *ал-ган идең* | *ал-ган идегез* |
| III зат | *ал-ган иде* | *ал-ган-нар иде / алган иделәр* |

Заманның парадигматик мәгънәсе:

1. Икенче бер үткән заманнан алда булган эш-хәлләрне белдерә. Күптән үткән заман белән мөнәсәбәтле «икенче бер үткән заман» *-ды, -ганда* яки *-ган, -а иде* һ.б. кушымчалы формалар белән белдерелә: *Болар урамга  ч ы к к а н д а , Петербургның кыска эңгер-меңгер вакыт кергән урамнарына фонарьлар  я г ы л г а н  и д е* (Г. Исхакый). *Ашыгып залга  к е р д е к . Пәрдә  а ч ы л м а г а н  и д е әле* (Ә. Еники). *Моннан ничәдер еллар элек без синең белән очрашырга  с ө й л ә ш к ә н  и д е к* (Р. Төхфәтуллин). *Әскыйның малайлары да үзенә  о х ш а г а н  и д е* (М. Мәһдиев).

2. Күптән үткән заман формасының «икенче бер үткән» заман белән мөнәсәбәте төрлечә була. Югарыда китерелгән мисалларда бу формалар күптән үткән заманнан алда килгәнне белдерә. Ләкин фор-

малар тәртибе җөмләдә башкача да булырга мөмкин: ягъни башта төп эшне белдергән *-ган иде* формасы килә, аннан соң күптән үткән заманга бәйле икенче эш күрсәтелә. Бу очракта эшнең бүленгәнлеге белдерелә яки көтелгәннең киресе булырга мөмкин. *Кызның, бернигә дә карамастан, берни белән дә исәпләшмәстән, Хөсәеннең кочагына ташланасы килгән иде. Ләкин ниндидер көч аны тыелырга мәҗбүр итте* (А. Расих). *Әни ишек алдына утын алырга чыккан иде. Аның кочагына күтәргән утыны дөбердәп җиргә коелды* (Г. Ахунов). *Бүлмәмне ачып кергән идем, телефон чылтырады* (Г. Афзал).

3. Үткәннең билгеле бер вакытына караган эш-хәлләрне белдерә: *Шәңгәрәй яшь вакытта мәктәптә укыган иде* (Г. Ибраһимов). *Көннәрдән бер көн падишаһ сунарга чыккан иде* (Дәрдемәнд). Эш-хәлләрнең билгеле вакытына караганлыгы лексик чаралар белән күрсәтелә ала: *ул чакта, ике ел элек, теге вакытка, фәлән елны* һ.б. *Авария турында ишетү белән иң башта баш инженер килеп җитте. Мин аның турында нефтьчеләрдән – «бик таләпчән, принципиаль» дигән сүзләр ишеткән идем. Әмма ул кемне дә булса ачуланырга, битәрләргә керешмәде* (М. Вәлиев). Соңгы мисалда ике очрак та чагылыш тапкан: *-ган иде* формасыннан алдагы эш (*килеп җитте*) һәм аннан соң булган эш (*битәрләргә керешмәде*).

**Форманың синтагматик мәгънәләре**

А. 1. Бу форма хәзерге заман, ягъни сөйләү моменты өчен актуаль эш-хәлләрне белдерә. Татарчаны яхшы өйрәнгән һәм фигыль заманнары турында махсус хезмәт язган Б. Серебренников, *-ган иде* формасы үткәндә булган, ләкин хәзерге заман өчен актуаль эш-хәлләрне белдерә ала, дип язды [Серебренников Б., 1963, с. 98]. Мәсәлән: *Белем ягы аның әллә ни зур түгел, сугышка хәтле җиденче классны тәмамлаган иде* (Г. Ахунов).

2. Шулай ук бу форма үткәндә булган һәм сөйләү моменты өчен актуаль эш-хәлләрне дә белдерә ала: *Сине анда шоферлар югалткан иде. Ком юк, дип. – Төяп җибәрдем инде. Башка урыннан* (Ә. Баянов). Бу очракта күптән үткән заман урынына нәтиҗәле үткән заман кулланыла алыр иде (*Сине анда шоферлар югалткан*). *Ләйсән тәрәзәдән Мансурны күреп алган икән. – Карале, кара, анда әтием... Мансур да кызны шәйләп алган иде, елмаеп кулын болгады* (М. Әмирханов).

3. Эмоциональ бәяләү төсмере белән кулланыла: – *Чит авыллар димме? – Ие. Без Микулай дәдәйне эзләп* *к и л г ә н   и д е к*... *Син, Микулай дәдәй, сугышта безнең әтине* *к ү р г ә н с е ң   и к ә н*. *Шуны белергә* *к и л г ә н   и д е к* (Р. Хафизова). Катгыйлыкны киметү өчен, *килдек* урынына *-гән иде* формасы кулланылган.

4. *-ган иде* формасы – эмфаза чарасы, ягъни аерып күрсәтү өчен кулланыла: *Нишләптер, көйсез* *к а й т к а н   и д е* *бүген Гыйният* (Ф. Хөсни).

Ә. Бу заман күчерелмә мәгънәдә дә кулланыла ала: *-ган иде* формасы шарт фигыльле җөмләнең нәтиҗә өлешендә килеп, фаразый эшне белдерә һәм бу очракта *-р иде / -мас иде, -ган булыр иде* кебек формаларга якыная: *Лейтенант килеп кермәсә, аларның тормышлары куркыныч астында* *к а л г а н   и д е* *(калыр иде)* (Р. Ишморатова). *Әтисе кайтып кермәсә, Нәүфәл якты дөньядан* *к и т к ә н   и д е* *(= киткән булыр иде)* (М. Хәсәнов).

**Кабатлаулы үткән заман.** Бу заман хәзерге заман сыйфат фигыльнең (*-а, -ә, -ый, -и + торган*) аналитик формасына нигезләнә, аңа *иде* ярдәмче фигыле кушылып, икенче төр зат кушымчалары белән төрләнә:

| | Берлек сан | Күплек сан |
|---|---|---|
| I зат | *ал-а торган идем* | *ал-а торган идек* |
| II зат | *ал-а торган идең* | *ал-а торган идегез* |
| III зат | *ал-а торган иде* | *ал-а торганнар иде / ал-а торган иделәр* |

Бу форманың заманга каравы И. Гиганов (1801), М. Иванов (1842), М. Мәхмүтев (1857), А. Троянский (I860) төзегән грамматикаларда ук әйтелгән. Ләкин кайбер очракта аны эшнең үтәлү дәрәҗәсен белдерә торган формаларга кайтарып калдыралар. Ләкин бу формалар мәгънәләре белән аерыла: дәрәҗә белдерә торган *яза тору* фигыле эшнең билгеле бер вакыт эчендә дәвам итүен белдерә һәм төрле формаларда килә ала: *яза тор, яза торгач, яза торды* һ.б. Заман нигезе булган хәзерге заман сыйфат фигыльнең дәрәҗә мәгънәсе юк: *я з а   т о р г а н   кеше,* *у й н ы й   т о р г а н* *бала,* *й о к л ы й   т о р г а н* *бүлмә.*

Кабатлаулы үткән заман формасының парадигматик мәгънәсе: *-а торган иде* формасы үткәндә булган гадәти, типик яки кабатланган эш-хәлләрне белдерә: *Садри мәктәптән соң гына* *к а й т а   т о р г а н*

*иде. Акрын гына, ... шыгырдап кына капка ачыла, шуннан соң тәрәзә чиртә торган иде* (А. Әхмәт).

Эшнең гадәти, типик яки кабатлаулы булуы фигыль семантикасына бөтенләй үк бәйсез түгел:

1) чиксез хәл-торыш, аеруча яшәеш фигыльләрендә *-а торган иде* формасы үткәндәге гадәти, дәвамлы эш-хәлләрне белдерә: *Айсылу үзеннән күп яшь булса да, Тимери аның киңәшләрен үзенә хас беркатлылык белән тыңлый торган иде* (Г. Бәширов). *Андый авылларда кызлар чая була торганнар иде* (М. Мәһдиев). *Каюмның авторитеты иң алда тора торган иде* (Ш. Камал);

2) чикле, аеруча хәрәкәтне белдерүче фигыльләрдә бу форма үткәндә кабатланган эш-хәлләрне белдерә: *Ишледән базарга килүче берәрсе бик сирәк кенә әнисенең киндер чүпрәккә төреп җибәргән тары ипиен яки берәр йомарлам маен кертеп чыга торган иде* (Ә. Еники). *Күп көннәрне ул мине, чыннан да, шушында каршы ала торган иде* (Г. Бәширов).

**Кабатлаулы үткән заманның синтагматик мәгънәләре.** Башкаручы затның үткәнгә караган ниндидер эше, хәле яки даими билгесе белдерелә: *Инде укый калса, аның әйберсе башкаларныкы төсле зар еламыйча гына язылган, күбрәк табигать күренешләре гади генә сурәтләнгән яки үзенчә берәр тормыш фәлсәфәсе әйтергә тырышкан кыска гына шигъри парча булып чыга торган иде* (Ә. Еники). *Садри мәктәптән соң гына кайта торган иде. Акрын гына... шыгырдатып кына капка ачыла, шуннан соң... акрын гына тәрәзә чиртә торган иде. Әмин ... аның аяк атлауларыннан таный идем* (А. Әхмәт). *Язидә утын сүндерә дә тынычлап йокыга китә торган иде* (Г. Бәширов).

*-а торган иде* формасы татар телендә чагыштырмача соңрак барлыкка килгән (аның синонимик *-р иде* кушымчалы варианты хәзер сирәк кулланыла), шуңа күрә аның парадигматик һәм синтагматик мәгънәләре бер-берсенә кискен рәвештә каршы тормыйлар.

*-а торган иде* һәм *-а иде* формаларының семантик охшашлыгына һәм аермасына тукталыйк. Бу формалар кайбер очракта мәгънәләре белән бер-берсенә туры киләләр, ләкин тулысынча түгел.

1) Әгәр контекст эшнең кабатлануына, гадәтилегенә ишарә итсә, бу формалар бер-берсен алыштыра алалар: *Исәнтәй исә аның янына*

*бары уртак эш өчен янып йөргәнгә генә* *к и л ә  и д е* (Н. Фәттах) ~ *килә торган иде.* Ләкин бу очракта *-а торган иде* формасына хас кабатлану төсмере югала.

2) Кайбер очракта формалар параллель дә кулланыла: – *Кассада күпме акча* *к а л а  т о р г а н  и д е ? ..* – *Кассада, гадәттә, ун-унбиш меңнән артык* *к а л м ы й  и д е* (М. Насыйбуллин). *Нәни кызы белән дә көе барда гына* *у й н ы й  т о р г а н  и д е  у л ,* *бала елый башлады исә, хатынына я әнисенә илтеп* *т о т т ы р а  и д е* (М. Маликова).

Мәгънәсе белән охшаш формаларны алмаштырып куллану кабатланудан качу өчен түгел, бәлки *-а торган иде* формасы белән эшнең гадәтилеген, типиклыгын ассызыклап үтү өчен эшләнә.

3) Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: формаларны һәр очракта алмаштырып булмый, чөнки *-а торган иде* формасына кабатлану хас, *-а иде* формасы исә кабатлауны белдерергә дә, белдермәскә дә мөмкин.

4) Кайбер очракта *-а торган иде* формасының парадигматик мәгънәсе *-а иде* формасының синтагматик мәгънәсе белән туры килергә мөмкин. Икенче бер очракта алар синтагматик мәгънәләрнең берсендә туры килергә мөмкин: *Ул русчаны яхшы* *б е л ә  т о р г а н  и д е* (М. Галәү). *Ул үлән һәм агач исемнәрен татарча гына* *б е л ә  и д е* (М. Юныс). Димәк, *-а торган иде* һәм *-а иде* формалары – мөстәкыйль заманнарны белдереп, үзара синонимик мөнәсәбәттә торалар.

### *Киләчәк заман формалары*

**I (билгесез) киләчәк заман.** Бу заман *-р/-мас* кушымчалары белән ясала һәм I төр зат кушымчалары *-мын/-мен, -сың/-сең, -быз/-без, -сыз/-сез, -лар/-ләр* алып төрләнә:

| | Берлек сан | Күплек сан |
|---|---|---|
| I зат | *ал-ыр -мын* | *ал-ыр-быз* |
| II зат | *ал-ыр-сың* | *ал-ыр-сыз* |
| III зат | *ал-ыр* | *ал-ыр-лар* |

Заманның парадигматик мәгънәсе: *-р/-мас* кушымчалы билгесез киләчәк заман сөйләү моментыннан соң булачак эш-хәлләрне белдерә һәм *-ачак/-әчәк, -ячак/-ячәк* кушымчалы билгеле, категорик (катгый киләчәк) заманга каршы куела. Алар арасындагы оппозиция (катгыйлык – бу мәгънәнең юклыгы; билгелелек – билгесезлек/фаразыйлык)

ягыннан *-р/-мас* формасы тамгаланмаган (билгесез) төр буларак кабул ителә, ягъни ул билгелелекне дә, билгесезлекне дә белдерә ала. Димәк, ул (форма буларак) семантик яктан *-ачак* формасыннан баерак. Аның күпмәгънәлелеге тарихи яктан да раслана, чөнки *-р/-мас* – кушымчалы заман төрки телләрнең иң борынгы заман формаларыннан санала.

Заманның парадигматик мәгънәсе – модаль яктан тамгаланмаган, сөйләү моментыннан соң булачак эш-хәлләрне белдерү: *Яз килер, Карлар эрер, Бозлар китәрләр, Тау битләре ачылыр, Безнең кырда Зәңгәр гөлләр күкрәп үсәрләр* (Һ. Такташ). *Ир сәфәрдә беленер. Ат чанада беленер* (мәкаль. Н. Исәнбәт).

**Форманың синтагматик мәгънәләре:**

А. 1. Билгесез киләчәк заман сөйләү моментыннан соң булачак эш-хәлне билгесезлек, фаразыйлык төсмере белән белдерә: *Бәлки тагын очрашырбыз әле* (Х. Туфан). *Укытучылыкны да ташларга туры килер, ахрысы* (А. Расих). *Пәйда булса күктә бәла кошы, Яшен сукса өмет-хыялымны, Туган яктан килер якты аваз, Томаннардан арындырыр юлны* (З. Хәким).

Китерелгән мисалларда фаразыйлык *бәлки, ахры* кебек модаль сүзләр һәм шарт фигыль белән ассызыкланган.

2. Бу заман контекст ярдәмендә эш-хәлнең катгыйлыгын да белдерә: *Җиңеп кайтырбыз, җиңүдә бөтен киләчәк!* (Ф. Кәрим) *...мин үләрмен, ләкин безнең түккән каннар әрәм китмәс, безнең чиккән газаплар... дошманның таш крепостьларын җимерерләр, дөньяга азатлык тудырырлар* (Г. Ибраһимов).

3. Тарихи яктан, *-р/-мас* кушымчалы форма хәзерге заманны да белдергән, анын эзләре хәзерге телдә дә саклана: *Ишек янындагы менә шундый агач сәкедә аларның зур-зур толыплары ятыр... Ул толыплар янында шыплап тулган төрле-төрле пичкәләр, кулёклар булыр... Авылга дигән ипи буханкалары бәләкәй генә тау сымак иттереп өеп куелыр...* (М. Вәли).

4. Бу формадан тәмамланмаган үткән заманның *-р иде* кушымчалы икенче төре ясалган булган: *Дәрийгъ, бер гомер икән сөргән әле без, йөрер бергә, көлер-уйнар идек без... Бу көндә Сак белән Соклар кебек без* (Дәрдемәнд) (~ *йөри, көлә-уйный идек*).

Ә. Форманың күчерелмә мәгънәләре. Контекстка бәйле *-р/-мас* формасы мөмкинлек, боеру, үтенү кебек модаль мәгънәләр дә белдерә.

*Ашарга ярата да инде ул, кызыгып карап торырсың* (А. Гыйләҗев). *Әгәренки колак салсаң, төннәре ул яктан дөп-дөп иткән фашист аяк тавышын ишетерсең* (Г. Бәширов). Боеру: *Кешеләр күренүгә куангандай, җигүле килеш ни гомер капка төбендә торган ат, тимерләрен шалтыратып, башын чайкап куйды. ... – Толыпка төренеп утырырсың, толып яңа* (Р. Мөхәммәдиев).

**II (билгеле яки катгый) киләчәк заман.** Бу заман *-ачак/-әчәк, -ячак/-ячәк* кушымчалары белән ясала һәм I төр зат кушымчалары алып төрләнә:

| | Берлек | Күплек |
|---|---|---|
| I зат | *ал-ачак-мын* | *ал-ачак-быз* |
| II зат | *ал-ачак-сың* | *ал-ачак-сыз* |
| III зат | *ал-ачак* | *ал-ачак-лар* |

Киләчәк заманның икенче формасы сөйләү моментыннан соң булачак эш-хәлне катгыйлык төсмере белән белдерә: *Ял! Юк инде, мин бу елны тарихчыларда борынгы Россия җәмгыяте буенча семинар дәресләре алып барачакмын* (Э. Касыймов). *Сез белмисез бит, белергә теләмисез дә: мин сезне бик сагыначакмын, озак сагыначакмын* (Г. Әпсәләмов). *Салих әйтә: бу озакка бармаячак, тиздән татар театрының үз бинасы булачак, ди. Милли сәнгатькә хәзер киң юл ачылачак. ... Ә театрга без, насыйп булса, иртәгә барачакбыз. Салихка хәбәр итә алмадык инде, ләкин ул мине барыбер көтәчәк. Әйе, көтәчәк!* (Ә. Еники). *Моннан соң ул, ничаклы тырышса да, артык сикерә алмаячак* (Ф. Хөсни).

Заманның юклык формасы фигыльдә кулланыла торган *-ма/-мә* кушымчасы белән белдерелә: *Мин, унҗидегә чыккан егет, малайга охшамаячакмын моннан ары* (Р. Төхфәтуллин). Ләкин юклыкны катгыйлык төсмере белән бирү өчен *түгел* кисәкчәсе дә кулланыла: *Нәүфәл бу хакта сөйләшәчәк түгел* (М. Хәсәнов) (~ *сөйләшмәячәк*). Бик сирәк очракларда *юк* модаль сүзе кулланыла: *Әби... җәйнең ямьле вакытларында ... шушы өйгә кайта, ташлый алмый балалар туып үскән изге нигезне. Ташлый алачагы да юк* (Ә. Баян). Шул ук мәгънәдә *-асы юк* әйләнмәсе файдаланыла*: Сәер бишмәт иде ул. Авыл җирендә андыйны гомер тектерәселәре юк* (К. Тимбикова).

*-ачак* кушымчалы заман формасы мәгънә төсмерләренә бай түгел.

**Киләчәк үткән заман.** Киләчәк үткән заман хикәя фигыль *-ачак* кушымчалы сыйфат фигыльгә *иде* ярдәмче фигыле кушылып ясала һәм II төр зат кушымчалары алып төрләнә:

| | Берлек | Күплек |
|---|---|---|
| I зат | *ал-ачак идем* | *ал-ачак идек* |
| II зат | *ал-ачак идең* | *ал-ачак идегез* |
| III зат | *ал-ачак иде* | *ал-ачаклар иде/ ал-ачак иделәр* |

Бу форма киләчәктә үтәләсе, үтәлергә тиеш булган эшне үткәнгә күчерү өчен кулланыла. Шул рәвешчә, *-ачак иде* формасының мәгънәсе сөйләү моментына мөнәсәбәттә түгел, бәлки үткәннең билгеле моментына нисбәттә билгеләнә: *Тәнәфес игълан ителде, аннары концерт булачак иде* (Ш. Маннур). *Моны кем генә күрсә дә, совет солдатларының батырлыгына сокланачак иде* (Н. Дәүли). *Рәхим анысына да каршы килмәде. Чөнки, аның фикеренчә, хәзер һәр адым файда китерәчәк иде* ( А. Расих).

Киләчәктә үтәләсе эшне үткәннең билгеле бер вакытына күчерү *-ачак иде* формасының реаль эш-хәлне белдерүен инкяр итми. Моны М. Мәһдиевнең «Без – кырык беренче ел балалары» исемле повестеннән алынган өзектән бик ачык күреп була. Педучилище студенткасы сеңелләренә күчтәнәч алып, товарный поездга утырып авылга кайтмакчы була, ләкин көтмәгәндә, паровоз тирәсендә шланг тотып йөрүчеләр аны су белән коендыралар. Өши башлагач, ул әҗәткә алган унике сумны кайтара алмавын, күчтәнәчкә алган рулетның әрәм булачагын, бәйрәмнән соң диктант буласын исенә төшерә... шунда кинәт аны күреп алалар: *– Я, куян баласы, син нишләп төнлә йөрисең? – Баязитова курыкмады. Хәзер ул исән калачак, сеңелләренә рулетны алып кайтачак, Әлтафига әҗәтен түләячәк һәм диктант дәресенә дә кайтып җитәчәк иде.*

Шул рәвешчә, *-ачак иде* формасы реаль эшне белдерә, ләкин аның реальме-түгелме икәнлеге сөйләү моментына мөнәсәбәттә түгел, бәлки үткәннең билгеле вакытына мөнәсәбәттә каралырга тиеш. Югарыда тасвирланган ситуациядә *-ачак иде* белән белдерелгән процесслар реаль, алар тормышка ашачак. Ләкин *-ачак иде* формасы өчен эшнең һичшиксез үтәлергә тиешлек мәгънәсе мәҗбүри түгел. Шулай ук *«Ленар бүтән килмәячәк»* дигәндә, без моңа ахырына хәтле ышана

алмыйбыз. Киләчәк заман белән хәтта логик яктан реаль булмаган эшне дә белдереп була: *Ачулансак, шлем киертербез айга да* (Һ. Такташ).

### Сирәк кулланыла торган (архаиклашкан) заман формалары

***-р/-мас* кушымчалы гадәти хәзерге заман.** *-р/-мас* кушымчалы заман – төрки телләрнең иң борынгы формаларыннан берсе. Башта ул хәзерге һәм киләчәк заманнарның күптөрле мәгънә төсмерләрен белдергән һәм киң мәгънәгә ия булган категорик үткән заманга каршы куелган. Вакытлар үтү белән татар һәм күп кенә төрки телләрдә *-р/-мас* формасы фәкать киләчәк заманны гына белдерә башлый, хәзерге заман исә татар телендә *-а/-ә, -ый/-и* кушымчалы формага күчә. Хәзерге заман мәгънәсендә *-р/-мас* формасын куллану хәзерге татар әдәби телендә бик сирәк очрый, һәм стилистик функция үти.

Форманың хәзерге заман мәгънәсендә кулланылуына кайбер мисаллар китерик:

1. Даими һәм гадәти эш-хәлләрне белдерә: *Безнең өстәлдә һәрвакыт ап-ак җәймә җәелгән булыр, һәркемнең алдына күк читле җитен тастымаллар куелыр, савыт-сабалар... җемелдәп тезелешеп торыр* (А. Гыйләҗев).

2. Даими эш-хәлне кешегә яки предметка хас билге итеп белдерә: *Шуның өстенә тагын гадел: берәүгә карата да шәхси мөнәсәбәттән чыгып эш итмәс* (М. Әмир). *Ләкин Хәмдия дә каты серле. Авызын ачып кешегә ләм-мим чыгармас* (Ф. Хөсни).

3. Мәкаль, әйтем, фразеологик әйләнмәләрдә киңәйтелгән хәзерге заман мәгънәсенә якын, хәтта заманга битараф мәгънәсендә килә. *Алтын-көмеш җирдә ятмас. Ат аяган ат менәр, тун аяган тун кияр.*

4. Конкрет хәзерге заман мәгънәсендә сирәк очрый: *Исәрме җил... тугай буйлап, Җырлармы кыз, моңын сөйләп, Көләрме шатланып, көйләп, – Агач, таш эчләре шаңрап, Киләдер бер нида яңрап* (Дәрдемәнд).

***-р/-мас иде* кушымчалы тәмамланмаган үткән заман (икенче имперфект).** Хәзерге заман мәгънәсендә килгән *-р/-мас* формасына *иде* ярдәмче фигыле өстәлеп, икенче имперфект формасы ясала.

| | Берлек | Күплек |
|---|---|---|
| I зат | *ал-ыр идем* | *ал-ыр идек* |
| II зат | *ал-ыр идең* | *ал-ыр идегез* |
| III зат | *ал-ыр иде* | *ал-ыр иделәр / ал-ырлар иде* |

Хәзерге әдәби татар телендә бу форма сирәк кулланыла һәм гадәти яки кабатланган эш-хәлләрне белдерә. Бу мәгънәдә ул *-а иде* кушымчалы имперфектка һәм *-а торган иде* кушымчалы кабатлаулы үткән заманга синонимик мөнәсәбәттә тора.

### Башка фигыль формаларының темпоральлеге

**Хикәя фигыльгә синонимик мөнәсәбәттә булган темпораль мәгънәле тасвирлама (перифрастик) формалар.** Татар телендә шактый санда тасвирлама, ягъни перифрастик формалар кулланыла. Алар төп фигыльнең заман формалары нигезенә *бул-* ярдәмче фигыле өстәлеп ясала [Тумашева Д., 1965, б. 147–154].

Тасвирлама формалары ике төргә аерыла: 1) заман мәгънәсен белдерә торган формалар; 2) модаль мәгънә белдерә торган формалар.

1. Тасвирлама формаларның ясалыш буенча түбәндәге төркемнәрен билгеләп үтәргә мөмкин:

*-ган бул-* төркеменә караган тасвирлама формалар: *-ган була (иде), -ган булды, -ган булган (иде), -ган була торган (иде), -ган булыр (иде), -ган булачак (иде), -ган бул, -ган булса, -ган булып, -ган булуы* һ.б.

*-а торган бул-* төркеменә караган тасвирлама формалар: *-а торган була (иде), -а торган булды, -а торган булса* һ.б.

*-р/-мас бул-*

*-ачак бул-* төркеме: *-ачак була, -ачак булды, -ачак булган, -ачак булса* һ.б.

*-а бул-* төркеме (сирәк кулланыла): *-а була, -а булыр, -а булып*.

2. Бу формалар бер үк вакытта модаль мәгънәләрне дә белдерә алалар. Контекст һәм интонация ярдәмендә сөйләүченең эшкә карата ризасызлыгын, ирониясен белдерәләр: *Мин дә, юләр, бензин әрәм итеп, машина пычратып, а л ы п  б а р г а н  б у л д ы м* (Ф. Хөсни). *Мин өстәл кырыенда юл дәфтәремә язып у т ы р г а н  б у л а м* (И. Гази). *Аркаларын сыйпап ал, ял төпләрен к а ш ы г а н  б у л* (Г. Бәширов). *Ү п к ә л ә г ә н  б у л д ы тагын* (Г. Ибраһимов). *Башыңны дураклыкка салып к ы л а н г а н  б у л м а, яме?* (Ф. Хөсни). *Син ш а я р г а н*

*б у л а с ы ң , егет, ләкин эчең тулы ут* (Ә. Баянов). *Нух та чыгып, килеп т о т ы н г а н б у л д ы* (Х. Сарьян). *...Яратам дигән була, өрмәгән урыннарга да утыртмам д и г ә н б у л а* (халык җыры).

*Бул* ярдәмче фигыле бу төзелмәләрдә төрле формада килә ала. Бу урында ул, нигездә, хикәя фигыль төрендә алыначак[1].

***-ган бул-* тасвирлама формасы.**

1. *-ган була*. Бу форма:

а) нәтиҗәлелекнең хәзерге заманга нисбәтле булуын һәм гадәтилек яки кабатлану мәгънәләрен белдерә: *Төн буе йөреп урамда Җил инде а р г а н б у л а . Ял итә иртән агачлар, Куе бәс с а р г а н б у л а* (С. Хәким). *Шушы тыкрыкның берсендә... бәләкәй генә агач йорт бар. Аның кыйшаеп беткән капкасы төбендә чәчәк сатучы Мортаза бабай у т ы р г а н б у л а . Әнә бүген дә ул шунда* (Г. Әпсәләмов);

ә) нәтиҗәлелек үткәннең билгеле бер вакытына карый: *Аю-Мамактан элегрәк Сылу-кызны тузбашлардан Йәрмәк улы Камаш с о р а г а н б у л а . Кызым яшь дип, Баян карт аны кире б о р ы п җ и б ә р г ә н б у л а* (Н. Фәттах);

б) нәтиҗәлелек киләчәк заманга карый: *Сине шәһәргә алма сатырга озатырбыз. Барырсың бит? – Барырмын да ..., мин бит әле кечкенә. – Соң бит син ул чакта дәү ү с к ә н б у л а с ы ң* (И. Гази).

Шул рәвешчә *-ган була* формасы нәтиҗәлелекне хәзерге, үткән һәм киләчәк заманнарга күчерә.

2. *-ган булыр*. Бу тасвирлама форманың берничә мәгънәсе бар:

а) *-ган* кушымчалы формага хас нәтиҗәлелекне киләчәкнең билгеле бер вакытына күчерә: *Шаулар урман, ләкин ул чакта Бу кырларда туплар шартламас, Игеннәрне танк таптамас. Ч и г е н г ә н н ә р б у л ы р еракка* (Ф. Кәрим);

ә) нәтиҗәлелекне хәзерге заманга күчерә һәм эшнең гадәти яки кабатланган булуына ишарә итә: *Әнкәй күмәч җибәрә, Кем килсә дә авылдан... Күмәче у ң г а н б у л ы р , К ү п е р е п т о р г а н б у л ы р . Һәрбер күзәнәгенә Бер кояш с е ң г ә н б у л ы р* (Ф. Яруллин).

3. *-ган булачак* формасы *-ган булыр* формасына синоним була һәм соңгысыннан катгыйлык һәм киләчәккә каравы белән аерылып

[1] Тулырак мәгълүмат һәм тасвирлама формаларның өйрәнелү тарихы Д. Тумашеваның «Перифрастические формы татарского глагола» мәкаләсендә бирелә [Тумашева Д., 1965, с. 147–184].

тора: Ул *кайтканчы, Рушад җәйге сессиягә* *киткән булачак* (М. Мәһдиев).

4. *-ган булган* тасвирлама формасы *-ган иде* кушымчалы күптән үткән заман хикәя фигыль мәгънәсен билгесезлек төсмере белән белдерә һәм бу яктан билгелелекне белдергән кушымчалы күптән үткән заманга каршы куела: *Гафиятулла әйләнеп кайтканда, Кушкаенда инде төп хуҗа булып совет власте* *утырган булган* (Ф. Хөсни) *~ утырган иде. Галиәкбәр абзый минем нинди хәлдә калуымны белгәч тә, Даутовка барып сөйләгән. Алар 14 нче – 15 нче елларны Бондюг заводында бергә* *эшләгән булганнар* (Г. Кутуй) *~ эшләгән иделәр / эшләгәннәр иде.*

Б. Серебренников «Система времен татарского глагола» исемле хезмәтендә *-ган булган* формасының аерым заман белдермәвен, фәкать экспрессив чара буларак кулланылуын таный: *Кайсы авылныкы булса да, хатын-кыз – хатын-кыз инде ул. Буровойда эшләр өчен бик зур физик көч кирәк, анда эш бик авыр. Рәхмәт, кызлар, рәхмәт, матур теләк белән* *килгән булгансыз* (А. Әхмәт) [Серебренников Б., 1963, с. 48].

5. *-ган була иде* тасвирлама формасы нәтиҗәлелек мәгънәсен үткәннең билгеле бер вакытына караган һәм кабатланган яки гадәти эш-хәлләрне белдерә: *Прокламацияләрнең икенче битендә немец фронты аша узарга пропуск та* *язылган була иде* (Н. Дәүли).

6. *-ган булган иде* формасы күптән үткән заманга караган нәтиҗәлелекне билгелелек төсмере белән белдерә: *Районга озаттым да, тукта, мин әйтәм, төшкә хәтле бераз селкенеп керим әле, дип, бакчага* *чыккан булган идем* (Ф. Хөсни).

7. *-ган булды* тасвирлама формасы нәтиҗәлелек һәм билгелелекне үткән заманга күчерә (билгесезлек мәгънәсе сакланмый): *Егетнең өс-башына да бераз культура йокты: майка өстеннән күлмәк киеп йөри башлады, пиджак-чалбар* *үтүкләнгән, чистартылган булды*, *моңарчы тузгытып йөргән чәчләрен дә матур гына итеп тарап куярга өйрәнде* (Ә. Еники).

8. *-а торган бул-* тасвирлама формасы:

1) *-а торган була* формасы кабатланган яки гадәти эш-хәлне предмет яки затка караган даими билге итеп белдерә: *Ерык авыздан кирәксез сүзләр* *коела торган була*. *Мин моны белә идем* (А. Гыйләҗев).

*Кыш көне агроном боларны укытканда ук әйткән иде: кояшта җылыткачыннан бодайның бәпчеге уяна икән дә, тишелмәстәй орлык та т и ш е л ә  т о р г а н  б у л а икән* (Г. Бәширов);

2) *-а торган булды* тасвирлама формасы предметка яки башкаручыга караган билгенең үсешен яки кабатлануын белдерә: а) *Кирәк-кирәксезгә бик еш сигарет к а б ы з а  т о р г а н  б у л д ы* (М. Мәһдиев); ә) *Күбрәк гомерен шул подвалдагы бүлмәсендә у з д ы р а  т о р г а н  б у л д ы* (М. Әмир). *Фәрит һәр көнне диярлек, кичен клубтан, я колхоз идарәсеннән кайтышлый. Язидәнең капка төбенә утырып, бер тәмәке т а р т а  т о р г а н  б у л д ы* (Г. Бәширов);

3) *-а торган булган* формасы ике төрле мәгънә белдерә: а) кабатлаулы үткән заман мәгънәсенә билгесезлек төсмере өсти: *Мәскәүдән аңа академиклар, профессорлар к и л ә  т о р г а н  б у л г а н ~ килә торган иде;* ә) *Борын заманнарда картлар шундый чибәр кызларны: «Болар болгар нәселеннән, сөякләре асыл аларның» дип м а к т ы й  т о р г а н  б у л г а н н а р* (Г. Әпсәләмов). *Алар азык эзләп, бер урыннан икенче урынга күчеп й ө р и  т о р г а н  б у л г а н н а р* (Г. Бәширов). (Кабатлаулы үткән заман формасы белән чагыштырыгыз: *йөри торганнар иде*);

4) *-а торган булачак* формасы сирәк кулланыла: *Айдар һәм аның иптәшләре сала торган өй – ул бөтенләй башка. Ул алты почмаклы гына түгел, ул – зур, ул – якты, кешенең кешелек хисләрен т о м а л а п  к а л д ы р м ы й  т о р г а н  б у л а ч а к ,  ул безнең барыбызныкы да булачак* (Ф. Хөсни).

***-р/-мас бул-* тасвирлама формасы.** *-р/-мас булган* форма сыйфат фигыль белән белдерелгән билгенең барлыкка килүен, үсешен, яңа сыйфатка күчүен белдерә: *...Ахырда бөтенләй терелгән, башы с е л к е н м ә с  б у л г а н ,  аягындагы яра урыны бөтенләй ямалган* (Ф. Хөсни). *Берничә битен ачкач, инде аннан а е р ы л м а с  б у л д ы м* (Д. Зөбәерова). *С ө я р  б у л с а ң ,  бир вәгъдәңне, С ө й м ә с  б у л с а ң ,  алдашма* (халык җыры). *Ләкин крестьянның төп катламы бу хәлдән соң үз эченә йомылып, мыштым гына й ө р е р  б у л д ы* (Ә. Фәйзи). *Шул көннән башлап күрше әтәче сарай астыннан ч ы к м а с  б у л г а н ...* (А. Гыйләҗев).

*-ачак бул-* тасвирлама формасы ике төрдә кулланыла: *-ачак булган, -ачак булды. Прокурорны, секретарьны к ү р ә ч ә к  б у л г а н*

(Ш. Камал). *Булатлар шунда, капка төбендә аны к ө т ә ч ә к б у л д ы л а р* (Г. Ибраһимов).

*-а бул-* тасвирлама формасы сирәк кулланыла һәм аның *-а/-ә, -ый/-и + булган* төре генә очрый.

*-а булган* тасвирлама формасын *-а иде* кушымчалы тәмамланмаган үткән заман белән чагыштырып булыр иде, аерма шунда гына: тасвирлама формага билгесезлек төсмере хас. *Ул сугыш башланган елда Киевта художество институтының соңгы курсында укыган һәм инде диплом эшен б е т е р е п к и л ә б у л г а н* (Н. Дәүли).

***-ган бар/-ган юк* конструкциясе.** Бу тезмә форма И. Гиганов тарафыннан язылган һәм Санкт-Петербургта 1801 елда басылган беренче «Татар теле грамматикасы»нда ук телгә алына. Алга таба аны М. Иванов үзенең грамматикасында китерә һәм, билгесез күптән үткән заман, дип атый. 1970 елларда башкорт теле нигезендә бу форманы Ә. Юлдашев тикшерә һәм мәгънәсен, вакыты анык булмаган үткән замандагы эшне белдерү, дип күрсәтә [Юлдашев А., 1965, с. 159–167].

Б. Серебренников *караганым бар, күргәнем юк* сүзтезмәләрен, эмфаза (аерып күрсәтү) чарасы буларак кулланыла, дигән нәтиҗә ясый [Серебренников Б., 1963, с. 31].

Формаль яктан конструкциянең дүрт варианты күзәтелә:

1. Башкаручы зат *-ган* формасына тартым кушымчасы өстәлү һәм исемне яки алмашлыкны иялек килешенә кую юлы белән белдерелә: *Еланнарның ч ы к к а н ы б а р каршыма, – Мин аларның баса беләм башына!* (Р. Әхмәтҗанов).

2. Башкаручы зат тартым кушымчалары белән генә белдерелә: *Мамалый балын э ч к ә н е м ю к и д е, шулай икән шул, барысын да юып төшерә икән* (Ф. Хөсни).

3. Башкаручы зат I һәм II зат кушымчаларының иялек килеше белән белдерелә: *Минем әле алар турында бит ярты сүз дә я з г а н ю к ә л е...* (Х. Туфан).

4. Сирәк очракта башкаручы зат баш килештәге алмашлык белән һәм *-ган* формасына ялганган тартым кушымчалары белән белдерелә: *Иллә мәгәр шүрәленең бер чүлмәк бирүе хак. М и н д ә и ш е т к ә н е м б а р* (Н. Исәнбәт). *Унга алты нарат бүрәнәле өйне к а й с ы г ы з с а л г а н ы б а р ?* (М. Мәһдиев). *Мин бит сезнең тәкъдимгә берничек тә җ а в а п б и р г ә н е м ю к ә л е* (Г. Әпсәләмов).

Л. Мәхмүтова *-ган бар / -ган юк* формасының мишәр диалектында түбәндәге вариантлары табылуын күрсәтә: *минем барганым юк / барганым юк, минем барган юк / мин барган юк* [Махмутова Л., 1978, с. 149].

Әдәби телдә кулланылган вариантларны тикшерү өчен мисалларны карап үтик: *Симет елгасының ярын күргәнегез бармы?* (М. Мәһдиев). *Судта булганы бармы?* (Г. Бәширов). *Алар арасында әле беркайчан мондый сөйләшү булганы юк иде* (Н. Фәттах). *Кичә кич шәһәрдән бик соң кайтып яткан. Әле торганы юк* (Н. Исәнбәт).

Мисаллардан *-ган бар / -ган юк* формасының, беренчедән, үткәннең билгесез вакытына караган эш-хәлне белдерүе күренә, икенчедән, ул, *-ган* кушымчалы формадан (перфекттан) билгеле эш-хәлне белдерүе белән аерылып тора һәм бу мәгънәсе белән *-ды* кушымчалы (билгеле) үткән заманга синоним мөнәсәбәтендә тора. Өченчедән, *-ган бар / -ган юк* катлаулы конструкциянең *-ган* формасы белән охшаш яклары бар: ул эшнең булу яки булмавын констатацияли, ягъни аны факт итеп күрсәтә; дүртенчедән, ул аспектуаль яктан тамгаланмаган – димәк, бер тапкыр булган эш-хәлләрне генә түгел, бәлки кабатланган эш-хәлләрне дә белдерә ала.

Ә. Юлдашев бу катлаулы форманың (конструкциянең) лексик мәгънәдән бәйсез булуын (ягъни һәрбер фигыльдән ясала алуын) һәм башка үткән заманнар белән мөнәсәбәттә торуын исәпкә алып, аны үткән заманның аерым бер формасы итеп таный [Юлдашев А., 1965, с. 159–160]. Ләкин конструкциянең төзелеше (*-ган бар / -ган юк*) индикатив, ягъни хикәя фигыльдән аерылып торганга, һәм исем белән охшаш булганга, аны хикәя фигыль формалары дип түгел, бәлки заманның функциональ семантик кырында торучы бер форма итеп карарга кирәктер.

*-ган(ы) бар иде* конструкциясе *-ган иде* кушымчалы күптән үткән заманга синоним булып тора.

Карап узган катлаулы формаларның синонимик вариантлары бар: *-ган* (+ тартым кушымчалары) һәм *бул-/булма-* фигыле (*-ды, -ган, -ган иде* формаларында). *Бу бәндәне элек күргәнем булмады* (А. Расих). *Дәүләтшинның ярдәм сорап профессор Ильясовага мөрәҗәгать иткәне булмаган икән* (М. Маликова). *Күргәнем*

*булмады, мөрәҗәгать иткәне булмаган* төрләр *-ган(ы) юк иде* конструкцияләренә синоним булып торалар. Алар арасындагы аерма түбәндәгедән гыйбарәт: *-ган(ы) юк иде* формасы кабатлауга битараф, ягъни бу яктан тамгаланмаган, димәк кабатланмаган һәм кабатланган процессларны белдерә ала. *-ган(ы) бар иде // -ган(ы) юк иде* формасына билгелелек хас булса, *-ганы булган / -ганы булмаган* тезмәләренә билгесезлек төсмере өстәлә.

*-ган юк* формасының билгесез затка каравы мөмкин. Контекстта ул сөйләүчегә карый, ләкин зат белдерелмәгәнгә, эшнең үзеннән-үзе башкарылуы, сөйләүче ихтыярыннан бәйсез булуы кебек мәгънәләр туа: *Нәрсәдер төптән үк, тамырдан ук үзгәрде. Ни уйларга белгән дә юк* (А. Гыйләҗев). *Барысы да, Миңлебай җаным, күз алдымда бит... Инде көненә бер сынык икмәксез ач утырган көннәрегез турында әйткән дә юк инде* (А. Расих), *-ган бар, -ган юк* формалары, *иде* ярдәмче фигыле белән килеп, үткән заманны да белдерә алалар: *Бик зур рәхмәт сезгә, туганнарым. Бик күптән шулай рәхәтләнеп сөйләшкән юк иде,– диде Мостай ага* (Г. Ахунов).

*Бар, юк* сүзләре белән ясалып, темпораль мәгънәгә ия булган башка аналитик төрләр дә очрый: *үгетлим юк, ташлый алачагы да юк, гомердә тектерәселәре юк*. Бу формалар һәм диалекталь *-ды(-м, -ң-) юк* формасы киләчәк эш-хәлне катгый рәвештә инкяр итү өчен кулланыла.

Югарыда күрсәтелгән аналитик формалар юклыкта килгәннәр, фәкать *-асы/-әсе, -ыйсы/-исе* формасы белән ясалган төрләрнең генә барлык формасы була: *күлмәк тектерәселәре бар, хат язасым бар, баланы бакчадан алып кайтасы бар.*

**-у һәм -ш кушымчалы исем фигыльләрнең хәбәр функциясендә килүе.** *-у/-ү* һәм *-ш* кушымчалы исем фигыльләр хәбәр хезмәтен үти алалар.

1. Тартымлы һәм тартымсыз исем фигыль хәбәр булып килә, башкаручы зат тартым кушымчасыннан аңлашыла: *Кайбер пошмас инженерларны селкеп карарга исәп. Шул хакта Мәскәүгә баруым* (Җ. Рәхимов). *Үзе куанычыннан чи-и итеп көлеп җибәрер, төн буе урманда тып-тып шуның чабуы* (Н. Исәнбәт).

2. – *Әә, Сәхәбин. Нишләп йөрү? – Менә сменадан кайтып килеш (Ә. Баян). Әйдәгән маршрутлар, әйләнеч булса да, төрләнмәде. Авылга да һаман шул рельслар буйлап кайтыш* (Д. Зөбәерова).

Шул ук формалар, *иде* ярдәмче фигыле белән килеп, үткән заманны белдерәләр: *Дүртенче караваттагы яңа авыруны Әбүзәр абзыйның беренче к ү р ү е и д е* (Г. Әпсәләмов). *Алъяпкычка алма җыеп, Чыгып к и л е ш е ң и д е , Бакчагызның бер алмасын Татып карыйсым килде* (Зөлфәт).

## 4.3.2. Модальлек

Модальлек, функциональ-семантик категория буларак, сөйләм эчтәлегенең чынбарлыкка мөнәсәбәтен сөйләүче аша белдерә. Наклонение – эш-хәлнең чынбарлыкка мөнәсәбәтен махсус кушымчалар белән белдерә торган грамматик категория. Эшнең чынбарлыкка мөнәсәбәте, иң элек, эшнең үтәлүе яки үтәлмәве реальме, түгелме икәнлеге белән билгеләнә. Хикәя фигыль эшнең үтәлү-үтәлмәвен реаль факт итеп белдерә. Эшнең реаль булмавын хикәя фигыльгә каршы куела торган боеру, теләк, шарт һәм кире шарт наклонениеләре белдерә.

### Боеру модальлеге

**Боеру наклонениесе (императив – боерык фигыль).** Боеру наклонениесенең категориаль мәгънәсе – эшкә кушу, эштән тыю, боеру, өндәү, үтенү. Эшкә кушу, боеру – сөйләүче (адресант) тарафыннан адресатка юнәлә. Адресат бер яки күп затлардан торырга мөмкин. Боеру наклонениясенең күрсәткече – нуль форма.

Яңгырашы белән боерык фигыль һәм фигыльнең нигезе бер-берсенә туры килсә дә, мәгънә һәм формасы ягыннан алар төрле: фигыльнең нигезе сүзнең лексик мәгънәсен генә белдерә: *укы-, сакла-, чакыр-, сөйлә-, ярдәм ит-, йокла-* һ.б. Бу нигездән грамматик формалар ясала: *укыды, саклар, чакыра, сөйләгән, йоклады* һ.б. Боерык фигыльләрдә исә лексик мәгънәгә грамматик мәгънә – эшкә өндәү, эшкә кушу, эштән тыю, боеру мәгънәсе өстәлә: *укы! сакла! чакыр! сөйлә! тынычлан! ярдәм ит!* Бу очракта кушымча юклыгы (нуль форма) боерык фигыльнең II зат берлек санын белдерә һәм грамматик күрсәткеч хезмәтен үти.

Димәк, II зат берлек формасы – Ø форма, II затның күплеге: *-(ы)гыз/-(е)гез, -гыз/-гез* һәм III зат формасы сөйләмдә катнашмый торган затны һәм затларны белдерә һәм берлектә *-сын/-сен,* күплектә *-сыннар/-сеннәр* кушымчалары ала.

| | Берлек | Күплек |
|---|---|---|
| I зат | – | – |
| II зат | *ал! эшлә!* | *ал-ыгыз! эшлә-гез!* |
| III зат | *ал-сын, эшлә-сен* | *ал-сын-нар, эшләсен-нәр* |

Боеру наклонениесенең семантикасы түбәндәге компонентлардан тора: сөйләүче (адресант, ягъни боерык бирүче зат), адресат (боеру юнәлгән зат), эш-хәлнең киләчәккә каравы һәм императив интонация (боеру интонациясе) белән әйтелүе.

II зат берлек һәм күплек сан формалары – боеру наклонениесенең үзәге. III зат формасы боеру-өндәүнең сөйләмдә катнашмый торган затка караганлыгын белдерә һәм аны II зат тапшыра: *Бар, Шәяхмәт, син тиз генә тимерчелеккә йөгер, җизнигә әйт, хәзер ук килеп җитсен* (Г. Ибраһимов),

Контекстта боеруның төсмерләрен – йомшаклыгын яки катгыйлыгын арттыру һәм киметү өчен төрле чаралар: интонация, кисәкчәләр, эндәш сүзләр, императив ымлыклар һ.б. кулланыла.

Боеруның мәгънә төсмерләрен, аларның иерархиясен аңлату өчен боеру ситуациясен төзелеше, ягъни структурасы ягыннан карарга кирәк. Рус теле мисалында моны И. Андреева эшләгән [Андреева И., 1973, с. 125]. Ул боеру мәгънәсенең өч тибын аерып күрсәтә:

1. Йомшак тип. Сөйләүче (адресант) адресаттан бәйле була, һәм боеру йомшак төс ала. Адресат бу үтенечне үтәргә дә, үтәмәскә дә мөмкин.

2. Катгый (категорик) тип. Адресат (тыңлаучы) адресанттан (боеручы заттан) бәйле һәм үтенечне башкарырга тиеш.

3. Нейтраль тип: адресант һәм адресат (боеручы һәм тыңлаучы) бер-берсеннән бәйсез.

Бу типлар эчендә, сөйләүче һәм адресат арасындагы мөнәсәбәтнең катгый яки йомшак булуына бәйле, императив мәгънә төсмерләре туарга мөмкин. Әлбәттә, бу бүленеш эчендә боеруның катгыйлык һәм йомшаклык төсмерләре дә төрле була ала:

I. Катгый боерык белдерүнең төрле вариантлары бар:

1. Адресат яки адресатлардан эшне катгый рәвештә үтәү таләп ителә. Мондый боеру III затка да карый ала: *Беренче: патша*

*семьясына дип Идел җирләрендә иген игүне безнең өстән а л ы г ы з ! Икенче: эшли алмый торган карт-корыларга, көненә бераз гына булса да, икмәк б и р е г е з ! Өченчесе: безнең басуда куян кудырып ашлык таптатуны т у к т а т ы г ы з ...* (Т. Гыйззәт). – *Ул гына аз. Башта киселгән агачның хакын т ү л ә с е н , тагын шуның урынына биш төп агач утыртып ү с т е р с е н !* (Г. Бәширов).

2. Боеру «команда» рәвешендә адресат яки адресатларга юнәлгән була: *Шәймәрдән, өй тулы халыкны күреп, ашыгып чигенә башлады, полицейский, кулына тотып йөргән наганын аңа төбәп: – К у з г а л а - с ы б у л м а ! Кулыңны күтәр! – дип акырды* (Г. Ахунов). *Хәзер ук ат менеп Йөзкәй түрәгә ч а п с ы н н а р* (Т. Гыйззәт).

3. Боеру юнәлгән «зат» – күңел, йөрәк, хис кебек мәгънәгә ия булган сүзләрнең мәгънәсен җанландыру (персонификация) нәтиҗәсе була: *Ничә әйттем: о н ы т , о н ы т , йөрәк! Юк, тыңламый мине йөрәгем...* (Х. Туфан). *Беренче дә булмый, бишенче дә... Мәхәббәт ул салкын сан түгел, Кайнар яшлектә дә, картлыкта да, С ү н м ә , д ө р л ә , мәңге я н , күңел!* (Р. Фәйзуллин).

4. II һәм III затка юнәлгән боеру эш кушу мәгънәсен ала: *Хәзер үк җ ы л ы т боткаңы, титанны т у к , яңа чәй к а й н а т* (Н. Фәттах). *Б а р , улым, – диде бабай, – Мәһруй апаңа ә й т , башка ат җ и б ә р - с е н* (Р. Батулла).

5. Боеру эштән тыю мәгънәсен дә белдерә ала. Бу очракта адресат эшнең үтәлүен яки дәвам итүен тели, сөйләүче – эшнең үтәлүен яки туктатылуын таләп итә: *Җ е б е п т ө ш м ә г е з , күз яшегезне миңа к ү р с ә т ә с е б у л м а г ы з !* (К. Тимбикова).

6. Боеру-кисәтү, янау төсмерен алырга мөмкин; II–III затларга юнәлә: *Без чикләвеккә барабыз. Сезгә анда берни калмаган, и я р ә с е б у л м а г ы з* (Н. Фәттах). *Пединститут йөзенә тап төшерергә бирмәбез сиңа, малай. Б е л е п т о р* (Г. Мөхәммәтшин).

II. Боеруның нейтраль формалары. Бу очракта сөйләүче һәм адресат бер-берсеннән бәйсез була:

1. Боеру беренче чиратта II затка юнәлгән киңәш мәгънәсен ала: *Яшьтәш! Сүземне т ы ң л а , ерактан – күпердән ә й л ә н е п к а й т . Минем өчен бер ә й л ә н* (М. Мәһдиев). *Син, туган, ч а р а с ы н к ү р . Э ш к ә у р н а ш . Язганнары яладыр, беләм, мәгәр бер пункты рас икән, т ө з ә т син аны* (А. Гыйләҗев). *Э з л ә м ә син диңгез төбеннән*

*һич табылмый торган энҗене; Т а п иптәшең булыр кешене, Гади бер дус – үз ишеңне* (С. Хәким). *Ераклардан кайткан кошлар кебек, Өметләрем, миңа к а й т ы г ы з ! К а й т ы г ы з да минем балачакның Бишегенә килеп ятыгыз!* (Н. Дәүли). *Һаман саен кулда күтәреп й ө р м ә г е з . Шуңа өйрәнер кызыгыз* (Г. Ахунов).

2. Боеру, эшне үтәргә рөхсәт итү, юл кую төсмерен алырга мөмкин: *Зилә. ... кызымның әйберләрен бүлешергә дип килдем! Хәсән. А л ы г ы з әйдә, Зилә ханым. Күңелегезгә ни ошаса, шуны а л ы г ы з . Тик китапларга гына т и м ә г е з* (Ю. Сафиуллин).

3. Боеруның бу мәгънәсе III затка да карый ала: *Тимим күңелемә, ө з г ә л ә н с е н , я н с ы н ! Кеше кайчак үзен к и ч е р ә д ә а л с ы н . Хисләрем я р с ы с ы н , Уйларым т а ш ы с ы н ...* (Р. Фәйзуллин).

III. Боеруның йомшак формалары.

1. Боеру эшне үтәргә яки үтәмәскә киңәш итү төсмерен ала: *Мөмкин булса, у к ы п к а р а г ы з ч ы , Камил абый. Бик тә борчуга салды әле бу мәкалә кисәге* (Г. Бәширов). *К и л , ө й р ә н , әй туган, бер башка телне, Бүтән телләр белү яхшы һөнәрдер. К а т н а ш т ы р м а вә ләкин телгә телне, Тел уйнатмак наданлыктан әсәрдер* (Дәрдемәнд).

2. III зат юклыкта килгән боеру эштән тыюны белдерә*: Сау бул, диеп кагылыйм иренеңә, Йөрәгемдә юшкын к а л м а с ы н , Һаман шулай кырыс булып яшә, Яман уйлар к у л ы н с а л м а с ы н* (М. Әгъләмов).

3. Мисаллардан күренгәнчә, II һәм III зат формалары арасында семантик аермалар бар. Команда рәвешендәге боеру сөйләмдә катнашучыларга, ягъни II зат яки затларга юнәлгән була, III затта килгән боеру, еш кына, нәрсәдән булса да, кисәтүне белдерә: *Тизрәк к а й т , буран ч ы к м а с ы н* (М. Хәбибуллин). *Тизрәк к ы й м ы л д а г ы з , машиналар к у з г а л м а с ы н* (Г. Галиев). *Планетабыз – кызган вулкан төсле, Утлы ташлар кинәт я у м а с ы н ; Айга буе җиткән кешелектән Кара таулар гына к а л м а с ы н !* (Ш. Галиев).

III затта команда рәвешендәге боеру мөмкин түгел, чөнки команда сөйләмдә катнашучыларга гына юнәлгән була. Усаллык теләү, каргау, эшкә юл кую яки куймау мәгънәләре күбрәк III зат өчен хас.

Боеру төсмерләре арасында чик кую шактый авыр, чөнки киңәш теләккә әверелә, эшкә чакыру – өндәүгә, рөхсәт итүгә; эшкә юл кую – эшнең үтәлешенә илтифатсыз карауга китерә ала. Шул рәвешчә, контекстта боеру күптөрле төсмерләр ала.

**Боерык фигыльнең (боеру наклонениесенең) күчерелмә мәгънәләре.** Мәгънә киңлегенә ия булган боеру наклонениесе сөйләмдә (контекстка һәм интонациягә мөнәсәбәттә) күчерелмә модаль мәгънәләр алырга мөмкин. Кайбер мәгънәләр сөйләм теле тәэсирендә барлыкка килә. Экстралингвистик факторлар да – коммуникатив актта катнашучыларга сөйләм теле тәэсир итүе, диалекталь күренешләрнең йогынтысы, икетеллелекнең киң таралуы һәм рус теленең тәэсире кебек күренешләрнең дә йогынтысы эзсез калмый.

**Кирәклек һәм тиешлек мәгънәләре.**

1. II зат берлек санда килгән боерык фигыль гомумиләшкән мәгънәдә эшнең үтәлү кирәклеген һәм тиешлеген белдерә ала: *Дөресен генә әйткәндә, Вафин хәзергә барысын бергә, ничектер, башына сыйдыра алмый. Колхозын да о е ш т ы р , спектаклен дә к у й . Укый-яза белмәучеләрне дә б е т е р* (Ф. Хөсни). Бу очракта II зат берлек санда килгән боерык фигыль сөйләүчегә, ягъни I затның берлек санына карый.

Боерык формасының III заты, *икән* модаль сүзе белән килеп, үтәлергә тиеш булган, ләкин тормышка аша алмаган эш-хәлләр турында үкенеч белән хәбәр итә: *Егет кеше читкә китеп эшләп к а й т с ы н , ил-җир к ү р с е н , армиядә б у л с ы н и к ә н ! Чит җирләрдә тулай торакларда я ш ә с е н , коллективта б е р а з э ш к ә р т е л с е н , ш о м а р с ы н и к ә н !* (М. Мәһдиев).

2. Боерык фигыльнең II зат берлек саны тиешлек, кирәклек мәгънәсен дә белдерә ала: *Карале, Айтуар, нигә газаплыйлар безне, табигатьнең иң матур чагында баканың ашказанын ө й р ә н е п у т ы р имеш* (И. Юзиев). *Мәнә сиңа мә,– диде кияүнең кечесе. – Менә бензин ягып й ө р и н д е* (М. Мәһдиев).

**Мөмкинлек мәгънәсе**

1. Боерык фигыльнең II зат берлек саны гомумиләшкән мәгънәдә килгәндә, мөмкинлек мәгънәсе барлыкка килә: *Кая инде ул кала артыннан җитү?! Әнә минем! Кайтып керүемә ванна, телевизор, тегесе-монысы. Чыгам дисәң, ишек төбендә машина. У т ы р д а ч а п !* (Г. Бәширов). *Менә аннан өч скамия алда Ләйләгөл утыра иде. Б а р д а э н д ә ш* (М. Мәһдиев).

2. Боерык фигыльнең III зат берлеге сорау җөмләләрендә мөмкинлек / мөмкин түгеллек мәгънәсен белдерә: *Ялкын хәлен боз кайдан*

*б е л с е н ?* (Т. Әйди). *Үзе белмәгәнне ничек инде башкалардан т а л ә п и т с е н ?* (А. Хәсәнов).

3. а) Боерык фигыльнең III зат берлек сан формасы, үзе генә һәм *иде* ярдәмче фигыле белән килеп, шартлы теләк наклонениесе мәгънәсен – фараз итү, теләк, шарт һ.б. шундый төсмерләр белән белдерә: *Бармы шундый тылсымлы, ялкынлы сүзләр, кайсын әйтү белән, ялкау эшкә к ү т ә р е л с е н , җәмәгать байлыгын әрәм-шәрәм итүче җир тишегенә к е р е р д ә й б у л с ы н , кешеләрдә эш дәрте к а б ы н с ы н* (Г. Бәширов);

ә) боерык фигыльнең II зат берлек сан формасы, *иде* ярдәмче фигыле белән килеп, шулай ук шартлы теләк наклонениесен (кирәклек төсмерен) белдерә ала: – *Иске йорт булса да, берни аунап ятмый.* – *Аунаганнарын ташып бетергәнгә күрә ул.* – *Ташып бетергәнче к а й т и д е ң* (Ә. Гаффар). Мондый форма татар диалектларында күзәтелә [Махмутова Л., 1978, с. 168];

б) боерык фигыльнең шарт һәм кире шарт мәгънәсендә кулланылуы. Бу, гадәттә, II зат берлек санда күзәтелә; җөмләдәге фигыльләр шарт һәм нәтиҗә мөнәсәбәтләрендә булып, бер-берсенә каршы куелганда очрый: *Чак кына ялгышлык җ и б ә р (җибәрсәң), сиңа ышаныч кими* (В. Нуруллин). Шундый ук төзелешкә ия булган җөмләдә III зат боерык фигыль кире шарт мәгънәсен бирә: *Бер канатының астына тыга башын, Уянмый ул – бөтен кеше т а в ы ш л а н с ы н* (Г. Тукай) = *тавышланса да.* (Кире шарт фигыль бүлекчәсен карагыз.)

В. Хангилдин да II затның I зат урынына кулланылуын билгеләп үткән: *Сагалап тордым да, э л ә к т е р д ә а л* [Хангилдин В., 1959, б. 22].

Императив формаларның карап узган кулланылышын академик В. Виноградов, үзенә бертөрле волюнтатив наклонениенең туып килә торган яралгысы, дип атаган. Икенче караш буенча бу очракта өндәү һәм эш-хәлнең ирреальлеге белән бернинди бәйләнеш сакланмаган. Монда сөйләүченең эш-хәлгә эмоциональ бәяләве бар, һәм бу кулланылыш III затта да саклана: *Ул т о т та т ө ш трамвайдан.*

Икенче зат боерык фигыльнең, еш кына, зат белән ярашмавы очрый: *Баш янында болар икәү тора куркып, Әйтәләр бер-берсенә: «С и н т о т . М и н т о т »* (Г. Тукай). *Атка сикереп менде дә, чи-и итеп бер сызгырды, әнә, с и н к ү р д ә м и н к ү р , урман эчләп чабып та китте, ди* (Н. Исәнбәт).

**Боерык фигыльнең тотрыклы сүзтезмәләрдә кулланылуы**

1. Кайбер императив формалар шаккату, соклану, канәгатьсезлек, янау һ.б.ш. мәгънәләр белдерә торган ымлык функциясен үтиләр. Ул күбрәк *карау* фигыленең II зат берлек сан формалары: *кара-: кара-кара, кара син аны, кара аны, карале, карасана, кара инде. Очраган бер кеше: «карасана, болар бигрәк тә пар килгәннәр икән ләбаса!» – дип әйтәчәк* (Г. Бәширов). *Кара син аны, йөр син аны бер надан карчык дип* (М. Мәһдиев).

2. Боерык фигыльнең II зат формалары тотрыклы сүзтезмәләрдә кулланыла: югарыда күрсәтелгәннәргә *күр дә тор, син күр дә мин күр,* III зат нигезендә ясалган тотрыклы сүзтезмәләрдән *хәерле булсын, күз тимәсен, алла сакласын, авызыңнан җил алсын, чәнчелеп китсен, кадалып китсен* һ.б.ны өстәргә була.

3. *Бул-, ди-* фигыльләреннән ясалган III зат формалары, теркәгеч сүз функциясендә кулланылып, диалог репликаларын бәйлиләр: *– Рәшидә өйдәме? – Рәшидә кайда булсын, әнә теге бүлмәдә йоклап ята* (Г. Галиев). *Мондый шартлар завод-фабрикаларда булсын, иген кырларында булсын, кешенең хезмәт җитештерүчәнлеген үстерүгә китерә* (Н. Дәүли).

Сорау алмашлыклары сыйфатында *кем (кемне, кемгә, кемнән, кемдә, кемнеке), кайда, кайдан, нәрсә* (барлык килеш формаларында), *ни, нигә, ник* һ.б. кулланыла.

Күчерелмә мәгънәләрендә дә боеру белән зат формалары арасында бәйләнеш барлыгы күренә. Мәсәлән, алда каралган *ал да кит, утыр да чап* конструкцияләре затка бәйле рәвештә грамматик яктан төрлечәрәк мәгънә белдерә алалар: 1) конкрет мәгънәле II затта боеруның нәкъ II затка юнәлгәнлеге белдерелә; 2) гомумиләшкән II затта эшнең үтәлү мөмкинлеге белдерелә; 3) конструкциянең гомумиләшкән теләсә нинди затка каравы көтелмәгәнрәк эш-хәл мәгънәсен барлыкка китерә: *Ә без тот та төш поездан. Кайт идең* формасы конкрет II зат берлек санга караса, шартлы теләк наклонениесе мәгънәсен белдерә (= *кайтыр идең*). Гомумиләшкән затка караса, I заттан белдерелгән теләк мәгънәсе барлыкка килә: *Кайт идең туган якларыңа!*

**Боеру мәгънәсен башка формалар белән белдерү.** Боеру мәгънәсе, контекстка карап, башка фигыль формалары белән дә белдерелә ала. Моның өчен формада боерык фигыльгә хас семалар булырга

тиеш: өндәү яки боеру, эш яки хәлнең адресатка каравы, киләчәккә юнәлүе. Бу формалар боерык фигыль белән синонимик мөнәсәбәткә керәләр.

Императив мәгънәдә куллану мөмкинлеге, беренче чиратта, II зат өчен хас, чөнки ул – боеруның адресаты. II затта килгән хәзерге һәм киләчәк заман хикәя фигыль формалары: инфинитив (чөнки ул белдергән мәгънәнең реальләшүе киләчәк заманга карый), шартлы теләк наклонениесе һ.б. Мондый очракта хикәя фигыль, үзенең парадигматик мәгънәсен югалтып, күчерелмә мәгънә белдерә. Шартлы теләк наклонениесендә синтагматикага караган семалар үзгәреш кичерә.

**Хикәя фигыльнең боеру мәгънәсе**

1. Хәзерге заман хикәя фигыль, II зат берлек һәм күплек санда килеп, боеру, таләп итү, эш кушу мәгънәләрен белдерә. *Кызым, хәзер үк киенәсең, шушы зур төенчекне аласың, абыең белән әтиеңә басуга ашарга илтәсең* (Ш. Маннур).

2. Билгесез киләчәк заманның II зат берлек һәм күплек формасы шулай ук адресатка юнәлә һәм боеруны белдерә. *...Ләкин укып чыккач, үземә кайтарып бирерсез...* (Ф. Хөсни). *Иртәгә мөдир янына керерсез. Кайсы районга китәсегезне ул әйтер* (Г. Мөхәммәтшин).

3. II зат берлектә һәм күплектә килгән хәзерге һәм киләчәк заман хикәя фигыль, юклык-сорау формаларында килеп, йомшак итеп эшкә кушуны белдерә. *Пыяла куярга чыгып кермисеңме соң, улым!* (Г. Бәширов). *Биләровка ничек шалтыратырга икәнен генә әйтмәссезме?* (К. Тимбикова).

4. Кайбер ситуацияләрдә III затка караган боеру хәзерге һәм киләчәк заман хикәя фигыльнең III зат берлек яки күплек формалары белән дә белдерелә ала: *Дөлделне иярләгез, бу ике байгыш Корган Күл җәйләвен карап кайтырлар!* (Г. Ибраһимов).

М. Мәһдиев «Без кырык беренче ел балалары» исемле повестенда, боерык фигыльнең III зат берлек һәм күплек формасын адресат һәм адресатлар урынына файдаланып, үзенчәлекле ситуация тудырган: *Безгә карамыйча гына, яны белән басып, болай диде: – Дежур укучы форточканы ача, парта өсләрен, тактаны сөртә. Калганнар барысы да, коридорга чыгып, җырлы уенга керәләр... Укучылар аның аларга III затта дәшүен яратмадылар, чөнки III зат сөйләмдә катнашмый торган зат ул. – Кара син аны... «Ачыгыз» дими, «уенга*

*чыгыгыз» дими... Ачалар, керәләр, имеш. Димәк, укучылар укытучының аларны бүлмәдә юк итеп сөйләвен аңладылар һәм үзләренчә ризасызлык белдерделәр.*

5. Боеру мәгънәсе категорик үткән заманның I зат күплек саны белән дә белдерелә ала, һәм бу күренеш күбрәк хәрәкәт фигыльләрендә күзәтелә: *Әйдә, үзең дә киен, Шамилне дә киендер. Бәрәңге казырга киттек!* (А. Расих). Ситуациягә карап, башка мәгънә белдергән фигыльләрнең I зат күплегендә дә боеру мәгънәсе очрарга мөмкин: *Яле, балалар! Дәфтәрләрне читкә алып куйдык, дәреслекләрне яптык. Хәзер яңа темага күчәбез.* (Студентларның мәктәптә үткәрелгән педагогик практикасыннан.)

**Шартлы теләк наклонениесенең боеру мәгънәсен белдерүе.** Гадәттә, II зат формасы йомшак боеру, киңәш яки үтенү мәгънәсе белән кулланыла: *Эскерт куярга булышыр идең, Гафиятулла абзый* (Ф. Хөсни). *Самат янына барып кайтыр идең, аз-маз күчтәнәч илтерсең, өстен-башын карап, юасын юарсың* (Б. Камалов). *Халкымның җаны тудырган җырны Онытсам әгәр – таң атмас иде; Шул җыр булмаса – җирдә беркайчан Таһир Зөһрәне яратмас иде* (Р. Әхмәтҗанов).

**Инфинитивның боеру мәгънәсен белдерүе**

1. Команда яки боерык мәгънәсе фигыльнең инфинитив формасы белән дә белдерелә ала. Башка формалардан аермалы буларак, инфинитив белән белдерелгән боеру затны белдерми. Бу сыйфат инфинитивны приказларда, команда биргәндә һәм гомумиләшкән төстә рәсми документларда, хәрби боерыкларда кулланырга мөмкинлек бирә: *Дошманга көнчыгышка, төньякка һәм көнбатышка таба үтәргә ирек бирмәскә. Дошман боҗрадан чыгарга омтылса, аны юк итәргә* (Г. Сафиуллин).

Инфинитив формасы өндәүләрдә дә кулланыла ала: *Көнкүреш хезмәтен яхшыртырга!*

2. Юклык формасы эштән катгый тыюны белдерә ала: *Барысы керәп урнашкач, Мортазин кнопканы басты: – Өч минуттан соң беркемне дә кертмәскә!*

3. Инфинитив белән киңәш итүне дә белдереп була: *Сөткә йомырка һәм бераз тоз салып болгатырга да май белән кыздырылган уртача зурлыктагы табага юка гына итеп салырга* (Ю. Әхмәтҗанов).

Китерелгән очракларда боеру һәм тыю мәгънәсенә кирәклек төсмере өстәлгән.

4. Боеру – лексик һәм интонацион чаралар, җөмлә төзелеше белән дә белдерелергә мөмкин: а) *Кырларга – мул ашлама! Фермаларга – ел ярым ашлык запасы!;*

ә) шау-шуны туктату өчен *чү, я, я...*, хайваннарны, кош-кортны куу яки чакыру өчен *чәбә, прес, тпру, дөгә-дөгә* кебек ымлыклар; тавыш-ызгышны туктату өчен *җитәр* яки *җитәрегез инде! чүегез, ягез* һ.б.ш. ымлыклар файдаланыла.

## Теләк наклонениесе

**Теләк наклонениесе (теләк фигыль).** Теләк фигыль *-ый, -и* кушымчалары белән ясала (бу форма сузык авазга тәмамланган хәзерге заман хикәя фигыль нигезе белән аваздаш), ләкин аның I зат формасы гына бар һәм ул икенче төр зат кушымчалары ала: *барай + ым > барыйм, аңлай + ым > аңлыйм, эшләй + ем > эшлим. Сау бул диеп кагылыйм иренеңә, Йөрәгемдә юшкын калмасын, һаман шулай кырыс булып яшә, Яман уйлар кулын салмасын* (М. Әгъләмов).

Теләк наклонениесенең үзәге – берлек һәм күплектә килгән I зат формасы. Аның азагына *әле* кисәкчәсе өстәлә: *Шул турыда аз гына – биш-алты сүз сөйлим әле, Гадәтемчә аз гына җырлыйм әле, көйлим әле* (Г. Тукай). *Балалыкка кайтыйм әле. Кире кайтыйм әле тагын бер, Туфлиләрне салып, тыкрыклардан Яланаяк чабып карыйм бер...* (И. Юзиев).

Беренче заты гына булган бу форманы кайвакыт II һәм III заты гына булган боерык фигыль белән берләштерәләр, ләкин алар мәгънә ягыннан да, форма ягыннан да аерылалар.

Теләк фигыль белән *әле, -чы, -че, инде* кисәкчәләре, *әйдә, әйдәгез* кебек ымлыклар кулланыла. *Әйдә, китик инде алай булгач, – диде Гарәпша* (Ш. Камал).

Теләк фигыль формалары контекстка бәйле рәвештә шарт, кире шарт, тиешлек, мөмкинлек кебек модаль мәгънәләр белдерә алалар (алдагы бүлекләрне карагыз). Теләк фигыльнең хикәяләү мәгънәсен белдерә алуына мисал: *Башымны күтәрсәм, ни күрим: ни арада төш тә җиткән, ни арада без таллыкка якынаеп та калганбыз* (Г. Ибраһимов).

Теләк мәгънәсен башка формалар белән белдерү. Синтетик формалар: *-гай/-гәй һәм -гыры/-гере, -кыры/-кере* кушымчалары белән ясала,

1. *-гай, -гәй* кушымчалы форма ике мәгънәдә кулланыла: ниндидер эштән кисәтү, курку, эшнең үтәлмәве хәерлерәк булу кебек мәгънә белдерелә, форма һәрчак юклыкта була; эш-хәлнең кайсы затка каравы тартым кушымчалары белән белдерелә: *Бодайның тамыры өзелмәгәе, йолкынып чыкмагае* (Г. Бәширов). *Ашыгасың түгелме соң? Әлләниләр булып бетмәгәе* (Р. Төхфәтуллин). *Анда аның ни эше бар, көлмәгәе, әллә нишләсен!* (Н. Фәттах).

Башкаручы зат бу формада тартым кушымчалары белән белдерелә: *Яңадан бер генә мәртәбә нәүбәтсез сүз башласагыз, мин сезне мәҗлестән чыгартачакмын... – Чыгартмагаең!.. Бик исем китми, чыгарта бир* (Г. Ибраһимов). *Салкын тидермәгәем*. Форманың I һәм II затка каравы сирәк очрый. III зат күплек сан – *чыгармагайлары, тидермәгәйләре.*

2. *-гыры/-гере, -кыры/-кере* формасы каргау ымлыкларына хас: *дөмеккере, башы беткере, күзең чыккыры, чәнчелеп киткере* һ.б. Сирәк очракта канәгатьләнү, шатлык билгесе буларак кулланыла: *шайтан алгыры, рәхмәт төшкере. Эх, җен алгыры! Ничек тизрәк үтеп китәргә?!* (М. Җәлил). *Зөһрә! Зөһрә... Вәли! Сез кайда? Чәнчелгереләре! Сиңа кирәк чакта берсе дә юк* (Г. Ибраһимов). *Әй беләсезме, күзегезне корт чаккырлары, ник кирәк миңа бу акчалар?! Акчаны ахмак кына ярата* (Г. Мөхәммәтшин). *Һәр заманның була үзенә күрә сволочы (каһәр суккыры)!* (Һ. Такташ).

3. *-асы кил-* формасының кайсы затка каравы – *-асы* кушымчасына ялганган тартым кушымчалары, заманы ярдәмче фигыль формасы белән белдерелә: *күрәсем килә, күрәсегез киләме? күрәсе килер, күрәсе килә иде* һ.б. – *Абаганың беркайчан да чәчәк атмаганын беләсезме? – дип сорый толымлы кыз. – Беләм, әмма чәчәк атарына ышанасым килә, ди Бакый...* (М. Галиев). *Китәр алдыннан аның шулай да яшь хатынга юату сүзләре әйтәсе килде* (Н. Фәттах). *Иртән торып эшкә килешеңә һич тә көтелмәгән хәл ишетәсең килсә – мәктәптә эшлә* (М. Мәһдиев). *Һәм аңарда үзлегеннән диярлек каршы торасы, тыңлыйсы килмәү хисе уянгандай булды* (Ә. Еники).

Тартым кушымчасы алмаган *-асы кил-* формасы теләсә кайсы затка карарга мөмкин: *Җирне илләр-дәүләтләргә бүлеп, Төрле чикләр*

*уйлап чыгарган Кешеләргә рәнҗи кебек дөнья, А р ы н а с ы  к и л ә шулардан. Кайчагында ерак киләчәккә Күчеп китәм дә бер хыялда: – Гражданины мин бер планетаның! – Дип ә й т ә с е  к и л ә җиһанга* (Н. Арсланов). *Арынасы килә* фигыленең субъекты – дөнья, *әйтәсе килә* сүзләренең субъекты – кеше, автор.

4. Теләкне белдергән *-асы иде* формасы грамматик затны белдерми, ләкин теләк, гадәттә, сөйләүчедән, ягъни беренче заттан әйтелә: *Кырларыңда, илем, юлларыңда Г и з ә с е  д ә  г и з ә с е  и д е, Җырга салып җырдай тормышыңны Үзеңә б ү л ә к  и т ә с е  и д е* (Х. Туфан). *Мин сау, сеңлем, Син дә сау микән? Сине бер к ү р ә с е  и д е, Кайтмый калган абыйларның Сәламнәрен б и р ә с е  и д е* (Х. Туфан).

Контекстка бәйле рәвештә теләк гомумиләшкән II һәм III затка карарга мөмкин: *К ү р ә с е  и д е дә иң изге серләреңне у р т а к л а ш а с ы  и д е үзе белән* (М. Хәбибуллин). *Балалар бик нык куркуга төштеләр. Хәзер мена тизрәк өйгә й ө г е р е п  к а й т а с ы  и д е дә берәр җылы караңгы урынга к е р е п  п о с а с ы  и д е* (Н. Фәттах).

*-асы* формасы, кагыйдә буларак, юклыкны *-ма, -мә* кушымчасы белән белдерми. Сөйләм телендә бик сирәк кулланылган мондый форманы аналитик конструкция составында очратырга мөмкин: *Скважиналарга к у е л а с ы автоматларның кимчелекләрен Себергә к е р т м и с е, аңа к и р т ә  к у я с ы  и д е* (Ш. Бикчурин).

5. Теләк мәгънәсен хәбәр функциясендә кулланылган инфинитив та белдерә ала: *Язып терсәк, басып куллар бөергә, Курай салмагына басып б и е р г ә !* (Дәрдемәнд). *Һай шул болытны безнең турыга гына э л е п  к у я р г а !* (Г. Бәширов).

6. *-рга иде* (инфинитив + *иде*) формасы: *Их, а у н а р г а  и д е шул таллар арасында!* (Р. Фәйзуллин). *Аннары бер туйганчы е л а р г а и д е. Кырык беренче елдан бирле җыелган сагышны, моңны ч ы г а р ы р г а  и д е* (М. Мәһдиев).

7. Шартлы теләк наклонениесенең I заты теләкне белдерә: *Син саганнарын барысын биреп, бер генә нәрсә а л ы р  и д е м ! Намуслы, керсез исемемне* (А. Гыйләҗев). *Сине к ү р ә с е  и д е. Бик сагындым. – Агыйдел буйларын бер сөйләшеп у т ы р ы р  и д е к* (Г. Ибраһимов).

8. II һәм III зат боерык фигыль, *иде* ярдәмче фигыле белән килеп, теләкне белдерә. Беренчесе диалектларга хас һәм, диалект үрнәге буларак, әдәби әсәрләрдә очрый: *Ах, бөтен дөньясын онытып к и т и е ң*

*(кит идең) флотка, й ө р и е ң (йөр идең) шул корабльләрдә* (М. Мәһдиев). *Их, ...т о р с ы н и д е калай түбәле өй ялтырап, а ч ы л с ы н и д е ике якка яңа капкаң, ... чакыр идең Казаннан Бикташир коданы, к и т е р и д е ң әркистр* (Ф. Хөсни).

9. Шарт фигыльнең *-са* кушымчасына *чы* кисәкчәсе өстәлеп ясалган һәм *-са иде* формалары, нәтиҗә өлешеннән башка килеп, теләкне белдерәләр: *Үләм, дидем, ярый, тик кайгырдым. К ү р е п ү л с ә м ч е, дип кызымны! Анам кабре – туган туфрагыма К у е п ү л с ә м ч е, дип йөземне!* (М. Җәлил). *Ал чәчәкләр арасында бер җ ы р л а п я т с а м и д е* (Ф. Кәрим).

## Шарт модальлеге

**Шарт наклонениесе (кондиционалис – шарт фигыль).** Шарт фигыль икенче бер эшнең үтәлүенә шарт булган эш яки хәлне белдерә. Наклонение күрсәткече *-са, -сә* кушымчасы, бу нигезгә II төр зат кушымчалары ялганып килә: *алса-м, алса-ң, алса-; алсак, алса-гыз, алса-лар.* Шарт-нәтиҗә мөнәсәбәтләрен белдерүдә җөмләнең синтаксик һәм интонацион структурасы катнаша, шарт һәм нәтиҗә фигыльләре арасында билгеле бер бәйләнеш урнаштырыла.

Эш яки хәлнең үтәлүе өчен кирәк булган шарт, хикәя фигыльдәге кебек, реаль эш-хәлләргә карамый. Ләкин аның реальләшү мөмкинлеге контекст һәм шартның үтәлү/үтәлмәү нәтиҗәсен белдергән фигыльгә карап өч төрле булырга мөмкин: шартның үтәлүе реаль, фаразый һәм ирреаль.

**Реаль шарт**

1. Реаль шарт *-са/-*сә формасы белән белдерелә. Шарт җөмләнең нәтиҗә өлешендә *-р/-мас*, *-ачак*, киләчәк заман мәгънәсендә килгән хәзерге заман, боерык фигыль һәм киләчәк заман темпоральлегенә ия булган башка формалар килә ала: *Кемнәр мине ю а т ы р л а р Гөлне карлар к ү м с ә л ә р* (Х. Туфан). *Безне озаткан сукмакларны Капламасын үләннәр; Я з к а й т м а с а к, к ө з к а й т ы р б ы з, С е з к ө т е г е з, сөйгәннәр!* (Г. Кутуй). *К ү ң е л е м б у л м ы й и д е, өй түреннән Тальян уйнап, җырлап ү т м ә с ә м, Йөрәгемне борчу б а с а и д е, Син сөялеп мине к ө т м ә с ә ң* (С. Хәким). *Т о м а л а с а юлны ак бураннар, Карлы җилләр Ү т е п к и т с ә л ә р, – Ап-ак тауга м е н син таң атканда, Мин сагындым сине шул кадәр!* (Зөлфәт).

2. Шарт нәтиҗәсен белдергән фигыль хәзерге заманда (аеруча киңәйтелгән хәзерге заманда) булса, шарт һәм нәтиҗәне белдергән фигыльләр гадәтилек мәгънәсендә килә: *Ә колхоз чәчүгә чыкканда, уракка төшкәндә минем белән киңәшә, сыйфат комиссиясенең башлыгы. Мин дигәнчә булмаса, талашам* (Т. Миңнуллин). *Агач яфраклары коелып бетмәсә, ел авыр килә* (М. Мәһдиев). *Бер көнлек юлга чыксаң, бер атналык ризык ал* (мәкаль).

Гадәти шарт *-а торган булса* формасы белән белдерелә ала: *Гөлшаһидә ханым минем сызмаларга андый таләп белән карый торган булса, мин аңа бүтән бер дәфтәр дә бирмим* (Г. Әпсәләмов). Мондый мәгънә мәкаль һәм әйтемнәрдә очрый: *Башың эшләмәсә, аягың ял итмәс.*

3. Шарт фигыльнең *-ган булса* тасвирлама формасы күпчелек очракта реаль булмаган һәм үткәнгә караган шартны белдерә (алдагы бүлекчәне карагыз). Ләкин *-ган булса* формасы реаль шарт мәгънәсендә дә кулланыла ала. Бу вакытта җөмләнең икенче өлешендә реаль шарт белән кулланылган барлык хикәя фигыль формалары килә ала: *-р/-мас* һәм *-ачак* кушымчалы киләчәк заманнар, киләчәк мәгънәсендә кулланылган хәзерге заман, боерык фигыль һәм киләчәк темпоральлегенә ия булган башка формалар. *Бабасы кабинет ишеген япкан булса, ачкыч тишегеннән карый* (Г. Әпсәләмов). Тагын шуны да билгеләп үтәргә кирәк: бу форма татар телендә реаль шартны белдерер өчен дә киң кулланыла: *Йоклаган булса, сез аны уятмагыз* (М. Әмир). *Кабызган булсаң, янсын. Алтыга килеп җиткән булса, мине очратыр.* Җөмләнең икенче өлешендә хәзерге заман, боерык фигыль, билгесез киләчәк заман кулланылган.

4. Реаль шарт үткән заманга да карый ала. Бу очракта *-са* кушымчалы шартның гадәтилеге, кабатлануы белдерелә һәм аны хәзерге заманга караган шарт-нәтиҗә мөнәсәбәтләре белән чагыштырып була: *-са* кушымчасы белән белдерелгән шарт каршында нәтиҗә фигыле *-а иде* кушымчалы тәмамланмаган үткән заман һәм *-р/-мас иде* кушымчалары белән ясалган гадәти үткән заман формаларын ала: *Халкымның җаны тудырган җырны Онытсам әгәр – таң атмас иде. Шул җыр булмаса – җирдә беркайчан Таһир Зөһрәне яратмас иде* (Р. Әхмәтҗанов). *Ә инде ашарына бетә башласа, тагын шулай бер авылга барып, тормышын көйләп кайта*

*иде* (Г. Галиев). *Иртән күрешмәсәк, кичкә кадәр зарыгып саргаеша торган идек* (А. Гыйләҗев). *Ул бит, исенә төшерүче булмаса, ашарга-эчәргә кирәклекне дә оныта...* (Г. Кутуй).

Үткәнгә караган шарт – сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтләрендә нәтиҗәне белдергән эш-хәл категорик үткән заманда килергә мөмкин: *Нинди эш килеп чыкса, барысын да маташтырды* (И. Гази).

Түбәндә китерелгән сызымда **реаль шарт** белән нәтиҗә өлешләре арасындагы мөнәсәбәтләр белдерелгән: протазиста (сул якта) – шарт, аподозиста (уң якта) шартка бәйле кулланылган фигыль формалары күрсәтелгән.




Реаль шартның темпоральлеге киләчәк, хәзерге һәм үткән заманга карый ала.

**Фаразый шарт.** Фаразый шарт *-са, -ган булса, -асы булса* формалары белән, шартка бәйле эш-хәл (нәтиҗә өлеше) *-р/-мас иде, -ачак иде, -ган булачак иде* формалары белән белдерелә: *Барлык кичергән газапларны сөйләсәң, кеше ышанмас иде* (Г. Әпсәләмов). *Зоотехник булып үзебезнең фермага кайтсаң, эшләп тә күрсәтер идек* (С. Шәкүров). *Китеп барган булсам, артымнан эзли чыгар идеңме соң?* (Ә. Гаффар). *Әгәр юл уңса, Байтүрәнең иң яман булган Биремҗан аксакал бу йортка килеп кымыз татыса, иттән авыз итсә, ул вакыт ике кабиләнең талаштан туктавына сукмак салынган булачак иде* (Г. Ибраһимов). *Бандит анда ычкынып китә алса, караңгылыкта, куе талтирәк арасында аны табуы кыен булачак иде* (Ш. Камал). *Көтәсе булсагыз, мин дә сезнең белән барыр идем.*

Фаразый шартның темпоральлеге киләчәк заманга карый.




**Ирреаль (реаль булмаган) шарт.** Шартның бу формасы *-са, -са иде, -ган булса, -асы булса, -асы булса иде* формалары белән белдерелә; нәтиҗә өлешендә *-р иде, -ачак иде, -ган иде, -а иде, -ган булыр иде* формалары кулланыла.

*Акча биреп, яшь гомерне кире кайтарып булса, кызганмас иде ул акчаны* (И. Гази). *Тик булса иде ирек, кылычым булса кынымда, Карабиным кулымда... Мин ирләрчә үләр идем Данлы сугыш кырында* (М. Җәлил). *Шулар тотмаса, күптән инде ул бу кар базыннан чыгып киткән булыр иде* (Л. Хәмидуллин). *Әгәр шушы авыру әнисен карыйсы булмаса, Әминә, һичшиксез, берәр институт тәмамлаячак, газет-журнал тирәсендә шагыйрә булып йөриячәк иде* (М. Мәһдиев). *Лейтенант килеп кермәсә, аларның тормышлары куркыныч астында калган иде* (М. Хәсәнов). *Чакыручы булган булса, мин дә барган булыр идем* (Ф. Хөсни). *Ул килгән булса, барысы да җайлана иде* (М. Мәһдиев).

Китерелгән мисаллардагы шарт-нәтиҗә мөнәсәбәтләрен түбәндәге сызым белән бирергә мөмкин.




Реаль булмаган шартның һәм шартка бәйле эш-хәлнең үтәлүе үткән заманга карый.

Югарыда әйтелгәннәрдән *-са, -сә* кушымчалы шарт фигыльнең күпмәгънәлелеге – реаль, фаразый һәм ирреаль (реаль булмаган) шартны белдерә алуы ачыкланды. Шарт фигыльнең заманы һәм аспектуаль үзенчәлеге тасвирлама формалар белән ачыклана: киләчәккә караган шарт – *-р/-мас булса, -а торган булса, -асы булса* формалары

белән; үткәнгә караган шарт *ган булса*, *-са иде* формалары белән тәгъбир ителә.

Катлаулы формалар күп мәгънәле булса, мәсьәләне нәтиҗә өлешендә килгән фигыль һәм контекст хәл итә. Мәсәлән, шарт фигыльнең *-ган булса* формасы реаль, фаразый һәм ирреаль шартны белдерә. Шартның нәтиҗә өлешендә хәзерге һәм киләчәк замандагы хикәя фигыль яки боерык фигыль килсә, шарт фигыльнең *-ган булса* формасы, *-са* формасы кебек, киләчәк заманга караган реаль шартны белдерә: *К а б ы з г а н б у л с а ң (кабызсаң), я н с ы н (янар, яначак).* Шул рәвешчә үткәнгә караган реаль шарт белдерелә.

Шартның нәтиҗә өлешендө *-р/-мас иде* һәм *-ачак иде* формалары килсә, шартның *-ган булса* формасы фаразый шартны белдерә. Бу вакытта шарт-нәтиҗә мөнәсәбәтләре киләчәккә юнәлгән була. *-р/-мас иде, -ачак иде*, шулай ук *-ган иде, -а иде, -ган булыр иде* формалары белән килгән ирреаль шарт-нәтиҗә мөнәсәбәтләре – үткәнгә карый.

Шарт фигыльнең *-асы булса* формасы фаразый шарт-нәтиҗә мөнәсәбәтләрен белдерсә – киләчәккә карый, ирреаль мөнәсәбәтләр булса – шарт киләчәк-үткәнгә карый (*карыйсы булмаса – карыйсы булмаса иде* мисалларын чагыштырыгыз).

Шарт-нәтиҗә фигыльләре арасындагы мөнәсәбәтләр күпмәгънәле булса, хәлиткеч роль нәтиҗә фигыльләренә һәм контекстка кала. Мәсәлән, *-са* һәм *-ган булса* шарт фигыль формалары, *-р/-мас иде, -ачак иде* формалары белән килеп, фаразый шарт-нәтиҗә мөнәсәбәтләрен белдерсәләр, икенче контекстта ирреаль мөнәсәбәтләр туа. Ирреальлекне тамгалау өчен шарт *-ган булса*, нәтиҗә фигыле *-ган булыр иде* формасында килә. Бу очракта *-ган булса* урынына, шарт фигыльнең *-са* формасын да кулланып була.

**Шарт фигыль формаларының башка мәгънәдә кулланылуы**

1. Парлы мөнәсәбәтле сүзләр белән килеп, шарт фигыль формалары субъект, объект, вакыт, урын, чагыштыру һәм башка төрле мөнәсәбәтләр белдерәләр: *К а й д а э л ә к с ә, ш у н д а башын куя да хырлап йоклап та китә* (Ф. Хөсни). *Син аңа хат яз. Элек н и ч е к я з г а н б у л с а ң, ш у л а й я з* (Г. Әпсәләмов). *Син б е л е п т у с а ң, мин э л е к т у г а н м ы н* (Ф. Хөсни). *Аларның яфраклары аз гына да куырылмады, кипмәде, бөгәрләнмәде – җәй уртасында н и н д и б у л с а л а р, ш у л а й саклandылар* (Г. Рәхим).

2. Вакыйгаларның эзлеклелеген һәм тиз алмашынуын белдерәләр:

а) *Сиңа, бәбкәем, арыш урагы җитсә, ун тула инде* (М. Мәһдиев). Бу очракта шарт фигыльне *-гач* кушымчалы хәл фигыль белән дә алмаштырып була;

ә) *Кызыбыз кайчан ашады, кайчан эчте. Күрми дә калдым, борылып карасам, күзге каршына килгән, чәчләрен төзәтә, кашларын сөрмәли* (И. Гази). *Сәгатькә карасам, кузгалырга вакыт* (Д. Зөбәерова).

3. Шарт нәтиҗәсен белдергән фигыльдән башка килеп, *-са, -са иде, -са икән, -са+чы* формалары көчле теләк, үкенү, курку, эшне үз агымына кую кебек төрле модаль төсмерләр белдерәләр: – *И-и, шул тиклем җирдән атна саен мәче дип кайтып йөрмәсәң* (М. Мәһдиев). *Мондый көндә, беренче бөртекләр җиргә яткан минутларда, яңгыр да явып китсәме!...* (А. Гыйләҗев). *Шунда үзең минем янга килгән булсаңчы!* (Г. Бәширов).

4. Шарт фигыль формалары катып калган әйләнмәләрдә очрый: *ни әйтсәң дә, әйтмәсәң дә, җитмәсә, җитмәсә тагын*; алмашлыклар составында кулланылалар: *кем булса да, ничек булса да, теләсә кем, теләсә нәрсә, теләсә кайда; теләсә ни;* теркәгеч хезмәтен үтиләр: *аз булса да, алайса, ичмаса, нигә дисәң;* модаль сүзләрдә кулланыла: *булса кирәк, алайса, ичмаса, булмаса* һ.б.

5. Кабатлауларда кулланылалар: *чыкса чыга, җыйса җыйды, килсә дә килә икән, чыдаса да чыдый икән, уйнамасаң уйнамассың, әйтсәм әйтим, әйтсә әйтсен, ишетсәң ишет* һ.б.

**Шарт фигыльне башка формалар белән белдерү.** Шарт наклонениесеннән тыш шартны башка фигыль формалары белән дә белдереп була.

1. Киң таралган очракларның берсе – хикәя фигыльнең хәзерге һәм нәтиҗәле-үткән заманнары + *икән* модаль сүзе. Интонацион яктан җөмлә бер-берсенә каршы куелган ике өлештән: шарт һәм нәтиҗәдән тора: а) *Легионерлар фронтка җибәрелә икән, үзебезнекеләр ягына чыгып, немецның коралын аның үзенә каршы төбәячәкләр* (Г. Әпсәләмов). *Үләм икән, үкенечле түгел Бу үлемнең миңа килүе. Бөек җыр ул Бөек Ватан өчен Сугыш кырларында үлүе* (Ф. Кәрим). *Иптәш буласың икән (булсаң), рәхим ит, арага кер. Борыныңны күтәреп йөрисең икән, үзеңә үпкәлә*

(Г. Коләхмәтов). *Кайгы чәчеп, ж ы я  и к ә н үзенә шатлык, – төкер аңа* (Р. Фәйзуллин).

Бу юл белән шарт-нәтиҗә мөнәсәбәтләренең хәзерге һәм киләчәк заманнарга караганнары белдерелә.

ә) *Ялгышып  а б ы н г а н с ы ң  и к ә н , күтәреп торгызырбыз* (Р. Хәмид). *Мин аңа о х ш а г а н м ы н  и к ә н , андагы буй-сын, андагы чәч, андагы тавыш миндә дә бар дигән* сүз (Д. Зөбәерова).

*-ган икән* формасына иң якын форма – *-ган булса: йоклаган икән / йоклаган булса, уятмагыз.*

2. Шартны белдерә торган формаларга категорик үткән заманның III зат формасына сорау кисәкчәсе *-мы/-ме* яки *исә* кисәкчәсе өстәлү юлы белән ясалган төрен дә кертергә мөмкин: *Ул гел шулай: башына и с ә п  т ө ш т е м е , утырып кына уйлый алмый, ялгызы калуга, читлектәге арыслан кебек, әрле-бирле йөгерә башлый* (Җ. Рәхимов). *Камырың к а б а р д ы м ы , күмәчеңне әвәлә; кызың ж и т т е м е , озату ягын кара* (Д. Зөбәерова). *Апрель  җ и т т е  и с ә , җаным ашкына, шаша* (Р. Фәйзуллин).

Китерелгән *-дымы* һәм *-ды исә* формалары реаль шартка карый һәм, нәтиҗә фигыле белән бергә, типик шарт-нәтиҗә мөнәсәбәтләренең хәзерге һәм үткән заманнарына караганлыгын белдерә. Шуның белән бергә бу формаларга ингрессивлык төсмере (эшнең тиз башлануы) хас, ягъни имплицит рәвештә категорик үткән заман төсмере сиземләнә.

3. Шарт – боерык фигыльнең II, III затлары һәм теләк фигыленең I зат формалары белән белдерелә ала. Структур һәм интонацион төзелеше ягыннан җөмлә бер-берсенә каршы куелган ике өлештән тора: *Чак кына я л г ы ш л ы к  җ и б ә р  – сиңа ышаныч кими* (В. Нуруллин). *Б у л с ы н  Кәрам аның урынында – Кузьманы тын алырга да ирек бирмичә, өстерәр иде* (Ш. Бикчурин). *Ярдәмен-ниен күреп торсам да, җае чыккан саен үртәп үзәгенә үтәм Факиһәнең. Әз генә а е р ы л ы п  т о р ы й к , сорау яудыра башлыйм* (Д. Зөбәерова).

4. Шарт мәгънәсе *-гач* һәм *-ганда* кушымчалы хәл фигыльләр белән дә белдерелә ала:

а) *Себер тимер юлы белән Казаннан алтмыш чакырым к и т к ә ч , Арча булыр* (Г. Ахунов). *Йосыф (тәмәке кабызып), Менә к а б ы з г а ч яна бит. К а б ы з м а с а ң , янмас иде* (Г. Коләхмәтов).

ә) *Логикадан бигрәк, хыялны эшкә җиккәндә, аның турында без шактый фикер әйтә ала идек инде* (А. Тимергалин). *Болай эшләгәндә, миллионлаган кубометр балчыкны арлы-бирле күчерәсе юк* (М. Зарипов). Шартның бу ысул белән белдерелүе газеталарда мәкалә исемнәрендә очрый: *Бергәләп тотынганда, икътисади фикерләүгә өйрәткәндә* һ.б.

Теләк фигыльнең I заты, *-гач* һәм *-ганда* кушымчалы хәл фигыль формалары белән белдерелгән шартның башкару вакыты нәтиҗә фигыле белән бер түгел. Беренче форма, шарт мәгънәсен белдереп, төп эштән алда булган эш-хәлләрне белдерә, затка һәм заманга битараф; икенчесе – төп эш белән бергә һәм төп эштән алда үтәлә торган эш-хәлләрне белдерә ала. Хәл фигыль формасы шарт фигыльдән зат һәм заман мәгънәсен белдермәве белән аерылып тора. *-гач* кушымчалы форма реаль шартны, *-ганда* формасы, нәтиҗә фигыленә бәйле рәвештә, реаль, фаразый һәм ирреаль шартны белдерә ала. Кулланылу закончалыгы шарт фигыльнеке белән бер.

5. Шарт һәм нәтиҗә хәзерге заманда килгән ике фигыльнең мәгънәви һәм интонацион яктан каршы куелу юлы белән дә белдерелергә мөмкин: *Сугышка алалар, үлемгә куалар дип, хатын-кыз шикелле елап торып булмый инде. Куалар – барасың! Сугышка кертеп, туп авызына каршы куялар – үләсең* (Г. Ибраһимов).

**Кире шарт фигыль (концессив, уступительная модальность).**

1. Кире шарт модальлеге җөмләнең нәтиҗә өлешендә белдерелгән эш-хәлнең үтәлү-үтәлмәвенә шарт табылса да, эшнең киресе булуын белдерә.

Кире шарт фигыль зат белән төрләнгән шарт фигыль формаларына *да/дә, та/тә* кисәкчәләре өстәлеп ясала: *алсам да, эшләсәм дә, алсак та, эшләсәк тә, алсаң да, эшләсәң дә, алсагыз да, эшләсәгез дә, алса да, эшләсә дә, алсалар да, эшләсәләр дә.*

Бу – кире шарт фигыльнең төп формасы.

*Нигъмәтулла абзый, Мәҗидне мәдрәсәгә бирергә кирәк, дип бик күптәннән хөкем итеп куйса да, бүген-иртәгә ди-ди, берике еллар үтеп киткән иде* (С. Рәмиев). *Капка шыгырдаса да, тычкан кыштырдаса да, йөрәге дерт-дерт итеп, сикереп торды* (А. Гыйләҗев). *Сәгать сигез булды. Кияү мулладан элек чәй эчү әдәпсезлек булса да, Мәрфуга абыстай чәйсез түзә алмады*

(Г. Исхакый). *Тойгы туташ иртәсен йокысыннан уянганда, кояш байтак к ү т ә р е л г ә н , хәтта төш вакытлары да я к ы н л а ш к а н б у л с а д а , сарай эче тын, кәнизәкләр һәнүз әле йоклыйлар икән* (Н. Думави).

2. Кире шарт мәгънәсе шулай ук III яки II зат боерык фигыль формаларының юклыгы, сирәк очракта барлык формасы белән белдерелә. Гадәттә, боерык фигыльнең III зат юклык формасы сорау алмашлыклары белән килә: *нәрсә генә әйтмәсен, ни генә күрмәсен, кайда гына бармасын, ничек кенә булмасын* һ.б. *Сугышлымы яки солыхлымы – Н и н д и г е н ә ч о р д а б у л м а с ы н . Шагыйрь гомере ул – һәрбер чорның «Ярлыкагыл!» – дигән догасы* (Зөлфәт). *Н и н д и г е н ә а в ы р ш а р т л а р д а я ш ә м ә с е н , тарихның афәт җилләре кайсы якларга ыргытып т а ш л а м а с ы н , халык һәрвакыт үзенең кем икәнен онытмаган, балаларына милли тәрбия, белем бирү, ата-бабаларының гореф-гадәтләрен саклау хәстәрен күргән...* (Ә. Кәримуллин). *Яшь Муса. Җилләр и с с е н , давыл к у п с ы н , – барырмын, Ташлар я у с ы н , яшен с у к с ы н , – барырмын* (И. Юзиев).

Кире шарт мәгънәсен кайбер очракларда теләк фигыльнең I зат юклык формасы белдерә: *Быелгы беренче күк күкрәү авазын ишеттем мин туган якта. Кайда гына яхшы с ү з и ш е т м и м (~ ишетсәм дә), колакта әлеге күкрәү аһәңе* (Р. Фәйзуллин). Шарт мәгънәсен белдергән *-гач, -ганда, -ып* формаларына *да/дә, та/тә* кисәкчәләре өстәлеп, кире шарт мәгънәсе барлыкка килә: *К а б ы з г а ч т а (кабызсаң да) янмый. Ә й т к ә н д ә д ә (әйтсәң дә) колак салмый. Яфраклар а ч ы л ы п т а , җил кагылмаса, кошлар к а н а т к а г ы п т а , оча алмаса, учак я н ы п - я н ы п т а , ялкынланмаса, сулар т а ш ы п - т а ш ы п т а , дулкынланмаса, бик тә сәер булыр иде ләбаса!* (Р. Фәйзуллин). *Үз-үзеңне н и ч е к х ә й л ә л ә м ә (хәйләләсәң дә), Үз-үзеңнән н и ч е к я ш е р м ә (яшерсәң дә) – Язмыш үзе кушкан, шагыйрь, Әрнүләргә түзеп яшәргә* (Г. Кутуй).

**Шартлы теләк наклонениесе. Конъюнктив-шартлы теләк.** Конъюнктивның мәгънәсе һәм формалары бу категориягә ия булган Европа телләрендә һәм рус телендә шактый бәхәсле. Татар телендә шартлы теләк наклонениесенең *булыр иде* формасын 1801 елда басылган хезмәтендә беренче булып И. Гиганов күрсәтә. Төрки телләрдә бу форманы Ә. Юлдашев өйрәнә һәм аның теләк, фараз итү һәм эшкә

кушу мәгънәләрен күрсәтә. Шартлы теләк наклонениесенә ул дүрт форма керткән: *-р иде* (төп форма), *-ган булыр иде, -ачак иде, -а иде.*

Димәк, шартлы теләк наклонениесе сөйләүче тарафыннан фараз ителгән һәм контекстта теләк, өндәү, үкенү кебек экспрессив-эмоциональ мәгънәләр алган эш-хәлләрне белдерә. Шул рәвешчә, бу наклонение фаразый һәм ирреаль (реаль булмаган) шарт-нәтиҗә җөмләләрдән аерылып чыккан булырга тиеш. Алда күрсәтелгәнчә, шарт фигыльнең *-са/-сә* кушымчалы формасы фаразый һәм ирреаль шартны белдерә алганга, ирреаль эш-хәлне махсус белдерү ихтыяҗы туган. Шул рәвешчә *-ган булыр иде* формасы барлыкка килә. Күп вакытта бу форма белән белдерелгән эш-хәлнең үтәлмәвенә карата үкенү, борчылу кебек мәгънә төсмерләре туа.

Шартлы теләк фигыль мәгънәсе *-ган булыр иде* формасы белән генә түгел, *ачак иде* формасы белән дә белдерелә ала, *-а иде* формасы исә шартлы теләк фигыль мәгънәсендә сирәк кулланыла, шуңа күрә наклонениегә кертелми, аның хәзерге татар телендә төп функциясе – тәмамланмаган үткән заманны белдерү.

***-р/-мас иде* формасы.** 1. Җөмләдә шартка бәйле рәвештә кулланылса, гипотетик (мөмкин булган) һәм ирреаль эш-хәлләрне белдерә:

а) *Менә кайтып, шулар белән ике куллап бер күрешсәгез, олылап бер җылы суз әйтсәгез, сез аларны күпме сөендерер идегез, һәм күпме рәхмәт, күпме изге теләк алардан ишетер идегез* (Ә. Еники);

ә) *Адәменнән күзен алмый Хава, карамыйча башка чараң юк. Карар иде, ятка карар иде – Җир йөзендә башка адәм юк* (И. Юзиев).

2. Шартка бәйсез кулланылса, зат формалары төрле мәгънә төсмерләре ала:

а) I зат берлектә фараз ителгән эш-хәл күпчелек очракта теләк төсмере белән килә: *Бездәге табигать, бездәге киек җәнлекләр! Яз көне мин сезгә кыр тавыгы уйнаган урыннарны күрсәтер идем!* (Г. Мөхәммәтшин);

ә) II зат берлек һәм күплек санда йомшак өндәү, үгетләү төсмере була: *Син ди, Гыймадетдин кордаш, ди, миңа шуларның Байрак дигән авылларын күрсәтер иден, ди* (Г. Ибраһимов).

*-ган булыр иде* формасы *-р иде*нең варианты: бу очракта *-ган бул-* тасвирлама формасына шартлы теләк фигыль күрсәткече *-ыр иде*

ялгана. Фараз ителгән эш-хәлне тасвирлама форма ярдәмендә үткәнгә күчерү нәтиҗәсендә эш-хәл ирреаль (реаль булмаган) төсмер ала: *Юлга чыгуыгызны әйтеп телеграмма суккан булсагыз, ичмаса, Можгадан җиңел машинада, йончымыйча, рәхәтләнеп к а й т ы р и д е г е з. Каршы алырга, минә балаларны да утыртып, үзем б а р г а н б у л ы р и д е м* (Э. Касыймов).

*-ачак иде* формасы, хикәя фигыльнең киләчәк-үткән заманын белдерү белән бергә, шартка бәйле эш-хәлләрне дә белдерә ала; кулланылу закончалыгы *-р/-мас иде* формасыныкы кебек, ул потенциаль шартка бәйле фаразый эш-хәлне белдерә ала: а) *Теге ике кыз авылларына китеп бардылар, Фәлинә урамга-фәләнгә чыкса, ялгызы б у л а ч а к и д е* (Г. Рәхим); үтәлә алмый торган шарттан бәйле ирреаль эш-хәлне белдерә ала: ә) *Әгәр Әнәс дигән, башы-күзе акайган дуамал малай аяк чалып екмаган булса, туп, һичшиксез, теләләр капкасына к и л е п к е р ә ч ә к и д е* (В. Нуруллин); эшнең үтәлүе фаразый булуы контексттан күренә: б) *Ялантауны дошманга бирү Кызыл Армия өчен, Совет хөкүмәте өчен гадәттән тыш авыр югалту б у л а ч а к и д е* (М. Әмир).

Шул рәвешчә, *-ачак иде* формасының мәгънәсе шартлы теләк наклонениесенә карый, шуның белән бергә ул *-ачак* формасына хас катгыйлык төсмерен саклый, җөмләнең нәтиҗә өлешендә кулланыла. Җөмләдәге хезмәте ягыннан ул *-р иде* формасына туры килә.

Формаларның икесе дә, шартлы теләк мәгънәсе белән бергә, хикәя фигыль мәгънәләрен белдерә, ләкин *-р иде* формасы бу мәгънәне югалта бара һәм төп функциясе шартлы теләк наклонениесен белдерүгә кала бара, *-ачак иде* формасында исә, функцияләрнең икесе дә саклана. Шуны гына өстәп әйтергә мөмкин: *-ачак иде* формасы хикәя фигыльнең үткән-киләчәк заманын белдерүдә бердәнбер форма булып кала. Заман мәгънәсе нигезендә модаль мәгънә туган *-р иде* формасына килгәндә исә, ул шарт җөмләләрнең нәтиҗә өлешендә кулланылып, шартлы теләк мәгънәсен алган, һәм ул аның төп мәгънәсе булып калган.

**Шартлы теләк мәгнәсен башка формалар белән белдерү.** Алдагы бүлекчәләрдә боерык фигыльнең кайбер мәгънәләре (фараз итү, теләк, кисәтү һ.б.) шартлы теләк мәгънәсенә туры килүе әйтелгән иде. Шулай ук шарт фигыль формасы, нәтиҗә өлешеннән башка

кулланылып, шартлы теләк наклонениесенә хас теләк, үкенү, йомшак өндәү кебек мәгънәләр белдерә ала: *Ичмасам, бала-чага ата-анасы булмасагыз икән* (Ф. Хөсни). *Мөмкин булса, этеңне дә ияртсәң иде* (М. Хәбибуллин).

Шартның нәтиҗә өлешендә, югарыда әйтелгәнчә, *-а иде* һәм *-ган иде* формалары килергә мөмкин: *Башымны бер якка борып өлгердем, юкса, шул җәһәннәм базында җан биргән идем* (М. Мәһдиев).

Теләк, үкенү кебек мәгънә төсмерләрен *-рга иде* формасы да белдерә ала: *Үткәнне, хәзергене, киләчәкне бер фокуска җыеп күрсәтергә иде* (Г. Бәширов).

Шартлы теләк мәгънәсен *-гай(ы), -асы иде, -сын иде, -рга иде* формалары да белдерә.

**Мөмкинлек модальлеге**
**(мөмкинлек мәгънәсен белдерә торган формалар)**

**Төп формалар.**

1. Мөмкинлек модальлеген белдерә торган төп форма *-а/-ә, -ый/-и* кушымчалы хәл фигыльгә барлык яки юклыкта килә торган *ал-* фигыле өстәлеп ясала: *бар-а ал- / бар-а алма-, укы-й ал- / укы-й алма-, әйтә ал- / әйтә алма-* һ.б. Ярдәмче *ал-* фигыле барлык формаларда диярлек кулланыла. Кыек наклонениеләрнең кайбер формалары гына чыгарма булып тора. Ярдәмче фигыль: а) хикәя фигыль заманнарында килә: *Айрат Арслан, һичшиксез, җиребезгә милләтебез тарафыннан бары тик нәфис сүз остасы булу өчен генә яратылган шәхес. Без аны башкача күз алдына да китерә алмыйбыз...* (А. Хәлим). *Киенгәч, кая барырга дигән мәсьәлә килеп басты. Үзе генә берни дә кыра алмаячак иде* (Ф. Хөсни); ә) боерык фигыль формаларында була ала: *Тавышым ерак еллар күкрәгендә яңгырый алсын!* (Һ. Такташ); б) кыек наклонениеләрдә кулланыла, боерык фигыль формасында килә: *Илемә лаек булып яши алсам иде гомремдә!* (М. Ногман); в) затланышсыз формаларда очрый: *Син утның сул ягын кара, утның сул ягын күрә алганнар сирәк* (М. Галиев).

2. *-п бул- / -п булма-* формасы мөмкинлек мәгънәсен затка бәйләмичә белдерә ала: – *Ну, ничек, йоклап булдымы?* – *дип, Курамшинга кул сузды* (Ш. Бикчурин); исемләшә ала: *Бу тормыштан алып булганның Бөтенесен телим алырга, һәм ашыгам бирә*

*а л г а н н ы Соңынача биреп калырга* (З. Мансур). Бу җөмләдә беренче форма мөмкинлек мәгънәсен затка битараф белдерә, икенчесе – мөмкинлекнең беренче затка каравын күрсәтә.

Төп һәм ярдәмче фигыль юклыкта булса, мөмкинлек, кирәклек белдерелә: *Рәхиләне сагындым, к а й т м ы й б у л м а с ахры* (Ф. Хөсни).

3. *-рга бул- / -маска бул-* формалары мөмкинлекне затка битараф белдерәләр. Бу очракта *бул-* фигыле өч-дүрт формада килә ала: *-рга була, -рга була иде, -рга булыр, -рга булыр иде. – Нәрсәгә ярый соң ул? – Ачкычка т а г а р г а б у л а* (М. Маликова). *Төн караңгылыгы шактый сыекланган... тирә-якны, аяк астын ачык к ү р е р г ә б у л а и д е инде* (Б. Камалов).

4. *-са була* формасы мөмкинлекне зат формасында белдерә: *Башка мәсьәләләр турында у й л а м а с а г ы з д а б у л а* (М. Әмир).

5. Тартым кушымчалары алган *-у/-ү* кушымчалы исем фигыль *бар* яки *ихтимал, мөмкин* кебек модаль сүзләр белән килеп, мөмкинлекне, ихтималлыкны белдерә: *Олы улым сельхозда укый. Менә аның т ө п - л ә н ү е б а р* (М. Мәһдиев). *Уеннан уймак ч ы г у ы б а р* (М. Насыйбуллин). *Кечкенә самолет ул, очмый к а л у ы и х т и м а л* (Г. Ахунов). *Кем ыргыткан б у л у ы м ө м к и н ?* (Ш. Маннур). *Моңардан да зур гарантиянең б у л у ы м ө м к и н т ү г е л* (Ә. Еники).

Соңгы өч форма *-у/-ү* кушымчалы исем фигыль тартым кушымчалары ярдәмендә башкаручы затны белдереп, *бар, ихтимал, мөмкин* сүзләре белән килә һәм мөмкинлек, ихтималлык мәгънәләрен белдерә.

*-рга/-маска мөмкин (мөмкин түгел, мөмкин түгел иде), -рга/ -маска мөмкин бул-/-булма-* формалары белән төрле заманга караган мөмкинлек белдерелә: *Аңа каршы килеп булмый, аның тапкырлыгына бары тик с о к л а н ы р г а г ы н а м ө м к и н и д е* (В. Нуруллин). *Теләсәгез, алар белән бергә э ш л ә р г ә м ө м к и н б у л ы р* (Ш. Камал).

**Башка формаларның мөмкинлек мәгънәсендә кулланылуы.**

1. Контекстка карап мөмкинлек мәгънәсе теләк фигыль формалары белән белдерелә ала: *Эчендә җаны булган хатын иренең ятлар белән шаяруын т о й м ы й м ы с о ң !* (М. Маликова). *Шулай булгач, синең белән н и ч е к б е р б у л ы й м да ничек бер юлдан б а р ы й м !* (И. Гази).

2. Боерык фигыль белән мөмкинлекне белдерү: *Киң булып яшел болын җәелеп ята..., ә бер читтә Айдарның мотоциклы тора – утыр да тагын очып кит* (Ф. Хөсни).

3. Хикәя фигыльнең хәзерге һәм киләчәк заман формалары гомумиләшкән III затта килеп, мөмкинлекне белдерә: *Тәмле ризыкны аракы белән бозалармы?* (А. Гыйләҗев). *Ухалап алыйкчы бер. Белуга ухасы. Зәйтүн белән... Телеңне йотарсың* (Г. Минский).

Мөмкин түгеллек тиешле интонация белән әйтелгән билгесез киләчәк заман формалары белән белдерелә ала: *Тамагы ач булса, чыра юндырып кына ризалатырсың Хәбирне!* (Ф. Шәфигуллин). *Алырсың синнән ярага ябарга бер уч туфрак!* (А. Гыйләҗев).

4. Чикләнгәнрәк хәлдә кулланыла торган *-ырлык/-рмаслык, -ырдай/-рмастай, -гысыз/-кысыз, -малы/-мәле* формалары мөмкинлекне, мөмкин түгеллекне белдерәләр. Алар күбесенчә атрибутив функциядә кулланыла, ягъни аергыч булып килә: *Җаза кылырлык һичбер эше сизелмәде* (Г. Ибраһимов). *Аит яңгыр чылатырдай нәрсәләрне болдырдан ташып бетерде* (Ә. Гаффар). *Ерып чыккысыз эш, сыйнфый көрәш, ә ул кыланчык үзен һәм күлмәген күрсәтергә килгән* (Ф. Хөсни). *Анда әйтеп бетергесез күңелле* (А. Расих). *У-у, исе син пешергән ашның! Телең йотмалы* (М. Хәбибуллин). *-гысыз* формасы лексик яктан чикләнгән һәм аның барлыкны белдерә торган формасы юк; *-ырлык* формасына атрибутив кулланылышта *-маслык* формасы, предикатив функциядә *-ырлык түгел* формасы туры килә; *-малы* формасы әдәби телдә сирәк кулланыла, ул татар диалектларында очрый, юклыгы *-малы түгел. Кызларга чынлап та сүз әйтмәле түгел. Бер минут вакыт әрәм итмиләр* (Ә. Баянов).

Хикәя фигыльдә мөмкинлек белдерә торган формаларның үзәге буларак *-а/-ый + ал-/алма-, -ә/-и + ал-/алма-* формалары санала*: бара ала / бара алмый, укый ала / укый алмый, килә ала / килә алмый, эшли ала / эшли алмый.*

### Кирәклек модальлеге
### (кирәклекне белдерә торган формалар)

#### -асы кушымчалы формалар һәм аннан ясалган төрләр

1. *-асы, -асы түгел, -асы иде, -асы түгел иде.*

*Әйтче, җаныем, авылыгызга кайсы юлдан барасы? Урманны чыкканчы, үр менәсе* (Р. Хафизова). *Юк әле, юк. Бу тирәдән*

*булмый, әнә теге баштан у р а п  к е р ә с е* (В. Нуруллин). *Иртәгә эшкә б а р а с ы  т ү г е л* (А. Гыйләҗев). *Эш бик җиңел – иянең астына бер сызык, хәбәрнеке астына ике сызык  с ы з а с ы  да шуны русча сөйләп кенә бирәсе иде* (М. Мәһдиев). *Күршегә  к е р ә с е  т ү г е л  и д е  Галимҗанга* (Ә. Маликов).

2. *-асы бар, -асы юк, -асы бар иде, -асы юк иде* формалары кирәклекне, кирәк түгеллекне белдерәләр: а) *Бирде дөнья кирәкне, Еламаска өйрәтте... Кайсыгызның кулы җылы, Б ә й л и с е  б а р  йөрәкне* (Х. Туфан). *Үз юлың – пластинкалар бүлегенә  к и л ә с е ң ,  мәктәпкә дә  к а г ы л а с ы ң  б а р . Синең юлың – алда, минеке артта калган* (А. Гыйләҗев); ә) *-асы юк* һәм *-асы түгел* – юклык формалары киләчәккә караган эш-хәлне катгый рәвештә инкяр итү өчен кулланыла һәм үзара синонимик мөнәсәбәттә тора: *Хәйрүшкә күп а ң л а т ы п  т о р а с ы  ю к . Намек кына бир* (Ф. Хөсни). *Мич сүтәргә дигәндә, сине  ө й р ә т е п  т о р а с ы  т ү г е л ,  диген* (Ф. Хөсни). *Йөрәк яна сүнмичә, Сүнәр көнен белмичә, Яшьли сөйгән сөеклесен  О н т а с ы  ю к  үлмичә* (Х. Туфан). *Мин – Сөю! Минем мәңге дә  с ү н ә с е м  ю к* (Р. Әхмәтҗанов). Соңгы форма *-ачак* кушымчалы катгый киләчәк заманның юклык формасы белән синонимлаша.

3. *-асы бул-* формасының берничә төре бар, алар ярдәмче *бул-* фигыленең төрле формаларында килүе белән бәйле: а) *-асы була*: *Алар, ни хикмәттер, гел ашыгалар. Кайсының эше көтә, кайсының курортка  к и т ә с е  б у л а* (Ә. Еники); ә) *Истәлекләр сөйләп кайтыр өчен, Мәскәүгә дә  б а р а с ы  б у л ы р . Күп яшәгән бәндә булганлыктан, Мемуар да  я з а с ы  б у л ы р* (Х. Туфан); б) *-асы булгач-: Үрдән түбән т ө ш ә с е  б у л г а ч , утын төялгән чаналарны  т а р т а с ы  д а  ю к ,  үзләреннән-үзе түбән төшәләр* (Р. Хафизова).

4. *-асы булган* формасы үтәлми калган эш турында үкенү төсмере белән хәбәр итә: *«Ул үлгән...» – диде Әбүзәр абзый. «Бик дөрес эшләгән, элегрәк тончыкса, тагын да яхшырак  и т ә с е  б у л г а н »* (Г. Әпсәләмов).

5. *-асы калган* формасы үтәлергә кирәк булган эшнең үтәлми калуы турында үкенеч белән хәбәр итә: *Әллә кайчан  к е р ә с е  к а л г а н  аны Хәбир күршеләргә* (Ф. Шәфигуллин). *С а т а с ы г ы з  к а л г а н  йортыгызны* (Ә. Гаффар). Беренче мисалда (*керәсе калган* формасында) зат белдерелмәгән, ләкин контексттан аның сөйләүчегә каравы

ачыклана. Икенче мисалда (*сатасыгыз калган*) башкаручы зат *-асы* формасына ялганган тартым кушымчалары белән белдерелгән.

6. Күп очракта *-асы кал-* формасы үзенең туры мәгънәсендә кулланыла: *Һәм аш әзер... Насыйрны чакырасы гына калды* (М. Хәбибуллин). *-асы калган* формасы да туры мәгънәсендә кулланыла: *Иртәгә актык печәнне җыясы да, авылга кайтасы гына калган иде инде* (Г. Бәширов). Туры мәгънәгә ия булган бу формаларда мәҗбүри рәвештә чикләүче *гына* кисәкчәсе кулланыла. *-асы кал-* формасына синоним рәвешендә кулланыла торган *-рга кал-* формасы да чикләүче *гына* кисәкчәсе белән кулланыла: *Ах, Гөлшәһидә Бәдриевна, бүтәннәр йөрүенә куанырга гына калдым бит* (Г. Әпсәләмов). Күпчелек очракта мондый формада башкаручы затны юнәлеш килешендәге алмашлык яки исем белән белдерергә мөмкин.

**Кирәклек мәгънәсен инфинитив һәм аның нигезендә ясалган формалар белән белдерү**

1. Контекстка бәйле рәвештә кирәклек инфинитив + модаль сүзе белән белдерелә: *Алар яшендә ашыгалармы соң? Менә безгә ашыгырга кирәк... Тәндә көч, сихәтлек барында өлгерергә, өлгерергә!* (А. Гыйләҗев).

2. *-рга иде* формасы белән: *Әтинең сүзенә дә колак салырга иде* (Д. Зөбәерова).

3. Кирәклек мәгънәсе шулай ук *-рга* һәм *-мак* кушымчалы инфинитив + *кирәк* модаль сүзе белән белдерелә: *Кирәк анчак яшәр микъдар ашарга. Кирәкми тик ашарга дип яшәргә* (Г. Тукай). *Күлмәк өчен дә үпкәләшә башласаң, аннары ул кая китмәк кирәк* (Ф. Хөсни). *Сакларга кирәк, юк, тагын да ныгытырга кирәк табигать белән дуслыкны* (Г. Бәширов).

Кирәклек мәгънәсенең заман төсмерләре *-рга/-маска кирәк иде, -рга кирәк түгел иде* һәм *-рга кирәк булган* фигыльләре белән белдерелә. Кирәклек мәгънәсе боерык фигыльнең күчерелмә мәгънәләре арасында да бар.

**Тиешлек модальлеге**
**(тиешлек мәгънәсен белдерә торган формалар)**

1. *-асы* һәм *-асы иде* формалары башкаручы затны белдереп, предикатив функциядә килгәндә, тиешлек мәгънәсен белдерәләр: *Бу*

*арада митинг б у л а с ы  б и т* (Г. Коләхмәтов). *Нәкъ синең янга синең Латыйбыңны у т ы р т а с ы л а р , ди* (Ф. Хөсни). *Алар өйгә кереп китүгә, без бакча янына с ы з а с ы  и д е к* (Г. Бәширов). *Хәер, унсигез яшь сентябрьдә т у л а с ы  и д е* (М. Мәһдиев).

Шул рәвешчә, *-асы* һәм *-асы иде* формалары ике төрле мәгънәгә ия: конкрет затка карамаганда – кирәклекне (а), конкрет затка карагаңда – тиешлекне (ә) белдерәләр.

а) *Әйтче, җаныем, авылыгызга кайсы юлдан б а р а с ы ?* – кирәклек.

ә) *Бу арада м и т и н г  б у л а с ы  бит* (Г. Коләхмәтов) – тиешлек.

*-асы иде* формасы зат белән төрләнә: *-аласы идем, -аласы идең*, *-аласы иде...* һ.б. *-асы* формасының төрләнеш парадигмасыннан III заты гына сакланган.

2. *-асы* һәм *-асы иде* формаларының тиешлек мәгънәсенә синоним буларак инфинитив + *тиеш* модаль сүзе кулланыла. Модаль сүз факультатив рәвештә зат кушымчалары ала: *Үз эшен яраткан врач авыруны тиз аңлый торган сизгер күзләргә дә, ягымлы йөрәккә дә и я б у л ы р г а  т и е ш* (Г. Кутуй). *Кемгә т а я н ы р г а  т и е ш  м и н ?* (А. Расих). *Шул арада без аңа ашламаны к и т е р е п  җ и т к е р е р г ә  т и е ш б е з* (М. Хәбибуллин).

3. *Бул-* фигыле белән ясалган тасвирлама формалар тиешлек мәгънәсен төрле заманга күчерә алалар: *Мин анда н и ш л ә р г ә  т и е ш б у л а м  инде, иптәш Бәдретдинов?* (М. Хәбибуллин). *Күптәннән дәшми утырган Рушад фельдшер кызга мәсьәләне а ң л а т ы р г а т и е ш  б у л д ы* (М. Мәһдиев).

4. Тиешлек төсмере *-ачак* һәм *-ачак иде* формаларына хас: *Сизәсеңме, Европа хәзер безгә үзе килә! Себер тиздән дөньяны ш а у л а т а ч а к* (Ш. Бикчурин).

5. Контекстка бәйле рәвештә тиешлек мәгънәсен теләк һәм боерык фигыль формалары белдерә ала: *Сәлим Әдһәме тарих язсын да, мин аңа иремнең истәлек язмаларын үз кулым белән т о т т ы р ы й м , д и !* (Б. Камалов).

Хәзерге татар әдәби телендә *-рга/-маска тиеш* (*иде, бул-*) формалары иң киң кулланыла торганнардан, һәм аларны *тиешле* мәгънәсенең үзәгендә торучы формалар, дип бәяләргә мөмкин.

**Ният модальлеге**
**(ният мәгънәсен белдерә торган формалар)**

1. Бу мәгънәне белдерә торган форма *-макчы*. Ул I төр зат кушымчалары алып төрләнә: *алмакчымын, алмакчысың, алмакчы; алмакчыбыз, алмакчысыз, алмакчылар.* Ләкин зат кушымчалары сирәк кулланыла: аеруча зат алмашлыгы төшеп калганда яки затны аерып күрсәтергә кирәк булганда: *Без – университеттан. Халык иҗаты – җыр, бәетләр җыймакчыбыз* (Ә. Гаффар). *Онытылмакчысың, ничектер акланмакчысың ...* (Р. Фәйзуллин). *Алар шәригать белән хөкем итмәкчеләр* (Г. Ибраһимов). *Нәрсә, абый? Әллә сигезенче дәрескә апкалмакчымы?* (М. Мәһдиев). Соңгы мисалда *-макчы* формасы, зат кушымчасы алмаса да, туры сөйләмдә кулланылган һәм II затка карый.

2. *-макчы иде* формасы II төр зат кушымчалары белән төрләнә: *алмакчы идем, алмакчы идең, алмакчы иде* һ.б. *Мин сездәге рационализация тәкъдимнәре белән кызыксынмакчы идем* (Ә. Баянов).

3. *-макчы бул- (-мак бул-)* формасы, башкалардан аермалы буларак, заман формаларын, шарт фигыль, затланышлы формаларын белдерә ала: *Сез бит әле кыш көне генә миңа өйләнмәкче булган идегез* (К. Тинчурин)/ *Язмышын да чукеп ясаган ул. Сандалына салган ачуын. Сандалында яньчемәкче булган Бөлгенлекне, сугыш ачуын* (Зөлфәт). *Ашагач-эчкәч, мин инде китмәкче булып ишеккә карый башладым* (Ф. Хөсни). *Ант итмәкче булуы аны бөтенләй аптырашта калдырды* (Г. Ибраһимов).

4. *-макчы бул-* формасының категорик үткән заманы, башка формалардан аермалы буларак, эшне үтәү турында карар кабул итү мәгънәсен белдерә: *Мин аңа сабакларымны тыңлатмакчы булдым* (Ф. Әмирхан). *Мулла кияүләрнең угыллары бар, ди. Бәбәй туена ни белән бармакчы буласың?* (Т. Исхакый).

**Инфинитив нигезендә ясалган формалар.**

1. *-рга/-*маска формасы контекстка бәйле рәвештә карар кабул итүне белдерә: *«Самат янына барырга!» – иртүк кабул иткән карары шул булды* (Б. Камалов). *Яшен тизлегендә уй узды: болынга! Әйе, әйе, болынга чабарга! Хәзер үк, сәгате, минуты белән* (Г. Ахунов).

2. *-рга/-маска булды* формасы да карарга килүне белдерә: *Мин башта сиңа читтән генә карап торырга булдым* (А. Расих).

*Фазылҗанов вак-төяк йомышлар белән күрше авылга үзе б а р ы п к а й т ы р г а  б у л г а н икән* (Ф. Хөсни). *Исмәт аны Хәернисага ө й - л ә н д е р е р г ә  б у л г а н  и д е* (Г. Әпсәләмов).

3. *-рга/-маска ит-* формасы *-макчы* формасына якын тора, ләкин мәгънәсе теләк-максатка якын: *Шатлыгыннан шыңшый-шыңшый урап йөрде, кулларыбызны я л а р г а  и т т е* (Г. Мөхәммәтшин). *Я т а р г а  и т с ә ң , менә бирегә минем урынга ятарсың* (М. Хәбибуллин).

4. *-рга тор-: Гөлчирә. Мин синең яныңа б а р ы р г а  т о р а  и д е м* (Т. Гыйззәт). *Онытылды телдән ы ч к ы н ы р г а  т о р г а н юк-бар сүзләр* (Ф. Яруллин). Форма эш-хәлнең менә-менә үтәлергә тиеш булуын белдерә.

5. *-рга йөр-: Ул нигә хәзер, авылны ташлап, калага к ү ч ә р г ә  й ө р и ?* (Г. Ибраһимов). *Бик дәү инженер и т ә р г ә  й ө р и м бит улыңны, Хәдичә* (Г. Ахунов).

6. *-рга/-маска* кушымчалы инфинитив формасы карар бирү, уйлау, җыену, исәпләү фигыльләре белән ясалганда ирекле сүзтезмәләргә якын: *Бу эшләрне ташлап, урманга, тауга к а ч а р г а  у й л а д ы м* (Г. Ибраһимов).

***-асы/-әсе* формасы һәм аның нигезендә ясалган төрләр.**

1. *-асы* формасы: *Үткән елларда читкә бергә чыккан белеше бар. Егор атлы. Шуның белән китмәкчеләр. Кул алмашка күрше малаен Ильясны и я р т ә с е л ә р* (Б. Камалов).

2. *-асы итте* формасы: *Җомга көн төштән соң ул да станциягә б а р а с ы  и т т е* (М. Мәһдиев). *Мәскәүдән килгән бер эксперт аны б ү л д е р ә с е  и т т е* (Ә. Баянов).

3. *-асы булды* формасы: *Мине Сабира кереп а л а с ы  б у л д ы* (Ә. Еники).

Бу формалар төрле төсмерләр белән ниятне белдерәләр.

Ният-максатны белдерә торган башка формалар.

1. *-ачак булды* формасы: *Булатлар шунда, капка төбендә аны к ө т ә ч ә к  б у л д ы л а р* (Г. Ибраһимов) – карар.

2. I зат теләк фигыль яки III зат боерык фигыльләр *дигән иде* фигыле белән килеп, максат, теләк, ният кебек модаль мәгънәләр белдерә: *Эшкә ө й р ә т и м  д и г ә н  и д е м . Әбүзәр Гиреевичның да к ү ң е л е  б у л с ы н  д и г ә н  и д е м* (Г. Әпсәләмов) – максат. *Д о ш - м а н л а ш м ы й к  д и с ә ң , моннан соң энекәшне кыстап, авыз ачасы*

*булма* (Б. Камалов) – максат. Югарыда ният-максат мәгънәләрен белдерә торган формалардан ешрак кулланыла торганнары китерелде: *-макчы бул-* һәм аннан ясалган төрләр, *-рга/-маска бул-, -рга/-маска итте-, -рга тор-.*

### Фараз итү модальлеге

Татар телендә фараз итү мәгънәсен белдерү өчен махсус форма: хәзерге-киләчәк фаразый заман бар.

Бу заман *-а/-ә, -ый/-и + торган* күрсәткечле хәзерге заман сыйфат фигыльгә нигезләнә, аңа I төр зат кушымчалары һәм *-дыр* кисәкчәсе ялгана:

| | Берлек | Күплек |
|---|---|---|
| I зат | *ала торган-мын-дыр* | *ала торган-быз-дыр* |
| II зат | *ала торган-сың-дыр* | *ала торган-быз-дыр* |
| III зат | *ала торган-дыр* | *ала торган-нар-дыр* |

*Отпуск алырсың. Көне-төне эшләп, кешегә тигән отпуск сиңа да тия торгандыр бит* (Ф. Хөсни). *Ихтимал, Ринатның зур музыкаль таланты әнисе ягыннан килә торгандыр* (Ә. Еники). *Сез, бәлки, минем җитди сөйләвемә ышанмый да торгансыздыр* (Г. Әпсәләмов). II затта *-дыр* кисәкчәсенең *икән* белән алышынуы мөмкин*: Шул сәбәпле килми торгансың икән* (А. Гыйләҗев).

Фараз итү модальлеге I (билгесез) киләчәк заман белән шарт фигыль формаларына *бәлки, мөгаен, булса кирәк, шаять* кебек модаль сүзләр кушылу юлы белән, *булыр* фигыле «ихтимал» мәгънәсендә кулланылганда: *килгән булыр, барасың булыр, бара булыр* һ.б. белән белдерелә.

## 4.3.3. Персональлек

**Зат категориясе.** Зат категориясе – фигыльнең нигез формаларыннан берсе. Фигыль, сүз төркеме буларак, тулы күләмдә фигыльнең затланышлы формаларында реальләшә. Аларга наклонениеләр: хикәя, боеру, теләк, шарт, кире шарт һәм шартлы теләк фигыльләре карый; хикәя фигыльгә заман һәм зат категорияләре хас.

1. Зат категориясенә ия булмаган башка фигыль формаларында – исем фигыль, сыйфат фигыль, хәл фигыльләрдә – фигыль мәгънәсе

көчсезләнә, чөнки аңа предметлык, предмет билгесе, эш-хәл билгесе кебек мәгънәләр өстәлә. Бу күренеш күрсәтелгән формаларда чагылыш таба: алар иң гомуми фигыль билгеләрен (барлык-юклыкны, аспектуаль үзенчәлекләрне, юнәлеш категориясен, фигыльгә хас башкару сәләтен) исем, сыйфат, рәвеш билгеләре белән кушалар,

Бу формаларның фигыльлек билгесе тагын бер үзенчәлектә чагыла: аларда белдерелгән эш-хәл атамасы (исем фигыль), эш-хәл буенча предмет билгесе (сыйфат фигыль), икенче бер эш-хәлнең билгесе (хәл фигыль) формаларының үз башкаручысы була ала, һәм ул лексик, морфологик яки контекстуаль чаралар белән белдерелә.

Башкаручы затны алмашлык (лексик чара) яки тартым кушымчасы белән белдерү грамматик зат категориясенә карамый, бәлки киң мәгънәдә аңлашыла торган **персональлек** дигән функциональ семантик категориягә карый: *Мин барып, бераз утыргач, Кәрим дә кайтты. Без күргән авырлыклар. Әйтәсе сүзләреңне әйтеп калдыр* (эш II затка карый). *Укытучы Нуриева. Беләм мин аны. Ишеткәнем дә, күргәнем дә бар* (Ә. Еники) – (эш I затка карый). *Әй, сез, чыбыклы юл буендагы чокырлар, орлар! Иңкүлектә уйнаган төлкеләргә әйтегез: сак булсыннар, аучы килгәнен сизми калмасыннар* (М. Мәһдиев) – (эш III затка карый). *Минем котыпта булганым юк, әмма папанинчыларга кабатланмас хөрмәт саклыйм* (А. Гыйләҗев) – (эш I затка карый).

Алга таба грамматик (морфологик) зат категориясе персональлекне белдерә торган башка чаралардан аерып каралачак.

Зат категориясе – эш яки хәлнең башкаручыга мөнәсәбәтен сөйләүче күзлегеннән белдерә торган грамматик категория. I зат эш-хәлнең сөйләүчегә каравын, II зат эш-хәлнең сөйләм юнәлгән адресатка каравын, III зат эш-хәлнең сөйләмдә катнашмый торган затка яки предметка каравын белдерә.

I һәм II зат формалары III затка ике билге буенча каршы куела:

а) I, II затлар һәрчак затны, кешене белдерә; ә) эшне башкаручы һәрвакыт сөйләмдә катнашучы була. III зат исә: а) затны да, предметны да белдерә ала; ә) III зат белән белдерелгән эш башкаручы сөйләмдә катнашмый. I, II зат белән III зат арасындагы мондый «ассиметрия»не, Э. Бенвенист фикеренчә, гарәп грамматикалары ачык күрсәтә [Бенвенист Э., 1973, с. 261–262]:

I зат – al-mutakallimu – сөйләүче,

II зат – al-muhatabu – сөйләм юнәлгән зат,

III зат исә – al-γaibu– «сөйләмдә катнашмый торган» (отсутствующий). III затның мин-син'нән аерылып торуы һәм заттан тыш предметны белдерә алуы Э. Бенвенистны шундый фикергә китерде: III зат – зат түгел. Чыннан да III затның шактый үзенчәлекле булуы алга таба күрсәтеләчәк.

Татар телендә зат категориясенең берьюлы затны-санны белдерә торган 6 формасы бар.Һәрбер форма ике морфологик вариантта кулланыла, һәм алар ике параллель парадигма хасил итә.

| Сан | Зат | Зат кушымчалары | |
|---|---|---|---|
| | | I (тулы) | II (кыска) |
| Берлек сан | I<br>II<br>III | *-мын, -мен*<br>*-сың, -сең*<br>-Ø | *-м*<br>*-ң*<br>-Ø |
| Күплек сан | I<br>II<br>III | *-быз, -без*<br>*-сыз, -сез*<br>-Ø*лар*, -Ø*ләр(-сын, -сен)* | -*къ, -к*<br>*-гыз, -гез, -ыгыз, -егез*<br>-Ø*лар*, -Ø*ләр (-сыннар, -сеннәр*) |

И с к ә р м ә : Җәя эчендә III зат боерык фигыльгә караган формалар күрсәтелгән.

I төр зат кушымчалары хәзерге, киләчәк, нәтиҗәле үткән заман нигезләренә ялгана. II төр зат кушымчалары исә хикәя фигыльнең калган үткән заманнарына һәм кыек наклонениеләргә кушыла.

И с к ә р м ә : Кайбер заман формаларында (хәзерге, беренче киләчәк һәм нәтиҗәле үткән заманнарда), I зат берлек санда (әдәби телдә), I, II зат берлек санда (диалектларда) тулы кушымчаларның кыска кушымчалар белән алышынуы очрый: *алам* формасы белән рәттән *аламын, алырмын* урынына – *алырым, алганмын, алгансың* урынына – *алганым, алганың*. Мәсәлән: *Башкалар аптырабрак торганда, ян сәкедән Корбангали карт җилкенеп торып басты: – Ялган! Син аны көчләп әйттергәнең!* (Г. Бәширов).

Хикәя, шарт, шартлы теләк (*-р иде*) наклонениеләрендә зат белән төрләнү формаларының тулы парадигмалары бар, шулай да аларда лексик яктан кайбер чикләүләр булуы мөмкин. Боеру һәм теләк наклонениеләренең зат парадигмалары тулы түгел. Боеруның II һәм III заты

бар, үзәк формасы – II зат берлек саны, чөнки ул эшкә кушу, боеруның төп адресатын белдерә. Теләк фигыльнең I заты гына сакланган, чөнки теләк – сөйләүче тарафыннан, ягъни беренче заттан әйтелә, һәм ул – аның төп формасы.

III зат берлек сан хикәя фигыль һәм II зат берлек сан боерык фигыль нуль форма белән белдерелә. «Мәгълүм булганча, индикатив парадигмасында үзәк форма итеп III зат берлек һәм күплек саналса, императив парадигмасының үзәге итеп II зат берлек һәм күплек саннары күрсәтелә. Мәгълүм булганча, үзәк формалар, кагыйдә буларак, нуль күрсәткечләренә ия була» [Володин А., Храковский В., с. 10–11]. Татар теленә карата мондый фикер 1927 елда Г. Алпаров тарафыннан әйтелгән иде. Ул – кушымча юклыгын иң киң кулланыла торган формаларга хас икәнлеген әйтә һәм татар телендә мондый формалар итеп II зат берлек сандагы боерык фигыльне һәм III зат берлек сан хикәя фигыльне күрсәтә [Алпаров Г., 1945, б. 91–92].

Эшне башкаручы зат алмашлыклары белән белдерелә ала, ләкин затланышлы формаларда аларның (затның) кулланылуы мәҗбүри түгел (факультатив), *-ган* кушымчалы үткән-хәзерге заманда (һәм өлешчә *-ачак* кушымчалы киләчәк заманда) затны аналитик юл белән, ягъни зат алмашлыклары белән белдерү ысулы очрый. Мәсәлән, әдәби телдә I, II зат күплек сан кушымчалары төшеп калырга мөмкин. Сөйләм телендә һәм диалектларда бу күренеш I зат берлек санда да очрый: *Без кемнәр белән генә бергә* *э ш л ә м ә г ә н ! Каян белеп бетерәсең аларны!* (Ә. Баянов). *Мин бер* *ә й т к ә н инде! Юыртырга исәбең бармы, юкмы?* (Г. Бәширов).

Аналитик юл белән затны белдерү *-макчы* кушымчалы ният һәм *-асы* кушымчалы тиешлек формаларына хас. Зат белән төрләнә торган *алмакчымын, алмакчысың* формалары бик сирәк һәм стилистик максат белән кулланыла: *Баланы кая* *к у й м а к ч ы с ы ң ?* (М. Хәбибуллин). Әмма бу формаларга караганда телдә *бул-* фигыле белән ясалган тасвирлама конструкцияләр өстенлек ала: *Мин бармакчы булам.*

**Зат формаларының мәгънәсе.** I зат берлек сан. Форманың парадигматик мәгънәсе – эш яки хәлнең сөйләүчегә каравы: *Мин монда көне-төне* *й о к ы н ы - я л н ы* *б е л м и* *у т ы р а м , минем исәпкә кемдер ансат кына ике йөзне алсын да куйсын* (Г. Ахунов). *Үзең ничек соң, – дип сорады ул аннары. – Эшлисеңме, укыйсыңмы?.. Ык-мык*

*итеп тордым да, куен кесәмдәге гаризаны чыгарып, аңа суздым* (Ш. Маннур).

**Синтагматик** мәгънәгә I затның мәкаль, әйтемнәрдә очрый торган гомумиләшкән мәгънәсе карый. *Русчаны белмим, татарчаны аңламыйм. Туры телемне тыялмыйм, туганыма керә алмыйм* (Н. Исәнбәт).

I зат күплек сан. Форманың **парадигматик** мәгънәсе – эш-хәлнең күпләгән затка каравын, шулардан берсе сөйләүче булуын белдерә. «Күпләгән» зат дигәнебез контекстта реальләшә. Эшне башкаручылар I зат күплектә сөйләүче һәм адресаттан (мин һәм син) торырга мөмкин: *Табынны әллә монда гына әзерлибезме, кызым, өйдә кызу булыр* (Т. Миңнуллин). *Без дөньяда синең белән икәү генә калдык, улым,.. – бер-беребезне ташламыйк, беребезне беребез рәнҗетмик... Икәү бергә сөйләшербез, икәү бергә дөнья көтәрбез* (Ф. Хөсни) (мин һәм син). *Инәй итәгендә энем белән мин дә, билгеле, кайтканбыз* (Ә. Еники) (ул һәм мин).

Автор сөйләменнән аңлашылган гомуми күплек: *Себергә китәсе булу, дөресен генә әйткәндә, сөендерде мине. Болай төп-тамыр белән йолкынып киткәч, кабат кайтмабыз инде. Җиргә, урманга бай Себердә нигезләнеп калырбыз дип уйладым. Сагынмабыз да шикелле тоелды...* (Ш. Маннур). *...Без бу юлның һәр квадратында үзебезнең эзләрне калдырдык. Фронтка без икмәкне шушы юлдан ташыдык. Язын чәчүлекнең байтак өлешен шушы юллардан алып кайттык* (А. Гыйләҗев). *Үткәннәргә борылып карый-карый, Киләчәккә юллар эзлибез. Бөек даннар булмаса да ярый, Яхшылыктан өмет өзмибез* (Г. Афзал).

Форманың **синтагматик** мәгънәләре:

1. Эш яки хәлнең сөйләүчегә каравы: – *Тимергали абзый! Комиссия белән син дә йөрсәң, бик тә яхшы булыр иде. – Соң, ярар, йөрербез, алай булгачыннан* (Г. Бәширов)

2. а) Эшнең гомумиләшкән затка каравы: *Ни өчен без, кыенлыклар килсә, кешеләрнең җаваплылыгын сызып ташлыйбыз әле* (М. Зарипов); ә) эш яки хәлнең сөйләүче дә катнашкан гомумиләшкән затка каравы: *Ярты гомеребез бергә үтә, ә кеше ничек яши – шуны рәтләп белмибез, – дип уйлады ул* (Г. Әпсәләмов); б) эш яки хәлнең сөйләүченең үзенә (адресант) һәм сөйләм юнәлгән адресатларны

үз эченә алган гомумиләшкән затка каравы: *Димәк, хәзерге көндә тел тарихын һәм әдәби тел тарихын язу өчен җитәрлек материал тупланды, дип ә й т ә  а л а б ы з* (Л. Мәхмүтова). *Мисалга менә бу җөмләне  а л ы й к* (С. Ибраһимов).

3. Эш яки хәлнең берлек сандагы адресатка каравы. – *Сәлам, күрше, я л  и т ә б е з м е ? – Ял итәбез....– диде карт өнәмичә генә* (Г. Ахунов).

II зат берлек сан. Форманың **парадигматик** мәгънәсе – эшнең адресатка каравы: – *Я л г ы ш а с ы ң , Гыймран! Б е л м и с е ң м е н и ? Галип кызы, диләр аны!* (Г. Ахунов). *Ике ел син хыянәт итеп я ш ә - г ә н с е ң ! (*А. Гыйләҗев).

Форманың **синтагматик** мәгънәләре:

1. Мәкаль, әйтем, афоризмнарга хас гомумиләштерелгән II зат мәгънәсе: *Күпне б е л с ә ң , тиз к а р т а е р с ы ң . Кеше ышанмастайны чын булса да, с ө й л ә м ә .*

2. а) Сөйләүче катнашындагы гомумиләшкән зат мәгънәсе: *Мифтах ачуыннан тешләрен шыкырдатып куйды. Юха елан! Ничек боргалана, ничек алдаша! Ү л ә р с е ң  гарьләнеп* (Г. Бәширов). – *Ашар вакыт җитте, иптәш капитан, ди бу. Үзен шул кадәр тыныч тота ки, ачуыңнан ш а р т л а р с ы ң !* (М. Харисов). Бу формага мөмкинлек, модальлек мәгънәсе дә хас; ә) эшнең сөйләүчегә каравы (беренче план) һәм гомумиләшкән зат мәгънәсе (икенче план): *Борчып бетерә инде бу бала сезне, Матвей Яковлич. Нишләтергә дә белмибез. Эштән кайтып керүгә, азрак и р к ә л и с е ң ,  с ө я с е ң , аннары я каһәр суккан телефон шалтырый, я китап а л а с ы ң ,  я газета, журнал к а - р а ш т ы р а с ы ң , ә бала онытыла* (Г. Әпсәләмов).

II зат берлек сан формасы сөйләүче дә катнашкан гомумиләшкән зат мәгънәсен белдерә. Бу фигыльләр, боерык фигыль формасында килеп, мөмкинлек, кирәклек, тиешлек мәгънәсен бирәләр: *Аркада – капчык, кулда – таяк. Алдыңда – очсыз кырыйсыз озын юл. А т л а  да а т л а ,  б а р  да б а р ! Туйдым!* (Г. Мөхәммәтшин).

3. II зат берлек сан гомумиләшкән I зат күплек сан мәгънәсен белдерә ала: – *Нишлибез? – диде берсе – Нишлибез? Пычагым э ш л и с е ң мени? Кендек сынды, тәртә каерылып чыкты. Бу килеш кая б а р а - с ы ң ? Чистай хәерчеләре шикелле, тәртә башын яндырып теләнергә к е р с ә ң  генә инде!* (Г. Бәширов).

II зат күплек сан. Форманың **парадигматик** мәгънәсе – эш яки хәлнең берничә зат тарафыннан башкарылуын белдерү, шуларның берсе (яки берничәсе) адресат (яки адресатлар) һәм сөйләмдә катнашмый торган зат (яки затлар): *Ни эшләп к а т ы п  к а л д ы г ы з  әле, кызлар? Марина, бар әле магазинга йөгер! Наташа, чәй куй, табын әзерлә!* (Ш. Бикчурин).

Форманың **синтагматик** мәгънәләре:

1. Эш-хәлнең берлек сандагы адресатына хөрмәт йөзеннән күплектә эндәшү: – *Сез дә апагызга  о х ш а г а н с ы з  икән. – Ә кемгә охшарга тиеш соң мин?* (М. Хәбибуллин)

2. Гомумиләшкән зат мәгънәсен белдерү: *Әйдә, үткәне, хәзергесе, кайгылары, шатлыклары – барысы өчен дә бүген берьюлы түксен ул күз яшен. Кирәкми,  ю а т м а г ы з  сез андый чакта кешене* (Ш. Бикчурин).

I һәм II зат формалары эш-хәлнең затка каравын белдерә, шуңа күрә табигать күренешләренә караган фигыльләр, хайваннар хәрәкәтен яки тавышларын белдергән фигыльләр I һәм II затта була алмый. Ләкин күчерелмә мәгънәдә килгәндә мондый фигыльләр бу затларда да килә ала. Икенче яктан «җанландыру» ярдәмендә затка карамаган күренешләрне адресат рәвешендә кулланып була: *Т а б и г а т ь ! К и т  минем юлларымнан!* (Һ. Такташ). *К а р а б а й ,  с и н  а к ы л л ы  и д е ң  бит! Олыны олы дип  б е л ә  и д е ң ... Иптәшлереңә  ә й т ,  тешләмәсеннәр мине* (А. Гыйләҗев).

III зат берлек сан. Форманың **парадигматик** мәгънәләре:

1. Эш яки хәлнең сөйләмдә катнашмый торган затка каравын белдерә: *Нәҗия Уразаева аның моңлы бер сагыш белән истәлекләр дөньясына кереп китүен, бүлдерми-нитми, озак кына  т ы ң л а п  у т ы р д ы* (Г. Ахунов).

2. Эш-хәлнең затка түгел, бәлки башка җан ияләренә, табигать күренешләренә караганын, хәл-торышны белдерә: *Кайдадыр якында гына  э т  ө р д е ... Я ң г ы р  сибәләргә  т о т ы н д ы* (А. Гыйләҗев).

3. III зат берлек сан III зат күплекне белдерә ала, ягъни эш-хәлнең сөйләмдә катнашмый торган затларга яки предметларга каравын күрсәтә. Зат яки предметлар күплектә булып, хәбәр берлектә килсә, эш яки хәлнең бүленмәгәнлеге белдерелә: чагыштырыгыз: *кунаклар килә* (бергәләп) һәм *кунаклар киләләр* (бер-бер артлы).

Форманың **синтагматик** мәгънәләре:

1. Башка зат формалары кебек, III зат берлек сан а) гомумиләшкән затны яки ә) билгесез затны белдерә ала. Бу очракта эш-хәлне башкаручы – исем, алмашлык яки башка субстантив сүз төркеме белән белдерелергә тиеш: а) *Җәй буе, көз буе урманнан кайтмый адәм баласы. Чикләвеген җыя, миләшен, баланын* (А. Гыйләҗев); ә) *Ишеттем мин кичә: бераү җырлый Чын безнеңчә матур милли көй* (Г. Тукай).

2. Фигыльнең III зат берлек формасы сөйләүче (I зат) һәм адресат (II зат)ны белдерә ала. Эш башкаручының белдерелүе мәҗбүри төс ала. Ләкин үзен һәм адресатны III зат белән белдергәндә, сөйләүче тыйнаклык, объективлык күрсәтергә тырыша: а) – *Һи, ахмак,– дип бүлдерде Сөләйман абзый улын. – Беләсең килсә, атаң алдында любой мастер бүреген сала... Әтиең мастер булырга теләсә, аны ике куллап мастер итәләр иде* (Г. Әпсәләмов); ә) *Матвей Яковличның уйчан йөзе кинәт яктырып китте. – О, Иштуган кайткан, – диде ул, кулларын җәеп (*Г. Әпсәләмов).

Күрсәтелгән синтагматик мәгънәләр III зат ясаган ияләренә, кешегә караганда гына туарга мөмкин. III зат предметларга караса, аның контексттa туа торган мәгънәләре чикле була.

3. III затта килгән *ди* фигыле гомумиләшкән III зат күплекне белдерә ала: *Туры әйткән туганына ярамаган, диме?* (Э. Касыймов). *Хәйран тамаша, ди, боларның тормышы* (Ф. Хөсни).

III зат берлек санның үзенчәлекле тагын бер мәгънәсе бар: ул субъектка мөнәсәбәтсез була ала, ягъни затны белдерми. Бу күренеш билгеле бер лексик мәгънәгә ия булган фигыльләргә, кайбер аналитик модаль конструкцияләргә хас:

1. Субъектсыз эш табигать күренешләрен чагылдырган фигыльләрдә күзәтелә [Зәкиев М., 1974, б. 47–48]: *Соң яктыра, бүген суыткан, җылыта, ява, караңгылана, болытлый, буранлый* һ.б. *Иртә аязмаса, кич аязмас* (мәкаль). *Бик корыга китте, улым* (М. Мәһдиев).

Бу төркемчәгә караган кайбер фигыльләрнең үз иясе дә була: *яшен яшенли, яңгыр ява, күк күкри, көн җылыта, таң ата, караңгы төшә, яшен сукты*. Бу фигыльләр III затта гына кулланыла.

2. а) Субъекты белдерелмәгән III зат берлек санда булганда һәм йөкләтү юнәлешендә килгән фигыльләр кешенең физик һәм рухи

халәтен чагылдыра: *туңдыра, өшетә, калтырата. Сызылып таңнар аткан чакта е л а т а да, җ ы р л а т а* (халык җыры); ә) бу төркемчәгә предикатив (хәбәрлек) мөнәсәбәткә нигезләнгән һәм III зат берлек санда гына кулланыла торган фразеологик фигыльләр якын тора: *салкын тию, хәл бетү, хәтер калу, эч пошу, ачу килү, көзән җыеру, бизгәк тоту* һ.б. Димәк, кешегә караган эш-хәлне белдерүче фигыльләрдә башкаручы зат тартым кушымчасы белән белдерелә ала: *эчем поша, хәтере калды, ачулары килгән* һ.б. (бу күренеш киң мәгънәдә аңлашыла торган функциональ-семантик категория – персональлеккә карый).

3. Зат категориясе юнәлеш (залог) категориясе белән мөнәсәбәткә керә: күчемсез фигыльләрдән ясалган III зат берлек сандагы, *бүген күп й ө р е л д е, озак й о к л а н г а н* кебек фигыльләр а) I зат – бер кешегә, ягъни сөйләүчегә, ә) сөйләүче катнашкан I зат күплеккә карый: *Ялгыш йоклап к и т е л г ә н бит, Тимергали абзый, түзә а л м а г а н м ы н* (Г. Бәширов). *Акрынлап атлый торуга «Ял» кафесына җ и т е л г ә н – шунда кердек* (Ә. Баянов).

4. Зат категориясе аналитик модаль формалар белән дә мөнәсәбәткә керә. Мәсәлән, а) III зат берлек сан субъектсыз эш-хәлне белдерү өчен кулланыла: *алып була, алып булыр, алырга иде, аласы калган* һ.б.; ә) III зат берлек, үз мәгънәсеннән тыш, белдерелмәгән субъектка карарга мөмкин: *аласым килә, аласың килә, аласы килә* парадигмасында – **теләкне** һәм *аласы иде* формасы, контекстка бәйле рәвештә, **тиешлекне** белдерә. Соңгы очракта тезмәнең модаль мәгънәсе дә үзгәрә.

Субъектны белдермәү III зат берлектә күзәтелә (эш-хәл исә, кагыйдә буларак, I затка карый): *И с к ә т ө ш ә : Тегермәнлек үрен менгән чакта, Мәңге җилдә калган каеннар...* (Р. Фәйзуллин).

Затны белдергән *аласы иде* формасы *(аласы идем, аласы идең, аласы иде)* парадигмасында үткәнгә караган тиешлек мәгънәсе белдерелә: *Эх, Рушанна, сыңар күз белән бер к а р а п а л а с ы и д е үзеңә* (А. Гыйләҗев).

III зат күплек санның **парадигматик** мәгънәсе: 1. Эшнең сөйләмдә катнашмый торган күп затларга каравы: *Өйдә кызлар, пычакны Фәез кулыннан алып, үзләре бәрәңге п е ш е р д е л ә р* (Ә. Баянов). 2. Затка карамаган предметларга каравы: *Ә була шундый шигырьләр..., күңел түренә у з а л а р алар* (М. Әмир).

Алда әйтелгәнчә, III зат берлек сан эш-хәлнең вакытын, урынын, хәтта субъектларны бүленмәгән бер бөтен итеп күрсәтү өчен файдаланыла: *Ул ашыкканга карап, б ө т е н  а т л а р  а ш ы г а , Акбәкәл, аларны үзенә ияртеп, кешни-кешни алга таба  ч а б а  и д е* (Г. Галиев). *Атналар буе вагонда килгән а т л а р , җиргә аяк басу белән, искиткеч җанлы  х ә р ә к ә т к ә  к и л д е л ә р , һәммәсе дә шунда ук борыннарын төртеп  җ и р  и с н ә р г ә ,  а у н а р г а  т о т ы н д ы л а р* (Г. Галиев).

III зат берлек һәм күплек сан абстракт төшенчәләрне белдергән исемнәргә карарга мөмкин: *У й л а р ы м , ак болытлар сымак, салмак кына  а г а ,  Үз агымын алар  т а б а* (К. Латыйп).

Форманың **синтагматик** мәгънәсе:

а) эшнең билгесез затка караганлыгын белдерү. Бу очракта эш-хәлне башкаручы конкрет зат яки предметлар әйтелми, ләкин алар күздә тотыла: *Менә бер әсәргә анализ  я с ы й л а р , эчтәлеге  т и к ш е р е л ә , идеясе  т и к ш е р е л ә , ә теле – юк* (Х. Сарьян);

ә) гомумиләшкән затны белдерү: *Яшь беткәнче,  е л ы й л а р м ы - н и !  Күзең ни белән белдерер, күкрәп шатлык килгәч?* (Р. Фәйзуллин). *Чәчәк исемнәрен бәләкәйдән  ө й р ә н ә л ә р* ( М. Юныс). Китерелгән мисалларда форманың мәгънәсе модаль әйләнмәләргә синоним була ала: *елыйлармыни – еларга ярыймыни; өйрәнәләр – өйрәнергә кирәк;*

б) эш-хәлнең сөйләүчегә каравын белдерү: *Бар инде, бар, йөгер, соңга калуың бар... Бар,  д и л ә р  сиңа... Иптәшләреңнән калырсың* (М. Хәбибуллин).

в) эш-хәлнең адресатка каравы: *– Бабай, ул үзе баткан. – К а - р а п  т о р а л а р  аны,  б а т ы р м ы й л а р* (А. Гыйләҗев). Фигыльнең III зат күплек саны да шартлы теләк мәгънәсендә килгән җөмләдә үтәлергә тиеш булган, ләкин үтәлми калган эш турында үкенү мәгънәсен белдерә: *С и н  д ә  б а р ы р л а р .*

**Затланышсыз формаларда персональлек.** Эш башкаручы зат сыйфат фигыль, хәл фигыль, исем фигыльләрдә дә, ягъни зат белән төрләнми торган формаларда да, белдерелә ала. Бу күренешнең сыйфат фигыльләрдә чагылышын Ф. Хисамова тикшергән иде [Хисамова Ф., 1969, б. 121].

Атрибутив функциядә килгән сыйфат фигыльләрдә эш башкаручы түбәндәге чаралар белән белдерелә:

1. Зат алмашлыгы яки баш килештәге исем белән: *мин (син, ул, без, сез, алар) укыган китап, без яулыйсы үрләр, сез укыган мәктәп, апам бүләк иткән күлмәк, бишенче класста укучы балалар, син тапшырачак имтихан.*

2. Аергыч белән аерылмыштан торган сүзтезмәләрдә *(безне укыта торган апа, бала карый торган хатын, машина йөртүче егет)* эш субъекты аерылмыш белән белдерелә, *-учы* кушымчалы сыйфат фигыль өчен эш субъектын ачыклау бердәнбер функция булып тора.

3. Исем фигыль һәм исемләшкән сыйфат фигыльләрдә эш башкаручы тартым кушымчалары белән белдерелә: *Камилне күптән күргәнем юк, ашаганы бал да май. Белмәгәне-күрмәгәне юк бу дөньяда* (М. Шабай). *Киләчәктә ул тапкан ысулны төзәтәчәкләрен, хәтта бөтенләй юкка чыгарулары ихтималын да белә...* (М. Зарипов).

4. Иялек килешендәге алмашлык һәм исемгә ялганган тартым кушымчалары белән: *Чибәркәй генәң түгел, иргә чыкканыма алты ел инде минем!* (Д. Вәлиев). *Нурия әтисенең кемгәдер өйләнәчәген аңлап алды* (Г. Ахунов).

5. Фигыль формасындагы тартым кушымчасы һәм исем яки алмашлыкның баш килеше белән (эмоциональ сөйләмдә): *Сез бит... беркайчан да әни булганыгыз юк!* (Д. Вәлиев).

6. Иялек килешендәге I һәм II зат алмашлыклары һәм тартым кушымчасы алмаган сыйфат фигыльләр белән: *Без беләбез сезнең киләчәкне, Без беләбез сезнең киләсен, без беләбез алгы көрәшләрнең Безгә җиңү алып киләсен* (Һ. Такташ). *Безнең җиңәчәк болай да билгеле бит инде* (М. Мәһдиев).

7. Башкаручы зат контексттан аңлашыла: *Я, белмәгәнгә салынма!* (Г. Бәширов). Боерык фигыльдән эшнең II зат берлеккә каравы аңлашыла. *Ах, бәла! Безне казый күргән имеш, уйнаганны ул карап торган имеш* (Г. Тукай). Эш I зат күплеккә карый (моңа *безне* алмашлыгы ишарә итә).

**Исем фигыльләрдә** персональлек исемләшкән сыйфат фигыльләрдәге кебек формалаша. Аларга зат белдерүнең түбәндәге юллары карый:

1. *Көз килүнең беренче билгесе тагын нәрсә?* (М. Мәһдиев). 2. *Ул көй отарга килүебезне бөтенләй онытты ахры* (Г. Ибраһимов). 3. *Нинаның кайтып төшүе Булатны канатландырып*

*җибәрде* (Г. Ибраһимов). 4. *Иртәгә кояш чыгуына ышанасыңмы? Моңа ышансаң, революция килүенә дә ышан* (Г. Ибраһимов). 5. *Соңгы көннәрдә көнен дә, төнен дә очтык без. Азрак черем итеп алуга – күккә* (Ш. Рәкыйпов).

**Хәл фигыльләрдә** башкаручы зат : 1) рус телендәге шикелле, төп фигыль белән бер үк булырга мөмкин: *Сәгать чамасы ишек төбе саклагач, кыз үзе кайтып килде. Шатлыклары эченә сыймады. Аталы-кызлы әкрен генә менделәр* (Ә. Баянов); 2) хәл фигыльгә караган башкаручы төп фигыльдәге заттан аерыла: *Ул көнне алар төн авышканчы йокламадылар* (Г. Мөхәммәтшин).

**Инфинитив формаларында** эш башкаручы зат төп фигыль белән бер үк булырга мөмкин: *Мин җавап бирергә теләмим, дип, кул куегыз* (Г. Ибраһимов).

Инфинитивның *кирәк, тиеш, мөмкин, ярый* кебек модаль сүзләр белән килүе – киң таралган күренеш. Ләкин тиешлек мәгънәсен белдергәндә генә башкаручы зат баш килеш белән белдерелә, хәбәр булып инфинитив янәшәсендә *тиеш* модаль сүзе килә, һәм ул зат кушымчалары ала: *Алдан сөйләшкәнчә, сез атнага ике мәртәбә килергә тиешсез* (Ә. Еники). Калган очракларда эш башкаручы зат алмашлыгы яки исемнең юнәлеш килеше белән белдерелә: *Безгә, Айдар, бик ныклап сөйләшергә кирәк* (Ф. Хөсни). *Миңа бер сорау бирергә мөмкинме?* (Г. Ахунов).

Сөйләм телендә башкаручы затның шундый ук әйләнмәдә баш килештәге исем яки алмашлык белән белдерелүе очрый: *Мин болай уйларга мөмкин, син бу хакта уйламаска мөмкин*. Бу алым әдәби телдә дә очрый: *Мәхәббәт кешене сукырайтырга мөмкин*. Бу әйләнмә затланышлы формага синоним булып тора. *(Мәхәббәт кешене сукырайта ала).*

Инфинитив белән белдерелгән эш-хәлнең башкаручысы контексттан яки сөйләм ситуациясеннән аңлашылырга мөмкин: *Рәмзи, өйгә дә кереп тормыйча, тәрәзәдән генә кычкырды: «Хәзер үк килергә әйттеләр»* (Г. Бәширов) – эш адресатка юнәлгән. *Тәвәккәлләп уңга борылдым... Хәзер биеккәрәк күтәрелергә тырышырга кирәк* (Ш. Рәкыйпов) – эш I зат берлеккә карый.

Инфинитив белән теләк белдерелгәндә эшне башкаручы I зат була: *Их, шушы җилгә ияреп, кырлар буйлап исәргә иде!* (М. Мәһдиев).

Инфинитив формасы белән эш кушу белдерелсә, аның башкаручысы күп вакытта адресат була: *Костин взводка таба борылды... «Атлардан төшәргә!»* (Г. Гобәй). *Китапларыгызны язганчы, бераз безнең арада кайнаштыргаларга иде сезгә* (М. Мәһдиев).

Затка төрле юллар белән ишарә ителгән затланышсыз формаларда зат белән мөнәсәбәтнең, затланышлы формалардагы кебек үк, парадигматик мәгънәсе була. Синтагматик яктан персональлекне, күбесенчә, гомумиләшкән зат һәм билгесез зат мәгънәләрен белдерә.

1. II зат берлек санның гомумиләшкән зат мәгънәсе:

а) зат тартым кушымчалары белән белдерелә: *Әйткәннәрең булсын туры сүз генә* (Р. Әхмәтҗанов). *Мондый көндә ышыкта ятуың хәерле* (М. Ауэзов). *Кешенең яңа киемен кигәнче, үз искеңне кигәнең артык* (әйтем);

ә) гомумиләшкән зат контексттан аңлашыла: *Артыгын җыю кайдан башлана? Мәхәббәтне, үзеңә ышанычны үз хәнҗәрең белән суюданмы?* (Б. Камалов). *Ят өйләргә төшкәч, шунысы яман: атна да гына узмый, кагалар* (М. Кәрим);

б) затланышсыз форманың башкаручысы төп фигыльнеке белән бер үк була икән, аның мәгънәсе дә төп фигыль белән бер үк була: *Ятып калганчы, атып кал* (әйтем). Гомумиләшкән мәгънә II зат берлек сан белән белдерелгән.

2. III зат берлек санның гомумиләшкән зат мәгънәсе. Зат тартым белән белдерелә: *Беренче тәэсиргә карап кына кеше турында фикер йөртүе кыен нәрсә* (М. Хәсәнов). *Прораб сорый идеме, әмер бирүе булдымы, аермачык әйтүе читен иде* (Б. Камалов).

3. III зат күплек санның билгесез зат мәгънәсе. Башкаручы зат тартым кушымчасы белән белдерелә: *Мондый сорауны бирәселәрен ул, әлбәттә, көткән, ләкин аңа җавап хәзерләп өлгермәгән иде сыман.*

4. Зат белдерелмәгән булса, башкаручы гомумиләшкән яки билгесез зат булырга мөмкин: а) *Шабашникларга гына исәп тоту – хата* (Б. Камалов); ә) *Мең кат ишеткәнче, бер кат күрү яхшырак* (Б. Камалов). *Азмы какканны вә сукканны күтәрдем мин ятим* (Г. Тукай).

Субъект-предикат мөнәсәбәтләренә нигезләнгән фразеологик фигыльләрдә башкаручы зат, затланышсыз формалардагы кебек, тартым кушымчасы белән белдерелә: *йокы-м килә, йокы-сы килә, исегез*

*китмәсен.* Мисаллардан күренгәнчә, башкаручы тартым кушымчалары белән белдерелгән фигыль өлеше төрле заман һәм наклонение формаларында килә, ләкин һәрчак III зат формасын яки, затланышсыз формалардагы кебек, тартым кушымчалары ала.

Грамматик зат категориясе һәм персональлекне белдерүче башка чаралар наклонение, заман һәм аларның функциональ-семантик кырлары белән мөнәсәбәттә торалар. Мәсәлән, хикәя фигыльнең күп кенә модаль мәгънәләре гомумиләшкән зат булганда барлыкка килә. Инфинитив формалары белән белдерелгән теләк күбесенчә I затка, ихтыярны белдергәндә – II һәм III затка карый.

Модаль конструкцияләрнең мәгънәсе, конкрет зат яки гомуми зат булуга, затны белдерү-белдермәвенә карап, үзгәрергә мөмкин.

**Нәтиҗә.** Функциональ-семантик аспектта тикшерелгән наклонение, заман һәм зат-сан категорияләре фигыльнең нигез категорияләре булып тора. Өчесе дә предикативлыкны белдерәләр. Хезмәттә өйрәнелгән функциональ-семантик кырлар: темпоральлек, модальлек һәм персональлек – шулай ук предикативлыкка карый. Аларның бурычы, әлбәттә, предикативлыкны белдерү белән чикләнми, шулай да бу үзенчәлек өйрәнелгән функциональ-семантик «кыр»ларның әһәмиятле ягы булып тора.

Тикшерелгән функциональ-семантик кырлар (ФСК) наклонение, заман һәм зат-сан категорияләре тирәсендә тупланган.

Беренче баскычта тикшерү формадан мәгънәгә таба парадигматик һәм синтагматик яссылыкта алып барылды. Болай эшләү грамматик формаларның мәгънә төзелешен, семантик мөмкинлекләрен, соңгыларының тел яки сөйләм дәрәҗәсенә караган булуын билгеләргә мөмкинлек бирде. Синтагматик мәгънәләр арасында формаларның күчерелмә мәгънәләре күрсәтелде. Болар һәммәсе татар фигыленең грамматик яктан стилистик мөмкинлекләре бай булуын күрсәтте.

Икенче баскычта мәгънәдән формага таба алып барган тикшерү бер үк грамматик мәгънәне белдерү өчен төрле фигыль формалары кулланылуын, грамматикалашкан һәм грамматикалашып җитмәгән, ләкин уртак грамматик мәгънә белдереп, үзара синонимик мөнәсәбәттә торган фигыльле сүзтезмәләр булуын ачыкларга ярдәм итте. Мәсәлән, мөмкинлекне белдерә торган *-уы бар, -уы ихтимал: югалтуы*

*бар, килмәве мөмкин/ихтимал*; тиешлекне белдерә торган һәм III затта гына кулланыла торган *-ачак булды, -асы булды, -рга булды* һ.б.

Фигыль категорияләрен мәгънә һәм функция ягыннан тикшерү – *-а иде* һәм *-а торган иде* формаларының синонимик мөнәсәбәтләрен һәм семантик аермасын ачыкларга мөмкинлек бирде; *-ачак иде* формасының ике яклы булуы: 1) киләчәк үткән заманны белдереп, хикәя фигыльгә каравы һәм 2) икенче мәгънә белдереп, шартлы теләк наклонениесенә каравы ачыкланды; *-р иде* формасының да ике төрле мәгънәсе бар: 1) шартлы теләк, 2) хикәя фигыльнең заман формасы булуы, һәм хәзер бу соңгы функциянең кими төшүе күренде.

Гомумән алганда, бер яктан, грамматик формаларның күпмәгънәлелеге, икенче яктан, бер үк грамматик мәгънәнең күп төрле формалар белән белдерелүе татар теле грамматик чараларының стилистик мөмкинлекләре бай булуын дәлилли.

### 4.3.4. Фигыль юнәлешләре

**Гомуми мәгълүмат.** Юнәлешләр – фигыльнең иң катлаулы һәм бәхәсле лексик-грамматик категорияләреннән берсе. Татар тел белемендә «юнәлеш» төшенчәсенең эчтәлеге һәм күләме бертөрле билгеләнми. Галимнәрнең зур күпчелеге юнәлешләрне грамматик категория итеп карый, әмма бу категориянең асылы турында төрле карашлар яшәп килә. Л. Җәләй, мәсәлән, юнәлешләрне эшнең объектка мөнәсәбәтен белдерүче категория дип билгели; В. Хангилдин эшнең объектка гына түгел, субъектка да мөнәсәбәттә булуын күрсәтә; Д. Тумашева бу категориянең эчтәлеген процессның субъектка мөнәсәбәт белдерүе дип аңлата.

Татар телен өйрәнү тарихында юнәлешләрне сүз ясагыч категория итеп караучылар да булды (А. Казимбәк, М. Мәхмүдов, Х. Фәезханов һ.б.). Кайбер тел белгечләре исә (Г. Фәезханов, Җ. Вәлиди һ.б.) юнәлеш формалары арасындагы эчке бәйләнешләргә игътибар итмичә, аларны бер категориягә берләштерми генә тикшерделәр.

«Юнәлеш» төшенчәсенең күләменә карата да карашлар күптөрле. Каюм Насыйри, мәсәлән, юнәлешләргә юнәлеш кушымчалары дип аталып йөртелә торган кушымчаларны алган барлык фигыльләрне дә керткән. Аннан соңгы авторлар бу категориядә юнәлеш формаларының бер уртак грамматик мәгънә белдерердәйләрен генә караганнар.

Юнәлешләр турындагы тәгълиматка күп кенә башка мәсьәләләр дә бәйле. Шуңа күрә бу катлаулы проблема татар тел белемендә махсус тикшерелде [Зиннатуллина К., 1969]. Тикшеренүләр юнәлешләрнең фигыльнең төрле объект-субъект мөнәсәбәтләрен белдерүче катлаулы категория булуын ачыкладылар.

Татар телендә биш юнәлеш бар: төп, төшем, кайтым, уртаклык һәм йөкләтү юнәлешләре. Алар махсус кушымчалар белән тәгъбир ителәләр. Мәсәлән, *бизәү* фигыле түбәндәге биш юнәлеш формасы белән характерлана: *бизәү* (төп юнәлеш), *бизә-л-ү* (төшем юнәлеше), *бизә-н-ү* (кайтым юнәлеше), *бизә-ш-ү* (уртаклык юнәлеше), *бизә-т-ү* (йөкләтү юнәлеше),

Телебездә берничә юнәлеш кушымчасы алган фигыльләр дә күзәтелә. Мәсәлән: *бозылышу, очраштыру, оештырылу* һ.б.ш. Гомуми грамматик хезмәтләрдә аларны тамыр фигыльнең (бу очракта б*озу, очрау, ою* фигыльләренең) бер формасы итеп карау кабул ителгән. Шулай итеп, алар биш юнәлеш системасында урын тапмыйлар. Фигыльнең, традицион төп, төшем, кайтым, уртаклык һәм йөкләтү юнәлешләреннән тыш, тагын төшем-уртаклык (*бозылышу*), уртаклык-йөкләтү (*очраштыру*), уртаклык-йөкләтү-төшем (*оештырылу*) һәм башка шундый дистәләгән юнәлешләре бар булып чыга.

Әмма мондый фигыльләрне кабул ителгән биш юнәлеш системасында аңлату җиңелрәк һәм урынлырак. Бу фигыльләрнең юнәлешләр системасындагы урыны К. Насыйри тарафыннан XIX гасырда ук ачык билгеләнгән [Насыйри К., 1895, б. 15]. Берничә юнәлеш кушымчасы алган фигыльләр алар – беренчел (ягъни бер юнәлеш кушымчасы булган) яки икенчел (ягъни ике юнәлеш кушымчасы булган) фигыль формаларының теге яки бу юнәлешләре. Шулай итеп, *бозылышу – бозылу*ның уртаклык юнәлеше, *очраштыру – очрашу*ның йөкләтү юнәлеше, *оештырылу – оештыру*ның төшем юнәлеше юнәлешләр системасында үзләренә тиешле урынны табалар.

Һәрбер фигыль теге яки бу юнәлеш формасында була. Әмма телдәге фигыльләрнең бик аз өлеше генә биш юнәлеш формасында да килә ала. Төшем юнәлеше фигыльләрнең биштән бер өлешендә, кайтым һәм уртаклык юнәлешләре өчтән бер өлешендә генә күзәтеләләр. Йөкләтү юнәлешен барлык фигыльләрдән дә диярлек ясарга мөмкин. Ләкин юнәлеш формалары искиткеч күптөрле мәгънәләр белдерәләр.

Алар арасында саф грамматик мәгънә белдергәннәре дә (*әйтү – әйтелү, язу– язылу*), лексик-грамматик мәгънәдәгеләре дә (*бизәү – бизәлү – бизәнү – бизәшү – бизәтү*), сүзнең лексик мәгънәсен үзгәрткәннәре дә (*сугу – сугышу, күрү – күрешү*) бар.

Шулай итеп, татар телендә традиция буенча бүленеп чыгарыла торган юнәлеш категориясе, асылда, төрле характердагы мәгънәләргә ия булган фигыль формаларын берләштергән катлаулы морфологик ясалмалар системасын тәшкил итә.

Юнәлеш кушымчалары затка яки предметка каратылган процессларны белдерүче фигыльләргә генә ялганалар. Мондый мөнәсәбәтне белдермәгән, нигездә табигать күренешләрен белдерүче фигыльләр бары тик төп юнәлеш формасында гына кулланылалар: *давыллый, буранлый, яңгырлый* һ.б.ш.

Барлык юнәлеш формалары да булган фигыльләрнең саны йөздән артмый: *актару, бизәү, йөрү, йөгерү, казу, карау* һ.б.ш. Фигыльләрнең күпчелегенә дүрт (*бору – борылу – борышу – бордыру; бөгү – бөгелү – бөгешү – бөктерү)*, өч (*эчү – эчелү – эчерү; аву – авышу – аудару*), ике (*сыну – сындыру; җиңеләю – җиңеләйтү*), хәтта бер генә (*үтү* – балта, пычак турында; *ию* – йон коелу мәгънәсендә) юнәлеш формасы хас.

Юнәлешләрне тикшергәндә, күчемлелек-күчемсезлек һәм аның юнәлешләргә мөнәсәбәте мәсьәләсен ачыклап китми мөмкин түгел. Билгеле булганча, күчемлелек-күчемсезлек – ул синтаксик юл белән фигыльнең исемнән баш яки төшем килешендә килүен таләп итүитмәвен белдерә торган лексик-семантик категория.

Күчемле фигыльләр төзелә, ясала, барлыкка китерелә торган (*йорт салу, икмәк пешерү*), үзгәртелә торган (*чыршыны бизәү, тимерчыбыкны бөгү*), юк ителә торган (*дошманны юк итү, савытны вату*), сизү органнары белән сизелә, тоела торган (*тавыш ишетү, тәм сизү*) предметларга юнәлгән эш-хәлләрне белдерәләр. Күчемсез фигыльләр зат яисә предметның физик (*туңу, җебү*) һәм психик (*кайгыру, сагыну*) халәтен, пространстводагы торышын, хәлен (*яту, утыру*), хәрәкәтен (*йөрү, очу*), билгенең барлыкка килүен (*агару, картаю*), берәр нәрсә белән шөгыльләнүен (*укытучылык итү, укыту*) белдерәләр.

Төрки телләр материалында күренекле тел белгечләре Ш. Рамазанов һәм Э. Севортян күчемлелек-күчемсезлекнең төрки телләрдә тарихи урынын һәм юнәлешләргә мөнәсәбәтен ачыкладылар: юнәлеш

кушымчалары тарихи планда исемнән фигыль ясаучы (ягъни сүз ясагыч) кушымчаларга кайтып калалар (*кара-л-у, җылы- н-у, җылы-т-у*). Фигыльләрдә көчемлелек-көчемсезлек чикләнмәгән чорда алар бу мәгънәләрне дифференциацияләү өчен кулланылганнар. Юнәлеш кушымчаларының хәзер күзәтелә торган төрләндергеч функциясе чагыштырмача соңгырак күренеш, ул – юнәлеш формаларының сүз ясагыч функциясеннән арынуы нәтиҗәсе.

### Төп юнәлеш

Төп юнәлешнең махсус кушымчасы юк. Ул – кушымчалы юнәлешләрнең чыганак формасы. Телдәге барлык фигыльләр бернинди юнәлеш кушымчасы алмаган хәлдә төп юнәлештә булалар. Аларның уртак грамматик мәгънәсе дә юк. Төп юнәлеш башка юнәлешләргә алар белдергән мәгънәгә ия булмаган форма буларак кына каршы куела. Нәкъ менә шуңа күрә төп юнәлеш функциясендә кыек юнәлештәге теләсә кайсы фигыль килә ала. Мәсәлән, *эшләү* фигыленең йөкләтү юнәлеше *(эшләтү) эшләтелү, эшләтешү* һәм *эшләттерү* формалары өчен, *кию* фигыленең кайтым юнәлеше *(киенү) киенешү* һәм *киендерү* формалары өчен төп юнәлеш булып килгән. Телдә өчәр юнәлеш кушымчасы ялганган формалар да күзәтелә: *киендерешү, караңгыландыру, бәрелештерү* һ.б.ш.

### Төшем юнәлеше

И. Гиганов, И. Хәлфин, А. Троянский грамматикаларында ук, башка юнәлеш формалары белән беррәттән, *-л-* кушымчалы төшем юнәлеше формалары да бүленеп чыгарыла: *бирәмен – биреләмен, сөямен – сөеләмен, җибәрмәк – җибәрелмәк.* Страдательный дигән атаманы бу формаларга мәгънәләреннән чыгып бирәләр: предмет яки затны аңа карата башка кеше башкарган эш ягыннан билгеләү, нинди дә булса эш-хәлгә дучар булуны белдерү: *бирелмәк, сөелмәк, җибәрелмәк* (кем дә булса башка бирәү тарафыннан).

Мәгънәләрендәге уртаклыктан чыгып, төшем юнәлешенә *-н-* кушымчалы кайбер формалар да кертелгән: *алынмак* (*алмак*тан), *сайланмак* (*сайламак*тан).

Төшем юнәлешенең бу төп мәгънәсе көчемле фигыльләрдән ясалган формаларда гына күзәтелә, шуңа күрә татар теле буенча беренче хезмәтләрдә төшем юнәлеше көчемле фигыльләрдән ясалган

формалар белән чикләнә. Ләкин соңрак тел белгечләре (К. Насыйри, Ш. Иманаев) төшем юнәлеше кушымчасының күчемсез фигыльләргә дә ялгана алуына игътибар иттеләр: *ага – агыла, утырды – утырылды, йөрде – йөрелде.* Күчемсез фигыльләрдән ясалган *-л- (-н-)* кушымчалы формалар төшем юнәлешенең төп мәгънәсен белдермәсәләр дә, алар да «страдательный залог» исеме белән йөртелә башладылар.

Төшем юнәлешенең мәгънәсен тел белгечләре төрлечә аңлаталар. В. Хангилдин фикеренчә, бу юнәлеш грамматик субъект-иянең пассивлыгын, эш башкаручының билгесез булуын күрсәтә. М. Зәкиев эш башкаручының пассивлыгы турында сүз алып бара, Д. Тумашева, күчемле фигыльләрдән ясалган төшем юнәлеше формалары процессны логик объект башкарган итеп бирәләр, ә күчемсез фигыльләрдән ясалганнары эшнең үтәүчесез башкарылганын белдерәләр, дип исәпли. Төшем юнәлеше формаларының кайбер башка мәгънәләре дә искә алына, ләкин аларны төрлечә аңлаталар: я аларны *-л-* кушымчасының сүз ясагыч функциясе нәтиҗәсе итеп карыйлар, я кайтым юнәлешенә кертәләр, яисә, гомумән, игътибарга алмыйлар, төшереп калдыралар.

**Төшем юнәлеше формаларының ясалышы.** Фигыльнең төшем юнәлеше формасы татар телендә *-л- (-ыл-, -ел-)* кушымчасы ярдәмендә ясала. Тартыкка тәмамланган һәм сузыкка тәмамланган бер иҗекле нигезләрдән соң бу кушымчаның *-ыл-, -ел-* вариантлары килә: *тапшыр-ыл-у, җибәр-ел-ү, у-ыл-у, бу-ыл-у, и-ел-ү.* Калган очракларда, ягъни берничә иҗекле, сузыкка тәмамланган нигезләрдә *-л-* кушымчасы күзәтелә: *аша-л-у, күрә-л-ү* һ.б.ш.

Төшем юнәлеше күчемле фигыльләрдән дә *(ачу – ачылу, башкару – башкарылу),* күчемсезләрдән дә *(тору – торылу, бару – барылу)* ясала. Нигездә болар актив (башлануы, дәвам итүе һәм тәмамлануы башкаручы ихтыярында булган) эшне белдерә торган фигыльләр.

*-л-* кушымчасы алмаган фигыльләр анык классификацияләнмиләр. Аларның билгеле бер өлеше *-л-* формаларына хас мәгънәне *-н-* кушымчасы ярдәмендә белдерә: *бүләкләнү, гаепләнү, сайлану.* Бу түбәндәге очракларда күзәтелә:

1) нигез *л* авазына тәмамланганда: *ал-у – ал-ын-у, бел-ү – бел-ен-ү, сал-у – сал-ын-у;*

2) нигез *-ла-/-лә-* кушымчасына тәмамланганда: *бик-лә-ү – бик- лән-ү, сак-ла-у – сакла-н-у, бөгәр-лә-ү – бөгәрлә-н-ү;*

3) ике иҗекле нигездә, соңгы иҗеге ачык булып, беренчесе *л* авазына тәмамланганда: *алдау – алда-н-у, чолгау – чолга-н-у, үлчә-ү – үлчә-н-ү.*

Калган барлык очракларда *-л-, -ыл-, -ел-* кушымчасы кулланыла.

Фигыльләрнең икенче, күләме ягыннан шактый зур өлеше *-л-* кушымчасын да, мәгънәсе ягыннан аңа туры килгән *-н-* ны да кабул итми. Бу фигыльләрне түбәндәге төркемнәргә таркатып булыр иде:

1. Составларында *-л-* кушымчасы булган, ләкин *-л-*сыз мөнәсәбәттәш сүзләре булмаган көчемсез фигыльләр. Аларның кайберләре йөкләтү юнәлеше кушымчасы булган сүзләр белән мөнәсәбәттәш: *котыл-у – кот-кар-у, тара-л-у – тара-т-у, кузга-л-у – кузга-т-у,* кайберләре исемнәр һәм башка сүз төркемнәре белән мөнәсәбәттә торалар: *оялу (оят), сүрелү (сүрән), югалу (юк),* кайберләренең *-л-* кушымчасыз мөнәсәбәттәш сүзләре юк: *кайшалу, омтылу, тайпылу*.

2. Предметның нинди дә булса билгесе барлыкка килүен һәм үсешен белдерә торган *-ай-/-әй-, -й-, -лыг-, -ыг-, -ар-/-әр-, -р-, -л-, -лан-/лән-, -лаш-/-ләш-* кушымчалы көчемсез фигыльләр һәм шушы ук мәгънәне белдерүче кайбер башка фигыльләр: *киңәю, шатлану, арту, кору, шиңү, черү.*

3. Кешенең эчке халәтен белдерүче көчемсез фигыльләр, аерым алганда*, -сын-/-сен-* кушымчалы *авырсыну, ятсыну, кызыксыну* һәм шундый ук мәгънәле башка кайбер фигыльләр: *йөдәү, каушау, аптырау* һ.б.ш.

4. Аваз ияртемнәреннән ясалган фигыльләр: *шартлау, безләү, чырлау* һ.б.ш.

5. Нигездә табигать күренешләрен һәм затның эчке халәтен белдерүче, затка каратылмаган фигыльләр: *яктыру, буранлау, чәнчү, укшу*.

6. *-гала-/-гәлә-, -әлә-, -штыр-/-штер-, -мсыра/-мсерә-, -нкыра-/-нкерә-* кушымчалары алган, процессның үтәлү характерын белдерүче фигыльләр*: баргалау, укыштыру, йокымсырау;* аларның чыганак формаларына *-л-* төшем юнәлеше кушымчасы да иркенләп ялгана: *бару-барылу, уку-укылу* һ.б.

Төшем юнәлеше кушымчасы составында юнәлеш кушымчалары булган фигыльләргә дә ялгана ала: *уз-дыр-ыл-у, яса-т-ыл-у, уйла-н-ыл-у, сөйлә-н-ел-ү.* Кагыйдә буларак, уртаклык һәм төшем юнәлеше

кушымчаларын алган фигыльләрдән төшем юнәлешенең катлаулы формалары ясалмый.

**Төшем юнәлеше формаларының мәгънәләре.** Төшем юнәлеше формаларының абсолют күпчелеге күчемле фигыльләрдән ясала. Алар ике мәгънә белдерәләр:

1. Чын мәгънәсендә төшем юнәлеше чынбарлыктагы процессларны объектка каратып, объектның процессуаль билгесе итеп бирә. Чагыштырыгыз: *Укытучы дәфтәрләр тикшерә* (төп юнәлеш) – *дәфтәрләр укытучы тарафыннан тикшерелә* (төшем юнәлеше); *секретарь белешмәләр бирә* (төп юнәлеш) – *белешмәләр секретарь тарафыннан бирелә* (төшем юнәлеше). Шулай итеп, төп һәм төшем юнәлешләре чынбарлыктагы бер үк процессларны – процесс, үтәүче һәм объект арасында булган бер үк мөнәсәбәтләрне ике төрле белдерәләр. Төп яки төшем юнәлеше формасын куллану коммуникатив максатларга бәйле: нинди дә булса процессның башкарылуы турында хәбәр итәргә кирәк булса, бу процесс үтәүчесенә каратылып, аның билгесе итеп бирелә һәм төп юнәлештәге фигыль белән белдерелә *(укытучы тикшерә, секретарь бирә),* әгәр дә нинди дә булса предметның яки затның шушы процесска дучар булуын хәбәр итәргә кирәк икән, бу вакытта процесс туры объектына каратылып, аның билгесе итеп бирелә һәм төшем юнәлешендәге фигыль аша белдерелә *(дәфтәрләр тикшерелә, белешмәләр бирелә).*

Реаль чынбарлыктагы бер үк мөнәсәбәтләрне ике төрле бирү мөмкинлеге, затлар һәм предметлар үзара тәэсир итешкәндә, эш башкаручының процесска бәйле билгесе генә түгел, шул эшкә дучар булучы объектның да процесска бәйле билгесе ачылуга нигезләнгән. Морфологик планда моңа – фигыль формалары, синтаксик планда махсус актив һәм пассив конструкцияләр аша ирешелә. Мәсәлән: *Җир йөзендәге иң гүзәл, иң мәһабәт нәрсәләрне кеше башы уйлап тапкан, кеше кулы ясаган. – Җир йөзендәге иң гүзәл, иң мәһабәт нәрсәләр кеше башы белән уйлап табылган, кеше кулы белән ясалган* (И. Гази). *...Игенче һөнәрен мин... бөтен халык ихтирам итәргә тиешле иң изге һөнәрләрнең берсе дип саныйм – ...Игенче һөнәрен мин... бөтен халык тарафыннан ихтирам ителергә тиешле иң изге һөнәрләрнең берсе дип саныйм* (Г. Бәширов). Төп юнәлеш эшне эш башкаручының процессуаль

билгесе итеп күрсәтә: *кеше башы уйлап тапкан, кеше кулы ясаган; бөтен халык ихтирам итәргә тиешле;* төшем юнәлеше – объектның эш ягыннан билгесе итеп бирә: *иң гүзәл, иң мәһабәт нәрсәләр уйлап табылган, ясалган; ихтирам итәлергә тиешле иң изге һөнәрләрнең берсе.*

Бу мәгънәдәге төшем юнәлеше формалары янында эш башкаручы күп очракта бирелми. Мәсәлән: *Һәр елыбыз безнең гасырга тиң: Күпме көрәш юлы* *у з ы л г а н !* (Г. Насрый). *Соңгы җырым палач балтасына Башым тоткан килеш* *я з ы л а* (М. Җәлил). Ләкин мондый ике членлы конструкцияләрдә эшнең үтәүче белән мөнәсәбәттәшлеге саклана, нәкъ шул мөнәсәбәттәшлек бу формаларга эшкә дучар булу мәгънәсен өсти дә инде: *Көрәш юлы узылган* (без узганбыз), *соңгы җырым языла* (мин язам).

Ике членлы конструкцияләр шушы мәгънәдәге теләсә нинди төшем юнәлеше формаларыннан ясала алалар. Объект һәм субъектның зат яки предмет булуы, заты, саны бернинди дә роль уйнамый. Мәсәлән: *Питердан Казанга барышлый, Мәскәүгә гаиләсе янына кереп чыгарга да* *җ а й  т а б ы л д ы* (Р. Мөхәммәдиев). *Гаҗәеп бит! Җиңгәчәсенең сүзендә ник бер* *с ы к р а н у  и ш е т е л с е н !* (Ә. Еники). *Озын яллы сары ат җиз кыңгыраулы кара дуга һәм эшлияле камыт белән читән тарантаска* *җ и г е л г ә н* (Ә. Еники). *Көчсез калып* *и з е л г ә н ч е ,* *көчәнеп из дошманыңны* (мәкаль).

Әйтелгәннәр бу конструкцияләрне куллану мөмкинлекләренең чикләнмәгән булуын күрсәтә. Татар теле буенча беренче хезмәтләрдә аларны төшем юнәлешенә нигезләнгән бердәнбер конструкция итеп караганнар.

Соңгырак хезмәтләрдә татар телендә эш башкаручысы билгеле булган конструкцияләрнең булуына да игътибар иткәннәр. Өч членлы дип аталган конструкцияләрдә эш башкаручы кеше яки кешеләр коллективы, учреждение, предприятие һ.б.ш. булганда, ул исем + *тарафынан* бәйлек сүзе белән белдерелгән тәмамлык аша бирелә. Калган очракларда эш башкаручы исем + *белән* бәйлеге ярдәмендә белдерелә. Мәсәлән: *1928 елда Г. Ибраһимовка* *В Ц С П С  П р е з и д и у м ы  т а р а ф ы н н а н* *Хезмәт Герое исеме* *б и р е л д е .* *Хат* *Г а л и у л л а  к у л ы  б е л ә н  я з ы л г а н* *иде* (А. Шамов).

Өч членлы конструкцияләр, ике членлылар белән чагыштырганда, соңгырак күренеш булса кирәк. Чөнки өч членлы конструкцияләрдә

еш кулланыла торган *тарафыннан* бәйлек сүзе – гарәп теленнән алынма. Эш башкаручының исем + *тарафыннан,* исем + *белән* тәмамлыклары аша бирү конструкцияне катлауландыра, авыр аңлаешлы итә. Шуңа күрә аның кулланылыш сферасы шактый чикле. Ул, нигездә, татар теленең фәнни, рәсми, эш кәгазьләре стильләренә генә хас.

Тикшерелә торган конструкцияләргә *Без «Динамо» командасына (командасыннан) җиңелдек* тибындагы әйләнмәләр якын тора. Аларда эш башкаручы исемнең юнәлеш һәм чыгыш килеше формалары белән бирелгән. Мондый конструкцияләр стилистик яктан нейтраль, актив кулланылышта йөриләр.

Төшем юнәлеше формаларына, бераз чикләнгән булсалар да, фигыльнең барлык морфологик категорияләре дә хас. Мәсәлән: зат-сан категориясе:

| | Берлек сан | Күплек сан |
|---|---|---|
| I зат | *мин онытылырмын* | *без онытылырбыз* |
| II зат | *син онытылырсың* | *сез онытылырсыз* |
| III зат | *ул онытылыр* | *алар онытылырлар* |

Мисаллар: *Сез үлсәгез, мин дә онытылырмын, Яшәсәгез, мин дә яшәрмен* (М. Җәлил). *Рәүфәнең гаризасы бик зур газаплардан соң гына каралды* (А. Шамов). *Аерым кимчелекләренә карамастан, бу шигырьләр нигездә уңышлы язылганнар* (Х. Хәйри). Әмма сөйләмдә күбрәк III зат берлек һәм күплек сан формалары кулланыла.

Бу мәгънәдәге төшем юнәлеше формалары фигыльнең барлык затланышсыз формаларын да ясый алалар: сыйфат фигыльләрне *(онытылучы, онытыла торган, онытылган, онытылачак, онытыласы, онытылыр),* хәл фигыльләрне *(онытыла, онытылып, онытылганчы),* исем фигыльне *(онытылу)* һәм инфинитивны *(онытылырга).* Мәсәлән: *Чирәмгә чыгарып, су бөркеп юдырылган, сөртелгән гөлләрне, кире кертеп, үз урыннарына куялар* (Ә. Еники). *Чакырылган кешеләр арасында Рәүфә дә бар иде* (А. Шамов). *Өтәргә дип бардылар, өтелеп кайттылар* (мәкаль).

Бу мәгънәдәге төшем юнәлеше формалары процессның чынбарлыкка мөнәсәбәтен дә белдерәләр. Иң күп кулланылганы – хикәяләү наклонениесендәге фигыль формалары. Сирәгрәк булса да, шарт фигыль формасы да күзәтелә. Мәсәлән: *Ә бераздан Мәрьям абыстайның*

*колагына сузып кычкырткан гудок тавышы килеп и ш е т е л ә* (Ә. Еники). *Әгәр т о т ы л с а ң , таякның авыр башы... аның җилкәсенә төшәчәк бит* (А. Шамов).

Боеру һәм теләк наклонениеләренә килгәндә, алар төшем юнәлешенең үзенчәлекле мәгънәсенә бәйле рәвештә, телдә кулланылмыйлар: төшем юнәлешендәге фигыль белдергән процесс объектның теләгенә, ихтыярына бәйле түгел.

Тикшерелә торган мәгънәдәге төшем юнәлеше формалары барлыкта да, юклыкта да булалар*: әйтелә – әйтелми, көтелә – көтелми;* процессның үтәлү характерын белдерә алалар: *языла башлады, языла килде, языла тора, язылып бетте.*

Кайбер төшем юнәлеше формалары мәгънәләрендә үзгәреш кичерәләр, алар нәрсәгә дә булса дучар булу мәгънәсен алалар: *кыйналу* (интегү мәгънәсендә), *җигелү* (авыр эшкә алыну мәгънәсендә), *сатылу* (үз теләгең белән дошманга бирелү мәгънәсендә). Мәсәлән: *Нигә шулкадәр к ы й н а л ы р г а , к и ч е р е р г ә !* (А. Расих). *Чыдамады өченең берсе, торып, « Б и р е л ә м » дип кулын күтәрде* (М. Җәлил).

Бу мәгънәдәге төшем юнәлеше формалары, эш һәм туры объект арасындагы бәйләнеш йомшара төшкәндә, эшнең ихтыярсыздан башкарылуы төсмере алалар: *Көндез җиңел я з ы л а . Эсседә күп э ч е л ә .*

Башка юнәлешләрдән аермалы буларак, бу юнәлештәге фигыльләр тагын башка юнәлеш кушымчаларын ала алмыйлар. Ләкин ясалма исемнәргә һәм сыйфатларга нигез булып киләләр: *асылма, башкарылыш, изелгәнлек, казылма, китерелмә, корылыш, кушылма, кырылыш, кысылыш, тагылма, өстәлмә, җыелма, ачылмалы, кулланылма, күчерелмә, тезелмә, түшәлмә, ясалма, өрелмәле* һ.б.ш.

Шулай итеп, чын мәгънәсендә төшем юнәлеше формалары – төп юнәлеш белдергән реаль чынбарлыктагы мөнәсәбәтләрнең икенче төрле бирелеше, ягъни грамматик күренеш кенә. Шул ук вакытта аларда мөстәкыйль фигыльләргә хас барлык үзенчәлекләрне дә табып була.

2. Күчемле фигыльләрдән ясалган төшем юнәлеше формаларының зур бер төркеме, предметның яки затның нинди дә булса бер эшкә дучар булуын белдерүдән тыш, процессның үтәүче сферасы белән чикләнүен, башка предметка яки затка юнәлмәгән булуын да белдерә

ала. Чагыштырыгыз: *бозу – бозылу, борчу – борчылу, бөгү – бөгелү, вату – ватылу.* Беренче булып мондый формаларга Д. Тумашева игътибар итә. Актив-көчемле фигыльләр, *-л-* кушымчасы ялгану белән, пассив-көчемсез фигыльләргә әйләнәләр. Мәсәлән: *Бомба чокырларына су ж ы е л г а н* (И. Гази). *Яңа елда тынып газаплардан К ү т ә р е л - с е н иде күңелләр* (М. Җәлил). Бу формалар процессны читтән юнәлтелгән итеп тә белдерә алалар. Мәсәлән: *Бер генә минутка а ч ы л г а н тимер ишек яңадан шыңгырдап ябылды* (Г. Әпсәләмов). *Ачылган* (үзе ачылган яки кемдер тарафыннан ачылган), *ябылды* (үзе ябылды яки кемдер тарафыннан ябылды). Нәкъ менә шуның нәтиҗәсендә пассив-көчемсез төшем юнәлеше формаларында соңыннан эшкә дучар булу мәгънәсе барлыкка килә. Мәсәлән: *Җиләк бердән җ ы е л а* (әйтем). *Һәм беренче бокал к ү т ә р е л е р Исеме белән батыр дусларның* (М. Җәлил).

Көчемле фигыльләрнең төшем юнәлеше формалары актив-көчемсез мәгънә дә белдерергә мөмкиннәр. Мәсәлән: *Дирижер, б о - р ы л ы п , башын ия* (И. Гази). *Су читенә и е л д е м , Төнбоекка ү р е л - д е м* (Ә. Фәйзи).

Көчемсезлек мәгънәсендәге төшем юнәлеше формаларына фигыльләрнең барлык категорияләре дә хас (зат-сан, наклонение, барлык-юклык, заман, эшнең үтәлү характерын белдерүче формалар). Алар барлык затланышсыз формаларда да килә алалар. Кайберләре мәгънәләрен төп юнәлештәгедән, нигездә, үзгәртәләр: *сугу – сугылу* (юл уңаенда кереп чыгу), *үрү – үрелү* (нәрсәгә дә булса сузылу), *кагу – кагылу* (тиеп алу). Мәсәлән: *Шул вакыт кош аның Иренәнә с у г ы - л а ...* (М. Җәлил). *Язмыш көлде, үлем к а г ы л м ы й ч а Үтте минем яннан тирәләп* (М. Җәлил). Алар, төп юнәлештәге фигыльләр кебек үк, берничә юнәлеш кушымчасы, аерым алганда, уртаклык һәм йөкләтү юнәлешләре кушымчаларын алалар: *аерылышу, борчылышу, егылышу, кагылдыру, үрелдерү.*

Көчемсезлек мәгънәсендәге *-л-* кушымчалы формалар яңа сүз ясауга нигез булып киләләр. Мәсәлән: *борылыш, тукталыш, буталыш, бөгелеш, йончыганлык, кагылыш, сузылыш, өелмә, уелдык, аерылгысыз, борчылучан, буталчык, буялучан, күтәрелмә, сыгылма* һ.б.ш.

Шулай итеп, төп һәм көчемсезлек мәгънәсендәге төшем юнәлеше формалары бер үк фигыльнең көчемле һәм көчемсез формаларын

тәшкил итәләр. Шул ук вакытта *-л-* кушымчалы формаларда мөстәкыйль фигыльләргә хас билгеләрнең барысы да бар.

Күчемсез фигыльләрнең төшем юнәлеше формалары бик чикле санда. Беренче булып аларны К. Насыйри билгеләп үтә. Алар ике мәгънә белдерәләр:

1. **Эшнең ихтыярсыздан башкарылуы мәгънәсе.** Бу мәгънә кешенең эш-хәлен белдерә торган күчемсез фигыльләрдән ясалган төшем юнәлеше формаларында күзәтелә: *ашыгыла, адашыла, барыла, кайтыла, йөрелә, арыла, торыла* һ.б.ш. Мәсәлән: *Йөри торгач, үзләре дә белешмичә, биек яр читенә – Агыйделгә к и л е п  ч ы г ы л г а н* (Р. Мөхәммәдиев). *Яшьлек үтте, инде к а р т а е л д ы , Яшим хәзер читтә, ышыкта* (М. Җәлил). *Борчылган күңеле китапка омтылмады. А р ы л г а н да* (Г. Әпсәләмов).

Эшнең ихтыярсыздан башкарылуы мәгънәсен белдерә торган төшем юнәлеше формалары грамматик яктан затланышсызлар. Алар хикәяләү һәм шарт наклонениеләренең III зат берлек сан формаларында гына кулланылалар. Ләкин алар белдергән эш-хәлләр теләсә нинди эш башкаручы – сөйләүче, тыңлаучы һәм сөйләм процессында катнашмаучы өченче бер зат белән мөнәсәбәткә керә алалар, шуңа күрә билгеле үтәүчеле һәм гомуми үтәүчеле бер составлы җөмләләрнең оештыручы үзәге функциясен үтиләр. Мәсәлән: *Җитмәсә, бу аягы тагын – уңайсызрак т ө ш е л д е  ахры* (И. Гази) – билгеле үтәүчеле бер составлы фигыль җөмлә. *Авылыгызга кайсы юлдан б а р ы л а ?* – гомуми үтәүчеле бер составлы фигыль җөмлә.

Бу мәгънәдәге төшем юнәлеше формаларында мөстәкыйль фигыльләргә хас билгеләр күзәтелми. Бу – саф грамматик күренеш.

2. **Чыганак фигыль белән мәгънәдәш формалар.** Телдә төп юнәлеш белән мәгънәдәш яки мәгънәләре белән якын төшем юнәлеше формалары да күзәтелә: *агу – агылу, туктау – тукталу, ыргу – ыргылу, ургу – ургылу* һ.б.ш. Мәсәлән: *Без алар т у к т а л г а н  авылга барып җиткәнче, җилләр искән* (Г. Бәширов). Бу формаларны чыганак фигыльләрнең морфологик вариантлары дип аңлату дөресрәк булыр.

**Төшем юнәлешенең катлаулы формалары.** Телдә төшем юнәлешенең катлауландырылган формалары шактый киң кулланыла: эшләтелү, буйсындырылу, караңгыландырылу һ.б.ш. Мәсәлән: *Пьеса табу эше класс старостасы Ләлә Хәмидовага й ө к л ә т е л г ә н  и д е*

(Г. Әпсәләмов). *Практикада т о р м ы ш к а  а ш ы р ы л г а н бу бурыч язучылар өстенә зур җаваплылык өсти* (Х. Хәйри).

*-л-* кушымчалы катлаулы формаларның мәгънәләре гади формалар белдергән мәгънәләргә туры киләләр. Күзәтелгән кайбер аермалар чыганак фигыльләрнең семантикасындагы аермалар белән аңлатылалар. Катлаулы формаларның иң зур күпчелеге эшкә дучар булу мәгънәсен белдерә.

**Кайтым юнәлеше**

Татар тел белемендә кайтым юнәлешен традиция буенча грамматик категория буларак бүлеп чыгаралар. И. Гиганов грамматикасында ул «эш башкаручының үзенә әйләнеп кайткан эш»ен белдерүче юнәлеш дип билгеләнә. Нәкъ менә шушы мәгънә аның төп мәгънәсе итеп карала да инде. Соңрак *-н-* кушымчалы кайтым юнәлеше формасының бик күп мәгънәләре табыла.

Фигыльнең кайтым юнәлеше формасы *-н- (-ын-/-ен-)* кушымчасы ярдәмендә ясала. Тартыкка тәмамланган нигезләргә һәм бер иҗекле сузыкка тәмамланган иҗекләргә кушымчаның *-ын-/-ен-* вариантлары ялгана: *агар-у – агар-ын-у, ю-у – ю-ын-у,* башка очракларда, ягъни берничә иҗекле сузыкка тәмамланган нигезләргә *-н-* кушымчасы ялгана: *бөркә-ү – бөркә-н-ү, караңгыла-у – караңгы-ла-н-у.* Кайтым юнәлеше күчемле фигыльләрдән дә *(буяу – буяну, алдау – алдану),* күчемсезләрдән дә ясала *(йөрү – йөренү, кызару – кызарыну). -н-* кушымчасы фигыльләрнең түбәндәге төркемнәренә ялганмый:

1. Составларында *-н-* кушымчасы булган, ләкин мөнәсәбәттәш төп юнәлеш формалары булмаган, нигездә кешеләрнең эш-хәлен белдергән күчемсез фигыльләр. Аларның кайберләренең мөнәсәбәттәш йөкләтү яки төшем юнәлеше кушымчалары булган фигыльләре бар: *юану – юату, өйрәнү – өйрәтү, имгәнү – имгәтү, тирбәнү – тирбәлү – тирбәтү* һ.б.ш. Шулай ук *-сын-/-сен-* кушымчалы, *-сыт-/-сет-* кушымчалы фигыльләр белән мөнәсәбәттәш фигыльләр: *кимсенү – кимсетү, баласыну – баласыту.* Аларның кайберләре исемнәр һәм башка сүз төркемнәре белән мөнәсәбәттә тора: *айну (аек), сагыну (сагыш), көчәнү (көч)*. Өченчеләренең *-н-* кушымчасыз мөнәсәбәттәш сүзләре юк: *ашкыну, куану, ышану* һ.б.ш.

2. *-ай-/-әй-/-и-, -ар-/-әр-, -р-, -лан-/-лән-, -лаш-/-ләш-* кушымчалы билгенең барлыкка килүен һәм үсүен белдергән күчемсез фигыльләр:

*якынаю, юанаю, яшәрү.* Бу кагыйдәдән чыгарма булып, төсләрнең барлыкка килүен, беленүен белдергән фигыльләр тора: *агару, кызару, күгәрү.*

3. Кешенең эчке халәтен белдергән *-сын-/-сен-* кушымчалы фигыльләр: *ятсыну, читсенү, юксыну* һ.б.ш.

4. Аваз ияртемнәреннән ясалган фигыльләр: *чикылдау, гөжләү, гөрләү.*

5. Затланышсыз фигыльләр: *буранлау, томанлау, яңгырлау* һ.б.

6. Процессның үтәлү характерын белдергән *-штыр-/-штер-, -мсыра-/-мсерә-, -гала-/-гәлә-, -älә-* кушымчалы фигыльләр: *барыштыру, әйткәләү, еламсырау* һ.б.

Кайтым юнәлеше формаларының мәгънәләре. Кайтым юнәлеше формаларының күпчелеген күчемле фигыльләрдән ясалган формалар тәшкил итә.

1. **Төшем юнәлеше мәгънәсе.** Күчемле фигыльләрдән ясалган кайтым юнәлешенең иң зур төркеме төшем юнәлешенең төп мәгънәсенә туры килгән мәгънәне белдерә – процессларны объектка карап, объектның процессуаль билгесе итеп бирә: *сайлану, үлчәнү, төгәлләнү* һ.б.ш. Мәсәлән: *Урамга чыктым: я ш е р е н г ә н батырлыгымны, көрәшкә ашкынуымны, о ч л а н м а г а н эшемне, киләчәктәге теләкләремне, җ ы р л а н м а г а н җырымны, ү т е л м ә г ә н юлымны үлчәп, тыкырыктан борылдым* (К. Нәҗми). *Юллар буенда берничә кат юан бүрәнәләр түшәп һәм балчык өеп э ш л ә н г ә н зур гына землянка ялгызы калкып тора* (Ә. Еники).

*-л-* кушымчалы формалар кебек үк, төшем юнәлеше мәгънәсенә ия булган кайтым юнәлеше формалары да ике ченлы (эш башкаручысы бирелмәгән) була: *Ул... зәвык белән с а й л а н г а н мебельны, а л т ы н л а н г а н рамнардагы матур репродукцияләрне карап торды* (А. Расих). *Киндер й о л к ы н г а н , бәрәңгеләр а л ы н г а н , ындырдагы кайбер эшләр дә беткән иде инде* (А. Шамов) һәм өч ченлы (эш башкаручысы бирелгән) пассив конструкцияләр төзиләр: *Дошман тарафыннан я н д ы р ы л г а н һәм т а л а н г а н совет авылын Галимнең беренче күрүе иде бу* (Г. Әпсәләмов).

Төшем юнәлеше формалары кебек үк, бу формалар процессны объектның процессуаль билгесе итеп бирәләр, ягъни грамматик категория тәшкил итәләр.

2. **Эшнең көчемсезлеген белдергән кайтым юнәлеше формалары.** Көчемле фигыльләрдән ясалган кайтым юнәлеше формаларының бер өлеше, төшем юнәлеше формалары кебек, үтәүче сферасы белән чикләнгән, читкә юнәлмәгән эш-хәлләрне белдереп киләләр. Бу – көчемсез фигыльләргә хас мәгънә: *мәшәкатьләнү, күренү, үтмәсләнү, ташлану, тотыну, назлану* һ.б.ш. Мәсәлән: *...Нәкъ каршында карт юкә агачлары ышыгына я ш е р е н г ә н кечкенә кызыл кирпеч станция бинасы һәм сарыга буялган кызыл түбәле җыйнак каралтылар кү р е н ә* (Ә. Еники). *Чаян чага үзен соңгы чиктә, Бөркет ярдан түбән т а ш л а н а* (М. Җәлил). *Назлы н а з л а н ы п т о р г а н ч ы , кыю ашап туйган* (мәкаль). Бу формаларда шушы мәгънәдәге төшем юнәлеше формаларына хас булган барлык үзенчәлекләр дә күзәтелә.

3. **Кайтым юнәлешенең төп мәгънәсе** – үтәүченең үзенә әйләнеп кайткан эшен белдерү. Бу мәгънә барлык грамматик хезмәтләрдә дә күрсәтелә һәм кайтым юнәлешенең төп мәгънәсе буларак карала: *юыну, бизәнү, төренү, сөртенү, чабыну, уыну, урану, ябыну, бөркәнү, киенү*. Мәсәлән: *Суфия ханым шәленә т ө р е н д е* (Г. Әпсәләмов). *Сулган гөл күк, мин дә кышны көтәм, Йоклар өчен я б ы н ы п юрганны* (М. Җәлил). *Безнең Кларабыз бик сылу кыз, бик чибәр к и е н г ә н иде* (Ә. Еники). Кайтым юнәлешенең бу мәгънәсен гадәти көчемсезлек, эшнең башкаручы сферасы белән чикләнүе мәгънәсенең көчемле фигыльләр семантикасында үзенчәлекле чагылыш табуы нәтиҗәсе дип карарга кирәк.

Бу мәгънәдәге кайтым юнәлеше формалары бар яклары белән дә мөстәкыйль фигыльләрне хәтерләтәләр, аларга хас грамматик үзенчәлекләр белән характерланалар.

Бу формаларга *кырыну, тарану* кебек мәгънәләренә билгеле объект төшенчәсе кергән *(сакал-мыек кыру; чәчне-башны тарау)* һәм *җыену, җыештырыну, төянү, асыну, ташыну* кебек билгесез объект төшенчәсе кергән кайтым юнәлеше формалары да якын торалар.

4. **Ихтыярсыздан башкарылган** эшне белдерүче формалар шундый мәгънәгә ия булган төшем юнәлеше формаларын хәтерләтәләр: *соңга калына, йоклана* һ.б. Мәсәлән: *Тынгысыз һәм ыгы-зыгылы бу фани дөньяга мин шушы гасырның нәкъ башында килергә иткәнмен, нибары бер генә атнага с о ң г а к а л г а н м ы н* (Г. Бәширов).

*Кондуктор, кызны танып: «Я л г ы ш  к и л е н г ә н м е н и ,  әллә адаштыгызмы?» – диде.* (И. Гази).

5. Физик хәрәкәтне белдерүче күчемсез фигыльләрдән ясалган бер төркем кайтым юнәлеше формаларына **процессның кабатлануын** белдерү хас: *йөгерү – йөгеренү, сикерү – сикеренү, тибү – тибенү* һ.б.ш. Мәсәлән: *Бакый, перрон буенча борчылып, й ө р е н ә - й ө р е н ә ,  аны көтеп тора иде* (Г. Әпсәләмов). *Әбүзәр абзый урыныннан торды: арлы-бирле й ө р е н е п  а л д ы* (Г. Әпсәләмов).

Бу формаларга «нинди дә булса аваз чыгару» мәгънәсендәге фигыльләрдән ясалган *-н-* кушымчалы формалар якын торалар: *сызгыру – сызгырыну, шыңшу – шыңшыну* һ.б.ш.

6. Күчемсез фигыльләрдән ясалган кайтым юнәлешле формаларның кайберсе **эш-хәлнең интенсивлашуын, көчәюен** белдерәләр: *шашу – шашыну, котыру – котырыну, сызлау – сызлану, шешү – шешенү, җебү – җебенү, агару – агарыну, кызару – кызарыну* һ.б.ш. Мәсәлән: *Шәфкать туташы, к у р к ы н ы п ,  тизрәк аның кулын алды, пульсын капшады* (Ә. Еники). *– Юк, юк, Хәлил абый! – диде Ләйлә ханым, артка чигенеп һәм  а г а р ы н ы п* (Ә. Еники).

Кайтым юнәлешенең катлаулы формалары аз күзәтелә: *килешенү, бушатыну, асылыну*. Мәгънәләре буенча алар, чыганак формалары кебек үк, эш-хәлнең күчемсезлеген, үтәүче сферасы белән чикләнүен һ.б.ны белдерәләр.

### Уртаклык юнәлеше

Уртаклык юнәлеше татар теленең беренче грамматикаларында ук бүленеп чыгарылган. Ул «ике яки берничә затның уртак эшен» белдерүче буларак каралган. Соңгырак хезмәтләрдә аның башка күпсанлы мәгънәләре булуы ачыкланган.

**Уртаклык юнәлеше формаларының ясалышы.** Уртаклык юнәлеше формасы *-ш- (-ыш-/-еш-)* кушымчасы ярдәмендә ясала. Тартыкка тәмамланган нигезләргә һәм сузыкка тәмамланган бер иҗекле нигезләргә *-ыш-/-еш-* кушымчасы ялгана: *таб-у – таб-ыш-у, озат-у – озат-ыш-у; у-у – у-ыш-у* һ.б. Башка очракларда, ягъни берничә иҗекле, сузыкка тәмамланган нигезләргә *-ш-* ялгана: *эшлә-ү – эшлә-ш-ү, сана-у – сана-ш-у* һ.б.

Уртаклык юнәлеше формалары күчемле фигыльләрдән дә *(ясау – ясашу, кочаклау – кочаклашу),* күчемсезләрдән дә ясалалар *(көлү –*

*көлешү, бизү – бизешү).* Бу – нигездә, актив эш-хәл, сөйләм, хәрәкәт фигыльләре, ягъни җан ияләренә, беренче чиратта, кешегә хас эш-хәлне белдерүче фигыльләр.

Уртаклык юнәлеше кушымчасы фигыльләрнең түбәндәге төркемнәренә ялганмый:

1. Составларында *-ш-* кушымчасы булган (еш кына катлаулы *-лаш-* кушымчасы эчендә), ләкин чыганак фигыльләре булмаган көчемсез фигыльләр. Аларның кайберләре составларында (катлаулы *-лан-* һәм *-лат-* кушымчалары эчендә) кайтым һәм йөкләтү юнәлеше кушымчалары булган фигыльләр белән мөнәсәбәттәшләр: *ризалашу – ризалату, тизләшү – тизләнү – тизләтү*. Башкалары исемнәр яки башка сүз төркемнәре белән мөнәсәбәттә торалар: *карышу (кару-көч), урнашу (урын) өләшү (өлеш)*. Өченчеләренең *-ш-* кушымчасыз мөнәсәбәттәш сүзләре юк: *алмашу, адашу, саташу.*

2. -ай-/*-әй-, -й-, -ар-/-әр-р-, -лан-/-лән, -лаш-/-ләш-* кушымчалы билгенең барлыкка килүе, үсүе мәгънәсендәге көчемсез фигыльләр: *авыраю, агару, дуслашу* һ.б.ш.

3. *-сын-/-сен-, -лыг-/-лег-, -ыг-* кушымчалы көчемсез фигыльләр: *җәберсенү, ятсыну, ачыгу* һ.б.ш.

4. Затка каратылмаган *буранлау, томанлау, яктыру* кебек фигыльләр.

5. *-штыр-/-штер-, -мсыра-/-мсерә-* кушымчалы көчемсез фигыльләр: *әйтештерү, көлемсерәү* һ.б.ш.

Составларында юнәлеш кушымчасы булган фигыльләрдән *-ш-* кушымчасын төшем һәм кайтым юнәлеше кушымчалары алган фигыльләр ялгый ала: *җыелу – җыелышу, төялү – төялешү; тотыну – тотынышу, бизәнү – бизәнешү* һ.б.

**Уртаклык юнәлеше формаларының мәгънәләре,** башка юнәлеш формаларының мәгънәләреннән аермалы буларак, чыганак фигыльнең көчемле яки көчемсез булуына гына бәйле түгел, гомумән фигыльнең башкаруына бәйле.

Көчемле фигыльләрнең уртаклык юнәлеше формалары берничә мәгънә белдерә:

1. Уртаклык мәгънәсе. Бу мәгънәнең асылы түбәндәгедән гыйбарәт. Процесс ике яки берничә предмет яки зат арасында башкарыла. Эш башкаручылар бер үк вакытта эшнең субъекты да, туры объекты да булалар: *кочаклашу, кочышу, бәхилләшү, каргашу, каһәрләшү,*

*кисәтешү, очрашу, үбешү, сәламләшү* һ.б.ш. Мәсәлән: *Ул китте инде Донбасска, Сүз бирдек ташлашмаска* (Ш. Маннур). *Шушы елда, дустым, җитәкләшеп Кайтсак иде туган йортларга* (М. Җәлил). *Көзге караңгы төндә кечкенә генә җимерек станциядә ике эшелон очрашып, янәшә туктадылар* (Ә. Еники).

Уртаклык мәгънәсе күчемсез фигыльләрдән ясалган формаларда да күзәтелә: *тую – туешу, бизү – бизешү, бару – барышу, йөрү – йөрешү.* Эш башкаручылар биредә субъект та, кыек объект та булалар: *туешу* (бер-береңнән тую), *барышу* (бер-береңә барып йөрү). Мәсәлән: *Башта ачуланышалар, аннан ничек килешергә белмиләр* (Г. Әпсәләмов). Бу мәгънәне белдергән бер төркем уртаклык юнәлеше формалары, чыганак формаларның мәгънә үзенчәлегенә бәйле рәвештә (алар, нигездә, хәрәкәт белдерүче фигыльләр) үзенчәлекле мәгънә төсмере – ярышу төсмере алалар: *узышу, куышу, сынашу, җиңешү* һ.б.ш. Мәсәлән: *Күктәге йолдызлар бер-берсен куышып чыгып беткәч, Рәүфә дә ята* (А. Шамов).

Уртак эш, әйтелү максатыннан чыгып, эш башкаручыларның барысының эше итеп тә, бер якның гына эше итеп тә бирелергә мөмкин. Мәсәлән: *Гаптрахман белән Зариф күзгә күз генә карашып алдылар* (А. Шамов). *Зәмзәм кем беләндер ишек артында шпаргалка турында сүз куеша* (Г. Әпсәләмов).

Күчемле фигыльләрдән ясалган уртаклык юнәлеше формаларында мөстәкыйль фигыльләргә хас барлык билгеләр дә бар.

2. Уртаклык юнәлеше формаларының икенче бер мәгънәсе – процессның башка бер затка ярдәм йөзеннән башкарылуын белдерү: *язышу* (язарга ярдәм итү), *эшләшү* (эшләргә ярдәм итү), *төяшү* (төяргә ярдәм итү). Мәсәлән: *Без аларга йорт салыштык.* Бу формаларның кайберләре ярдәм йөзеннән эшләүне дә, уртак эшне дә белдерәләр. Аларның мәгънәсе синтаксик юл белән – махсус төзелмәләр ярдәмендә ачыклана: *язышу* (кемгә дә булса язарга ярдәм итү; бер-береңә язу), *егышу* (кемгә дә булса кемне дә булса егарга ярдәм итү; бер-береңне егу).

3. Актив-объектсыз мәгънә. Бу мәгънәдәге күчемле фигыльләрдән ясалган юнәлеш формалары актив-күчемсез, башкаручыны характерлый торган эш-хәлне белдерәләр. Объектка мөнәсәбәт икенче планга күчә. Эш кабатлана торган, дәвамлы итеп, кайвакыт башкаручыга хас

билге буларак бирелә: *язышу* (язу белән шөгыльләнү), *юнышу* (юну белән шөгыльләнү), *урлашу* (урлау белән шөгыльләнү), *әләкләшү* (әләк белән шөгыльләнү).

Күчемсез фигыльләрдән ясалган уртаклык юнәлеше формалары да берничә мәгънә белдерәләр.

4. Эшне бергәләп башкару мәгънәсе. Күчемсез фигыльләрдән ясалган уртаклык юнәлеше формаларының күбесе эшне бергәләшеп башкаруны белдерәләр: *йөгерү – йөгерешү, елмаю – елмаешу, утыру – утырышу.* Мәсәлән: *Киек казлар к ы й г ы л д а ш а, Җ ы р л а ш а л а р микәнни? Туган илләр кала бит, дип Е л а ш а л а р микәнни?* (Х. Туфан). *Разыя белән бергә китүче кызлар күп к ө л е ш ә л ә р, күп җ ы р л а ш а л а р* (И. Гази). Фигыльләрнең күплек саны формаларыннан аермалы буларак, алар күп затларның бергәләшеп башкарылган эшләрен бер процесс итеп түгел, ә аерым, һәрберсенең үз үзенчәлекләре белән вакыт ягыннан туры килмәгән эш-хәлләр суммасы итеп бирәләр. Бергәләшеп башкарылган эш күләмле, динамик булып күз алдына килеп баса. Шуңа күрә дә бу формалар матур әдәбият әсәрләрендә һәм җанлы сөйләмдә киң кулланылалар.

5. Күпсанлы булмаган уртаклык юнәлеше формалары процессны тәмамланмаган, өлешчә генә булган итеп бирәләр: *шуу – шуы-шу, аву – авышу, калу – калышу* – яки, киресенчә, интенсивлашуны белдерәләр: *кайнау – кайнашу, кызу – кызышу, әчу – әчешү.* Мәсәлән: *...Рельслар буйлап җиңел кара тәрәзәләрдән к а л ы ш м ы й ч а, чуар яктылык йөгерә* (Ә. Еники). *Башларыбызда мең төрле у й л а р к а й н а ш а* (Г. Бәширов). *Муендагы кан тамырлары бүртеп чыккан атаның, колаклары к ы з ы ш а башлады* (Р. Мөхәммәдиев).

6. Чыганак формалар белән мәгънәви мөнәсәбәттәшлеген югалткан уртаклык юнәлеше формалары. Биредә сүз түбәндәге фигыль формалары турында бара: *күрү – күрешү* (исәнләшү мәгънәсендә), *ору – орышу* (ачулану мәгънәсендә), *сорау – сорашу* (хәер эстәү мәгънәсендә), *сугу – сугышу* (кораллы сугыш мәгънәсендә), *ябу – ябышу* (берегү мәгънәсендә), *керү – керешү* (йон турында) һ.б.ш. Бу фигыльләрнең мәгънәләрен игътибар белән тикшергәндә, уртаклык юнәлеше формаларының мәгънәләре асылда юнәлеш мәгънәләренең үзгәрүе, үсүе нәтиҗәсе икәнлеге ачыклана. Мәсәлән, *күрешү* (исәнләшү) чыганак форма белән тыгыз бәйләнештә: ул, бу юнәлешнең төп мәгънәсе

булган «бер-береңне күрү» мәгънәсе аша, бер-береңне күргәч була торган эш – исәнләшү мәгънәсен белдерә башлаган. *Сугышу* фигыле дә бер-беренә сугу мәгънәсенең киңәюе нәтиҗәсендә барлыкка килгән.

**Уртаклык юнәлешенең катлаулы формалары.** Уртаклык юнәлешенең үзеннән кала, барлык беренчел юнәлешләр *-ш-* кушымчасы алалар: җыйналышу, киенешү, киптерешү һ.б.ш. Мәсәлән: *Алар, кулга кул тотынышып, йөгереп киттеләр* (Г. Әпсәләмов). *Озакламый мине разведкадан күчерделәр һәм без Дәүләтшин белән аерылыштык* (И. Гази). *-ш-* кушымчасы икенчел юнәлеш формаларына да ялгана ала: *киендерешү, ябыштырышу.*

Уртаклык юнәлешенең кабатлаулы формалары беренчел формалары белдергән мәгънәләрне – эшне бергәләшеп башкару, уртак эшне башкару, ярдәм йөзеннән башкару һ.б.ш. мәгънәләр белдерәләр.

### Йөкләтү юнәлеше

Йөкләтү юнәлеше татар теле буенча беренче хезмәтләрдә үк бүленеп чыгарыла. Аның төп мәгънәсен И. Гиганов «башка кешедән кушып эшләтелгән эш» дип саный. Йөкләтү юнәлешенең асылын А. Троянский төгәлрәк билгели. Ул башка предметны, затны эшкә этәрүче сәбәпнең төрле характерда булу мөмкинлеген әйтә. Ул – боеру да, үтенеч тә, рөхсәт бирү дә, хаталану да, эш-хәлгә каршы тора алмау да, эшне башкаруның табигый мәҗбүрилеге дә һ.б.ш.

**Йөкләтү юнәлеше формаларының ясалышы.** Йөкләтү юнәлеше кушымчалары искиткеч күпсанлы һәм күптөрле. Менә алар: *-т-, -тыр-/-тер-, -дыр-/-дер, -тәр-, -дар-, -кар-/-кәр-, -кыр-/-кер-, -гер, -ар-/-әр-, -ыр-/-ер-, -кыз-/-кез-, -гыз-/-гез-, -гәз-, -ыз-/-ез-, -сәт-*. Нигездә, теге яки бу кушымчаны ялгау чыганак фигыльнең фонетик үзенчәлекләренә бәйле. Мәсәлән, *-т-* кушымчасы берничә иҗекле сузыкка тәмамланган нигезләргә *(аша-у – аша-т-у, иснә-ү – иснә-т-ү, эшлә-ү – эшлә-т-ү)* һәм *й, р* авазларына тәмамланган нигезләргә *(авырай-у – авырай-т-у, кызар-у – кы-зар-т-у); -дыр-/-дер-* кушымчасы бер иҗекле сузык авазга, я яңгырау тартыкка тәмамланган нигезләргә *(и-ю – и-дер-ү, ю-у – ю-дыр-у, ал-у – ал-дыр-у, юнәл-ү – юнәл-дер-ү); -тыр-/-тер-* кушымчасы саңгырау тартыкларга тәмамланган нигезләргә (*ат-у – ат-тыр-у, а-су – ас-тыр-у* һ.б.ш.) ялгана. Ләкин теге яки бу кушымча ялгануны фигыльләрнең фонетик үзенчәлекләре белән генә

аңлатып бетереп булмый. Фонетик планда бер-берсеннән аерылып тормаган фигыльләр дә кайвакыт төрле йөкләтү юнәлеше кушымчалары алалар: *кызару – кызарту,* ләкин *бирү – бирдерү; сату – саттыру,* ләкин *яту – яткыру* һ.б.

Йөкләтү юнәлеше кушымчаларының иң киң таралганнары – *-т-, -тыр-/-тер-, -дыр-/-дер-.*

Йөкләтү юнәлеше формалары күчемле фигыльләргә дә, күчемсезләргә дә ялгана алалар: *язу – яздыру, сөйләү – сөйләтү, әйтү –әйттерү һәм көлү – көлдерү, елау – елату.* Юнәлеш формалары башка кеше ихтыяры белән үтәп булмый торган процессларны белдергән фигыльләрдән генә ясалмыйлар. Соңгыларына *яңгырлау, буранлау, томанлау, укшыту* һ.б. шуның кебек табигать күренешләрен һәм кешенең эчке халәтен белдергән фигыльләр керә.

Йөкләтү юнәлеше кушымчасы, составында юнәлеш кушымчалары булган фигыльләргә ялганып, юнәлешнең катлаулы формаларын да ясарга мөмкин: *буяндыру, очраштыру, эшләштерү.*

**Йөкләтү юнәлеше формаларының мәгънәләре.**

1. Күчемсез фигыльләрдән ясалган йөкләтү юнәлеше формалары башка предмет яки затка юнәлгән һәм ул предметка теге яки бу үзгәрешләр кертә торган процессларны белдерәләр: *бушау – бушату, кибү – киптерү, көлү – көлдерү.* Бу – эш-хәлнең күчемлелеге мәгънәсе. Гадәти күчемле фигыльләрдән аермалы буларак, йөкләтү юнәлеше формалары эш-хәлне аның нәтиҗәсе аша белдерәләр. Төшем юнәлеше формалары исә, киресенчә, сәбәбе аша белдереләләр. Чагыштырыгыз: *вату – ватылу, көлү – көлдерү.* Шуңа күрә йөкләтү юнәлешенең процессуаль билгесен йөртүче зат туры объектка мөнәсәбәттә, чыганак фигыльнең процессуаль билгесен йөртүчегә карата, аны эшкә этәрүче буларак характерлана. Шуның нәтиҗәсе буларак, бу юнәлештәге фигыльләрдә йөкләтү мәгънәсе барлыкка килә.

Күчемсез фигыльләрнең йөкләтү юнәлеше формалары төрле дәрәҗәдәге йөкләтүне белдерәләр. Аларның кайберләре зат яисә предметны яңа халәткә керүгә яки яңа билге алуга этәрәләр: *Кешенеке пешергәнче, минем хатын к ө й д е р ә* (мәкаль). *Нигә әле ул аның күптән мәрткә киткән күңелен төртеп уятып, күптән сүнгән хисләрен, онытылган уйларын яңадан к а б ы н д ы р ы п , д ө р л ә т е п җ и - б ә р д е ?* (Ә. Еники). Башкалары зат яки предметларга нинди дә

булса эш башкаруны йөклиләр: *Богау салды дошман кулларыма һәм хурлыклы юлдан атлатты* (М. Җәлил). *Ул иң элек Зәйнәпне читкә чакырып алып, колагына нәрсәдер әйтеп, каядыр йөгертте* (Ә. Еники). Өченчеләре, обстановкага бәйле рәвештә, тегесен дә, монысын да белдерәләр, *кайтару* – нәрсәне дә булса кире алу һәм кемне дә булса кайтырга мәҗбүр итү, *кертү* – нәрсәне дә булса алып керү, кемгә дә булса керергә мөмкинлек бирү мәгънәләрендә. Гомумән алганда, йөкләтү юнәлешенең мәгънә төсмерләре, нигездә, чыганак фигыльнең семантикасына бәйле. Әгәр ул пассив-күчемсез икән, йөкләтү юнәлеше формасы күчемлелек мәгънәсен генә бирә, актив-күчемсез икән, предметка яки затка кушып эшләткән эшне белдерә. Актив-күчемсез фигыльләр, нигездә, җан ияләренең, беренче чиратта кешеләрнең эш-хәлләрен белдерәләр, йөкләтү юнәлеше формаларының мәгънәләре дә шуңа бәйле. Мәсәлән*: Кучердагы егет, ишек алдын уратып, атларын баскыч төбенә үк китереп туктатты* (Ә. Еники). *Сабан туенда иң элек малай-шалайларны көрәштергән кебек, Мирсәеткә дә кичәнең башында ук сүз бирделәр* (Р. Мөхәммәдиев).

2. Туры мәгънәсендә йөкләтү. Йөкләтү мәгънәсе күчемле фигыльләрдән ясалган йөкләтү юнәлеше формаларында тулы чагылыш таба: *ачу – ачтыру, язу – яздыру, көту – көттерү* һ.б.ш. Бу очракта да йөкләтү юнәлеше формасының нәтиҗәсе чыганак форма белдергән эш-хәлнең процессын белдерә. *Дөресе аның шул,– диде Лотфи карт, бераз көттереп, – Рамазан бабагыз Әсмабикәсенә күрми өйләнгән* (Ә. Еники). Йөкләтү юнәлеше формаларының мәгънәсен, эш башкаруда ике кеше катнаша, берсе куша, икенчесе башкара, дип аңлату дөрес түгел. Йөкләтү юнәлеше формасы белән белдерелгән процессны фигыльнең зат-сан кушымчасы белдергән зат башкара: *Мин аннан ишек ачтырдым. Ул Илдардан хат яздырган.* Йөкләтү юнәлеше формасы белдергән эш-хәлнең нәтиҗәсе булган процессны башкаручылар икәү генә: ул ишекне ачкан һәм Илдар хат язган икенче бер кешенең кушуы, үтенече буенча.

3. Процессның объектив сәбәпләр аркасында үзеннән-үзе башкарылуын белдерү. Бу мәгънә табигать күренешләрен һәм кешенең эчке халәтен белдергән йөкләтү юнәлеше формаларында күзәтелә: *салкынайту, җылыту, туңдыру, өшетү, калтырату* һ.б.ш. Мәсәлән: *Төннәрен салкынайта да, көндезләрен нәкъ май аендагыча кыздырырга*

*т о т ы н а* (Г. Әпсәләмов). *Таңнар ата, өзелә үзәк, Җ ы р л а т а да е л а т а* (Н. Исәнбәт). Алар чыганак фигыль белдергән процессларны белдерәләр, ләкин ул процесслар эш башкаручының ихтыярына бәйсез, үзеннән-үзе башкарылганлыкны аңлаталар. Чагыштырыгыз: *җырлыйм – җырлата, елыйм – елата.* Бу формалар грамматик яктан затланышсыз, III зат берлек сан формасында гына кулланылалар һәм бер составлы җөмләләрнең оештыручы үзәге функциясен үтиләр.

Кеше халәтен белдерүче йөкләтү юнәлеше формалары мәгънәләре буенча күчемсез фигыльләрнең төшем юнәлешләре белән охшаш: – *А р ы л д ы да, а ч ы к т ы р д ы да, – диде Мөхәмматҗанов* (А. Расих). Ике очракта да *(арылды – ачыктырды)* фигыль формалары затланышсыз, бер составлы җөмлә оештырганнар, затның халәтен аның теләгенә, ихтыярына бәйсез итеп бирәләр.

Телдә йөкләтү юнәлешенең **катлаулы формалары** да күзәтелә: *иелдерү, киендерү, күрештерү* һ.б.ш. Мәсәлән: *Әминә апа сүзен бүлә, нәнине ч и ш е н д е р е п тагаракка сала да юындыра башлый* (Г. Гобәй), *Өченче көн төнлә белән генә безне о ч р а ш т ы р д ы л а р* (И. Гази). *Картым шул хәлфәдән махсус а л д ы р т т ы* (Г. Әпсәләмов).

Йөкләтү юнәлешенең катлаулы формаларының мәгънәләре гади формаларныкы кебек үк: нигездә алар процессны аның нәтиҗәсе аша белдерәләр. Йөкләтү юнәлеше кушымчаларының икенчесе йөкләтү мәгънәсен көчәйтә генә: *әйттерү – әйттертү, яздыру – яздырту, алдыру – алдырту.*

Шулай итеп, татар телендә юнәлешләр фигыльләрнең барысын да үз эченә ала торган күренеш түгел. Биш юнәлеш формасы да фигыльләрнең бик аз өлешендә генә күзәтелә.

Традиция буенча бүленеп чыгарыла торган биш юнәлеш формасы бик катлаулы сүз ясагыч һәм сүз төрләндергеч категорияләр системасын тәшкил итә

Төп юнәлеш мәгънәсе һәм ясалышы ягыннан башка юнәлешләргә каршы куела торган, алардагы мәгънәгә ия булмаган форма буларак кына бүленеп чыгарыла. Шуңа күрә дә төп юнәлеш функциясендә составларында юнәлеш кушымчалары булган фигыль формалары да йөри.

Юнәлеш формалары чиксез күп һәм үзенчәлекле мәгънәләргә ия. Шуның белән алар телебезнең үзенчәлеген һәм байлыгын тәшкил итәләр.

### 4.3.5. Затланышсыз фигыльләр

#### Сыйфат фигыль

Сыйфат фигыль үзендә фигыль һәм сыйфат сүз төркемнәренең үзенчәлекләрен берләштергән затланышсыз фигыль формасы.

**Фигыль билгеләре:**

Семантик яктан сыйфат фигыльләрдә, башка фигыль формаларындагы кебек үк, эш-хәл, процесс мәгънәсе белдерелә: *кайтучы агайлар, килгән кеше, исә торган җил.*

Морфологик яктан сыйфат фигыльләрдә фигыльгә хас төп грамматик категорияләр саклана:

1) барлык-юклык фигыльләрдәгечә *-ма/-мә* кушымчасы белән белдерелә: *укыган китап, укымаган китап, кайткан солдатлар, кайтмаган солдатлар;*

2) юнәлеш категориясе кушымчаларын ала: *сөйләүче кеше, сөйләнгән сүз, сөйләшүче кешеләр, сөйләтүче кеше.*

3) эшнең үтәлү дәрәҗәсе синтетик һәм аналитик юл белән белдерелә ала: *килгәләгән кеше, баргалаган җир, укый башлаган роман, укып чыккан китап.*

Синтаксик яктан:

1) сыйфат фигыльләр, башка фигыль формалары кебек үк, килешләр белән башкарылалар: *суга бара торган сукмак, урманнан кайтучы кешеләр, сиңа әйтер сүзем бар;*

2) сыйфат фигыльләр иярчен җөмләнең хәбәре булып киләләр: *Син йөргән юлларга быел да Май ае чәчәкләр китерде* (Х. Туфан). *Укулар башланыр көн җитә* (Ф. Хөсни). *Алар, чатыр эченә сыенып, яңгыр туктаганны көтә иделәр* (Ш. Камал).

**Сыйфат билгеләре:**

1) Сыйфат фигыльләр предметның эш-хәл буенча булган билгесен белдерәләр: *агылучы болытлар, килгән кунак, ярларыннан чыккан елга, матур җырлый торган кыз.*

2) Аергыч функциясендә килгәндә сыйфат фигыльләр төрләнми. Бу яктан алар морфологик билгеләре буенча шулай ук сыйфатка якын торалар. Чагыштырыгыз: *килгән кунак, килгән кунакны, килгән кунакка* (*килгән* – сыйфат фигыль); *тансык кунак, тансык кунакны, тансык кунакка* (*тансык* – сыйфат). Сыйфат фигыль

формалары, сыйфатлар кебек үк, контекстта исемләшәләр, һәм бу очракта алар килеш, тартым, сан белән төрләнәләр: *Ашаганыбыз ап-ак калач та, дөге боткасы* (Ә. Еники). *Биргәнгә биш тә күп, алганга алты да аз* (мәкаль). *Ялгышымны күрсәтүчеләргә озын гомер телим* (Р. Гаташ).

3) Җөмләдә сыйфат фигыльләр күбрәк аергыч функциясендә кулланыла: *Әйткән сүз – аткан ук* (мәкаль). *Укып барган һәрбер юлым, һәрбер сүзем була минем юл күрсәткүче йолдызым* (Г. Тукай).

Татар телендәге сыйфат фигыльләр, башка төрки телләрдәге кебек үк, гаять үзенчәлекле грамматик табигатькә ия. Типологик яктан алар рус телендәге «причастие»ләр белән уртаклык күрсәтсәләр дә, күп кенә яктан алардан аерылып торалар:

1. Татар телендә сыйфат фигыльләр сыйфатланмышлары белән күп төрле мәгънә мөнәсәбәтендә тора алалар. Аларның синтетик иярчен аергыч җөмләләр һәм төрле сыйфат фигыльле әйләнмәләр ясауда катнашуы да нәкъ шушы үзенчәлекләренә бәйле.

Рус телендәге «причастие»ләр, мәсәлән, төп юнәлештә килгәндә, һәрвакыт шушы «причастие» белән белдерелгән процессның субъектын, ә төшем юнәлешендә (страдательные причастия) шул процессның объектын ачыклап киләләр; *играющий ребенок, прочитанная книга,* ә татар телендә төп юнәлештәге сыйфат фигыльләр үзләре белдергән процессның **субъектын**, бу процесска дучар булган, яки шул процесс юнәлгән **объектны**, процессның кайда, кайчан башкарылуын, ягъни **урынын, вакытын** белдергән сүзләрне һ.б. ачыклап килергә мөмкин.

1) *укыган кеше* (субъект);
2) *укыган китап* (объект);
3) *укыган мәктәп* (урын);
4) *укыган еллар* (вакыт);

2, 3, 4 мисалларда «уку» процессының башкаручысы (субъекты) сыйфат фигыльнең үз эчендә, ягъни сыйфатланмыш аша күрсәтелмәгән. Андый очракларда субъект тартым кушымчалары яки исемнәр (алмашлыклар) белән белдерелә:

*укыган китабым – мин укыган китап*
*укыган мәктәбем – мин укыган мәктәп*
*укыган елларым – мин укыган еллар.*

Бу күренеш төрки телләрдәге сыйфат фигыльләрдә башкаручы зат төшенчәсенең (агентивность), рус телендәге причастиеләр белән чагыштырганда, көчсезрәк булуы белән аңлатыла [Иванов С., 1969, с. 179; Иванов С., 1959, с. 64–72], Төрки телләрдә сыйфат фигыльнең нинди сыйфатланмышны ачыклап килүе, гомумән, фигыльнең семантик-синтаксик бәйләнешләре белән билгеләнә. Ягъни фигыль, процессны белдерүче сүз буларак, шул процессны башкаручы субъект белән бәйләнешкә керә, урын, вакыт ягыннан ачыклана һәм тәмамлыклар белән конкретлаштырыла. Бу күренешне икенче төрле «фигыльнең валентлыгы» дип атау да бар. Фигыльне (процессны) ачыклап килгән һәрбер шундый кисәк, исемнәр белән белдерелеп, үз чиратында, сыйфат фигыль тарафыннан ачыкланучы сыйфатланмыш позициясендә килә ала. *Балалар быел мәктәптә укыйлар: укыган б а л а л а р, балалар укыган м ә к т ә п, балалар укыган е л* һ.б.

Шулай ук төрки тел белемендә чагылыш тапкан икенче караш буенча, сыйфат фигыльләрнең нинди сүзләрне ачыклап килә алуы тагын да киңрәк нигезгә куела: «Определяемым в трехчленной определительной конструкции (сыйфат фигыльле әйләнмә) может быть любое существительное при наличии более или менее ощущаемых и осознаваемых отношений между ним и ядром определяющей части (не периферийных ее частей) или же определяющей частью в целом» [Поцелуевский Е., 1967, с. 21].

Шул рәвешле сыйфат фигыль атрибутив позициядә килеп, тамырдагы процессның **субъектын, объектын, урынын, вакытын** һ.б. сүзләрне ачыклый ала, ә бу сүзләр һәрберсе, үз чиратында, фигыль белән семантик-синтаксик мөнәсәбәттә торалар, ягъни процессны төрле яклап характерлауда катнашалар.

2. Аергыч функциясендә (атрибутив мәгънәдә) кулланылудан тыш, татар телендә сыйфат фигыльләр, еш кына, эш-хәл, процессны атап, исем фигыль мәгънәсендә киләләр. Бу очракта да алар, исемнәр кебек, килеш, тартым, сан белән төрләнәләр. *Сәҗидә апайның үги әбидән яшереп кенә ю а т к а н ы н  в ә  с ө й г ә н е н  хәтеремдә саклыйм* (Г. Тукай). *Яңгыр боткасы п е ш к ә н н е  көтеп утырудан да күңелле нәрсә юктыр бу дөньяда!* (И. Гази). *Апрель җиле май к и л ә с е н  хәбәр итә* (Г. Афзал).

Аергыч функциясендә килгәндә сыйфат фигыльләр төрләнми, контекстта алар бернинди кушымчасыз кулланыла: *Һавадан кара туфрак*

*исе, киселгән нарат агачы исе, черегән яфрак исе аңкый* (И. Гази). *Кыз кеше, кеше арасына кияр күлмәге юк* (Ф. Хөсни).

Ә исем фигыль мәгънәсендәге һәм исемләшкән сыйфат фигыльләр исемнәр кебек тартым, килеш, күплек кушымчалары белән кулланыла алганлыктан, тышкы яктан күп вакытта бер-берсенә тулысынча охшаш булалар. Чагыштырыгыз: *Урманбаш авылы кешеләренең кунакчыллыгы бар, килгәнне-киткәнне сыйлап җибәрергә яраталар* (Ф. Хөсни) – исемләшкән сыйфат фигыль. *Волость советына чакырып кәгазь килде. Син килгәнне көтеп бармыйча тордым* (И. Гази) – исем фигыль функциясе.

Әмма белдергән грамматик мәгънәләре буенча алар бер-берсеннән аерылалар. Сыйфат фигыльләр нигездә субъектны (а) һәм объектны (ә) ачыклаганда исемләшәләр һәм аларда исемләшкәндә дә шул ук мәгънәләр сакланып кала:

а) исемләшкән сыйфат фигыль фигыль нигезендә бирелгән эшнең башкаручысын (субъектын) белдерә: *Тырышкан табар* (мәкаль). *Тыяры юк туйга киткән* (мәкаль);

ә) исемләшкән сыйфат фигыль фигыль нигезендә белдерелгән эшнең туры объекты: *Малай бик иркә үсте, Галиулланың карап торганы шул бер Хәлим булды* (И. Гази). *Ашыйсын ашаган, яшисен яшәгән* (мәкаль).

Исем фигыль функциясендә килгәндә сыйфат фигыль, исем фигыль кебек, процессны атый, процесс исемен белдерә[1]. *Ах, бәла! Безне казый күргән имеш, Уйнаганны ул карап торган имеш* (Г. Тукай). *Аннан ерак түгел ике тракторның җай гына эшләп йөргәне күренә* (Ф. Хөсни). *Карт каушады, уеннан уймак чыгарын сизенде булса кирәк* (Г. Ибраһимов).

Татар телендә сыйфат фигыль формалары заман төсмерен белдерү буенча төркемләнәләр: 1) хәзерге заман сыйфат фигыль: а) *-учы/-үче*; ә) *-а торган / -ә торган (-ый торган / -и торган)*; үткән заман

[1] Типологиягә мөрәҗәгать итсәк, һинд-Европа телләрендәге «причастие»ләр бер үк вакытта эш башкаручы субъектны һәм эш-хәлнең үзен белдерә алмыйлар: «Имена действия и имена действующего лица, имеюшие вообще говоря свои специальные морфемы, никогда не смешиваются, они внутри более общей категории имени составляют две специальные категории, четко разграниченные» [Вандриес Ж., 1937, с. 124].

сыйфат фигыль: *-ган/-гән (-кан/-кән);* киләчәк заман сыйфат фигыль: а) *-ыр/-ер, -р, (-ар/-әр);* ә) *-ачак/-әчәк (-ячак/-ячәк);* б) *-асы/-әсе (-ыйсы/-исе).*

Сыйфат фигыльләрнең югарыда искә алынган үзенчәлекле яклары төрле сыйфат фигыль формаларында төрлечәрәк чагылыш таба. Үзендә төрки телләрдәге сыйфат фигыльләргә хас барлык үзенчәлекләрне саклаган һәм телдә бик актив кулланыла торган форма – ул үткән заман сыйфат фигыль.

**Үткән заман сыйфат фигыль.** Үткән заман сыйфат фигыль *-ган/-гән (-кан/-кән)* кушымчасы белән ясала: *җыйган җиләк, килгән кеше, кушкан эш, пешкән аш*. Юклыгы башка фигыльләрдәгечә *-ма/-мә* кушымчасы белән белдерелә: *укымаган китап, көтелмәгән хәл, килмәгән кунак*.

И с к ә р м ә : Кайбер очракларда сыйфат фигыльнең юклыгы исемнәрдәгечә *түгел* кисәкчәсе белән дә белдерелергә мөмкин: *күргән кешем түгел; Үзем тапкан мал түгел, әтинеке җәл түгел* (мәкаль). *Түгел* кисәкчәсе бу очракта сыйфатланмыш – исемнең юклыгын түгел, ә сыйфат фигыльнең юклыгын белдерә. (Чагыштырыгыз: *кешем түгел, күргән түгел.*)

Үткән заман сыйфат фигыль күпфункцияле, ул контекстта **аергыч** функциясендә, **исемләшкән хәлдә** һәм **исем фигыль** функциясендә бердәй ешлыкта диярлек кулланыла.

1**. Аергыч** функциясендә килгәндә ул сыйфатланмышы белән күп төрле мәгънә мөнәсәбәтендә тора ала:

а) *-ган* формасы тамырдагы процессның **субъектын** ачыклый, ягъни сыйфатланмыш – сыйфат фигыль белдергән процессның субъекты. *К и л г ә н к е ш е л ә р алгы рәтләрдән урын ала бардылар* (Ф. Хөсни). *Галиулла дөньяның ачысын-төчесен т а т ы г а н к е ш е ул* (И. Гази);

ә) **объектны** ачыклый: *Гыйльмениса к у з г а т к а н э ш үз юлын тапты* (Ф. Хөсни). *Ул читкәрәк китеп, с ө р г ә н җ и р н е караштырган иде* (Н. Фәттах);

б) сыйфатланмыш тамырдагы процессны **урын** ягыннан характерлый: *Хуш, г о м е р и т к ә н ш ә һ ә р !* (Г. Тукай). *Әнә, безнең юкәдән ясалган тубаллар белән җиләк җ ы й г а н у й с у л а р ы б ы з* (Г. Ибраһимов). *Аның каравы, буровой у т ы р г а н яңа у р ы н искиткеч матур булып чыкты* (Ш. Бикчурин);

в) **вакыт** ягыннан характерлый: *Исемдә курка-курка төрле уйлар уйлаган чаклар* (Г. Тукай). *Монда эштән туктаган арада еш кына шашка уйнап маташалар иде* (Ш. Камал).

Югарыда китерелгән дүрт очрак, ягъни *-ган* формасының атрибутив позициядә тамырдагы процессның субъектын, объектын, урынын, вакытын ачыклап килүе – татар теле өчен иң характерлы күренеш. Болардан тыш бу форма:

г) тамырдагы процессны башкаруда кулланылган корал мәгънәсендәге сүзне ачыклап килергә мөмкин (кыек объект): *Ашаган савытларыңны җыеп куй! Ит кискән пычакны алып бир әле;*

д) сыйфатланмыш (ачыкланучы кисәк) ачыклаучы кисәк составындагы сүз белән иялек нисбәтендә тора: *Очрый моңа аягын тышаулаган бер кеше* (әкият). *Якуб тәрәзәне ачып җибәреп, чирәмен кояш көйдергән ишек алдына карап торды* (И. Гази). *Бер мәхәббәтнең газабын, михнәтен сизгән кеше... Күңеле бозланган кешедер...* (Г. Тукай);

е) үзе белдергән процесс нәтиҗәсендә туган төрле күренешләрне ачыклап килә. Мәсәлән: *сораудан курыккан төс; утлы күмер йоткан чырай*. Бу күренеш төрки телләр даирәсендә дә билгеләнгән. *Төс, чырай* сүзләреннән тыш, татар телендә бу очракта, *кыяфәт, хәл* сүзләре дә килергә мөмкин. *Курыккан кыяфәттә басып тора. Йөрәк турысында чәнчүле бер хәлсезлек тойган хәлдә, пышылдап диярлек әйтте* (Н. Фәттах). Ләкин саналып киткән сүзләрнең, сыйфатланмыш буларак, мөстәкыйльлекләрен югалта төшүләре дә сизелә, алар бу очракта, еш кына, бәйләүче чара хезмәтен үтиләр һәм, гадәттә, я урын-вакыт килешендә, я *белән* бәйлеге янында киләләр*: курыккан төс, чырай, кыяфәт белән; курыккан төстә, кыяфәттә, рәвештә, хәлдә...* Җөмлә кисәге буларак та, сыйфатланмыш белән сыйфат фигыль бергә каралалар.

2. Үткән заман сыйфат фигыль, еш кына, сыйфатланмышыннан башка кулланыла, ягъни **контекстта исемләшә.** Бу очракта ул, исемнәр кебек, килеш, тартым, сан кушымчаларын алып төрләнә:

а) баш килештә: *Тырышкан табар* (мәкаль). *Эшләгән узар, эшләмәгән тузар* (мәкаль). *Нишлим инде, чарасызмын, Тел тидерткән дөньядыр* (Г. Тукай);

ә) иялек килешендә: *Б е л м ә г ә н н е ң беләге авыртмый* (мәкаль). *Шул арада үзе к и л г ә н - к и т к ә н н е ң йомышын тыңларга да өлгерә* (Ф. Хөсни);

б) юнәлеш килешендә: *К ө т к ә н г ә көн үтми, э ш л ә г ә н г ә сәгать җитми* (мәкаль). *Алдан к и л г ә н н ә р г ә бүләк тапшырдылар;*

в) төшем килешендә: *Мин кабыздым җырда ялкын итеп. Йөрәгем һәм хаклык к у ш к а н н ы* (М. Җәлил*). Ил к ү р г ә н н е күрербез* (әйтем). *Шунда ул кыз әллә ничек сүзгә китеп, К ү р г ә н н ә р е н , б е л г ә н н ә р е н сөйли башлый* (Г. Тукай);

г) чыгыш килешендә: *Күп т о р г а н н а н сорама, күп к ү р г ә н н ә н сора* (мәкаль). *Син моңарчы с ө й л ә г ә н н ә р д ә н шуны исеңдә тот...* (Ә. Еники);

д) урын-вакыт килешендә: *Җиде колхоз күпләп сарык асрый, к а л г а н н а р ы н д а мөгезле эре терлек* («Социалистик Татарстан»).

3. Үткән заман сыйфат фигыль, атрибутив позициядә (аергыч функциясе һәм исемләшү) кулланылудан тыш, процесс исемен атап, **исем фигыль функциясендә дә кулланыла** ала. Бу очракта да *-ган* формасы исемнәр кебек килеш, тартым, сан белән төрләнә:

а) баш килештә: *Еракта көтү к а й т к а н ы күренде* (Г. Ибраһимов). *Син у й н а г а н , без җ ы р л а г а н калсын сагынып сөйләргә* (җыр). *Безнең җиргә карлыгачның яз көне к и л г ә н е мәгълүмдер* (Г. Тукай);

ә) иялек килешендә: *Без б а е г а н н ы ң икенче көнендә үк кып-кызыл кар явачак* (И. Гази). *Торасың дөньяда ник т о р г а н ы ң н ы ң хикмәтен белми...* (М. Гафури);

б) юнәлеш килешендә: *Бүген май урталары б у л г а н г а , кояш туры һәм матур карый* (Г. Ибраһимов). *Бик куе б у л г а н г а монда Җен-пәриләр бар, диләр...* (Г. Тукай). *Шул заманнан бирле айның т у г а н ы н а һәм алтын көпчәк төсле Т у л г а н ы н а карап, күңлем кайчак минем хәйран кала...* (Г. Тукай);

в) төшем килешендә: *Пароход к и л г ә н н е көтеп утыручылар арасында ыгы-зыгы башланды* (И. Гази). *Еллар үтә, хәтерлә син безнең Киләчәккә ничек б а р г а н н ы* (Х. Туфан). *Азмы к а к к а н н ы вә с у к к а н н ы күтәрдем мин ятим?!* (Г. Тукай);

г) чыгыш килешендә: *Шулай да һич у й л а м а г а н н а н гына әйтеп ташлаган бу чагыштыруда хәтәр мәгънә булган икән* (Ә. Еники). *Зур бәхетләр сызганып э ш к ә б и р е л г ә н н ә н килә* (Г. Тукай);

д) урын-вакыт килешендә: *Тимербулат сумкасына хатны санап с а л г а н д а , Бик еш кына күзе төшә шул конвертка һаман да...* (М. Җәлил). *Шушы этләр пулясыннан ү л г ә н е ң д ә ни файда* (Ш. Мөдәррис).

Шул рәвешле, *-ган* кушымчалы сыйфат фигыль исемләшкән хәлдә һәм исем фигыль функциясендә төрле килеш формаларында кулланыла һәм, еш кына, алар тышкы яктан бер-берсенә тулысынча охшаш булалар. Мәсәлән: *Т ы р ы ш к а н табар. Т ы р ы ш к а н бушка китте.* Шул ук вакытта сыйфат фигыльнең бу ике функциясенең телдә гомуми кулланылышында беркадәр аерымлану билгеләре дә чагыла. Исемләшкән *-га/-гән* формасы, мәсәлән, күбрәк баш һәм иялек килеше формаларында, тартым кушымчаларсыз кулланыла: *Иртә т о р г а н эшен бетергән* (мәкаль). *Шул тирәдә у т ы р г а н н а р иң элек картка, аннары теге егеткә карап алдылар* (Ф. Хөсни). *Б е л м ә г ә н н е ң беләге авыртмый* (мәкаль).

Исем фигыль функциясендә ул баш килештә күбрәк тартым кушымчалары белән кулланыла, ә иялек килешендә кулланылышы сирәк очрый: *Тирә-якта кемнең дә булса аны җ и ң г ә н е ишетелми* (Г. Ибраһимов). *Аларның әкрен генә с ө й л ә ш к ә н е ишетелә* (Г. Әпсәләмов).

Исем фигыль мәгънәсендә килгән *-ган/-гән* кушымчалы сыйфат фигыль контекстта күбрәк төшем, юнәлеш, урын-вакыт килешләрендә очрый:

а) юнәлеш килешендә: *син ч а к ы р г а н г а килдек; а в ы р г а н г а килмәде;*

ә) төшем килешендә: *поезд к и л г ә н н е көтәләр; к а й т к а н ы ң н ы белмәдем;*

б) урын-вакыт килешендә: *к а й т к а н д а күрдек.*

Ә исемләшкән сыйфат фигыль шул ук килешләрдә, нигездә, мәкаль-әйтемнәрдә генә очрый: *А е р ы л г а н н ы аю ашар, б ү л е н г ә н н е бүре ашар* (мәкаль). *Э ш л ә г ә н г ә көн җитми* (мәкаль).

Кайбер очракларда сыйфат фигыльнең бу ике мәгънәсен аеру өчен күплек кушымчасы *-лар/-ләр* кулланыла. Юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешләрендә исемләшкән *-ган* формасы күбрәк *-лар* кушымчасы белән кулланыла: *Мин сугышта йөрдем, туплар аттым, Ирек алдым ирек к ө т к ә н н ә р г ә* («Совет әдәбияты»). *Хәзер инде*

*я з г а н н а р ы ң н а н нәтиҗә чыгарырга кирәк* (И. Гази). *Җиде колхоз күпләп сарык асрый, к а л г а н н а р ы н д а мөгезле эре терлек* («Социалистик Татарстан»).

И с к ә р м ә . Иске татар әдәби теле ядкәрләрендә *-ган* кушымчалы сыйфат фигыльнең исем фигыль функциясендә дә *-лар* кушымчасы белән кулланылышы очрый: *вә бәгыд... юлларында вә эзләрендә, сәфәрләрендә вә хәзерләрендә, ултыргиннарында вә т о р г а н н а р ы н д а ...* (Сәхиб-Гәрәй хан ярлыгы).

***-ган*** **кушымчалы сыйфат фигыльдә заман мәгънәсенең белдерелү үзенчәлекләре.** Лингвистик әдәбиятта фигыльләрнең абсолют заманны һәм мөнәсәбәтле заманны (относительное время) белдерүе турында кайбер мәгълүматлар табарга мөмкин. Әгәр теге яки бу фигыль формасы заман төшенчәсен сөйләү моментына мөнәсәбәттә белдерә икән – ул абсолют заман мәгънәсенә, ә заман төшенчәсен сөйләмдәге икенче бер процессның үтәлү вакытына мөнәсәбәттә белдерә икән – мөнәсәбәтле заман мәгънәсенә ия була [Бондарко А., Буланин Л.]. Искә алынган хезмәттә, шулай ук, гомумән фигыль формаларының абсолют һәм мөнәсәбәтле заманны белдерүдәге үзенчәлекле яклары турында да әһәмиятле искәрмә ясала. «В морфологическом плане, вне контекста, нет ни абсолютного, ни относительного временного значения. Это различие появляетея лишь в конкретном высказывании. ...Глагольная форма (в морфологическом плане) обладает лишь грамматическим значением времени, которое ориентируется на грамматическую точку отсчета...» [шунда ук].

Аергыч мәгънәсендә килгән *-ган* формасына грамматик заман төшенчәсе дә хас. Грамматик санау ноктасыннан чыгып караганда, атрибутив позициядә (аергыч функциясендә) кулланылган бу форма, һәрвакыт диярлек, үткәндәге эшне белдерә: *килгән юл, җыйган җиләк, укыган китап.* Аның бу мәгънәсе, ягъни предметны үткәндә булган процесс буенча характерлавы, хәзерге яки киләчәк заман сыйфат фигыльләр белән параллель алганда бигрәк тә ачык күренә: *к и л г ә н юл – к и л ә с е юл, җ ы й г а н җиләк – җ ы я с ы җиләк, җ ы я т о р г а н җиләк, у к ы г а н китап – у к ы й с ы китап, у к ы я ч а к китап.*

Контекстта *-ган* формасының нинди заманны белдерүе күпчелек очракта икенче бер фигыльнең (еш кына ул җөмләнең хәбәре була) заманына карап билгеләнә. Бу форма гадәттә предметны (төп

фигыльнең нинди заманда булуына карамастан) **төп фигыльгә кадәр** булган, яки аның белән **бер үк вакытта булган** процесс буенча характерлый:

1. Хәбәре үткән заман формалары белән белдерелгән җөмләләрдә:

а) сыйфат фигыль предметны **хәбәрдән алда** тәмамланган процесс буенча яки аның нәтиҗәсе буенча характерлый: *Кайчан гына б у л ы п у з г а н шул күңелле чакларны ул уфталанып с а г ы н ы п к у й д ы* (Н. Фәттах). *Өй ишегеннән башына кара шәл б ө р к ә н г ә н , кулына ак төенчек тоткан, бит урталары а л с у л а н г а н Фатыйма кайтып керде* (И. Гази);

ә) сыйфат фигыль предметны җөмләнең **хәбәре белән бер үк вакытта** башкарылган процесс буенча характерларга мөмкин, ул вакытта да сыйфат фигыль үткән заман мәгънәсенә ия була: *Авыл морҗаларыннан к ү т ә р е л г ә н ак төтеннәргә карап тиз-тиз а т л ы й б а ш л а д ы л а р* (И. Гази). *Күтәрелде күк йөзенә сабан тургай, И ш е т е л д е чырлап т ү к к ә н моңлы зары* (Дәрдемәнд).

2. Хәбәре хәзерге заман хикәя фигыль белән белдерелгән җөмләләрдә:

а) сыйфат фигыль предметны **хәбәрдән алда** (ягъни сөйләү моментыннан алда) тәмамланган эш, хәл, хәрәкәт буенча, яки шул эшнең нәтиҗәсе буенча характерлый, ягъни үткән заман мәгънәсенә ия була: *...көтүдән к а ч ы п к а л г а н бер кәҗә читәнгә ы ш к ы н ы п т о р а* (И. Гази). *Шахталарда йөреп т а б а а л м а г а н байлыкны шушы алмагачлардан көтә ул* (И. Гази). *К а т к а н , т у ң г а н агачларны хәзер кара: һәрберсе яшәрешеп, яфрак я р а* (Г. Тукай).

*-ган* формасы бу очракта гадәттә предметка гомумән хас билгене белдерә: *Үзем с ө й г ә н илем өчен Кызганмыйм бөтен көчем* (Н. Исәнбәт). *Т е л б е л м ә г ә н балалар белән энигә җиңел түгеллеген мин сизеп йөрим* (Ф. Хөсни). *Телим ташлап к и р ә к м ә г ә н вак сүзләрне... Сөям, җаным, ләфызларына ашуын...* (Г. Тукай);

ә) хәбәре хәзерге заман хикәя фигыль белән бирелгән очракта да сыйфат фигыль хәбәр белән **бер үк вакытта** булган процессны белдерә ала. Бу вакытта инде сыйфат фигыль предметны үткәндәге эш буенча түгел, ә сөйләү моментында башкарылган эш, хәл, хәрәкәт буенча характерлый, ягъни хәзерге заман мәгънәсен белдерә. *Сабыр гына и с к ә н урман җиле Айлы юлга чәчәк с и б ә л и* (Х. Туфан). *Үзе*

*турында с ө й л ә н г ә н хикәяне Габдулла үзе дә т ы ң л ы й* ... (Ә. Фәйзи). *Искән әкрен җил белән яфрак-агачлар к а л т ы р ы й* (Г. Тукай).

3. Хәбәре киләчәк заман фигыль формалары белән, шулай ук киләчәк заман семантикасына ия булган боеру наклонениесендәге фигыль яки теләкне белдерүче әйләнмәләр белән бирелгәндә, *-ган* формасы предметны гадәттә хәбәр белдергән процесстан алда булган эш, хәл, хәрәкәт буенча характерлый, димәк, алда китерелгән очраклардан аермалы буларак, *-ган* формасы биредә төп фигыль белән бер үк вакытта булган процессны белдерә алмый. Тик бу очракта сыйфат фигыль белдергән заман мәгънәсенең сөйләү моментына мөнәсәбәте үзенчәлекле. Мәсәлән, *К и л г ә н кунакларны безгә дә алып б а р ы р с ы з,* дибез икән, сөйләү моментында кунаклар инде килгән булырга мөмкин (үткән заман), шулай ук әле килмәгән булулары, аларның киләчәктә килүләре генә күздә тотылуы да мөмкин (киләчәк заман).

а) *-ган* формасы сөйләү моментына кадәр булган процессны, ягъни төп фигыль киләчәк заманда булуга карамастан, сыйфат фигыль үткән заманны белдерә. *Максут җитәр, бара торгач, юл кыскарыр, әллә кайда я т к а н хиссият к у з г а л ы р* (Г. Тукай). *Яңадан җир өләшкәнче, аннан к а л г а н шул бер иманабызны шәт, тартып а л м а с л а р* (И. Гази).

ә) *-ган* формасы сөйләү моментыннан соң булачак процессны белдерә: *Янып к а л с ы н гомерең маяк булып, Үзеңнән соң к и л г ә н буынга. Ул һәйкәлгә мәңге к ө л е п т о р г а н Охрави бер авыз уярсыз* (Һ. Такташ). *Йөз елдан соң Ул чак кешеләре Таныйсалар безнең эш белән, Фикер йөртер зур һәм кечеләре Бик г а җ ә п к ә к а л г а н төс белән* (Ш. Маннур).

Хәбәре фигыльдән башка сүзләр белән белдерелгән җөмләдә, шулай ук атау җөмләләрдә *-ган* формасы гадәттә предметны үткәндәге эш буенча характерлый: *Галиулла дөньяның әчесен-төчесен җитәрлек т а т ы г а н кеше ул (*И. Гази). *Ник дисәң, минекеләр бит алар, мин ү с т е р г ә н балалар* (Ф. Хөсни). *И фәләкнең төрле, төрле зольменә к ү н г ә н күңел!* (Г. Тукай).

Шул рәвешле *-ган* формасы аергыч функциясендә мөнәсәбәтле заманны белдерә һәм контекстта, башлыча, төп фигыльдән алда булган, яки төп фигыль белән бер үк вакытта булган процессны атый.

Ләкин шул ук вакытта атрибутив позициядә кулланылган *-ган* формасына күпчелек очракта нәтиҗәлелек, сөйләү моментына кадәр үтәлгәнлек төсмере хас. Бу *-ган* формасы белдергән заман мәгънәсен сөйләү моментына мөнәсәбәттә күзәтеп чыгудан да ачык күренә:

а) төп фигыль үткән заманда булса, *-ган* формасы предметны төп фигыльдән **алда** булган процесс буенча характерлап, **күптән үткән заман мәгънәсен,** ә предметны төп фигыль белән **бер үк** вакытта булган процесс буенча характерлап, **үткән заман** мәгънәсен белдерә;

ә) төп фигыль хәзерге заманда булса, шул ук форма предметны төп фигыльдән **алда** булган процесс буенча характерлап, шулай ук үткән заман мәгънәсен, ә предметны төп фигыль белән бер үк вакытта булган процесс буенча характерлап, **хәзерге заманны** белдерә;

б) төп фигыль киләчәк заманга караган булса, *-ган* формасы предметны бары тик төп фигыльдән **алда** булган процесс буенча гына характерлый ала һәм күпчелек очракта предметны шулай ук сөйләү моментыннан алда булган, ягъни **үткәндәге** эш, хәл, хәрәкәт буенча характерлый. Аерым очракларда*-ган* формасы белән белдерелгән, төп фигыльдән алда булган процессның **киләчәк заманга** караган булуы да мөмкин.

Исем фигыль мәгънәсендә килгәндә дә *-ган/-гән* кушымчалы сыйфат фигыль заман мәгънәсен саклый һәм шул ягы белән ул заманга битараф булган *-у, -ү* кушымчалы исем фигыльдән аерылып тора.

Бу очракта *-ган* формасының заман төшенчәсен белдерүдә үзе ияргән фигыль формасыннан (җөмләнең хәбәре яки башка фигыль формасыннан) бәйлелеге тагын да көчәя. Ул контекстта бары тик мөнәсәбәтле заманны гына белдерә һәм җөмләнең хәбәре белдергән процесстан: а) алда булган, ә) бер үк вакытта булган, б) хәбәрдән соң булачак эш, хәл, хәрәкәт исемен атап килә:

а) *Хатлар аша аңа җиткергәннәр Бу күперне Айдар салганын* (Р. Әхмәтҗанов). *Тирә-якта кемнең дә булса аны җиңгәне ишетелми* (Г. Ибраһимов);

ә) *Утырып тыңлыйм таңгы кош җырларын, Карыйм моңсу кояш батканын* (җыр). *Сугу машинасының җайлы ритм белән эшләп торганы ишетелә* (Ф. Хөсни).

б) *Көтеп тора сабый балалар, Аждаһаның башын өзгәнне* (Х. Туфан). *Егет тәмам каушап төн булганны көтә* (Ш. Камал). *Алар чатыр эченә сыенып, яңгыр туктаганны көтә иделәр.*

*-ган* формасының җөмләдә бу рәвешле хәбәрдән алда булган, бер үк вакытта яисә соң булачак процессны белдереп килүе күп кенә өстәмә шартларга да бәйле. Җөмләнең хәбәре нинди заманны (үткән, хәзерге, киләчәк) белдерүе белән бергә, бу очракта *-ган* формасының нинди килеш кушымчасы белән куллануының да әһәмияте бар.

**Урын-вакыт** килеше кушымчасы белән кулланылган *-ган* формасы, мәсәлән, һәрвакыт хәбәр белән **бер үк вакытта** булган эшне, хәлне, хәрәкәтне белдерә. Сөйләү моментына мөнәсәбәттә караганда, төп фигыль кайсы заманда булса, димәк, *-ган* формасы да шул ук заман мәгънәсендә килә: *Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл – Кырлай, диләр, Җырлаганда көй өчен, «тавыклары җырлай», диләр* (Г. Тукай). *Тимербулат сумкасына хатны санап салганда, Бик еш кына күзе төшә бер конвертка һаман да* (М. Җәлил). Ә шул ук форма **юнәлеш килешендә,** һәрвакыт диярлек, хәбәрдән **алда** булган эш-хәлне белдерә һәм ул эш-хәл күп вакытта икенче бер процессны китереп чыгаручы яки китереп чыгарачак сәбәп семантикасын ала: *Солдаттан русча укый-яза белеп кайтканга, һәм кем булыптыр больницада хезмәт иткәнгә, аны Сәхип морза дип тә атыйлар* (Ә. Фәйзи). *Дөньяга килгәнемә мин үкендем...* (М. Гафури).

Калган килешләрдә (башлыча, баш һәм төшем килешләрендә) *-ган* формасы шулай ук төп фигыльдән **алда,** яки **бер үк вакытта** булган, ә кайвакыт төп фигыльдән соң булачак процессларны белдерә ала. Шунысы кызыклы, бу очракта *-ган* формасы ияргән төп фигыльнең лексик мәгънәсе дә мәгълүм дәрәҗәдә роль уйный. Мәсәлән: **искә алу, хәтерләү** мәгънәсендәге фигыльгә ияргәндә, *-ган* формасы, гадәттә, бу фигыль белдергән процесстан алда булган эшне, хәлне, хәрәкәтне атый: *Соңгарак, кайбер күңелсезлекләрне ничек кыен үткәргәнебез искә төшкәч, аптырап калабыз...* («Социалистик Татарстан»), *Саҗидә апайның үги әбидән яшереп кенә юатканын вә сөйгәнен... хәтеремдә саклыйм* (Г. Тукай). *Мин хәзер дә атка утырып Саснага барганымны... юлда барганда күз алдымда әллә нинди нурлар уйнаганын онытмаган шикелле булам* (Г. Тукай).

Контекстта *-ган* формасы белән аталган процессны күрү, турыдан-туры аны тыңлау, ишетү турында сүз барса, бу форма гадәттә җөмләнең хәбәре белән бер үк вакытта булган процессны белдерә. *Бөтен взводта бары Василийда гына андый сәгать, келт-келт*

*иткәне* бөтен палаткага *ишетелә* (Р. Төхфәтуллин). *Була шундый тыныч көннәр, без блиндаж алдына чыгып утыра идек тә... я кояш чыкканны, я кояш баеганны карап... тып-тын утыра идек* (И. Гази). *Ишек алдыннан ниндидер этнең ялкау гына өргәне ишетелде* (А. Расих).

*-ган* формасы үзенең лексик мәгънәсе белән көтеп торуны белдерүче фигыльләргә иярсә, һәрвакыт хәбәрдән соң булачак процессны атый, ягъни киләчәк заман төсмерен ала: *Яз җиткәнне көтеп шулай тыныч кына яшәгәндә, Галиулладан бик начар хат килеп төште* (И. Гази). *Алар чатыр эченә сыенып, яңгыр туктаганны көтә иделәр* (Ш. Камал). *Бу бит шигырьләрем, алдан килеп, Мин кайтканны көтеп торганнар* (М. Кәрим).

Шул рәвешле, исем фигыль мәгънәсендә килгән *-ган* формасы мөнәсәбәтле заманны гына белдергәнлектән, ул сөйләү моментына карата төрле заман яссылыгында ята торган процесс исемен атый.

1) Хәбәре **үткән заман** фигыльләре белән белдерелгән җөмләләрдә бу форма сөйләү моментыннан элек булган эшне, хәлне, хәрәкәтне белдерә: *Бай каршында хезмәт итә-итә сизми калдым гомерем узганын* (җыр). *Волость советына чакырып кәгазь килде, син кайтканны көтеп бармый тордым* (И. Гази).

2) Хәбәре **хәзерге заман** формасы белән бирелгәндә, *-ган* формасы:

а) сөйләү моментыннан элек булган процесс исемен белдерә: *Карт үзенең арттырыбрак җибәргәнен үзе дә сизә...* (Ф. Хөсни). *Зур бәхетләр сызганып эшкә бирелгәннән килә...* (Г. Тукай). *Замананың аргамактай чапканын йөрәк тоя* (Ә. Ерикәй);

ә) сөйләү моментыннан соң булачак процессны белдерә: *Көтеп тора сабый балалар Аждаһаның башын өзгәнне (*Х. Туфан).

3) Хәбәр **киләчәк заман** фигыль формасы белән бирелгәндә:

а) сөйләү моментына кадәр булган процессны белдерә: *Гомер буе истән җибәрмәмен Башларымнан ниләр үткәнне...* (Ш. Мөдәррис);

ә) *-ган* формасы сөйләү моментыннан соң булачак процессны атый: *Күрерсең син боларның йөргәнен һәрдаим коридорда...* (Г. Тукай).

**Үткән заман сыйфат фигыльдә башкаручы затның белдерелүе.** Үткән заман сыйфат фигыль аергыч функциясендә дә, исем

фигыль мәгънәсендә килгәндә дә, гадәттә, башкаручы затка бәйле эш-хәлне, процессны белдерә. Аның чаралары төрле булырга мөмкин.

**Аергыч** функциясендә килгәндә сыйфат фигыль фигыль нигезендә белдерелгән эшнең **субъектын** ачыкласа, башкаручы зат сыйфатланмыш аша белдерелә: *килгән кешеләр, кайткан кунак, яуган яңгыр* һ.б. *Яшьли ирдән калып, күп газаплар кичергән ана һаман ирен көтте* (А. Расих).

Сыйфат фигыль нигездә бирелгән эшнең **объектын, урынын, вакытын** һ.б.ны ачыклап килгәндә, башкаручы зат төшенчәсе сыйфатланмышка ялганган тартым кушымчалары аша белдерелә*: әйткән сүзем, язган хатың, барган юлларыбыз* һ.б. *Җырлап торам, торган җирем тар булса да, курыкмыйм сөйгән халкым бу, татар булса да* (Г. Тукай). *Болар пар ат белән килгән юлларыннан китеп бардылар* (әкият). *Шулай итеп безнең Гыйльменисабыз картайган көнендә тагын ялгыз калды* (Ф. Хөсни).

Искәрмә. Борынгы татар әдәби телендә, шулай ук XX йөз башы татар әдәби телендә башкаручы затка ишарә итә торган тартым кушымчаларының турыдан-туры сыйфат фигыльгә ялгану очраклары да бар: *Атыгызга нәзым кыйлганым китап Хәтем кыйлдым аны мән төрки ясап...* (Мөхәммәдьяр). *Җиңелләнәм, могъсумланам мин шул чакта, рәхмәт әйтәм укыганым шул китапка* (Г. Тукай). *Күргәнең миннән яфаларны оныт, Әйләмә яд, ул хафаларны оныт!* (Дәрдемәнд).

Сыйфат фигыль субъектны ачыклап килгәндә дә, сыйфатланмышка тартым кушымчалары ялганырга мөмкин. Ләкин ул вакытта инде алар башкаручы затка ишарәләмиләр, ә үзләренең туры мәгънәләрендә кулланылалар, ягъни предметның кайсы затка караганлыгын белдерәләр: *йөгереп, йөгереп туктаган, яулык болгап сыктаган Нәзкәй билем исән бул!* (Дәрдемәнд).

Сыйфат фигыль белдергән процессның субъекты шулай ук баш килештәге (сирәгрәк иялек килешендәге) алмашлык я исем белән дә белдерелә ала: *без яшәгән авыл, ул биргән киңәш, мин күргән кеше* һ.б. *Граниттай нык итеп койгансың мин торган йортның нигез ташын* (Г. Зәйнашева). *Без кабызган утлар сүнмәс алар...* (җыр). Бу очракта сыйфат фигыль, эш башкаручы субъектны белдергән сүз белән берлектә, синтетик иярчен аергыч җөмләләр төзи [Бу турыда кара: Закиев М., 1963, с. 276–279].

**Исем фигыль** функциясендә килгәндә башкаручы зат мәгънәсе:

а) сыйфат фигыльгә ялганган тартым кушымчалары белән белдерелә: *Тегермән тавыннан т ө ш к ә н е ң н е малайлар күреп торганнар* (И. Гази). *Урынымнан ничек сикереп т о р г а н ы м н ы белмим* (Г. Ибраһимов).

Тартым кушымчасы белән белдерелгән субъект баш яки иялек килешендәге алмашлыклар яки исемнәр белән ачыкланырга мөмкин: *М и н е м шунда к у а н г а н н а р ы м биш минутлык төш кебек кенә әле дә булса хәтеремдә* (Г. Тукай). *Килде, с и н е ң к е р г ә н е ң н е көтә* (И. Гази). *Җ ә й н е ң ү т к ә н е сизелми дә калды* (И. Гази). *Иртәнге тынлыкны бозып, һавада с а м о л е т л а р о ч к а н ы ишетелә* (Р. Төхфәтуллин).

И с к ә р м ә . Субъектка ишарәләүче тартым кушымчалары шулай ук исемләшкән сыйфат фигыльгә дә ялганырга мөмкин: *А ш а г а н ы б ы з ап-ак калач та дөге боткасы...* (Ә. Еники).

ә) эш башкаручы субъект тартым кушымчасыннан башка, аналитик юл белән бирелә: *С и н к а й т к а н н ы көтеп бармый тордым* (И. Гази). *Алар, чатыр эченә сыенып, я ң г ы р т у к т а г а н н ы көтә иделәр* (Ш. Камал). Субъектка ишарәләүче алмашлыклар бу очракта иялек килешендә дә килергә мөмкин: *Әсма м и н е м к а р а г а н н ы күрде, миңа ялт итеп карап алды* (Г. Ибраһимов). *Еллар үтәр, хәтерлә син б е з н е ң киләчәккә ничек б а р г а н н ы* (Х. Туфан).

Аерым очракларда исем фигыль мәгънәсендә кулланылган *-ган/-гән* формасы башкаручысы билгесез булган, яки эш башкаручы субъекттан аерылган эш-хәлләрне дә белдерә ала. Бу очракта ул грамматик яктан үзенең функциональ рәтенә, ягъни *-у/-ү* кушымчалы исем фигыльгә аеруча якын тора*: Азмы к а к к а н н ы вә с у к к а н н ы күтәрдем мин ятим* (Г. Тукай). *Көтеп тора сабый балалар Аждаһаның башын ө з г ә н н е* (Х. Туфан).

**Сыйфат фигыльле әйләнмәләр һәм икенчел формалар.** *-ган* кушымчалы үткән заман сыйфат фигыльнең гомумән телдә кулланылышы бик киң. Алда саналган мәгънәләреннән тыш, ул һәртөрле әйләнмәләр, икенчел формалар ясауда катнаша.

*-ган бар, -ган юк* әйләнмәләре, *-ган* кушымчалы фигыль *бар, юк* модаль сүзләре белән килеп, эш башкаручының күз алдында үтәлгән (яки үтәлмәгән) эшне белдерә, һәм грамматик мәгънәсе белән ул

күптән үткән заман хикәя фигыльгә якын тора. [Бу турыда кара: Тумашева Д., 1986, б. 73–77.] *Кыя таулар күкрәгенә м е н г ә н е м б а р, Кузгалаклы болыннарда й ө р г ә н е м б а р* (Г. Афзал). *Дилә белән бу урманнарда й ө р г ә н е б а р аның* (А. Гыйләҗев). *Менә атнага якын инде аларның о ч р а ш к а н н а р ы ю к иде* (Ф. Хөсни). Бу әйләнмә составындагы *-ган* формасы һәрвакыт исем фигыль мәгънәсендә кулланыла, ягъни үткәндә булган процесс исемен атый, ә *бар* сүзе белән килеп, ул исеме аталган процессның булуын, *юк* сүзе белән килгәндә булмавын констатацияли: *алганым бар* – ягъни үткәндә теге яки бу әйберне алу факты (минем тарафтан) булды – алдым. Хәзерге татар әдәби телендә бу әйләнмә тарафынан белдерелгән процессның субъекты, күпчелек очракта, тартым кушымчалары һәм иялек килешендәге исемнәр яки алмашлыклар белән белдерелә: *Менә ничә ел инде яңа о п е р а н ы ң сәхнәгә ч ы к к а н ы ю к* («Социалистик Татарстан»). *Төпләрендә я т к а н ы м б а р, хәл җыеп, күккә карап* (Г. Тукай).

Аерым очракта субъект төшенчәсе тартым кушымчаларыннан башка да иялек килешендәге алмашлыклар белән белдерелергә мөмкин: *Әкиятләрнең алтын сараенда б е з н е ң инде й ө р г ә н б а р иде* (Х. Туфан). *Басыйр белән б е з н е ң бу араларда юньләп очрашкан да, с ө й л ә ш е п й ө р г ә н - у т ы р г а н д а ю к* (Ә. Еники).

Җөмлә эчендә субъектка ишарәләүче сүз яки кушымча булмаганда, *-ган бар (юк)* әйләнмәсе тарафыннан башкарылган процесс гадәттә беренче затка карый: *Өч ел инде иңгә к ө я н т ә с а л г а н ю к* («Азат хатын»). *Күптән инде үзебезнең җырларны и ш е т к ә н ю к* (И. Гази). *Бүген әнә шул көчне кая куярга б е л г ә н ю к* (М. Мәһдиев). Шунысы характерлы, *-ган юк* ның антонимы булган *-ган бар* әйләнмәсе мондый мәгънәдә сирәк кулланыла: *Аны и ш е т к ә н б а р ла ул!* (сөйләм теленнән).

И с к ә р м ә . Борынгы татар әдәби телендә дә эш башкаручы субъектның бу рәвешле бирелеше шулай ук характерлы күренеш: *Кеше андак әрмәгән к ү р г ә н е ю к...* (Мөхәммәдьяр, XVI йөз). *Татлы с у э ч к ә н е ю к ирди гарәб. Таңлап аны кыйлды ул өрсү гаҗәб* (Мөхәммәдьяр, «Нуры содур»).

***-ганлык/-гәнлек* формасы.** Тюркологик әдәбиятта сыйфат фигыльләргә ялганып килгән *-лык/-лек* кушымчасының фигыль сүз төркеме эчендә форма ясау хезмәтен үтәве күрсәтелә. Мәсәлән, каракалпак телендәге *-ар (-мас) лык, -а туганлык, -ганлык* формаларын

Н. Баскаков, икенчел исем фигыльләр (вторичные имена действия), дип атый [Баскаков Н., 1952, с. 422).

Татар телендә *-лык* кушымчасы гадәттә исем фигыль мәгънәсендә кулланылган *-ган* формасына ялганып килә, шуңа күрә ул бу формага өр-яңа лексик, яки грамматик мәгънә өстәми, ә бәлки *-ган* формасына хас процессны атау, процесс исемен белдерү мәгънәсен көчәйтә, аны законлаштыра.

Татар телендә *-ган*лык формасы, иялек һәм урын-вакыт килешеннән тыш, барлык килешләрдә диярлек очрый.

**Баш килештә:** *Бу иптәшнең шатлыгы зур булганлыгы да мәсьәләне үз башында йөрткәнлеге, уйлаганлыгы, теге яктан да, бу яктан да үлчәп караганлыгы... күренеп тора иде* (Ф. Хөсни). *Иптәшләрдә ялыкканлык сизелә башлады* (Г. Ибраһимов).

**Юнәлеш килешендә:** *Ул үзенең улы Әхмәтне миссионер дип белеп, шул кадәр кайгырган һәм елаганлыгына гаҗәпләнергә дә, гаҗәпләнмәскә дә белмәде* (Ф. Әмирхан). *Күк китабының сине белгәнлегенә шаккатып, ул хәзер алган «Сабах»тан бер Кәләмулла сатып...* (Г. Тукай).

**Төшем килешендә:** *Ут янына бүреләр дә киләлмәсләр, Безнең анда кунганлыкны беләлмәсләр* (Г. Тукай). *Карт үзенең арттырыбрак җибәргәнен үзе дә сизә, мин аның сизгәнлеген күзләреннән күреп торам* (Ф. Хөсни).

**Чыгыш килешендә:** *Һәр олуглар эшләгәнлектән олуглыклар таба* (Г. Тукай).

Шул рәвешле, *-ганлык* формасы процесс исемен белдереп исем фигыль буларак кулланыла. Бу җәһәттән күп яклары белән *-ганлык* формасы процесс исемен атап килүче *-ган* формасына охшаш, һәм аерым очракларда җөмләдә бу ике форманың кайсы кулланылу ирекле булырга мөмкин. Ләкин аларның кулланылышында үзләренә генә хас үзенчәлекләр дә бар. *-ганлык* формасы, мәсәлән, процессның үтәлгән булуына, нәтиҗәлелегенә басым ясарга кирәк булганда аеруча уңышлы яңгырый: *Барысының да мәсьәләне үз башында йөрткәнлеге, уйлаганлыгы, теге яктан да, бу яктан да үлчәп караганлыгы... күренеп тора* (Ф. Хөсни), *-ган* формасы, үз чиратында, һәрвакыт *-ганлык* белән алмаштырыла алмый.

Шулай ук *-л ы к* кушымчасының аерым очракларда, *-ган* формасына ялганып, сүз ясау хезмәтен үтәвен билгеләп үтәргә кирәк. *Оешканлык* (организованность), *өлгергәнлек* (зрелость), *бирелгәнлек* (преданность), *уңганлык* һ.б.

**Киләчәк заман сыйфат фигыль.** Хәзерге татар телендә киләчәк заман сыйфат фигыльнең өч формасы актив кулланылышта йөри: *-р, -асы/-әсе, -ачак/-әчәк* формалары. Грамматик табигатьләре буенча бу сыйфат фигыльләр үткән заман сыйфат фигыль *(-ган* формасы) белән охшаш: алар сыйфатланмыш белән күп төрле мәгънә мөнәсәбәтендә (субъект, объект, урын, вакыт) тора алалар, контекстта исемләшәләр, исем фигыль мәгънәсендә кулланылалар.

***-ыр/-ер (-ар/-әр), -р* кушымчалы сыйфат фигыль.** Киләчәк заман сыйфат фигыльнең бу формасы фигыль нигезенә *-ыр/-ер (-ар/-әр), -р* кушымчалары ялганып ясала, *-р* аффиксы сузык авазга тәмамланган фигыль нигезенә ялгана: *сөйлә-р сүз, эшлә-р эш.* Тартык авазга тәмамланган сүзләргә:

а) ярымтар сузыклар белән килә торган *-ыр/-ер* кушымчасы ялгана: *кил-ер көн, кайт-ыр вакыт, йөр-ер чак;*

ә) киң сузыклар белән килгән *-ар/-әр* кушымчасы ялгана: *үс-әр (гөлләр үсәр көн), там-ар (тамчылар тамар чаклар).*

Искәрмә. 1. Бу очракта фигыль нигезенә кайсы кушымчаның (тар сузыклар белән яки киң сузыклар белән) ялгануын кагыйдә белән беркетү шактый авыр. Әгәр фигыль *р* авазына яки *л* авазына бетсә, аңа кушымчаның киң варианты ялганмый диярлек, мәсәлән: *бар-ыр җир, ал-ыр акча.* Калган очракта практик кулланылышта тар һәм киң кушымчаларның икесе дә ялганырга мөмкин, мәсәлән: *ту-ар* (ту-ыр) *таң, ис-әр* (исер) *җил.* Әдәби нормага киң кушымча ялгау туры килә төшә.

2. *у, ү, и* авазларына тәмамланган фигыль нигезләренә, кагыйдә буларак, *-ар/-әр* кушымчалары ялгана: *ту-ар көн, кий-әр* (кияр) *күлмәк.* Бу күренеш исә тарихи рәвештә мондый сүзләрнең ахырында тартык (ярымсузык) *w* һәм *й* авазлары булу белән аңлатыла: *туг > туw > ту; киг > кий > ки.*

*-р* кушымчалы сыйфат фигыльнең юклыгы *-ма-с/-мә-с* кушымчалары белән ясала: *с у л м а с гөл, ш и ң м ә с чәчәк, т а л м а с беләк. Халык җырлары халык күңеленең һич тә т у т ы к м а с вә к ү г ә р м ә с саф вә рәушан көзгеседер* (Г. Тукай). *Тормыш к ү з и я р м ә с тизлек белән алга бара* («Социалистик Татарстан»).

Киләчәк заман сыйфат фигыльнең бу формасы аергыч функциясендә килгәндә үзенең сыйфатланмышы белән күп төрле мәгънә мөнәсәбәтендә тора:

а) сыйфатланмыш – тамырдагы процессның **субъекты:** *Такташ, синең үпкәң искә төште, Итмәгәннәр нарком беразга... Син шигырьдә н а р к о м  б у л ы р  к е ш е, Тирән синең ерган буразнаң* (С. Хәким). *С а г ы н м а с  к е ш е л ә р булмас, сагынам, сабыр итәм* (җыр);

ә) сыйфатланмыш – тамырдагы процессның **объекты:** *С ө й л ә р с ү з е н оныткандай, беравык ул тынып торды* (Н. Фәттах). *Сиңа ә й т е р  с ү з е м бар...* (Ш. Галиев);

б) сыйфатланмыш тамырдагы процессны **урын** ягыннан характерлый: *Тирән сахра минем б а р ы р  ю л л а р* (Һ. Такташ). *Ашкынамын мин ә б ә т  б е т м ә с  у р ы н г а, мәңгегә* (Г. Тукай). *К а й т ы р ю л г а юнәлделәр хәзер* (әкият);

в) **вакыт** ягыннан характерлый: *С а у б у л л а ш ы р, к и т ә р м и н у т җитте, Ә килми лә, килми китәсе* (Х. Туфан). *Крестьянның утка баскан кебек й ө р е р  ч а г ы  җитте* (И. Гази).

Болардан тыш, *-ыр/-ер* формасы *чама, исәп* кебек сүзләр белән һәм *алдыннан* сүзе белән шактый еш очрый: *Кунакның да к у з г а л ы р и с ә б е күренми* (Ф. Хөсни). *Җавапны озак көтеп т о р ы р  ч а м а б ы з юк безнең дигән кебек, текәлеп карап тора башлады* (Ф. Хөсни). *Син к и л е р  а л д ы н н а н безнең позицияләр өстенә биш снаряд төште* (И. Гази). Әмма татар телендә бу очраклар *-р* формасының исем фигыль мәгънәсе буларак карала ала, чөнки бу позициядә *-ыр/-ер* формасы, еш кына, *-у/-ү* кушымчалы фигыль белән алыштырыла: *кузгалыр исәбе – кузгалу исәбе, килер алдыннан – килү алдыннан* һ.б.

*-р* формасы хәл сүзен ачыклаганда күпчелек очракта *юк* сүзе белән килә: *Хәзер шундый вакыт, җитәкчесез бер адым а т л а р  х ә л  ю к* (И. Гази). *Бер яртын тоз с а т ы п  а л ы р  х ә л  ю к* (И. Гази). *Булмаганны «бар» дип ә й т е р  х ә л е м  ю к* (Ф. Хөсни). Бу очракта *хәл* сүзе сыйфатланмыш буларак үзенең мөстәкыйльлеген югалткан һәм *-ыр хәл юк* тезмәсе модаль мәгънә белдерә торган сыйфат фигыльле әйләнмә буларак карала ала (ул мөмкин түгеллекне катгыйлык белән белдерә).

Шул рәвешле, үзенең сыйфатланмышы белән күп төрле мәгънә мөнәсәбәтендә тора алуы ягыннан *-ыр/-ер* формасы *-ган* формасына

охшаш. Шунысы үзенчәлекле: әгәр *-ган* формасы тамырдагы процессның объектын яки субъектын ачыклап килсә, *-ыр/-ер* формасының тамырдагы процессның урынын яки вакытын белдерүче сүзләрне ачыклау мөмкинлеге күбрәк.

***-р* кушымчалы сыйфат фигыльнең заман белдерү үзенчәлекләре.** Мәгълүм булганча, төрки телләрдәге *-ыр/-ер, -ар/-әр* формасы тарихи рәвештә хәзерге-киләчәк заман мәгънәсен белдергән. Мәсәлән, татар халык мәкальләрендә бу сыйфат фигыль бик еш хәзерге-киләчәк заман төсмере белән кулланыла: *С ө р т е н м ә с тояк булмас, я л г ы ш м а с тел булмас* (мәкаль). Аның бу үзенчәлеге, өлешчә, хәзерге әдәби телдә дә чагыла.

Аергыч функциясендә *-р (-мас/-мәс)* формасы предметны:

а) хәзерге-киләчәк заман төсмерен белдерүче процесс буенча характерлый: *Әйләнмәле тормыш чылбырында А л м а ш ы н м а с бөҗра бармы соң?* (К. Булатова*). Без менә чыктык я н а р таулар булып...* (Һ. Такташ). *Кыз кеше, кеше арасына к и я р күлмәге юк* (Ф. Хөсни);

ә) сөйләү моментында башкарылучы процесс буенча характерлый, ягъни хәзерге заманны белдерә: *Кем аны, кояш микән, Алтынлы нуры белән Күңелгә язып куйды к ү р е н м ә с кулы белән* (Х. Туфан). *Кырыкта да әле тальяныңның Сандугачтай с а й р а р чаклары* («Совет әдәбияты»).

Бу очракта *-р* формасын *-а торган* формасы белән алыштырырга мөмкин. *Сайрар җир – сайрый торган җир, күренмәс кул – күренми торган кул, сайрар чак – сайрый торган чак;*

б) киләчәктә булачак эш, хәл, хәрәкәт буенча характерлый: *Үткән көннәр алар ярылып ята, К и л е р көннәр генә сер тулы* (М. Шабаев). *Үткәннәрдә түгел, т у а р көндә Ишетелсен иде тавышым* (Р. Әхмәтҗанов). *Бу көннәрнең барлык истәлеген алып кит син к и л е р көнеңә* (Х. Туфан).

И с к ә р м ә . *-р* формасының бу рәвешле киләчәк заман төсмере белән кулланылуы татар әдәби теле өчен чагыштырмача яңа күренеш, һәм бу күренешнең активлашуына хәзерге телдә аның хәбәр функциясендә дә киләчәк заман төсмере белән кулланылуы тәэсир иткән булырга мөмкин.

в) аерым очракларда *-р* формасы заман төшенчәсен тулысынча диярлек югалтып, затка яки предметка гомумән хас билгене белдерә башлый һәм сыйфатларга якыная, яки тулысынча сыйфат сүз

төркеменә күчә: *к а й н а р хисләр, я н а р чәчәк, я н а р тау, ү л м ә с җыр, с ү р е л м ә с дәрт, с у л м а с гөл, с ү н м ә с нур* һ.б.

Контекстта исә *-р* кушымчалы сыйфат фигыльнең заманы күбрәк төп фигыльгә бәйле була, ягъни ул*, -ган* формасы шикелле үк, мөнәсәбәтле заманны белдерә: *Крестьянның утка баскан кебек й ө р е р чагы җ и т т е* (И. Гази). *Аккошның к и т ә р сәгате, яшьлекнең соңы җ и т ә р* (Х. Туфан).

*-р* кушымчалы киләчәк заман сыйфат фигыльдә эш башкаручы субъект төрле юллар белән белдерелә ала:

а) сыйфатланмыш янындагы тартым кушымчасы аркылы белдерелә: *Ә й т е р с ү з е м әйтә алмадым Күңелләрем тулганга* (җыр). *Бөтен өмет синдә, Малик туган, бүтән с о р а р к е ш е б е з юк* (И. Гази). *Т ү з ә р х ә л е м калмады...* (Г. Ахунов). Еш кына, тартым кушымчасы белән белдерелгән субъектны ачыклап, иялек килешендәге исем яки алмашлык килергә мөмкин*: А һ, м и н е м с а й р а р җ и р е м урман иде...* (Г. Тукай). *К р е с т ь я н н ы ң утка баскан кебек й ө р е р ч а г ы җитте* (И. Гази).

Тартым кушымчасыннан башка, сыйфат фигыль белдергән процессның субъекты баш килештәге исем яки алмашлык белән белдерелә: *Б е з н е к е л ә р әйләнеп к а й т ы р в а к ы т җитте* (Ф. Хөсни). *Мәктәптә у к у л а р б а ш л а н ы р к ө н җитә* (Ф. Хөсни). *Болыннарда г ө л л ә р ү с ә р к ө н н ә р килә...* (З. Мансур);

ә) эш башкаручы субъект контексттан аңлашыла: *К а й т ы р юлга юнәлделәр* (әкият);

б) *-р* формасы, еш кына, субъекттан аерылган эш-хәлне белдереп килә: Ч*ыкчы тышка, нинди һәйбәт, нинди шәп у й н а р заман!* (Г. Тукай).

***-р* кушымчалы сыйфат фигыльнең исемләшүе һәм исем фигыль мәгънәсендә кулланылуы.** Барлык сыйфат фигыль формалары кебек үк, *-р* формасына да контекстта исемләшү хас. Әмма хәзерге телдә аның барлык һәм юклык формаларында исемләшүе нигездә мәкаль-әйтемнәрдә генә очрый: *Т ы я р ы юк туйга киткән (*мәкаль). *Коралы ү т м ә с н е ң эше бетмәс* (мәкаль). *Алты я ш ә р юлдан кайтса, алтмыш я ш ә р күрешә килер* (мәкаль).

Исем фигыль мәгънәсендә исә бу сыйфат фигыль формасы барлык килеш формаларында диярлек очрый:

а) баш килештә: *Аларның кайчан к а й т ы р ы билгеле булмаса да, чамалап, һич югы чәйне яңадан кайнатып җибәрергә мөмкин булган булыр иде* (Н. Фәттах);

ә) юнәлеш килешендә: *К а й т ы р ы н а ак чәчәкләр өзгән таңда Ил күгенә карап ауды батыр егет* (Р. Әхмәтҗанов). *Менә бусы салып я т ы р ы г ы з г а , диде ул, төргәктән өч мендәр... чыгарып* (Ф. Хөсни);

б) төшем килешендә: *Карт каушады, уеннан уймак ч ы г а р ы н сизенде булса кирәк* (Г. Ибраһимов). *Ярым кем б у л ы р ы н белмим, Мин әле ялгыз йөрим* (Ш. Галиев);

в) чыгыш килешендә: *Ү л ә р е н н ә н берничә көн элек телдән калды, мескен* (И. Гази). *Төшендә, юл өчен, чәчкәен тарасын. Гарипнең к а й т ы р ы н н а н фал карасын* (Дәрдемәнд).

И с к ә р м ә . 1. Исем фигыль мәгънәсендә *-р* кушымчалы сыйфат фигыль хәзерге телдә иялек һәм урын-вакыт килешләрендә очрамый диярлек. Әмма борынгы төрки телдә һәм иске татар әдәби телендә бу форма урын-вакыт килешендә дә шактый актив кулланылган. Мәсәлән: *Бу угыл ул инәкне и л т ә р д ә* (Мәхмүд бине Гали, «Нәһҗел-фәрадис»). *Сата алмаен янә эвгә к и л е р е н д ә берәү балык сата ултырыр юлында* (Мөхәммәдьяр).

2. Бу сыйфат фигыльнең кайбер килеш формалары, мәгълүм булганча, морфологик изоляция кичергән. Мәсәлән: инфинитив кушымчасы *-ырга/-ергә, -арга/-әргә, -рга/-ргә* сыйфат фигыльнең юнәлеш килеше формасыннан барлыкка килгән; *-мас- тан* формасы (*-р* кушымчалы киләчәк заман сыйфат фигыльнең юклыгы чыгыш килеш формасында) хәл фигыльләргә якынайган: *Мансур күзләрен а л м а с т а н шәһәр өстен күзәтеп барды* (А. Расих). *Төн буена т у к т а м а с т а н Тышта ап-ак кар ява* (Н. Думави).

***-р* кушымчалы сыйфат фигыльдән ясалган икенчел формалар.** *-лык/-лек* һәм -дай/*-дәй* кушымчалары ярдәмендә киләчәк заман сыйфат фигыльнең икенчел формалары ясала.

И с к ә р м ә . *-лык/-лек, -дай/-дәй* кушымчалары, мәгълүм булганча, хәзерге тел белемендә сүз ясагычларга кертелә, әмма сыйфат фигыль формаларына ялганып килгәндә алар һәрвакыт яңа сүз, яңа лексик берәмлек ясамыйлар, форма ясагычлар сыйфатында сыйфат фигыльләрнең икенчел формаларын барлыкка китерәләр.

*-рлык(-маслык)* кушымчалы форма күбрәк аергыч функциясендә (атрибутив мәгънәдә) кулланыла һәм предметның эш-хәл буенча билгесен белдерә: *Бакчадагы радио соңгы хәбәрләр бирергә тотына. К ү ң е л г ә я т а р л ы к бер генә җылы хәбәр дә юк* (И. Гази). *Айлы*

*төндә бәсле урман юлы, Бер карасаң, хәйран калырлык* (Г. Афзал). *Тышта күз ачмаслык буран* (сөйләм теленнән).

*-рдай(-мастай*) формалары да, еш кына, аергыч фунциясендә килә: *Яндырырдай, көйдерердәй көлү көче* (Г. Афзал). *Таш тауларны эретердәй шәфкать нуры Балкый төпсез күзләренең карашында* (Һ. Такташ). *Бу бик авыр мәсьәлә иде, бу һич тә хәл итеп булмастай мәсьәлә иде* (Н. Фәттах).

Татар телендә *-рдай, -мастай* формасы, еш кына, процессны ачыклап рәвеш сүз төркеменә якын мәгънәдә кулланыла. Нәкъ шуңа күрә дә татар тел белемендә *-дай/-дәй* кушымчасы, нинди сүз төркеменә ялганып килүенә карамастан, рәвеш ясагыч кушымча дип танылa [Тумашева Д., 1964, б. 243; Современный..., 1969, с. 302][1]. *Тәзкирә бер елмайды, бер бозылды, елардай булды* (Н. Фәттах). *Күрердәй генә булмадым* (сөйләм телендә).

***-асы/-әсе, -ыйсы/-исе* кушымчалы сыйфат фигыль.** *-асы* кушымчалы киләчәк заман сыйфат фигыль үзенең күп яклары белән алда тикшерелгән *-ган*, *-р* формаларына охшаш. Ул шулай ук күп төрле функцияләрдә кулланыла:

а) аергыч функциясендә килә һәм предметны киләчәктә булачак, эшләнергә тиешле эш буенча ачыклый: *Күзләрем алмый карыймын кайтасы юлларыңа* (җыр).

Үзе ачыклаган сүз төшеп калганда, вакытлыча исемләшә: *Буласы булган, буявы сеңгән* (мәкаль). *Аласыңны ал да чыгып кит* (Т. Гыйззәт);

ә) *-асы* формасы, башка сыйфат фигыльләр кебек үк, исем фигыль мәгънәсендә кулланыла: *Апрель җиле май киләсен хәбәр итә* (Г. Афзал);

б) *-асы* формасы хәбәр функциясендә килә: *Арышка төшәсе бу айда* (Г. Афзал). Мәгълүм булганча, татар телендә *-ган, -р (-ачак)* кушымчалы сыйфат фигыльләр нигезендә затланышлы формалар – хикәя фигыль заманнары ясалган. *-асы* формасы затланышлы фигыль буларак кулланылмый, әмма аның бернинди кушымча алмаган хәлдә хәбәр функциясендә кулланылуы үзенчәлекле күренеш булып тора:

---

[1] Кайбер галимнәр бу кушымчаны махсус килеш-охшату килеше кушымчасы дип тә саныйлар [Зәкиев М., 1964, с. 207].

*Нәрсәгә ул кадәр янып-көеп йөрергә, барыбер «Туры юл» колхозы белән кушыласы ич, дип мыгырдап алды ул* (Ф. Хөсни).

***-асы/-әсе* кушымчалы сыйфат фигыльнец аергыч функциясендә кулланылышы.** *-асы/-әсе* формасы аергыч функциясендә килеп, предметны киләчәктә булачак, булырга тиешле эш-хәл буенча характерлый. Бу очракта ул, *-ган/-гән, -р* формалары кебек, тамырдагы процессның субъектын (а), объектын (ә), урынын (б), вакытын (в) ачыклап килә.

а) *Үләсе күбәләк ут күзенә керер* (мәкаль). *Син, анасы, балаларны яхшы кара, алар киләчәктә яшисе кешеләр* (Г. Әпсәләмов);

ә) *Майга чаклы бетерәсе эшләр бар монда* (Ф. Хөсни). *Бу – чишелмәгән, уйлыйсы мәсьәлә* (Л. Ихсанова);

б) *Алмагачлар чәчәк атсын йөрисе юлыгызга* (җыр). *Фатыйманың битләре кабынып китте, йөгереп барып, Якуб утырасы җиргә мендәр салды* (И. Гази);

в) *Гөлшаһидә Әбүзәр абзыйларга барасы көнне түземсезлек белән көтте* (Г. Әпсәләмов).

*-асы/-әсе* формасы аергыч функциясендә килгәндә гадәттә сөйләү моментыннан соң булачак эш-хәлне, ягъни тиешлек модаль мәгънә төсмере катыш абсолют киләчәк заманны белдерә. *Минем халкымның күңелендә дә әле җырга салынасы, повесть, романнарга күчәсе изге хисләре ята* (С. Хәким). *Яшел келәмнәр җәегез Без киләсе сукмакка* (җыр). *Бетерәсе эшем бар,– диде* (Ф. Хөсни).

Әмма төп фигыль дә, сыйфат фигыль дә бер үк процессны белдергән җөмләләрдә *-асы/-әсе* формасы абсолют заманны түгел, мөнәсәбәтле заманны белдерә, ягъни бу форма белдергән заман мәгънәсе төп фигыльгә бәйле була. *Сөйләшәсе кешеләр белән сөйләштем (сөйләшәм, сөйләшермен). Урыласы иген урылып бетте (урылып бетә, урылып бетәчәк). Сөйлисе кешеләр сөйләп бетергәч, берничә сүз әйтмәкче булып, Якуб күтәрелде* (И. Гази).

*-асы* кушымчалы сыйфат фигыль аергыч функциясендә килгәндә күпчелек очракта субъектка бәйле процессны белдерә:

а) субъект сыйфатланмыш аша бирелә: *Разведкага барасы солдат каядыр китеп югалды* (И. Гази);

ә) сыйфат фигыль тамырдагы процессның **объектын, урынын, вакытын** ачыклап килгәндә субъект сыйфатланмышка ялганган тартым кушымчасы аркылы белдерелә: *Күзләрем алмый карыймын*

*к а й т а с ы юлларың а* (җыр). *Ә б и р ә с е бүләгең булса,... Шау-шусыз гына менгезеп бир* (Ф. Хөсни);

б) субъект аналитик юл белән белдерелә: *Яшел келәмнәр җәегез б е з к и л ә с е сукмакка* (җыр). *Фатыйма... Я к у б у т ы р а с ы җиргә мендәр китереп салды* (И. Гази);

в) аерым очракларда *-асы* формасы субъекттан аерылган процессны белдерә, яки субъект контексттан аңлашыла: *Ул өч а т л ы й с ы җ и р н е бер атлап, базардан чыгып бара иде* (Ф. Хөсни). *Гөлшәһидә Әбүзәр абзыйларга б а р а с ы к ө н н е түземсезлек белән көтте* (Г. Әпсәләмов).

Аергыч функциясендә килгәндә *-асы/-әсе* кушымчалы сыйфат фигыль юклыкта кулланылмый диярлек, һәрхәлдә, аның юклыгы фигыльләрдәгечә *-ма, -мә* кушымчасы белән белдерелми, бары тик сирәк очракларда гына, исемнәрдәгечә, *түгел* сүзе ярдәмендә белдерелә ала: *Мин сезгә сыңар шырпы да б и р ә с е к е ш е т ү г е л* (И. Гази). *Шушы актыгы булсын. Моннан ары аяк та а т л ы й с ы к е ш е т ү г е л ул* (И. Гази).

***-асы/-әсе* кушымчалы сыйфат фигыльнең исемләшүе һәм исем фигыль мәгънәсендә кулланылышы.** *-асы* формасы исемләшә һәм контекстта төрле килеш кушымчалары белән кулланыла:

а) баш килештә: *Ала каргада а л а с ы ң булсын* (мәкаль). *Т ө я л ә с е төялеп, а л ы н а с ы алынып беткәннән соң, хәер, озак тормадылар* (Ф. Хөсни).

ә) төшем килешендә: *А ш ы й с ы н ашаган, я ш и с е н яшәгән* (мәкаль). *Ичмасам теге малай да кайтмый, с ө й л ә ш ә с е н сөйләшер идем дә кайтып китәр идем* (Ф. Хөсни). *Һай йөрәкләр янып, ялкын йотып, к ү р ә с е н ә күңел җилкенде* (Г. Афзал).

*-асы/-әсе* кушымчалы сыйфат фигыльнең исем фигыль мәгънәсендә кулланылышы бик актив. Әдәби әсәрләрдә дә, сөйләм телендә дә ул бу мәгънәдә бик еш очрый:

баш килештә: *Синең к и л ә с е ң кичә ук билгеле иде инде* (сөйләм теленнән). *Дөресен әйткәндә, үзенең киләчәге, кая укырга б а р а с ы турында ачык итеп уйлаганы юк әле Гәрәйнең* (С. Сабиров);

төшем килешендә: *Ул чакта мин үземнең сугышка к и т ә с е м н е тәмам оныттым* (Г. Әпсәләмов). *Талдыйн тартма ясадым, тар б у л а с ы н белмәдем* (Г. Тукай);

юнәлеш килешендә: *Ул планы уңышлы чыгасына тәмам ышанган* (Ф. Хөсни). *Гәүһәр һәлакәт киләсенә һич ышанмый иде* (Г. Әпсәләмов).

Мисаллардан күренгәнчә, *-асы/-әсе* формасы исемләшкән хәлдә һәм исем фигыль мәгънәсендә күбрәк баш, төшем, юнәлеш килеше кушымчалары белән кулланыла. Аның чыгыш килеше формасы сөйләм телендә очрый: *Аның киләсеннән хәбәрем юк иде.*

Исем фигыль мәгънәсендә килгәндә эш башкаручы субъект төшенчәсе түбәндәге юллар белән белдерелә:

а) сыйфат фигыльгә ялганган тартым кушымчалары белән: *«Әхбар» бай дип еллык яздым, ябыласын белмәдем* (Г. Тукай). *Киләсеңне алдан хәбәр итәргә идең;*

ә) тартым кушымчасы һәм иялек килешендәге исем яки алмашлыклар белән: *Кышның яман киләсен алдан ук сизеп... Донбасс якларына сыздым* (Ф. Хөсни). *«Бурлак»ның кызыл яр турыннан кайчак үтәсен алдан белдереп торган икән* (С. Сабиров);

Искәрмә. III затта *-асы/-әсе* формасына гадәттә өстәмә рәвештә тартым кушымчасы ялганмый *(киләсе-м, -не, киләсе-ң, -не, киләсен),* әмма бу очракта да ул тартымлы төрләнеш кушымчаларын ала. Бары тик сөйләм телендә генә *-асы/-әсе* формасына өстәмә рәвештә III зат тартым кушымчасы ялганып килү очраклары бар: *Хәзер «Ирек мәйданы», киләсесе «Университет» тукталышы.*

б) субъект баш килештәге исем яки алмашлыклар белән белдерелә: *Гөлләр инде яфрак яралар хәбәр итеп язлар җитәсен* (Х. Туфан). *Апрель җиле май киләсен хәбәр итә* (Г. Афзал);

в) билгесез, яки гомумиләштерелгән субъектны белдерә: *Еллар үтәсен атналарда, айларда үтәргә тиеш булуыбызны уйлап та карамыйбыз* (Г. Әпсәләмов).

***-асы/-әсе* формасының мөстәкыйль җөмләнең хәбәре функциясендә кулланылуы.** *-асы* формасы, атрибутив функциядә һәм исем фигыль мәгънәсендә кулланылудан тыш, җөмләдә мөстәкыйль позициядә хәбәр булып та килә ала. Бу очракта ул, гадәттә, кирәклек, тиешлек, теләк модаль мәгънәләре катыш киләчәктә булачак эшне белдерә: *Арышка төшәсе бу айда* (Г. Афзал). *Иртәгә районга барасы* (Ф. Хөсни). *Бу караңгы чормага ничек менәсе инде тагын!* (И. Гази). *Бетәр иде күңел ярасы, тагын анда ничек барасы?* (җыр).

Татар телендә *-асы/-әсе* формасының бу мәгънәсе *-рга/-ргә* формалы инфинитивның мөстәкыйль кулланылышына да охшаш [Борһанова Н., 1969, б. 636]. Чагыштырыгыз: *Миңа иртәгә районга б а р а с ы . Миңа иртәгә районга б а р ы р г а .*

Диалектология буенча язылган хезмәтләрдә дә *-асы* формасының инфинитив ролендә килүе, аның бу мәгънәсенең аерым диалектларда, әдәби тел белән чагыштырганда, киңрәк таралган булуы да билгеләнә.

*-асы/-әсе* формасының хәбәр ролендә килүен мәгълүм дәрәҗәдә *-ган, -ыр, -ачак* кушымчалы хикәя фигыльләр кулланылышы белән чагыштырып булыр иде. Тик бу формалар хәбәр функциясендә килеп, зат-сан белән төрләнәләр, һәм алар инде, затланышлы фигыльләр буларак, сыйфат фигыльләрнең башка мәгънәләреннән аерымланганнар, *-асы* формасы хәбәр позициясендә килсә дә, зат-сан белән төрләнми, шуңа күрә аның бу рәвешле кулланылышы сыйфат фигыльнең үз мәгънәләреннән берсе, үз үзенчәлеге булып кала.

Әмма *-асы* кушымчалы сыйфат фигыль бу очракта да субъектка бәйле эш-хәлне белдерә, һәм контекстта эш башкаручы субъект түбәндәге юллар белән белдерелә:

а) юнәлеш килешендәге исем яки алмашлык белән[1]: *Таң тарала. М и ң а таңнан торып, басуларга эшкә ч ы г а с ы* (Г. Афзал). *А ң а бай малае булып кыланасы юк, ч ы г а с ы д а у й н ы й с ы гына* (Ә. Еники);

ә) иялек килешендәге алмашлык белән: *М и н е м әле тагын бер сәгать к ө т ә с е* (Г. Ахунов);

б) баш килештәге исем яки алмашлык белән: *Бүген к и н о к и л ә с е дип сөйләгәннәр иде* (Ф. Хөсни). *Һ и н д и М и н һ а җ шул җирләрдә дәрелфөнүн с а л а с ы* (Г. Тукай). *Азык әзерләргә кирәк, барысына да М ө н и р ә ч а б а с ы* (Ф. Хөсни);

в) эш башкаручы субъект билгесез, яки ул контексттан аңлашыла: *Бетәр иде күңел ярасы, Тагын анда ничек б а р а с ы ?* (җыр).

*-асы/-әсе* формасының юклык аспектында кулланылуы аның бу мәгънәсендә ешрак очрый. Юклык формасы гадәттә исемнәрдәгечә *түгел* кисәкчәсе ярдәмендә белдерелә: *Аларның икесенә дә бердәй кагыла торган сүзләр б е т ә с е т ү г е л* (Ф. Хөсни). *Машина бит үз*

[1] *-асы/-әсе* формасының бу үзенчәлеге дә аны *-рга/-ргә* кушымчалы инфинитивка якынайта.

*кулыңда, тирә-карага ялынып й ө р и с е  т ү г е л* (Г. Ахунов). Юклык формасы шулай ук *юк* модаль сүзе белән дә белдерелергә мөмкин: *Моннан соң самолетлар ягына а я к  т а  а т л ы й с ы м  ю к* (С. Баттал). Сирәк очракларда гына юклык фигыльләрдәгечә *-ма/-мә* кушымчасы белән бирелергә мөмкин: *Тозга баручы авылдашларын ул басу капкасы төбендә куып җитте. Тагын бераз мыштырдаса, бөтенләй ө л г е р м и с е  икән* (И. Гази).

***-асы* формасы нигезендә ясалган модаль әйләнмәләр.** *-асы* формасы нигезендә төрле ярдәмче фигыльләр һәм модаль сүзләр белән ясалган әйләнмәләр күбрәк хәбәр позициясендә киләләр һәм төрле модаль мәгънәләрне белдерәләр:

а) *бар, юк* сүзләре белән килгәндә *-асы* формасы киләчәктә булачак эшне кирәклек модаль мәгънә төсмере белән белдерә: *Безнең бит әле а т  а л а с ы б ы з  б а р,  әти, – дип куйды ул* (И. Гази).

Бу әйләнмә составындагы *-асы* формасы гадәттә тартым кушымчалары белән килә, һәм тартым кушымчалары бу очракта да эш башкаручы субъектка ишарәлиләр, ягъни бу форма тартым кушымчалары (һәм зат алмашлыклары) ярдәмендә өч зат белән мөнәсәбәткә керә: *Минем  а л а с ы м  б а р, безнең  а л а с ы б ы з  б а р, синең  а л а с ы ң  б а р, сезнең  а л а с ы г ы з  б а р, аның  а л а с ы  б а р, аларның  а л а с ы л а р ы  б а р.*

Әгәр затка ишарәләүче чаралар булмаса, бу әйләнмә белдергән эш-хәл гадәттә беренче затка карый: *Түбәне ныгытып я б а с ы  б а р* (Н. Фәттах). *Җыелыш була, Газзәгә байрак  т а п ш ы р а с ы  б а р* (С. Баттал). Юклык аспекты *-асы юк/-әсе юк* рәвешендә бирелә: *Азапланып бер дә  м е н ә с е  ю к...* (Н. Такташ). *Тагын,  я ш е р е п  т о р а с ы  ю к, бу кушамат минем үземә дә ошый* (Г. Әпсәләмов).

Шигъри сөйләмдә бу әйләнмәнең компонентлары бер-берсеннән ераклашып яки инверсияләнеп тә килергә мөмкин: *Ю к  синсез  я ш и  а л а с ы м ! Кайтырмын кайлардан да* (Ш. Галиев). *Ю к  икенче  а я к  б а с а с ы м . Рәис кеше үзе ашасын!* (Ш. Галиев).

ә) *-асы килә*[1] әйләнмәсе татар телендә теләк мәгънәсен белдерә: *У з а с ы   к и л ә  бер җыр җырлап киек каз юллары буйлап...*

---

[1] *-асы* формасының нигезендә ясалган модаль конструкцияләр Д. Тумашева һәм М. Зәкиев хезмәтләрендә тулы яктыртылган.

(И. Юзиев). Бу әйләнмә белдергән процессның затка мөнәсәбәте шулай ук тартым кушымчалары һәм иялек килешендәге исемнәр яки алмашлыклар ярдәмендә белдерелә *(минем җырлыйсым килә, синең җырлыйсың килә, аның җырлыйсы килә).* Әгәр *-асы* формасы тартымсыз кулланылса, ягъни затка ишарәләүче чаралар булмаса, *-асы килә* әйләнмәсе белдергән теләк (эш-хәл) беренче затка карый: *Шундый уйчан, аулак таңнарда С ү з к у ш а с ы к и л ә талларга* (Х. Туфан);

б) *-асы иде* аналитик формасы теләкне белдерә, һәм ул процесс шулай ук беренче затка карый: *Менә шулай трактордан төшмичә б а р а с ы д а, б а р а с ы и д е !* (Н. Фәттах). *Кызыл мәйданны к ү р ә с е и д е !* (Г. Әпсәләмов).

Юклык аспекты исемнәрдәге кебек түгел сүзе ярдәмендә, сирәгрәк фигыльләрдәгечә *-мый/-ми* кушымчасы белән дә ясала: *Һич булмаганда, «Туры юл» колхозыннан к а л ы ш а с ы т ү г е л иде* (Ф. Хөсни). *Аны бүген җ и б ә р м и с е и д е .*

в) *-асы калган* әйләнмәсе эшнең үтәлми калуына үкенүне белдерә: *Күз керфекләрем талганчы, к а р ы й с ы м к а л г а н и к ә н* (жыр). *Шәп булган, тагын берне ө с т и с е к а л г а н* (Г. Әпсәләмов).

д) *-асы итте* әйләнмәсе карар кылу модальлеген белдерә: *Ничек к и л е п ч ы г а с ы и т т е ң ?* (Г. Ахунов). *Авылга утырмага б а р а с ы и т т е әби...* (Х. Туфан).

***-ачак/-әчәк, -ячак/-ячәк* формасы.** Киләчәк заман сыйфат фигыльнең өченче формасы *-ачак/-әчәк, -ячак/-ячәк* кушымчалы фигыль шулай ук күпмәгънәле, һәм ул күп төрле функцияләрдә кулланыла.

**Атрибутив** функциядә кулланылган *-ачак/-әчек* формасы предметны киләчәктә булачак эш-хәл, хәрәкәт буенча характерлый: *б е т е р ә ч ә к эш, ә й т е л ә ч ә к фикер, б у л а ч а к җыелыш.*

Башка сыйфат фигыль формалары кебек үк, аергыч функциясендә *-ачак/-әчәк* формасы сыйфатланмышы белән күп төрле мәгънә мөнәсәбәтендә тора ала:

а) тамырдагы процессның субъектын ачыклый: *Инде хәзер бу далада беркайчан да т у к т а п - т ы н ы п т о р м а я ч а к э ш башланды* (Н. Фәттах). *Парлашып җырлап куялар, Йөрәкне телеп-телеп, Күлләрдән диңгез буена к и т ә ч ә к к о ш л а р кебек* (Х. Туфан);

ә) объектны ачыклый: *Хәзер т е р е л т ә ч ә к а д ә м хакында бераз мәгълүмат бирергә үтенде* (Ф. Әмирхан);

б) урынны ачыклый: *Тәгәрмәчләр, тәгәрмәчләр, Йөгереп үтә. Алда без шәһәр* *с а л а ч а к   д а л а л а р* *көтә* (Ш. Галиев). *Якуб* *б а р а ч а к   ө я з   ш ә һ ә р е* *дә аклар кулына эләкте* (И. Гази);

в) вакытны ачыклый: *Без күбрәк* *к и л ә ч ә к   к ө н н ә р* *турында хыялланырга яратабыз, Гөлшәһидә!* (Г. Әпсәләмов).

*-ачак/-әчәк* формасы фигыль нигезендә бирелгән эшнең **объектын, урынын, вакытын** ачыклап килгәндә, сыйфатланмышлар составындагы тартым кушымчалары эш башкаручы субъектка ишарәли. *Бередә* *ә й т е л ә ч ә к   ф и к е р л ә р е м* (Н. Исәнбәт). *С ө й л ә я ч ә к   с ү з л ә р е ң н е* *исеңдә тот.* Субъект төшенчәсе шулай ук аналитик юл белән, исемнәр, алмашлыклар ярдәмендә дә белдерелә ала: *Икенче* *б р и г а д а   с ө р ә ч ә к* *җиргә килеп тә җиттеләр* (Ф. Хөсни). Сыйфат фигыль төшем юнәлешендә килгәндә субъект, гадәттә, билгесез була: *Алдагы атнада* *у з д ы р ы л а ч а к* *җыелышта нәкъ менә шул мәсьәлә* *к а р а л а ч а к* (А. Расих).

*-ачак/-әчәк* кушымчалы сыйфат фигыльнең контекстта исемләшеп килүе сирәк, ә исемләшкәндә бу форманың тулысынча исемнәргә күчү тенденциясе дә бар: *киләчәк тормыш – киләчәк* (исем); *бирәчәк бурыч – бирәчәк* (*бирәчәгем бар* – исем).

Исем фигыль мәгънәсендә *-ачак* формасы шактый еш очрый, төрле килеш кушымчалары белән кулланыла: *Сез хәзерге минутта бөтен дөньяның язмышын* *ү з г ә р т ә ч ә г е* *ачык мәгълүм булган бер зур эшне башкарырга тиешлесез* (Г. Әпсәләмов). *Эшнең мондый әйләнеш* *а л а ч а г ы н* *күз алдына да китермәгән иде ул* (Ф. Хөсни). *Үзенең* *я л г ы ш м а я ч ы г ы н а* *әз генә дә шикләнмичә, барды да барды* (Н. Фәттах). *Әткәй, син күп эшләдең, хәзер инде сиңа ял итәргә вакыт...* *д и я ч ә г е н* *уйлап, күңеле янә күтәрелә* (Ш. Камал).

*-ачак* формасы исем фигыль мәгънәсендә кулланылганда гадәттә субъектка бәйле процессны белдерә. Субъект тартым кушымчалары, баш һәм иялек килешендәге исем яки алмашлыклар белән белдерелә: *М и н е м* *сәнаигы нәфисе* *б у л а ч а г ы м* *да тәмам билгеле булып җитте* (Ф. Әмирхан). *Таҗи Вильданов хәзер* *о р к е с т р   к и л е п   җ и т ә ч ә г е н* *хәбәр итте* (Г. Ахунов).

И с к ә р м ә. XX йөз башында язылган кайбер әдәби әсәрләрдә *-ачак* формасы исем фигыль мәгънәсендә килгәндә еш кына *икән, икәнлек* сүзләре белән кулланыла: *Шәкертләренә, тәҗрибә өчен, кабинетта әзерләнгән бер*

*адәмне* т е р е л т ә ч ә к и к ә н е н *бәян итте* (Ф. Әмирхан). *42 ел моннан әувәл вафат булган Фәтхулла хәзрәтне* т е р е л т ә ч ә к и к ә н л е г е *хәбәр бирелгән* (Ф. Әмирхан).

Шул рәвешле, киләчәк заман сыйфат фигыльләрнең өч формасы *(-ыр, -асы, -ачак)* кулланылыш үзенчәлекләре һәм мәгънә төсмерләре буенча бер-берсеннән аерылып тора: *-ыр* формасы, мәсәлән, предметны киләчәктә булачак, булырга мөмкин булган эш-хәл буенча характерлый; ә традицион кулланылышта исә хәзерге киләчәк заманны белдерә *(барыр юл, әйтер сүз); -асы* формасына исә күбрәк тиешлек, кирәклек модаль мәгънә төсмере хас *(барасы юл, әйтәсе сүз);* ә *-ачак* формасы предметны яки затны саф киләчәктә булачак эш буенча характерлый *(булачак җыелыш, әйтәчәк сүз).* Аңа шулай ук катгыйлык төсмере дә хас.

**Хәзерге заман сыйфат фигыль.** Хәзерге татар әдәби телендә хәзерге заман сыйфат фигыльнең ике формасы актив кулланылышта йөри: *-учы/-үче* формасы *(*к и л ү ч е *кешеләр,* к а й т у ч ы *солдатлар),* һәм аналитик юл белән ясалган *-а торган/-ә торган* формасы *(суга бара торган сукмак, күп сөйли торган кеше).*

***-учы/-үче* кушымчалы сыйфат фигыль.** *-учы* аффикслы хәзерге заман сыйфат фигыль гомумән татар телендәге сыйфат фигыльләр арасында үзенчәлекле урынны алып тора. *-ган, -ачак, -ыр, -асы* формаларыннан аермалы буларак, *-учы* формасы татар телендә башлыча атрибутив позициядә, ягъни сыйфат фигыльнең үз мәгънәсендә генә кулланыла (аергыч функциясе һәм исемләшү): *Ләкин* с ө й л ә ү ч е *агай аптырамый, уңайсыз хәлдән чыгу өчен, тагын мәкальгә ябыша* (Н. Исәнбәт) – аергыч функциясе; *Ишек* к а г у ч ы н ы ң *кем икәнлеген сорагач, ишек ачыла* (Ш. Камал). И ш е к н е а ч у ч ы *– өч-дүрт яшьләрдәге матур бер кыз бала иде* (А. Расих) – исемләшкән сыйфат фигыльләр.

*-учы* формасының исем фигыль мәгънәсендә кулланылышы хәзерге татар телендә очрамый, һәм аның нигезендә затланышлы формалар да ясалмаган.

И с к ә р м ә . 1. *-учы* формасының исем фигыль мәгънәсен белдерә алуы төрки телләр күләмендә билгеләнмәгән. Шул ук XX йөз башы әдәби әсәрләрендә татар телендә *-учы* формасының *-лык* кушымчасы ярдәмендә исем фигыль мәгънәсен белдереп килүенә генә кайбер мисаллар табарга мөмкин:

*Хәзрәтнең хәтеренә мондагы кешеләрнең миссионер б у л у ч ы л ы к л а р ы килде* (Ф. Әмирхан). *Тирә-ягындагы күренешнең бик матур б у л у ч ы л ы г ы , үзенең уңайлылыгы белән һәрвакыт мине тарта, балыкка, су керергә дип, еш-еш чаптыра иде* (Г. Ибраһимов). *Ул бер газета идарәсендә я з у ч ы л ы к - т а иде* (Ш. Камал). Ләкин хәзерге әдәби тел өчен бу күренеш шулай ук хас түгел.

2. Кайбер төрки телләрдә татар телендәге *-учы* формасы затланышлы фигыль буларак та кулланыла ала. Мәсәлән, карачай-балкар телендә *-ыучу, -еучю* формасы зат-сан белән төрләнә:

| | |
|---|---|
| I зат | *бурыучума* |
| II зат | *барыучуса* |
| III зат | *барыучуду* [Урусбиев И., 1963, с. 123]. |

Алтай телендә *-аачы, -еечи* формасы *иде (еди)* ярдәмче фигыле һәм *бол* сүзләре белән килеп, зат-сан белән төрләнә: *Поезд ике часта келеечи еди, келбейтер* [Тадыкин В., 1967, с. 158]. Шуңа охшаш күренеш Көнбатыш Себер татарлары теленең тәвриз сөйләшендә дә бар: *Син кунучы булма, мин сине күтәрем.*

Аергыч функциясендә килгәндә төп юнәлештә бары тик тамырдагы процессның субъектын гына ачыклап килә: *Уфа мединститутында у к ы т у ч ы е г е т шул җыр яратуы аркасында поездан да калган, ди* (М. Рафиков). *Моны өр-яңа сары чыпталар өелгән арбада у т ы р у ч ы киез эшләпәле а г а й янәшә б а р у ч ы җ ә я ү л е л ә р - д ә н сорады* (Ә. Фәйзи)[1].

Аңлашыла ки, *-учы* формасы исемләшеп килгәндә дә һәрвакыт тамырдагы процессның башкаручысын, субъектын белдерә: *Аягүрә а л к ы ш л а у ч ы л а р арасыннан ул таныш йөзләрне эзләде* (Ш. Хөсәенов). *Бу төнне авылда й о к л а у ч ы булгандырмы, ләкин Фатыйманың күзенә йокы кермәде* (И. Гази).

И с к ә р м ә . Фигыльгә *-учы* аффиксы ялганып ясалган сүзләрне элеккерәк чорда язылган грамматикаларда «эш башкаручыны белдерүче исем (имя действующего)» дип карау да булган [Казембек М., 1839, с. 67]. Ләкин шул ук хезмәттә мондый искәрмә дә бирелә: «Имя действующего в разных отношениях может быть рассматриваемо как род причастия настоящего. Образуется оно прибавлением частицы *-у, -чы (-учы)*» [шунда ук].

***-учы* формасының заман белдерү үзенчәлекләре.** *-учы/-үче* формасы татар телендә еш кына предметка хас билге булып әверелгән,

---

[1] Бу үзенчәлеге белән, ягъни бернинди өстәмә кушымчаларсыз килгәндә тамырдагы процессның субъектын гына ачыклавы белән, бу форма рус телендәге причастиеләргә охшашлык күрсәтә.

заманга мөнәсәбәтсез процессны белдерә. *Шулай, Шәрифҗан, мылтык т о т а  б е л ү ч е  ничә кешең бар?* (И. Гази). *Үзенең мәхәббәтеннән башка берни белән дә к ы з ы к с ы н м а у ч ы  яшь, чибәр кыздан чын-чыннан хатын кешегә әверелгәндәй итеп тойды* (Н. Фәттах).

Шул ук вакытта *-учы/-үче* формасы контекстта төп фигыльдән бәйле, мөнәсәбәтле заман мәгънәсен дә белдереп килә ала:

а) Төп фигыль белән бер үк вакытта булган процессны белдерә: *Түбән очка  к а й т ы п  б а р у ч ы  Гафият, Бер ярым Миңнулла, Гапсаттар һәм тагын берничә кеше язгы чәчу турында  с ө й л ә ш ә л ә р* (И. Гази). *Хәер, һәрберсе үзенчә терекөмеш булып  т ә г ә р ә ү ч е  авыл малайлары Сәфәргалинең ул сүзләренә  к о л а к  т а  с а л м а д ы л а р . Гөлшәһидә коридор буйлап  к и л ү ч е  кешене  т а н ы м а д ы  да* (Г. Әпсәләмов);

ә) төп фигыльдән алда булган процессны белдерә: *Менә шулай салкын көндә теге эш эзләп  ч ы г у ч ы  ярлылар үзләренең мәҗмәгыйль фокара булган урыннарына әллә кайчан  к и л е п  т у л г а н н а р* (М. Гафури). *Ә, энем Якуб, ул субранҗа дигәннәре кайчан җыелачак соң? – д и д е  әлеге су турында  с ү з  к у з г а т у ч ы  карт* (И. Гази). *Бу яңа йортларны дию патшасын  җ и ң е п  к а й т у ч ы  ике батыр  с а л д ы р а* (әкият). Төп фигыль белән бер үк вакытта булган процессны белдергән *-учы* формасын (а) *-а торган* формасы белән, (ә) төп фигыльгә кадәр булган процессны белдергәндә *-ган* формасы белән алыштырырга мөмкин: а) *кайтып баручы Гафият – кайтып бара торган Гафият, тәгәрәүче авыл малайлары – тәгәри торган авыл малайлары;* ә) *сүз кузгатучы карт – сүз кузгаткан карт, җиңеп кайтучы ике батыр – җиңеп кайткан ике батыр.*

***-учы/-үче* формасында эш башкаручы субъектның белдерелүе.** Төп юнәлештә (шулай ук кайтым, уртаклык, йөкләтү юнәлешләрендә) килгән *-учы* формалы сыйфат фигыльдә эш башкаручы субъект бары бер юл белән генә белдерелә ала, ягъни сыйфатланмыш тамырдагы процессның башкаручысын белдерә: *килүче кешеләр, кайтучы солдатлар...*

*Авылда кияүгә чыгуны өмет итеп  й ө р ү ч е  к ы з л а р  шактый күп иде* (Ф. Хөсни). *Мостафаны авылга  и л т ү ч е  к е ш е  алтмыш яшьлек бер бабай иде* (Ш. Камал). Димәк, эш башкаручы субъектның тартым кушымчасы ярдәмендә белдерелүе, яки синтаксик юл белән,

иялек яки баш килештәге исем (алмашлык) ярдәмендә белдерелүе *-учы* формасы өчен хас түгел. Шуңа күрә дә *-учы* формасы нигезендә сыйфат фигыльле әйләнмәләр һәм, бигрәк тә, хәбәре *-учы* формасы белән белдерелгән синтетик иярчен җөмләләр ясала алмый.

*Минем кайгыртучы кызым* сүзтезмәсе белән *минем яраткан кешем* әйләнмәсе арасында тышкы яктан охшашлык бар, ләкин *-учы* формасы кергән сүзтезмәне сыйфат фигыльле әйләнмә дип карап булмый, чөнки *минем* алмашлыгы биредә *кайгыртучы* сүзе белән турыдан-туры бәйләнешкә керми, ә ул *кызым* сүзенә карый, кызның кемнеке икәнен, ягъни иялек нисбәтен белдерә, ә икенче әйләнмәдә исә *минем* алмашлыгы *яраткан* сыйфат фигыле белдергән эшнең, хәлнең башкаручысына ишарәли, шул ук вазифаны бер үк вакытта *кешем* сүзе составындагы *-ем* тартым кушымчасы да үти.

Искәрмә. Димәк, төрки телләрдә сыйфат фигыль формалары нигезендә синтетик иярчен җөмләләр (бу очракта иярчен аергыч җөмләләр) ясалу мөмкинлеге гомумән төрки телләрдәге сыйфат фигыльләрнең (причастиеләрнең) үзенчәлекле грамматик табигатенә бәйле, ягъни бернинди өстәмә кушымчалар алмаган хәлдә, *-ган, -р, -ачак, -асы* формаларының тамырдагы процессның объектын, урынын, вакытын ачыклап килүләре, һәм шул ук процессның субъекты синтаксик юл белән белдерелүе нәтиҗәсендә үзенчәлекле иярчен җөмләләр барлыкка килә. Ә *-учы* формасы өчен, алда әйтелгәнчә, бу үзенчәлек хас түгел.

***-учы/-үче* формасының исемләшүе.** Аергыч функциясендә кулланылудан тыш, *-учы/-үче* формасы шактый еш исемләшеп килә, ягъни тамырдагы процессның башкаручысы, субъекты мәгънәсендә кулланыла. *Көрәшүчеләр кулына бишәр йомырка китереп тоттырдылар* (Г. Ахунов). *Һәм минә монда беренче буразна салучыларның да берсе ул булачак* (Н. Фәттах). *Гомумән авылда Маликны яратмаучылар аз түгел* (И. Гази). *Ялгышымны күрсәтүчеләргә озын гомер телим* (Р. Гаташ).

Татар телендә *-учы/-үче* кушымчалы сыйфат фигыль, еш кына, исемләшкән хәлдә фигыль билгеләрен югалтып, исемгә күчә [Татарская грамматика, т. I]. Мәсәлән: *язучы, укучы, төзүче, сайлаучы* һ.б. Әйтергә кирәк, *-учы* формасының башкаручы затны белдерүче исем буларак кулланылу мөмкинлеге шактый киң. Әйтик *бораулаучы, көтүче, укытучы* кебек гадәти исемнәрдән тыш, сүзлекләрдә, мәсәлән, *икмәк әзерләүче* (хлебозаготовитель), *сал агызучы* (сплавщик) кебек

сүзләр дә шактый күп теркәлгән. Бу сыйфат фигыль шулай ук күп кенә фәнни терминнар ясауда да катнаша: *уртак ваклаучы, санаучы, бүлүче, бәйләүче* чара һ.б.

***-а торган* формасы.** Хәзерге заман сыйфат фигыльнең аналитик формасы -а/*-ә (-ый/-и)* кушымчалы фигыль, һәм *торган* ярдәмче сүзе белән ясала: *Ул борынгычарак уйлый торган картларның ашына кара таракан булып төшкәнлеген үзе дә сизеп йөри иде* (Ф. Хөсни). *Маликка бара торган сукмакны онытмагансың ич әле? – диделәр аңа* (И. Гази). *Җирне күтәрәсең, тургай үзең сайрый торган нокта нибары* (Р. Әхмәтҗанов).

Искәрмә. *-а торган* аффикслы сыйфат фигыль төрки телләр өчен дә хас. Күпчелек төрки телләрдә бу аналитик форма төрле дәрәҗәдә кыскартылуга дучар булган: *-диган* – үзбәк телендә, *-атын* – казакъ телендә, *-атан, -итан* – алтай телендә, *-аткын, -атын, -атаган, -атыгын* – себер татарлары телендә һ.б. Ә татар телендә исә, ул үзенең беренчел хәлендә, аналитик форма буларак кулланыла.

*-а торган* формасы татар телендә күбрәк атрибутив позициядә (аергыч функциясендә) кулланыла һәм тамырдагы процессның субъектын (а), объектын (ә), урынын (б), вакытын (в) белдергән, корал мәгънәсендәге сүзне (г) ачыклап килә:

а) *Майор Ильин музыкага бик исе китми торган, башаягы белән сугыш эшенә чумган бер кеше иде* (И. Гази). *Бара торган кешеләрнең берсе борылып нәрсәдер кычкырды һәм кулын болгады* («Совет әдәбияты»);

ә) *Светлана үрелеп кенә өстәл өстеннән укый торган китабын алды* (Л. Ихсанова). *Бу төргәктә аның яшь вакыттан ук язып килә торган көндәлекләре иде* (Л. Ихсанова);

б) *Фукс бакчасына бара торган сукмак Гөлшәһидәгә нидер хәтерләтә иде* (Г. Әпсәләмов). *Мәрьям тора торган йортның бер башында түбәсе җимерелеп беткән ташландык бер куыш бар иде* (Н. Фәттах);

в) *Куркып тора торган чак түгел* (И. Гази);

г) *Ипи кисә торган пычак.*

*-а торган* формасының исемләшүе сирәк, ә исем фигыль функциясендә ул бөтенләй диярлек кулланылмый. Исемләшү очрагына мисаллар: *Ул алай түбәнгә карап, авызына су кабып тора*

*т о р г а н н а р д а н түгел* (Ф. Хөсни). *КамАЗ-колос! Ә үзләре кемнәр, Бу гигантны т ө з и т о р г а н н а р !?* (Х. Туфан).

***-а/-ә торган* формасында заман мәгънәсенең белдерелүе.** Күпчелек очракта *-а/-ә торган* формасы татар әдәби телендә заманга мөнәсәбәтсез, предметка гомумән хас булган билгене белдерә: *Галиулла шахтерлар к и я т о р г а н җеп чабаталарны чишенеп ташлады да сәке өстенә сузылып ятты* (И. Гази). *Әнә, җәйләрен бөтенләй к и - б е п б е т ә т о р г а н тегермәне түкелдәп утыра* (Г. Бәширов).

Чагыштырмача сирәк очракларда *-а торган* формасы хәзерге заман мәгънәсен белдерә, ягъни предметны сөйләү моментында эшләнүче эш, хәл, хәрәкәт буенча характерлый: *Б а р а т о р г а н кешеләрнең берсе безгә борылып нәрсәдер әйтте... Сәфәргали б а р а т о р г а н җиреннән тукталып, бераз хәл җыеп торды* (Ф. Хөсни). Киләчәк заман төсмере белән кулланылуы тагын да сирәгрәк: *суя торган мал* (суеласы мал), *ура торган ашлык* (урыласы ашлык), *тия торган хезмәт хакы* (тиячәк хезмәт хакы). Бу форма киләчәк заман мәгънәсендә кулланылганда, анда тиешлек модаль мәгънә төсмере дә сиземләнә.

***-а торган* формасында эш башкаручы субъектның белдерелүе.** *-а/-ә* торган формасы белдерелгән процессның субъекты сыйфатланмыш ярдәмендә бирелә: *Бик ачык, сүзгә җитез, егәрле, колхозчылар белән үз булып с ө й л ә ш ә т о р г а н к е ш е* (Н. Исәнбәт).

Шул ук форма тамырдагы процессның объектын, урынын, вакытын ачыклап килгәндә, эш башкаручы субъект:

а) сыйфатланмыш составындагы тартым кушымчасы ярдәмендә белдерелә: *Сәфәргали б а р а т о р г а н җ и р е н н ә н тукталып бераз хәл җыеп торды* (Ф. Хөсни). *Кызым, кешелеккә к и я т о р г а н к ү л м ә к л ә р е ң н е дә тапландыргансың...* (М. Әмир);

ә) субъект аналитик рәвештә, баш килештә алмашлык яки исем белән белдерелергә мөмкин: *Мин т о р а т о р г а н ш ә һ ә р н е ң уртасында базар булып...* (М. Гафури). *Мәрьям т о р а т о р г а н й о р т - н ы ң башында... ташландык бер куыш бар иде* (Н. Фәттах). Димәк, *-учы* формасыннан аермалы буларак*, -а торган* кушымчалы сыйфат фигыль нигезендә синтетик иярчен аергыч җөмләләр дә ясала ала;

б) еш кына *-а торган* формасы предметны субъекттан аерылган процесс буенча характерлый: *Ял йортына б а р а т о р г а н с у к м а к...*

*Куркып тора торган чак түгел!* (И. Гази). *Бүген өстәл савыт-сабадан бушатылган, өстенә көн кисә торган калын такта куелган* (Ә. Фәйзи).

**Хәл фигыль**

Хәл фигыль инде күптәннән тел белгечләренең игътибарын үзенә җәлеп итеп килә. Ул барлык дәреслекләрдә, кулланмаларда, фәнни грамматикаларда һәм татар фигыле морфологиясенә кагылышлы барча хезмәтләрдә урын алган. Күренекле тюрколог Ә. Юлдашевның «Соотношение деепричастных и личных форм глагола в тюркских языках» (М., 1977) исемле монографиясендә, башка төрки телләрдәге хәл фигыльләр белән беррәттән, татар хәл фигыле дә махсус фәнни тикшеренү объекты итеп алынган.

Хәл фигыль ул – фигыльнең эш-хәлне башка бер эш-хәлгә мөнәсәбәттә белдерүче махсус формасы: *калдырып кайту* (*калдырып* хәл фигыле *кайту* фигыле белән бирелгән эштән алдан башкарылган эшне белдерә), *көлә-көлә сөйләү* (*көлә-көлә* хәл фигыле сөйләү фигыле белән бирелгән эшнең бер үк вакытта башкарылуын белдерә), *кайткач белү* (*кайткач* хәл фигыле *белү* фигыле белән бирелгән эштән алда башкарылган эшне белдерә), *киткәнче әйтү* (*киткәнче* хәл фигыле *әйтү* фигыле белдергән эшкә кадәр булган эшнең вакыт ягыннан чиген белдерә). Мәсәлән: *Кайсы юллар, Нинди упкын Тарта безне, җан сорап?!* (Дәрдемәнд). *Карлар ера-ера, Күптәнгегә йөрәк юл сала...* (Х. Туфан). *Колхозчылар килеп кергәч кенә, исемә төште ялгыз түгелем* (Һ. Такташ). *Юлга чыкканчы – юлдаш сораш; өй салганчы – күршең сораш* (мәкаль).

Тел белемендә шактый киң таралган фикердән аермалы буларак, хәл фигыль затланышлы фигыль формалары белән генә түгел, барлык затланышсыз формалар белән дә, шул исәптән башка хәл фигыльләр белән дә мөнәсәбәттә торырга мөмкин. Мәсәлән: *Өрә белми өргән эт авылга бүре китерер* (мәкаль) – хәл фигыль сыйфат фигыль белән мөнәсәбәттә тора. *Читен дә соң артык һичбер вакыт күрешмәсне белеп аерылу...* (М. Җәлил) – хәл фигыль исем фигыль белән мөнәсәбәттә тора. *Туры ат, сүзне аңлап, башын кага-кага, тырышыбрак юыртырга тотына* (Ә. Еники) – хәл фигыль инфинитив белән мөнәсәбәттә тора. *Төн үтеп, күңелле Көн тугач, азактан*

*Берсе дә булмаган шикелле тоела* (М. Җәлил) – хәл фигыль башка хәл фигыль белән мөнәсәбәттә тора.

Хәл фигыль, фигыльнең башка формалары кебек үк, башкаручыга каратылган эш-хәлне белдерә. Ләкин аның составында эш башкаручыга ишарә итүче махсус морфологик күрсәткечләр булмый: *(мин, син, ул, без, сез, алар) кайткач, (мин, син, ул, без, сез, алар) кайтып, (мин син, ул, без, сез, алар) кайтканчы* һ.б.ш. Шуның белән бергә татар хәл фигыле үзе мөнәсәбәткә кергән фигыльнең эш башкаручысына карарга да, бүтән бер башкаручының эш-хәлен белдерергә дә мөмкин: *(мин) кайткач (мин) күрдем – (син) кайткач (мин) күрдем.* Мәсәлән: *Әйе, бабасы мәрхүм дә кайчандыр бу юллардан менә шулай чапкан печән өстенә утырып, авыз эченнән генә җырлый-җырлый, юырттырып узгандыр* (Ә. Еники). *Көннәр бер-бер артлы уза торды. Көзләр үтеп, кышка керделәр* (Р. Мөхөммәдиев). *Җәй җиткәч, Китә Зәйнең сулары...* (халык җыры).

Морфологик планда хәл фигыльгә фигыльнең универсаль категорияләре – барлык-юклык *(кайткач – кайтмагач, кайтып – кайтмыйча),* юнәлеш *(күреп, күренеп, күрелеп, күрешеп, күрсәтеп),* процессның үтәлү характерын белдерү (*кайткалагач, кайтып торгач, кайтып беткәч* һ.б.ш.) хас. Мәсәлән: *Чәчәк юлларыннан тауга менеп, мин сокланып карыйм илемә* (Ш. Маннур). *Хәрәкәт басылгач, зур бер тантана алдыннан гына була торганча, нәрсәнедер, шауламыйча, кабаланмыйча, сабыр гына көтү сизелә* (Ә. Еники). Бу җөмләләрдә *менеп, сокланып, басылгач* хәл фигыльләре – барлыкта, *шауламыйча, кабаланмыйча* – юклыкта бирелгән. *Урман тарафыннан сузып-сузып бүре улаганы ишетелеп куя* (Р. Мөхәммәдиев). *Шәфкать туташы, куркынып, тизрәк аның кулын алды, пульсын капшады* (Ә. Еники). *Менә алар, җитәкләшеп, ашыга-ашыга, Идел тавына menәләр* (Ә. Еники). *Ниһаять, кич тә булды. Тузан, сөт исе аңкытып, көтү кайтты* (Ә. Еники). Бу җөмләләрдәге *сузып-сузып, ашыга-ашыга* хәл фигыльләре – төп юнәлештә, *куркынып* – кайтым юнәлешендә, *ишетелеп* – төшем юнәлешендә, *җитәкләшеп* – уртаклык юнәлешендә, *аңкытып* йөкләтү юнәлешендә килгәннәр.

*Күк итәгендә ут кабынып, дала өсте яктыра башлагач, бер чокырга яшеренделәр* (И. Гази). *...Бу егетнең аңлатуы барак ягында уен-көлке, гармун-җыр тавышлары ишетелә башлаганчы*

*дәвам итә* (Г. Ахунов). *Нигъмәтулла абзыкай... башта ике куллап, иелә биреп, бабасы һәм әбисе белән көреште...* (Ә. Еники). *Сораша торгач, белдем: торбаны ишек алдыннан уздырсалар, тиз дә, якын да буласы, арзанга да төшәсе икән* (Г. Бәширов). Әлеге җөмләләрдәге *актырта башлагач, ишетелә башлаганчы, иелә биреп, сораша торгач* хәл фигыльләре процессның үтәлү характерын – башлануын, өлешчә башкарылуын, дәвамлылыгын белдерәләр.

Хәл фигыльләрнең төп функциясе башка эш-хәлгә бәйләнешле процессны белдергәндә, ә төп эш, гадәттә, хикәя һәм сыйфат фигыльләрнең заман формалары белән бирелгәндә, хәл фигыльгә заман категориясе хас түгел. Сөйләү моментына мөнәсәбәтенә килгәндә исә, ул, кагыйдә буларак, үзе бәйләнешкә кергән фигыльнең заманына туры килгән эш-хәлне белдерә: *елмаеп сөйли* (ике процесс та сөйләү моментында башкарылалар), *елмаеп сөйләде* (ике процесс та сөйләү моментыннан алда башкарылганнар), *елмаеп сөйләр* (ике процесс та сөйләү моментыннан соң башкарылачаклар). Мәсәлән: *Күккә таба үрелеп, бер-берсенә нык сыенып, яр өстендә баһадир агачлар утыра* (Н. Фәттах). *Ул бер кулына сары портфелен, икенче кулына йөнтәс зур бүреген тотып, кием элгеченә карап, уңайсызланып басып тора иде* (Г. Ахунов). *Мәдәният мәйданында урын алыйк, – Егыла-тора, алга таба имди* (Г. Тукай). Бу җөмләләрдәге *үрелеп, сыенып (утыра)* хәл фигыльләре хәзерге заманга караган процессларны, *тотып, карап, уңайсызланып (басып тора иде)* үткән заманга караганнарын, *егыла-тора (атлыйк)* киләчәккә караган эш-хәлне белдерәләр.

Синтаксик планда хәл фигыльләр тиңдәш иярүле хәбәр һәм хәлләр (вакыт, рәвеш, күләм, сәбәп, максат, шарт, кире хәлләр), шулай ук тезмә кушма җөмлә составындагы җөмләләрнең беренчесенең һәм синтетик иярченле кушма җөмләләрдәге иярчен хәл җөмләләрнең хәбәре функцияләрен үтиләр. Мәсәлән: *Зур казанны асып, ут ягып җибәрделәр* (Ш. Камал). *Тагын ун минуттан без инде Днепрга төшеп, көймәләргә төялгән идек* (Г. Бәширов) – гади җөмләләрдәге тиңдәш иярүле хәбәрләр. *Ялт! итте яз кылычы, кыеп күкне, Бушанды күк – ягъмурны коеп түкте* (Дәрдемәнд). *Урамга чыккач, күкрәк тутырып, иркенләп бер сулыш алды* (Г. Ахунов) – хәлләр. *Яз үтеп, көннәр бетеп, булды тәмам гомерем кышы...* (Дәрдемәнд).

*Ирнең сүзе у л г ә н ч е , үзе үлсен* (мәкаль). *Әтисе шәһәргә к ү ч к ә ч , Хөсәения мәдрәсәсенең башлангыч классларына керә* (Г. Кашшаф) – кушма җөмләләрдәге беренче җөмләнең хәбәре.

Хәл фигыль фигыльнең исемне башкаруын үзендә саклый: *т ә р ә з ә н е ачу – т ә р ә з ә н е ачкач, т ә р ә з ә н е ачып, т ә р ә з ә н е ачканчы; э ш к ә бару – э ш к ә баргач, э ш к ә барып, э ш к ә барганчы* һ.б.ш.

Татар телендә хәл фигыльнең биш формасы бар. Алар түбәндәге кушымчалар ярдәмендә ясалалар:

1) *-ып/-еп, -п: барып, көлеп, сайлап, сөйләп*;

2) *-а/-ә, -ый/-и: бара (бара-бара), көлә (көлә-көлә), сайлый (сайлый-сайлый), сөйли (сөйли-сөйли)*;

3) *-гач/-гәч, -кач/-кәч: баргач, көлгәч, сайлагач, сөйләгәч*;

4) *-ганчы/-гәнче, -канчы/-кәнче: барганчы, көлгәнче, сайлаганчы, сөйләгәнче;*

5) *-ышлый/-ешли: барышлый, кайтышлый, үтешли, китешли* (нигездә, физик хәрәкәтне белдергән фигыльләрдән генә ясала).

***-ып/-еп* кушымчалы форма.** Бу кушымчаның *-п* варианты сузык авазга тәмамланган нигезләрдән соң килә: *сана-п, кара-п, бәйлә-п, көйлә-п; -ып/-еп* варианты – тартык авазга тәмамланганнарыннан соң: *ал-ып, сыз-ып, кер-еп, сең-еп.* Хәл фигыльнең бу формасы барлык фигыльләрнең нигезенә ялгана ала.

Бу форма, башкаларыннан аермалы буларак, шактый күп мәгънәле. Аның төп мәгънәсе – ул үзе мөнәсәбәттә торган башка бер фигыльнең синтаксик аналогы функциясен үти, үзеннән соң килгән төп фигыль белдергән процесстан алда яки аның белән бер үк вакытта башкарылган эш-хәлне белдерә. Мәсәлән: *Урал-таудан агып төшкән гөрләвекләр буенда, кәгазь көймә а г ы з ы п , малайлар й ө г е р е ш ә* (Р. Мөхәммәдиев). *Төннәр буе нәрсә к ү ч е р е п у т ы р а с ы ң син? Кая, башкаларын да күрсәт әле...* (Р. Мөхәммәдиев). Төп фигыль белән бер үк вакытта башкарылган эшне белдерәләр: *агызып йөгерешә, күчереп утыра. Йомры гына ат кырын-кырын гына борылды да, юлга т ө ш е п , вак адымнар белән ю ы р т ы п к и т т е* (Ә. Еники). *Биле сыгылыбрак торган тарантаска яңа чапкан печән т у т ы р ы п , өстенә чуар палас б ө к л ә п с а л г а н н а р* (Ә. Еники). Хәл фигыльләр төп фигыльдән алда башкарылган процессларны белдерәләр:

*төшеп юыртып китте, тутырып бөкләп салганнар.* Бу мәгънәнең аерым очрагы буларак, *-ып/-еп, -п* кушымчалы форма гади җөмләнең тиңдәш иярүле хәбәре, шулай ук тезмә кушма җөмлә составындагы беренче гади җөмләнең һәм күп иярченле катлаулы кушма җөмләләрдә тиңдәш иярчен җөмләләрдән беренчесенең хәбәре функциясен үти. Мәсәлән: *Йосыф, тагын бер урамны у т е п , вокзалга таба борылды* (К. Нәҗми). *Һәр ел саен к а й т ы п и с н ә п киләм Авылыбызның чиста һавасын* (С. Хәким) – гади җөмләләрнең тиңдәш иярүле хәбәрләре. *Миңа әти булганы Мөхәммәтвәли исемле б у л ы п , әни булганы Газизә исемле иде* (Г. Тукай). *Авыл е р а к л а ш ы п , машина асфальт юлга килеп чыккач, Атнабай авыр итеп бер к ө р с е н д е* (Г. Ахунов) – кушма җөмләләрдәге беренче җөмләнең хәбәре.

*-ып/-еп* кушымчалы хәл фигыльнең өстәмә мәгънәләре түбәндәгеләр:

1. **Эшнең үтәлү рәвеше мәгънәсе.** Ул, еш кына, аваз ияртемнәреннән ясалган фигыльләрдә, хис-тойгы белдергән, эмоциональ-экспрессив төсмерле фигыльләрдә күзәтелә: *гөрләп агу, пышылдап сөйләшү, елмаеп каршы алу.* Мәсәлән: *Рус белән тормыш кичердек с а й р а ш ы п , Тел, лөгать, гадәт вә әхлак а л м а ш ы п ...* (Г. Тукай). *Килер-килмәс борын г ө р л ә п матур яз, Ничөн бөктең, умырзая, билеңне* (Дәрдемәнд). *Җ ы р л а п үттем данлы көрәш юлын, Җ ы р л а п килдем тормыш языма* (М. Җәлил). *К ы з д ы р ы п кояш чыкмыйча, Уйсу җирдә су кипми. К ө л е м с е р ә п карауларың Күз алларымнан китми* (халык җыры).

Эшнең үтәлү рәвеше мәгънәсе гадәттә процессларның бер үк вакытта башкарылуы мәгънәсенә өстәлә. Ләкин кайбер очракларда ул хәл фигыль белдергән эш-хәлнең төп фигыль белдергәненнән алда башкарылуы мәгънәсен бирә: *Басуларда э ш л ә п ү с ә Кызларның уңганнары. С а г ы н д ы р ы п и с к ә т ө ш ә Татарстан таңнары* (Г. Афзал). *Кышны к у ы п илемнән, К о ш к и т е р ә язларны. Син – Иделем акчарлагы, И Казаным!* (Р. Вәлиев).

Процессның үтәлү рәвешен белдергән хәл фигыльләр кайвакыт, сыйфатлар һәм рәвешләр кебек, чагыштыру дәрәҗәсе алалар. Мәсәлән: *Бабай, тагы да т ө п ч е н е б р ә к сораша башлады: «Соң син үзең, канатым, кем кызы буласың?»* (Ә. Еники). *Биле с ы г ы л ы б р а к торган тарантаска яңа чапкан печән тутырып, өстенә чуар*

*палас бөкләп салганнар* (Ә. Еники). *Тургайлар, чынлап та аңа кушылгандай, тын, якты кырлар өстендә тагы да т а л п ы н ы б р а к , и с е р е б р ә к сайрарга тотыналар иде кебек* (Ә. Еники). Бу төр хәл фигыльләрдә, гадәттә, эш-хәлнең төрле вакытка караган бер үк билгесе үзара чагыштырыла: *төпченеп – төпченебрәк, сыгылып – сыгылыбрак, талпынып – талпыныбрак, исереп – исеребрәк.*

Хәл фигыльнең бер үк формасын кабатлау аңа эш-хәлнең интенсивлыгы, дәвамлылыгы, кабатлануы мәгънә төсмере өсти: *Менә аның улы, к и з ә н е п - к и з ә н е п , багана юна* (Г. Ахунов). Шушы мәгънәне белдереп, синоним хәл фигыльләрнең кабатланып килүе дә мөмкин: *Миңа юл буе йөк машинасында б ә р е л е п - с у г ы л ы п барырга туры килде* (И. Гази). *Аның шулай һәрвакыт у й н а п - к ө л е п сөйләшүенә Гөлчирә кайчакта кызыга, кайчакта ачулана иде* (Г. Әпсәләмов).

2. **Эш-хәлнең сәбәбе мәгънәсе.** Бу мәгънә контекст фонында һәм нәтиҗәсе булырдай эш-хәлне белдергән хәл фигыль формаларын кулланганда тагын да көчәя төшә*: ишетеп, сизеп, күреп, онытып, авырып, чирләп* һ.б.ш.

*Э ш л ә п үлмәссең, ч и р л ә п үләрсең* (мәкаль). *Ачылды, кар э р е п , таулар, тугайлар* (Дәрдемәнд).

3. **Эш-хәлнец максаты мәгънәсе.** Бу мәгънә дә контекст фонында һәм максаты булырдай эш-хәлне белдергән хәл фигыль формаларын куллану нәтиҗәсендә була: *сорап, эзләп, теләп* һ.б.ш. Мәсәлән: *Давылга әгәр юлыксам Болытлы төндә, эндәшим фонарь с о р а п мин Кемгә соң? Кемгә?* (Х. Туфан). *Камил Мөстәкыймов... иптәшләрен э з л ә п , күрше вагонга киткән иде* (Г. Ахунов).

4. **Кире шарт мәгънәсе.** Бу мәгънә хәл фигыль янында *та/тә* кисәкчәсе ярдәмендә белдерелә: *Урманнан у т е п т ә , утын күрмәгән* (мәкаль). *Я ш ә п т ә моңа кадәр, Белмичә йөргән икәнмен Кадереңне Маһибәдәр* (С. Хәким).

*-ып/-еп* кушымчалы хәл фигыльнең юклык формасы тарихи планда *-а/-ә, -ый/-и* кушымчалы хәл фигыльнең юклык формасына кайтып кала: *бармый, бармыйча; килми, килмичә.* Ул түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1.**Эшнең үтәлү рәвеше:** *Син киләсе юлдан күзем а л м ы й , Сине көтәм, иркәм, кич-иртән* (С. Хәким). *Язмыш көлде, үлем к а г ы л м ы й ч а үтте яннан минем тирәләп* (М. Җәлил).

2. **Эшнең шарты:** *Җил и с м и яфрак селкенми* (мәкаль). *Апрель җ и т м и агып китми Агыйделнең сулары* (халык җыры).

3. **Эшнең сәбәбе:** *Ул, н и э ш л ә р г ә б е л м и ч ә , ары-бире йөри башлады. Бала, авыртуына т ү з ә а л м ы й ч а , кычкырып җибәрде.*

***-а/-ә, -ый/-и* кушымчалы хәл фигыль.** Хәл фигыльнең бу формасы тартыкка тәмамланган нигезгә *-а/-ә* кушымчасы ялганып ясала: *ал-а, бар-а, бәр-ә, тиб-ә.* Сузыкка тәмамланган нигезләргә *-ый/-и* кушымчасы ялгана. Бер үк вакытта нигезнең соңгы сузык авазы тарая: *кара+й → карый, сана+й → саный, бәйлә+й → бәйли, сөйлә+й → сөйли* һ.б.ш. Хәл фигыльнең бу формасы үз функциясендә кулланылганда, хәзерге татар әдәби телендә, гадәттә, кабатланып килә. Бу аңа эш-хәлнең кабатлануы, дәвамлылыгы, тәмамланмаганлыгы төсмерләрен өсти. Хәл фигыльнең *-а/-ә, -ый/-и* кушымчалы формалары барлык фигыльләрдән дә ясалмый. Алар процессның төп фигыль белдергән эш-хәл белән бер үк вакытта яки аннан алда башкарылуы мәгънәсе фонында эшнең үтәлү рәвеше һәм сәбәбе мәгънәләрен белдереп киләләр. Мәсәлән: *Үткәннәргә кайта күңел, Т у к т ы й - т у к т ы й таныш чатларга* (Х. Туфан). *Карда ш у а - ш у а Алсу килә, җиң эченә тыккан кулларын* (Һ. Такташ). *У к ы й - у к ы й баш авыртып бетте. Е л ы й - е л ы й күзләре шешенгән.*

Кайбер *-а/-ә* кушымчалы хәл фигыльләр, санаулы фигыльләрдән генә ясалып, төп эшкә мөнәсәбәтле эшнең үтәлү вакытын яки аның максатын белдереп киләләр: *Кай тарафларга юл тотасың? Минем вакыт бар, о з а т а барыйм бераз* (Р. Мөхәммәдиев). *Туа мөгез чыкмый, т о р а мөгез чыга* (мәкаль). *Эт баласы т о р а азар* (мәкаль). *Алты яшәр юлдан кайтса, алтмыш яшәр к ү р е ш ә килер* (мәкаль).

*Җитә* хәл фигыленә һәм процессның үтәлү характерын *җитү* ярдәмче фигыле аша биргән хәл фигыльләргә *-рак/-рәк* кушымчасы ялганып, алар вакыт яки урын хәле мәгънәләре алырга мөмкиннәр: *Җәйгә җ и т ә р ә к , әзерлек эшләре башлана. Авылга к и л е п җ и т ә р ә к , юл икегә аерыла.*

*-а/-ә, -ый/-и* кушымчалы хәл фигыльләрнең юклык формалары хәзерге татар телендә күзәтелми.

***-гач/-гәч, -кач/-кач* кушымчалы форма.** Бу форма, хәл фигыльнең башка формаларыннан аермалы буларак, теләсә нинди фигыль нигезеннән ясала. Кушымчаның яңгырау варианты – сузыкка яки

яңгырау варианты тартыкка тәмамланган нигезләргә *(аша-гач, күрә-гәч, ал-гач, бир-гәч),* саңгырау варианты тартыкка тәмамланганнарына ялгана *(ат-кач, тап-кач, кит-кәч, кис-кәч).*

Бу форманың төп мәгънәсе – төп фигыль белдергән процесстан алда әле генә башкарылган эш-хәлне белдерү. Ә. Юлдашевның сүзләре белән әйткәндә, бу форма «төп эшнең башкарылу вакытын чикләүче шарты» вазифасын үти: *кайткач күрү, күргәч әйтү, әйткәч белү*. Мәсәлән: *Күк итәгендә ут кабынып, дала өсте я к т ы р а б а ш л а г а ч , бер чокырга яшеренделәр* (И. Гази). *Су алганчы, юлга бер карыйсың, чиләкләрең т у л г а ч , тагын бер* (С. Хәким*). Аңа к а - р а г а ч , сөенеп елмаймыйча мөмкин түгел иде* (Ә. Еники).

Төп эштән алдан башкарылу икенче эш-хәлнең башкарылуына вакыт ягыннан фон булып килә. *Та/тә, да/дә* көчәйткеч кисәкчәләре хәл фигыльнең бу формасына икенче эш-хәлнең турыдан-туры аннан соң башкарылу мәгънәсен өсти: *кайткач та әйтү, әйткәч тә эшләү, күргәч тә аңлау.*

*-гач/-гәч, -кач/-кәч* кушымчалы хәл фигыль сәбәп-нәтиҗә, шарт мөнәсәбәтләрен дә белдерергә мөмкин: *Газизә апа, чыгып, Габдулланы дәште, җавабы б у л м а г а ч , ул да аны эзли башлады* (Ә. Фәйзи). *Агачлар б у л м а г а ч , бу урында кар да тизрәк эрегән һәм, кар китәр-китмәс, беренче яз чәчәге – умырзая да баш күтәргән* (Г. Ибраһимов).

Бу форма башка эш-хәлнең башкарылуы өчен кирәкле шартны белдерә: *Нәрсә соң ул, иркем б у л м а г а ч , Бар булуым белән юклыгым?* (М. Җәлил ). *Э ш л ә г ә ч , намус белән эшләргә кирәк дип кырт кисә* (Г. Ахунов).

Хәл фигыльнең юклык формасы *-ма/-мә* кушымчасы ярдәмендә ясала: *уйлагач – уйламагач, эшләгәч – эшләмәгәч* һ.б.ш. *Каз канаты каурый-каурый, хатлар язарга ярый. У й н а м а г а ч т а к ө л м ә г ә ч , Бу дөнья нигә ярый* (халык җыры).

***-ганчы/-гәнче, -канчы/-кәнче* кушымчалы форма** фигыль нигезләренең күпчелегеннән ясала. Кушымчаның *-ганчы/-гәнче* варианты сузыкка һәм яңгырау тартыкларга тәмамланган нигезләргә *(укы-ганчы, кара-ганчы, яз-ганчы, бел-гәнче), -канчы/-кәнче* варианты саңгырау тартыкка тәмамланганнарына ялгана *(ат-канчы, кап-канчы, бет-кәнче, ак-канчы).*

Бу хәл фигыльләр берничә мәгънә белдерәләр.

1. Төп мәгънәсе – икенче бер фигыль белдергән эш-хәлнең вакыт яки пространство ягыннан чиген билгеләү. Мәсәлән: *Клара, к е р е п у т ы р г а н ч ы , иң элек стена буенда торган чемоданын алып, йөзен көзге тау җиленә куеп, күзләрен дым к а п л а г а н ч ы , чиксез киңлекләргә карап торды* (Ә. Еники). *Күзләрем т а л г а н ч ы күрсәм, Миңа бит шул да җитә* (Х. Туфан). *Кайда сез, безне ерактан таный алганнар, – Без офыкка к ү м е л г ә н ч е озатып калганнар?* (Х. Туфан).

2. Бу мәгънә еш кына эшнең күләм-чамасы мәгънәсе белән бергә килә: *Иңкәйгәнгә иңкәй – башың җиргә җ и т к ә н ч е , чайкалганга чайкал – башың күккә т и г ә н ч е* (мәкаль). *Оныклар ү с к ә н ч е яшә, ятка сер бирмә икән* (С. Хәким).

3. Күп кенә очракта хәл фигыльнең бу формасы берничә эш-хәл арасыннан, аларны үзара чагыштырып, берсен яхшырак дип табу өчен кулланыла: *Ахмак дустың б у л г а н ч ы – акыллы дошманың булсын* (мәкаль). *Ятып к а л г а н ч ы , атып кал* (мәкаль).

Бу хәл фигыльнең юклык формасын ясау теоретик планда мөмкин булса да, ул *-гач/-гәч, -кач/-кәч* кушымчалы хәл фигыльнең мәгънә үзенчәлегенә бәйле рәвештә телдә кулланылмый. Реаль эш-хәлне генә аннан алдан башкарылган эшнең вакыт ягыннан чиге итеп биреп була.

***-ышлы/-ешли* кушымчалы хәл фигыль.** Хәл фигыльнең бу формасын ясый торган *-ышлы/-ешли* кушымчасы тарихи планда берничә кушымчаның кушылмасын тәшкил итә: архаик исем фигыль кушымчасы *-ыш/-еш* + фигыль ясагыч *-ла/-лә* кушымчасы + хәл фигыльнең *-а/-ә, -ый/-и* кушымчасы. *-ышлы/-ешли* кушымчалы хәл фигыльләр физик хәрәкәтне, ягъни пространствода урын алыштыруны белдергән фигыльләрдән генә ясалалар. Алар башка бер эш-хәлгә фон булып, шул эш процессында башкарылган эш-хәлне белдерәләр: *кайтышлый керү, барышлый кереп чыгу, үтешли сорау* һ.б.ш. Мәсәлән: *Судан к а й т ы ш л ы й , Миңзифа апа урам уртасыннан төз сафларга тезелеп узучы кораллыларны күрде* (К. Нәҗми). *Өе янынннан ү т е ш л и «Әллә кереп, юынып, өсне алыштырып чыгыйммы икән?» – дигән уй чагылып китте* (М. Хәсәнов).

*-ышлы/-ешли* кушымчалы хәл фигыль мөнәсәбәттәш фигыль эше белән бер үк вакытта, юл уңаенда гына башкарылган эш-хәлне белдерә. Шул ук вакытта, ул, *-а/-ә, -ый/-и* формалы хәл фигыль кебек

үк һәм башка формалардан аермалы буларак, гадәттә, мөнәсәбәттәш фигыльнең эш башкаручысына караган эш-хәлне генә белдерә. *Мин делегат түгел. Бакудан Питерга үтеп барышлый, очраклы рәвештә генә килеп эләктем монда* (Р. Мөхәммәдиев). *Бер кичне шулай түбән очның Лотфи карт, узып барышлый, безнең янда туктап, бездә бераз утырып торды* (Ә. Еники).

Бу хәл фигыль башкаларыннан морфологик яктан да аерылып тора: аның юклык формалары кулланылмый, ул юнәлеш кушымчаларын да, эш-хәлнең үтәлү характерын белдергән күрсәткечләрне дә ала алмый.

## Исем фигыль

Исем фигыльләр наклонениегә һәм заманга бәйләнмәгән эш-хәрәкәтне (халәтне, процессны һ.б.) белдерәләр. Аларны кайбер төрки грамматикада фигыльнең исемләшкән формалары дип тә атыйлар.

Исем фигыльләр беренчел һәм икенчел формаларга аерылалар.

Беренчел исем фигыльләр «саф» фигыль нигезләренә *-у/-ү* кушымчалары ялгап ясала. Калын нигезләргә *-у* кушымчасы, нечкә нигезләргә *-ү* кушымчасы кушыла*: акла+у, кайт+у, сакла+у, тот+у. сөйлә+ү, кит+ү, кил+ү, бел+ү, укы+у.*

Икенчел исем фигыльләр «саф» фигыль нигезләреннән ясалмыйча, *-ган/-гән (-кан/-кән)* кушымчасына тәмамланган сыйфат фигыльләргә *-лык/-лек* кушымчасы ялгану юлы белән барлыкка киләләр: *барган+лык, килгән+лек, эшләгән+лек, уйнаган+лык.*

Телдә *-ыш/-еш, -ш* кушымчасы белән ясалган исем фигыльләр дә очрый. Сузык авазларга тәмамланган фигыль нигезләренә *-ш* кушымчасы ялгана, тартык авазларга тәмамланган калын фигыль нигезләренә *-ыш*, нечкә фигыль нигезләренә *-еш* кушымчасы кушыла. Исем фигыльнең бу формасы, нигездә, сөйләшү телендә генә кулланыла: *Кая барыш? Шәһәрдән кайтышым.*

Беренчел исем фигыльләр барлык фигыльләрдән ясалалар. Алар һәм фигыль, һәм исем билгесенә ияләр. Фигыль билгеләре:

1. Юклык кушымчасы алалар: *кил+мә+ү, сөйлә+мә+ү, тот+ма+у, ташла+ма+у.* Юклык кушымчасы фигыльнең нигезеннән соң ук килә, исем фигыль кушымчасы ялгана.

2. Юнәлеш категориясенең кушымчалары белән дә килә ала*: юу – ю+ыл+у, ю+ыш+у, ю+дырт+у, ю+ын+у.*

3. Кабатлауны белдергән кушымчалар да ялгана ала: *кил+гәлә+ү, бар+гала+у, ташла+штыр+у, эшлә+штер+ү.*

Әмма алар наклонение һәм заман билгеләренә ия түгелләр. Беренчел исем фигыльләр исемнең түбәндәге билгеләре белән характерланалар:

1. Килеш белән төрләнәләр: *кайту+ның, кайту+га, кайту+ны, кайту+дан, кайту+да.*

2. Санны белдерәләр: *кайту+лар+ыгыз, кайту+лар+ы.*

3. Тартым категориясе кушымчасын алалар: *кайту+ы, кайту+ың, кайту+ым.*

Мисаллардан күренгәнчә, беренчел исем фигыльләр исемнәрнең барлык билгеләрен (килеш, сан, тартым категорияләрен), фигыльләрнең өлешчә билгеләрен (юнәлеш, юклык категорияләрен, кабатлауны) үзләрендә берләштерәләр. Күренгәнчә, исем фигыльләр үзләренең грамматик билгеләре буенча күбрәк исемнәргә тартылалар, шуның өчен дә күпчелек очракта исем функциясендә киләләр яисә, еш кына, исемләшәләр дә: *Мин гомеремнең кая барганын, уйнауның, балачакның ни икәнен белми яшим* (Г. Ибраһимов). *Агачларның чак шаулауларыннан йөрәгемдә кузгалган шомлы курку эчендә йокыга китәм* (Г. Ибраһимов). *Бу шомлы сүзләрне пионерларның беренче ишетүләре түгел иде* (Г. Гобәй). Исем фигыльләр, исемнәр кебек үк, изафә конструкцияләрнең һәм беренче, һәм икенче компоненты булып килә алалар: *кайту хәбәре, үлчәү таягы, артистның уйнавы, атның атлавы.*

Телнең яшәеш һәм үсеш чорында исем фигыльләрнең шактый формалары бөтенләй исемләшкән, ягъни исемгә күчкән: *Бөек Ватан сугышы безнең җиңүебез белән тәмамланды. Баганага белдерү тагылган иде* (А. Шамов). *Иртәгә уку дәресе булачак. Афишалар яшел буяу белән буялган иде* (Ш. Камал).

Исем фигыль формалары бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр белән дә килә ала.

*Исем фигыль + белән* бәйлеге: *[көймә] Көчле бер дулкын селтәве белән кырыйга үрләшеп, шып туктады* (Ш. Камал). *Җирнең карбыз кебек түгәрәк икәнен әйтү белән сыйныфта җанлылык башланды* (Ә. Фәйзи).

Исем фигыль + *ө ч е н* бәйлеге: *Бишьеллыкны үтәү ө ч е н шахтерлар кирәк* (Һ. Такташ). *Моның шулай икәнен к ү р ү ө ч е н поэмадан берничә мисрагъ китерү җитә* (Г. Нигъмәти).

Исем фигыль + *с ә б ә п л е* бәйлеге: *Мине Москвага к ү ч е р ү л ә р е с ә б ә п л е вәгъдәмне тулысы белән үтәргә туры килмәде* (М. Гали). *Вакытында яңгыр б у л м а у с ә б ә п л е сабаннар да уңмады* (И. Гази).

Исем фигыль + *х а к ы н д а* бәйлек сүзе: *Сезнең эшелоннар к и л ү х а к ы н д а хәбәрдән башка бер информация дә алганыбыз юк* (Ш. Усманов).

Исем фигыль + *т у р ы н д а* бәйлек сүзе: *Хәлим тәрбиягә а т а л у т у р ы н д а әнисе белән киңәшләшү өчен өенә йөгерде* (Г. Гобәй). *Хәйдәр комиссиягә б а р ы р г а у й л а в ы т у р ы н д а әйтми уздырды* (Г. Бәширов).

Исем фигыль + *б у е н ч а* бәйлек сүзе: *Аның ә й т ү е б у е н ч а .*

Беренчел исем фигыльләрдә наклонение һәм заман категорияләре белдерелми. Икенчел фигыль формалары, әйткәнебезчә, сыйфат фигыльләрдән ясалып, үзләренең төп мәгънәләре буенча беренчел сыйфатларның мәгънәләреннән әллә ни аерылмыйлар. Шулай да беркадәр үзенчәлекләре бар. Алар беренчел исем фигыльләр кебек заманга бәйле булмаган эш-хәрәкәтне түгел, эш-хәрәкәтнең үткәнгә караганын белдерәләр: *[Аның] моны б е л г ә н л е г е н ә шаккатып... сүземне бетерәм* (Г. Тукай).

Икенчел исем фигыльләр *-ган/-гән (-кан/-кән)* кушымчасы белән ясалган барлык сыйфат фигыльләрдән хасыйл була. Фигыльләрнең формалары буларак, алар фигыльнең кайбер билгеләрен белдерәләр: юклыкны *(кил+мә+гән+лек, бар+ма+ган+лык;, тик тор+ма+ган+лык);* юнәлешне *(ю+ыл+ган+лык);* дәрәҗәне *(кил+гәлә+гән+лек).* Икенчел исем фигыльләр, беренчел исем фигыльләр кебек үк, исемнең барлык билгеләрен (килеш, сан, тартым категорияләрен) белдерәләр: *Ул моны эшләргә я р а м а г а н л ы г ы н аңлый иде* (З. Фәтхетдинов). *Безнең анда б а р г а н л ы г ы б ы з н ы беркем дә белмәде. Кулдан сатучыларның еш к и л г ә н л е к л ә р е безне йөдәтеп бетерде.* Икенчел исем фигыль формалары, беренчел исем фигыль формалары кебек үк, җөмләнең барлык кисәкләре булып килә ала. Әмма алар телдә сирәк кулланылалар: *Каләмнең көченнән к и л г ә н л е г е н ә шаккатып, сүзне бетерәм* (Г. Тукай).

## Инфинитив

Инфинитив – эш-хәрәкәтне субъектка бәйләмичә, аның заманын, затын, санын, наклонениесен белдерми торган фигыль формасы. Инфинитив фигыль билгесен, ягъни эш-хәрәкәтне бик гомуми формада гына чагылдыра. Ул – фигыльнең затланышсыз формасы булып санала.

Татар телендә инфинитивның төп формасын вариантлары белән *-рга* кушымчасы белдерә.

Тартык авазларга тәмамланган ике яки аннан да күбрәк иҗекле фигыль нигезләренә *-ырга/-ергә* кушымчасы ялгана: *укыт+ырга, тотын+ырга, чыгар+ырга, бетер+ергә.*

Сузык авазларга тәмамланган ике яки аннан да күбрәк иҗекле фигыль нигезләренә *-рга/-ргә* кушымчасы ялгана: *укы+рга, киме+ргә, тенте+ргә, ыргы+рга.*

Сонор *-р* авазына тәмамланган фигыль нигезләренә *-ырга/-ергә* кушымчасы ялгана: *бар+ырга, үр+ергә, кайтар+ырга, күр+ергә.*

Дүрт яки аннан да күбрәк авазлардан гыйбарәт һәм *т* авазына тәмамланган фигыль нигезләренә *-ырга/-ергә* форманты кушыла: *төрт+ергә, кайт+ырга, утырт+ырга.*

Калган очракларда тартык һәм сузык авазларга тәмамланган бер иҗекле фигыль нигезләренә *-арга/-әргә* кушымчасы ялгана: *ту+арга, ку+арга, иг+әргә, үб+әргә, тын+арга, эл+әргә, ат+арга.*

Бу соңгы кагыйдәдән кайбер чыгармалар да булырга мөмкин: *биз+ергә, кил+ергә, кит+ергә* (отломить), *кыл+ырга.*

*-ырга/-ергә* кушымчасы катлаулы кушымча булып санала: *-ыр* кисәге – сыйфат фигыль күрсәткече, *-га* кисәге юнәлеш килеш күрсәткече. Хәзерге көндә алар бер формант – инфинитив кушымчасы буларак кулланылалар. Фигыльнең бу формасы татар теленең беренче дәреслекләрендә үк очрый: *Һәркем сәне алырга лаек дәгел* («Кыйссаи Йосыф вә Зөләйха»),

Инфинитив фигыльнең түбәндәге морфологик билгеләре белән характерлана:

1. Юнәлеш категориясенә ия: *биз+әргә* (украшать), *бизә+н+ергә, бизә+л+ергә, бизә+ш+ергә, бизә+т+ергә.*

2. *-гала/-гәлә (-кала/-кәлә), -ышты/-ештер (-штыр/-штер)* кебек кабатлаулы кушымчалар алырга мөмкин: *сат+кала+рга, эшлә+штер+ергә, ал+гала+рга, бар+гала+рга.*

3. Бу формага сорау кисәкчәсе ялганырга мөмкин: *чакыр+ырга+мы?*

4. *-дыр/-дер (-тыр/-тер)* кебек билгесезлек кушымчасы белән дә килергә мөмкин: *әйтергә+дер бит?*

5. Юклык кушымчасы алырга мөмкин. Инфинитивта ул *-маска/-мәскә* кушымчасы ярдәмендә белдерелә: *төш+мә+скә, бар+ма+ска, кил+м+әскә.*

*-рга* формалы инфинитив бәйле һәм бәйсез функциядә кулланылырга мөмкин. Бәйле инфинитив бәйле сүздән алда кулланыла: *Белергә тели. Барырга кирәк.* Поэтик сөйләмдә бу сүзләрнең мондый тәртибе үзгәрергә мөмкин. Бәйсез инфинитив нигездә боерык функциясендә кулланыла: *Укыгач күчереп алырга!*

Инфинитив җөмләдә ия, хәбәр, тәмамлык, аергыч һәм максат хәле булып килергә мөмкин. Ия функциясендәге инфинитив: *Хәзер ашарга бетте* (ашамлык бетте мәгънәсендә).

Хәбәр функциясендәге инфинитив: *Вәгъдәне үтәргә!* Шулай ук инфинитивның бу формасы тезмә хәбәрнең компоненты буларак та кулланылырга мөмкин: *Почмакка басты да җырларга тотынды* (Ф. Әмирхан).

Аергыч функциясендәге инфинитив*: Әмма китәргә вакыт җиткәч, карчык үксеп-үксеп елады* (Ш. Камал).

Тәмамлык функциясендәге инфинитив: *Ирек бирмәбез дошманга, Ирек илне таларга* (М. Җәлил). *Калырга риза булды.*

Максат хәле функциясендәге инфинитив: *Утын әзерләргә киттеләр.* Инфинитивның бу функциясе аның төп функциясен тәшкил итә.

*-мак/-мәк* кушымчалы инфинитив татар теле өчен искергән форма булып тора. Бу форма борынгы вакыттан алып XX гасырның башына кадәр кулланылган: *Сорар ирсә, җавап вирмәк кәрәк имди* («Кыйссаи Йосыф вә Зөләйха»). Бу форма соңгырак булган әсәрләрдә дә очрый. XX гасыр башында инфинитивның бу формасы кулланылыштан төшеп кала башлый. Ул бары урын-вакыт форманты *-та/-тә* белән генә күренгәли: *Иртә белән кайнамакта бу базар, кайсысы сатмактадыр, кайсы ала* (Г. Тукай). Хәзерге көндә *-мак/-мәк* кушымчалы инфинитив архаик формага әйләнгән, бары мәкальләрдә, әйтемнәрдә һәм сөйләмдә генә очрый: *Май язмак – җан чыкмак* (мәкаль). *Ир бирмәк – җан бирмәк* (мәкаль). *Нишләмәк кирәк?* (сөйл.).

Татар телендә инфинитивның диалекталь формалары да бар: 1) *-мага/-мәгә* кушымчалы инфинитив *(бар+мага, кил+мәгә): Кызын а л м а г а калага китте;* 2) *-малы/-мәле* кушымчалы инфинитив *(укы+малы бар+малы, бел+мәле): Бүген сөт а л м а л ы иде;* 3) *-ма/-мә* кушымчалы инфинитив: *барма кели, китмә тели.*

Искәрмә. **«Фигыльләрдә дәрәҗә-ысул категориясе»** (М. Зәкиев), **«Дәрәҗә категориясе»** (Ф. Ганиев), **«Хәрәкәт фигыльләре ярдәмендә эшнең субъект-объектка караган юнәлешен (ориентациясен) белдерү», «Татар телендә эшнең субъект-объектка караган юнәлешен (ориентациясен) белдерү»** (Д. Тумашева). Фигыль үзенчәлекләренә караган бу бүлекчәләр үзләренең исемнәре һәм эчтәлекләре буенча бер-берсеннән аерылып торалар. Ләкин аларда кушма фигыльләрнең формаларын һәм семантикасын төрлечә өйрәнү бар.

Чыннан да, татар теленең кушма фигыльләрен өйрәнү юнәлешендә хәзерге көн лингвистикасында кабул ителгән уртак караш урнашмаган. Аларны төрле галим төрлечәрәк яктырта, нигездә, грамматик күренеш, дип саный.

XXI гасыр башында кушма фигыльләрне сүзьясалыш темасына кертеп өйрәнү тәкъдим ителде. Моны да инкяр итеп булмый.

### 4.3.6. Фигыльдә дәрәҗә-ысул категориясе

Татар фигыльләрендә процессның ничек һәм ни дәрәҗәдә үтәлүен белдерә торган гади һәм кушма формалар бар: *көлемсерә* фигыле ‘көлү’ процессының өлешчә генә үтәлешен белдерә; *килгәлә* фигыле ‘килү’ процессының кабатлана-кабатлана үтәләчәген белдерә; *егыла язды* фигылендә ‘егылу’ процессы башланыр алдыннан туктап кала; *бара бирә* фигылеңдә ‘бару’ процессы дәвамлы үтәлә, *белер-белмәс* фигылендә ‘белү’ процессы ахырга кадәр үтәлми, аның үтәлү дәрәҗәсе бик аз; *эшли-эшли (арыды)* фигылендә ‘эшләү’ процессы башлану һәм тәмамлану арасында озак дәвам итә, шул мәгънәне бирү өчен фигыль кабатлана.

Бу төр фигыльләрдә ике төрле грамматик мәгънә күзәтелә: 1) процессның ничек үтәлеше, ягъни үтәлеш ысулын, характерын белдерү һәм 2) процессның ни дәрәҗәдә үтәлешен, ягъни үтәлеш дәрәҗәсен белдерү. Шуннан чыгып бу категорияне **ысул** (способ) **категориясе** яисә **дәрәҗә категориясе** дип атау күзәтелә, икесен бергә кушып, процессның ничек һәм ни дәрәҗәдә үтәлешен белдерүче фигыль формалары, дип тә атыйлар. Бу категорияне, шунда ук ысулын һәм характерын да кертеп, дәрәҗә категориясе дип атау тәкъдим ителгән иде.

Г. Алпаров аның кушымчалар белән күрсәтелгәнен дәрәҗә дип атады, М. Зәкиев кушма юл белән бирелгәннәрен дә дәрәҗә категориясе дип атарга тәкъдим итте [Зәкиев М., 1959, б. 53]. Шуннан соң ул Л. Җәләй, Д. Тумашева, К. Зиннәтуллина һәм Ф. Сафиуллиналар тарафыннан морфология китапларына кертелде. В. Хангилдин аларны рус телендәге «вид» сүзен «төрчә» дип тәрҗемә итеп кулланды. Ф. Ганиев исә бу төр категория буенча кандидатлык диссертациясе язды, һәм ул андый фигыльләрне, А. Кононов хезмәтләрендәгечә, тасвирый рәвештә фигыльдә эшнең **үтәлү ысулын белдерү** дип атады. Русча язылган академик морфологиядә дә ул бу категорияне «способы действия глаголов» дип атады. Термин-атама тапмыйча гына бу күренешне тасвирый атаганда, аны, һичшиксез, ысул дип кенә түгел, дәрәҗә дип тә атау, ягъни, процессның ничек һәм ни дәрәҗәдә үтәлүен белдерү, дип йөртү уңышлырак санала. Тасвирый атаудан термин белән атауга күчсәк, бу күренешне, төгәлрәк булсын өчен, дәрәҗә-ысул дип атарга тиеш булабыз, чөнки бу категориядә процессның үтәлү дәрәҗәсе дә, үтәлү ысулы да бер-берсенә тыгыз бәйләнеп бирелә.

Дәрәҗәнең кушма юл белән бирелешен татар тел гыйлемендә В. Богородицкий, М. Корбангалиев, Р. Газизов, Г. Алпаров, башкортларда Ә. Юлдашев русчадагы «вид» категориясенә охшатканнар. Г. Алпаров бу категорияне, рус телендәге «вид» сүзеннән алып, **күренеш категориясе** дип атаган [Алпаров Г., 1945, б. 180]. Ләкин татар телендәге дәрәҗә категориясен рус телендәге «вид» категориясенә һич тә тәңгәлләштереп булмый. Татар телендә рус телендәге вид категориясе юк, русчада исә татарчадагы дәрәҗә категориясе юк.

Тагын шуны истә тотарга кирәк: дәрәҗә-ысул мәгънәсенең кушымчалар белән бирелеше – грамматик категория була, ягъни андый кушымчалар һәрбер фигыльгә ялгана алалар, ә процессның ничек һәм ни дәрәҗәдә үтәлүен белдерүче ярдәмче фигыльләрнең күбесе дәрәҗәне теләсә нинди фигыль янында белдерә алмыйлар. Билгеле бер семантикалы фигыль янында гына алар дәрәҗә-ысул белдерә алалар. Мәсәлән, *сөйләп китте* фигылендә, *китте* ярдәмче фигыле процесс башлану дәрәҗәсен белдерә, ә *язып китте* дигәндә *китте* фигыле үзенең лексик мәгънәсендә килә, дәрәҗә белдерми; *каушап төште* фигылендә *төште* ярдәмче фигыле процессның кинәт кенә үтәлеп тәмамлануын белдерә, ә *язу* фигыле белән ул дәрәҗә белдерә алмый:

*язып төште* дигәндә, *төште* ярдәмче фигыле язу процессының ничек һәм ни дәрәҗәдә үтәлүен белдерә алмый, анда 'язу' процессы һәм 'төшү' процессы икесе дә бар; *әйтеп салды* дигәндә, *салу* ярдәмче фигыле әйтү процессының кинәт кенә, бик тиз үтәлүен белдерә, *укып салды* дип, гомумән әйтеп булмый.

Кайбер ярдәмче фигыль, төп фигыльнең формасына карап, төрле мәгънә белдерергә мөмкин. Мәсәлән, *ал* ярдәмче фигыле, *-ып/-п* формалы кайбер хәл фигыль янында килеп, процессның тиз генә үтәлешен хәбәр итә *(карап алды),* ә *-а/-п* формалы хәл фигыль янында килсә, процесстагы мөмкинлек модаль мәгънәсен белдерә *(укый ала).*

Процессның ничек һәм ни дәрәҗәдә үтәлүен белдерүче кайбер ярдәмче фигыльләр барлык наклонение һәм заман формалары белән төрләнә алмыйлар. Мәсәлән, *(яшелчәләр) өлгереп килә* дигәндәге *килә* ярдәмче фигыле *килде, килгән, килсә* һ.б. формаларда кулланыла алмый, аны бары *өлгереп килә иде* дип кенә үзгәртеп була.

Нәкъ менә шундый үзенчәлекләре булганлыктан, дәрәҗә-ысул категориясенең кушма төрләрен грамматик категориягә кертмиләр, лексик-семантик категория дип йөртәләр, бер үк вакытта сүз ясалышы рәтендә дә карыйлар.

**Дәрәҗә-ысул мәгънәсенең кушымчалар белән белдерелүе.** Татар телендә эшнең к**абатлануын, кимлеген, өлешчә үтәлү төсмерләрен** белдерү өчен түбәндәге кушымчалар кулланыла:

*-гала/-гәлә/-кала/-кәлә* кушымчасы эшнең эзлекле яки даими кабатлануын белдерә: *баргала, килгәлә, әйткәлә, уйнаткала* һ.б. Бу кушымча тартык авазга тәмамланган фигыльләргә генә ялгана: *Шулай ук акча тота белмәве дә хатын өчен бик күп кайгылар т у д ы р г а л а д ы* (Г. Ибраһимов). *Бригадага колынлы бия килгәч, ул, бик нык шатланып, колын тирәсендә ә й л ә н г ә л ә р г ә тотынды* (Ф. Хөсни).

*-гала/гәлә* кушымчасы процессның кабатлануын гына түгел, бәлки тулы булмавын, урыны-урыны белән генә булуын да белдерә: *Тиресе к у п к а л а г а н күгелҗем иреннәрен... ялады* (К. Нәҗми). Хәтта ул яңа мәгънәле фигыль ясауда да катнашырга мөмкин: *Ул яшь кәләшне тынычландырырга тырышты. Нәгыймә аның саен ө з г ә л ә н ә иде* (Г. Ибраһимов);

*-штыр/-штер/-ыштыр/-ештер* кушымчасы эшнең сирәк, аратирә генә булуын белдерә: *кара-штыр, эшлә-штер, укы-штыр,*

*яз-ыштыр* һ.б. *Мохтар, аны караштырырга дип, кроватька суз-ылды* (Ш. Камал). Бу кушымча күбрәк сузык авазлардан соң ялгана; *-гала/-гәлә* кушымчасы белән бергә кулланылуы да очрый: *уйлаштыр-гала, сайлаштыргала, эшләштергәлә, очраштыргала* һ.б.;

*-ынкыра/-енкерә/-нкыра/-нкерә* кушымчасы эшнең кимлеген, тулы булмавын белдерә: *тартынкыра, җитенкерә, исәнкерә, ошанкыра.* Мәсәлән: *Яңа чакта бик матур иделәр, яратып кигән идем, бизәүле читеккә о ш а н к ы р ы й иделәр... – диде* (Ш. Камал);

*-ымсыра/-емсерә/-мсыра/-мсерә* кушымчасы да шулай ук эшнең кимлеген белдерә: *көлемсерә, йокымсыра, -ынкыра* һәм *-ымсыра* кушымчалары аз сандагы фигыльләрдә очрый.

И с к ә р м ә . Бу параграф Д. Тумашсваның «Хәзерге татар әдәби теле. Морфология» китабыннан алынды [Тумашева Д., 1978, б. 172–173].

**Дәрәҗә-ысул мәгънәсенең ярдәмче фигыльләр белән бирелүе.** Ярдәмче фигыльләрне русчадагы вид категориясе белән янәшә тикшерү чорында, аларның барысы да бергә алына, мәгънәләре аерылмый иде. Мәсәлән, Г. Алпаров, *эшли алдым, ала күрмәгез, алып булмый* кебек фигыльләрдә дә күренеш (вид) категориясе бар, дип саный [Алпаров Г., 1945, б. 181–182]. Күп кенә хезмәтләрдә эзлекле яки параллель процессларны белдерүче кушма фигыльләрне дә вид яки дәрәҗә белдерүчеләр рәтеннән карау күзәтелде. Ләкин 50 нче елларда ярдәмче фигыльләрнең системасы тулысынча ачыкланды: алар функцияләре буенча 1) сүз ясагычларга, 2) модаль мәгънә белдерүчеләргә, 3) заман белдерүчеләргә, 4) дәрәҗә-ысул белдерүчеләргә, 5) эзлекле яки параллель процессларны белдерүчеләргә аерылдылар [Зәкиев М., 1959, б. 45–67].

1. Ярдәмче фигыльләрнең сүз ясалышында катнашулары: *юк итү, бар булу, риза булу, тәкъдим кылу, ду килү, чара күрү, җавап бирү, үч алу, колак салу, уй йөртү, ирек бирү, күзен алмау, күз салу, гомер сөрү, йокыга китү, искә төшү, сүзгә керешү, хәлдән таю, кире кагу, котын алу* һ.б.

2. Ярдәмче фигыльләрнең модаль мәгънә белдерүе. Бу мәгънәләр шактый күп:

1) боеру, үтенү: *югалта күрмә, белә күр;*

2) теләк: *күрсеннәр иде;*

3) ниятләү: *тотарга итә, китәргә тора, ачуланмакчы була, торырга маташа;*

4) шарт: *килде исә, ачуланмас иде;*

5) үкенү: *барган булсам, утырган була (шунда);*

6) мөмкинлек: *сөйли ала, сөйли белә;*

7) гаҗәпләнү, шикләнү: *(ул да шулай каты) ачуланыр икән! килдеме икән?*

8) ихтималлык: *килә торгандыр*, *белә булыр;*

9) сынап карау: *әйтеп карады;*

10) хикәяләү: *йөрер булды, дәшмәс булды, чыга торган булды, китте барды булыр, әйтми булмады* һ.б.

3. Ярдәмче фигыльләрнең заман төсмерләрен белдерүе: *килә иде, яши булган, килгән иде, килгән булган, барачак иде, барачак булган, (ул элек шулай) укыр иде дә язып куяр иде.*

4. Ярдәмче фигыльләрнең эзлекле яки параллель процессларны белдерүдә катнашулары.

Эзлекле процесслар: *килеп китү, барып карау, торып китү, эзләп табу, торып чыгу, китеп югалу, яздырып алу, күтәрелеп карау* һ.б.

Параллель процесслар: *төшеп китү, менеп китү, эзләп йөрү, китеп бару, чабып төшеп килү, карап калу* һ.б.

5. Ярдәмче фигыльләрнең дәрәҗә-ысул мәгънәләрен белдерүләре шул ук югарыда күрсәтелгән ярдәмче фигыльләр дә булырга мөмкин. Инде әйтелгәнчә, абстракт-грамматик мәгънәнең төрен ярдәмче фигыль үзе генә билгели алмый, монда төп фигыльнең формасы да зур роль уйный.

Дәрәҗә-ысул категориясенең мәгънәләре шактый күп. Тәртипле итеп өйрәнү өчен, аларны төп өч төргә аеру уңайлы: 1) процессның башлану дәрәҗәсен һәм ысулын белдерү очраклары; 2) процессның ике чик (башлану һәм тәмамлану) арасында үтәлү дәрәҗәсен һәм ысулын белдерү очраклары; 3) процессның тәмамлану дәрәҗәсен һәм ысулын белдерү очраклары.

Процессның башлану дәрәҗәсен һәм ысулын кушма юл белән белдерү. Башлану дәрәҗәсе һәм ысулы төрле формадагы фигыльләр янында түбәндәге ярдәмче фигыльләр килү юлы белән белдерелә.

1. *Яз* ярдәмче фигыле, *-а/-и* формасын алган фигыль янында килеп, башланыр алдыннан туктап калган процессны белдерә: *Кеше алдында ярамаганны с ө й л и я з д ы . Ай-яй, җил көчле икән монда: йөгереп барганда кәләпүшне алып к а л а я з д ы* (И. Гази).

2. *Җибәр* ярдәмче фигыле*, -ып/-п* формасын алган фигыль белән килеп, процессның бик тиз башланып китүен белдерә: *Егет җырлап җибәрә. Алпавыт ялына бичара,– дип кычкырып к ө л е п җ и б ә р - д е* (Г. Тукай).

Күп кенә очракларда *җибәр* ярдәмче фигыле процессның бик тиз башланып, бик тиз тәмамлануын да белдерә: *Теге башта Марсельеза җырлаган тавыш бөтен бинаны я ң г ы р а т ы п җ и б ә р д е* (М. Гафури).

3. *Алып кит, алып биреп кит* конструкцияләре дә *-ып/-п* формасын алган фигыль белдергән процессның башлану дәрәҗәсен күрсәтәләр. Процесс бик тиз башланып китә, сөйләүче процессның ничек, ни дәрәҗәдә дәвам итүенә һәм тәмамлануына басым ясамый: *Әсма хәлен аңлатты, сәламәтлеген сагынды, авыруның ни икәнен дә белмәгән яшьлеге турында с ө й л ә п а л ы п к и т т е* (Ә. Фәйзи).

Мондый кушма хәбәрләр сөйләмдә бик күп кулланылалар һәм аңа аерым җанлылык бирәләр.

4. *Башла* фигыле, үзенең конкрет мәгънәсен югалтып ук бетермәсә дә, *-а/-и* формасындагы фигыль белән килеп, процессның гомумән башлануын гына хәбәр итә: *Бу турыга килеп җиткәч тагын да дәртләнебрәк у й н ы й б а ш л а д ы л а р* (М. Гафури). Т*ора-бара бу кыз туганнарын с а г ы н а , җ и р с и б а ш л ы й* (хал. иҗаты).

*Башла* фигыле башка формадагы фигыльләр белән бергә дә процессның башлануын белдерә ала: *Багдад падишаһсы... юлны к ү з - л ә м ә г ә б а ш л а д ы* (К. Насыйри).

5. *Тотын, кереш* фигыльләре дә, үзләренең төп конкрет мәгънәләрен югалтып, инфинитив белән бергә процессның башлануын белдерәләр: *Тыштагы ай яктысы тагын аның йөрәк моңнарын т и б р ә - т е р г ә т о т ы н д ы* (Г. Бәширов). *Шуның артыннан ук кызыл флаглар күтәреп эшче төркемнәре ү т ә р г ә к е р е ш т е л ә р* (М. Гафури).

Бу бүлекчәдә китерелгән фигыльләр белдерә торган процесс тәмамланган булырга да мөмкин. Ләкин сөйләүче аңа игътибар итми. Сөйләүче процессның ничек һәм ни дәрәҗәдә башлануына гына басым ясый.

**Процессның ике чик арасында барышын, дәвам итүен кушма юл белән белдерү.** Бу төр кушма фигыльләр ике чик (башлану һәм тәмамлану) арасында дәвам итү дәрәҗәсен төрлечә характерлыйлар: алар процессның яки бик тиз үтәлүен, яки эзлекле рәвештә үсә ба-

руын, яки кабатлана-кабатлана дәвам итүен, яки үзгәрешсез дәвам итүен, яки әкрен, салмак кына агышын белдерәләр. Андый кушма фигыльләр хәл фигыльләр янында түбәндәге ярдәмче сүзләр килү юлы белән ясалалар.

1. *Ят* ярдәмче фигыле хәзерге татар телендә *-ып/-п* формасын алган фигыль белән бергә генә кушма фигыль ясый, һәм ул процессның ике чик (башлану һәм тәмамлану) арасында салмак кына, үзгәрешсез дәвам итүен белдерә: *Урамда митинг ясалып ята иде* (М. Гафури). *Бер тарафта балдан һәм сөттән гыйбарәт кәүсәр елгасы агып ята* (Г. Тукай).

2. *Тор* ярдәмче фигыле, *-ып/-п* һәм *-а/-и* формасын алган фигыльләр янында килеп, процессның үзгәрешсез дәвам итүен белдерә: *Парашюты бер якта асылынып тора, үзе – икенче якта* (хал. иҗаты).

Контекстка һәм җөмләнең эчтәлегенә карап, *тор* ярдәмче фигыле процессның башка бер процесс үтәлгән чорда башкарылуын белдерә. Мәсәлән, *Әминә апа язганда, Мортаза бабай, ике кулына ике чыра тотып, яктыртып торды* (Г. Гобәй) җөмләсендә ‘яктыртып тору’ процессының ни дәрәҗәдә дәвам итүе ‘язу’ процессының күпме дәвам итүе белән билгеләнә. Мондый кушма фигыль процессның вакытлыча үтәлүен дә белдерә: *Мә, син менә бу карандаш белән яза тор, Гарифулла күрәген бирер тормас микән!* (И. Гази).

*Торган* ярдәмче фигыле *иде* ярдәмлек фигыле белән бергә, хәзерге заман хәл фигыль янында килеп, процессның кат-кат дәвам итүен белдерә: *Мин аларга бик еш бара торган идем. Ул миңа үзенең хатларын укый торган иде.*

3. *Кал* ярдәмче фигыле, *-а/-и* формасын алган фигыль янында килеп, җөмләнең тулы эчтәлегенә карап, процессның дәвам итүен белдерә: *Газизә ялгыз гына утыра калды* (Ш. Камал). *Без чыгып киттек, ул шунда йөри калды.*

4. *Утыр* ярдәмче фигыле *-ып/-п,* сирәгрәк, *-а/-и* формасын алган фигыль белдергән процессның дәвамлылыгын күрсәтә: *Газизә апа, яшенә буылып, чыга алмый утырды* (Ә. Фәйзи). *Син менә шул картиналарны карый утыр.*

Искәрмә. Татар тел белемендә *тор, ят, утыр* ярдәмче фигыльләрен хәзерге заманны белдерүче фигыльләр итеп караучылар да бар. Мәсәлән,

*Гали хәзер хат язып ята* җөмләсендә *ята* фигыленең, *язып* хәл фигыле белән бергә, хәзерге заманны (моментны) белдерә, диләр кайберәүләр. Мондый аңлату *ят* ярдәмче фигыле бирә торган абстракт-грамматик мәгънәне андагы хәзерге заман формасы *(ят-а)* бирә торган абстаркт-грамматик мәгънә белән буташтыруга китерә. Ныклабрак тикшереп караганда, хәзерге заман мәгънәсен *ят* ярдәмче фигыле түгел, бәлки андагы хәзерге заман кушымчасы *(-и)* биргәнлеге аңлашыла. Моның өчен *ят* ярдәмче фигылен башка төрле заман кушымчасы белән төрләндереп карау да җитә: *Гали хат язып ятты* яки ... *язып яткан.* Бу хәбәрләрнең икесендә дә, *ят* ярдәмче фигыле саклануга карамастан, хәзерге заман мәгънәсенең эзе дә калмаган, ләкин бу хәбәрләрнең барысында да бер абстракт-грамматик мәгънә – ‘язу’ процессының дәвамлылыгы аңлашыла. Димәк, *ят (тор, утыр)* ярдәмче фигыле, кушма хәбәр составында килеп, заман грамматик мәгънәсен түгел, бәлки дәрәҗә һәм ысул грамматик мәгънәсен (процессның ничек һәм ни дәрәҗәдә үтәлүен, дәвам итүен) белдерә.

5. *Бир* ярдәмче фигыле, *-а/-и* формасын алган фигыль белән килеп, процессның ике чик (башлану – тәмамлану) арасында үзгәрешсез дәвам итүен белдерә: *Як юненә каранып б а р а б и р ә Хәлим* (И. Гази).

6. *Бар* ярдәмче фигыле, *-ып/-п* һәм *-а/-и* формаларын алган фигыльләр янында килеп, процессның дәвамлылыгын белдерә. Җөмләнең тулы эчтәлегенә карап, мондый кушма фигыль белдергән процессның дәвам итү дәрәҗәсе башка бер процессның дәвам итү дәрәҗәсе белән бәйләнгән була: бер процесс, башка бер процесска бәйле рәвештә, аның белән параллель дәвам итә: *Әллә без барган саен, «чыпчык» ераккарак о ч а б а р а* (Г. Тукай). *Бала күңелен тетрәткән ул фаҗиганең ярасы акрынлап т ө з ә л ә б а р д ы* (Г. Бәширов). *Ул сөйләгәннәрнең барысын да я з ы п б а р д ы м .*

7. *Кил* ярдәмче фигыле, *-ып/-п* формасын алган фигыль белән бергә, процессның ике чик арасында үзгәрешсез дәвам итүен яки соңына якынлашып килүен белдерә: *Атасы Бикбулат килгәндә, Нәфисә яза торган хәбәрен о ч л а п к и л ә иде* (Г. Бәширов). *Яшелчәләр ө л г е р е п к и л ә л ә р .*

*Кил* ярдәмче фигыле, *-а/-и* формасын алган фигыль белән дә, билгеле вакыт эчендә дәвам итә торган процессны белдерә: *Мин сезгә бу турыда ел буена и с к ә р т ә к и л д е м .*

8. *Төш* ярдәмче фигыле, *-а/-и* формасын алган фигыль белән бергә, ике чик арасында эзлекле рәвештә үсә барган процессны белдерә: *Акларның ашкынулары с ү р е л ә т ө ш т е* (Г. Бәширов*). Морозко*

*Хома Рябцев бакчасы янында атын туктата төште* (А. Фадеев). *Күзләре дә икенче төрле карый башладылар, өс-башы да рәтләнә төште* (Г. Гобәй).

9. *Тот* ярдәмче фигыле, *-ып/-п* формасын алган фигыль белән бергә, процессның дәвамлы булуын белдерә: *Дару урынына гына салып тоттым. Чыгып китмәсен дип карап тоттым.*

10. *Маташ* фигыле дә, *-ып/-п* формасын алган фигыль янында килеп, процессның дәвамлы булуын белдерә: *Буфетчы әрмән шешәләрен җыештырып маташа* (Ш. Камал). *Тыкрыкка сыенып утырган кечкенә мастерскойда картлар тырма һәм арба кебекләрне төзәтеп маташалар* (Г. Бәширов).

**Процессның тәмамлану дәрәҗәсен һәм ысулын кушма юл белән белдерү.** Мондый кушма фигыльләр процессның тәмамлану дәрәҗәсен ике төрле характерлыйлар: кайберләре процессның гомумән тәмамлануын, кайберләре исә процессның, бик тиз үтәлеп, бик тиз тәмамлануын белдерәләр. Андый кушма фигыльләрнең төп өлеше бары *-ып/-п* формасын алган фигыль белән генә бирелә, ә ярдәмче өлеше булып түбәндәге ярдәмче фигыльләр йөриләр.

1. *Кит* ярдәмче фигыле төп фигыль белән бирелгән процессның бик тиз тәмамлануын белдерә: *Нәфисәнең колагындагы алкасы җемелдәп китте* (Г. Бәширов). *Соңгы көннәрдә ялгыз йортка ямь кереп китте* (Г. Гобәй).

2. *Ал* ярдәмче фигыле, *-ып/-п* формасын алган фигыль белән килеп, процессның бик кыска вакыт эчендә үтәлеп, бик тиз тәмамлануын белдерә: *Сөйләр алдыннан төрле якка карап алалар* (М. Гафури). *Мортаза бабай комиссарга астан гына карап алды* (Г. Гобәй).

3. *Төш* ярдәмче фигыле *-ып-п* формасын алган фигыль белдергән процессның кинәт кенә үтәлеп, тәмамланып куюын күрсәтә: *Коралсызландырылган Мечик кинәт җебеп төште* (А. Фадеев). *Талчыбыктай бөгелеп төшмәмен* (Ә. Исхак). *Бу хәбәрдән Фатыйма каушап төште* (И. Гази).

4. *Куй* ярдәмче фигыле процессның тиз үтәлеп, бик тиз тәмамлануын белдерә: *Аның шпорлары зәңгырдап куйды* (Г. Бәширов). *Еракта, бик еракта пароход кычкыртып куйды* (Г. Гобәй).

*Куй* ярдәмче фигыле белән төп фигыль арасында, еш кына, *да–дә, та–тә* кисәкчәләре килә. Бу вакытта төп фигыль башка төрле

грамматик формаларны да алырга мөмкин: *Ләкин бу өмет, тиз генә кабынган кебек, шунда ук с ү н е п т ә к у я* (Ә. Фәйзи). *Сакалыннан өрлеккә а с т ы д а к у й д ы* (әкият).

5. *Кал* ярдәмче фигыле, *-ып/-п* формасын алган фигыль белән бергә, процессның соңына кадәр үтәлеп, тәмамлануын белдерә: *Габдулланың уйлары шунда б ү л е н е п к а л д ы* (Ә. Фәйзи). *Карван юл уртасында т у к т а п к а л г а н* (К. Насыйри).

*Кал* ярдәмче фигыле төп фигыль белдергән процессның башка процесс башланганчы тәмамлануын тәгъбир итә: *Яңгырлар башланганчы, бәрәңгеләрне җ ы е п к а л д ы к. Эш бөтенләй икенче якка әйләнеп киткәнче, дөресен с ө й л ә п к а л д ы.*

6. *Ташла* ярдәмче фигыле дә төп фигыль белдергән процессның ахырына кадәр үтәлүен, тәмамлануын тәгъбир итә: *Армия фашистларны т а п т а п т а ш л а д ы. Ярый, абый. Мин самовардан калган су белән керләрне ч а й к а п т а ш л а р м ы н* (Һ. Такташ).

7. *Ат* фигыле дә, үзенең конкрет мәгънәсен югалтып, *-ып/-п* формасын алган фигыль белән бергә, процессның бик тиз тәмамлануын белдерә: *Мин ул гаризаны кичә үк я з ы п а т т ы м. Ул артлы чананы кичә үк я с а п а т к а н.*

8. *Сал* ярдәмче фигыле процессның тиз генә тәмамлануын белдерә: *Сүзгә бик үткен нәрсә икән, к и с т е р е п к е н ә с а л д ы* (Г. Бәширов). *Барлык белгәннәрен ә й т е п с а л д ы.*

9. *Бир* фигыле дә, *-ып/-п* формасын алган фигыль белән бергә, процессның тәмамлануын белдерә: *Галия үзе ә й т е п б и р е р. Туганы аңа ничек итеп хәкыйкать эшләвен с ө й л ә п б и р г ә н* (хал. иҗаты).

10. *Җит, җиткер* фигыле дә процессның чигенә җитеп тәмамлануын белдерә: *Галиянең тагарактагы суы җ ы л ы н ы п җ и т ә* (Г. Гобәй). *Стенаны а г а р т ы п җ и т к е р д е м.*

11. *Бет, бетер* фигыле процессның чигенә җитүен белдерә: *Бабай к а р т а е п б е т к ә н. Без «Мәрфугат» мәйданына килеп җиткәнче й ө д ә п б е т т е к* (Ш. Камал). *Ташчылар бинаны с а л ы п б е т е р д е л ә р. Мәктәп киштәсендә аунап яткан китапларның барысын да у к ы п б е т е р д е инде ул* (Г. Гази).

12. *Чык, чыгар* фигыле процессның, дәвамлылыктан соң, чигенә җитеп тәмамлануын белдерә: *Пика бүреге тирәли кулын й ө р т е п ч ы к т ы* (А. Фадеев). *Ике араны үткәнче минем баш берничә җирдән*

*күбеп чыкты* (Ш. Камал). *Таһир бөтен залны күзе белән сөзеп чыкты* (Ш. Камал). *Тәртәне сындырып чыгарган. Чана бавын өзеп чыгарды.*

*Чык* ярдәмче фигыле, *булып* ярдәмче фигыле белән килеп, көтелгән процессның яки күренешнең киресе булуын белдерә: *Эшеннән чыккан дигәннәр иде. Кичә үз янына бардым: эшли булып чыкты.*

**Дәрәҗә-ысул категориясен гомумиләштерү.** Дәрәҗә-ысул категориясен белдерү өчен кушма фигыльләрнең ярдәмче өлеше булып йөрүче фигыльләр 27 гә җитә. Алар: *яз, тор, бар, бир, кил, кит, кал, төш, ят, утыр, тот, ал, җибәр, куй, ташла, ат, сал, җит, җиткер, бет, бетер, чык, чыгар, башла, тотын, кереш, маташ.*

Бу ярдәмче фигыльләрне түбәндәгечә гомумиләштереп күрсәтергә мөмкин.

| Кушма фигыль белдерә торган дәрәҗә-ысул категориясе төрләре | Кушма фигыльдәге төп фигыль формасы | | |
|---|---|---|---|
| | *-а/-и* формасын алган фигыль *(сөйли.., әйтә...)* | *-ып/-п* формасын алган фигыль *(сөйләп..., әйтеп...)* | инфинитив *(-рга) (сөйләр-гә... әйтергә...)* |
| Процессның ничек һәм ни дәрәҗәдә башлануын белдерү | *яза башла* | *җибәр, алып кит, алып биреп кит* | *тотын, кереш (башла)* |
| Процессның ничек һәм ни дәрәҗәдә дәвам итүен белдерү | *тор, кал, утыр, бир, бар, кил, төш* | *ят, тор, утыр, бар, кил, от, маташ* | |
| Процессның ничек һәм ни дәрәҗәдә тәмамлануын белдерү | | *кит, ал, (җибәр), төш, куй, кал, ташла, ат, сал, бир, җит, җиткер, бет, бетер, чык, чыгар* | |

**Дәрәҗә-ысул мәгънәсенең редупликация юлы белән бирелүе.** Билгеле бер мәгънә төсмерен бирү өчен, сүзләрне кабатлау редупликация дип атала. Бу күренешне Ф. Галләмов, махсус тикшереп, аның күп төрле мәгънәләрен теркәде. Алар арасында процессның ничек һәм ни дәрәҗәдә үтәлүен белдерү дә бар. Бу очракларны фигыльдә дәрәҗә-ысул мәгънәләрен белдерү дип карыйлар. Бер үк фигыльне кабатлау юлы белән дәрәҗә-ысул мәгънәсенең берничә төсмере белдерелә.

1. *-а/-и* формасындагы хәл фигыль кабатланып килсә, процессның дәвамлылыгы белдерелә: *У к ы й - у к ы й шомарып китте. Җил дә юк кебек, әяфраклар к о е л а л а р д а к о е л а л а р* (Г. Әпсәләмов*). Әти у й л а д ы , у й л а д ы да баш тартты* (Х. Сарьян). *Малайлар карап т о р д ы л а р , т о р д ы л а р да таралдылар* (Г. Тукай).

2. Дәвамлылык мәгънәсе белән процессның кабатланып үтәлеше мәгънәсе үзара тыгыз бәйләнгән. Кабатлану – ул дәвамлылыкны тәэмин итү дигән сүз. Мисаллар: *Ара бик ерак, я л и т ә - и т ә барырга туры килде* (Ә. Фәйзи). *Урылып бетмәгән сабан ашлыкларын с ы - г ы л д ы р ы п - с ы г ы л д ы р ы п , салкын яңгыр җиле исә* (А. Шамов). *Шул сүздән соң егетләр, колакларын угалап, берсен-берсе т ө р т ә - т ө р т ә , эчкә кереп тулалар* (М. Җәлил). *Зөбәйдәнең әнисе күлмәк тегә, ч ә н ч е п - ч ә н ч е п ала энәсен* (Һ. Такташ). *К а р а п - к а р а п торды да эчкә үтте* (А. Шамов).

3. Процессның, тулысынча түгел, өлешчә үтәлүен дә редупликация юлы белән белдереп була: *Т е л ә р - т е л ә м ә с кенә чыгып китте* (әкият). *Редактор исә, т е л ә д е м е - т е л ә м ә д е м е , тәнкыйтьче дә була* (М. Максуд). *Татарчага о х ш а г а н д а , о х ш а м а г а н д а бер тел белән мөнәҗәт әйтәләр* (Х. Сарьян*). Бибисара түтинең бу сүзләрен ә л л ә и ш е т т е , ә л л ә и ш е т м ә д е* (Г. Әпсәләмов).

Мисаллардан күренгәнчә, биредә фигыль раслау һәм инкяр формаларында кабатлана.

4. Үтәлү дәрәҗәсенең югары булуын белдерә: *Менә бу кыз чынлап әзерләнгән, б е л ә д и с ә ң д ә б е л ә* (Х. Сарьян). *Т у з а д и с ә ң д ә т у з а икән, томар җире калмаган* (А. Шамов).

Фигыльләр төрле формаларда һәм аларга төрле ярдәмче сүзләр катнашып кабатланалар. Теләсә нинди фигыль теләсә нинди формада кабатлана алмый. Бу яктан караганда, редупликация грамматик чара түгел, ул стилистик һәм лексик-семантик күренеш буларак өйрәнелә.

И с к ә р м ә . Фигыльләрдә дәрәҗә-ысул категориясе буенча татар тел гыйлемендә башкачарак карашлар да бар. Түбәндә алар өстәмә материал буларак бирелә (Ф. Ганиев – 270–293 б., Д. Тумашева – 294–307 б.).

**Дәрәҗә категориясе**

Татар телендә тәмамланган һәм тәмамланмаган төр категориясе юк. Мәгълүм булганча, рус телендә тәмамланган төр фигыле – семантикасында белдерелгән, үзенең эчке чигенә барып җиткән эш-хәрәкәт-

не тәгъбир итә, һәм ул хәзерге заман формасында кулланыла алмый. Татар телендә исә бу күренеш юк, беренчедән, гади фигыль дә, тезмә фигыль дә хәзерге заман формасында кулланыла ала. Икенчедән, рус телендә фигыльләр тәмамланганлык һәм тәмамланмаганлык ягыннан икегә аерылалар: *прочитать – прочитывать, записать – записывать.* Татар телендә фигыльләр, үзләренең семантикасын үзгәртмичә генә икегә аерыла алмыйлар. Шуңа күрә аларны теге яки бу төргә кертеп булмый. Мәсәлән, *чыгу* фигыле рус теленә *выйти* дип тә, *выходить* дип тә, *эшләү* фигыле *делать* дип тә, *сделать* дип тә тәрҗемә ителә, ягъни аларның эчтәлеге ике төрнең дә мәгънәсенә туры килә, алар төр ягыннан нейтраль булып торалар, бары контекстка бәйле рәвештә генә теге яки бу төрнең мәгънәсен бирә алалар. Бу фигыльләр *Азат өйдән чыга. Кичә ул эшләде* дигән җөмләләрдә рус телендәге тәмамланмаган төр мәгънәсен бирәләр, *Марат өйдән чыкты* һәм *Рөстәм бер уенчык эшләде* дигәндә аларның эчтәлеге рус телендә тәмамланган төр мәгънәсенә туры килә. Татар теленең барлык фигыльләре, шул исәптән төр белдерә дип саналган тезмә фигыльләр дә, хәзерге заман формасында кулланыла алалар: *Мондый вакытларда ул үзенең авылын үтә сагынып куя* (Г. Ибраһимов). *Чын музыка яхшы тойгыларыңны уятып чыгара* (Г. Бәширов). *Кошлар бала чыгарып бетерәләр* (Ә. Еники). Әгәр дә югарыдагы мисалларда тезмә фигыльләр тәмамланган төр белдерсә, алар хәзерге заман формасында кулланыла алмаслар иде. В. Виноградов әйткәнчә, «тәмамланган төргә хас булган чик мәгънәсе хәзерге заман төшенчәсенә каршы килә» [Виноградов В., 1947, с. 573].

Әмма татар телендә тәмамланган һәм тәмамланмаган төрнең булмавы татар телендә андый мәгънәләрне имплицит рәвештә бирүгә киртә була алмый. Татар телендә андый мәгънәләр, грамматик чаралардан башка, заман (контекст) формалары белән белдереләләр. Фигыльләрнең заман формалары, мәсәлән, тәмамланган төр мәгънәсен бирсен өчен, ягъни чигенә җиткән эшне белдерсен өчен, ул фигыльләрнең семантикасында эш-хәрәкәтнең чиге күрсәтелергә тиеш. Әгәр дә фигыльдә эш-хәрәкәтнең чиге күрсәтелмәсә, хәтта контекстта да ул фигыль тәмамланган төр мәгънәсен бирә алмас иде.

Татар телендә төр категориясе белән тиңләштереп яки кулланылып йөргән, һәм төр категориясе белән бернинди уртаклыгы булмаган

лексик-грамматик категория – дәрәҗә категориясе бар. Дәрәҗә категориясен белдерүдә лексик чаралар да, грамматик чаралар да кулланыла, шуңа күрә ул лексик-грамматик категория тәшкил итә. Бу категория эш-хәрәкәт башкарылуның, аның башкарылу ысулының күп төрле мәгънәләрен белдерә.

Дәрәҗә категориясен белдерүдә 1) модификация фигыльләре, 2) кушымчалар, 3) формаларны редупликацияләү катнаша.

**Дәрәҗә категориясенең модификацияләүче фигыльләр белән белдерелүе.** Модификацияләүче фигыльләр *-п* га яки *-а, -ә, -ый, -й, -и* гә тәмамланган хәл фигыльләр белән килеп, тезмә фигыльләр барлыкка китерәләр һәм ул тезмә фигыльләр дәрәҗә категориясен, ягъни эш-хәрәкәтнең башкарылу үзенчәлекләрен белдерәләр.

Тезмә фигыльләр турында беренче мәгълүматны без И. Гиганов, А. Троянский, А. Казимбәк, М.Иванов грамматикаларында очратабыз. Тезмә фигыльләр турында мәгълүмат Ә. Максуди, Г. Нугайбәк, Г. Сәгъди грамматикаларында да бирелә. Октябрь инкыйлабыннан соң татар теленең грамматик төзелешен тикшерү шактый көчәеп китә. Г. Ибраһимов, М. Корбангалиев, Х. Бәдигый, Җ. Вәлиди, Г. Алпаров хезмәтләрендә тезмә фигыльләргә теге яки бу күләмдә анализ ясала. Г. Алпаров фикеренчә, ярдәмче фигыльләр төп фигыльгә өстәмә мәгънә бирү өчен кулланылалар. Р. Газизов тезмә фигыльләрне лексик берәмлекләр рәтенә кертеп карый. В. Хангилин, ярдәмче фигыльләр кушма фигыльләр ясаганда төп фигыльнең семантикасына йогынты ясыйлар, дип саный.

А. Кононов, В. Насилов, Н. Баскаков, Д. Насилов үзләренең хезмәтләрендә төрки телләрдәге тезмә фигыльләрнең үзенчәлекләрен ачыклыйлар. А. Алекперов азәрбайҗан телендә, Н. Оралбаева казакъ телендә, М. Текуев карачай-балкар телендә, тезмә фигыльләр мөстәкыйль фигыль тәшкил итә һәм алар грамматик төр мәгънәсен белдерми, дип карыйлар.

Тезмә («кушма») фигыльләр барлык телләрдә дә юк (мәсәлән, рус телендә), ә менә япон һәм һинд телләрендә киң таралган. Икенче тип телләргә шулай ук төрки телләр дә, шул исәптән татар теле дә керә.

Тюркологиядә тезмә фигыльләр соңгы вакытка кадәр диярлек грамматик төр категориясен белдерә дип саналды. Шуннан чыгып булса кирәк, алар бүгенге көнгә кадәр төрки телләр сүзлекләрендә лексик берәмлек буларак үзләренә урын тапмадылар.

Татар телендә тезмә фигыльләр *-п* га яки *-а, -ә, -и, -й* гә беткән хәл фигыльләргә аларны модификацияләүче кайбер фигыльләр кушылып ясала. Әмма шундый ук конструкцияләр ирекле сүзтезмәләр дә тәшкил итәргә мөмкин. Шуңа күрә, аерым очракларда, мондый тезмәнең ирекле сүзтезмәме яки тезмә фигыльме булуын билгеләве кыенлык тудыра.

Мондый конструкцияләр түбәндәге очракларда ирекле сүзтезмә тәшкил итәләр: 1) хәл фигыль җөмлә кисәге булган хәлне белдереп, аның артыннан килгән фигыль төп эш-хәрәкәтне тәгъбир итсә; 2) хәл фигыль белән аның артыннан килгән фигыльләр эзлекле яки параллель мөстәкыйль эш-хәрәкәтне белдерсәләр.

Беренчедән, хәл фигыль җөмләдә рәвеш, сәбәп хәлләре булып, аның артыннан килгән затланышлы фигыль – башка җөмлә кисәге, гадәттә хәбәр булып килергә мөмкин: *Бу хатны ничек башларга белмичә бик озак аптырап утырдык* (Г. Бәширов). *Өйдә авырып калдым. Юлда егылып калдым.*

Китерелгән конструкцияләрдә (ирекле сүзтезмәләрендә) хәл фигыль белән килгән фигыльләр җөмләдә өченче бер мөстәкыйль сүз белән аерыла алалар. Мәсәлән, *Бу хатны ничек башларга белмичә бик озак аптырап утырдык* җөмләсендәге тезмә фигыльгә охшаш комбинациягә кергән сүзләрне җөмләдә өченче мөстәкыйль сүз белән аерырга була: *Бу хатны ничек башларга белмичә бик озак аптырап, уйланып утырдык*. Күренгәнчә, комбинациягә кергән сүзләрне аерудан җөмләнең бөтенлеге бозылмый. Бу комбинациядә хәл фигыль бөтенләй булмаса да, җөмләнең бөтенлегенә зыян килми: *Бу хатны ничек башларга белмичә озак... утырдык*.

*Аптырап утырдык* комбинациясендә ике фигыль дә мөстәкыйль җөмлә кисәкләре булып килгән. Димәк, ирекле сүзтезмәләр (биредә хәл фигыль белән хәбәр тезмәсе), тышкы күренеше ягыннан тезмә фигыльләргә охшаса да, түбәндәге билгеләре аларны тезмә (кушма) фигыльләрдән аера: 1) комбинациягә кергән сүзләрнең өченче мөстәкыйль сүз белән аерыла алу мөмкинлеге; 2) хәл фигыльне төшереп калдырудан җөмләнең бөтенлеге югалмау; 3) һәр ике фигыльнең дә семантикаларының мөстәкыйльлеге һәм бөтенлеге; 4) җөмләдә һәр икесе аерым җөмлә кисәге булып килүе. Тезмә фигыльләргә исә бу сыйфатлар хас түгел.

Икенчедән, хәл фигыль белән аның артыннан килгән фигыль эзлекле эш-хәрәкәтне белдерәләр: *Ул җилтерәп кенә чыгып, сыерын ябып, юынып керде* (Г. Бәширов). *Бала тудыру йортына керәп чыкты* (Г. Әпсәләмов). *Айсылу... сәхнәдәге кызыл япмалы озын өстәл артына менеп басты* (Г. Бәширов). *Шәһәргә барып кайттым.*

Китерелгән мисалларда хәл фигыль + затланышлы фигыль тезмәләре тышкы күренеше белән тезмә фигыльләрне хәтерләтә, әмма үзләренең эчтәлеге ягыннан алардан тамырыннан аерыла. Чөнки бу комбинацияләрдә фигыльләр бердәм мәгънә барлыкка китермиләр, ә эзлекле ике мөстәкыйль эш-хәрәкәтне белдерәләр. Өстәвенә, бу комбинацияләргә кергән сүзләр өченче сүз белән аерыла. Мәсәлән, *барып кайттым* тезмәсенә кергән сүзләрне *Шәһәргә барып кайттым* җөмләсендә өченче мөстәкыйль сүз белән аерырга мөмкин: *Шәһәргә барып әйберләр сатып алып кайттым.* Өченче мөстәкыйль сүз белән бу комбинациянең аерыла алуы бу тезмәнең фигыльләренә үзара мәгънә кереше һәм үзара бәйләнгәнлек хас булмавын күрсәтә. Алар бу яктан мөстәкыйльләр, бөтенләй төрле мәгънә белдерәләр, болар исә кушма фигыль булу принцибына каршы киләләр. Моннан әлеге тезмәләр тезмә фигыльләргә охшасалар да, бу охшашлык тышкы яктан гына булуы аңлашыла.

Тезмә фигыльләрне шулай ук фигыльләрнең кушма формаларыннан (заман, модаль формалардан) аерырга кирәк. Чөнки татар телендә аналитик заман формалары яңа сүз тәшкил итмиләр. Мәсәлән, *барган иде, бара иде* заман формалары, аналитик (кушма) булсалар да, икенче элемент бернинди дә лексик мәгънә кертмәгәнлектән, бары грамматик мәгънә белдергәнлектән, аларны кушма сүзләр дип карап булмый.

Татар телендә фигыльләрнең модаль формалары тезмә (кушма) фигыльләр тәшкил итмиләр. Яза алу формасында икенче компонент бары грамматик функциягә генә – модальлек функциясенә генә ия. Күренгәнчә, ике сүздән торган заман формалары да, модаль формалар да татар телендә кушма сүз тәшкил итмиләр. Чөнки «фигыльнең кушма формасы әле кушма фигыль түгел» (А. Алекперов).

Кушма формалар ясалышы рус телендә дә очрый: *самый хороший, буду писать* һ.б. Ләкин бу формаларны кушма сүзләр дип карап булмый, чөнки компонентларның берсе реаль мәгънәгә ия түгел, бары грамматик мәгънә генә белдерә.

Нәрсә соң ул тезмә фигыль? Тезмә фигыльләр түбәндәге үзенчәлекләр белән тасвирланалар. Беренчедән, тезмә фигыльләр бер лексик мәгънә белдерәләр һәм шуңа бәйләнешле рәвештә җөмләдә бары бер җөмлә кисәге буларак кына киләләр. Мәсәлән, *Мин китапны укып чыктым* җөмләсендә тезмә фигыль бер эшне белдерә һәм мөстәкыйль җөмлә кисәге – хәбәр булып килә. Ә ирекле сүзтезмәләр исә, формалары ягыннан кушма фигыльләргә охшаса да, ике төрле эш-хәрәкәт белдерәләр, җөмләдә ике җөмлә кисәге булып киләләр, эзлекле яки параллель эш-хәрәкәт белдерәләр.

Кайбер тезмә фигыльләрнең мәгънәсе аларны тәшкил итә торган компонентларның гади суммасына тигез. Мәсәлән, *язып бетерү, ашап бетерү* тезмә фигыльләренең мәгънәсе аларны тәшкил итә торган компонентларның мәгънәләре суммасына тигез. Ләкин күпчелек тезмә фигыльләрнең мәгънәләре күчмә була, ягъни аларның мәгънәләре аларны тәшкил итә торган компонентларның мәгънәләреннән турыдан-туры чыкмый, мәсәлән, *укып чыгу, каушап төшү, карап алу* һ.б. Икенчедән, тезмә фигыльләрнең компонентлары җөмләдә ирекле сүзтезмәләрдәге кебек аерым кулланыла алмый. Тезмә фигыльләрнең компонентларын, мәгънәгә зыян китермичә, өченче мөстәкыйль сүз белән аерып булмый. Фигыльле тезмәләргә кергән сүзләрнең өченче сүз белән аерылу мөмкинлекләре аларның мөстәкыйльлекләре, тезмәнең ирекле сүз булуы турында сөйли. Әйтик, *барып кайтырга* комбинациясе мөстәкыйль сүз белән аерылырга мөмкин. Мәсәлән: *Шәһәргә барып, авылга кире кайтты* дип әйтергә була, *барып* һәм *кайт* фигыльләре үзләренең мөстәкыйльлекләрен саклыйлар, лексик яктан үзара бәйләнмәгәннәр, үзара мәгънә кереше юк. Алар эзлекле барган эш-хәрәкәтне белдерәләр. Рус телендә дә аларга тиңдәш хәбәрләр бар.

Тезмә фигыльләрнең компонентлары арасына мәгънәне бозмыйча яңа мөстәкыйль сүз куеп булмый. Телнең синтаксик нормаларын бозмыйча, түбәндәгечә сөйләп булмый: *Бу китапны укып мин чыктым* яки *Укып бу китапны мин чыктым. Бу хәбәрдән каушап мин төштем. Мин каушап бу хәбәрдән төштем.*

Татар телендә тезмә фигыльләрнең компонентлары бары мөстәкыйль булмаган сүзләр белән генә, атап әйткәндә көчәйткеч кисәкчәләр *-да/-дә (-та/-тә)* һәм чикләүче кисәкчәләр *-гына/-генә*

*(-кына/-кенә)* белән аерылырга мөмкин. Мондый очракларда көчәйткеч кисәкчәләр тезмә фигыльгә тизлек, интенсивлык мәгънәсен бирә: *Наташа... сәхнәгә м е н е п т ә җ и т т е* (Г. Бәширов). Чикләүче кисәкчәләр тезмә фигыльгә чикләү мәгънәсен һәм эш-хәрәкәтнең әле генә башкарылуын белдерә: *Китапны у к ы п к ы н а ч ы к к а н идем, иптәшем килде.*

Өченчедән, тезмә фигыльләрдә компонентлар арасында, иректе сүзтезмәләрдәге кебек, үзара синтаксик бәйләнешләр табып булмый. Мәсәлән, *укып чыкты* дигән тезмә фигыльдә бернинди дә синтаксик мөнәсәбәт булмый, ә *аптырап утырдык* дигән сүзтезмәдә ачыктан-ачык синтаксик бәйләнеш күзәтелә (хәл белән хәбәр бәйләнеше).

Дүртенчедән, тезмә фигыльләрнең компонентлары арасында үзара мәгънә кереше һәм шартлы бәйлелек бар, чөнки фигыльләрнең икенче компоненты төп фигыльнең мәгънәсен модификацияли, конкретлаштыра, бары аңа гына бәйле, аңардан башка җөмләнең бөтенлеген бозмыйча яши алмый. Мәсәлән, *Мин бу китапны укып чыктым* җөмләсендә *чыктым* компоненты *укып* сүзеннән башка мөстәкыйль яши алмый. Мәсәлән, мәгънәне яки җөмләне бозмыйча *Бу китапны чыктым* дип әйтеп булмый. Чөнки компонентлар арасындагы мәгънә кереше һәм шартлы бәйлелек югала. Тезмә фигыльләргә охшаш ирекле сүзтезмәләрдә мондый хәл күзәтелми. Ирекле сүзтезмәләрдә затланышлы фигыль (сүзтезмәнең икенче сүзе) җөмлә кисәге булып һәм җөмләнең башка кисәкләре белән бәйләнгәнлектән, ул хәл фигыльгә генә түгел, ә бөтен җөмләгә карый һәм хәл фигыльсез дә, мөстәкыйль кулланылырга мөмкин. Бу – хәл фигыль белән аннан соң килә торган фигыль арасында сүзтезмәләрдәге кебек мәгънә кереше һәм шартлы бәйлелек булмаганлыктан килеп чыга. Мәсәлән: *Бу хатны ничек башларга белмичә бик озак а п т ы р а п у т ы р д ы к* җөмләсендә ирекле сүзтезмәдәге хәл фигыльне төшереп тә калдырырга мөмкин. Бу вакытта җөмләнең бөтенлеге бозылмый, ә тезмә фигыльләрдә моны эшләп булмый.

Бишенчедән, тезмә фигыльләрнең бер генә басымы була, аларның компонентлары беренче компонентка төшкән гомуми төп басым белән үзара беркетелә: *укып чыгу, каушап төшү.*

Шуны да әйтергә кирәк, югарыда китерелгән билгеләрнең берсе дә абсолют түгел, күрсәтелгән үзенчәлекләрнең барысы бергә генә

тезмә фигыль китереп чыгара, тел фактлары күрсәткәнчә, татар теленең лексик берәмлеген тәшкил итә.

Тюркологиядә тезмә фигыльнең төп мәгънәсе беренче компонент (хәл фигыль) белән белдерелә, ә модификацияләүче фигыль өстәмә мәгънә бирә, беренче фигыльнең мәгънәсен конкретлаштыра дигән традицион караш яшәп килә.

Татар теле фактлары күрсәткәнчә, беренче һәм икенче компонентлар арасында үзара бәйләнеш үзгәрергә дә мөмкин, төп мәгънә кайвакытта икенче компонент – фигыльнең затланышлы формасы белән, өстәмә мәгънә – хәл фигыль формасы белән дә белдерелергә мөмкин. Мәсәлән, *алып бару, алып килү, алып кую, алып бирү, алып чыгу, алып калу, алып китү* тезмә фигыльләренең тулысынча семантикасы саклануын, төп мәгънәне белдерүен, беренче компонентлар исә, модификацияләүче фигыльгә әйләнеп, икенче компонентларның мәгънәләрен конкретлаштыруын күрсәтә. Шул сәбәптән сөйләшү телендә беренче компонентлар сүз формасын югалтып префиксоидка әйләнгәннәр: *алып бару = аппару, апару; алып килү = апкилү; алып кую = апкую; алып бирү = аппирү; алып чыгу = апчыгу; алып китү = апкитү; алып керү = апкерү.*

Шулай итеп, тезмә фигыльдә хәл фигыль формасы – модификацияләүче фигыльне, ә икенче компонент төп фигыльне тәшкил итәргә мөмкин. Бу хәл теләсә нинди структур берәмлектә, кагыйдә буларак, икенче дәрәҗәдәге элементның үзгәрүгә дучар булуы белән аңлатыла. Шундый хәл *алып кит* тибындагы тезмә фигыльләрдә күзәтелә.

Югарыда китерелгән мисалларда *ап* элементы *алып* фигыленең матди сүз формасын югалткан (кыскарма) формасын тәшкил итә, ул инде сүз дәрәҗәсендәге структур берәмлек була алмый, шуңа күрә аларны сүзләр кушылып сүзьясалышына кертеп булмый.

Тезмә фигыльләрнең компонентлары арасында, һичшиксез, тере синтаксик бәйләнеш юк, шуңа да карамастан, бәйләнешләрнең шартлы рәвештә сүзтезмәләренә туры килүеннән чыгып, алар арасында ияртүле бәйләнеш күзәтелә, дип әйтергә мөмкин. Тезмә фигыльләр нигездә, сүзләр кушылу юлы белән барлыкка килгәннәр һәм киләләр. Мәсәлән, барлык неологизм булган фигыльләр шунда ук ярдәмче фигыльләр белән кушылып, тезмә фигыльләр ясыйлар: *күзаллап чыгу, автоматлаштырып бетерү, анализлап тору, абстракцияли төшү.*

Татар телендә тезмә фигыльләр ясалышының түбәндәге типлары бар:

| | |
|---|---|
| хәл фигыль + *алу* | хәл фигыль + *җиткерү* |
| хәл фигыль + *бару* | хәл фигыль + *ату (ташлау)* |
| хәл фигыль + *бетү* | хәл фигыль + *башлау* |
| хәл фигыль + *бирү* | хәл фигыль + *бетерү* |
| хәл фигыль + *калу* | хәл фигыль + *йөрү* |
| хәл фигыль + *керү* | хәл фигыль + *карау* |
| хәл фигыль + *китү* | хәл фигыль + *килү* |
| хәл фигыль + *салу* | хәл фигыль + *кую* |
| хәл фигыль + *төшү* | хәл фигыль + *тору* |
| хәл фигыль + *утыру* | хәл фигыль + *узу* |
| хәл фигыль + *чыгару* | хәл фигыль + *чыгу* |
| хәл фигыль + *яту* | хәл фигыль + *үтү* |
| хәл фигыль + *җибәрү* | хәл фигыль + *җитү* |

Бу типтагы тезмә фигыльләрнең икенче компонентлары модификацияләүче фигыльләрне тәшкил итәләр. Аларны тюркологиядә ярдәмче фигыльләр дип йөртәләр. Бер үк модификацияләүче фигыль (ярдәмче фигыль) контекстка һәм нинди фигыль белән килүенә карап бәйләнешле рәвештә берничә мәгънә белдерә ала.

Модификацияләүче фигыль белән ясалган тезмә фигыльләр дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр.

*-ып, -еп, -п* кушымчаларына тәмамланган хәл фигыльгә *алу* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр:

1. Кыска вакыт эчендә эш-хәрәкәт башкаруны: *Күз кырыен төшереп алды* (И. Гази).

2. Тәкрарлы, әмма озак бармаган эш-хәрәкәтне: *Карт... таягын тукылдатып алды* (Г. Бәширов).

3. Аз вакыт эчендә башкарылган эш-хәрәкәтне: *Сәлим бераз йоклап алды.*

*-п, -ып, -еп* кушымчаларына тәмамланган хәл фигыльгә *ату* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр тиз башкарылган эш-хәрәкәтне белдерә: *Туганыма хат язып аттым.*

*-п, -ып, -еп* кушымчаларына тәмамланган хәл фигыльгә *бару* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр:

1. Көчәя, арта барган эш-хәрәкәтне: *Тормыш яхшыланып бара.*

2. Үзенең ахырына, чигенә таба барган эш-хәрәкәтне: *Запаслар бетеп бара.*

3. Даими башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Газеталарны укып бара.*

4. Билгеле бер юнәлештә башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Тауга менеп барабыз.*

*-а, -ә, -ый, -и* гә тәмамланган хәл фигыльгә *бару* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр:

1. Эш-хәрәкәтнең көчәя, арта баруын: *Эш кыза барды.*

2. Даими башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Без суны түгә бардык.*

*-а, -ә, -ый, -и* гә тәмамланган хәл фигыль + *башлау* модификацияләүче фигыленнән ясалган тезмә фигыльләр эш-хәрәкәтнең башланып китүен белдерә: *Яз җитеп, карлар эри башлады* (Г. Тукай).

*-п* га тәмамланган хәл фигыль + *бетү* модификацияләүче фигыленнән ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр:

1. Эш-хәрәкәтнең тулысынча тәмамлануын: *Утын тиз янып бетте. Эш эшләнеп бетте.*

2. Эш-хәрәкәтнең ахыр чиккә җитүен, соң дәрәҗәдә булуын: *Көтә-көтә зарыгып беттем* (Һ. Такташ).

*-п* га тәмамланган хәл фигыль һәм *бетерү* модификацияләүче фигыле ярдәмендә ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр:

1. Эш-хәрәкәтнең тулысынча тәмамлануын: *Ул тәмәкесен тартып бетерде* (М. Гафури).

2. Эш-хәрәкәтнең ахыргы чиккә, соң дәрәҗәгә җитүен: *Күчереп тинтерәтеп бетерделәр* (Ш. Камал).

3. Күп предметларга яисә берәр нәрсәнең өслегенә тулысынча таралган эш-хәрәкәтне: *Стенага рәсемнәрябыштырып бетергән.*

*-ып, -еп, -п* кушымчасына тәмамланган хәл фигыльгә *бирү* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр берәр объект яки субъект юнәлешендә, мәнфәгатендә башкарылган эш-хәрәкәтне белдерәләр: *Өйгә кайткач, картына бөтен нәрсәне сөйләп бирде.*

*-а, -ә, -ый, -и* гә тәмамланган хәл фигыльгә *бирү* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр бернәрсәгә карамастан башкарыла торган эш-хәрәкәтне белдерә: *Үз хәлен кешегә белдермичә йөри бирде.*

*-п* га тәмамланган хәл фигыльгә *йөрү* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр өзлексез, субъект өчен чагыштырмача даими булган эш-хәрәкәтне белдерә: *Бик һәйбәт кенә тырышып укып йөриләр* (Г. Ибраһимов). *Рәхәт-рәхәт көчеп йөриләр иде* (Г. Ибраһимов).

*-п* га тәмамланган хәл фигыльгә *калу* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр:

1. Нәтиҗәле эш-хәрәкәтне: *Йөрәк ярасыннан күңелгә моң утырып кала.*

2. Субъектны тулысынча чолгап алган эш-хәрәкәтне: *Туташ аптырап калды* (Г. Ибраһимов).

3. Беркадәр дәвамлы хәл барлыкка килеп, тәмамланган эш-хәрәкәтне: *Өчесе дә тынып калдылар* (Г. Гобәй).

*-а, -ә, -ый, -и* гә тәмамланган хәл фигыльгә *калу* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр башкаручының эш-хәрәкәтне әле тәмамлап бетермәвен белдерә: *Марат яза калды.*

*-п* га тәмамланган хәл фигыльгә *карау* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр эш-хәрәкәтне сынап карауны яки башкарырга омтылуны белдерә: *Мәкалә язып карадым.*

*-п* га тәмамланган хәл фигыльгә *керү* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр берәр нәрсәнең эченә юнәлгән эш-хәрәкәтне белдерә. Кайбер очракларда кинәтлек төсмере дә чагыла: *Шул арада әни кайтып керде.*

*-п* га тәмамланган хәл фигыль һәм *килү* модификацияләүче фигыле ярдәмендә ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр:

1. Берәр урынга яки сөйләүчегә юнәлгән эш-хәрәкәтне: *Зиннәт авылына кайтып килә* (Г. Бәширов).

2. Үзенең чигенә, соңгы дәрәҗәсенә акрынлап якынлашып барган эш-хәрәкәтне: *Көн караңгыланып килә* (Һ. Такташ).

3. Нәтиҗәле эш-хәрәкәтне: *Бүләк алып килделәр.*

4. Тәкрарлы (регуляр) башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Аны кисәтеп килделәр.*

*-а, -ә. -ый, -и* гә тәмамланган хәл фигыльгә *килү* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр билгеле бер вакытка кадәр башкарыла торган тәкрарлы эш-хәрәкәтне белдерәләр: *Аңа мин әйтә килдем.*

*-п* га тәмамланган хәл фигыльгә *китү* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр:

1. Берәр чыгыш урыныннан яки сөйләүчедән ераклаша барып башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Мәктәптән кайтып китте.*

2. Үзара мөнәсәбәттә берәр үзенчәлек, сыйфат алуны: *Эш чыгырында яңадан дусланып киттеләр* (Ш. Камал).

3. Эш-хәрәкәтнең башланып китүен*: Алмаев кабинеты буйлап йөреп китте* (И. Гази).

4. Кинәт яки тиз башкарылган эш-хәрәкәтне: *Караңгы зал кинәт яктырып китә* (Һ. Такташ).

*-п* га тәмамланган хәл фигыльгә *кую* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр:

1. Кинәттән бер кат башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Гыйльманов баскан урынында сикереп куйды* (И. Гази).

2. Нәтиҗәле эш-хәрәкәтне: *Утынны күп итеп ярып куйдылар* (Г. Бәширов).

*-п* га тәмамланган хәл фигыльгә *салу* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр кинәт яки көтелмәстән башкарылган эш-хәрәкәтне белдерә: *Ул иптәше белмәгәнне әйтеп салды.*

*-п* га тәмамланган фигыльгә *ташлау* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр:

1. Бөтен тулылыгы белән башкарылган нәтиҗәле эш-хәрәкәтне: *Берүзе өч-дүрт эскерт куеп ташлады* (Г. Бәширов).

2. Кинәттән яки көтмәстән башкарылган эш-хәрәкәтне: *Ни өчендер ул моны әйтеп ташлады.*

*-п* га тәмамланган хәл фигыльгә *тору* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр:

1. Теге яки бу дәрәҗәдә үзгәрешсез бара торган эш-хәрәкәтне: *Вак яңгыр с и б ә л ә п  т о р а* (Ш. Камал).

2. Тәкрарлы (даими) эш-хәрәкәтне: *Мин эшемнең һәр үрнәген я з ы п  т о р д ы м аларга* (М. Җәлил).

3. Предмет өчен даими яки гадәти булган эш-хәрәкәтне: *Миләш тәлгәшләре  а с ы л ы н ы п  т о р а* (Г. Бәширов).

*-а, -ый, -и* гә тәмамланган хәл фигыльгә *тору* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр:

1. Озак дәвам итә торган яки тәкрарлы (регуляр) эш-хәрәкәтне: *Эшелоннар  к и т ә  т о р д ы л а р* (Ш. Усманов).

2. Өлешчә башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Алар  б а р а  т о р с ы н н а р.*

*-п* га тәмамланган хәл фигыльгә *төшү* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр:

1. Субъектны яки предметны тулысынча чолгап алган эш-хәрәкәтне: *Хәдичә  к а у ш а п  т ө ш т е* (Г. Бәширов). *Ботак  б ө г е л е п  т ө ш т е.*

2. Кинәт яки тиз башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Кычкырын  к и л е п  т ө ш т е* (Ш. Камал).

*-а, -ә, -ый, -и* гә тәмамланган хәл фигыльгә *төшү* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр:

1. Берәр урын яки вакыт аралыгында бара торган өлешчә эш-хәрәкәтне: *Түргә  у з а  т ө ш т е.*

2. Эш-хәрәкәтнең өлешчә көчәюен яки көчәеп килүен: *Үләннәр я ш е л л ә н ә  т ө ш т е. Ул  а г а р а  т ө ш т е.*

*-п* га тәмамланган хәл фигыльгә *узу* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр:

1. Берәр нәрсә аркылы яки барышлый башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Айсылуниләр язуын  б е л е ш е п  у з а* (Г. Бәширов).

2. Тулысынча (тулаем) башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Ул бу хәлләрне  с ө й л ә п  у з д ы.*

*-п* га тәмамланган хәл фигыльгә *утыру* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр дәвамлы, өзлексез бара торган

эш-хәрәкәтне белдерәләр: *Мичкә агып утыра. Су кайнап утыра.*

*-п* га тәмамланган хәл фигыльгә *чыгу* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр:

1. Берәр нәрсәнең эченнән, уртасыннан читкә таба бара торган эш-хәрәкәтне: *Корт алманы тишеп чыккан.*

2. Билгеле бер вакыт аралыгында тулысынча бара торган эш-хәрәкәтне: *Төн буе мич ягып чыгалар* (М. Гафури).

3. Предметның барлык өслегенә таралган эш-хәрәкәтне: *Идәнне буяп чыктык.*

4. Башыннан ахырына кадәр башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Кулымдагы хатны тагын бер кат укып чыктым* (М. Гафури).

5. Бик күп затларга һәм предметларга караган эш-хәрәкәтне: *Киткәндә барыбызны да үбеп чыкты. Сарыкларны санап чыктылар.*

6. Көтелмәгән яки кинәттән башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Түрәгә охшаган бер адәм килеп чыкты* (Г. Ибраһимов).

7. Билгеле бер урын аралыгында башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Бөтен авылны әйләнеп чыктык. Рәис үзенең хуҗалыгын йөреп чыкты.*

8. Нәтиҗәле эш-хәрәкәтне: *Без җиңеп чыгачакбыз.*

9. Берәр урын, предмет аша башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Бүрәнәне атлап чыктылар. Елга аша йөзеп чыктык.*

*-п* га тәмамланган хәл фигыльгә *чыгару* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр нәтиҗәле эш-хәрәкәтне белдерәләр: *Әни бер армый-талмый байларга кәләпүш эшләп чыгара иде* (Г. Тукай). *Нәфисә үзе исәпләп чыгара* (Г. Бәширов).

*-а, -ә, -ый, -и* гә тәмамланган хәл фигыльгә *язу* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр.

1. Башкарылмый калган эш-хәрәкәтне: *Хәлим авылга китә язды.*

2. Берәр эш-хәрәкәтнең чигенә җитә язып тукталып калуын: *Гали үлә язган.*

-*п* га тәмамланган хәл фигыльгә *яту* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр:

1. Билгеле бер вакыт эчендә дәвам иткән эш-хәрәкәтне: *Комиссия бодаеңны сугып ята* (Г. Бәширов).

2. Предметның гадәти хәлен: *Дала көзге кебек җәелеп ята.*

-*п* га тәмамланган хәл фигыльгә *үтү* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр:

1. Юл уңаенда яки берәр нәрсә аркылы башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Безнең бөтен юл сөйләшеп үтте.*

2. Тулысынча (тулаем) башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Укытучы моның турында сөйләп үтте.*

-*п* га тәмамланган хәл фигыльгә *җибәрде* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр:

1. Кинәтлек төсмере белән башкарылган кискен эш-хәрәкәтне: *Урманов сызгырып җибәрде* (Г. Ибраһимов). *Бала кычкырып җибәрде.*

2. Эш-хәрәкәтнең гомумән башлануын: *Кызый елап җибәрде* (Ә. Еники).

-*п* га тәмамланган хәл фигыльгә *җитү* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр:

1. Билгеле бер объектка, урынга җитә торган эш-хәрәкәтне: *Актүш көймәне бик тиз куып җитте* (Г. Гобәй).

2. Билгеле бер хәлгә, чиккә җитә торган эш-хәрәкәтне: *Ул хәлне тәмам аңлап җитә* (Г. Ибраһимов).

-*п* га тәмамланган хәл фигыльгә *җиткерү* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр билгеле бер урынга, объектка җиткерелә торган эш-хәрәкәтне белдерә: *Китапны аңа илтеп җиткер.*

**Дәрәҗә категориясенең кушымчалар белән белдерелүе.** Дәрәҗә категориясе кушымчалар белән дә белдерелә. Шуңа күрә дә ул лексик-грамматик категория тәшкил итә.

Фигыль нигезләренә түбәндәге кушымчалар ялганып дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр:

*-гала/-гәлә (-кала/-кәлә), -штыр/-штер, -ымсыра/-емсерә, -ынкыра/-енкерә.*

*-галә/-гәлә(-кала/-кәлә)* һәм *-ыштыр/-ештер* мәгънәләре якынча бердәйләр. Аерма бары шунда гына: икенче кушымчада эш-хәрәкәтнең тулы башкарылмавы ныграк чагыла.

*-гала/-гәлә (-кала/-кәлә)* кушымчасы тартыкларга яки *и, у, ү* сузыкларына тәмамланган фигыль нигезләренә ялгана. *-ыштыр/-ештер* кушымчасы *и, у, ү* сузыкларыннан башка сузыкларга тәмамланган фигыль нигезләренә ялгана.

***-гала/-гәлә (-кала/-кәлә)* кушымчасы.** Яңгырау тартыкларга тәмамланган фигыль нигезләренә *-галә/-гәлә (кил+гәлә, бар+гала, йөр+гәлә, сал+гала),* саңгырау тартыкларга тәмамланган фигыль нигезләренә *-кала/-кәлә (тот+кала, эт+кәлә)* ялгана.

*-гала/-гәлә* кушымчасы фигыльләргә ялганып, эш-хәрәкәтнең башкарылу ысулын ачыклый. Ул түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерә:

1. Тәкрарлы, әмма даими булмаган эш-хәрәкәтне: *Вакыты-вакыты белән о ч р а ш к а л ы й б ы з* (Ш. Усманов). *Күрше авылның атлары белән я р ы ш к а л ы й м* (Г. Ибраһимов).

2. Тулысынча булмаган, өстән-өстән генә булган эш-хәрәкәтне*: Аннан башка да аз-маз ансын-монсын б е л г ә л и б е з* (Ш. Камал). Бу кушымча татар телендә дәрәҗә мәгънәләрен белдерүдә шактый киң кулланыла.

***-ыштыр/-ештер* кушымчасы.** Әйтелгәнчә, *-штыр/-штер* кушымчасы сузыкларга тәмамланган фигыль нигезләренә ялгана: *укы+штыр, эшлә+штер.* Ул түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерә:

1. Тулы булмаган, өстән-өстән генә башкарыла торган эш-хәрәкәтне: *Мин ч и т л ә ш т е р е п сораган идем* (Г. Ибраһимов). *Мине дә б у т а ш т ы р д ы ң м ы н и ?* (Ш. Камал).

2. Тәкрарлы, әмма даими булмаган, өстән-өстән генә башкарыла торган эш-хәрәкәтне*: Гөлбикә аны бераз т и р г ә ш т е р г ә н и д е* (Ш. Камал.)

Татар телендә *-гала/-гәлә (-кала/-кәлә)* һәм *-штер/-штер* кушымчалары бергә дә килергә мөмкин. Әгәр дә фигыль нигезенә *-гала/-гәлә (-кала/-кәлә)* ялганса, бу очракта аңардан соң *-штыр/-штер* кушымчасы килә *(бар+гала+штыр, килә+гәлә+штер).* Һәм киресенчә, әгәр фигыль нигезенә *-штыр/-штер* ялганган булса, ул вакытта аңардан

соң *-гала/-гәлә (-кала/-кәлә)* ялгана *(укы+штыр+гала, сөйлә+штер+гәлә)*. Күренгәнчә, бу формалар эш-хәрәкәтнең өстән-өстән генә яки бик сирәк башкарылуын белдерә.

Бу кушымчалар чиратлашып ике, өч, теоретик яктан хәтта күбрәк тә ялганырга мөмкин: *укы+штыр+гала+штыр, эшлә+штер+гәлә+штер+гәлә*. Бу очракта эш-хәрәкәтнең бик сирәк һәм җиренә җиткерелмичә, сыйфатсыз башкарылуы белдерелә. Бу кушымчалар тезмә фигыльләр белән дә килергә мөмкин, алар тезмә фигыльнең хәл фигыленә дә (ягъни төп фигыльгә дә), модификацияләүче фигыленә дә ялганырга мөмкин: *Айсылу... баядан бирле к а р а ш т ы р г а л а п к и л г ә н хатны ача башлады* (Г. Бәширов). *Гәрәйнең... Андрей Петровичка б у л ы ш к а л а п й ө р ү е н ә бер елдан артык вакыт узып китте* (К. Нәҗми). *Син кияүләргә ш а л т ы р а т к а л а п т о р* (Г. Әпсәләмов). Мисаллар күрсәткәнчә, сирәк һәм даими булмаган эш-хәрәкәт белдерелә.

Бу кушымчалар, шулай ук, тезмә фигыльнең икенче өлешенә, ягъни модификацияләүче фигыльгә дә ялганырга мөмкин: *Еш кына, эчемнән генә ү к с е п к у й г а л а д ы м* (Ә. Еники). *Кайбер иптәшләр шулай к и л е п ч ы к к а л ы й* (К. Нәҗми). Бу мисаллардагы тезмә фигыльләр эш-хәрәкәтнең бик сирәк башкарылуын тәгъбир итәләр.

***-мсыра/-мсерә* кушымчасы.** Бу кушымча продуктив түгел, бары берничә генә фигыль нигезенә ялгана ала. Ул фигыльгә ялганып, эш-хәрәкәтнең җиңелчә генә башкарылуын белдерә: *көлемсерә, йокымсыра.*

***-ынкыра/-енкерә* кушымчасы.** Бу кушымча әдәби телдә сирәк, диалектларда күбрәк очрый. Ул түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерә:

1. Пространстводагы өлешчә хәрәкәтне: *Бераз б а р ы н к ы р а.*

2. Эш-хәрәкәтнең бары өлешчә генә чагылуын: *Бу кыяфәте белән хирург профессорга о х ш а н к ы р ы й* (К. Нәҗми). *Писарьлар бераз и с ә н к е р ә г ә н н ә р* (Г. Әмиров). *Тәрҗемәдә эмоциональ бизәк җ и т е н к е р ә м и* (Ш. Рамазанов).

**Фигыль формаларын кабатлау юлы белән белдерелгән дәрәҗә мәгънәләре.** Бер үк фигыль формаларын кабатлау, ягъни редупликацияләү юлы белән эш-хәрәкәтне башкаруның төрле ысулларын белдерү – татар теленә хас күренеш. Кабатлаулы фигыль формаларын тезмә фигыльләрдән аера белергә кирәк. Тезмә фигыльләр ике фигыльдән

ясалса, кабатлаулы фигыль бер үк фигыльнең нигезен кабатлау юлы белән барлыкка килә. Фигыль нигезләрен кабатлау билгеле бер схема (модель) белән бара.

Татар телендә дәрәҗә категориясен белдерә торган дүрт төрле редупликацияне (фигыльләрнең кабатлануын) билгеләргә мөмкин: 1) *-а, -ә, -ый, -и, -й* гә тәмамланган хәл фигыльләрнең кабатлануы *(бара-бара, килә-килә, сөйли-сөйли, укый-укый);* 2) *-п* га тәмамланган хәл фигыльләрнең кабатлануы *(сузып-сузып, сугып-сугып, эшләп-эшләп);* 3) сыйфат фигыль формаларының барлыкта һәм юклыкта (асиндентик) кабатлануы *(яуар-яумас, ашар-ашамас, белер-белмәс);* 4) затланышлы фигыль формаларының кабатлануы *(ага да ага, бара да бара).*

Фигыль формаларының кабатлануы яңа лексик берәмлек барлыкка китерми, бары эш-хәрәкәтнең башкарылу дәрәҗәсен генә белдерә.

***-а, -ә, -ый, -и, -ый* гә тәмамланган хәл фигыльләрнең кабатлануы.** Фигыльләрнең бу типтагы редупликациясе татар телендә еш очрый. Ул түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерә:

1) Дәвамлы эш-хәрәкәтне: *Менә Хәйдәр урам буйлап җырлый-җырлый тәрәзәгә килде* (Г. Бәширов). *Ул зур тазда кайнар су белән тәлинкәләрен юа-юа абыйсына яңадан карап алды* (Г. Әпсәләмов).

2) Кабатлаулы (тәкрарлы) эш-хәрәкәтне: *Ул башын чайкый-чайкый берничә тапкыр ботын чабып алды* (А. Расих). *Поезд урман эчләрендә, кечкенә разъездларда туктый-туктый бик озак барды* (Г. Бәширов).

***-п* га тәмамланган хәл фигыльләрнең кабатлануы.** Фигыль формаларының бу төр кабатлануы телдә еш очрамый. Бу форма, кабатлаулы эш-хәрәкәтне белдереп, дәрәҗә мәгънәсен бирә: *Бу тавышсыз дулкыннар эченә ай үзе дә чумып-чумып ала* (Г. Ибраһимов). *Ул догаларын тәңрегә ишеттерим дигән кебек, кычкырып-кычкырып, шәехеннән мәдәт сорый* (Г. Ибраһимов). *Зөбәйдәнең әнисе күлмәк тегә, чәнчеп-чәнчеп ала энәсен* (Һ. Такташ).

**Затланышлы фигыльләрнең кабатлануы.** Бу юл белән кайвакыт эш-хәрәкәтнең башкарылу ысулы белдерелә. Фигыльләрнең кабатлануы дәвамлы яки тәкрарлы эш-хәрәкәтне тәгъбир итә: *Малайлар карап тордылар-тордылар да таралдылар* (Г. Тукай). *Агыйдел тын гына ага да ага* (Г. Гобәй).

**Барлык һәм юклык формаларындагы сыйфат фигыльнең кабатлануы.** Мондый форма сыйфат фигыльләрдә кабатлануның тышкы билгеләре юк. Ул бары бер фигыль формаларының кушылуыннан гына гыйбарәт. Мондый формалар эш-хәрәкәтнең башлануын гына, тулысынча башкарылып җитмәвен белдерә: *Килер-килмәс борын гөрләп матур яз. Ничек бөктең умырзая биленңне? Исәр-исмәс икән таңда җиләс җил, Ничек кызганмадың түктең гөлеңне?* (Дәрдемәнд). *Нәрсә ашар-ашамас утырасың? Явар-яумас яңгырдан куркырга ярамый.*

**Дәрәҗә категориясенең аерым мәгънәләре һәм системасы.** Шулай итеп, лексик-грамматик дәрәҗә категориясенең барлык мәгънәләрен төркемләсәк, эш-хәрәкәт башкарылуының түбәндәге төп дәрәҗәләрен билгеләргә мөмкин:

1) башлану;
2) юнәлү;
3) дәвамлылык;
4) кинәтлек;
5) кабатлану;
6) нәтиҗәлелек;
7) тәмамланганлык;
8) эш-хәрәкәтнең өлешчә башкарылуы.

Бу дәрәҗәләрнең һәрберсе, белдерелү ысулына карап, берничә төсмер тәгъбир итәргә мөмкин.

**1. Эш-хәрәкәтнең башлануы.** Татар телендә эш-хәрәкәтнең башлануы *-а, -ә, -ай, -и, -й* гә тәмамланган хәл фигыльләргә *башлау* модификацияләүче фигыле, *п* га тәмамланган хәл фигыльләргә *җибәрү, китү* кебек модификацияләүче фигыльләр кушылып белдерелә: *Яз җитеп карлар эри башлады* (Г. Тукай). *Алмаев язып бетерде дә урынынан торып, кабинет буйлап йөреп китте* (И. Гази). *Марианна полякча сөйләп җибәрде* (Ш. Усманов).

**2. Эш-хәрәкәтнең юнәлеше.** Бу дәрәҗә татар телендә *чыгу, керү, килү, китү, бару* кебек модификацияләүче фигыльләр ярдәмендә ясалган тезмә фигыльләр белән белдерелә:

а) эш-хәрәкәтнең сөйләүчедән яки чыгу ноктасыннан берәр якка юнәлүе. Бу очракта тезмә фигыльләр *китү* модификацияләүче фигыле

белән килә: *Һәм Мансурның әнисен, приклад белән бәргәләп, урманга таба а л ы п  к и т т е л ә р* (А. Расих);

ә) эш-хәрәкәтнең сөйләүчегә яки берәр предметка таба юнәлүе. *Нәгыймә атка абзардан печән  к ү т ә р е п  к и л ә  и д е* (Г. Ибраһимов);

б) эш-хәрәкәтнең берәр нәрсәнең эченнән тышка юнәлүе. Бу дәрәҗә *чыгу* фигыле белән килгән тезмә фигыль ярдәмендә белдерелә: *Әнә тегесен дә  а л ы п  ч ы к т ы л а р* (М. Гафури);

в) эш-хәрәкәтнең берәр нәрсәнең эченә юнәлүе. Бу дәрәҗә *керү* дигән модификацияләүче фигыль ярдәмендә ясалган тезмә фигыль белән белдерелә: *Өйгә  б а р ы п  к е р д е м , анда әни каршылады. Таш стеналарны  ү т е п  к е р ү ч е  бу көчнең сере нәрсәдә?* (Г. Ибраһимов);

г) эш-хәрәкәтнең үтеп барышлый башкарылуы. Бу дәрәҗә *узу, үтү* кебек модификацияләүче фигыльләр ярдәмендә ясалган тезмә фигыльләр белән белдерелә: *Улларының, кияүләренең сугыштанниләр язуын  б е л е ш е п  у з а* (Г. Бәширов).

**3. Эш-хәрәкәтнең яки халәтнең дәвамлылыгы.** Бу дәрәҗә: а) *яту, утыру, йөрү, тору, бару, килү, чыгу, бирү* кебек модификацияләүче фигыльләр белән ясалган тезмә фигыльләр ярдәмендә; ә) *-а, -ә, -й, -и* гә тәмамланган хәл фигыльләрнең кабатлануы белән белдерелә. Мәгънәләре:

а) берәр затка яки предметка хас гадәти халәт. Бу дәрәҗә *тору, яту* кебек модификацияләүче фигыльләр ярдәмендә ясалган тезмә фигыльләр белән белдерелә: *Елга читендә су эченнән үләннәр  ч ы г ы п  т о р а* (М. Максуд). *Түбәндә авыл  җ ә е л е п  я т а ;*

ә) өзлексез, дәвамлы яки чагыштырмача дәвамлы эш-хәрәкәт. Бу дәрәҗә *утыру, яту, бару, бирү, тору, йөрү, чыгу* кебек модификацияләүче фигыльләр белән ясалган тезмә фигыльләр, затланышлы фигыльләрнең һәм *-а, -ә, -й, -и* гә тәмамланган хәл фигыльләрнең кабатлануы белән белдерелә: *Бу яктан караганда язучы гаҗәп тынгысыз тормыш  а л ы п  б а р а* (Ф. Хөсни). *Еллар  у з а  б и р д е* (Г. Бәширов). *Бераз вакыт заводта  э ш л ә п  й ө р д е . Төн буе  с ө й л ә ш е п  ч ы к т ы к . Агыйдел тын гына  а г а  д а  а г а* (Г. Гобәй). *У к ы й - у к ы й  баш авыртып китте. Мичкә  а г ы п  у т ы р а . Безнең улыбыз шәһәрдә  у к ы п  я т а ;*

б) үзенең чигенә бара торган дәвамлы эш-хәрәкәт. *-п* кушымчалы хәл фигыльләргә *бару, килү* кебек модификацияләүче фигыльләр

кушылып ясалган тезмә фигыльләр ярдәмендә белдерелә: *Тоз б е т е п к и л ә . Яше җитмешкә җ и т е п б а р а ;*

в) даими рәвештә көчәя, үсә барган эш-хәрәкәт. *-а, -ә, -ый, -и* гә тәмамланган хәл фигыльгә *бару* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыль ярдәмендә белдерелә: *Тормыш я х ш ы л а н а б а р а . Киндер кояшта а г а р а б а р а .*

**4. Кыска вакыт эчендә башкарыла торган эш-хәрәкәт**. *-ып/-еп, -п* кушымчалы хәл фигыльгә *алу* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыль ярдәмендә белдерелә: *Заводта э ш л ә п а л - д ы м . Китап у к ы п а л д ы м .*

**5. Күп мәртәбәләр кабатлаулы (кабатланулы) эш-хәрәкәт.** Эш-хәрәкәтнең күп мәртәбәләр кабатлануы түбәндәге чаралар ярдәмендә бирелә: а) *-а, -ә, -й, -и* һәм *-п* кушымчалы хәл фигыльләргә *бару, килү, тору* кебек модификацияләүче фигыльләр кушылып ясалган тезмә фигыльләр белән; ә) *-а, -ә, -й, -и гә б*еткән хәл фигыльләрнең кабатлануы аша; б) *-п* кушымчалы хәл фигыльләрнең кабатлануы ярдәмендә. Болар түбәндәге дәрәҗә мәгънәләрен белдерәләр.

а) күп мәртәбәләр кабатлана торган даими эш-хәрәкәт: *Мин эшемнең һәр үрнәген я з ы п т о р д ы м аларга* (М. Җәлил). *Милләтнең теле юк, гәзит кирәк диделәр – еллар буенча аңа т ү г ә б а р - д ы к* (Г. Ибраһимов). *Поезд урман эчләрендә, кечкенә разъездларда т у к т ы й - т у к т ы й бик озак барды* (Г. Бәширов). *Бабай вакыт-вакыт к ы ч к ы р ы п - к ы ч к ы р ы п җибәрә. Аны к и с ә т ә к и л - д е л ә р . Мин моны сиңа ә й т ә к и л д е м . Килгәне бер к и т ә б а р д ы ;*

ә) күп мәртәбәләр кабатлана торган, әмма даими булмаган эш-хәрәкәт. Бу дәрәҗә мәгънәсе *-гала/-гәлә (-кала/-кәлә)* һәм *-ыштыр/-ештер* кушымчалары белән белдерелә: *Вахит безгә к и л г ә л и . Химия журналларын да у к ы ш т ы р а м .*

**6. Эш-хәрәкәтнең яки халәтнең өлешчә башкарылуы.** Дәрәҗәнең бу мәгънәсе а) *-а, -ә, -й, -и* гә тәмамланган хәл фигыльләргә *төшү, язу* кебек модификацияләүче фигыльләр һәм *-п* кушымчалы хәл фигыльләргә *карау, багу* (диал.), *язу* кебек модификацияләүче фигыльләр кушылып ясалган тезмә фигыльләр белән; ә) *-ынкыра/-енкерә, -ымсыра/-емсерә, -штыр/-штер, -гала/-гәлә (-кала/-кәлә)* кушымчалары кушылып ясалган фигыльләр ярдәмендә; б) барлык һәм юклык

формасындагы сыйфат фигыль формаларының бергә килүе аша белдерелә. Алар түбәндәге дәрәҗә мәгънәләренә ия:

а) эш-хәрәкәтнең өлешчә генә, җиңелчә генә башкарылуы. Бу мәгънә *-а, -ә, -й, -и* гә тәмамланган хәл фигыльләргә *төшү* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр һәм *-ынкыра/-енкерә* кушымчалы фигыльләр ярдәмендә белдерелә: *Егет бераз а п т ы р ы й  т ө ш т е. Бомба шартлаудан без бераз и с ә н к е р ә д е к. Базар бераз җ а н л а н а  т ө ш т е;*

ә) эш-хәрәкәтнең бик аз гына чагылуы, тулы көч белән бармавы. Дәрәҗәнең бу мәгънәсе *-гала/-гәлә (-кала/-кәлә), ымсыра/-емсерә, штыр/-штер* кушымчалы фигыльләр һәм барлыкта яки юклыкта килгән сыйфат фигыльләрнең бергә килүе белән белдерелә: *Аннан башка да аз-маз ансын-монсын б е л г ә л и б е з* (Ш. Камал). *Менә журнал у к ы ш т ы р а м  әле. Мансур сүрән генә к ө л е м с е р ә д е. Я в а р - я у м а с  яңгырдан куркырга кирәк түгел;*

б) эш-хәрәкәтнең башлану белән үк тукталуы, өзелүе. Дәрәҗәнең бу мәгънәсе *-а/-ә,-ый/-и* кушымчалы хәл фигыльләргә *язу* модификацияләүче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр белән белдерелә: *Гали е г ы л а  я з д ы. Айрат шәһәргә  к и т ә  я з д ы;*

в) эш-хәрәкәтне башкарып карау, сынап карау. Дәрәҗәнең бу мәгънәсе *-п* га тәмамланган хәл фигыльләргә *карау, багу* (диал.) кебек модификацияләүче фигыльләр кушылып ясалган тезмә фигыльләр белән белдерелә: *Шигырь я з ы п  к а р а д ы  Мансур. Син я с а п  б а к.*

**7. Кинәт башланып киткән кискен эш-хәрәкәт.** Бу мәгънә *-п, -ып/-еп* кушымчасына тәмамланган хәл фигыльләргә *җибәрү, салу, китү, ташлау, кую, алу* кебек модификацияләүче фигыльләр кушылып ясалган тезмә фигыльләр белән тәгъбир ителә. Бу дәрәҗәгә түбәндәге мәгънәләр карый:

а) кинәт һәм тиз башкарылган эш-хәрәкәт. Бу мәгънә *-п* га тәмамланган хәл фигыльләргә *җибәрү, китү* кебек модификацияләүче фигыльләр кушылып ясалган тезмә фигыльләр ярдәмендә белдерелә: *Солдат к ы ч к ы р ы п  җ и б ә р д е* (Ш. Камал). *Зал я к т ы р ы п  к и т т е. А к т ы  к и т т е  күз яшем;*

ә) кинәт һәм көтелмәстән башкарылган эш-хәрәкәт. *-п* га тәмамланган хәл фигыльләргә *калу, салу, төшү* кебек модификацияләүче фигыльләр кушылып ясалган тезмә фигыльләр ярдәмендә белде-

реләː *Нигә моны әйтеп салдың? Туташ аптырап калды* (Г. Ибраһимов). *Хәдичә... каушап төште* (Г. Бәширов);

б) кинәт яки кискен рәвештә бер генә мәртәбә башкарылган эш-хәрәкәт. Дәрәҗәнең бу мәгънәсе *-п* га тәмамланган хәл фигыльләргә *алу, кую* кебек модификацияләүче фигыльләр кушылып ясалган тезмә фигыльләр белән белдерелә: *Гыйльманов... сикереп куйды* (И. Гази*). Күршем миңа карап алды.*

**8. Эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсе, тәмамлануы.** Бу дәрәҗә *-п* га тәмамланган хәл фигыльләргә *алу, бетерү, бетү, бирү, калу, китү, кую, чыгу, чыгару, узу, үтү, җитү* кебек модификацияләүче фигыльләр кушылып ясалган тезмә фигыльләр ярдәмендә тәгъбир ителә. Ул түбәндәге мәгънәләргә һәм мәгънә төсмерләренә ия:

а) эш-хәрәкәтнең тәмамлануы, тулысынча башкарылуы. Бу мәгънә *-п* га тәмамланган хәл фигыльләр *бетерү, бетү, чыгу, узу, үтү* кебек модификацияләүче фигыльләргә кушылып ясалган тезмә фигыльләр белән белдерелә: *Китапны укып бетердем. Урман каравылчысы үзенең биләмәсен йөреп чыкты. Бу турыда яңадан сөйләп үттек;*

ә) нәтиҗәле эш-хәрәкәт. Бу дәрәҗә мәгънәсе *-п* га тәмамланган хәл фигыльләргә *алу, бетерү, бетү, бирү, кую, чыгу, чыгару, җитү, җиткерү* кебек модификацияләүче фигыльләр кушылып ясалган тезмә фигыльләр ярдәмендә белдерелә: *Идәндәге чүп-чарны себереп алды. Ялгышын сизеп алды. Мичкәдән су агып беткән. Билетларны сатып бетергәннәр. Утын ярып куйдык. Бу хәлдән түбәндәге нәтиҗә килеп чыга. Күпме материал кирәклеген исәпләп чыгарганнар. Су җылынып җитте;*

б) нинди дә булса үзенчәлек, сыйфат барлыкка килү. Дәрәҗәнең бу мәгънәсе *-п* га тәмамланган хәл фигыльләргә *китү* дигән модификацияләүче фигыль кушылып ясалган тезмә фигыльләр белән белдерелә: *Үләннәр яшелләнеп китте. Алар соңгы вакытта дуслашып киттеләр;*

в) берәр халәт барлыкка килеп, эш-хәрәкәт тукталып калу. Бу дәрәҗә *-п* га тәмамланган хәл фигыльләргә *калу* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр белән белдерелә: *Сискәнеп безнең егет, катып кала аягүрә* (Г. Тукай). *Өчесе дә тынып калдылар* (Г. Гобәй);

г) кискен башкарылган нәтиҗәле эш-хәрәкәт. Бу мәгънә *-п* га тәмамланган хәл фигыльләргә *ташлау, ату* кебек ярдәмче фигыльләр кушылып ясалган тезмә фигыльләр белән белдерелә: *Дустыма хат я з ы п  а т т ы м . Ул тиз генә бер уенчык  э ш л ә п  т а ш л а д ы .*

д) субъектны яки предметны тулысынча чолгап алган эш-хәрәкәт. Бу мәгънә *-п, -ып/-еп* кушымчалы хәл фигыльләргә *бетү* ярдәмче фигыле кушылып ясалган тезмә фигыльләр белән белдерелә: *Көтә-көтә з а р ы г ы п  б е т т е м ;*

е) берничә предметка яки затка караган яисә предметның бөтен өслегенә таралган эш-хәрәкәт. Бу мәгънә *-п, -ып/-еп* кушымчалы хәл фигыльләргә *чыгу, бетеру* кебек ярдәмче фигыльләр кушылып ясалган тезмә фигыльләр белән белдерелә: *Китәр алдыннан ул барыбызны да  ү б е п  ч ы к т ы . Альбомның өч битенә рәсемнәр  я б ы ш т ы - р ы п  б е т е р г ә н ;*

ж) берәр предметка яки берәр нәрсәнең чигенә барып җитә торган эш-хәрәкәт. Дәрәҗәнең бу мәгънәсе *-п, -ып/-еп* кушымчалы хәл фигыльләргә *җитү, җиткерү* кебек модификацияләүче фигыльләр кушылып ясалган тезмә фигыльләр белән белдерелә: *Алар чатка  б а - р ы п  җ и т т е л ә р .*

**Хәрәкәт фигыльләре ярдәмендә эшнең субъект-объектка карата юнәлешен (ориентациясен) белдерү**

Хәрәкәт фигыльләренең ярдәмче рольдә килүен мәгънә төзелешләренә бәйләп өйрәнү нәтиҗәсендә аларның татар теле өчен хас булган тагын бер үзенчәлекле күренеше ачылды: алар эшнең һәм хәрәкәтнең субъект һәм объектка карата ориентациясен, ягъни субъект-объектка карата юнәлешен (урын-ара мөнәсәбәтен) билгеләүдә катнашалар. Мондый функциянең әлегә кадәр аерым каралмавының сәбәбе, беренчедән, татар телендәге ярдәмче фигыльләрнең вазифасы рус телендәге вид категориясе белән чагыштырып өйрәнелде; икенчедән, субъект-объект ориентациясен белдерүче аналитик фигыльләр, еш кына, эшнең ысулын белдерүче фигыльләр белән омонимия мөнәсәбәтенә керәләр, һәм бу очракта аларны контекстта гына аерып була.

Ф. Ганиев беренче китабында, һәр ярдәмче фигыльнең эш ысулларын белдерүдәге вазифасын күрсәткәндә, кайбер хәрәкәт фигыльләренең юнәлешне белдерүен дә әйтә һәм биш хәрәкәт фигыле белән мисаллар китерә; *менеп барабыз* – билгеле юнәлештә үтәлә торган эш

[Ганиев Ф., 1963, с. 135]; *кайтып керде* – эшнең эчкә юнәлүен белдерә [шунда ук, б. 138]; *кайтып килә* – предметка яки сөйләүчегә юнәлгән эш [шунда ук, б. 138]; *чыгып киттеләр, алып киттеләр* – чыгыш урыныннан яки сөйләүчедән ераклашу юнәлешендәге эш [шунда ук, б. 139]; *җит-* – эшнең объектка яки чиккә җитүен [шунда ук, б. 145] белдерә.

Хәрәкәт фигыльләре белән ясалган аналитик фигыльләр башкорт телендә Ә. Юлдашев тарафыннан тикшерелә. Ул хәрәкәт фигыльләренең *-п бар-, -п кил-* рәвешендә ясалган формаларында ахырдагы хәрәкәт фигыльләренең лексик мәгънәсе өлешчә саклануын, ә бары тик *-п* кушымчалы хәл фигыльнең генә тулысынча десемантизациягә (грамматик мәгънәсен югалтуга) дучар булуын раслый: *менеп бара, төшеп килә, китеп бара, кереп бара, кереп килә* [Юлдашев А., 1977, с. 126]. *-п кит-* компонентлары белән ясалган төрне тикшергәндә, автор ярдәмче фигыльнең кайбер кушма фигыльләрдә тулысынча лексик мәгънәсен югалтып грамматикалашкан булуын (*дәртләнеп кит-, кызып кит-* һ.б.) [шунда ук], икенче очракта *(кайтып кит-, килеп кит-* кебек төрләрдә) компонентларның копулятив, ягъни синтаксик яктан тигез мөнәсәбәттә торуын күрсәтә [шунда ук, б. 127], һәм бөтеннең лексик мәгънәсе фигыльләр суммасына туры килмәгәнгә, аларны, гадәттә, кушма фигыльләргә кертүен әйтә [шунда ук, б. 207].

Әйтеп үтелгән фикерләр хәрәкәт фигыльләре белән ясалган аналитик фигыльләрне өйрәнгәндә төп игътибар аларның урын-ара ориентациясен ачыклауга түгел, ә бәлки аларның грамматикалашу дәрәҗәсенә һәм тел күренешләре арасында урыннарын ачыклауга юнәлгән булуын дәлилли.

Д. Насилов борынгы төрки телләрдәге ярдәмче фигыльләрне тикшереп, аларның өч төрле функциясен билгели: 1) эшнең тәмамлануын, 2) эшнең тәмамланмавын, ягъни дәвамлы булуын һәм 3) эшнең урын-ара ягъни **субъект-объект ориентациясен** белдерү [Насилов Д., 1978, с. 122]. Соңгы күренеш аерым бирелсә дә, әле җитәрлек тикшерелмәгән. Эш ысулын белдерүгә китерелгән мисаллар арасында *tezip bardï – йөгереп китте* [шунда ук, б. 116], *ertip bar- – үтеп бар-* [шунда ук, б. 116], *kirip kel- – кереп кил-, janïp kel- – кайтып кил-* [шунда ук, б. 117], *qacïp ket- – качып кит-* [шунда ук, б. 118], *sürä kel- – куып кил-* кебек **юнәлешне** белдергәннәре дә бар.

1993 елда басылган Татар теленең академик грамматикасында (II том) Ф. Ганиев ярдәмче фигыльләрнең эш ысулын ачыклый. Анда ул **хәрәкәт юнәлешен** билгели торган *чыгу, керү, килү, китү* фигыльләре белән ясалган **эш ысулларын күрсәтә:** 1) сөйләүчедән яки чыгыш ноктасыннан билгеле юнәлештә үтә торган эшне белдерү: *алып китү, чыгып китү;* 2) сөйләүчегә яки предметка юнәлгән эшне белдерү: *якынлашып килү, кайтып килү;* 3) эчтән тышка юнәлгән эшне белдерү: *алып чыгу, тишеп чыгу, бәреп чыгу, ташып чыгу;* 4) тыштан эчкә юнәлгән эшне белдерү: *барып керү, үтеп керү;* 5) юл уңаенда башкарылган эшне белдерү *узу, үтү* фигыльләре белән ясалганы күрсәтелә: *Улларының, кияүләренең сугыштанниләр язуын б е л е ш е п   у з а* (Г. Бәширов) һ.б.ш. [Татарская грамматика, т. II, 1993, с. 187–199]. Әмма эшнең юнәлешен белдерү эшнең үтәлү ысулларына («вид» категориясенә) карамый. «Вид (аспект) – фигыль белән белдерелгән эшнең вакыт эчендә ничек үтәлүен яки бүленешен гомумиләштереп белдерә торган грамматик категория» [Лингвистический энциклопедический словарь, 1990, с. 83].

Димәк, хәрәкәт фигыльләренең урын-ара мөнәсәбәтләрне белдерүгә караган кайбер мәгънәләре Д. Насилов, Ф. Ганиев, Ә. Юлдашев хезмәтләрендә телгә алына, ләкин алар анда фигыльнең **эш ысулы мәгънәләре** итеп каралган.

Тел белемендә башка караш та бар. Ул турыда элегрәк Вл. Насилов һәм Б. Серебренников болай яздылар: «Ярдәмче фигыльләрнең эшнең **урын-ара юнәлешен белдерүдә** кулланылуы бик киң таралган, әмма **мондый тезмәләрнең мәгънәсе вид билгеләренә туры килеп бетми**» [Насилов Вл., 1947, с. 38]. «Фигыльдә белдерелгән **эшнең юнәлеше вид билгеләмәсенә (характеристикасына) карамый**» [Серебренников Б., 1958, с. 26]. Бу хезмәтләр язылганда, төп игътибар төрки телләрдә «вид» категориясенең юклыгын исбат итүгә юнәлгән була. Хәзерге тел белемендә шул рәвешле ярдәмче фигыльләрнең аналитик бөтенгә керткән мәгънәләре (эшнең ахырынача, тулысынча, өлешчә үтәлүе һ.б.) **эшнең үтәлү ысулын** белдерүче мәгънәләр эчендә карала. Эшнең үтәлү ысулын белдерү – **аспектуаль мәгънәгә** карый, чөнки аспектуальлек – эшнең үтәлү характерын һәм вакыт эчендә бүленешен белдерә [Бондарко А., 1983, с. 76). Әмма хәрәкәт фигыльләренең, ярдәмче рольдә килеп, **урын-ара** мөнәсәбәтләрне белдерүе эш ысулы

мәгънәләренә туры килми, һәм алар аерым өйрәнелергә тиеш [Тумашева Д., 1987, б. 202–209].

**Татар телендә эшнең субъект-объектка карата юнәлешен (ориентациясен) белдерү.**

Урын-ара мөнәсәбәтләрне белдерүдә унбишләп хәрәкәт фигыле катнаша: эшнең ысулын белдерүчеләрдән – *кит-, кил-, бар-, чык-, төш-, җит-, үт-, уз-, җиткер-;* аларга тагын берничә хәрәкәт фигыле өстәлә: *мен-, кер-, кайт-* һәм кайбер каузатив фигыльләр: *керт-, китер-, кайтар-, чыгар-.*

Аерым очракларда бу ярдәмче фигыльләр белән ясалган аналитик фигыльләр эшнең үтәлү ысулын түгел, бәлки субъект-объект ориентациясен, ягъни урын-ара мөнәсәбәтләрне белдерәләр.

Төп лексик мәгънәне, эш ысулын белдерүче аналитик фигыльләрдәге кебек, беренче фигыль белдерә. Аңа төрле юнәлештәге хәрәкәтләрне белдерә торган ярдәмче фигыльләр өстәлә: алар төп фигыль мәгънәсен урын-ара мөнәсәбәте ягыннан үзгәртәләр һәм, эш ысулын белдергәндәге кебек, бөтен морфологик күрсәткечләрне үзләренә алалар. Мәсәлән, *чабып килә, йөгереп китә, очып кайткан, йөзеп чыгар, йөгереп керсәләр* һ.б.

Урын-ара мөнәсәбәтне белдерүче аналитик фигыльләр, составындагы төп фигыльнең кайсы семантик төркемчәдән булуына һәм мәгънә үзенчәлекләренә карап, ике зур төркемгә аерыла. Беренче төркемгә төп лексик мәгънәсен **хәрәкәт** фигыльләре белдергән аналитик фигыльләр кертелә. Икенче төркемне төп мәгънәне эш, хәл-торыш фигыльләре белдергән аналитик фигыльләр хасил итә. Ярдәмче фигыль хезмәтен ике очракта да хәрәкәт фигыльләре үти.

**Беренче төркем.** Төп һәм ярдәмче фигыль буларак хәрәкәт фигыльләре кулланыла. Төрле мәгънәдәге хәрәкәт фигыльләре кулланылудан өч мәгънә төркемчәсе барлыкка килә.

1) Төп фигыль буларак хәрәкәтнең ысулын (ни рәвештә үтәлүен) белдереп, юнәлешен белдерми торган фигыльләр килә: *очу, йөгерү, чабу, йөзү, йөрү, тәгәрәү, үрмәләү, мүкәләү, сикерү, атлау, куу* (соңгысы – хәрәкәтне барлыкка китерүче каузатив фигыль). Ярдәмче рольдә исә, хәрәкәт ысулын белдермичә, юнәлешкә генә ишарә итүче фигыльләр килеп, аларга кирәкле юнәлеш мәгънәсен өстиләр. Мәсәлән: *очып килү, очып китү, очып бару, очып менү, очып төшү, очып керү, очып*

*чыгу, очып кайту, очып үтү, сикереп чыгу, сикереп төшү, сикереп менү* һ.б.

*Кара каргалар төркеме ашыга-ашыга, берсен-берсе уздыра-уздыра, каргылдашып бөтенләй түбән генә о ч ы п  ү т т е л ә р* (Р. Төхфәтуллин). *Муеннарын сузып, күкне күзәттеләр: тилгәннәр эскадрильясы о ч ы п  к и л г ә н м е  әллә...* (А. Гыйләҗев). *Чуар кепка о ч ы п  т ө ш т е ... Тәкә алып китеп ч а б ы п  к и т т е ... Бу вакыт Гөлчирә, капканы ачып, ишле генә бер оя казларын к у ы п  к е р т т е* (Р. Төхфәтуллин). *...һәм минем янга, арбадан с и к е р е п  т ө ш е п , Рәшит абый килә. Мин елый идем, Рәшит абый й ө г е р е п  б а р ы п  ат арбасына утырды* (М. Мәһдиев).

Субъект хәрәкәтенең урын-ара ориентациясен белдерү өчен нинди дә булса объект кирәк, чөнки вертикаль яки горизонталь хәрәкәт нindидер объектка мөнәсәбәттә билгеләнә. Ул объект я күздә тотыла (беренче мисалда *каргалар к ү з ә т ү ч е л ә р н е  очып үттеләр, чуар кепка б а ш т а н  очып төште*), я текстта аңа ишарә итүче сүзләр була (*Муеннарын сузып күкне күзәттеләр: тилгәннәр эскадрильясы а л а р г а  т а б а  очып килгәнме әллә...*).

Контекст ярдәмендә *йөгереп йөрү* фигыле әрле-бирле йөгерү төсмерен ала: *Лейтенант Рәшит Әхәтов кулына кечкенә генә төенчек тотып разъездда й ө г е р е п  й ө р и : – Казакълар авылыннан берәр кем юкмы? Гөберчәк авылыннан берәр кеше юкмы?* (М. Мәһдиев).

Бу күренешнең киң таралганлыгын һәм шул ук вакытта чыгармалар булуын күрсәтү өчен тагын мисаллар китерик: *йөгереп килү, йөгереп китү, йөгереп бару, йөгереп чыгу; чабып килү, чабып китү, чабып бару, чабып керү, чабып чыгу; йөзеп китү, йөзеп килү, йөзеп чыгу, йөзеп керү, йөзеп үтү* һ.б.

*Куу* – каузатив хәрәкәт фигыле: ул эшнең нәрсәгә яки кемгә дә булса юнәлтелгән булуын белдерә: *куып китү, куып килү (казларны ике чакрым куып килде), куып бару.* Шул ук фигыль янында каузатив ярдәмче фигыльләр булса, объектларны хәрәкәткә китерү һәм нәтиҗәлелек мәгънәсе барлыкка килә. Чагыштырыгыз: *куып китү – куып җибәрү, куып килү – куып китерү, куып кайту – куып кайтару, куып чыгару – куып кертү.*

Югарыда каралган мисалларда фигыльләр ике бербөтен процессны: беренчесе – лексик мәгънәсе белән хәрәкәтнең ысулын,

икенчесе – шул ук хәрәкәтнең юнәлешен белдерә, һәм алар берьюлы үтәлә.

Бу төр аналитик фигыльләр, киң таралган булуларына карамастан, кайбер очракта башка төрле мәгънә белдерәләр, чөнки эш ысулын белдерүче төп фигыль белән юнәлешне белдерүче ярдәмче фигыль семантик яктан яраша алмыйлар, һәм шул сәбәпле чыгармалар туа. Мәсәлән, эш ысулын (аяк ярдәмендә хәрәкәт итүне) белдергән *йөрү* фигыле *китү* ярдәмче фигыле белән килгәндә, урын-ара мөнәсәбәте түгел, бәлки эшнең башланып китүе, ягъни аспектуаль мәгънә белдерелә: *бала йөреп китте (йөри башлады)*. Шул ук фигыль *бару* ярдәмче фигыле белән (*йөреп бару)* бөтенләй кулланыла алмый; *йөреп килү, йөреп кайту* фигыльләре исә икешәр процесстан тора, ләкин алар, алда каралган фигыльләрдән аермалы буларак, бер-бер артлы башкарыла һәм юнәлешләре белән аерыла: *йөреп (кире) килү, йөреп кайту* (3 нче мәгънәне кара).

2) Икенче очракта төп фигыль булып юнәлешне белдерә торган хәрәкәт фигыльләре килә. Ярдәмче фигыль дә юнәлешле хәрәкәтне белдерә. Бу очракта беренче фигыльдә берәр объектка яки сөйләүчегә карата булган юнәлеш мәгънәсенә өстәп, ярдәмче фигыльдәге хәрәкәт юнәлеше белән икенче бер объектка карата координация (урын мөнәсәбәте) белдерелә. Мәсәлән, *чык-* фигыле ниндидер урын яки объект эченнән (тышка) хәрәкәт итүне, *төш-* фигыле объекттан аска таба хәрәкәт итүне белдерәләр. Ләкин башка объектларга яки сөйләүчегә карата бу хәрәкәтләрнең юнәлеше я якынаю, я ераклашу булырга мөмкин. Әнә шул икенчел юнәлеш ярдәмче фигыльләр белән белдерелә: *чыгып китү* (сөйләүчедән читкә юнәлү), *чыгып килү* (сөйләүчегә таба юнәлү), *чыгып бару; төшеп килү, төшеп китү;* (баскычтан) *төшеп бару; кереп китү*, (каршыма) *кереп килә иде; кайтып китү, кайтып килә* һ.б.

*Хәзер үк урамга, иреккә ч ы г ы п  к и т ә с е  килде... Пальтосын чыгышлый гына эләктереп, баскычтан т ө ш е п  к и т т е* (А. Расих). *Мин капкадан кергәндә, ул өйдән ч ы г ы п  к и л ә  иде* (А. Шамов). *Нәкъ бүгенгедәй, кичке эңгер т ө ш е п  к и л г ә н  чаклар иде* (Р. Төхфәтуллин). *Безнең турыдан у з ы п  к и т т е л ә р . Капка баганасына сөялеп, мин т о р а  и д е м* (М. Мәһдиев*). Әбигә үзенең бүлмә карарга килгәнлеген сөйләде һәм әбинең чакыруы белән аның*

*артыннан м е н е п к и т т е* (Ф. Әмирхан). *...Больница тәрәзәләрен дырылдатып, товар поезды у з ы п к и т т е* (Г. Ахунов). *Тизрәк моннан да чыгарга кирәк! Сүз тәки әллә кайларга юл ярып к е р е п к и т ә р , чыга алмассың* (А. Гыйләҗев). *Театр ишегеннән җил-җил атлап, ... эшләпәсен кулына тоткан... берәү к е р е п к и л ә иде* (А. Гыйләҗев). *Анасы, улын күрә алмаганга үзәкләре өзелеп, бернисез авылга... к а й т ы п к и т ә р иде* (Г. Бәширов).

Югарыдагы мисалда *өйдән чыгу* (беренче ориентация) һәм аннан ераклашу: *чыгып китәсе* (икенче ориентация); *төшеп киту, аска төшү* (беренче ориентация) һәм өстәгеләрдән ераклашу: *төшеп киту* (икенче ориентация) белдерелгән. Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, аналитик фигыльнең беренче өлешендә юнәлешне белдерү өчен *чыгу, төшү, мену, керу, кайту, узу, үту* кебек фигыльләр, икенче юнәлешне белдерү өчен *килү, киту,* сирәгрәк *керү* фигыльләре кулланылган. Алдагы очрактагы кебек, процесслар бер үк вакытта уза: *чыгып килү* (кайдандыр чыгу һәм шул ук вакытта икенче бер объектка, күпчелек очракта сөйләүчегә таба килү, аңа якынлашу). Фигыльләр тигез дәрәҗәле, һәм бөтеннең мәгънәсе икесенең суммасына туры килә.

3) Өченче очракта аналитик фигыль капма-каршы юнәлешле ике фигыльдән тора*: кайтып килү* (мәсәлән, өйгә кайтып, кире килү), *барып килү, килеп киту, менеп төшү, төшеп мену, чыгып керу, кереп чыгу* һ.б. Бу очракта компонентлар тигез хокуклы. Аналитик фигыль белдергән процесс өч фазадан (өлештән) тора. Мәсәлән, өйгә кайтып килү: (а) өйгә кайту, (ә) өйдә булу, (б) чыгып киткән җиргә кире килү. Телдә исә бу ситуациянең ике фазасы: (а) һәм (б) белдерелгән. Мисаллар: *Алайса мин тиз генә өйгә к а й т ы п к и л и м , абыстай* (Г. Галиев). *«Кызымның рәсемен күрсәм, өйгә к а й т ы п к и л г ә н күк булыр идем», ди* (Р. Төхфәтуллин). *Мәликә башлап тузынды, шулай да б а - р ы п к и л е р г ә рөхсәт итте* (А. Шамов). *Машина тиз генә б а р ы п к и л е р г ә җай бирә иде, шунда юнәлдек* (А. Гыйләҗев). *Нык үпкәләгән ахры... Шулай да син аның янына б а р ы п к а й т* (А. Гыйләҗев). *Гали к и л е п к и т к ә н н ә н соң (аның) кәефе кырылып кала... Ә син к е р е п ч ы к к а ч , аның кәефе ничек булыр?..* (А. Гыйләҗев). *Бишалты көнгә булса да, к а й т ы п к и т .*

Мисалларда китерелгән *кайтып килү, барып килү, барып кайту, килеп киту, кайтып киту* фигыльләре мәгънә төзелеше буенча

охшаш, әмма сөйләмдә катнашучыларга яки өченче объектка карата хәрәкәтнең башлангыч ноктасы белән аерылалар:

| | | | |
|---|---|---|---|
| барып | → | кайтып | ← |
| кайту | ← | китү | → |
| барып | → | килеп | ← |
| килү | ← | китү | → |
| кайтып | → | | |
| килү | ← | | |

*«кайтып килү»* – сөйләүчедән икенче объектка *кайту* һәм кире *килү*.

*«килеп китү»* – сөйләмдә катнашмый торган III зат (объект) янына *килү* һәм аннан беренче чыккан җиргә *китү*.

Бу фигыльләр арасында алдагы төркемдәгеләр белән омонимлашып килгәннәре дә бар: 1. а) *Атна саен өйгә кайтып килә иде* (мәсәлән, яши торган җирдән авылга кайтып, анда күпмедер булып, кире килү); ә) *Без очраштык. Ул эштән кайтып килә иде* (Эштән кайтканда, сөйләүчегә якынлашып килү). 2. а) *Ике көнгә кунакка кайтып китте* (антонимнардан торган фигыль: кайтты, ике көн торды һәм кире китте); ә) *Эштән туры өйгә кайтып китте* (кайтканда, эшләгән җирдән ераклашу).

Антонимнардан төзелгән *кереп чыгу* һәм *чыгып керү* фигыльләрен дә карап үтик: *Ул аның хәлен белмәде... рәсми кеше буларак та бер кереп чыкмады* (Ф. Хөсни). *– Нәзирә өйдәме? – Бу вакытта ишек ачмыйбыз. – Нәзирә, бәлки үзегез чыгып керерсез?* (Д. Зөбәерова). *Керү* һәм *чыгу* фигыльләре – чикле, капма-каршы юнәлешле һәм аларны бергә хәл фигыль ярдәмендә бәйләү процессларның үтә тиз алмашуына ишарә итә һәм аспектуаль характеристика тудыра.

Фәнни хезмәтләрдә мондый фигыльләр төрлечә бәяләнә. Ә. Юлдашев башкорт телендә *барып кил-, барып кайт-, кереп сык-* кебек «тигез дәрәҗәле компонентлардан торган» фигыльләрне аерып чыгара, әмма аларны кушма сүзгә кертү бәхәсле икәнлеген әйтә, чөнки хәл фигыль үз функциясендә килә, компонентлары да үз мәгънәсен саклаганнар. Ләкин шундый ук төзелештәге *килеп кит-* фигыле турында

«компонентлары копулятив мөнәсәбәттә, үз мәгънәсендә килә», дип әйтсә дә, «аларны, гадәттә кушма сүзләргә кертәләр», дигән нәтиҗә ясый [Юлдашев А., 1977, с. 104].

Кайбер галимнәр мондый фигыльләрнең иректе бәйләнештәге ике сүздән торуын һәм «бер-бер артлы яки параллель үтәлә торган эшләрне белдерүен» әйтә: *Бала тудыру йортына кереп чыкты* (Г. Әпсәләмов). – Вошла в родильный дом и вышла. *Шәһәргә барып кайттым.* – Съездил в город. «Бу урында сүзләр тезмәсе русчага бер сүз белән тәрҗемә ителгән, әмма бу – татар телендә аның бер кушма сүз икәнен дәлилләми» [Ганиев Ф., 1982, с. 97]. Әлбәттә, рус теленә бер яки ике сүз белән тәрҗемә итүнең татар телендә кушма сүз белән сүзтезмәне аеру өчен бернинди әһәмияте юк. Шулай да авторның фикере белән килешеп булмый. Моны исбатлау өчен бу аналитик фигыльне (аналитик тезмәне) юклык төренә куеп карау да җитә: *Бала тудыру йортына кереп чыкмады.* Икенче фигыльдәге юклык кушымчасы «бөтен»не инкяр итә: *кереп чыкмады,* ягъни *кермәде.* Бу фигыльләрне бер-бер артлы үтәлә торган тигез дәрәҗәле эшләрне белдерә дип карасак (*керде* һәм *чыкты*), юклыкта аны болай аңларга туры килер иде: *Бала тудыру йортына керде һәм чыкмады.* Ләкин югарыда китерелгән мисалда сүз кыска вакытка гына кереп чыгу турында бара, һәм бу мәгънәне капма-каршы юнәлештәге чикле фигыльләрнең янәшә торуы барлыкка китерә. Әлеге ситуациянең өч өлешеннән (а) *керү,* ә) *кергән җирдә булу,* б) *чыгу*) икесе генә (а) һәм (б) белдерелгән. Кергән җирдә субъектның күпме калуы билгесез, шуңа күрә татар телендә бу җөмләне ике төрле аңларга була: 1) *Бала тудыру йортына* (тиз генә) *кереп чыкты;* русчасы: «Она зашла ненадолго в родильный дом». 2) *Бала тудыру йортына кереп чыкты* (кыска вакытка булса да анда булырга туры килде); русчасы: «Она побывала в родильном доме».

Әлбәттә, аналитик төзелештәге мондый фигыльне компонентларының мәгънә бәйләнешләре югалган (*сатып алу* кебек) фигыльләр белән бер рәткә куеп булмый. Аларны эш ысулын белдерүче фигыльләр белән чагыштырып була: төп мәгънәне – беренче компоненты, өстәмә мәгънәне (бу очракта юнәлеш мәгънәсен) – ярдәмче фигыль белдерә: *Бәлки үзегез чыгып керерсез,* төп мәгънә – *бәлки, үзегез чыгарсыз. Чыгып керерсез* дигәндә, юнәлеш мәгънәсе өстәлә,

фигыльләр капма-каршы һәм чикле булганга, аспектуаль, ягъни, тизлек мәгънәсе туа.

**Икенче төркем.** Төрле мәгънәдәге фигыльләрнең, юнәлешле хәрәкәт фигыле белән килеп, субъект-объект ориентациясен (урын-ара мөнәсәбәтләрен) белдерүләре аналитик фигыльләрнең икенче төркемен хасил итә.

1) Төп фигыльдән соң булган хәрәкәтне *кит-* ярдәмче фигыле белдерә: *Шамгун картта азмыни кеше кунак була да, азмыни кеше к у н ы п  к и т ә?* (А. Шамов). *Йөргән кызыңны ятлар ч ә л д е р е п  к и т к ә н н е авыз ачып көтеп торыргамы?* (Г. Бәширов). *Җыенып, ташынып йөрү, бигрәк тә үзен бик кадерләп тота торган бүлмә хуҗалары белән к ү р е ш е п  к и т ү мәсьәләләре аны борчый башлады* (Ф. Әмирхан). *Идрис. Кемнән оялыйм үз өемдә?Җырлыйммы? Тимергазин. И ш е т е п  к и т и м, мин дә җырлармын* (Т. Миңнуллин).

2) Төп фигыльнең *кайт-* хәрәкәт фигыле белән килүе: *Иртәгесен аны кирәкле үләннәр  җ ы е п  к а й т у өчен басуга җибәрде* (Г. Галиев). *Мин флот хезмәтен  ү т ә п  к а й т к а ч, җәй көне велосипедка утырып, еш кына, Казакълар авылы болынына су коенырга төшә идем... Балтыйк диңгезендә йөзеп, чумып,  р ә х ә т  к ү р е п  к а й т к а н  тән су сорый иде* (М. Мәһдиев). Бу мисалдагы *«үтәп кайткач»*ны вакыт хәле дип караганда, ике фигыль дә мөстәкыйль: төп мәгънәне хәрәкәт фигыле – *кайткач* белдерә, аны хәл фигыль – *үтәп* ачыклап килә. Әгәр җөмләнең беренче өлеше су коенырга бару гадәтенең сәбәбен ачыклап, сәбәп хәле булып килсә, *үтәп кайткач* аналитик тезмәдә *үтәп* хәл фигыле – төп мәгънәне, *кайткач* – субъект-объект ориентациясен белдерә.

Бу мисаллларда тасвирланган ситуацияне *барып килү, кайтып килү* кебек антонимнардан торган аналитик фигыльләр белән чагыштырып карарга мөмкин. Әйтеп үтелгәнчә, өч өлештән торган эшнең (мәсәлән, (а) *бару*, барган җирдә (ә) *булу* һәм кире (б) *килү*) бары ике өлеше – (а) һәм (б), ягъни беренче һәм өченчесе күрсәтелгән була: *барып килү*. Югарыда каралган *кунып китү, чәлдереп китү, җыеп кайту* кебек фигыльләр дә өч фазадан тора: *килү, куну, китү; бару* (яки *килү*), *чәлдерү* һәм *китү; бару, үләннәр җыю* һәм *кайту*. Бу очракта (ә) һәм (б) өлешләре белдерелгән. Әмма кайбер очракта өчесе дә була: *Б а р, апа, рәхәтләнеп  я л  и т е п  к а й т!* (Д. Зөбәерова).

*Син к е р , Зиннур,  җ ы л ы н ы п  ч ы к* (Р. Төхфәтуллин) [Гак В., 1971, с. 93]. Шуны да әйтергә кирәк: рус телендә ситуациянең (а) һәм (ә) өлешләре белдерелә, ягъни беренче хәрәкәт һәм төп эш: *прийти переночевать*, татарча – төп эш (ә) һәм аннан соңгы хәрәкәт (б): *кунып китәләр*; русча: *зайди поздоровайся,* татарча: *күрешеп чык;* русча: *пойти собрать ягод,* татарча: *җиләк җыеп кайту* һ.б. Татар телендә төп эш, хәл фигыль формасы белән белдерелгәнлектән, хәрәкәт фигыле белән тыгызрак береккән.

Барлык очракларда да төп эшне һәм хәрәкәтне белдерүче фигыль бер актантка карый, икесе дә реаль, бер-бер артлы үтәлә торган процессларны белдерә. Бу – аларны тигез дәрәҗәгә куя кебек, ләкин төп мәгънәне (эш ысулларын белдерүдәге кебек) беренче фигыль үти. Бу фигыльләрнең синтаксик бәйләнешләренә килгәндә, тәмамлыклар (мәҗбүри актантлар) беренче фигыльгә карый, хәлләр (мәҗбүри булмаган актантлар) икесенә дә карарга мөмкин: *кызыңны чәлдереп киткәнне; хуҗалары белән күрешеп китү; үләннәр җыеп кайткач, таныклык алып чыктык; өйдән үк колакка тукып чыгарды, мине үз бүлмәсенә чакырып китерде* һ.б.

Бәйләнешләрне караганда, тикшерелә торган аналитик тезмәнең бөтенлеге, фигыльләрнең тыгыз бәйләнгәнлеге һәм аларга ияреп килгән сүзләрнең берьюлы икесенә дә нисбәтле икәнлеге күренә. *Мин базардан бер  с ү з  и ш е т е п  к а й т т ы м* (Д. Зөбәерова) җөмләсендә фигыльләрне таркатып, бәйләнешләрне *бер сүз ишетеп, базардан кайттым* рәвешендә аңлау хата булыр иде. Хәбәр итүнең актуальлегенә, яңалыгына килгәндә исә, беренче урынга *ишетү* сүзе куелырга тиеш. *Кайттым* – субъектның төп эштән соң булган хәрәкәт юнәлеше.

Бу төр тезмәләр телдә бик еш очрый:

*– Ашарга утыр. – Рәхмәт, мин  а ш а п  к а й т т ы м* (ашадым).

*Ул шифаханәдә  я т ы п  ч ы к к а н* (яткан).

*– Почта ящигын  к а р а п  м е н  әле, гәзитләр килмәгән микән? (кара әле).*

*– Өстәгеләргә инглиз телендә бер хат килгән. Зинһар өчен  у к ы п  т ө ш с е н  (укысын) әле, дип синнән үтенделәр.*

*Җыелыш буласын  х ә б ә р  и т е п  к и т т е,  классташларына да  ә й т е п  к и л г ә н .*

Хәрәкәт фигыльләре белән ясалган һәм субъектның юнәлешен белдерә торган тезмәләр эш ысулын белдерүче фигыльләр белән омонимлашалар, һәм контекст ярдәмендә генә аларны аерырга мөмкин. Мәсәлән: *Танышларына әйтеп чыкты*. 1. Эш ысулы: һәммәсенә берәм-берәм әйтте (дистрибутив эш). 2. Икенчел хәрәкәт: *кереп, әйтеп, чыкты*; *Йоклап китте:* 1. Эш ысулы: тиз генә йокыга китте. 2. Икенчел хәрәкәт: *килеп, йоклап* (кунып) *китте*; *Карап килде:* 1. Эш ысулы (дәвамлы эш): *Хәсән, чиркәү чатына җиткәнче, шул матур толымның матур селкенүен карап килде дә, чаттан борылып, Лобачевский урамы белән китте* (Ф. Әмирхан). 2. Икенчел хәрәкәт: *Студентларның җыелганмы-юкмы икәнлеген карап килде* (барып, карап, килде).

2. Эш фигыльләре артыннан хәрәкәт фигыльләре килүнең тагын бер очрагы бар. Телдә киң таралган *алып китү, алып килү, алып чыгу, алып кайту, алып керү, алып бару* фигыльләре шулай ук эш һәм юнәлешле хәрәкәт белдерүче фигыльләрдән тора, әмма аларның мәгънә төзелеше югарыда каралган, бер-бер артлы үтәлә торган тезмәләрдән аерыла. Беренчедән, алар ике процесстан тора: *алу* һәм *китү*, *алү* һәм *чыгу*, *алу* һәм *керү*, *алу* һәм *кайту* һ.б. Икенчедән, бу процесслар беренчесеннән башланып, икесе бергә башкарыла һәм бербөтен буларак күз алдына килә. Шул ягы белән алар *кайтып килү, кайтып китү, кайтып бару* кебек берьюлы башкарылган ике процесстан (хәрәкәттән) торган аналитик фигыльләргә охшый. *Алып килү, алып бару, алып керү* һ.б.ш. фигыльләр фонетик һәм лексик яктан да бербөтенгә омтыла. *Ал-* фигыленең бер иҗекле булуы һәм кулланылу ешлыгы моңа ярдәм иткән. Ике фигыль кушылганда, эшне белдерүче фигыль кыскара һәм кушма сүз фонетик яктан да татар телендәге сүз күләменә тәңгәлләшә: *апкитү, апкилү, апкайту* һ.б. Шундый ук төзелештәге озынрак фигыль хәрәкәт фигыле белән кушылмый: *Гариза күтәреп килгән* (*күтәреп киткән, күтәреп чыккан, күтәреп кергән* һ.б.). *Алып* + хәрәкәт фигыльләре калыбында ясалган төр Ф. Ганиев тарафыннан өйрәнелгән [Ганиев Ф., 1982, с. 102]. Ләкин беренче *ап-* өлешен префиксоид дип бәяләү белән килешеп булмый, чөнки префикс сүзнең нигезенә мәгънә вариантлылыгы кертергә, ә нигез үзгәрешсез калырга тиеш: *принести, унести, вынести, занести, внести* һ.б. Татар телендә бөтенгә үзгәреш керткән өлеше – нәкъ азакта

килгән хәрәкәт фигыльләре. Аларның төп сүз азагында килүе татар теленең агглютинатив табигатенә, кушымчаларның сүз азагына ялгану закончалыгына туры килә. Һәм бу фигыльләр төп өлеш белән (*алып → ап*) бербөтен мәгънә белдерә: *апчыгу, аппару, апкилү* һ.б.

Ф. Ганиев эшнең юнәлешен белдерүне эш ысулларына кертә һәм бу күренешнең түбәндәге очракларын китерә:

1. Эшнең сөйләүчедән яки нинди дә булса ноктадан чыгу юнәлешендә үтәлүе (*кит-* фигыле ярдәмендә): *...Мансурның әнисен, приклад белән бәргәләп, урманга таба алып киттеләр* (А. Расих).

2. Эшнең сөйләүче яки берәр предметка таба юнәлеп башкарылуы (*кил-* фигыле ярдәмендә): *Нәгыймә ... атка абзардан печән күтәреп килә иде* (Г. Ибраһимов).

3. Эшнең нәрсәнең булса да эченнән юнәлүе (*чык-* фигыле ярдәмендә): *Әнә тегесен дә алып чыктылар* (М. Гафури).

4. Эшнең эчкә юнәлүе (*кер-* фигыле ярдәмендә): *Өйгә барып кердем, анда мине әни каршылады* (Г. Тукай). *Таш стеналарны үтеп керүче бу көчнең сере нәрсәдә?*

5. Узышлый башкарыла торган эш (*узу, үтү* фигыльләре ярдәмендә): *Улларының, кияүләренең сугыштанниләр язуын белешеп уза* (Г. Бәширов).

Китерелгән мисалларның беренче өчесе «*алып* + хәрәкәт фигыле» калыбында ясалган, дүртенчесе ике юнәлешле фигыльдән тора: *барып керу, үтеп керү.* Бу вакытта беренче фигыльдәге юнәлеш икенче фигыль ярдәмендә башка субъект-объектларга карата өстәмә юнәлеш ала, һәм ул эчкә юнәлү белән генә чикләнми: *үтеп керү, үтеп бару, үтеп китү, үтеп килү* һ.б. *Үтү, узу* фигыльләре нәрсәнеңдер яныннан хәрәкәт итүне белдерсә, *керү, бару, китү, килү* һ.б. фигыльләр шул ук процессның икенче субъект яки предметка карата юнәлешен белдерә: *Пароход Югары Осланны үтеп килә иде* (Югары Осланны *үтү* – беренче ориентация; *килү* фигыле пароходның икенче субъектка (мәсәлән, сөйләүчегә) яки объектка (мәсәлән, пристаньга) якынлашуын да белдерә – икенчел ориентация). *Пароход пристаньне узып бара. Алар күперне узып чыктылар* һ.б. Соңгы мисалда хәрәкәт фигыле субъектның төп эштән соң булган юнәлешен белдерә: *белешеп уза, белешеп китә, белешеп чыга* һ.б. Һәрбер фигыльнең хәрәкәт фигыльләре белән бергә кулланылуыннан күптөрле мәгънәләр

туарга мөмкин, һәм алар арасында эш ысулын белдерү очраклары да бар (узышлый эшләнгән эш).

Шул рәвешчә, югарыда юнәлеш фигыльләре ярдәмендә ясалган һәм урын-ара мөнәсәбәтләрен белдергән ике төркем аналитик фигыльләр каралды: I хәрәкәт фигыле + хәрәкәт фигыле; II эш фигыле + хәрәкәт фигыле.

I төркем а) хәрәкәт ысулын белдергән фигыльләр + юнәлешне белдерүче фигыльләрдән тора*: чабып килү, йөгереп килү, очып бару, шуышып төшү, сикереп чыгу, үрмәләп менү* һ.б.;

ә) төрле юнәлешне белдергән ике хәрәкәт фигыленнән тора: *кайтып керү, менеп бару, төшеп килү, чыгып китү, чыгып бару* һ.б.;

б) капма-каршы юнәлешле ике фигыльдән тора: *кереп чыгу, чыгып керү, кайтып килү (кайтып, кире килү), менеп төшү, төшеп менү* һ.б.

II төркем эш фигыльләре белән хәрәкәт фигыльләреннән тора. Төрле юнәлешне белдерә торган фигыльләр субъектның төп эштән соң булачак юнәлешенә (ягъни субъект-объект ориентациясенә) ишарә итәләр: *Мин аңарда эшләп киттем (эшләп кайттым). Ул заводта эшләп килгән. Теманы аңлатып чыгыгыз* һ.б. Күпчелек очракта хәрәкәт фигыле эш юнәлешен түгел, бәлки субъектның төп эштән соңгы юнәлешен белдерә. Ләкин *күтәреп килү, алып бару* кебек аналитик төрләр берьюлы үтәлгән ике процесстан тора,

Соңгы төрдән *алып* + хәрәкәт фигыльләреннән торганнары кушма сүзгә әйләнгән. Калган очраклардагы тезмәләрне кушма сүз дип карап булмый. Ләкин аларны ирекле сүзтезмәгә дә кертеп булмый. Аларны шартлы рәвештә аналитик фигыльләр яки аналитик тезмәләр дип атап булыр иде.

Бүлекнең беренче өлешендә хәрәкәт фигыльләре ярдәмендә ясалган эш ысуллары каралды. Бу очракта хәрәкәт фигыльләрендәге юнәлеш мәгънәсе (урын-ара мөнәсәбәтләре турындагы информация), абстрактлашып, эшнең вакыт эчендә үтәлү төсмерләренә, ягъни аспектуаль мәгънә белдерүгә җайлаша. Шуңа күрә, эш ысулын белдерүче хәрәкәт фигыльләре, аналитик тезмәләрдә урын-ара мөнәсәбәтләрне белдерүчеләргә караганда, грамматикалашуның югарырак дәрәҗәсендә торалар.

# 5. АЛМАШЛЫК

Алмашлык – башка сүз төркемнәреннән аермалы буларак, объектив чынбарлык күренешләрен атамый, бары тик аларга ишарәле генә торган сүз төркеме. Эчтәлеге, грамматик һәм сүз ясагыч билгеләре ягыннан ул башка сүз төркемнәре белән мөнәсәбәттәш. Кайсы сүз төркеме белән мөнәсәбәттәш булуларыннан чыгып, алмашлыклар исем алмашлыкларына (*мин* – укытучы, *ул* – йорт), сыйфат алмашлыкларына (*шундый* – яхшы), рәвеш алмашлыкларына (*болай* – акрын), сан алмашлыкларына (*берничә* – биш), теркәгеч алмашлыкларына (*кем* – шул, *кайчан* – шунда) һәм кисәкчә алмашлыкларына *(әнә, менә, әле)* бүленәләр. Алмашлыклар шулай ук сүзтезмәләр һәм җөмләләр белән дә мөнәсәбәттәш булырга мемкиннәр: *Т е г е* (кеше) *– җәй көне безгә шатлыклы хәбәр алып килгән* (кеше). *Урып-җыюны безнең колхоз үз вакытында тәмамлады. Б у – авылдашларымның зур уңышы.*

«Рус грамматикасы»нда алмашлыклар, нигездә, үзләре белән мөнәсәбәттәш сүз төркеме составында каралалар. Исемнәрне алмаштырып килгәннәре генә аерым сүз төркеме буларак бүленеп чыгарылалар. Татар тел белемендә алмашлыклар традиция буенча күптәннән аерым мөстәкыйль сүз төркеме итеп каралалар. Ләкин биредә эзлеклелек сакланып бетмәгән: башка сүз төркеме белән мөнәсәбәттәш, күрсәтү мәгънәсенә ия булган сүзләрнең бер өлеше алмашлыкларга түгел, алар белән мөнәсәбәттәш сүз төркемнәренә кертелгәннәр. Сүз *анда, шунда, монда, әлеге, ары, бире, берничә, беркайда, берничек, әнә, менә, беркадәр, берникадәр, фәлән, итү, нитү* һ.б.ш. сүзләр турында бара. Татар телендә сүз төркемнәрен системалаштыру логикасы буенча бу сүзләр алмашлыклар составында каралырга тиешләр.

Алмашлыкларның, атама сүзләрдән аермалы буларак, конкрет лексик эчтәлекләре юк. Аларның нинди реаль чынбарлык күренешләренә ишарә итүләре сөйләм ситуациясендә, контекстта гына ачыклана.

Сөйләмдә башка сүз төркемнәрен, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, җөмләләр тезмәсен алмаштырып килә ала торган алмашлыкларны куллану урынсыз кабатлanулардан коткара, сөйләмне кыска, ачык, аңлаешлы итеп формалаштыра.

**Исем алмашлыклары.** Исем алмашлыкларына *мин, син, ул, без, сез, алар, кем, нәрсә, кемдер, әллә кем, нәрсәдер, әллә нәрсә, һичкем, беркем, һичнәрсә, бернәрсә, һәркем, һәрнәрсә, үз* һ.б. алмашлыклар керә. Исем алмашлыклары зат яки предметка, предметлаштырылган билге, сыйфат, эш-хәл, күренешләргә ишарә итә һәм, эзлекле булмаса да, исемгә хас морфологик категорияләргә ия була. Алар килешләр *(без, безнең, безгә, безне, бездән, бездә)* һәм тартым белән *(кемем, кемең, кеме, кемебез, кемегез, кемнәре)* төрләнәләр, берлек һәм күплек санда киләләр *(кем – кемнәр, нәрсәдер – нәрсәләрдер).* Мәсәлән: *Н ә р с ә бу? Төннәр буе н ә р с ә күчереп утырасың син?* (Р. Мөхәммәдиев). *Ярдан кулъяулык болгый-болгый озатып калучылар арасында аның күздән югалганчы карап барырлык б е р к е м е дә юк иде* (Ә. Еники). *Миңа, ничек кенә булса да, кызыллар ягына – ү з е б е з н е к е л ә р г ә барып чыгарга кирәк* (К. Нәҗми). Синтаксик планда исем алмашлыклары башка сүзләр белән исемгә хас бәйләүче чаралар ярдәмендә бәйләнәләр. Кушымчалар ярдәмендә: *аны* (укытучыны) күрү, *аннан* (укучыдан) сорау; бәйлек һәм бәйлек сүзләр ярдәмендә: *аның белән* (апам белән) күрешү, *аның өстенә* (укытучы өстенә) йөкләү; янәшәлек ярдәмендә: *нәрсә* (тырышлык) нәтиҗәсе. Алмашлыклар исемнәрнең баш килештә килүләрен таләп итә торган бәйлек һәм бәйлек сүзләр белән килгән очракларда күзәтелә торган кайбер үзенчәлекләр: *аның белән* (апам белән) күрешү, *аның өстенә* (укытучы өстенә) йөкләнү. Бәйлек һәм бәйлек сүзләр алмашлыкның иялек килешендә килүен таләп итәләр. Бу алмашлыклар шулай ук фигыльгә янәшәлек ярдәмендә иярә алмыйлар.

Исем алмашлыклары җөмләдә исемнәр үтәгән синтаксик функцияләрне – нигездә, ия һәм тәмамлык функцияләрен үтиләр: *К е м кычкыра, к е м г ә кычкыра...– Бакый аңлый алмый* (Г. Әпсәләмов). *Дөрес, а н ы чын ихластан куанып, зурлап каршы алдылар* (Ә. Еники). *Егетнең хәле авыр, уң аягы а н ы ң тездән югары киселгән* (Ә. Еники).

**Сыйфат алмашлыклары.** Аларга *бу, шушы, теге, ул, шул, андый, мондый, шундый, нинди, кайсы, ниндидер, әллә нинди, кайсыдыр, әллә*

*кайсы, фәлән, бернинди, һичнинди, бары, барлык, барча, бөтен, һәммә, һәр, һәрбер, кайбер, әлеге, андагы, мондагы, биредәге* һ.б. керә. Сыйфат алмашлыклары предмет һәм затларның билгеләренә ишарә итәләр, сыйфатлар кебек, исемгә янәшәлек ярдәмендә бәйләнәләр *(бу эш, ниндидер кош, һәр кеше),* бик эзлекле булмаса да, чагыштыру дәрәҗәсе күрсәткечен алып, төгәл булмаган, якынчарак билге мәгънәсен белдерәләр: *андыйрак, мондыйрак, әллә ниндирәк.*

Сыйфат алмашлыклары җөмләдә аергыч һәм хәбәр функцияләрен үтиләр*: Зәйнәпкә өстәл өстенә хат язып калдырамыз: фәлән урамга, фәлән йортка, фәлән өйгә* (Г. Исхакый). *Нишләрләр? Нинди җавап бирерләр* (Г. Әпсәләмов). *Дуслары да шундыйлар аның, Рахметов күк тимер татарлар* (Х. Туфан).

Исемләшкән сыйфат алмашлыклары башка җөмлә кисәге булып та килә алалар. Мәсәлән: *Һәммәсе дә кызык, һәммәсен дә беләсе килә, һәммәсендә дә ниндидер бер сер, яңалык ачылып китәр кебек хис итә идем* (Г. Бәширов).

**Рәвеш алмашлыклары.** Рәвеш алмашлыкларына *ничек, болай, шулай, тегеләй, кайчан, кайда, кайдан, кая, ничектер, әллә ничек, кайдадыр, әллә кайда, кайчандыр, әллә кайдан, каядыр, әллә кая, ник, нигә, нилектән, нишләп, никтер, әллә нигә, берничек, һичничек, беркайда, һичкайда, беркайчан, һичкайчан, беркайдан, һичкайдан, беркайда, һичкайда, беркая, һичкая, әнә, менә, минемчә, синеңчә, аныңча, безнеңчә, сезнеңчә, аларча, үзенчә, шунлыктан, анда, монда, шунда, ары, бире, әле, аннары* һ.б. керә. Рәвеш алмашлыклары эш-хәл яки билге билгесенә ишарә итә һәм рәвешләр кебек, фигыльгә, сыйфатка, башка бер рәвешкә, хәбәрлек сүзгә янәшәлек ярдәмендә бәйләнә һәм, бигүк эзлекле булмаса да, чагыштыру дәрәҗәсе кушымчасы алып, билгенең билгесен якынчалык төсмере өстәп бирә: *ничегрәк, шулайрак, тегендәрәк.* Типик синтаксик функцияләре – хәл һәм хәбәр: *Ул, иң элек, Зәйнәпне читкә чакырып алып, колагына нәрсәдер әйтеп, каядыр йөгертте* (Ә. Еники). *Монда гел шулай инде: әз генә куанычың булырга өлгерми, шунда ук хәсрәт килеп баса* (Ш. Маннур). *Ул аны кулында тегеләй әйләндергән, болай әйләндергән, ләкин укый алмаган* (Г. Әпсәләмов).

**Сан алмашлыклары.** Аларга *ничә, ничәнче, ничәләп, ничаклы, никадәр, күпме, берничә, беркадәр, шулчаклы* һ.б. алмашлыклар керә.

Алар предмет һәм затларның микъдарына, тәртип ягыннан санына ишарә итәләр, саннар кебек, исемнәргә янәшәлек ярдәмендә бәйләнәләр һәм, бик эзлекле булмаса да, сан төркемчәләренең кушымчаларын алалар *(ничә, ничәү, ничәнче, ничәшәр, ничәләп)*. Җөмләдә бу алмашлыклар саннар үтәгән функцияләрне башкаралар – аергыч, хәл, хәбәр булып киләләр: *Әтинең солдаттан алып кайткан б е р н и ч ә әйберсе бар иде* (М. Мәһдиев). *К у п м е булса сездә көч һәм ялкын, Ш у л к а д ә р л е җирдә хаккыгыз* (М. Җәлил). *Киң Россиянең Уралын, Иделен, Донбассын, Себерен авыр ботинкалары белән н и ч ә ш ә р к а т атлап үткән егетләрнең батырлыгын сөйләргә кереште* (К. Нәҗми).

Алмашлыклар мәгънәләре буенча зат, күрсәтү, сорау, билгесезлек, юклык һәм билгеләү алмашлыкларына бүленәләр.

**Зат алмашлыкларына** *мин, син, ул, без, сез, алар* керә. Зат алмашлыклары исемнәр белән мөнәсәбәттәш һәм, бик эзлекле булмаса да, исемгә хас категорияләр белән характерланалар: берлектә һәм күплектә киләләр, килеш һәм тартым белән төрләнәләр.

*Мин* алмашлыгы – сөйләүчене, *син* – тыңлаучыны, *ул* – сөйләмдә катнашмаган яки сөйләм ситуациясе вакытында, гомумән булмаган затны, шулай ук үзе турында сүз барган предметны белдерә. *Без* алмашлыгы сөйләүчене һәм аның тарафыннан нинди дә булса уртак билгеләре буенча бер төркемгә берләштерелгән затларны белдерә. Соңгылары сөйләмдә катнашмаска яки сөйләм моментында, гомумән, булмаска мөмкиннәр. *Сез* алмашлыгы сөйләүче мөрәҗәгать иткән затны, сөйләмдә катнашмаган яки гомумән бу моментта булмаган нинди дә булса уртак билгеләре буенча сөйләүче тарафыннан бер төркемгә берләштерелгән затларны белдерә. *Алар* сөйләмдә катнашмаган затларны һәм алар турында сүз барган предметларны белдерә. Мәсәлән: *М и н , киресенчә, һәркемнең бәхетле булуын телим, – диде ул, үзенең кем белән янәшә барганлыгын искә төшереп* (Р. Мөхәммәдиев). *Ул шундый нәрсә, тик с и н сорама, м и н әйтмим* (Г. Бәширов). *Карасана, дигәннәр, с е з дә колхоз, б е з дә колхоз!* (Г. Бәширов). *Иң беренче сынауларын шунда кичкәннәр а л а р* (Ә. Исхак).

Шулай итеп, зат алмашлыкларында сан категориясе үзенчәлеклерәк чагылыш таба. *Без, сез* алмашлыклары, күплек сандагы исемнәрдән аермалы буларак, *мин, син* алмашлыклары белән белдерелгән затларның гади күплеге генә була алмый, чөнки соңгылары индивидуаль,

кабатланмас, табигатьтә бердәнбер кеше шәхесләре. *Без, сез* алмашлыклары төрле затларның күплеген белдерәләр. *Ул* алмашлыгы теләсә нинди предметны һәм сөйләмдә катнашмаган затны белдерә. *Алар* алмашлыгы аңа бу зат һәм предметларның гади күплеген белдерүче, ягъни күплек саны формасы буларак каршы куела. Шулай итеп, шушы очракта гына грамматик сан категорясе турында сүз алып барып була.

Кайбер зат алмашлыклары, стилистик максатлардан чыгып, башка мәгънәләрдә дә кулланылырга мөмкиннәр. *Без, сез* алмашлыклары бер генә затны белдерә ала: беренчесе – сөйләүчене, икенчесе – тыңлаучыны. Мәсәлән: *Китапның беренче бүлеген б е з бу күренешнең асылын ачыклауга багышладык. Мосафирның йөзенә аптырау һәм шатлык билгеләре йөгерде: – С е з теге шагыйрь Габдулла Тукай түгелдер бит?* (А. Расих).

Тулаем алганда, зат алмашлыкларының килешләр белән төрләнеше исемнәрнеке кебек үк диярлек. Үзенчәлек шунда гына: зат алмашлыкларының кайбер килеш кушымчалары фонетик үзгәрешләргә дучар булганнар. Мәсәлән, иялек килешендә I зат берлек сан зат алмашлыгының кушымчасы *-ем (минем),* II затныкы *-ең (синең),* юнәлеш килешендә *-а (миңа, сиңа),* төшем килешендә *-е (мине, сине).*

III зат берлек сан зат алмашлыгының кыек килеш формалары башка нигездән ясалалар: *ул – аның, аңа, аны, аннан, анда.* Рус теленнән аермалы буларак, татар телендә зат алмашлыкларының супплетивизм күренеше шушы алмашлыклар белән чикләнә.

Зат алмашлыкларында лексик эчтәлекнең каршы торуы нәтиҗәсендә тартым категориясе өлешчә генә чагылыш таба: *ул – анысы, алар – алары.* Ләкин бу алмашлыклар, иялек килеше һәм *-ныкы/-неке* кушымчаларын алып, иялек мөнәсәбәтен белдерүдә катнашалар: *безнең мәктәп, мәктәп безнеке.*

Синтаксик планда зат алмашлыклары үзләрен исемнәр кебек тоталар. Башка сүзләр белен синтаксик бәйләнешкә килеш кушымчалары *(сиңа әйтү, аннан көтү), -сыз/-сез, -дагы/-дәге, -ча/-чә, -дай/-дәй, -ныкы/-неке* кушымчалары *(минсез үти, сездәге китап, минемчә эшләү, синдәй матур, китап минеке),* бәйлек һәм бәйлек сүзләр ярдәмендә бәйләнәләр *(аның белән килү, синең янга бару, миннән соң кайту).*

Зат алмашлыкларының типик функциясе – ия һәм тәмамлык. Ләкин алар җөмләнең теләсә нинди кисәге булып та килә алалар.

Мәсәлән: *С е з д ә  минем бөтен тойгыларым, С е з д ә минем керсез яшьләрем, С е з  үлсәгез, мин дә онытылырмын, Яшәсәгез, мин дә яшәрмен* (М. Җәлил). *А н ы ң бүтән сүзләре утырыш беткәч кенә исенә төштеләр* (Г. Бәширов). *Вахитов  а ң а р  һәр саксыз сүзне йөрәгенә якын алмаска, кайчакта дәшми калуның да зур әһәмияткә ия булуы турында искәртте* (Р. Мөхәммәдиев).

**Күрсәтү алмашлыклары.** Аларга *бу, шушы, теге, ул, шул, андый, мондый, шундый; әлеге, андагы, шундагы; болай, тегеләй, шулай; әнә, менә; анда, шунда, монда; ары, бире; шулкадәр, шулчаклы* керә. Алар предметларның, эш-хәлләрнең, билгеләрнең билгеләрен күрсәтеп белдерәләр; сыйфатлар, рәвешләр, кисәкчәләр белән мөнәсәбәттәшләр.

*Бу, шушы, теге, шул, ул, андый, мондый* алмашлыклары сыйфатлар белән мөнәсәбәттәш, исемгә янәшәлек ярдәмендә бәйләнәләр. Җөмләдә, гадәттә, аергыч, сирәгрәк – хәбәр функцияләрендә киләләр. Мәсәлән: *М о н д ы й  чакта аның тирәсенә утырышкан такта яручылар да, тын калып, һәрберсе үз уена чума торган булган* (Г. Әпсәләмов). Аларның кайберләре рәвеш, сыйфат, фигыльләрне ачыклап киләләр. Мәсәлән: *Ш у н д ы й  якын күңелгә, ш у н д ы й газиз, белмим, туган шәһәрең булса да, б о л а й ук үзәк өзелмәс иде кебек* (Г. Бәширов). *Ш у н д ы й сагындырдың син, Айсылу апа! – диде* (Г. Бәширов).

Мөстәкыйль кулланылышта сыйфатлар белән мөнәсәбәттәш күрсәтү алмашлыклары исемнең грамматик билгеләрен алып, килеш һәм тартым белән төрләнә башлыйлар, берлектә һәм күплектә киләләр *(бу – моның, моңа, моны, моннан, монда; бусы – болары; бу – болар).* Шуны да әйтергә кирәк, *бу* һәм *ул* алмашлыкларының кыек килешләрендә супплетивизм күзәтелә. Бу алмашлыкларның бер өлешендә, зат алмашлыклары очрагындагы кебек, килеш кушымчалары үзенчәлекле (иялек килеше – *аның, моның, шуның;* юнәлеш килеше – *аңа, моңа, шуңа;* чыгыш килеше – *аннан, моннан, шуннан;* урын-вакыт килеше – *анда, монда, шунда*).

*Болай, тегеләй, шулай, әнә, менә, монда, ары, бире* күрсәтү алмашлыклары рәвешләр белән мөнәсәбәттәшләр, фигыль, сыйфат, рәвешне һәм хәбәр функциясендәге теләсә нинди сүз төркемен ачыклап киләләр һәм җөмләдә хәл һәм хәбәр булып йөриләр. Мәсәлән: *Клара өчен б и р е д ә  һәрнәрсә яңа, сәер, кызыклы иде* (Ә. Еники). *М о н д а*

*ул разведрота командиры иде* (Г. *Әпсәләмов). А н д а бик күпләр ятып калды* (Г. Бәширов),

*Шулкадәр, шулчаклы* алмашлыклары саннар белән мөнәсәбәттәш һәм җөмләдә шушы сүз төркеме кебек кулланылалар. Мәсәлән*: Без күпме китәбез, манаралар ш у л ч а к л ы кечерәя бара* (Г. Ибраһимов).

*Әнә, менә* алмашлыклары кисәкчәләр белән дә, рәвешләр белән дә мөнәсәбәттәш. Чагыштырыгыз*: Ә н ә шул бөек вакыйгалар тормышны ничек үзгәртте...* (Г. Әпсәләмов). *Ә н ә урман, таулар* (Г. Әпсәләмов).

Күрсәтү алмашлыкларының күбесе (*шул, бу, шундый, шулай, шулкадәр, шулчаклы* һ.б.) иярченле кушма җөмлә компонентларын бәйләүче чара булып та кулланылалар*: Кем сабыр, ш у л эшнең җаен табар (*мәкаль). *Дөнья ш у н д ы й матур; һәр каравым саен сөенәм* (Ш. Маннур). *Күпме кеше – ш у н ы ң к а д ә р язмыш* (М. Мәһдиев).

**Сорау алмашлыклары:** *кем, нәрсә, нинди, кай, кайсы, ничә, ничәү, никадәр, ничаклы, ничәнче, ничәшәр, ничәләп, ничек, кайда, кая, каян, кайчан, нишләү, нихәл итү.*

*Кем, ни, нәрсә* алмашлыклары исемнәр белән мөнәсәбәттәш һәм шул сүз төркеменең грамматик билгеләренә ия: килеш *(кем, кемнең, кемгә, кемне, кемнән, кемдә),* тартым белән төрләнә *(кемем, кемең, кеме),* берлектә, күплектә килә *(кем – кемнәр, нәрсә – нәрсәләр).* Татар телендә *кем* алмашлыгы затка-кешегә карата гына кулланыла. Калган барлык очракларда да *нәрсә, ни* алмашлыклары йөри (*нәрсә, ни? – аю, балык, төклетура* һ.б.)

*Нинди, кай, кайсы* алмашлыклары – сыйфатлар; *ничә, ничәнче, ничәшәр, ничәләп, никадәр, ничаклы* – саннар; *ничек, кайда, каян, кая, кайчан* – рәвешләр; *нишләү, нихәл итү* – фигыльләр белән мөнәсәбәттәш һәм шушы сүз төркемнәренең грамматик билгеләренә ия. Мәсәлән: *Әнә шул вакыйгалар тормышны н и ч е к үзгәртте, аерым шәхесләр язмышына н и ч е к тәэсир итте, гомер юлында к е м н ә р б е л ә н очраштым, к е м н ә р д ә н аерылдым, н и л ә р күрдем, н и л ә р г ә ирештем, к е м н ә р н е югалттым, к е м н ә р н е таптым* (Г. Бәширов).

Сорау алмашлыклары сөйләмдә иярченле кушма җөмлә составындагы гади җөмләләрне бәйләүче чара – мөнәсәбәтле сүз буларак та кулланыла. Мәсәлән: *Ул менә шунда ята. Ул, ул – кеше! К а й с ы с ы н гасырлар тудырды, Минутлар үтерде* (Һ. Такташ). *К е м аерылмый, ш у л а р белми аерылу сагышларын...* (халык җыры).

**Билгесезлек алмашлыклары:** *кемдер, әллә кем, берәү, нәрсәдер, әллә нәрсә, нидер, әллә ни; ниндидер, әллә нинди; кайсыдыр, әллә кайсы, фәлән, кайбер, берничә, беркадәр, берникадәр; ничектер, әллә ничек, әллә кайда, каяндыр, әллә каян; кайчандыр, әллә кайчан; әллә нитү, әллә нишләү.*

Алар, нигездә, сорау алмашлыкларына *-дыр/-дер* һәм *әллә* кисәкчәләре ялганып ясалалар. Аларның кайберләре генә *(фәлән)* тамыр сүз яки башка юл белән ясалган сүзләр *(кайбер, берәү, берничә, беркадәр, берникадәр).*

Билгесезлек алмашлыклары, сорау алмашлыклары кебек үк, төрле сүз төркемнәре белән мөнәсәбәттәшләр һәм аларның төп грамматик билгеләре белән характерланалар. Мәсәлән: *Әллә нәрсә сизенә күңелем, Әлләниләр уйланам...* (Һ. Такташ). *Ниндидер очсыз-кырыйсыз буш сахра имеш* (Г. Әпсәләмов). *Әллә ничек булды синең гомер, Син, Мокамай, әллә нишләдең!* (Һ. Такташ) (билгесезлек рәвеш алмашлыгы һәм фигыль алмашлыгы). *Назиров берничә минут, күзләрен киереп ачып, картка карап торды* (Г. Әпсәләмов) (сан алмашлыгы), *-дыр/-дер* кисәкчәле билгесезлек алмашлыкларында мөнәсәбәт белдерүче кушымчалар кисәкчә алдыннан урнашалар: *кемнәрнедер, ниләредер, кемнекедер, нәрсәгәдер, ниндирәктер.* Мәсәлән: *Кемгәдер яшьлеге кайтты, кемнеңдер заяга узган гомере күз алдыннан кичте, кемнеңдер күптән онытылган ярасы ачылды, әмма барысын да ниндидер бер искиткеч ләззәт-шашыну биләп алды* (Ә. Еники).

**Юклык алмашлыклары:** *һичкем, беркем, һичберкем, һичнәрсә, бернәрсә, һичбернәрсә, берни, һични, һичбер, һичнинди, бернинди, һичничек, берничек, һичкая, беркая, һичкайчан, беркайчан, һичкайда, беркайда, бер җирдә.* Билгесезлек алмашлыклары кебек үк, нигездә сорау алмашлыкларыннан *һич, бер, һичбер* кисәкчәләре ярдәмендә ясалалар. Еш кына *бер* кисәкчәсе ярдәмендә ясалган алмашлыкларда юклык мәгънәсе *-да/-дә* кисәкчәләре белән көчәйтелә: *беркем дә, бернәрсә дә, бернинди дә* һ.б.ш.

Юклык алмашлыклары, сорау һәм билгесезлек алмашлыклары кебек үк, төрле сүз төркемнәре белән мөнәсәбәттә торалар һәм аларга хас грамматик үзенчәлекләр белән характерланалар: *Анда беркем дә юк иде* (Г. Әпсәләмов) – исем белән мөнәсәбәттәш, хәбәрне

ияртеп, ия булып килгән. *Тырышып-тырышып фамилия үзгәртергә нинди сәбәп булгандыр, Гөлнур моны бернichек тә аңлый алмады* (Г. Ахунов) – рәвеш белән мөнәсәбәттәш, фигыльгә ияреп, рәвеш хәле булып килгән.

**Билгеләү алмашлыклары:** *бар, барча, барлык, бөтен, һәммә, һәр, һәркем, һәрнәрсә, һәрбер, һәртөрле, һәрвакыт, һәрчак, һәркайчан, һәрдаим, һәркайда, һәртөштә, үз.* Аларның күбесе сорау алмашлыкларыннан һәм вакыт, урын һ.б. мәгънәләрне белдерүче абстракт исемнәргә һәм сыйфатларга *һәр* алмашлыгы кушылып ясала *(һәркем, һәрнәрсә, һәрчак, һәртөрле).* Бер өлеше – *бар* хәбәрлек сүзенең (шулай ук аннан ясалган *барча, барлык* алмашлыкларының) һәм *бөтен* сыйфатының мәгънәләре үзгәрү нәтиҗәсе: *барча, барлык, бөтен*. Билгеләү алмашлыкларының кайберләре генә тамыр сүзләр. Нигездә бу алмашлыклар сыйфатлар белән мөнәсәбәттәш һәм җөмләдә аергыч функциясен үтиләр: *Аның ана йөрәге улы турындагы һәрбер сүзне, улына булган һәрбер карашны ычкындырмыйча аулап тора иде* (Ә. Еники). *Һәр чишмә суының үзенә генә хас тәме, үзенчәлеге бар* (Г. Бәширов). *Без, бөтен дөнья, урамда: Франция. Испания, Дания, Германия...* (Һ. Такташ). Ләкин билгеләү алмашлыкларының башка сүз төркемнәре белән мөнәсәбәттәшләре дә бар: *Клара өчен бирседә һәрнәрсә яңа, сәер, кызыклы иде* (Ә. Еники). *Һәркемгә бәхетле яшәргә, иркенләп суларга һава бар* (Ә. Ерикәй). *Һәрнәрсә, һәркемгә* – исем белән мөнәсәбәттәшләр. *Кеше күңелен һәрвакытта җылыта дуслык* (Ә. Ерикәй). *Һәркайда балкый бүген нурлар, Шау килә син саклаган кырлар* (Ә. Ерикәй). *Һәрвакытта, һәркайда* – рәвеш белән мөнәсәбәттәшләр.

*Үз* алмашлыгының лексик һәм грамматик мәгънәләре үзенчәлекле. Ул исемне алмаштырып килә. Мәсәлән: *Шулай да аңа үзләре үстергән бодайның сугышның иң кыен урынына бара дип уйлау бик рәхәт иде* (Г. Бәширов). *Бары тик күңеле күтәренке чакларда гына ул, онытылып китеп, үзенең ата-бабалары турында сөйли торган булган* (Г. Әпсәләмов). Ләкин *үз* алмашлыгы, ешрак исем яки башка алмашлыктан соң килеп, эшне зат яки предмет үзе башкарганны яки аңа үзе дучар булганны ассызыклый. Мәсәлән: *Үзегез бу турыда ничек уйлыйсыз соң?* (Р. Мөхәммәдиев). *Бу вариант үзе яңадан икегә – көндезге һәм төнге вариантларга бүленә* (Г. Әпсәләмов). Ике

очракта да бу алмашлык үзе алмаштырып килгән (беренче җөмләдә) һәм аныклап килгән (икенче җөмләдә) исемнең зат-санына туры килгән тартым кушымчасы ала: *(сез) үз-егез,* вариант *үз-е.* Килешләр белән төрләндергәндә, аныкланмыш функциясендә килгән сүз иялек килеше кушымчасын ала*: мин-ем үземнең, ми-нем үземә, мин-ем үземне, мин-ем үземнән, мин-ем үземдә*. I һәм II төр изафә конструкцияләрендә генә ул иялек килеше кушымчасын алмый: *үз китабы.* Мәсәлән: *Үз кызларымны бирмим, мин аларны бодай җирләрендә эшләтмәкче булам, – дидем* (Г. Бәширов). *Аның үз туксаны – туксан* (әйтем).

## 6. РӘВЕШ

Рәвеш – эш, хәл, билгеләрнең, сирәгрәк предмет һәм затларның процесска бәйле булмаган билгеләрен белдерә торган сүз төркеме. Процесска бәйле булмаган билгеләр дигәндә, эш, хәл һәм билгеләрнең сыйфаты *(акрын бару, тиз кайту, берөзлексез эшләү),* күләме һәм дәрәҗәсе *(озак көтү, шактый зур, тулысынча түләү),* урыны *(түбән төшү, югары менү, ерак китү),* вакыты *(иртән китү, кич кайту, бүген күрү),* сәбәбе һәм максаты *(юкка борчылу, юри эшләү)* күздә тотыла.

Үзләренең гомуми лексик-грамматик мәгънәләре – процесска бәйле булмаган билге белдерүләре белән рәвешләр, башка телләрдәге рәвешләр кебек үк, сыйфатларга якын торалар. Алай гына да түгел, татар телендә эш һәм предметларның сыйфат, сан һәм башка яктан билгеләрен белдерү өчен бер үк лексемалар кулланыла. Чагыштырыгыз: *яхшы кеше – яхшы эшләү, туры сызык – туры бару, ерак юл – ерак утыру, күп кеше – күп йөрү; югары белем – югары менү.* Татар телендә, рус телендәге кебек, асыл сыйфатларга нигезләнгән рәвешләр юк. Чагыштырыгыз: *хороший человек – хорошо жить, прямая линия – идти прямо* һ.б.

Морфологик планда рәвеш, сыйфат кебек үк, грамматик яктан формалашмаган. Ул – төрләнми торган сүз төркеме. Рәвешләрнең бер өлеше генә чагыштыру һәм артыклык дәрәҗәләрендә килә алалар. Сыйфатлар кебек үк, төп дәрәҗәдәге рәвешләр билгене башка билгеләр белән чагыштырмыйча белдерә, чагыштыру дәрәҗәсендә билге чагыштырмача күбрәк, артыклык дәрәҗәсендә иң югары дәрәҗәдә итеп бирелә. Дәрәҗә категорияләренең күрсәткечләре дә бу ике сүз төркемендә бердәй*: ерак – ераг-рак, соң – соң-рак, аз – аз-рак; якын – яп-якын, көндез – көпә-көндез, яңадан – өр-яңадан* һ.б.

Синтаксик планда рәвеш фигыльне *(җәяү бару, кинәт әйтү, йөзтүбән яту),* башка рәвешне *(шактый озак, бик югары, бераз китапча),* сыйфатны *(бик кызыклы, ифрат тыйнак, гаять*

*каршылыклы),* хәбәрлек сүзне *(б ү г е н бар, к ө з е н юк, к и ч е н кирәк),* сирәгрәк исемне ачыклап килә *(т а т а р ч а көрәш, о з ы н - о з а к балачак, я ш е р т е н эш).*

Рәвеш, нигездә, җөмләдә хәл функциясен үти. Мәсәлән: *Ул ир-тәгә дә шулай бер-ике җыр җырлап узар, б е р с е к ө н г ә д ә* (М. Мәһдиев). *Корал складлары турысыннан узган чакта, Назимов тирә-юньне ш а к т ы й озак күзәтеп торды (*Г. Әпсәләмов). *Киләчәк ул һәрвакыт б е р а з томанлы* (Г. Әпсәләмов). *Б ү г е н бар, и р т ә - г ә юк* (мәкаль).

Рәвеш аергыч һәм хәбәр функцияләрен дә үти ала: *Әлбәттә, Кла-раның үзеннән дә к ү п нәрсәләр турында сораштылар* (Ә. Еники). *Әниемнең к ө м е ш т ә й чәчләрен сагындым* (М. Хәсәнов). *Аның юлы е р а к т ү г е л иде* (К. Нәҗми). *Миләш кебек таң кызыллыгы я к ы н - м ы , е р а к м ы – берәү дә белми* (К. Нәҗми).

**Рәвешләрнең лексик составы.** Рәвешләрнең күп кенә өлешен тамыр сүзләр тәшкил итә. Мәсәлән: *еш, бик, аз, соң, гел, юри, иртә, кинәт, шәп, җәяү, элек, һаман, гаять, хәзер, ифрат* һ.б. Нигездә болар – гомумтөрки сүзләр, ләкин араларында гарәп һәм фарсы алынмалары да бар: *тәмам, ифрат, гаять, һаман* һ.б.ш.

Рәвешләрнең төп өлешен ясалма сүзләр тәшкил итә. Аларның лексик һәм грамматик структуралары кушымчалау, сүзләрнең кабатлануы, кушылуы һәм рәвешкә күчүе юллары белән тулылана һәм камилләшә. Кушымчалау юлы белән рәвешләр төрле сүз төркемнәреннән, шул исәптән рәвешләрнең үзләреннән дә ясала: *кыскача, бөтенләй, бушлай, икеләтә, күпләп, берәмләп* һ.б.ш.

Сүзләрне кабатлау юлы белән түбәндәге рәвешләр ясалган*: вакыт-вакыт, гомер-гомергә, алмаш-тилмәш, борын-борыннан, әледән-әле, елның елына, буйдан-буйга.* Сүзләрне кушу нигезендә түбәндәге рәвешләр барлыкка килгән: *бүген, беркөн, быел, берсүзсез, яланаяк, яланөс* һ.б.

Рәвешләрнең зур төркеме – адвербиализация нәтиҗәсе. Түбәндәге рәвешләр төрле сүз төркемнәренең аерым формалары изоляциядә калып адвербиализацияләнүе нәтиҗәсендә ясалганнар: *җәен, төнен, көчкә, эчтән, алдан* (исемнәрдән), *чынлап, бушка, яңадан, уңга* (сыйфатлардан), *юкка, кирәккә* (хәбәрлек сүзләрдән), *бергә, бергәләшеп* (саннардан), *тора-бара* (фигыльләрдән), *бераздан, күптән* (рәвешләрнең үзләреннән) һ.б.

Рәвешләр, үз чиратында, башка сүз төркемнәренең, аерым алганда бәйлек һәм кисәкчәләрнең, лексик составын баетуда катнашалар. Мәсәлән, *элек, соң* бәйлекләре, *әле, соң, инде* кисәкчәләре рәвешләргә барып тоташалар. Чагыштырыгыз: *Ул с о ң кайтты; Ул миннән с о ң кайтты; Ул кайчан кайтты с о ң ?* Беренче җөмләдә *соң* – рәвеш, икенчесендә – бәйлек, өченчесендә – кисәкчә.

**Рәвеш төркемчәләре.** Лексик-грамматик мәгънәләре буенча рәвешләр билге рәвешләре һәм хәл рәвешләренә бүленәләр.

**Билге рәвешләре** эш-хәл яки билгенең сыйфатын, үтәлү рәвешен, микъдарын, күләм-чамасын белдерәләр һәм үз эчләрендә ике төркемчәгә бүленәләр:

**1. Эш-хәлнең үтәлү рәвешен белдергән рәвешләр:** *тиз, әкрен, аягүрә, яланаяк, тын, ашык-пошык, кинәт, тора-бара, җәяү, бертавыштан, өзлексез, искәрмәстән, төрлечә, бергә, бергәләшеп, берьюлы, өчәүләп* һ.б. Мәсәлән: *Гәрәй белән Гриша, калын тактага тезелгән гранкаларны б ө г е л ә - с ы г ы л а күтәреп, машинага узалар* (К. Нәҗми). *Смердов б ә й н ә - б ә й н ә аңлатып бирде* (Г. Әпсәләмов). *Врангельның үлем чәчеп килүче сигез танкысын беренче булып без яндырдык, барысының башына б е р ь ю л ы без җиттек, – диештеләр иптәшләрем* (Г. Бәширов),

Охшату-чагыштыру рәвешләре дә шушы төркемчәгә керәләр: *бәйрәмчә, көндәгечә, татарча, сөлектәй, таудай.*

**2. Күләм-чама рәвешләре:** *бик, шактый, аз, бераз, күп, озак, байтак, бөтенләй, тулаем, тулысынча, өлешчә, яртылаш, көне-төне, искиткеч, сирәк, еш, ара-тирә* һ.б. Мәсәлән: *Көн урталарында ш а к т ы й җылыта* (Г. Әпсәләмов). *Киләчәктә биреләсе шушы сорауларга җавап эзләп, о з а к утырдык* (Г. Әпсәләмов).

Күләм-чама рәвешләре эш-хәл һәм билгенең билгеле һәм билгесез санын, шулай ук күләм-чамасын белдерәләр.

Билге рәвешләре, беренче чиратта, эш-хәлнең һәм билгенең күләм-чамасын белдергәндә, даими булмаса да, югарыда әйтелгәнчә, асыл сыйфатлар кебек, чагыштыру һәм артыклык дәрәҗәләрендә килә алалар: *тиз – тизрәк – тип-тиз, тиз-тиз; сирәк – сирәгрәк – сип-сирәк, сирәк-сирәк.* Мәсәлән: *Кешенең минутлары санаулы... Килен, самавырыңны т и з р ә к өлгерт!* (Ә. Еники). *Аның иреннәре к ы з у - к ы з у кыймылдый башлады: әллә ул шатлык авазы белән кычкырыр-*

*га тели иде, әллә к ы з у гына пышылдап, берәр дога укымакчы иде* (Ә. Еники).

Китерелгән мисаллардан күренгәнчә, билге рәвешләре, нигездә, фигыльләрне, сыйфатларны, башка рәвешләрне, сирәгрәк исемнәрне ачыклап киләләр, хәл рәвешләре исә фигыльләрне һәм хәбәрлек сүзләрне ачыклыйлар.

**Хәл рәвешләре** эш-хәлнең үтәлү вакытын, урынын, сәбәбен, максатын белдерәләр.

**1. Урын рәвешләре:** *ерак, якын, югары, түбән, янәшә, ары, бире.* Мәсәлән: *Тау башына салынгандыр безнең авыл, Бер чишмә бар, я к ы н безнең авылга ул* (Г. Тукай). *Шушы биеклек өстеннән кайсы якка гына карасаң да, ... бөдрә куаклыклар белән капланган озын чокырлар, я к ы н д а һәм е р а к т а утырган тагын ниндидер мәһабәт таулар күренә* (Ә. Еники).

**2. Вакыт рәвешләре:** *хәзер, иртәгә, бүген, кичә, быел, былтыр, көндез, иртән, кышын, башта, бераздан, күптән.* Мәсәлән: *Т и з д ә н һөҗүм, т и з д ә н атака* (К. Нәҗми). *Сынны авылын к ү п т ә н уздык, инде Ивановка дигән зур рус авылына җитеп киләбез* (Ә. Еники).

**3. Сәбәп-максат рәвешләре:** *юри, юкка, бушка, әрәмгә, тиккә, заяга, тикмәгә, тиктомалга.* Мәсәлән: *Бу дөньяда без яшибез икән, ю к к а түгел, ю к к а түгелдер* (Н. Нәҗми). *Төн уртасы җиткәч, бер кыз елый, Зөлхиҗҗә, Яшь гомерем з а я г а , ай, үтә дип, Зөлхиҗҗә* (халык җыры).

## 7. ХӘБӘРЛЕК СҮЗЛӘР

Тюркологик әдәбиятта хәбәрлек сүзләрне («предикатив»ларны) мөстәкыйль сүз төркеме итеп билгеләү һәм моны төрле җәһәттән нигезләргә омтылу беренче буларак азәрбайҗан галиме Җ. Әхмәдиев тарафыннан башкарылды дигән фикерләр бар [Щербак А., 1987, с. 48]. Асылда исә, бу мәсьәлә безнең галимнәребез тарафыннан инде ярты гасыр элек үк хәл ителгән булган.

Октябрь инкыйлабына кадәр төзелгән грамматикаларда хәбәрлек сүзләргә караган аерым мисалларны гына очратабыз [Насыйри К., 1895, б. 133], аннан соң инде ул сүзләрне галимнәр мөстәкыйль сүз төркеме итеп өйрәнә башлыйлар. Хәбәрлек сүзләр, беренче булып, Җ. Вәлидинең игътибарын җәлеп итәләр. Ул аларны исем фигыль дип атый һәм «вак сүзләр»нең бер төркеменә кертә [Вәлиди Җ., 1918, б. 32]. Бу уңай белән Г. Ибраһимов «ләкин “вак сүзләр” атамасы, ничектер, күңелгә ятмый» дигән искәрмәне ясап, әлеге атаманы бик үк хуплап бетермәвен белдерә [Ибраһимов Г., 1987, б. 124].

Г. Алпаров *кирәк, тиеш, мөмкин, бар* һәм *юк* сүзләре турында «үзләренә бер төркем сүзләр итеп карарга ярый» дигән фикерне әйтә һәм аларны «хәбәрлек сүзләр» дип атарга тәкъдим итә [Алпаров Г., 1945, б. 193].

Шулай итеп, Җ. Әхмәдев хезмәтләре [Ахмедов Дж., 1970] дөньяга чыкканчы ярты гасыр элек үк инде татар тел гыйлемендә хәбәрлек сүзләрнең мөстәкыйль сүз төркеме буларак билгеләнүләрен һәм аның «хәбәрлек сүз» дигән уңышлы атамасы да булуын билгеләп үтәргә кирәк. Шуны әйтергә кирәк: әлеге атаманың язмышы бәхетле була: ул фәнни термин буларак кабул ителә һәм гыйльми хезмәтләрдә, дәреслекләрдә киң кулланыла да башлый,

Хәбәрлек сүзләр дигәндә, беренче чиратта, җөмләдә ялгыз гади предикатив кисәк яки кушма хәбәр составында предикатив компонент буларак кулланыла торган *бар, юк, кирәк, тиеш, мөмкин, ярый*

кебек сүзләр күздә тотыла [Алпаров Г., 1945, б. 193; Хангилдин В., 1959, б. 243; Кононов А., 1980, с. 208–210; Щербак А., 1987, с. 47–49; Татарская грамматика, т. II, 1993, с. 293–297; Зәкиев М. Татар грамматикасы, т. III, 1999, б. 71]. Болардан тыш, В. Хангилдин *я (йә), мә* һәм *чү* кебек сүзләрне дә хәбәрлек сүзләр дип билгели һәм анализлый [Хангилдин В., 1959, б. 243]. Ләкин бу караш белән һич тә килешеп булмый, чөнки әлеге сүзләр, асылда, хәбәрлек сүзләр түгел, бәлки императив ымлыклар булып саналалар.

Этимологияләре белән хәбәрлек сүзләр төрле сүз төркемнәренә карыйлар; алар арасында һәм исемнәр, һәм фигыльләрдән ясалган сүзләр бар. Н. Дмитриев фикеренчә, *бар* һәм *юк* сүзләре, мәсәлән, башта исем булганнар, шул ук вакытта сыйфат функциясен дә үти алганнар [Дмитриев Н., 1950, с. 63–64]; «Алтай теле грамматикасы»ның авторлары *йок* сүзен, ә Э. Севортян *бар* сүзен исем сүз (имя) дип билгелиләр [Грамматика алтайского..., 1869, с. 272; Севортян Э., 1978, с. 62]. Н. Хангилдин исә, киресенчә, әлеге сүзләрдә фигыль табигате көчле дип саный [Хангилдин В., 1959, б. 244].

М. Зәкиев *бар, юк, кирәк* һәм *ярый* хәбәрлек сүзләре, бер яктан, исемнәргә, икенче яктан, фигыльләргә якын торалар дигән фикерне әйтә [Татар грамматикасы, т. III, 1999, б. 228].

Мондый синкретизм, ягъни кайбер сүзләрдә башка сүз төркемнәренә хас булган билгеләрнең дә берләшкән хәлдә яшәве, мәгълүм ки, төрле телләрдә күзәтелә торган күренеш. Безнең телдә андый синкретизм, мәсәлән, исем, сыйфат һәм хәл фигыльләрдә дә күзәтелә; рус телендәге кисәкчәләрдә исә дүрт-биш сүз төркеменә хас булган мәгънәләрнең элементлары бергә үрелгән хәлдә яшәүләре билгеле [Русская грамматика, т. I,  с. 724, 730]. Шуның өчен хәбәрлек сүзләрдә күзәтелә торган ике сүз төркеменә тартымлыкка да табигый бер күренеш дип карарга кирәктер. Бу – бер; икенчедән, төрле хәбәрлек сүзләрнең башка сүз төркемнәре белән булган мөнәсәбәтләре дә төрлечә. Әгәр *бар* һәм *юк* сүзләрендә исем табигате көчлерәк булса, *кирәк, тиеш* һәм *ярый* сүзләрендә, киресенчә, фигыль табигате көчлерәк булуны күрәбез.

*Бар* һәм *юк* сүзләре – капма-каршы мәгънәле сүзләр (антонимнар): *бар (= есть, имеется)* берәр нәрсәнең барлыгын, булуын, ә *юк (= нет, не имеется),* киресенчә, аның юклыгын, булмавын белдерә. Ул сүзләр,

шул рәвешчә, раслау һәм инкярны тәгъбир итә торган төп чараларның берсе булып торалар; алар җирлегендә раслау һәм инкяр җөмләләр формалашалар. Мисаллар: *Хак тәгалә нәрсә кылса, ирке б а р ; Рус Микитинның Казанда циркы б а р* (Г. Тукай). *Һәрбер көннең аерым төсе б а р , һәрбер көннең аерым эзе б а р* (Х. Туфан). *Бакчаның бер ягында бик матур бер елга б а р* (Г. Ибраһимов). *Бу начар өйнең эчендә икмәге юк ярлы б а р* (Г. Тукай). *Б а р иде, ялгыз калып, җырлап юанган чакларым; Ярты җырда инде күкрәкне тотам да йөткерәм* (Г. Тукай). *Әй кая ул көн ки бездә – Шәп торулар б а р иде. Әмма дошманнарда гамьнәр, эч пошулар б а р иде* (Дәрдемәнд). *Заман кичте, сулар акты, хәзер ю к инде ул ялкын, кызу сүнде йөрәктә, мәңгелеккә ул салкын* (Г. Тукай). *Җилнең әсәре дә ю к* (Г. Ахунов). *Уйлану б а р , сизенү б а р , ә чын дөресен генә белү ю к иде* (Ә. Еники). *Мин аны юньләп аңламадым да бугай... Гомумән, миңа дөнья әллә б а р иде, әллә ю к иде* (Г. Ибраһимов).

*Бар/юк* сүзләре күп тезмәле һәм катнаш кушма җөмләләрдә, шулай ук күрше мөстәкыйль җөмләләрдә гади хәбәр буларак берничә тапкыр кабатланып килә алалар: *Күңелемнең әзрәк кенә кинәсе б а р , телемнең дә зәһәр очлы инәсе б а р* (Дәрдемәнд). *Дөньяда ничә җан булса, шунча йөрәк, шунча табигать б а р ; һәм шунча теләк вә әмәл б а р* (Г. Ибраһимов). *Үз-үзем белән гел мавыгып, Керешсәм чәчәргә очкыннар; Яңгырый шул вакыт бер аваз: Онытма: Пушкин б а р , Пушкин б а р* (С. Хәким). *Әллә нәрсәм юк кеби, бер нәрсә ю к , бер нәрсә ким; б а р да б а р , тик ю к туганнар, мин ятим, монда ятим* (Г. Тукай). *Дин, шәригать синдә ю к , ю к тыелуың, ю к боерыгың; син – чабак Иделдәге, тик күрсәтәсең койрыгың* (Г. Тукай). *Анда ю к Урак, анда ю к сабан, Анда икмәкне алалар сатып* (К. Тинчурин). *Ә ай ялгыз, Айда бернәрсә ю к , әтәч тә ю к анда, песи дә; Катык та ю к анда, ипи дә ю к безнеңише ярлы кешегә* (Һ .Такташ). *Менә ничә ел инде ул идән астында яши. Торырга бүлмәсе ю к . Исем-фамилиясе ю к . Ай саен яңа паспорт, яңа исем. Туры килсә – ашый, булмаса – ач бүре кебек йөри* (Г. Ибраһимов).

Хәбәр функциясеннән тыш, сирәк булса да, *бар/юк* сүзләренең аергыч функциясендә кулланылу очраклары да бар: *[Кызларның] Өченчеләре, дүртенчеләрендә тагы шунда куркаклыкмы, үзенә үзе хуҗа түгеллекме – бер сызык күргәнгә, Аннада б а р хасиятләр, сый-*

*фатлар күрелмәгәнгә, өстән генә карарга тотынды* (Г. Исхакый). *Мәсьәләнең ничек барышын Фәхри дә аңлый иде. Шуңа күрә дә ул, Зыя алынгач, юк йомышны б а р итеп, унсигез көндә ике мәртәбә боларга килеп китте* (Г. Ибраһимов).

*Бар/юк* сүзләре заман һәм зат-сан белән төрләнмиләр. Югарыда китерелгән җөмләләрдә, күренә ки, алар хәзерге һәм тәмамланмаган үткән заманнарда гына кулланылганнар; матур әдәбият әсәрләрендә *юк* сүзенең генә, автор окказионализмнары сыйфатында, күплек саны һәм хәзерге заман берлек сан өченче зат формаларында кулланылуы күзәтелә: *Тәнемдә тирегә сыймаган бер көч, бер дәрт бар төсле: сикерәсе, дулыйсы, әллә нинди биек җирләргә менәсе, егыласы килә иде. Шуңа күрә малайларның акрынлавына ачуым килде. Әле һаман ю к л а р !* (Г. Ибраһимов). *Ю к т ы р с ы ң ла, Алла... Әгәр булсаң, сабыр итмәс идең бу эшкә, Бөтен кодрәтеңне баглап куймас идең җирдә алтын, көмешкә* (М. Гафури).

*Юк* сүзенең шарт фигыль формасы *югыйсә (юкса)* каршы куючы теркәгеч *(= в противном случае, а то, иначе)* буларак кулланыла: *Хезмәт көнен ул да маңгай тире белән эшләп алсын. Ю к с а , кадере булмас* (Г. Бәширов). *Бер тауда ун чишмә, унысы ун төстә; Ю г ы й с ә , бер үк тау, Ю г ы й с ә , бер үк җир, юлы бер...* (С. Хәким). *Мин телеграммаңны алгач, каршы алырга төшәрмен. Ю к с а , үзең табып килә алмассың* (М. Җәлил). *Ярый, кендек буш икән, ю к с а (арба) минем атны да өстерәр иде* (Г. Ибраһимов).

*Барның/юкның, барга/юкка, барын/югын, барда/юкта, юктан* кебек тартым һәм килеш формалары исә исемләшкән яки рәвешләшкән формалар дип билгеләнәләр [Хангилдин В., 1959, б. 245, 268; Вәлиуллина З. ..., 1972, б. 76; Тумашева Д., 1978, б. 81]: *Җаны б а р н ы ң җүне бар* (мәкаль). *Үзе ю к н ы ң күзе юк* (мәкаль); *Ул күреп тора җир йөзендә без б а р ы н . Үтәлде теләгем... Борчымый вөҗданым* (С. Хәким). *Хәялдән сүз ачып, берничә галим Ачып күрсәттеләр... аларда б а р ы н* (Дәрдемәнд). *Сөймә ю к к а , көймә ю к к а , йөрмәче шул кыз белән; Бер дә сөйми ул сине, син ю к т а , ул синнән көлә* (Г. Тукай). *Куйсана ю к н ы , көлдермәсәнә, Ю к к а сүземне бүлдермәсәнә* (С. Рәмиев). *Ю к т а н бар я х ш ы* (мәкаль). *Акча б а р д а , бар да дус шул, бар да яр; акча исе чыкмый торса, бар да яныңнан таяр*! (Г. Тукай).

Диалогик сөйләмдәге җавап репликаларында *бар/юк* сүзләре бик еш ким яки сүз җөмләләр булып киләләр. Түбәндәге өзектә, мәсәлән, *Бар* һәм *юк* репликалары иясе (винтовка) әйтелмәгән ким җөмләләр булып торалар: *Салават зур таза гәүдәсе белән хуҗалык командасы начальнигы каршына килеп басты: – Винтовкалар бармы? – Ю к . – Б а р бит. – Барлыгын беләбез. – Санитарларга ул. – Ничек инде ул: Санитарларга бар, ә безгә юк!? – Яралылырга юк* (А. Шамов) – *Бер нәрсә дә ишетә алмадыгызмы? – Ю к* (Г. Ибраһимов). – *Шаярасың? – Ю к* (К. Нәҗми) дигән мисалларда исә *юк* сүзе сүз җөмлә буларак кулланылган.

Җавап репликаларында *бар/юк* сүзләре, еш кына, кабатланып килергә яки *юк* сүзеннән соң *түгел* юклык кисәкчәсе дә кулланылырга мөмкин. *Мәсәлән: – Тәмәкегез бармы? – Б а р билгеле, б а р ...* (Г. Ибраһимов). – *Бергә йөргән вакытларны оныттың ахры? – Ю к , онытканым ю к , – диде Салихов.– Онытырлык түгел аны* (А. Шамов*). – Алайса, бу гөрелдәү Кырым капкасы төбендә түгелмени әле? – Ю к , түгел* (Г. Бәширов). – *Татар кызы булгач, ул инде кара туткыллырактыр? – Ю к , түгел* (Г. Исхакый). – *Ю к , алай түгел, анасы... Бу «Кәрван» чәе торып торсын әле...* (Ф. Әмирхан).

Җавап репликалары башында кабатланып килгән *юк* сүзе сөйләүченең яки башка персонажларның фикерләре белән килешмәү, аңа кискен каршы төшүне яки аны кискен инкяр итүне белдерә: – *Ю к , ю к ! Без риза түгел, Тимергали абзый, сабыр ит!* (Г. Бәширов). – *Син инде кул куйдыңмы? – Ю к, ю к, күрсәтмә бирмәдем* (И. Салахов). *Сәләхиев моңа әрнеп җавап кайтарды. Кискен сүз әйтте; – Ю к, ю к ! Бу да хата! Монда мин интрига корбаны булдым* (Г. Ибраһимов).

*Юк* сүзенең югарыда әйтелгән функциядә кулланылуы шигъри әсәрләрдә шактый еш күзәтелә. Мәсәлән: *Ю к , ю к . Мин ант итәм: һичбер вакытта да сине карак итеп сөйләмәм* (Һ. Такташ*). Ю к бу дөнья каплаган күк, Ю к бу җирләр берсе дә. Ю к табигать, ю к кешеләр. Үлесе дә ю к , тересе дә!* (С. Рәмиев). *Кем ул анда, бүре улыймы? Адашкан бер бала елыймы? Ю к , ю к , Берәү җырлый урманда. Кара төндә Нишләп йөри икән ул анда* (И. Юзиев).

Төрле телләрдә, шул исәптән татар телендә дә, күзәтелә торган бер кызык күренеш – бер үк хәбәр составында ике инкяр формасы булу («двойное отрицание»): *Ю к т ү г е л аю, бүре, төлке – җиһан*

*корткыч та бар* (Г. Тукай). *Шәрәфи агайның тәҗрибәсе буенча, суның җылылыгына, акчарлакларның хәзердән үк чит буйларда очып йөрүләренә караганда, быел да балык күп булырга чамасы ю к т ү г е л* (Ш. Камал). *Атым с ы н а л м а г а н т ү г е л* (Г. Ибраһимов).

Күренә ки, югарыда китерелгән һәр җөмләдә икешәр инкяр бар: беренче инкяр аларда *ю к* сүзе яки фигыльнең юклык формасы *ма/-мә* белән белдерелсә, икенче инкяр *т ү г е л* сүзе белән белдерелә. Ләкин әлеге җөмләләр, асылда, инкярны белдермиләр, ә, киресенчә, раслауны белдерәләр. Эш шунда ки, ул җөмләләрдә ике инкяр бер-берсен инкяр итәләр, шуның аркасында җөмләләр дә раслау мәгънәсен алалар [Сафиуллина Ф., 1980, с. 63; Бондаренко В., 1983, с. 132–133]. Ә инде моның шулай икәнлеген, ике инкярлы җөмләләрдән соң, мәгънәләре белән аларга адекват булган раслау җөмләләр кулланылу да күрсәтеп тора: *К ү р м ә д е к т ү г е л , күрдек; Хәйбулла аяк чолгауларын сүтә-сүтә: – Шул-шул эшләр дә ю к т ү г е л , ансы да бар,– диде* (Ш. Камал).

Ике инкярлы җөмләләр фикерне тәгъбир итүдә бер стилистик алым буларак кулланылалар, ләкин логик эчтәлекләре белән алар, раслау турыдан-туры белдерелгән җөмләләр белән бердәй булсалар да, үзләренең стилистик, экспрессив-эмоциональ төсмерләре ягыннан соңгы төр җөмләләрдән аерылалар. Шунысы игътибарга лаек, «двойное отрицание» дигән логик-грамматик категориянең төрки телләрдә яшәвенә «Алтай теле грамматикасы» авторлары да игътибар иткән булалар һәм алтай телендә әлеге категориянең ничек тәгъбир ителү очракларын дөрес билгели алганнар [Грамматика алтайского..., 1869, с. 117, 269]: *Кижи паспас јер јок (Кеше басмаган җир юк); Уурбас јер јок (Авыртмаган җирем юк).* Китапта «двойное отрицание»нең рәвеш хәлләрендәге *бейчі (= -мичә)* яки *-па (= -ма)* һәм хәбәр составындагы *-бас (= -мас)* яки *-пе (= -мә)* формалары белән тәгъбир ителү очракларына *Кудай берер, бербийчі калбас; Үлгенге чашпайынчы ічпей теник (Үлгәнгә су бөркемичә, эчмибез)* [*Үлгән* – алтайлыларда мифик зат]; *Айлу јерде јургенде, Арынбайлы јыл ертмас (Ай астында гомер кичергәндә талмыйча, хәлдән таймыйча бер генә дә ел үтмәс)* кебек мисаллар китерелә.

Борынгы грек һәм латин, шулай ук француз һәм немец телләрен яхшы белгән (әлбәттә инде, ул телләрдәге «двойное отрицание» белән

дә яхшы таныш булган) «Алтай теле грамматикасы»н төзегән миссионерларга алтай телендә дә әлеге логик-грамматик категорияне билгеләү кыен булмаган күрәсең.

*Бар/юк* сүзләре өч төрле аналитик фигыль формаларында да киң кулланылалар: (1) үткән заман сыйфат фигыль – *бар/юк: барганым бар/юк, килгәнем бар/юк;* (2) киләчәк заман сыйфат фигыль – *бар/юк: барасым бар/юк, киләсем бар/юк;* (3) исем фигыль + *бар/юк: бару бар/юк; килү бар/юк.*

Татар теленең генә түгел, ә башка кайбер төрки телләрнең дә шул ук структурадагы формалары турында беренче фикерләр XIX гасырда төзелгән грамматик хезмәтләрдә үк әйтеләләр [Иванов М., 1842, с. 195; Грамматика алтайского..., 1869, с. 200, 272]. Кызганычка каршы, шуннан соң әлеге формаларга озак еллар буена игътибар ителми. Аларны өйрәнү белән берәү дә шөгыльләнми, һәм бары тик бер гасыр вакыт үткәннән соң гына галимнәр бу мәсьәлә белән кызыксына башлыйлар. Ниһаять, 1960–1980 елларда әлеге формаларга Ә. Юлдашев һәм Д. Тумашева хезмәтләрендә җитди анализ ясалды [Юлдашев А., 1965, с. 159–167; Тумашева Д., 1986, б. 73–74, 144]. Түбәндә шул анализның кыскача нәтиҗәләре тәкъдим ителә.

Әйтеп үтелгән өч форма да, авторлар фикеренчә, *атым бар* тибындагы конструкция моделе буенча ясалган формалар булып торалар. Шуңа күрә алар структуралары белән әлеге исем конструкциядән берни белән дә аерылмыйлар. Өч аналитик форма да, исем конструкцияләр кебек үк, ике компоненттан торалар: беренчесе – тартым кушымчалары (*-ым/-ем, -ың/-ең, -ы/-е,* һ.б.) ялганган компонент, икенчесе – шул ук *бар/юк* сүзләре. Бу компонентлар, кайчандыр, үзара хәбәрлек мөнәсәбәте белән бәйләнгән булалар. Ниһаять, исем конструкциядә предметның иясе, ә фигыль формаларында эшнең субъекты, үткән чорлардагы кебек үк бер ысул белән, ягъни зат алмашлыклары һәм тартым (фигыль формаларында зат) кушымчалары, яисә ул чараларның берсе белән генә белдереләләр. Әгәр ул чараларның берсе дә юк икән, әлеге семантик компонентлар контексттан, обстановкадан чыгып билгеләнәләр. Мәсәлән: *М и н е м колхоз председателен озак йөрткән шофер белән кырлар-басулар буйлап узганым б а р* (С. Хәким). *Ничә тапкыр күргәне б а р : һәйбәт тачанкалар, бер-берсеннән шәп кара атлар* (Г. Бәширов). *Перекопка барып җиткәнче бик*

*каты бәрелешәсе б а р әле* (Г. Бәширов). *Менә кайда ул кино! Билетка акча әрәм итеп йөрисе дә ю к !* (М. Мәһдиев). *Монда «тост» дигән нәрсә дә, мактанып утыру да ю к ...* (Ә. Еники).

Ләкин әлеге аналитик фигыль формалары белән *атым бар* тибындагы исем конструкциясе арасында элекке уртаклык бөтенләй юкка чыккан; чөнки тора-бара өч фигыль формасы да бик җитди һәм семантик, һәм функциональ үзгәрешкә дучар булганнар: (1) тартым кушымчалары зат кушымчалары функциясен үти башлаганнар; (2) ике компонент арасында хәбәрлек мөнәсәбәте дә юкка чыккан. Нәтиҗәдә өч фигыль формасы да компонентлары бердәм грамматик мәгънә белән беркетелгән, ныгытылган формалар булып үзгәргәннәр. Шул рәвешчә, ул формалар хәзер бернинди кисәкләргә таркалмый торган монолит формалар булып кабул ителәләр. Шуның өчен алар бер җөмлә кисәге буларак кулланылалар да. Моның шулай икәнлеге әлеге формаларның грамматик ияләргә буйсынып килү очраклары белән исбат ителә: *Кайткан чакларда мин моны үзем дә күреп, бик курыкканым б а р* (Ә. Еники). *Аның бик зур кыенлыклардан чыкканы б а р* (Ш. Усманов). *Тимер юл ачылгач кына бу якларга килеп утырган татар авылын мин белмим, ишеткәнем ю к* (Ә. Еники). *Яшь көчләр әле оешып җиткәне ю к* (Һ. Такташ).

Әлеге формалар турында тагын шуны әйтергә кирәк: *-ган бар* формасында *-ган* морфемасы белән *бар* сүзе икесе дә үзләрен фигыль нигезе белән мөстәкыйль рәвештә бәйләнешкә керү мөмкинлегеннән мәхрүм итә торган бик җитди сыйфат үзгәрешенә дучар булалар: *-ган* морфемасы билгесез (сөйләүче күзәтмәгән) үткән заман мәгънәсен югалта һәм билгеле (сөйләүче күзәткән) үткән заман мәгънәсен ала; *бар* сүзе исә хәзерге заман мәгънәсен югалта. Шул рәвешчә, әлеге форма эшне чын факт, үтәлүен сөйләүче үзе күзәткән эш итеп характерлый торган формага әверелә. Бу билге аны категорик үткән заман формасы *(-ды)* һәм составларында *иде* ярдәмче фигыле булган аналитик формалар белән берләштерә. Һәм, киресенчә, билгесез үткән заман формасыннан (*-ган* морфемасыннан) аера. Менә шушы үзенчәлекләр *-ган бар* формасын хикәя фигыльнең мөстәкыйль үткән заман формасы итеп билгеләргә мөмкинлек бирәләр. Шуны әйтергә кирәк: составында *иде* ярдәмче фигыле кулланылганда да, әлеге форма үзенең төп функциональ мәгънәсен, ягъни үтәлүен сөйләүче үзе

күзәткән эшне белдерү функциясен югалтмый. Ләкин бу очракта инде эш заман планында икенче бер эш белән мөнәсәбәттә карала, төгәлрәк әйткәндә, башка бер эшкә кадәр үтәлгән эш буларак сурәтләнә, шуңа күрә ул тарихи экскурс рәвешендә кабул ителә: *Туйларны күргән б а р иде – андагы кызык, шау-шу, җыр-музыка!..* (Ә. Еники). *Ә Дәүләкәннең инде турыдан туры Дәүләтхан исеме белән бәйләнгән булуын үземнең дә ишеткәнем б а р иде* (Ә. Еники). *Күптәннән болай рәхәт кичереп, һәр сызыгыннан мәгънә табып, әдәби әсәр укыганым ю к иде* (А. Гыйлаҗев).

*-асы бар* формасы да – компонентлары җитди үзгәрешләргә дучар булган форма. Аның беренче компоненты – эшне предметның билгесе итеп белдерү сәләтен, ә *бар* – хәзерге заман мәгънәсен югалткан. Ике компонент, хәзер инде бергә килеп, тиешлек мәгънәсен белдерә торган бердәм аналитик форма буларак функцияләшәләр. Форманың семантикасы – киләчәктә үтәлергә тиеш эшне белдерү. Мисаллар: *Безнең яшьләрне уңыш алуның нечкә серләренә өйрәтәсебез б а р* (Г. Бәширов). *Иртәгә демонстрациягә барасы б а р бит!* (И. Салахов). *Юк шул, әле аның тагын ике атна чамасы укыйсы б а р* (Я.Зәнкиев). *Димәк, проблема б а р , эзләп торасы ю к* (С.Рәфыйков).

Мисаллардан күренгәнчә, *-асы бар* формасы *-ырга кирәк* конструкциясенең стилистик варианты буларак кулланыла.

*Кирәк, тиеш (тиешле), мөмкин* – болар өч төрле модаль мәгънәне белдерә торган сүзләр. *Кирәк* сүзе (1) – заруриилык (необходимость), *тиеш* сүзе (2) – тиешлек (долженствование), ә *мөмкин* сүзе (3) – мөмкинлек (возможность) мәгънәләрен белдерәләр: (1) *Ияреrgә түгел, өйрәнергә к и р ә к . Дәрдемәндтән осталыкка, техникага өйрәнергә к и р ә к* (С. Хәким). Т*еге яки бу хәл турында моңарчы бер дә әйтелмәгәнчә итеп, нәкъ үзеңчә, фәкать үзеңчә генә яза белергә к и р ә к* (Г. Бәширов). *Солдат белән солдатча сөйләтергә к и р ә к* (Г. Бәширов); 2) И*җатта, сәнгатьтә изгелек к и р ә к , җанда, күңел түрендә шул саф, керсез изге хис ятарга т и е ш* (С. Хәким). *Бер-ике җаваплы иптәш алдан барып хәбәр итүне үз өстенә алырга т и е ш л е* (Ш. Усманов); 3) *Сездән аерылып, туганнар! – җайсыз, уңайсыз тору; Бу тору, әйтергә м ө м к и н д е р , кояш, айсыз тору* (Г. Тукай). *Гади солдатка хас кичерешләрнең һәммәсен дә аңарда күрергә м ө м к и н* (Ш. Усманов).

Югарыда күрсәтелгән мәгънәләр өч модаль сүзнең дә бердәнбер номинатив мәгънәләре булып торалар, һәм ул сүзләр, мәгълүм булганча, сүзлекләрдә дә шул мәгънәләре белән мөстәкыйль лексик берәмлек буларак теркәлгәннәр.

Тарихи бер экскурс рәвешендә шуны да әйтергә кирәк: Октябрь инкыйлабына кадәр булган татар әдәби телендә, белгәнебезчә, инфинитив яки исем фигыль формалары белән *лазем* яки *имкян* модаль сүзләреннән ясалган аналитик конструкцияләр дә шактый киң кулланылышта булганнар: *Язу вә тәгълим биргәндә дә сабак баланың үзенә тәкърир кылдырып тасниф кагыйдәсен үзгәртмәк л а з е м д е р* (К. Насыйри). *Һәр хәрефне бер генә төкселдә калдыру л а з е м* (Г. Ибраһимов). *Бу көннәрдә һәр көн дүрт сәгать шөгыльләнү л а з е м түгел* (Г. Ибраһимов). *Булса, хатларын укырга да, шулар аркылы аның сурәтләрен хыялында ясарга гына и м к я н бар* (Г. Ибраһимов).

Инде төп мәсьәләгә кайтып, югарыда күрсәтелгән өч модаль сүзнең дә телнең төрле ярусларында күзәтелә торган үзенчәлекләрен билгелик.

1) *Кирәк* сүзенең юклыгы -*ми* юклык кушымчасы һәм *түгел* кисәкчәсе белән дә белдерелә, ә *тиеш (тиешле)* һәм *мөмкин* сүзләренең юклыгы *түгел* сүзе белән генә белдерелә ала: *К и р ә к м и , ташлыйбыз иске тормышны. К и р ә к м и , яңаны башлыйбыз!* (С. Рәмиев). *Зур шагыйрьләрнең йогынтысын аерым юллардан эзләргә к и р ә к - м и* (С. Хәким). *Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен, тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын, көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен, К и р ә к т ү г е л мәгънәсе юк көлке-уен* (Г. Тукай). *К и р ә к т ү - г е л , мин яңадан ташчы булам, әүвәлгечә иҗтиһатлы эшче булам...* (Г. Тукай). *Яралы кызылармеец бер генә минутка да ярдәмсез калырга т и е ш т ү г е л* (Ш. Усманов). *Һич мөмкин т ү г е л . Мондый авыр вакытта полкны ташлап китәргә булмый* (Ш. Усманов).

2) Өч сүзнең дә төп синтаксик функцияләре – инфинитив яки исем фигыль белән бергә килеп, аналитик конструкцияләр составында модаль компонентлар буларак кулланылу. *(-ырга* + модаль сүз моделендәге конструкцияләргә мисаллар югарыда китерелде, шуңа күрә биредә -*у/-ү* + модаль сүз моделендәге конструкцияләргә генә мисаллар китерелә: *Беренче чор. Бу чорда һаваның берникадәр салкынрак б у л у ы к и р ә к* (Г. Бәширов). – *Сез, атакай, мандолинада бик яхшы*

*уйныйсыз икән. Яшь кешегә уйный б е л ү к и р ә к шул, менә кызлар мактап утыралар әле сезне* (Ф. Әмирхан). *Ләкин «вак сүзләр» атамасы, ничектер, күңелгә ятмый. Аннан соң ул аерылуны сүз уңаенда гына әйтеп китмичә, аны бер нигез кагыйдә итеп к а р а у т и е ш* (Г. Ибраһимов). *Сукырны г а е п л ә ү м ө м к и н т ү г е л . Аның күе нәкъ татардагыча* (Г. Ибраһимов). *Күрдем хәзер: эшкә һич нәрсә тиң түгел, Эштән көчле нәрсә табу м ө м к и н т ү г е л* (Г. Тукай). – *Әй, әгәр сез болай йоклап барсагыз, Ташкентка кадәр бернәрсә күрмичә к а л у ы г ы з м ө м к и н* (Ш. Усманов). *Әдәбиятта беркетеп куелган тарихны б о з у м ө м к и н т ү г е л иде* (А. Гыйлаҗев). *«Аваз»ны белми торып, әлифба б а ш л а у һич м ө м к и н т ү г е л иде* (Г. Ибраһимов).

3) *Мөмкин* сүзеннән аермалы буларак, *кирәк* һәм *тиеш (тиешле)* сүзләре ике составлы җөмләләрдә гади хәбәр, хәтта аергыч булып та килә алалар: *Синең төсле матур кызлар сирәк бит, хатын алсаң, иләк, чүмеч к и р ә к бит* (Г. Тукай). *Ышаныч к и р ә к , зур максат, перспектива к и р ә к шагыйрьгә* (С. Хәким). *Өйдә эш кулы к и р ә к иде* (Г. Ибраһимов). *Үзең складта кичләрен килеп булыштың – тугыз тапкыр уникең... җәмгысы... Шулай итеп синнән безгә т и е ш ун алты сум 43 тиен көмеш...* (К. Нәҗми). – *Аларның бит комиссарлары гына итек кия. Боларына чабата т и е ш л е* (Г. Бәширов). *Менмәмен мин, Ходай кушса, мич башына, шигырьләрдән килер миңа к и р ә к җылы* (Г. Тукай). *Кулга мылтык алсаң, әле пулялар да кеше хуры итеп бетәрләр, К и р ә к җиргә барып эләкмичә, «сөт эчәргә» очып китәрләр* (Һ. Такташ). *Алдыбызда торган бурычларның онытылмаска т и е ш җирләрен, окопларда җылынып искә алырга җырга салып язып бирмәдем!..* (Һ. Такташ).

Болардан тыш, *кирәк* сүзе ихтималлыкны, чамалап әйтүне, икеләнүле раслауны белдерә торган *булса кирәк, булырга кирәк* тезмәләрендә һәм хәзер, инде стандарт әзер сөйләм формулаларына (клишеләргә) әверелгән *иң элек, аннан соң, тагын, бу урында, биредә, монда, сүз азагында, өстәп, йомгаклап, җыеп, тик [шуны (да), бер нәрсәне] әйтергә кирәк* кебек әйләнмәләрдә дә киң кулланыла: *Мондагы сатучы марҗалар да, кассада утыручы да Исмәгыйльне беләләр б у л ы р г а к и р ә к , аны аерым бер якты йөз белән каршы алдылар һәм баш иеп сәламләделәр* (Ф. Әмирхан). *Яныңа, читтән кайткан кеше белән кы-*

*зыксынып* *б у л с а   к и р ә к* , *күршеләрең җыела* (С. Хәким). *Кайдадыр яңгыр ява* *б у л с а   к и р ә к* , *йомшак кына гөлдерәү ишетелеп ала* (М. Мәһдиев). *Перекоп ягында өзлексез орудиеләр гөрелди, аның дивизиясе сугышкан якта да каты бәрелешләр бара иде* *б у л с а   к и р ә к* (Г. Бәширов). *Ә й т е р г ә   к и р ә к : Дәүләкән башкортларыннан бүтән Себергә җибәрелүче булмады шикелле* (Ә. Еники). *Тагын шуны* *ә й т е р г ә   к и р ә к : хәбәре төрле килештәге исем, фигыль белән белдерелгән синтетик җөмләләр ярым хәбәрлекле төзелмәләргә бик җиңел үзгәртеләләр* (М. Зәкиев). *А н н а н   с о ң   ш у н ы   д а   ә й т е р г ә   к и р ә к : бу модельне парадигма эчендә генә калдырсак, татар теленең үзенчәлеге бераз игътибарсыз кала* (М. Зәкиев).

Ике составлы җөмләләрдә гади хәбәр буларак кулланылганда *кирәк* сүзе хикәяләү һәм шарт наклонениеләрендә зат һәм сан белән төрләнә, хикәяләү наклонениесендә исә ул өч төрле заман белән төрләнә.

**Хикәяләү наклонениесе**

Хәзерге заман

| | Берлек сан | Күплек сан |
|---|---|---|
| I зат | *мин кирәк(мен)* | *без кирәкбез* |
| II зат | *син кирәк (сең)* | *сез кирәксез* |
| III зат | *ул кирәк* | *алар кирәк* |

Категорик (билгеле) үткән заман

| | Берлек сан | Күплек сан |
|---|---|---|
| I зат | *мин кирәктем* | *без кирәктек* |
| II зат | *син кирәктең* | *сез кирәктегез* |
| III зат | *ул кирәкте* | *алар кирәкте (ләр)* |

Билгеле киләчәк заман

| | Берлек сан | Күплек сан |
|---|---|---|
| I зат | *мин кирәгәячәкмен* | *без кирәгәячәкбез* |
| II зат | *син кирәгәячәксең* | *сез кирәгәячәксез* |
| III зат | *ул кирәгәячәк* | *алар кирәгәячәк(ләр)* |

Билгесез киләчәк заман

| | Берлек сан | Күплек сан |
|---|---|---|
| I зат | *мин кирәгермен* | *без кирәгербез* |
| II зат | *син кирәгерсең* | *сез кирәгерсез* |
| III зат | *ул кирәгер* | *алар кирәгерләр* |

**Шарт наклонениесе**

| | Берлек сан | Күплек сан |
|---|---|---|
| I зат | *мин кирәксәм* | *без кирәксәк* |
| II зат | *син кирәксәң* | *сез кирәксәгез* |
| III зат | *ул кирәксә* | *алар кирәксә(ләр)* |

*Тиеш* һәм *тиешле* сүзләре исә хәзерге заманда гына зат һәм сан белән төрләнәләр:

| | Берлек сан | Күплек сан |
|---|---|---|
| I зат | *мин тиеш(ле)мен* | *без тиеш(ле)без* |
| II зат | *син тиеш(ле)сең* | *сез тиеш(ле)сез* |
| III зат | *ул тиеш(ле)* | *алар тиеш(ле)ләр* |

*Кирәк* һәм *тиеш* сүзләренең хикәяләү һәм шарт наклонениеләрендә зат-сан белән төрләнүләре *бул* һәм *иде* ярдәмче фигыльләре аша да белдерелә ала.

**Хикәяләү наклонениесе**

I зат. *мин кирәк (тиеш) булам (булдым, булачакмын, булырмын); кирәк (тиеш) идем;*

II зат. *син кирәк (тиеш) буласың (булдың, булачаксың, булырсың); кирәк (тиеш) идең;*

III зат. *ул кирәк (тиеш) була (булды, булачак, булыр); кирәк (тиеш) иде.*

Күплек сан

I зат. *без кирәк (тиеш) булабыз (булдык, булачакбыз, булырбыз); кирәк (тиеш) идек;*

II зат. *сез кирәк (тиеш) буласыз (булдыгыз, булачаксыз, булырсыз); кирәк (тиеш) идегез;*

III зат. *алар кирәк (тиеш) булалар (булдылар, булачаклар, булырлар); кирәк (тиеш) иделәр.*

**Шарт наклонениесе**

| | Берлек сан | Күплек сан |
|---|---|---|
| I зат | *мин кирәк (тиеш) булсам (иде)* | *без кирәк (тиеш) булсак (иде)* |
| II зат | *син кирәк (тиеш) булсаң (иде)* | *сез кирәк (тиеш) булсагыз (иде)* |
| III зат | *ул кирәк (тиеш) булса (иде)* | *алар кирәк (тиеш) булсалар (иде)* |

*Мөмкин* сүзенең наклонение һәм заман мәгънәләре бары тик аналитик ысул – *бул* һәм *иде* ярдәмче фигыльләренең III зат формасы белән генә белдерелә ала: *мөмкин була (иде), булды, булачак (иде); булса (иде)*.

*Ярый* – полифункциональ хәбәрлек сүз. Инфинитивлы аналитик конструкцияләрдә ул мөмкинлек мәгънәсен белдерә: *Яратырга я р ы й җәйне: матур ул, анда зур ямь бар* (Г. Тукай). *Хәреф вә имля мәсьәләсе хакында, бер мөнәсәбәт чыккач, шуны да хәтергә алып узарга я р ы й* (Г. Ибраһимов). *Бездә командирлар белән иркенләп торып сөйләшергә я р ы й* (Ш. Усманов).

*Ярый* сүзенең юклык формасы *ярамый* түбәндәге конструкцияләрдә мөмкин түгеллекне, тыюны, кисәтүне белдерә: – *Ни өчен сезгә Ташкентка барырга я р а м ы й соң?* (Ш. Усманов). *Мин башымны артка бордым. Гәүдә белән борылырга я р а м ы й. Конвой һәр хәрәкәтне качарга әзерләнә дип исәпли һәм шундук ата* (И. Салахов). *Бу тирәдә яланаяк йөрергә я р а м ы й: җылан чагар* (Г. Бәширов). *Кыскасы, бу хикәянең теле яшь язучыга бары бер яктан гына үрнәк була ала: болай язарга һич я р а м ы й* (Г. Бәширов).

Диалогларда мөстәкыйль рәвештә кулланылганда *ярый* сүзе түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1) тыңлаучының гамәлен хуплау: *Шунда тагын фәрештәсе килеп җитә: «Я р а р, яхшы, шундый бул син»,– диеп китә* (Г. Тукай). *Менә анысы я р ы й, кызым! Яраган анысы! – диде Хәйбулла һәм, урыныннан кузгалып, батыр гына адымнар белән өйгә кереп китте* (Ш. Камал). – *Я р ы й, Гөлзәбәр, бик я р ы й. Алай гынамы әле! Мондый авыр вакытта сезнең бу эшегез галимнәрнең зур бер яңалык ачулары шикелле, шундый ук кирәкле...* (Г. Бәширов);

2) сөйләүченең тәкъдимен кабул итү, үтенечен үтәргә риза булу: *[Булат] Су буена төш, көтәрмен. [Мәйсәрә] Я р ы й, я р ы й* (К. Тинчурин). *Куе вуаль эченә яшеренеп, караңгы кичтә Гәүһәрнең*

*конспиратив рәвештә үз итеп килеп керүе – аның дәртен канатландырып җибәрде: – Ярый. Ярый. Бик ярый. Бик мөмкин. Баш өсте, тулаш. Беләсең, мин партияле түгел. Шулай да бик ярый. Бик мөмкин, дип, кат-кат ризалык сүзләрен тезде* (Г. Ибраһимов). *Тимри, кәләпүшен арткарак чигереп, түгәрәк сакалын сыпыргалап торды да: – Ярый, Айсылу сеңелем, мин риза, – диде* (Г. Бәширов). *Ул да көлемсерәп: – Ярый, Хәйбулла абзый, рәхмәт яхшы сүзегезгә, анысын шулай итәрсез. Ләкин чиләк белән генә эш бетмәсен, сез аңар сүз белән дә ярдәм итегез, җыелышлардан тыймагыз, яме? – диде. Хәйбулла уйга калган төслерәк чырай белән: – Шулаймы? ... Ярар, ярар, анысын гына булдырып булыр ла! – диде* (Ш. Камал). *Мактанма, дисеңме, Сибгать дус? Ярар, ярар, мактанмыйм алайса. Әйттем исә кайттым...* (А. Шамов);

3) диалог барышында яки ахырында, я берәр эшне уңышлы башкарып чыкканнан соң; я булмаса, берәр читен хәлдән чыгу җае табылганда әйтелә торган кисәкчә (русча *ладно*) функциясендә куллану: – *Ярый. Эшеңдә мең төрле уңышлар телим, Нәфисә* (Г. Бәширов). *Икәүдән икәү калгач, Андрей табын янына, берни дә булмаган төсле, тыныч кына килеп утырды: – Ярар, чәй эчик, әйдә* (К. Нәҗми). *Ярар, булмаса, яңадан үзем күргәннәргә кайтыйм әле* (Ә. Еники). *Ярый әле, бәхеткә каршы, Хәдичә түтинең тозлаган казы бар икән* (Г. Бәширов). – *Җитмәсә, тагын нәкъ шундый вакытта әнкәйне дә йомыш-юлга җибәргәннәр. Ярый әле, Серафима карчык килеп булышты* (К. Нәҗми).

Искәрмә. *Ярый* хәбәрлек сүзен *ярый* фигыле белән бутамаска кирәк. Болар – ике сүз: *ярый* (1) – мөмкин (можно), ә *ярый* (2) – яраклы (годится) мәгънәләрен белдерә торган лексик омонимнар. Бу – бер; икенчедән, *ярый* (2) бервакытта да ярый (1) кебек бер составлы аналитик конструкцияләрдә модаль компонент буларак кулланылмый, ә ике составлы җөмләләрдә гади фигыль хәбәр булып кына килә ала: *Гәрәй белән Гриша сарайдан чыккач, ул йозакны бикләде дә, елмаеп, аларга кулын сузды: – Күрсәтергә ярый хәзер* (К. Нәҗми). *Мөгаллим. Чалма булгач, казаки да ярар. Хөснетдин. Идел-гарский, кара әле, үзебезнең теге чапан ярамыймы? Җәләй. Ярар, ярар; шуны гына киярсең* (Ш. Камал). – *Купшы кеше имеш: Өр-яңа киез каталарын тупассынып утыз тиенгә сата... Тупас булсалар да, менә мондый көннәрдә киеп йөрергә ярарлар иде әле...* (Ф. Әмирхан). *Бирчугур шахталарыннан чыгарылган вак күмер паровозларга ягарга ярамый* (Ш. Усманов).

# 8. МОДАЛЬ СҮЗЛӘР

Хәбәр ителә торган фикергә сөйләүченең мөнәсәбәтен белдерә торган сүзләр модаль сүзләр дип аталалар [Грамматика современного..., 1970, с. 545, 610; Русская грамматика, 1980, с. 215; Лингвистический..., 1990, с. 303].

Модаль сүзләр субъектив-модаль мәгънәләрне белдерүдә төп лексик чара хезмәтен үтиләр. Төрле аспектларда аларның түбәндәге үзенчәлекләрен билгеләргә мөмкин:

1. Мөстәкыйль лексик-грамматик сүз төркеме буларак, модаль сүзләр төрле сүз төркемнәре җирлегендә формалашканнар; аларның составында һәм семантикалары, һәм функцияләре белән үз сүз төркемнәреннән аерылган һәм изоляцияләнгән сыйфатлар да (*дөрес, билгеле, кызганыч, бәхәссез* һ.б.), рәвешләр дә (*чынлап, чыннан, һичшиксез* һ.б.) һәм кайбер фигыль формалары да (*бугай, икән, имеш, күрәсең, әйтерсең, диярсең* һ.б.) бар; ләкин ул сүзләр хәзер инде уртак семантик табигатьләре һәм функцияләре белен модаль сүзләр исеме астында бер сүз төркеменә берләшәләр.

2. Генетик яктан модаль сүзләр өч төркемчәгә бүленәләр:

а) төрки-татар сүзләре: *чыннан, чынлап, билгеле, бугай, күрәсең, әйтерсең, диярсең, икән, имеш, аяныч, кызганыч, үкенеч;*

ә) гарәп алынмалары: *әлбәттә, вакыйган, шөбһә(сез), бәхәс(сез), шик(сез), мәгълүм (ки), асылда, ахры(сы), мөгаен, ихтимал, шаять (шәт);*

б) фарсы алынмалары: *бәлки, гүя(ки), дөрес(т), рас(т).*

3. Модаль сүзләр – конкрет лексик мәгънәләрен югалткан сүзләр. Шуңа күрә аларны галимнәр номинатив функцияләрдән мәхрүм ителгән сүзләр дип билгелиләр дә [Розенталь Д., Теленкова М., 1972, с. 164; Розенталь Д., Теленкова М., Голуб И., 2000, с. 144]. Ләкин конкрет лексик семантикалы сүзләр булмасалар да, модаль сүзләр сөйләмдә мөһим рольне үтиләр: алар ярдәмендә хәбәрләмә (сообщение)

эчтәлеген логик (интеллектуаль, рациональ) яки эмоциональ (иррациональ) бәяләү тормышка ашырыла (Лингвистический..., 1990, с. 303]: *Ә л б ә т т ә , зур сәясәт бик катлаулы, бик нечкә эш...* (Ә. Еники). *Д ө р е с , яшьләрнең күбесе язу таный иде* (Г. Бәширов). *Кызганыч, бу сөенеч озакка бармады* (И. Салахов). *Ичмаса, белмим мин дигәнсыман тәртипсез, мәгънәсез чиертеп тә җавап бирми. Ә й т е р с е ң , үлгәннәр* (Г. Ибраһимов).

Модаль сүзләрнең семантик нигезен, шул рәвешчә, хәбәрләмәне (сообщение) логик (интеллектуаль, рациональ) квалификацияләү генә түгел, ә эмоциональ реакциянең төрле төрләрен дә эченә ала торган киң мәгънәдәге бәяләү төшенчәсе хасыйл итә [Лингвистический..., 1990, с. 303].

4. Модаль сүзләр ясагыч һәм төрләндергеч кушымчаларны кабул итмиләр. Алардан яңа сүзләр дә, яңа грамматик формалар да ясалмый.

5. Модаль сүзләр җөмлә кисәге була алмыйлар һәм җөмләдәге башка сүзләр белән грамматик бәйләнешкә кермиләр. Алар җөмләдә мөстәкыйль (автоном) урынны билиләр һәм башка сүзләрдән җанлы сөйләмдә интонация, ә язуда өтер белән аерылалар: *Ч ы н н а н д а , бу сугыш дигәннәре әллә нинди куркыныч нәрсә икән* (М. Мәһдиев). *Без бик гарьләндек, ә л б ә т т ә* (М. Мәһдиев). *М ө г а е н , бу манарага менә торган баскыч белән чормага да үтеп буладыр* (Ә. Еники).

Ләкин модаль сүзләр җөмлә структурасына керми торган чит бер элементлар түгелләр. Асылда, һәр модаль сүз диярлек синтаксик структураның элементы булып тора: модаль сүзне алып ташлау белән җөмләнең субъектив-модаль характеристикасы юкка чыга, өлешчә мәгънә үзгәрә, ә кайчакта хәтта җөмләнең бөтенлеге бозыла [Щербак А., 1987, с. 45].

6. Модаль сүзләр ике төрле синтаксик функциядә: кереш сүзләр (а) һәм, сирәк булса да, сүз-җөмлә (ә) буларак та кулланылалар: а) *Д ө р е с , төнге марш үзебез өчен дә бик җиңелдән булмас, ләкин безгә башка юл юк* (Ш. Усманов). *Д ө р е с т , аның* (Тукайның) *телендә, өслүбендә үзенчәлек бар* (Г. Ибраһимов). *Д ө р е с , безнең барыбыз өчен дә бөтенесеннән өстен, бөтенесеннән якын – Тукай иде, иң күп күчерелгән, иң сөеп укылган да Тукай иде* (Ә. Еники). *Ч ы н н а н д а , әллә нинди шигъри як, романтик як* (С. Хәким). *Ч ы н л а п т а , безнең шрапнель шәһәр читендә, позицияләр өстендә ярыла башлады*

(Ш. Усманов). *Ш ө б һ ә с е з , мин башка нәрсәләрем белән сине дә, сиңа булган мөнәсәбәтне дә югалткан идем* (Г. Ибраһимов); ә) *Кем икән соң ул мондый эсседә чабып йөрүче? Малик абзый айгыры түгелме соң бу? Ч ы н л а п  т а ! Кара, нинди җилдереп килә!* (И. Гази). *Мөнирә. Илгиз Кәримович, мин үз дәресемә үзем хуҗа. Туктаров. Ә л б ә т т ә* (Т. Миңнуллин). *Миләүшә. Алар безнең уртак дусларыбыз. Шәһит. Б ә л к и* (Т. Миңнуллин). *Берничә егет: – Д ө р е с ! – дип кычкырып куйдылар* (Ш. Усманов).

Ләкин һәр модаль сүзне дә (мәсәлән: *бугай, икән* сүзләрен) кереш сүз дип һәм, киресенчә, һәр кереш сүзне дә модаль сүз дип билгеләү дөрес булмас иде [Тумашева Д., 1978, б. 211]. Түбәндәге кереш сүзләр, мәсәлән, безнең карашыбызча, модаль сүзләргә карамыйлар:

а) фикерләрне иншалау тәртибен белдерүче кереш сүзләр: *беренчедән, икенчедән... ниһаять* һ.б.; ә) хәбәр ителә торган мәгълүматларның чыганагын белдерүче кереш сүзләр: *минемчә, синеңчә, белгәнебезчә, күргәнебезчә* һ.б.; б) сөйләмнең фикерне яңа фактлар, дәлилләр белән баету, үстерү, тирәнәйтү максатларында китерелгән компонентларын контекст белән бәйләү өчен кулланыла торган кереш сүзләр: *ягъни, мәсәлән, әйтик, бер яктан, икенче яктан* һ.б.; в) фикерләрне гомумиләштерү, йомгаклау, нәтиҗә ясау, сүзләрнең тәмамлануын белдерүче кереш сүзләр: *димәк, бәс, кыскасы, гомумән* һ.б.; г) фикерләрне бер-берсенә капма-каршы куюны белдерүче кереш сүзләр: *киресенчә, хәлбуки, мәгәр, хәер* һ.б.

Лексик-грамматик табигатьләре һәм контекстны оештыруда, җөмләнең структурасын төзүдә рольләре ифрат та төрле булган һәм, гадәттә, сүз җилемнәре дип кенә аталып йөртелә торган әлеге сүзләрне дә [Виноградов В., 1947, с. 736–741; Грамматика..., 1970, с. 614; Петров Н., 1982, с. 60–66] модаль сүзләр кысаларында карау ул сүз төркемен нindидер аморф бер категориягә әвереләдерә [Панфилов В., 1982, с. 161].

7. Модаль сүзләрнең җөмләдәге урыннары, беренче чиратта, бәяләү объекты нәрсә булу белән билгеләнә. Җөмләнең эчтәлеге тулаем бәяләнсә, модаль сүзләр, кагыйдә буларак, я аның алдында, я ахырында киләләр: *Ә л б ә т т ә , кышкы йокыга талган аю язын барыбер уяныр иде* (Т. Галиуллин). *Һ и ч ш и к с е з , бу темалар барысы да балалар өчен якын һәм кирәк темалар* (М. Җәлил). *Нинди сагыш икән*

*ул? М ө г а е н , аерылышудыр, Һичшиксез шулайдыр* (И. Салахов). *Б ә л к е м ә л е , Сафаны солдатка алмаслар да сугыш-орышы да алай кисәк кенә килеп чыкмас, иншалла* (М. Галәү). *И х т и м а л , шушы ишетүләр нәтиҗәсендәдер, минем күңелдә Троицк каласына гомерлек бер мәхәббәт тә уелып калган иде* (Ә. Еники). *Бер карау белән Хәйбулланың күз алдында ачылган бу күренеш аның күңелен биләп торырлык түгел иде ә л б ә т т ә* (Ш. Камал). *Бозылмаган табигать, өркетелмәгән кошлар күпме гасырлардан бирле шулай сакланып килә а х р ы - с ы ...* (Ә. Еники). *Биктаһир карт рәтләп ишетмәде б у г а й : нәрсәдер мыгырданып тегермән эченә кереп китте* (И. Гази).

Бәяләү җөмләнең бер өлеше, кисәгенә генә караса, модаль сүзләр, гадәттә, шул өлеш, кисәкнең алдында киләләр: *Мин барам, ә л б ә т , барам; Бармасам, дөнья йөзе булсын хәрам* (Г. Тукай). *Ләкин аңарда [Гәрәй Солтановта] кискен ышану туа: – Гәүһәрнең шикләнүе, ә л б ә т т ә , дөрес. Серләр, ә л б ә т т ә , Шаһвәлиев аркылы бирелгәннәр* (Г. Ибраһимов). *Әдәбиятның танылган бәхәссез лидеры, ә л б ә т - т ә , Галимҗан Ибраһимов иде* (С. Хәким). *Сезнең чорда, ш и к с е з , социаль чыгыш зур нәрсә итеп каралмас* (Һ. Такташ). *Алар самовар өлгергәндә, һ и ч ш и к с е з , кайтып керерләр шикелле...* (С. Хәким). *Хәзер менә күлдә йөзеп йөргән аккошлар, б ә л к и , теге вакытта окоплар өстеннән очып узган аккошлардыр* (С. Хәким). *Бөтен җирдә сирень. Алар безнең Казанга, м ө г а е н , шул бакчадан күчкәннәрдер* (С. Хәким).

Шуның белән бергә, модаль сүзләр арасында җөмләнең билгеле бер урыннарында гына кулланыла торганнары да бар. *Бугай* һәм *икән* сүзләре, мәсәлән, бары тик җөмләнең ахырында гына, ә *дөрес, чыннан, чыннан да, чынлап та, шиксез* һәм *шөбһәсез* сүзләре җөмлә башында һәм уртасында гына киләләр.

8. Модаль сүзләр еш кына *бик, иң, инде, әле, ки, лә* һәм *-да/-та* көчәйткеч кисәкчәләре белән кулланылалар: *бик дөрес (кызганыч), иң гаҗәбе (аянычы), билгеле (мәгълүм, әлбәттә) инде, билгеле (мәгълүм) ки, бәлки әле, әйтерсең лә, чыннан да, чынлап та.*

Модаль сүзләрнең иң зур семантик төркемен фикернең чынлык дәрәҗәсен (степень достоверности) логик яктан бәйләүне белдерә торган сүзләр тәшкил итә. Алар мәгънә төсмерләре буенча ике төркемчәгә бүленәләр.

1. Фикернең чынлыгын катгый рәвештә раслауны белдерә торган модаль сүзләр: *әлбәттә, (һич)шиксез, (һич)шөбһәсез, вакыйган, бәхәссез, тәгаен, чын, чыннан, чыннан да, чынлап та, асылда, дөрес(т), дөресендә, дөресрәге, билгеле (инде, ки), мәгълүм (инде, ки), рас(т).*

*Ә л б ә т т ә , ... мин: «Халык җырларына тәкълит итүчеләр билгомум булдымы?» – дигән сөальне тәкрар итәм* (Г. Тукай). *Мөндәриҗә, ә л б ә т т ә , күктән түгел, татардан алына* (Г. Ибраһимов). *Ә л б ә т т ә , монда әдипнең табигате вә әхвәле рухиясенең дә катнашы булыр...* (Җ. Вәлиди). *Һәрбер шигырьдә фикер булырга тиеш. Сүз, ә л б ә т т ә , шигъри фикер турында бара (Г. Ахунов). Дөньяның яртысы, ниһаять, җиңел суласа, икенче яртысы, һ и ч ш и к с е з , авыр сулагандыр...* (Ә. Еники). *Җиткерәбез аңар бик матур хәбәр: алдагы көзгә арыш, һ и ч ш ө б һ ә с е з , булыр чибәр* (Г. Тукай). *Гаяз! Бу исем хәзер, һ и ч ш ө б һ ә с е з , татар әдәбиятының, татар поэзиясенең үзәгендә тора* (Җ. Вәлиди). *В а к ы й г а н , буңа сәбәпләр дә юк түгел, ләкин мин андый бер тәгаеннән еракмын* (Г. Ибраһимов). *В а к ы й г а н , бу вакытта башкорт ихтиляльчеләре Казан әтрафы хезмәт әһеле белән берләшеп килгән чакларында хөкүмәт Казан йомышчыларын мобилизовать итеп алып, башкорт вә башка гайре рус кузгалучыларына каршы куеп аларны җиңгән иде* (Г. Гобәйдуллин). *«Бер заманда, ш ө б һ ә с е з , бу күл кибәр»,– дип гакыллы зур хәкимнәр сөйлиләр* (Г. Тукай). *Сезнең чорда, ш и к с е з , социаль чыгыш зур бер нәрсә итеп каралмас* (Һ. Такташ). *Сабан туена, т ә г а е н , кайтырбыз* (Г. Бәширов). *Күк, Җир, Су матурлыгына битараф булгач инде, – димәк, эш вәгазьдән узган, җаның, т ә г а е н , чирле* (Р. Фәйзуллин). *Бу «бер-берсе күрер» сүзе миндә икенче уй уятты. Ч ы н , бер-берсе күрмәсә, моның берлә төн үткәреп, шул берсенә берсе охшаган мәгънәсез тормышны үзгәләштерсәң ни булыр иде?* (Г. Исхакый). *Әйе, ул өйләнә. Ч ы н д а , кемгә?* (Г. Исхакый). *Ч ы н н а н д а , урам буйлап, төркем-төркем булып хатын-кызлар килгәне күренде* (Ш. Камал). *Безнең, ч ы н н а н д а , горурланып сөйләрлек шагыйрьләребез бар* (С. Хәким). *Ч ы н н а н д а , аның Гомере шундый көтмәгәндә кайткан иде, аның Гомере шундый тиз китеп тә барды* (Ә. Еники). *Әдәбият, а с ы л д а , хатирәләр иле ич, бу әсәр М. Мәһдиевнең хатирәләре диңгез кебек киң икәнлеген сиздереп китте* (А. Гыйләҗев). *Минем «Нәни разбойник» чыгу белән, б и л г е л е , бик нык шауладылар* (Һ. Такташ). *Поэзиядә Такташ чоры...*

*Бу чорны, билгеле, Такташ үзе генә тудырмады* (С. Хәким). *Билгеле, бәйрәм белән генә эш бетми, аның белән артык мавыгырга да ярамый* (Г. Бәширов). *Мәгълүм ки, һәрнәрсәнең чиге бар. Кеше никадәр генә акыллы, никадәр көчле булмасын, ул да үзе теләгәннең һәммәсен дә булдыра алмый* (Г. Бәширов). *Безнең бит әле дәртле, яшь чакларыбыз – билгеле инде, уен-көлке, җыр-музыканы яратабыз* (Ә. Еники). *Рас, бу шагыйрьлек белән мин, чыннан да, аурыйм бугай* (Г. Тукай). *Дөрест, Тукайның телендә, өслүбендә үзенчәлек бар* (Г. Ибраһимов). *Дөрес, бу амбарлар хәзер дә буш түгел* (А. Шамов). *Дөресрәге, яшермичә әйтим, бер чиркану тойгысы йөрәкне өшетеп җибәргәндәй булды* (Ә. Еники). *Каләм кулда була торып, яшь шагыйрьгә, Мәгълүмдер ки, курку белән өркү харам* (Г. Тукай). *Мәгълүм инде, бу бүре дә кача шулай, Хәйлә белән качарга юл ача шулай* (Г. Тукай). *Мәгълүм ки, ул елларда Урта Азиягә киткән татар яшьләренең бик күбесе шунда торып, төпләнеп тә калды* (Ә. Еники).

2. Фикернең чынлыгын фараз кылу, мөмкинлек, ихтималлык яки икеләнү төсмерләре белән белдерә торган модаль сүзләр: *бәлки, бугай, шаять, (шәт), мөгаен, ихтимал, ахры(сы), күрәсең.*

*Аклы киемен кигәндер, Бәлки, кайтыр дигәндер, Зәңгәр карны ера-ера вокзалларга килгәндер... Бәлки, табылыр дигәндер* (Х. Туфан). *Җанын талкып, артык йөдәтмә син уйчан калган ялгыз кешене, җиңәр өчен күпләрне ул, бәлки, ялгызлыгы белән көчледер?* (Р. Фәйзуллин). *Бәлки, ул таш астыннан чыккан яшь үлән шикелле саф мәхәббәтем мине гел генә хыял дөньясына китеп яшәргә, шуннан үземә ләззәт, юаныч табарга өйрәткәндер, бәлки, ул мине Дим буйлары өстендәге айлы кичләрнең тирән тынлыгын ишетергә өйрәткәндер, бәлки, ул мине җирдәге һәм судагы барча җан ияләренә миһербанлы булырга өйрәткәндер...* (Ә. Еники). *Син миңа хат язуны үзеңнең бишьеллык планыңа кертмәгәнсең бугай* (Һ. Такташ). *Бу куе су, тигезсез ташлар белән корыштырылган черек почмаклардан саркый бугай, тышта кар яуган саен арта бара* (К. Нәҗми). *Сыенмадык, шаять, сыенмабыз Нафталинлы уют астына* (Х. Туфан). *Шәт, беләсездер инде, без монда сезгә хәтле бик күп еллар элек килгән кешеләр* (М. Галәү). *Мөгаен, ярсып сугышкан – Таныклык түгел йөзе: Битендә дүрт-биш урында Ямалган яра эзе* (Х. Туфан). *Мөгаен, бу манарага менә торган баскыч белән чормага үтеп була*

*торгандыр...* (Ә. Еники). *И х т и м а л, ул чорда Гомәр Гали чит илгә чыгучы татар совет язучыларының беренчесе булгандыр* (Г. Ахунов). *Сине күрәм мин төшемдә, Сине сагынам өнемдә. Теләсәм дә, а х р ы, сине мин онталмам гомергә* (М. Җәлил). *Атлар каядыр югалалар. Минә ике сәгать инде аларның берсе дә күренми. А х р ы с ы, чабарга киткәннәрдер* (Г. Ибраһимов). *К ү р ә с е ң, зур сәнгать әсәрләре тудыру өчен авторга алдан тирән рухи әзерлек кирәк* (С. Хәким). *Әти базардан шактый ук кызу кайткандыр к ү р ә с е ң, байталдан әчкелтем тир исе бөркелеп тора* (Г. Бәширов). *Гаҗәп хәл: тулы бәхет бирәүгә дә насыйп түгел к ү р ә с е ң* (Ә. Еники).

Хәбәр ителә торган фикерне эмоциональ яктан бәяләүне белдерә торган модаль сүзләр: *(ни) гаҗәп, (иң) гаҗәбе, (ни) кызганыч, (ни) үкенеч, (ни) аяныч.*

*Г а җ ә п, миңа да Дәүләкәннән китәргә өч кенә ел калган икән инде* (Ә. Еники). *Әмма, и ң г а җ ә б е, әнә шундый гадәттән тыш шартларга барып эләгүемә карамастан, миндә, ничектер, үзеннән-үзе язасы килү теләге кабынды* (Ә. Еники). *К ы з г а н ы ч, бу сөенеч тә озакка бармады* (И. Салахов). *Әмма, н и к ы з г а н ы ч, Рәхилә барлык туганнары арасында иң гомерсезе дә булды* (Ә. Еники). *Н и ү к е н е ч, бәхетле җәй томырылып үтә-китә икән* (А. Гыйләҗев). *Н и а я н ы ч, минем уртакул әсәрләр, уртакул тәрҗемәчеләр аша үтеп чыгып, аның күңелендә теләктәшлек уятмадылар шикелле* (А. Гыйләҗев).

*Икән, микән* сүзләре түбәндәге субъектив-модаль мәгънәләрне белдерә:

а) сөйләүче (яки автор) тарафыннан тормыш тәҗрибәсенә, күргән-белгәннәргә нигезләнеп ясалган фикри нәтиҗә-сентенцияләрне: *Кеше хәлен кеше белмәс и к ә н д е р, Бу хәсрәт китәр көн бар микәндер* (Г. Кандалый). *Сөю шундый нәрсә и к ә н, һич суынмый икән шул, Бик онытырга теләсәң дә, онтып булмый икән шул* (М. Җәлил). *Тел ил белән и к ә н, аерым түгел икән. Ил язмышы – тел язмышы икән* (С. Хәким). *Тора-бара мин ныклы бер фикергә килдем. Әйбәт әсәр шагыйрь һәм композиторның, җырчының бергә януында туа и к ә н* (С. Хәким). *Минем иманым тагын да ныгыды, халык моңнарына бернинди аңлатмалар да, комментарийлар да кирәк түгел и к ә н...* (С. Хәким). *Олы кешегә бишмәтсез килешми и к ә н шул...* (Г. Бәширов). *Мин моның сәбәбен соңыннан гына аңладым: сандугач канаты –*

*сөйдергеч* *и к ә н* (Г. Бәширов). *Дөньяда иң авыр газап – сөйләшмәү* *и к ә н* (И. Салахов). *Кояш сүрәнләнер вакыт. Әмма монда, Ерак Көнчыгышта, кояш якын* *и к ә н* (И. Салахов). *Ә кыргый капитализм бернинди мораль кагыйдәләрне белми һәм белергә дә теләми* *и к ә н* *ул!* (Ә. Еники). *Мусаның да үз куанычы бар иде: солдат күңеле – гөл бакчасы* *и к ә н !..* (Ш. Маннур). *Кайбер илләрдә шосседан егерме биш метр киңлегендәге арада печәнне терлеккә бөтенләй бирмиләр* *и к ә н* (М. Мәһдиев). *Мин, сабый чактагы күзәтүләремнән чыгып, бер нәтиҗә ясадым: ил өстенә сугыш афәте килгәндә ир кеше сугышка китсен, өйдә калмасын* *и к ә н* (М. Мәһдиев). *Кеше җаны – эт җаны* *и к ә н . Контузия алган – шулай да исән калган* (М. Мәһдиев). *Яшьлектә дә, хәтта картлыкта да яндыра* *и к ә н* *сөю – ни чара?! – димәк татлы!* (Р. Фәйзуллин). *Илнең зурлык-хурлыгы да – барсы бу җирдә* *и к ә н . Башың күккә тигәндә сыгылмам димә* *и к ә н !* (Р. Фәйзуллин). *...Фаҗига башларны яргач, зиһенне ача икән. Җиңгәннәр итеге белән күзеңә баса* *и к ә н ...* (Р. Фәйзуллин);

ә) искәртмәстән бер кешегә яки күренеш-хәлгә тап булганда кинәттән туган уйны яки әйтелгән раслауны белдерә [Юлдашев А., 1958, с. 186]: *Фәхри аны чак таныды: Гәрәй Солтан* *и к ә н !* (Г. Ибраһимов). *Караса, дәһри Садыйкның дошман шәрикләреннән Гали белән Сафа* *и к ә н !* (Г. Ибраһимов). *Хәсән, көчәнеп кенә елмаеп: Ә, Саматов* *и к ә н ! Саумы? Нихәлләр? – дип, егет белән күреште* (Ф. Әмирхан). *Җәлал тәрәзәгә карады да, сискәнеп киткән адәмсыман: – Ә..., яктырып беткән* *и к ә н ... Соңга калмасак ярар иде. Тизрәк булырга кирәк,– дип урыныннан торды* (Г. Ибраһимов). *Абау!.. Без таңны атыра язганбыз* *и к ә н , – диде дә Гайния урыныннан кузгалды* (Г. Ибраһимов). *Вагонга килеп кергән яңа дежурный Исмәгыйль, борынын тотып, кире чигенде: – Уф! Сездә чын кыямәт* *и к ә н . Бу ни ясыйсыз бу?* (Ш. Усманов). *Шунда тәрәзәгә күзем төште. Нәкъ манара өстендә генә тулган ай эленеп тора* *и к ә н* (Г. Бәширов). *Баксаң, ике ел эчендә авылда ике оя кызлар өлгергән* *и к ә н . Ике елда малайлар үсеп җиткән* *и к ә н ...* (М. Мәһдиев*). Поезд инде Курса Почмак басуыннан бар*а *и к ә н* (М. Мәһдиев);

б) сорау алмашлыклары һәм кисәкчәләр белән бергә гаҗәпләнү, соклану кебек мәгънәләрне белдерә: *Мәҗлестә моңа авыз гына тидерделәр, тәмләп-тәмләп өчәр генә йоттылар, шунда үзара:*

*– Фәтхия апаның кулы гаҗәп* и к ә н *. Телеңне йотарсың, шундый тәмле, – диешеп, өзлексез сөйләнеп, мактап, күтәреп шаулаштылар* (Г. Ибраһимов). *Чыннан, хәйран булып, карап, мактап, һәрберсенә: «Ай, рәхмәт, һай рәхмәт, бик зур килгәннәр* и к ә н *, кызыбызга бик зур хөрмәт күрсәткәннәр* и к ә н *? Һай рәхмәт, бик рәхмәт!» – дип, туктаусыз шаулашып, мулла артынан кул күтәреп дога кылдылар да кодаларның күчтәнәчләрен кире, теге якка чыгардылар* (Г. Ибраһимов). *Я Алла, мондый да гүзәл җан булыр* и к ә н *дөньяда!* (И. Салахов). *Нинди бөек көч* и к ә н *ул сагыну, көтү, өметләнү!* (И. Салахов). *Гаҗәп* и к ә н *ул яңа явып торган тәңкә кар исе – шәрап эчкән кебек тәмле исертә, дәрт өсти* (И. Салахов). *Бик ямьле, бик хозур җир* и к ә н *!..* (Ә. Еники). *Шулай да, сабактан кайткач, бу яңа кунакларны төшеп карамый чыдап булмады... Төштем, ни күзем белән күрим, бу бәтиләр шул кадәр матурлар. шул кадәр матурлар* и к ә н *...* (Ф. Әмирхан). *Кызы бигрәк сөйкемле* и к ә н *шул! Пешкән алма шикелле* и к ә н *шул!* (М. Җәлил). *Йөрешләрең гаҗәиб хәйран* и к ә н д е р *, Хода сәни мәңа язган микәндер?* (Г. Кандалый). *Торналар, озын биек аяклы күк йөзендәге болыт кебек, зәңгәрсу-кургаш каурыйлы, хәтәр озын томшыклы кошлар* и к ә н (М. Мәһдиев). *Их, дөнья! Адәм бу чаклы үзгәрсә үзгәрә* и к ә н (Г. Ибраһимов);

в) фараз кылу, икеләнү, шикләнү, шөбһәләнү кебек субъектив-модаль төсмерләр белән катлауландырылган сорауны белдерә: *Языйм* м и к ә н *, җитәр* м и к ә н *, Язу файда итәр* м и к ә н *! Бу кайтулар бетәр* м и к ә н *. Гомерлеккә китәр* м и к ә н *?* (Г. Кандалый). *Тыштаниләр бар* и к ә н *: Юллар зәңгәр кар* м и к ә н *? Боз тәрәзә алсулана, Пожар* м и к ә н *, таң* м и к ә н *? Тышта ниләр бар* и к ә н *?* (Х. Туфан). *Ни* и к ә н *соң ул шытырдаучы вә нинди җан* и к ә н *? Ул әле яшьрен: песигә дус* м и к ә н *, дошман* м и к ә н *?* (Г. Тукай). *Тәрәзәгә кагыла Акрын гына...– Кем* и к ә н *бу? – дисәм, җил* и к ә н *; йомышы бардыр, бәлки? Ләкин дәшми: «Әйтимме* и к ә н *... юкмы?..» – ди* м и к ә н (Х. Туфан). *Бу ни эш* и к ә н *?.. Гөлбануның электән йөргән егете булдымы* и к ә н *? Миңа дигән кызны алды, дип, үч итеп, кисәргә маташтымы* и к ә н *? Ул кем* и к ә н *? Кара юргада чакта нигә бернәрсә дә беленмәде* и к ә н *?* (Г. Ибраһимов). *– Ни эшләп һөҗүм башламыйлар* и к ә н *? – әллә штаб безне бөтенләй онытты мы* и к ә н *?* (Ш. Усманов). *Кемнәрнең иңнәренә кулны салырга* и к ә н *? Җилкәнле*

*ялгыз көймәмә кемне алырга и к ә н ?* (Р. Фәйзуллин). *Ул шигырьләрнең авторы кем булды и к ә н ?* (М. Мәһдиев). *Бигрәк дәртле и к ә н шул йөрәге, Кайда и к ә н егетнең сөйгәне?* (М. Җәлил). *Кичке бишләр булдымы и к ә н , җил тынган, көн кинәт кенә җылыткан, такта-коймалардан җылы, рәхимле ис – такта исе борынга бәрелә* (М. Мәһдиев).

*Имеш* һәм *янәсе (янәсә)* модаль сүзләре кемнең дә булса уй-фикерләре сөйләүче яки автор тарафыннан юмор (а) яки ирония, сарказм (б) тонында бирелгүен белдерәләр [Курбатов Х., 1956, б. 128–129]:

а) *Шигырь белән, болай диеп Язып куйды бер читкә: «Хат ташучы эшен кара, Шул да эш була, и м е ш ! Үзе язган хатларны да Үзе ташырга тиеш»* (М. Җәлил). *Кибете янына килгән кешеләр өчен кафесы.., «Шүрәле» кафесы. Кырлайга кил дә, Шүрәлесен күрми кит и м е ш* (С. Хәким). *«Йолдыз җиле» – Рәдиф булсын да аңа «йолдыз җиле» кагылмасын, и м е ш* (С. Хәким). *Ах, бу фән кешеләре! Кара син аларны, халык өчен бары тик «җир» дигән сүз генә бар иде, болар нишләтеп ваклап бетергәннәр! Кәзле – карбонатлы, и м е ш !* (М. Мәһдиев). *Шуннан соң иптәшләр миңа ябыштылар: давай да давай, син җиңел сөякле, син йөрергә иренмисең и м е ш ...* (Ә. Еники). *Малайның авызы колагына җитә: я н ә с е , ул хәзер ындыр суга белә башлады* (И. Гази). *Бервакытны Сәүбән аңа: акча гына юнәтик, шәһәргә күчәрбез дигән иде. Шәһәрдә, я н ә с е , бөтен Тигәнәле халкы сыярлык йортлар бар* (К. Нәҗми). *Кешегә әйтми генә җыена башладык. Яңа дөньялар күрәбез, китап өчен кызыклы кешеләр эзлибез я н ә с е* (Г. Ахунов);

ә) *Кара инде. Оятыңнан җир ярыгына чәнчелеп кит бит. Үзең өчен генә түгел, аның өчен дә оят! Шагыйрь и м е ш , мәшһүр и м е ш : өйләнми и м е ш : бер-ике атна башымны әйләндереп чыгарды бит, каһәр!* (Ш. Камал). *Әйе, лезвие белән газонда печән җыю. Авыл хуҗалыгына ярдәм я н ә с е* (М. Мәһдиев). *И м е ш , төш юрау – зарарлы гореф-гадәт, бу – диннән, ә дин – халык өчен әфиун. Әфиун и к ә н , димәк, аңа каршы көрәшергә кирәк. Төш күрмә. Йокла и вчу!..* *Бюрократ галим әнә шулай фикер йөртә* (М. Мәһдиев). *Ни юләр сатып килеп керде соң әле ул берегә? Акча күбрәк төшерә и м е ш . Төшерден!* (И. Гази). *Күзен йомган, муен бөккән, башында чалма чорналган, Кибән чалма кибәк башта: Ишан булган и м е ш , хайван* (Г. Тукай). *«Шайтан аздырган» и м е ш , «Юлдан яздырган» и м е ш ! Кире та-*

*тар, иң элек Вөҗданың берлән килеш!* (Г. Тукай). *Фельдшер: хайван кебек сырага җибәреләләр дә – пидимия и м е ш !., холера и м е ш !., бер дә юкка кеше хафалап йөриләр, чәнчелгерләре!...– дип сүгенә калды* (Ш. Камал). *Гайнетдин алай тиз каушардай күренмәде, яман усал кызган тавыш белән бөтен театрны яңгыратып: – Чыгарырсың!!! Тапкан бер сүз: и м е ш , мәҗлестән чыгартам. Бик исем китми, чыгарта бир!* (Г. Ибраһимов). *– Адәм көлкесе бит: и м е ш , сигез сәгать эш вакыты! И м е ш , бер ярым кат арттырылсын! Тот капчыгыңны!* (Г. Ибраһимов). *– Әйе, и м е ш тә, миллионлап акча ясаганнар икән, ясасалар, фаразан, үзләре тырышып ясадылар: гомерләре буена өсләренә җүнле кием дә кимәделәр!* (Ф. Әмирхан). *Якупның җыелыштагы чыгышын Малик игътибар белән тыңлады. «Кара син аны.– дип уйлап утырды ул,– нинди сүзләр лыгырдарга өйрәнеп кайткан! Политика турында... Хөкүмәт алдаган и м е ш . Җир бирмәячәк и м е ш . Ник бирсен ул сезгә җир!»* (И. Гази). *...Бүгенге авыл җыелышында Малик абзагыз сабын ящигы өстендә тәкәббер генә елмаеп утырды: «Я н ә с е , эх, сез, бичаралар! Сезгәме соң инде алпавытның ышна җирен алу!..»* (И. Гази). *Шуның өстенә хәвефле бер караш соңгы вакытларда үзен ачык сиздерә башлады: я н ә с е , татар теленең киләчәге юк, иртәме-соңмы ул йотылырга тиеш...* (Ә. Еники). *Хатны колхоз председателе малае Фикърәт язган булырга тиеш. Нәрсә дигән була бит, я н ә с е : «Хатлар язып, Айзирәне борчыма, аның ансыз да үз кайгысы үзенә җиткән...»* (М. Хәсәнов).

*Имеш* сүзе кемнеңдер (яки кемнәрнеңдер) сүзләренә сөйләүченең (яки авторның) ышанмавын (яки ышанып бетмәвен), шик-шөбһә белән каравын да белдерә: *Ышандырмакчы булды ул, юләр! – безне; и м е ш , тәңре аның аузы белән сөйли, аңа килгән, имеш, әмре!* (Г. Тукай). *Күңелемә кинәт бернәрсә килде: тукта әле, кайдадыр юлда, пароходтамы, бер станциядәме, чех дип, словак дип, нидер лыгырдаганнар иде түгелме соң?.. Йөз мең кеше и м е ш , баштанаяк кораллылар имеш, Самараны алганнармы, алаларны и м е ш , аннан башка калаларга китәләр и м е ш ... Белмим, тагы шундый «имеш-мимешләр» сөйләгәннәр иде...* (Г. Ибраһимов). *«Керосинны бик күп эчә и м е ш , җимерелгәч, төзәтеп булмый и м е ш »,– дигән булалар* (Ш. Камал). *Шулай көйләнер төсле тоелганда, озын телләр, кайсы көнләп, кайберләре үч итеп, карчыкның күңел ярасына тоз сибә башладылар.*

*И м е ш , Нәфисә Зиннәттән бизгән икән инде. «Ачуым ачу, кибектерәм әле мин аны», – дип әйтеп әйтәдер, ди* (Г. Бәширов). *Малик тагын хәлфәнең сүзен бүлде: – Ә менә әйтәләр: ул Учредительный дигән собраниегез бөтенләй җыелмаячак и м е ш ?* (И. Гази). *– Мин дә ишеткән идем аны ишетүен, тик күңел дигәнең әллә ничек ышанып бетми: бер тиенсез ике йөз дисәтинә җир бирсеннәр и м е ш* (И. Гази).

*Гүя (ки)* һәм *әйтерсең, диярсең* кебек модаль теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр субъектив ассоциацияләргә нигезләнгән чагыштыруны белдерәләр. Мондый чагыштыруда чынбарлыкта реаль факт буларак яши торган бер күренеш (яки ситуация) икенче бер (ирреаль) күренешкә (яки ситуациягә) охшатыла, шул юл белән чагыштыруның беренче элементына субъектив аңлатма (интерпретация) бирелә, нәтиҗәдә сөйләм субъектив-модаль мәгънәләр белән баетыла [Грамматика..., 1970, с. 733; Русская грамматика, 1986, с. 607].

Чагыштыру һәм чын түгеллек мәгънәләре дә югарыда күрсәтелгән модаль теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр белән белдереләләр. *Сукранам мин, кар арасыннан карый да ай көлә, Мин фәкыйрь михнәттә, г ү я чарлагыннан бай көлә* (Г. Тукай). *Безнең маэмай рәхәт тора, сафа сөрә, Җитезләнә, уйный, һаман йөгерә, өрә, Карый миңа мәхәббәтле күзе белән, г ү я уйныйк дигән була, г ү я көлә* (Г. Тукай). *Аның һәрнәрсәсе, һәрбер хәрәкәте миңа салкынлык бирә, аның эчендә г ү я боз диңгезе бар...* (Г. Ибраһимов). *Әнә, атлар чыдаша алмый, баскан җирендә түзә алмый торалар, г ү я , йөрәкләре ашкына, г ү я , әллә кемне тизрәк алып китәргә ашыгалар* (Г. Ибраһимов). *Ай түбәнләнә һәм кызара, йолдызлар, г ү я , күз яше аркылы карап елмаялар* (Ш. Камал). *Бу тавыш, бу такмаклар башка вакытта депутат әфәндедең йокысын китерсәләр дә, хәзер, ничектер, уңайсыз, эчен пошыра иделәр. Г ү я , баягы өч алъяпкычлы татар кочаклашып биеп, аны мыскыллап шул такмакларны әйтә иделәр* (Ш. Камал). *Ак чәчәкләр ява, дөнья матур, шундый матур булып тоела; Күге зәңгәр, г ү я , йолдызлары Ак кар булып җиргә коела* (Х. Туфан). *Еламыйм, дим, тынычсызлап тынган булам, Ләкин һаман йоклый алмыйм. Г ү я , минем Баш астында йоклап ята кара елан* (Һ. Такташ). *Ромашкалар төшеп килә үрдән, Бар да тигез, бар да бер корма, Сүз куешып бергә үскән алар, Бер урында, г ү я бер кырда* (С. Хәким). *Томан басты, г ү я күзләренә, Шуып төште маңгай чәчләре. Иптәш кызы нидер әйткән иде... Дәшмәде*

(И. Юзиев). *Хәвеф – кемгә аста. Хәвеф – кемгә өстә..., Яшенле күктә ут булып, г ү я уйлар кисешкән* (Р. Фәйзуллин).

*Бөтен ил өстенә, ә й т е р с е ң , ниндидер кара сөрем күтәрелде* (Г. Ибраһимов). *Ә й т е р с е ң , бөтен табигать үлә – тынлык шул дәрәҗәдә көчәя...* (Г. Ибраһимов). *Гөрләп тора бүлмә, ә й т е р с е ң лә, тугыз Туфан анда, ун Такташ* (Х. Туфан). *Шәүлегән шундый ачыргаланып кычкыра, шундый кырыкка бөтерелә, ә й т е р с е ң , без аның явыз дошманнары, ә й т е р с е ң , нәселен корытырга килгәнбез* (Г. Бәширов). *Ашыкмыйча, калгый гына тәнкә кар ява, ә й т е р с е ң лә күктән йолдызлар коела...* (И. Салахов). *Бу – сирәк була торган хәл. Ә й т е р с е ң , көчле инструментның бер кылы өзелде* (М. Мәһдиев). *Яшьлекләр инде үтсә дә, моңаер чаклар җитсә дә, күңел һәм тынычлык теләми һаман да. Ә й т е р с е ң лә, бәхет көткән бер борылыш бар анда* (Р. Фәйзуллин).

*Шакир бара җырлап, аяклары җиргә тими ахры, д и я р с е ң* (М. Җәлил). *Шуның кияүдән кайткан бер кызы бар. Шайтан белсен аны, төсенә карап, бернәрсә әйтеп булмый. Шундый төс инде менә, противогаз кигән д и я р с е ң* (А. Шамов). *Менә бервакыт мәчетнең икенче ягыннан бер адәм килеп чыкты. Хозыр-Ильяс д и я р с е ң : апак сакал, яшел чапан, яшел читек, кулда бик озын яшел таяк, башта саргылт чалма, аның да түбәсеннән очлаеп, яшел тышлы бүрек күренеп тора* (Г. Ибраһимов).

# 9. БӘЙЛЕКЛӘР ҺӘМ БӘЙЛЕК СҮЗЛӘР

Бәйлекләр – ярдәмлек категориясенә керә торган лексик берәмлекләр, аларның төп вазифасы – мөстәкыйль сүзләр арасында төрле-төрле мәгънә мөнәсәбәтен белдерү, аларны бер-берсенә бәйләү. Бәйлекләр, шулай ук бәйлек сүзләр, мөстәкыйль лексик берәмлекләрнең формасын тәшкил итеп, иярүче сүзнең составында тора: *бинт б е л ә н чорнады, урманга т а б а китте, ут к е б е к кызыл, авыл а ш а узу, сугышка к а д ә р салынган, килгән с а е н тикшерә.*

Бәйлекләр синтетик чара булып исәпләнә, чөнки алар, кушымчалар кебек үк, үзләреннән алда килгән сүз белән тыгыз бәйләнештә карала.

Бәйлекләрнең барлыкка килүе дә аларның синтетик характерга ия булулары турында сөйли: мөстәкыйльлекләрен югалтып, алар, тора-бара, ярдәмлеккә әйләнеп китәләр.

Төрки телләрнең күбесендә бәйлек вазифасын үтәп йөргән берәмлекләрнең аерым телләрдә кушымчага әйләнеп китү очраклары да бар: мәсәлән, *белән, өчен* бәйлекләре чуваш телендә килеш кушымчасына әверелгән: *ылтынпа* – алтын белән, *камшан* – кем өчен.

Иярченле кушма җөмләдә алар иярүче компонентны баш җөмләгә бәйләүдә катнашалар, шуңа күрә синтетик төрне формалаштыруга булышалар, бу яклары белән дә алар кушымча һәм фигыль формасына тәңгәл киләләр: *Мохтаров килеп туктауга, алар сүзләрен бүлделәр* (Ш. Камал). – *Мохтаров килеп туктау б е л ә н , алар сүзләрен бүлделәр,* һәр ике төзелмә дә синтетик төргә турыдан-туры карый, бәйләнеш тыгызлыгы һәр ике төзелмәдә бердәй.

Бәйлек сүзләр бәйлекләрдән шуның белән аерыла: алар мөстәкыйль сүзләрне үзара бәйләүдә дә катнашалар, икенче очракта, лексик мәгънәгә ия булып, мөстәкыйльлекләрен югалтмыйлар: 1) *Профессор уйланып торган а р а д а , Вера Павловна белән дәвалаучы врач Маһирә ханым Бариева кабинетка килеп керделәр* (Г. Әпсәләмов); 2) *Садыйк ике лабаз а р а с ы н бүлеп алган* (Г. Гобәй).

Мондый сүзләр хәтта вакыт, сәбәп, көн, нәтиҗә, урын, заман шикелле лексик берәмлекләрне дә үзләренә сыйдыралар.

Бәйлек сүзләрнең икенче төр бәйләүче чараларны формалаштыруда бик актив катнашуларын да әйтеп китәргә кирәк. Мөнәсәбәтле сүзләр составында аларны без бик еш очратабыз: *Сыер кертергә бер абзар күрсәтте, шул арада Каюм белән Мостафа килеп чыктылар* (Ш. Камал). *Ачылды бер заманны күк йөзе, инде болыт китте, Күңелгә шул вакыт бер төрле рәхәтлек тулып китте* (Г. Тукай). *Мин Нәгыймне көзгә хәтле коммунада эшләсен дип әйтеп әйткән чагында, Мәдинә белән Габделхәй речь сөйләмәгәннәр иде әле* (Ш. Камал). *Фронт якынлашу сәбәпле, приют эвакуациягә әзерләнә* (Д. Юлтый). *Аның бер аягы – агач, шулай булуга карамастан ул өлгер, хәрәкәтләре җитез* (М. Хәсәнов). *Нәфисә Карлыгачны үз бригадасына алды, шул көннән алар аерылмас дуслар булып киттеләр* (Г. Бәширов).

Шул рәвешле мөнәсәбәтле сүзләрне формалаштыруда күп кенә лексик берәмлекләр катнаша: *йөзендә, борын, аркасында, нисбәттән, уңаеннан, ярдәмендә, җирлектә* һ.б.

**Бәйлек һәм бәйлек сүзләрнең морфологик үзенчәлекләре.** Үзләренең составлары ягыннан бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр ике зур төркемне тәшкил итә:

1. Гади төрләр.
2. Берничә сүзне үз эченә алган төрләр.

Беренчеләре: *белән, кебек, шикелле, чаклы, хәтле, аркылы, өчен, соң, карамастан, турында, хакында, таба, максаттан* һ.б.

Икенче төрне тәшкил итүчеләр: *мөнәсәбәте белән, уңае белән, аермалы буларак, өчен дип* һ.б. *Туй уңае беләндер инде, сиплəп яңартылган мунча курчак өе кебек иде* (Ә. Еники). *Кыз, чәчен рәтләгән төс белән, кулын башына куйды* (М. Хөсәен). *Алар Галимҗан Ибраһимов белән бергә Уфа мәдрәсәсендә укыдылар* (С. Кудаш).

Бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр генетик яктан берничә төркемгә бүленә:

1. Фигыль сүз төркеменә бәйле төрләр: *Тирә-юньдә атышлар булуга, шау-шуга карамастан, кошлар, өзеп-өзеп сайрап алалар* (А. Шамов). *Чыгабыз дигәндә генә, ишектән мастер*

*Габитов килеп керде* (И. Гази). *Сумкасын алырга була, мәктәпкә керде* (И. Гази). *Бүлмәдә Мансурдан кала беркем дә юк иде* («Казан утлары»).

2. Исем сүз төркеменә бәйле төрләр гаять күп: *Эшләп аргач чумдык инешкә, чабак төсле йөзеп шаярдык* (М. Җәлил). *Җил кай якка иссә, камыш шул якка борылыр* (мәкаль). *Яр буендагы үләннәргә төшкән чык бөртекләре кыйммәтле зөбәрҗәтләрдәй җемелдәшә* (Д. Галимов). *Утырам мин тимер читлек эчендә, каты кайгы, ачы хәсрәт эчемдә* (Г. Тукай). *Революция килгән вакытта, байтак урман кискәннәр иде* (Г. Ибраһимов).

3. Рәвеш сүз төркеме белән бәйле төрләр: *Җыеннан соң озак тормады, халык арыш урагына төште* (М. Гали). *Кыңгыр эш кырык елдан соң да беленә* (мәкаль). *Күңелем пакь, сүзем хак, ил каршында йөзем ак* (мәкаль).

**Бәйлекләрне һәм бәйлек сүзләрне куллану.** Бәйлекләр үзләренең кулланылышлары, мәгънә мөнәсәбәтен бирүдә катнашулары ягыннан бердәй түгел: бар бик нык чикләнгәннәре, бар күп вазифага ия булганнары, бар сүзтезмәдә генә урын алганнары, бар кушма җөмләне оештыруда катнашканнары, ике төрдә дә урын алганнары да күп. Мисалларны *белән (берлән)* бәйлегеннән башлап китик.

Бу бәйлек ярдәмендә оешкан сүзтезмәләрдә күпләгән мәгънә төсмере чагылыш таба:

1. Катнашлык нисбәте белдерелә: *Ул әтисе белән әйбәтләп кенә, матур гына сөйләшергә тиеш* (Г. Рәхим). *Безнең белән барасыңмы?* (Ә. Еники). *Безнең Гали бигрәк тату кәҗә белән* (Г. Тукай).

2. Эш-хәрәкәтне башкаргандагы коралны ачыклый: *Суккалыйдыр балта белән кыстырылган чөйгә бу* (Г. Тукай). *Юынганда да Сапарбай песи кебек бит очларын гына юа да күзләрен дымлы сөлге белән сөртә* (Ш. Бикчурин).

3. Материалны белдергән сүз янында кулланыла: *Ул көн буе авызы белән балчык ташый. Балчык берлән матур итеп оя ясый* (Г. Тукай).

4. Эш-хәрәкәтне башкару чарасын белдергән сүз янында кулланыла: *Ә бит аның иртәнге самолет белән очасы бар* (Л. Ихсанова),

5. Эш-хәрәкәтнең урынын белдергән сүз янында: *Ул яңадан күзләрен ачканда, юлдаш абыйлар юк, ат нindидер авыл у р а м ы б е л ә н бара иде* (Ә. Фәйзи).

6. Эш-хәрәкәтнең башкарылу вакытын белдергән сүзләр янында кулланыла: *И р т ә б е л ә н кайнамакта бу базар. Кайда баксаң, анда тулган сәүдәгәр* (Г. Тукай).

7. Эш-хәрәкәтнең тиз генә алмашынуын белдерә: *Гыйлемхан абыйсы турында уйлый б а ш л а у б е л ә н , Сөмбел җырлавыннан туктап калды* (М. Хәсәнов). *Самолеттан т ө ш ү б е л ә н , аэропорт бинасыннан читтәрәк тезелешеп торган автобуслар, машиналар ягына ашыктым* (М. Хәсәнов).

8. Эш-хәрәкәтнең максаты күз уңында тотыла: *Сәгыйтьҗан ихтыярсыз бүленгән юлын тизрәк д ә в а м и т т е р ү т е л ә г е б е л ә н , урынында түземсез генә кузгалып куйды* (Ә. Фәйзи).

9. Эш-хәрәкәтнең нәтиҗәсен белдерүдә кулланыла: *Т ү з е м с е з л е к б е л ә н көтеп тора башлады* (Ф. Хөсни).

10. Сәбәпне белдерү өчен: *Яшь кызларның алсу йөзе саргаядыр х ә с р ә т - у й б е л ә н* (җыр).

11. Эш-хәрәкәтнең кире нәтиҗәсен белдерү өчен: *Шушы з и ф а л ы г ы б е л ә н ялгыз яшәде микәнни?* (Г. Ахунов).

12. Чагыштыруны белдерә: *Караңгыда без – чәйдә эрегән ш и к ә р б е л ә н бер* (Ә. Гаффар).

13. Эш-хәрәкәтнең нигезен бирү өчен: *Рушадның к и ң ә ш е б е л ә н ул инде флот турында күпме китап укыды* (М. Мәһдиев).

14. Тышкы күренешне бирү өчен: *Йокларга ята идем аклы к ү л м ә к л ә р б е л ә н* (Бәет).

15. Эш-хәрәкәт булган урынның күләмен белдерү өчен: *Без торган фронт сызыгы 40–50 к и л о м е т р б е л ә н исәпләнә* (Х. Мөҗәй).

16. Гомумиләштерүне белдерә: *Алар н ә с е л - н ә с ә п л ә р е б е л ә н гаскәри кеше булганнар* (Д. Зөбәерова).

17. Тулылык төсмере бирү өчен: *Очрый һаман миңа юлларда и л һ а м б е л ә н т у л ы йөрәкләр* (Х. Туфан).

18. Төшем юнәлеше белән белдерелгән эш-хәрәкәтнең үтәүчесен бирү өчен: *Карак к а р а к б е л ә н тотылыр* (мәкаль).

19. Ким җөмләләрне оештыруда катнаша: *Агач җ и м е ш е б е л ә н , адәм э ш е б е л ә н* (мәкаль).

20. Тезүле бәйләнешне оештыруда да катнаша: *Керсәм, а б з ы к а й б е л ә н җ и ң г ә ч ә й өсләренә киенгәннәр, чыгып утырырга гына торалар* (Ә. Еники).

*Өчен* бәйлеге дә – күп кенә яссылыкта кулланылыш тапкан ярдәмлек сүз:

1. Эш-хәрәкәтнең максатын ачыклый: *Мин ярама яптым ул яулыкны, Б а с а р ө ч е н агышын канымның* (М. Җәлил).

2. Эш-хәрәкәтнең сәбәбен белдерүдә катнаша: *Сугышчан иптәшләре Газинурны матур җ ы р л а в ы ө ч е н дә яраталар иде* (Г. Әпсәләмов).

3. Эш-хәрәкәтнең үтәүчесе алмашынуны белдерә: *Шулай да бу китапларны ычкындырырга ярамый, мин түлим с е з н е ң ө ч е н* (Җ. Тәрҗеманов).

4. Эш-хәрәкәтнең кем өчен икәнен күрсәтә: *Бигрәк уңган кыз икәнсең, к е м б ә х е т е ө ч е н үстең син?* (җыр).

5. Эш-хәрәкәтнең кем җилкәсенә төшүен аңлата: *Г а б д е л б ә р ө ч е н бу көтелмәгән сорау иде, ул баш кагып кына җавап бирде* (М. Шабай).

6. *Өчен* бәйлеге дә мөнәсәбәтле сүзне формалаштыруда катнаша. Мәсәлән: *шуның өчен.*

**Бәйлек һәм бәйлек сүзләрнең кулланылу үзенчәлекләре.** Гадәттә, бәйлекләрне төркемләгәндә, аларның кайсы килеш белән нисбәттәш булуларына игътибар бирелә. Әйтик:

1. Билгесез килеш белән нисбәттә торучы бәйлекләр:

1) *белән* бәйлегенең кулланылышы инде киң тасвирланды;

2) *өчен* бәйлегенең кулланылышына да урын бирелде;

3) а) *кебек, шикелле, сыман, төсле* бәйлекләре охшату төсмерен бирүдә катнаша: *Борны кәп-кәкре – бөгелгәндер тәмам к а р м а к к е б и, Төз түгел куллар, аяклар да б о т а к - т а р м а к к е б и* (Г. Тукай);

ә) шөбһәләнү белдерелә: *Таныйм да т ө с л е, юк та т ө с л е* (К. Нәҗми);

б) предметның төрен аңлата: *Юынгыч, кисәү агачы, табагач к е б е к әйберләрне ишек алдына чыгарып өйделәр* (Г. Рәхим).

2. *Аркылы, аша* бәйлек сүзләре берничә мәгънә мөнәсәбәтен бирүдә катнаша:

1) эш-хәрәкәтнең үтәүчесен бирү өчен: *Ул үзенең тәнкыйть фикерләрен, әйбәт теләкләрен я Такташ, я Гомәр Гали аркылы җиткереп торды* (Г. Минский);

2) эш-хәрәкәтнең урынын белдерү өчен: *Бакча аркылы узганда туктап, Җидегән йолдызга карап тордык* (И. Гази). *Моннан өч өй аркылы безнең өй, – диде кыз, һаман да шулай Сәфәргалигә күтәрелеп карамыйча гына* (Ф. Хөсни);

3) эш-хәрәкәтнең вакытын белдерү өчен: *Итле аш та көн аша, сөтле аш та көн аша* (Н. Исәнбәт);

4) эш-хәрәкәтнең нигезен күрсәтү өчен: *Аның язганнары аша солдатлар орден һәм медальләр белән бүләкләнә иделәр* (Ш. Маннур). *Элек шигырьне укый да белмәгән Рушатов Муса аркылы шигырьнең чын тәмен, образлар тирәнлеген аңлый башлады* (Ш. Маннур);

5) эш-хәрәкәтне башкаруда катнашкан предметка ишарә: *Ул аның белән телефон аркылы сөйләшкән икән инде* (Г. Әпсәләмов);

6) эш-хәрәкәттән көтелгәннең киресен белдерә: *Буран юл аркылы ташкын кебек кар өермәсен очырта иде* (М. Хәсәнов).

3. *Аркасында, сәбәпле* бәйлек сүзләре сәбәп мөнәсәбәтен белдерүдә катнаша: *Әмирҗанның матур планнарын чиктән тыш бирелеп тыңлау аркасында, корал мәсьәләсе Садыйк Хаҗиның бөтенләй дә исеннән үк чыгып киткән иде* (Ш. Камал). *Җитәкчесенең начар эшләве сәбәпле, укулар тәртипле бармый* (Г. Әпсәләмов).

4. *Нигезендә, нәтиҗәсендә* бәйлек сүзләре, шулай ук, сәбәп мөнәсәбәтен белдерүдә катнаша: *Еллар буе сугышу нәтиҗәсендә, Җәмалыйның борыны янчелеп калды* (Һ. Такташ). *Шигырь бит ул бик күп көч куеп, озак вакытлар эшләү нәтиҗәсендә генә чын сәнгать үрнәге булу дәрәҗәсенә ирешә ала* (Т. Гыйззәт).

5. а) *Турында, хакында* бәйлек сүзләре сөйләшүгә бәйле лексик берәмлекләр янында кулланыла: *Тереләсез, бүтән бер нәрсә турында да уйламагыз* (Г. Әпсәләмов). *Евгений Николаевич тактика хакында бер пункт язып куйды* (И. Гази); ә) *турында* бәйлек сүзе урын төшенчәсен бирү өчен дә кулланыла: *Песнәк кунган тәрәзә турында, урамда, ике малай чана тартып йөриләр* (Г. Әпсәләмов).

6. *Тарафыннан* бәйлек сүзе башкаручы затны белдерә: *Кичәне оештыруда актив катнашкан ике иптәшкә бер яисә берничә к у л а к т а р а ф ы н н а н оештырылган каты дошманлык һөҗүме ясалды* (Ш. Камал).

7. *Арасына, арасыннан* бәйлек сүзләре урын нисбәтенә бәйле рәвештә кулланыла: *Басу капкасын чыккач, куе а р ы ш а р а с ы н а кереп яттым* (Г. Сабитов). *Киң яфраклы кыска а г а ч л а р а р а - с ы н н а н Фәхрине табып чыктылар* (Г. Ибраһимов).

8. *Арада* бәйлек сүзе вакыт нисбәтен белдерүдә катнаша: *Б у - ш а г а н а р а д а , атлар янына боргалыйм* (Х. Хәйруллин). *Мин аш-су белән м ә ш ә л ә н г ә н а р а д а , тагын әллә никадәр кеше килде* (Ф. Яруллин).

9. *Арасында* бәйлек сүзе:

а) арадашлык мәгънәсен бирү өчен кулланыла: *Нинди язмышлар бәйләгән бу кешеләрне, нинди серләр саклана а л а р а р а с ы н д а ?* (Ә. Еники). *Кече кодача шыпырт кына әйтте: мин а л а р а р а с ы н д а ;*

ә) коллективтагы шәхесне аерым күрсәтү өчен: *Тырыштым, укыттым баланы, к е ш е а р а с ы н д а абруйлы булыр, дидем* (Ә. Айдар).

10. *Алдыннан, алдына* бәйлек сүзләре:

а) урын нисбәтен белдерә: *К у н а к л а р а л д ы н а ике-өч кулдан тәлинкә-кашыклар тарата башладылар* (Ә. Еники);

ә) вакыт нисбәтен белдерә: *Иярне эшләргә т о т ы н у а л д ы н - н а н , Нигъмәтҗан хатыны белән озак кына киңәште* (Ә. Фәйзи). *Кич кояш и ң ә р а л д ы н н а н , Газизә, әнкәсе карчык белән, казарманың ишегалды баскычына чыгып утырды* (Ш. Камал).

11. *Эчендә* бәйлек сүзе берничә мәгънә мөнәсәбәтен бирүдә катнаша:

а) урын нисбәте: *Иделнең таулы-ташлы, урманлы биек я р л а - р ы э ч е н д ә Байрак белән «Хезмәт» арасында Ямankүл атлы озын, тирән чокыр бар* (Г. Ибраһимов);

ә) нинди дә булса вакыйганың үзәгендә булу: *Үзенең малайлары у т э ч е н д ә булмагач, аңа ник шунда бөтен дөньяң кырылып бетми* (И. Гази);

б) вакыт нисбәте: *Нәби ике-өч е л э ч е н д ә күзгә күренеп картаеп китте* (Р. Төхфәтуллин). *Рәхим ө ч к ө н э ч е н д ә , районга барып, балаларын алып кайтты* (А. Расих).

12. *Ас, өс* сүзләре аеруча игътибарны таләп итә, чөнки алар катнашында төзелгән гыйбарәләр урынсыз калькаларны, омонимнарны формалаштыруга юнәлдерелә: *Төннәр буе китап өстендә, күз бетәштереп, йөз саргайтып, утырганчы, мин аны үзем йорт алып бару үнәренә өйрәтермен* («Казан утлары»). *Геннадий Баев, төн йокыларын онытып, китап өстендә утырды* («Казан утлары»).

13. *Буенча, буена* бәйлек сүзләре урын, вакыт аралыгын һ.б. ны белдерә: *Аның авыруы ел буена дәвам итте* («Яңарыш»). *Инеш буенча бара торгач, зур бер күлгә килеп чыктылар* («Казан утлары»).

## 10. ТЕРКӘГЕЧ ҺӘМ ТЕРКӘГЕЧ СҮЗЛӘР

Җөмлә кисәкләренең, шулай ук җөмләләрнең морфологик нигезен үзгәртмичә теркәп килгән бәйләүче чараларны **теркәгеч** һәм **теркәгеч сүзләр** дип йөртәләр. Алар синтаксик бәйләнешнең ике (ияртүле һәм тезүле) төрендә урын алалар, күпләгән мәгънә мөнәсәбәтен булдыруны тәэмин итәләр; сүз һәм җөмләләрне бер-беренә каршы куялар, тезеп алып китәләр, эш-хәрәкәтнең вакытын, сәбәбен, үтәлү дәрәҗәсен, рәвешен төгәл ачыклауга ярдәм итәләр. Мәсәлән: *Минем дә сиңа әйтәсе кызык хәбәрем бар, мәгәр аның кыяфәте рәнҗетелгән кешенекеннән аермаслык иде* (Ә. Баянов). *Аның һаман да сеңлесе белән ялгыз гына калып сөйләшәсе килә иде, тик хәзергә моның бер дә җае күренми* (А. Расих). *Кызлар укып бетергәч, абыстай чәй урынын үзе әзерли, кызып килә торган мичтә берәр таба гына пәрәмәч пешереп алуны яисә бер-ике таба гына әчегән коймак салып алуны үзенә генә калдыра* (Г. Исхакый). *Аны уенчык та кызыктырмады, тәмле конфетлар да куандырмады, апасы, җизнәсенең йомшак сүзләре дә тынычландырмады* (Г. Исхакый). *Бу мәҗлесемезнең тиз арада таралачагы беленде, чөнки алда шәһәр күренә башлаган иде* (Ф. Әмирхан). *Мехбаза яңа оешкан бер хуҗалык булгач, аның бөтен коллективы да, билгеле, яңа иде, ягъни бер вакыттарак җыеп алган кешеләрдән тора иде* (Ә. Еники). *Бигрәк тә каеннар нәфис, әйтерсең аларның ботакларын иң-иң оста куллар энҗеле ак ефәк белән ураганнар* (Г. Әпсәләмов). *Гөлшаһидәнең дә яхшылыкка, матурлыкка, хезмәткә булган омтылышлары бу көннәрдә гөрләп үсте, нурланды, гүя аңарга тагын да, үткенрәк күзләр, тагын да дәртлерәк йөрәк, тагын да яктырак акыл бирделәр* (Г. Әпсәләмов).

**Тезүче теркәгечләр** җөмлә эчендәге үзара тигез хокуклы сүзләрне бәйләүдә катнашалар яки бер-берсенә буйсынмаган җөмләләрне теркәп килү өчен хезмәт итәләр. Беренче очракта тезүче теркәгечләр

тиңдәш кисәкләр янында урын ала, икенче очракта исә тезмә кушма җөмләләрне оештыру вазифасын үти.

Беренче очракка мисаллар: *Кодагый әби көләргә итте, көлә алмады, күзләренә яшьләре килгәндәй булды, ләкин аларны да күрсәтмәде, т и к тирләгән битен генә яулык очы белән сөртеп куйды* (Ә. Еники). *Кара инде, өн микән бу ә л л ә төш микән?* (Р. Төхфәтуллин).

Икенче очракка мисаллар: *Кайдадыр, еракта, кемдер курай уйный, һ ә м аның моңнары бөтен Агыйдел буйларына тарала* (М. Әмир). *Барысы да куркуга кала, т и к аю гына курыкмый, һаман алга бара* (С. Алиш). *Аның тирләгән битенә, маңгаена тузан кунган, б а р ы тешләре генә ялтырап киткәли* (Г. Бәширов). *Яз аена кердек, ә көннәр һаман салкын* (И. Гази).

**Ияртүче теркәгечләр** гади җөмләдә ияргүче сүзне ияртүче сүзгә буйсындыруда катнашалар, кушма җөмләдә иярчен җөмләне баш җөмләгә ияртеп киләләр. Җөмләнең иярчен кисәкләрен бәйләүдә катнашучы теркәгечләрне, башлыча, аныклаучы теркәгечләр дип йөртәләр: *Бүген, я г ъ н и егерменче октябрьдә, тагын бик зур митинг уздырылды* (А. Расих). *Һәм менә, ниһаять, ул Казанда, д ө р е с р ә г е нәкъ Казан артындагы Карьер поселогында* (А. Расих). *Хисамиев минем өемә төкле аягы белән килеп керде, я г ъ н и үзе белән бәхет ияртеп алып керде* (С. Хәким). Иярчен җөмләне баш җөмләгә ияртүдә күпләгән теркәгечләр катнаша һәм ике компонент арасында төрле-төрле мәгънә мөнәсәбәтләре урнаша: *Таһир һаман елмая иде, г ү я к и энесенең ташып торган тазалыгы аңа да күчкән* (Х. Сарьян). *Исе дә чыкмый, ч ө н к и күмернең хәзер иң гөжләп торган чагы* (Г. Рәхим). *Рамазанның күптән күзе яна иде ул бүрәнәләргә, н и г ә д и с ә ң , мунча бурый башларга вакыт җитте* (Җ. Рәхимов).

Төзелешләре ягыннан теркәгечләрне өч төргә бүлеп йөртәләр: 1) гади теркәгечләр; 2) кушма теркәгечләр; 3) тезмә теркәгечләр.

**Гади теркәгечләр** бары тик бер тамыр яки нигез сүз белән генә бирелә: *Г ә р ч ә тел әйләндереп сүзен әйтә алмаса да, рәхәт булып китте безнең бәләкәй һөнәрчебезгә* (Ф. Хөсни). *Әллә кайдан, даладан, яз җиле исеп китте, һ ә м Габдулла күккә карады* (Ә. Фәйзи). *Шешәдән ясалган лампа янмады, л ә к и н аларның күз аллары барыбер якты иде* (Ф. Хөсни).

**Кушма теркәгечләр**, исеменнән үк күренгәнчә, ике тамыр сүзнең бергә килүеннән ясала: *Гәүһәр дашдыр, в ә л ә к и н даш гәүһәр улмаз* (Кол Гали).

**Тезмә теркәгечләр,** берничә сүзне үзенә берләштереп, бер төшенчәгә ия булалар һәм бәйләүче чара хезмәтен үтиләр: *Мәхәббәт кебек эштә, егет, минемчә дип кенә котылып булмый, н и к д и с ә ң һәркем үзенчә гыйшык тота* (И. Туктаров). *Атлар тагын бер артка чигенеп, бер алга омтылып куйдылар, б и г р ә к т ә төптәге ат түземсез: берөзлексез башын чайкап тора* (М. Шабай). *Мостафин бу урыннан очып төште, б а ш к а ч а ә й т к ә н д ә, аны яңадан сайламадылар* (Ә. Еники).

Җөмлә эчендә ничә урынны алып торулары ягыннан теркәгечләрне икегә бүлеп йөртү гадәткә кергән. Аларның беренче төрен бер урынлы, икенчесен күп урынлы теркәгечләр дип атап йөртергә була. Бер генә урынлы теркәгеч җөмлә эчендә яңадан кабатлауны таләп итми. Тезүче теркәгеч булганда, ул ике тиңдәш кисәк арасында яки тезмә кушма җөмләнең компонентлары аралыгында килә: *Мин аның цехка килеп кергәнен күрмәсәм дә сизәм һ ә м ялгышмыйм* (Ә. Еники). *Низами атын тугармаган, т и к аркалыгын бушатып куйган* (Г. Ибраһимов).

Тезмә кушма җөмләдә: *Станция артта калды, ә без һаман басып тора идек әле* (Г. Әпсәләмов). *Көн кояшлы, л ә к и н җиле бар* (Х. Сарьян).

Иярченле кушма җөмләдә мондый теркәгеч һәрвакыт иярчен җөмлә ягыннан урын ала: *Тынсыз, кайнар, әрсез уйлар һаман алга ыргыла, г ү я барысы да өлгереп җиткән, алар инде бу кечкенә булмәдә бикләнеп кала алмыйлар* (Г. Әпсәләмов). *Озын кара керфекләрдә әле тәгәрәп төшәргә өлгермәгән яшь тамчылары, ә й т е р с е ң л ә чык белән юылган кара карлыган* (И.Салахов).

Күп урынлы теркәгечләр тиңдәш кисәкләр янында яисә кушма җөмлә компонентларының башкаларында да кабатлана, үзенә якын мәгънәдәгеләр белән алмаштырыла: *Ә л л ә чынлап, ә л л ә үчекләп, ә л л ә саташып әйтә бу бернигә исе китми торган, әҗәлгә дә күптән кулын селтәгән, ялан таптаучы йөз яшәр Миңлебай карт!* (Ә. Еники). *Моңарчы яннан искән җил ә л е каршыдан бәрде, ә л е артка төште* (А. Гыйләҗев).

Икенче очракта бер үк мәгънә мөнәсәбәтен бирүче теркәгеч башкасы белән алыштырыла: *Я ул нәрсәләр бөтенләй монда килмәгәннәр, я и с ә шундый оста итеп яшергәннәр* (Ш. Камал). *Һаман рәт чыкмый. Я бөтен җәй буена егерме тәңкә генә бирәләр, я и с ә вакытлы эшләр генә күрсәтәләр* (М. Гафури).

**Тезүче теркәгечләр.** Җөмләнең тиңдәш кисәкләрен һәм тезмә кушма җөмлә компонентларын теркәп килә торган бу төр теркәгечләрне, нинди мәгънә мөнәсәбәте урнаштыруларына карап, өч төркемгә бүлеп йөртү гадәткә кергән:

1. Җыючы теркәгечләр;
2. Каршы куючы теркәгечләр;
3. Бүлүче теркәгечләр.

**Җыючы теркәгечләр** белән бәйләнешкә кергән җөмлә кисәкләре һәм җөмләләр арасында берничә сүзне бергә тезеп, санап китү, җөмлә компонентлары белдергән эш-хәрәкәтнең бер үк вакытта яки бер-бер артлы башкарылуы тәсмерләнә, шулай ук өстәлмә вакыйга, билгеле бер төшенчә теркәп куела. Мондый күренеш тиңдәш кисәкләр һәм тезмә кушма җөмлә компонентлары арасында гына түгел, бәлки катлаулы кушма җөмләләрнең аерым төрләре эчендә дә күзәтелә.

**Каршы куючы теркәгечләр** гади җөмлә кисәкләрен һәм тезмә кушма җөмләнең компонентларын бер-беренә каршы куялар. Бер җөмләне икенчесенә каршы кую антитеза күренешен барлыкка китерә.

**Бүлүче теркәгечләр** ярдәмендә бәйләнешкә кергән төзелмәдә берничә компонентның берәрсенә өстенлек бирелә, я алар чиратлашып килә.

**Җыючы теркәгечләр.** Җөмләнең җыючы теркәгеч *һәм* белән бәйләнештә торган кисәкләре дә, кушма төрнең компонентлары да түбәндәге мөнәсәбәтләргә килеп керәләр:

1) бер үк вакытта булган эш-хәрәкәттә катнашалар: *Маңгаенда батыр яра эзе һ ә м билендә поход каешы* (М. Җәлил). *Бу томан, эчендә исәпсез күп энҗе тузаны йөзгән шикелле, җем-җем килеп, күзләрне кытыклап тибрәнә һ ә м күңел әнә шул нурлы томан артына китеп югалган яшел кырлар түреннән ерактагы поездның дәртле кычкыртып килеп чыгуын тоеп тора* (Ә. Еники), *Ул, катгый һөҗүмгә әзерләнгән солдат шикелле, командир боерыгын көтә, һ ә м Искәндәров*

*аның бу мәһабәт, батыр утырышына тирән соклану белән карап тора* (Ә. Еники);

2) бер-бер артлы булган күренеш һәм эш хәрәкәтне аңлаталар: *Палата ишеге ачылып китте, һ ә м анда ак халат кигән, култык астына төргәк кыстырган зур гына гәүдәле бер кеше пәйда булды* (Э. Касыймов). *Мәрьямгә шыпырт кына аны күзәтәләр кебек тоелды, һ ә м ул, тәрәзәгә борылып, урамга карап тора башлады* (Г. Әпсәләмов);

3) җөмләнең бер өлешендә бирелгән эш-хәрәкәт икенчесенең нәтиҗәсе булып аңлашыла: *Бер-берсе өстенә менә башлаган бозлар ярсулы ачу белән свайларны кысрыклыйлар, һ ә м свайлар сыкранып чатныйлар, шыгырдыйлар* (Ә. Еники). *Вәлишин аның чынлап та күн технологиясеннән тәҗрибәсе зурлыкка ышанды, һ ә м алар бик тиз килештеләр* (К. Нәҗми). *Кайдадыр, еракта, кемдер курай уйный, һ ә м аның моңнары бөтен Агыйдел буйларына тарала* (М. Әмир);

4) алда килгән өлешкә җөмлә кисәгеn яки тулы җөмләне өстәп куя: *Мин дә сезнең авылга барам. Һ ә м беренче мәртәбә* (А. Гыйләҗев). *Минемчә, булырга тиеш бирсдә нефть, һ ә м без аны табарга тиеш* (А. Хәсәнов). *Кичке шәфәкъ өзелеп өлгерми, икенче яктан, нәзек кенә булып, җәйге таң шәфәгы сызыла башлый, һ ә м авыл тагын аякка баса* (Ә. Фәйзи).

Бу теркәгечнең сөйләмдә кулланыла торган башка вазифалары да бар. Мәсәлән, ул һәр тиңдәш кисәк алдыннан яки кушма җөмләнең һәр компонентында кабатланып килә, шуның нәтиҗәсендә сөйләмнең тәэсир итү көче арта: *Мәхәббәтем минем һ ә м матур да, һ ә м батыр да булган кешедә* (Н. Баян).

Бу теркәгеч шулай ук берничә тиңдәш кисәкне парлап берүгә хезмәт итә: *Иртәдән башлап кичкә чаклы балта һ ә м пычкы, китмән һ ә м көрәк куллардан төшмәде* (Ш. Камал). *Шул ук вакытта бу шундый саф һ ә м нәзакәтле, шундый тансык һ ә м тирән тойгы иде ки, ул аны хәтта Нәфисәнең үзенә дә сиздермәскә тырышты* (Г. Бәширов).

*Һәм* теркәгече санап кителгән сүзләрнең (җөмләләрнең) соңгысы алдыннан гына килеп, тиңдәш кисәкләрнең (җөмләләрнең) рәте тәмамланганлыкны белдерә:

а) тиңдәш кисәкләр рәтен тәмамлап куя: *Бакчада, гөлләр эчендә, Тукай һәйкәле торыр. Анда шигырь, җыр, музыка һ ә м дан мәйданы*

*булыр* (Ш. Маннур). *Шүрәле фөрьят итәдер, аудан ычкынмак була, һәм дә, ычкынгач, егеткә бер-бер эш кылмак була* (Г. Тукай);

ә) тиңдәш ияртүле күп иярченле катлаулы кушма җөмләдә иярчен җөмләләр рәтен тәмамлый;

б) тиңдәшләнеп килгән җөмләләрнең рәтен тәмамлый: *Алдынгыларның эшенә читтән сокланып карап тора торган чак үтте, барлык нефтьчеләрне алдынгы итәр вакыт җитте, һәм мин ышанам: без барлык бригадаларны да алдынгы итәрбез!* (И. Гази). *Тик кенә торганда капланды томанга бар һава; Кар оча, кар себерелә, кар котырына һәм кар ява* (Г. Тукай).

*Һәм* теркәгечен кулланудагы бу таләпләрне үтәмәү сөйләмнең төгәллегенә зарар китерә: *Агымдагы тәүлек дәвамында командир һәм бортинженер корабль һәм станциянең төрле системалары һәм агрегатлары эшен тикшерделәр* (көндәлек матбугат).

Җыючы *да-дә/та-тә* теркәгечләре җөмләнең вакыт нисбәтендә торган кисәкләрен һәм тезмә кушма җөмлә компонентларын теркәүдә катнашалар: *Паровоз берничә мәртәбә ахылдап куйды да урыныннан кузгалды* (Р. Ильяс). *Бөтен авыл бер хуҗалыкка оеша да, бөтен ызаннарны пыран-заран китереп, трактор белән сөреп ташлыйсың* (М. Әмир). *Самолет гүләвен ишетү белән эт, койрыгын бот арасына кыстырып куя да, артына ялт-йолт карый-карый, алдан чаба* (И. Гази).

Әлеге теркәгечләр җөмләләрдә берничә мәгънә төсмерен билгелиләр:

1) кабатланып килгән эш-хәрәкәтнең бик тиз, кинәт алмашынуы төсмерләнә: *Сикереп, кинәт ияргә басты, артына борылды... борылды да, күз ачып йомган арада, сөңгесен ераклаша барган җайдакка тондырды* (Н. Фәттах). *Кайчакларда, юри үч иткәндәй, берничә төрле эш берьюлы килеп чыга да, кайсысын башлап китәргә аптырап каласың* (М. Шабай);

2) бер үк вакытта башкарылган күренешне, эш-хәрәкәтне тезеп тасвирлый: *Моны ул үзе дә белми, башкалар да сөйләмиләр* (Г. Ибраһимов). *Ай тау башына менеп кунаклаган да шуннан Ургыл өстенә нурларын сибә* (Х. Хәйруллин);

3) бер-бер артлы башкарылган эш-хәрәкәт тезелеп китә: *Ишек төбенә озата чыккан ана тагын бер мәртәбә улының чәчләрен, муенын,*

*френч якасын үпте д ә , яшенә тыгылып, улына китәргә әйтте: – Бар, иптәшләреңне көттермә, улым* (Ф. Хөсни). *Гайнан ясаган чәен эчте д ә , чыгып, радиоалгычны борып җибәрде* (Г. Бәширов). *Күпер д ә артта калды, инешнең чылтыравы да ишетелмәс булды* (К. Нәҗми).

Һәр тиңдәш кисәк янында, кушма җөмләнең һәр компоненты ягында кабатланып килгән бу теркәгечләр шулай ук көчәйтү төсмерен арттыралар: *Муса д а , мин д ә бик дус яши идек* (М. Максуд). *Юынганда д а , киенгәндә д ә , аның башына бертөрле уйлар килделәр дә тыгылдылар* (М. Әмир).

Кабатлаулы *ни* теркәгече инкяр җөмләләрне оештыруда катнаша: *Көн кояшлы, ләкин җиле бар иде; җәймә чаклы гына болытлар н и кушылмый, н и таралмый* (Х. Сарьян). *Бу төшләргә килеп җитә алмый н и бер сәлам, н и хат, н и хәбәр* (Х. Туфан).

Телебездә шушы мәгънәдә йөргән бу теркәгеч раслау мәгънәсен бирүдә дә катнаша ала: *Н и бармыйдыр ат, н и кыйныйдыр карт* (Н. Исәнбәт).

Җыючы теркәгечләрдән *тагын, тагы, янә* бер-бер артлы кабатланып килә торган эш-хәрәкәтләрне тасвирлауда булышлык итәләр: *Т а г ы н шәһәр шау-гөр килә башлады, т а г ы н шәһәр эчендә шау-шу купты, т а г ы н вакыйгалар яшен тизлеге белән төрле почмакларга тарала башлады* (Х. Садри). *Т а г ы н яшен яшьни, т а г ы н күкри, т а г ы н шулай җилләр исәләр...* (Һ. Такташ). *Галәветдин агай т а г ы н керде* (Ш. Маннур).

*Янә* теркәгече дә кабатланып килә һәм вакыйгаларның әледән-әле алмашынып торуын белдерә: *Я н ә яшен яшьнәде, я н ә күк күкрәде* (М. Әмир). *Алар өйгә кереп тә тормадылар. Хатын я н ә урамга атылып чыкты, я н ә югары очка йөгерде* (М. Маликова).

Җыючы теркәгечләр рәтеннән кулланылып йөри торган *кирәк, булсын, булмасын* сүзләре дә эш-хәрәкәтнең, предмет һәм затның кабатланып килүен белдерә: *К и р ә к Борһан абзыйга вә к и р ә к Хәятнең үзенә шулкадәр нәрсә бөтенләй җитә иде* (Ф. Әмирхан). *Соңгы елларда аңа митингларда б у л с ы н , җыелышларда б у л с ы н , күп кенә чыгышлар ясарга туры килде* (А. Расих). *Трагедия жанры, әлбәттә, к и р ә к язучыдан, к и р ә к театр коллективыннан зур осталык, кыюлык таләп итә* («Казан утлары»).

*Белән* бәйлеге, ике тиңдәш арасында килеп, җыючы теркәгеч урынында кулланыла. Тиңдәш кисәкләр арасындагы мөнәсәбәттә ул *һәм* теркәгечен алыштыра: *Госман тиз арада Кәрим б е л ә н Мәдинәгә Машаның кем булуын аңлатып бирде* (И. Салахов). *Бары сары туфрак өстендә зәһәрле елан б е л ә н аны ауларга чыккан керпене генә очратырга була* (Ш. Усманов).

**Каршы куючы теркәгечләр.** Каршы куючы теркәгечләр белән бәйләнешкә кергән компонентлар арасында берничә төрле мәгънә мөнәсәбәте урнаша.

1. *Ләкин, ә, әмма* теркәгечләре белән килгән тиңдәш кисәкләр, тезмә кушма җөмләнең компонентлары бер-берсенә каршы куела: *Мин күрмәгәндә генә карый, ә күзгә-күз очрашудан кача* (Ә. Еники). *Газинур кычкырып көлеп җибәрде, л ә к и н йөрәге тынычланмды* (Г. Әпсәләмов). *Өчиленең табигате матур, ә м м а кешеләре кырыс иде* (Ә. Фәйзи).

2. *Тик, бары, бары тик* теркәгечләре белән үзара бәйләнештә торган тиңдәш кисәкләрнең, тезмә кушма җөмлә компонентларының икенчесе чикләү төсмере белән килә: *Ул барлык коралларын шулай ук чаңгы янына ташлады, б а р ы тиреләрен генә үзе белән алды* (Н. Фәттах). *Роза чәчәгенең карасы да була, искиткеч матур, затлы чәчәк ул, т и к бик чәнечкеле* (Ә. Еники).

3. *Фәкать* теркәгече ярдәмендә бәйләнешкә кергән төзелмәләрдә шактый кискен каршы кую, катгый чикләү белдерелә: *Бик салкын җил без кеби чәнчеп-чәнчеп ала, ф ә к а т ь ярлылык борчасына сабыр итә* (М. Гафури). *Рәхәтләнеп эшләвемне белдем, тәм таптым мин ф ә к а т ь хезмәттән* (З. Мансур). *Авыл күптән йоклый, ф ә к а т ь урам саен бер я ике диярлек кенә кич утыручы кызларның барлыгы беленә* (Н. Думави).

4. *Исә* теркәгече бер-беренә каршы куелган компонентларның үзара шактый тыгыз бәйләнештә торуларын искәртә: *–Үги ана берөзлексез шелтәли-иги дә, Зәйтүнәнең и с ә кеше арасына да керәсе килә, кеше кигәнне киярлгә дә тели* (Ф. Хөсни). *Кулларын тартып алып, тагын биленнән эләктерергә итә Җаббар, егет и с ә , «абзый»ның үз биленнән кысып алырга чамалый* (Р. Төхфәтуллин). *Инде башка пассажирлар да уяна башлады. Уянганы бере палубага чыгып баса иде, пароход и с ә , Гаяз күңеледәй ашкынып, чапкан ат тизлеге белән алдыра гына* (Х.Садри).

Каршылык нисбәтен белдерү өчен татар телендә тагын *бәлки, мәгәр, мәгәренки, хәлбуки* теркәгечләре кулланыла: *Азым әкә, үзең яхшысың, м ә г ә р кайбер вакыт яман телең адәмне чагып куя* (Г. Ибраһимов). *Аның йөзендә һичбер шатлык әсәре күренми, б ә л к и киресенчә аның чырае гадәттәгедән караңгылана төшкән, иреннәре бер-берсенә ныграк кысылган* (Ш. Камал). *Моржалардан, ишелеп-бөтерелеп, зәңгәрсу-аксыл төтен күтәрелә, м ә г ә р көндәгечә өскә һавага менеп китми, телевизор антенналары тирәсендә тулгана* (М. Хәбибуллин).

**Бүлүче теркәгечләр.** Бүлүче теркәгечләр шулай ук берничә мәгънә төсмерен бирү өчен сөйләмгә кертелә:

1. *Яки, я (йә), яисә* теркәгечләре белән бәйләнешкә кергән төрләрнең берсенә өстенлек бирелә, кайсысының да булса үтәлү ихтималы күздә тотыла: *Аның я агроном, я урман белгече, я бакчачы буласы килә* (Г. Бәширов). *Давытның Нәфисәгә хат язасы я к и барып күреп кайтасы бар иде* (Г. Ибраһимов).

Бу теркәгечләр сорау, икеләнү рәвешендә бирелгән ике ихтималлыкны бер-берсе белән тәңгәл куя: *Әллә ычкынганмы баудан каф тау арты җеннәре. Я тишелгәнме ходайның бихисап зур мендәре?* (Г. Тукай).

2. *Әле – әле, бер – бер* теркәгечләре күренеш, вакыйга, эш-хәлләрнең кабатланып килүен белдерәләр: *Бу юлдан байтак кешеләрне ә л е сугышка, ә л е бәхет эзләргә Пермь, Ярослау якларына озатканым бар* (А. Гыйләҗев). *Габдулла гаҗәпләнебрәк, б е р әтисенә, б е р Хавизга карап алды һәм, теләр-теләмәс кенә, әтисе янына килде* (Ә.Фәйзи).

3. *Әллә – әллә* теркәгече сөйләмгә икеләнү, ышанып бетмәү төсмере алып килә, саналып киткән күренеш һәм әйберләрнең үтәлү яки булуына шикләнү белдерелә: *Ә л л ә инде ул... кинәт яшәреп китте, ә л л ә инде аның эчендә гомер буена яшеренеп ятканниндидер бер көч калкып чыкты* (А. Шамов). *Җәе дә шундый матур инде быел: ә л л ә ел саен табигать үзгәрә, ә л л ә Гали – һич белмәссең* (М. Шабай).

**Ияртүче теркәгечләр.** Ияртүче теркәгечләрне башка бәйләүче чаралар белән бутамас өчен, аларга хас һәр үзенчәлекне төгәл күзалларга кирәк. Югыйсә ияртүче теркәгечләргә чит-ят төрләр килеп кушыла.

Иярүче теркәгечләрнең төп үзенчәлекләреннән түбәндәгеләрне истә тоту зарур:

1. **Иярүче теркәгеч** – тезүче теркәгечләр кебек үк морфологик күренеш. Алар билгеле бер сүз төркеменә кушылып киләләр. Бу яктан

аларны мөнәсәбәтле сүзләргә каршы куярга була. Соңгылары төрле сүз төркемнәреннән һәм төркемчәләреннән туплана. Теркәгечләрнең морфологиядә үз урыннары, үз билгеләре, тамгалары бар. Бу төркемне тәшкил итәләр: *чөнки, әгәр, әгәренки, һәрчә, гүя, гүяки, диярсең, әйтерсең, ки, ягъни, бигрәк тә, дөресрәге, башлыча, аеруча, ник дисәң, ник дигәндә, икенче төрле әйткәндә, җитмәсә* һ.б. *Бездән соң бүтән йорт юк, чөнки, тигез җир бетеп, текә яр башлана* (Ә. Еники). *Аның бик канәгать булып кеткелдәп көлеп торуы, җитмәсә, ачыктан-ачык мактануы, минем кәефемне кырды* (Г. Ахунов). *Шуларның барысын да, ягъни йортыннан алып капка-коймасына кадәр, лимон төсендәге сарыга буятты. Моның музыкасы шул кадәр җанлы иде ки, Ләйлә туташның тавышы илә кушылып, тыңлаучыны шатлык дөньясына алып китә иде* (Ф. Әмирхан).

2. Теркәгеч, шул исәптән ияртүче теркәгеч тә, бары тик бәйләүче чара вазифасын гына үти. Бу үзенчәлеге белән ул **теркәгеч сүзгә** каршы куела, чөнки соңгысы җөмләнең бер кисәге итеп тә карала. Ияртүче теркәгечләр бәйләүче чара булып кына йөриләр: *Чит күзләрдән артык сакланмадылар, гүя нindидер киртәне атлап үттеләр* (Г. Әпсәләмов). *Гөлүс, үзе дә сизмәстән, алгарак омтылды, чөнки яшь төзүчеләр арасында Миләүшә дә бар иде* (Р. Кәрами).

Теркәгеч сүзләр түбәндәге мисалларда һәм бәйләүче чара, һәм җөмлә кисәге булып килгән: *Бу җәһаннәм чокырларын ташлап китәргә вакыт җитте дип беләм мин, кем тели – иярсен миңа!* (И. Туктар). *Өстенә ни кигәндер – белмим инде* (Т. Миңнуллин). *Ничек мин аларга барам, аның күзләре ут уйный башлый* (Ф. Әмирхан).

Биредә китерелгән үрнәкләрнең беренчесендәге бәйләүче чара (*кем* теркәгеч сүзе) җөмләнең иясе булып килә, икенчесендә тәмамлык вазифасы үти, өченчесендә вакыт хәле итеп карала.

3. Теркәгеч (һәм теркәгеч сүз), башка аналитик бәйләүче чаралардан аермалы буларак, **иярүче компонент ягында** килә, ияртүче компонент эчендә урын алмый. Рус һәм төрки телләрнең кайберләрендә **нәтиҗә** җөмлә төрләрен билгеләгәндә, андагы бәйләүче чараны иярчен җөмлә ягында килә дип карау телнең эзлекле төзелешенә зарар китерә. *Биредә эш кайный, шуңа күрә күңелле* (М. Гафури) калыбындагы җөмләләрнең бәйләүче чарасын иярчен җөмлә ягында дип билгеләү нәкъ менә шул турыда сөйли. Ике өлештән торган бу

җөмләнең беренче өлешен иярчен сәбәп җөмлә, ә икенчесен баш җөмлә (ияртүче компонент) ягында тора дип исәпләү дөрес булыр. Шул рәвешле теркәгечләрнең урыны ияртүче компонент белән бәйле итеп билгеләнергә тиеш икән. Түбәндәге җөмләләр дә шуңа мисал: *Әгәр Идриснең беләгеннән тотканда озын һәм кытыршы бармаклары дерелдәп китмәсә, бәлки аның борчылуы сизелми дә калган булыр иде* (Г. Бәширов). *Капкада тимер йозак, Хәдичә көткән озак. Тышта кунып булмый бит, булса да гәрчә йөз ак* (М. Җәлил). *Ул кызның чырае бик якты, чөнки аңар шәһәргә бару рәхәт, шәһәрдә аны шатлык көтә* (Ф. Әмирхан).

Бу кагыйдәнең бер чыгармасы да бар. Ияртүче теркәгечләрдән *ки* теркәгече хәзер инде ияртүче компонент ягына күчкән, кайчандыр ул да иярчен җөмлә ягында булган: *Нәзар дәрьяларын гиздем, ки сәндин тапмадым әүля* (Г. Кандалый). *Алда һәм була балың, ки чин кәсага салың, көмеш кашык белән алың* (бәет). *И бу дүрт ел, и бу дүрт ел, ки бер сәгате дә дүрт ел!* (Г. Кандалый).

Хәзерге әдәби телдә ул, үз урынын алмаштырып, ияртүче компонент ягында я үзе генә бәйләүче чара булып килә, яисә мөнәсәбәтле сүзләр белән берлектә йөри. Беренче очракка мисал: *Күп адәмнәр бар ки, мин хак юлдан адашмам, диләр* (Н. Думави).

Икенче очракка мисаллар: *Ул миңа шул дәрәҗәдә ошады ки, ишектән керу белән күңелемне алып, мин башка кайгымны бөтенләй оныттым* (Г. Ибраһимов). *Тимер мич шундый кызу итеп ягылган ки, ишек төбенә муенчалап куелган бозау һәм сарык бәрәннәре, эсселектән әлсерәп, сузылып ятканнар* (С. Кудаш).

4. Ияртүче теркәгеч, мөнәсәбәтле сүздән аермалы буларак, үзеннән алда яки соң килгән җөмләне алмаштыру сәләтенә ия түгел. Мөнәсәбәтле сүз урынына иярчен җөмләне куеп булса да, теркәгечле җөмләдә аны эшләү мөмкин түгел, алмаштырырга тырышу җөмләнең мәгънәсен бөтенләй башкага борып куя: *Сакмар буенда булган хәлләрне язып тормыйм, чөнки хат озынга китәчәк* (Ш. Камал). Чагыштырыйк: *Сакмар буенда булган хәлләрне язып тормаганга, хат озынга китәчәк.*

Кайбер морфология яки мәктәп дәреслекләрендә теркәгеч, теркәгеч сүзләр рәтенә куела торган *шуңа күрә, шул сәбәпле, шуның өчен* бәйләүче чаралары урынына иярчен җөмләне куя алабыз һәм мәгънә

дә бозылмый, бары тик бер пар синтаксик синоним гына барлыкка килә, телебезнең мөмкинлекләре генә ачыла. Мәсәлән: *Агачны райбашкарма комитеты бүрәнәләп тараткандай гына тарата иде, шул сәбәпле колхозлар да, аерым кешеләр дә урманны Караиделгә менеп кисә башладылар* (Х. Сарьян). Чагыштыр: *Агачны райбашкарма комитеты бүрәнәләп тараткандай гына тарату сәбәпле, колхозлар да, аерым кешеләр дә урманны Караиделгә менеп кисә башладылар.*

Күренә ки, һәр бәйләүче чараның үзенә генә хас үзенчәлеге бар һәм һәрвакыт шуңа таянып эш итәргә кирәк.

5. Гомумән, ияртүче теркәгечләргә, теркәгеч сүзләргә карап кына, иярүче компонентның җөмләдәге вазифасын билгеләү отышлы булмаска мөмкин, чөнки баш җөмләдә килгән мөнәсәбәтле сүз аны үз кулына ала. Бу – беренчедән. Икенчедән, теркәгечләр үзләре дә берничә мәгънә мөнәсәбәтен белдерүдә катнашалар. Боларга да карамастан, аерым теркәгечләр билгеле бер вазифа үтәүгә хезмәт итә. Мәсәлән, *чөнки* теркәгече сәбәп нисбәтендәге, *әгәр, әгәренки* шарт нисбәтендәге компонентларны теркәп килә. Шушы нигездә татар теленең аныклаучы теркәгечләре дигән атама барлыкка килгән; *ягъни, бигрәк тә, аеруча* һәм башка шуның кебек теркәгечләр аныклагычларны яки ияртүчен аныклагыч җөмләләрне бәйләүдә катнашалар.

6. Ияртүче теркәгечләр төркеме дә алынмалар исәбенә тулыланып килгән. Хәзерге дәреслек һәм кулланмаларда аларның кайсы телдән алынулары да күрсәтелә: *ягъни, хәтта* теркәгечләре – гарәп теленнән, *әгәр, әгәренки, ки, чөнки, гүя, гүяки, яки* кебек теркәгечләр фарсы теленнән алынган. Хәзерге татар әдәби телендә, төрки лексикага нигезләнеп, гади һәм тезмә теркәгечләрне куллану арта бара. Болар рәтенә *аеруча, дөресрәге, башлыча, ник дисәң, әйтерсең* һ.б. ияртүче теркәгечләр керә.

Ияртүче теркәгечләрнең барысы да аналитик чара дип исәпләнә, чөнки алар иярүче сүзнең составында тормыйлар, аның формасын тәшкил итмиләр, иярүче компонент эчендә мөстәкыйльлек саклыйлар. *Дип, икән* сүзләре теркәгеч функциясендә йөри дигән аңлатма югарыда санап киткән һәм теркәгечләргә хас дип каралган үзенчәлекләргә туры килми. Алар теркәгеч, теркәгеч сүзләргә бәйле рәвештә каралмыйча, бәлки, бәйлек сүзләр төркеменә кертеп йөртелергә тиешләр. Бу яктан алар синтаксик синонимнар күренешенә дә бик төгәл туры килә:

*Солдат белән көрешергә д и п , әледән-әле күршеләр керә торды* (М. Галәү). – *Солдат белән көрешер өчен, әледән-әле күршеләр керә торды.* Һәр ике мисалда да бер үк күренешкә тап булабыз: бәйләүче чара сүзнең составын тәшкил итә, аннан алда килгән сүз белән бәйлек арасына башка лексик берәмлекне урнаштыру мөмкинлеге юк. Теркәгечләр, теркәгеч сүзләр алдагы компонентка алай «ябышып» тормыйлар.

Ияртүче теркәгечләрнең җөмләдәге вазифасын билгеләгәндә, гадәттә аларны кушма җөмлә белән генә чикләү күренә, әмма, бу фикерне алга сөргәндә, аныклаучы теркәгечләр читтә кала бирә, шуның өчен аларны (ияртүче теркәгечләрне) гади җөмлә эчендә дә шактый киң кулланыла торган бәйләүче чара итеп йөртү чынбарлыкка ныграк туры килә. Менә бу мисаллар шуны хаклый: *Урман өскә авып тора, я г ъ н и ындыр артында гына* (Ш. Рәкыйпов). *Ташлытау, б и г р ә к т ә кешеләре, миңа ошады* (Г. Минский). *Шушы тигәнәк аркасында, д ө р е с р ә г е тигәнәккә бәйле рәвештә, бер совхоз директоры бөтен республикада дан алды* (Р. Төхфәтуллин).

Ияртүче теркәгечләр белән бәйләнешкә кергән җөмләләр, җөмлә кисәкләре арасында күп төрле мәгънә мөнәсәбәте урнаша, шуның өчен аларның аерым төркемнәрен берәм-берәм карап чыгарга кирәк.

1. Сәбәп нисбәтен белдерүдә берничә ияртүче теркәгеч катнаша:

1) *чөнки* теркәгече – сәбәп-нәтиҗә нисбәтен белдерүдә иң киң кулланыла торган теркәгечләрнең берсе: *Бүреләрне тагын каты курку басты, ч ө н к и хәзер башлыклары чыгып качты* (Г. Тукай). *Заводтан ул китмәячәк, ч ө н к и китәр өчен һичбер җитди сәбәп юк иде* (Г. Әпсәләмов). *Чираттагы ялыгызга чыккач кына, әти-әниегез янына кайтачаксыз, ч ө н к и башка вакытта кайтырга мөмкинлеге булмаячак* (Р. Хәмид).

*Чөнки* теркәгече гадәттә ияртчен сәбәп җөмләнең алдыннан килә, аны башлап алып китә, әмма, сөйләмнең үтемлерәк булуын арттыру максатыннан чыгып, автор ияртчен җөмлә эчендә аның урынын үзгәртә ала: *Алар шактый күп сөйләштеләр, хәтта елашып та алдылар, әмма Габдулла моның белән генә канәгатьләнмәде, ул апасын бик, бик сагынган иде ч ө н к и* (Ә. Фәйзи).

Шигъри, тойгылы сөйләмдә *чөнки* теркәгече ияртчен җөмләнең төрле урынын алып торырга мөмкин: *Җан кадерле, дуслар сугышта, сугышырга ч ө н к и җан кирәк* (Ф. Кәрим).

Иярченле кушма җөмләнең ияртүче компонентында, мәгънә мөнәсәбәтен көчәйтә торган лексик берәмлек хезмәтен үтәп, *булса кирәк* тезмәсе шактый еш очрый. Сөйләмдә ул иярчен сәбәп җөмләнең килергә тиешлеген алдан ук кисәтеп тора: *Староста... түшенә зур калай аскан иде. Бу калайның мәгънәсен ул үзе бөтен кешегә караганда да яхшырак белә иде б у л с а к и р ә к , ч ө н к и , күкрәген калкыта биреп, төркемнең башында баручы кеше иде ул* (Ф. Хөсни). *Пан терлекчелек белән дә шөгыльләнгән б у л с а к и р ә к , ч ө н к и чүлмәк түбәле, балконлы һәм колонналы таш өйнең каршында ук терлек абзарлары да бар иде* (А. Расих);

2) *ник дисәң, нигә дисәң, ник дигәндә* тезмә теркәгечләре шулай ук сәбәп-нәтиҗә мөнәсәбәтендәге җөмләләрне бәйләүдә катнашалар: *Без Әхмәт Рәшитовның әлеге китабын көткән идек. Нindiрәк булыр дип көтү иде бу, н и к д и г ә н д ә , беренче китапларга карап кына, шагыйрь турында авыз тутырып сүз әйтү читен була* (Б. Камалов). *Кайтырга булдым, н и к д и с ә ң , хакым бар* (И. Туктар). *Икеләнергә сәбәпләр бар иде, н и к д и г ә н д ә , музыкаль гаиләдә үсмәде ул* (Х. Гайнуллин).

2. *Гәрчә* теркәгече белән җөмләнең иярчен кисәге дә, иярчен җөмлә дә бәйләнешкә керә ала, бу очракта компонентлар инде каршылык нисбәтенә куелган була. Чөнки бу теркәгеч әзер мөнәсәбәткә генә килеп кушыла һәм өстәмә, ярдәмче вазифаны гына башкара: *Г ә р ч ә анда тугмасам да, мин бераз торгән идем* (Г. Тукай). *Тышта куныл булмый бит, Булса да г ә р ч ә йөз ак* (М. Җәлил).

3. *Әгәр, әгәренки* теркәгечләре шарт нисбәтен белдергән төзелмәләрдә кулланыла, алар дә өстәмә, ярдәмче вазифа үтиләр: *Ә г ә р Нәфисә ишек алдына чыкмаса, ишекләрен ватып керергә әзер идек* (А. Шамов). *Ә г ә р Тукай башта яза башлаган тел белән калса, бүгенге Тукай булмас иде* (С. Кудаш).

*Әгәр* теркәгече, *дә* кисәкчәсе белән килеп, теләк мәгънәсен көчәйтүдә катнаша: *Эх, ә г ә р д ә Газинур шул карлы тау башларын, якыннан торып, бер күрсә иде!* (Г. Әпсәләмов).

4. Аныклаулы мөнәсәбәтне белдерүче теркәгечләр, ияртүче һәм ияртүче сүзләрнең, җөмләләрнең мәгънә күләменә карап, ике төркемгә бүлеп йөртелә:

1) ияртүче һәм ияртүче компонент арасындагы мәгънә күләме бердәй була;

2) компонентлар арасындагы мәгънә күләме бер-берсенә туры килми: ул я кимрәк, я артыграк була.

Беренче төркемдәге теркәгечләр арасында гадиләре дә, тезмәләре дә бар:

а) *ягъни* теркәгече гади җөмләдә аныклагыч белән аныкланмышны, кушма җөмләдә ияртүче компонент белән иярчен аныклагыч җөмләне бәйләп килә: *Дәшмәдем, тындым эчемнән, я г ъ н и сер бирмим* (Н. Исәнбәт). *Ачасыр атасыз дигән сүз буладыр, я г ъ н и атасыз бер ялгыз чуваш булгандыр* (К. Насыйри);

ә) *башкача әйткәндә, икенче төрле әйткәндә, төгәлрәк әйткәндә* кебек теркәгечләр үзләре үк бердәй мәгънә күләмен белдерүгә ишарә итеп торалар, текст эчендә шул вазифаны үтиләр: *Ә аның, к ә н к р и т а л ы п ә й т к ә н д ә, әлеге шул Мөхәммәди карт кызының, сөт тешләре дә төшеп бетмәгән* (Ф. Хөсни). *Студентлар бөтен уку-укыту системасын тамырдан үзгәртүне таләп итә, и к е н ч е т ө р л е ә й т к ә н д ә, студентларның чыгышы патша хөкүмәтенең бу өлкәдә алып бара торган рәсми сәясәтенә каршы юнәлгән* (Г. Әпсәләмов).

Икенче төркемгә караган аныклаучы теркәгечләрнең саны шактый мул: *дөресрәге, аеруча, башлыча, хәтта, мәсәлән, җитмәсә, өстәвенә* һ.б. Бу теркәгечләр татар телендә еш кулланыла торган бәйләүче чаралардан санала: *Тагын аз гына җил истеме, җәйрәп яткан шушы тип-тигез җирләр тоташ хәрәкәткә килә, д ө р е с р ә г е, ерып үткесез үләннәр күктән яңгыр даулагандай дулкынланып тора башлый* (М. Шабай). *Рәмиевләр, б и г р ә к т ә Закиры, матбугат һәм әдәбиятка зур мәхәббәт белән караганлыктан, бу эшкә сәүдә-табыш ягыннан гына килмәделәр* (З. Бәшири). *Үзеннән башка берәүгә дә, х ә т т а дус күргән иптәш кызларына да, билгеле булмаган бу халәттән ул көннән-көн чәчәк ата бара иде* (Ф. Хөсни).

Ияртүче теркәгечләрнең югарыда санап кителгән төрләре билгеле бер мәгънә мөнәсәбәтенә карый, алар үзләренең тотрыклы бер мәгънәгә ия булуларын дәвам итәләр. Ияртүче теркәгечләрнең икенче төркеме берничә мәгънә мөнәсәбәтен бирүдә катнаша ала.

1. *Әйтерсең, әйтерсең лә* теркәгечләре түбәндәге вазифаларны үтиләр:

1) җөмләдә үзләре генә төп бәйләүче чара булып киләләр икән, алар ияртүче компоненттагы эш-хәрәкәтнең үтәлү рәвешен чагылды-

руга хезмәт итәләр: *Бер минуттан туплар гөрселдәве ишетелде, ә й т е р с е ң кайдадыр якында гына таулар ишелә башлады* (Г. Әпсәләмов). *Гаскәр өстендә ә й т е р с е ң л ә урман үсеп чыкты, сөңгеләрен, кылычларын айкап, ирләр ярсып- әрнеп кычкырды* (В. Имамов);

2) әйтерсең (*әйтерсең лә*) теркәгече ихтималлыкны белдерү өчен килә: *Бу чиертешү һөнәре Баязит өчен зур бер шатлык булып китте, ә й т е р с е ң ул таш стеналарны, тимер ишекләрне, мылтыклы тыгыз каравылны бер кул селтәү белән җимереп, теләгән вакытта чыгып китә алырлык хәлгә килде* (Г. Ибраһимов). *Бусагадан атлаганда, ул бөтенләй икенче бер кеше иде инде: чырае караңгы, хәрәкәтләре әкрен, ә й т е р с е ң ул коточкыч арыган да хәзер көч-хәл белән өйгә кереп егылырга тора* (Г.Әпсәләмов);

3) мөнәсәбәтле сүз белән бергә парлашып килгәндә, шулай ук эш-хәрәкәтнең үтәлү рәвешен белдерә;

4) мөнәсәбәтле сүз белән килеп, иярчен күләм җөмләне ияртә: *Ә тегесе, зур күзләрен тутырып, шундый ягымлы итеп карап куйды, ә й т е р с е ң ул Хәбирәне менә бүген генә күргән* (Ә. Фазылҗанов). *Ә күге шундый матур, шундый зәңгәр, ә й т е р с е ң Ягетнинең зәңгәр күлен алып килгәннәр дә, бик-бик югарыга менгезеп, йөзтүбән асып куйганнар* (Г. Гобәй);

5) мөнәсәбәтле сүз белән бергә иярчен аергыч җөмләне бәйләүдә катнаша.

2. *Ки* теркәгече үзенең күп мәгънәгә яраклаша алуы белән башка теркәгечләрдән нык аерылып тора. Ул, үзе генә төп бәйләүче чара булып килгәндә дә, мөнәсәбәтле сүз белән булганда да, берничә вазифаны үтәүдә катнаша:

1) иярчен ия җөмләне бәйли: *Билгеле к и , ул моны ирләргә карата әйткән* (Г. Минский);

2) иярчен хәбәр җөмләне бәйли: *Бөтен мәсьәлә шунда к и , ул күптән инде шәһәргә күчү хакында кайгырта* («Казан утлары»);

3) иярчен тәмамлык җөмләне бәйли*: Соңыннан, Җаекка килгәч, белдем к и , «өлкән» – «олуг» дигән сүз икән* (Г. Тукай). *Алдан күреп торырга мөмкин к и , бу сөйләшеп караудан бер нәтиҗә барып чыкмас* (Ф. Әмирхан);

4) иярчен аергыч җөмләне бәйли: *Бераз йолдызлар бардыр к и , күктән йолдыз эзлиләр* (Г. Тукай). *Дөньяда күп кешеләр бар к и , үткен*

*вә акыллы кешеләрдән куркып, үз тирәләрендә күбрәк ахмакларны йөртәләр* (Г. Тукай);

5) иярчен рәвеш җөмләне бәйли: *Аның чәе шундый итеп әзерләнгән иде к и , минем юлдашым капкан саен: «Мондый сыйларны дүрт ел мәдрәсәдә ятып кайткач, сагынып көткән әниләреңдә генә күрергә мөмкин», – дип кабатлый иде* (Г. Ибраһимов);

6) иярчен күләм җөмләне бәйли: *Бәкәлләренә карагач, хәйран калдым: алар шундый озыннар к и , мин гомеремдә андыйны күргәнем юк* (Г. Ибраһимов). *Аңа бу абзарда шундый бөркү, тынчу булып китте к и , ул инде монда бер генә минутка да кала алмады* (М. Шәрифуллин);

7) *ки* теркәгече вакыт, шарт нисбәтендәге төзелмәләрдә дә бәйләүче чара буларак катнаша [Закиев М., 1963, с. 323]: *Башка халыкта ничектер, бездә бер ел үтми к и , анда бер-бер төрле яңа көй чыкмасын*мы (Г. Тукай). *Ерак качтың к и , эзләмим* (Н. Борһанова).

**Теркәгеч сүзләр.** Теркәгеч сүзләрнең телебездә, сөйләмдә тоткан урыны, табигате, төп үзенчәлекләре әлегә кадәр җитәрлек тикшерелмәгән. Бу терминның кулланылышы да фәнни әдәбиятта ныклап утырып җитмәгән, морфологиядә ул аерым алып тикшерелми, синтаксиста бәйләүче чара буларак ике төшенчәне берләштереп йөри.

Югары уку йортлары, урта мәктәпләр өчен язылган морфология дәреслекләрендә бөтенләй башка үзенчәлеккә ия булган бәйләүче чаралар кертелә, чөнки теркәгеч сүзләрнең төп үзенчәлеге, морфологик нигезе, җөмләдәге урыны исәпкә алынмый.

Теркәгеч сүзләрнең үзләренә генә хас төп билгеләре бар, шуның өчен аларны башка бәйләүче чаралардан, грамматикада өйрәнелеп килә торган башка төрләрдән аерып карау мөһим.

Теркәгеч сүзләргә хас билгеләрнең кайберләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1. Теркәгеч сүзләр – ике (морфологик һәм синтаксис) яссылыкка карый торган күренеш. Морфологиядә ул теркәгечләр белән, синтаксиста мөнәсәбәтле сүзләр белән чагыштырып өйрәнелә. Мисаллар: *Сәфәргали, к а й д а кушсалар, шунда эшли* (Ф. Хөсни). *К а й ч а н җил күтәрелер дә, к а й ч а н ул томан күтәрелер, анысын әйтүе кыен* (Г. Бәширов). *Элек сез к е м н ә н алган булсагыз, без дә шуңардан сорарга уйлап торабыз* (Г. Ибраһимов).

2. Теркәгеч сүзләрнең нигезендә сорау алмашлыгы ята. Бу яктан ул башка бер төр бәйләүче чарага да охшамый, бу билге аны бүтән чаралардан аерырга мөмкинлек бирә: *Ул, ул – кеше, к а й с ы н гасырлар тудырды, минутлар үтерде* (Һ. Такташ). *Диләфрүз элек бу зур дөньяда япа-ялгыз н и ч е к яши алгандыр да, Юматкыны күрмичә, аның белән сөйләшмичә, аның назларыннан исермичә, ничек көннәрен үткәргәндер, хәзер һич башына сыярлык түгел* (Г. Әпсәләмов). *Зәңгәр кашлы йөзегем к е м д ә булыр, минем күңелем шунда булыр* (Н. Исәнбәт).

3. Теркәгеч сүз тулы бер җөмләне алыштыру сәләтенә ия була алмый, бу яктан ул мөнәсәбәтле сүздән тулысы белән аерылып тора; икенчедән, теркәгеч сүз үзеннән алда яки соң килгән компонентка (җөмләгә) ишарә дә ясамый: анда «күрсәтү кыры» дип йөртелгән үзенчәлек юк. Ике төр бәйләүче чараны чагыштырып караганда, мондый аерма бик ачык күренә.

Теркәгеч сүз бәйләүче чара булып килгән мисалны карыйк: *Н и бар канда, н и бар җанда – ачтым салдым. Ышандым* (Р. Фәйзуллин). Бу очракта *ни* алмашлыгы урынына башка компонентны *(ачтым салдым)* куеп булмый: *ни* теркәгеч сүзе үзеннән соң килгән компонентка ишарә ясамый. Ә менә бу җөмләдә эш бөтенләй башка: *Конференция ике көнгә сузылды, ш у ң а к ү р ә Якуп Оксанадан алдарак кайтып җитте* (Х. Хәйруллин). *Шуңа күрә* – биредә бәйләүче чара, ул алдагы җөмләне тулысы белән алыштыра ала: *Конференция ике көнгә сузылганга к ү р ә, Якуп Оксанадан алдарак кайтып җитте*. Шул рәвешле бу ике төр бәйләүче чараны бер рәткә куеп йөртү дөрес була алмый.

4. Теркәгеч сүз һәрвакыт иярүче компонент ягында (иярчен җөмлә эчендә) була, аның ияртүче компонент ягына чыгу хокукы юк. *Оясында н и кыланса, очканында шуны кыланыр* (мәкаль). *Җыр н и ч е к көтмәгәндә башланган булса, шулай кинәт өзелде* (М. Мөлеков).

5. Бу санап кителгән билгеләр теркәгеч сүзне ияртүче теркәгеч белән бер рәткә куя. Бары тик бер генә чыгарылма бар: ияртүче теркәгечләрнең кайберләре генә сорау алмашлыгына нигезләнгән. Мәсәлән: *ник дисәң, нигә дисәң.* Теркәгеч сүз, бәйләүче чара булу белән бергә, җөмләнең тулы хокуклы бер кисәге дә булып килә. Мисаллар:

а) җөмләнең иясе булып килә: *Бу – бик сер әйбер. К е м туры килсә, шуңардан сорар хәл юк* (Г. Ибраһимов). *Н ә р с ә ачылыр ул томан артында – миңа билгесез* (Ә. Еники);

ә) җөмләнең тәмамлыгы булып килә: *Ни кыланса, шул килешми өйләнмәгән егеткә* (Х. Туфан). *Сезнең бүлек нәрсә эшләргә уйлый – менә шул турыда сөйләгез* (Г. Әпсәләмов);

б) җөмләнең аергычы булып килә: *Нинди эш уңай булса, шул эшне эшлидер* (Г. Тукай). *Кемнең эше юк, шуның ашы юк* (мәкаль);

в) җөмләнең хәл кисәге булып килә: *Анда хәзер Демблин һәм Седельцедән яңа кешеләр китерелгән, ә батальонның иске солдатлары, кая җибәрсәләр, шуннан качып беткәннәр* (Ш. Маннур). *Без йөргән бу илләрне Кавказ таулары ничек бизәп торса, Идел буенда Жигули таулары да безнең якларны шулай гаҗәеп матур бизәп торалар бит* (Г. Иделле).

6. Теркәгеч сүз – аналитик чара, ягъни ул иярүче сүзнең составын тәшкил итми, бары тик иярүче компонент ягында үзе ияртүче сүзнең таләбе белән төрле бәйләүче чаралар ролен үти. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: теркәгеч сүзнең җөмләдә нинди кисәк булып килүе иярүче компонентның төрен (функциясен) билгеләми, бу ягы белән дә ул мөнәсәбәтле сүзләрдән кискен аерыла. Түбәндәге җөмләдә *ни кадәр* теркәгеч сүзе бар, ул, исемгә ияреп килеп, аергыч функциясен үти, әмма, аңа карап, иярчен җөмләне аергыч җөмлә дип билгели алмыйбыз, иярчен җөмләнең төрен баш җөмләдәге *шуны* мөнәсәбәтле сүзе билгели, һәм без иярчен тәмамлык җөмлә белән эш итәбез: *Болар бабаларын каршы алырга бигрәк дәрт белән әзерләнәләр һәм аталарының көтепханәсендә XX гасыр башына даир ни кадәр китаплар булса, шуны укып чыгарга тырышалар иде* (Ф. Әмирхан).

Мөнәсәбәтле сүзнең төзелешенә охшатып, ияреп кулланыла торган, телебездә инде бер калыпка салынган теркәгеч сүзләрнең функциясе иярчен җөмләнең төре белән туры да килә, ләкин бу нигезле бер кагыйдә итеп кулланыла алмый. Мисаллар: *Ни кушсам, шуны тыңлаучы җирән сакаллы угланнарым...* (К. Нәҗми). *Кайда мылтык шартлый, ул шунда барып җитә* (Ш. Усманов). *Көтүчесе нинди, көтүе шундый* (мәкаль).

Теркәгеч сүзләрнең менә шундый үзенчәлекләрен истә тоту аларны башка төр чаралар белән буташтырудан сакларга ярдәм итә.

Татар телендә теркәгеч сүзләрнең саны гаять мул. Әйтик, баш килештәге сорау алмашлыклары *кем, нәрсә, ни, кайсы, күпме, ничә, ни-*

*чек* башка килешләрдә дә килә һәм ул бу төр сүзләрнең санын тагын да арттыра. Димәк, теркәгеч сүзләрнең дә чиге киңәя.

1. Теркәгеч сүз баш килештә кулланыла: *Кем дә кем явызлыкны җиңәргә ышанмый икән, кылычын безгә калдырып кайтып китсен* (К. Нәҗми). *Кеше тәне бияләй түгел: кем утырса, шул тегә алмый* (мәкаль), З*олым, җәбер һәм кыенлыкларны күтәрәләр шул кешеләр ки, Кайсылары кан-тирләргә батып эшлиләр, тир түгәләр* (Г. Тукай).

2. Теркәгеч сүз билгесез килештә кулланыла: *Сезнең бүлек нәрсә эшләргә тели, миңа шул турыда сөйләгез* (Г. Әпсәләмов).

3. Теркәгеч сүз иялек килешендә кулланыла: *Кемнең арбасына утырсаң, шуның җырын җырларсың. Кемнең җырын җырласаң шуның көен көйләрсең* (мәкаль). *Кемнең кызы бар, аның капка төбендә җитмеш ат торыр* (мәкаль).

4. Теркәгеч сүз юнәлеш килешендә кулланыла: *Ул кая барса, Газиз дә, аның артыннан калмый, шунда ашыга иде* (М. Хәсәнов). *Кая карама, шунда бәрәңге сабагы исе таралган, ул ис башны әйләндерә, йөрәккә кан куа, ул ис исертә* (М. Мәһдиев). *Кая теләсә, шунда китә ала* (М. Мәһдиев). *Эш күпмегә уңышлы булып чыга, анысын алдагы көн күрсәтер* (көндәлек матбугат).

5. Теркәгеч сүз төшем килешендә кулланыла: *Ул нәрсәнедер искә төшереп тора, егет вакыт-вакыт шуны хәтерендә яңарта* (М. Харисов). *Яшь вакытта кемне сөйсәң, күңелең шунда була* (җыр).

6. Теркәгеч сүз чыгыш килешендә кулланыла: *Җил кайдан иссә, яңгыр да шуннан ява* (мәкаль). *Шулай инде: кайда кыен, шунда без; каян ага башласа, шунда тизрәк илтеп тыгалар безне* (Ә. Еники).

7. Теркәгеч сүз урын-вакыт килешендә кулланыла: *Казан суы кайнап ыргыла, Идел белән кушылып бер була, Аннан ага, тулып еракка, кайда дошман котыра, шул якка* (Ә. Фәйзи). *Кайда эләксә, шунда баш куеп, йокыга киттеләр* (Ш. Усманов). *Кайда кирәк эшче кулы, шунда булды аның урыны* (С. Сөләйманова).

8. Теркәгеч сүз нәрсәгә булса да охшатуны белдерә: *Җирең нинди булса, икмәгең дә шундый була* (мәкаль). *Күр, ничек талдым фикергә мин дә бер хәким кебек* (Н. Думави). *Ничек инде караңгы була, дөнья аларныкы инде* (Ф. Әмирхан).

9. Теркәгеч сүз сорау алмашлыгы һәм бәйлек ярдәмендә оеша: *Күктә йолдыз, җирдә гөл ни хәтле, Өметләрем ләкин, бел, шул*

*ч а к л ы* (Ә. Баянов). *Электәрәк үз башыңа көн күрү хыяллары н и к а д ә р куәтле булса да, хәзер ул теләкләрнең шул дәрәҗәдә үк әһәмиятләре дә калмады* (К. Тинчурин). *Катя н и к а д ә р Каратаевны онытырга тырышса, егет аның күңелендә шул кадәр ныграк урнашты* (И. Гази).

10. Теркәгеч сүз сорау алмашлыгы һәм бәйлек сүз ярдәмендә оеша: *Кошлар к а й якка очкан булсалар, ш у л яктан кайтырлар да* (мәкаль). *Н и з а м а н к е м син хөкемдарлар кулында кол идең, падишаһлар каршысында баш идең* (С. Сүнчәләй).

Болардан тыш теркәгеч сүзләрнең кайберләре *к и* теркәгече белән бергә калыплашкан хәлдә дә кулланылып йөри: *Кайсы азау вата алсын инде, к а й ч а н к и син каты чикләвек* (Х. Туфан). *Син дә түгел, бабай, янкилар да, иң көчле зат – к е м к и иректе. Сөяк түгел, чуен күсәкләр дә вата алмый фикри иректе!* (Х. Туфан).

Шул рәвешле теркәгеч сүзләр нинди кушымчалар алуга, нинди бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр белән оешуга карап, сан ягыннан арта баралар.

Китергән мисаллардан күренгәнчә, теркәгеч сүзләрне куллануда ике төрле төзелеш урын ала, аның беренчесендә теркәгеч сүзләр төзелмәдәге компонентларны бәйләүдә бердәнбер чара булып торалар, ә икенчесендә тагын бер мөһим бәйләүче чара катнаша: ул – күрсәтү яки билгеләү алмашлыклары белән бирелгән мөнәсәбәтле сүз.

Беренче төркемдәге теркәгеч сүзләр үзләре генә кулланылган булсалар да, килергә мөмкин булып та, җөмлә эчендә урын алмаган мөнәсәбәтле сүзне күз алдына китерү кыен түгел: *К е м д ә к е м Семенов Сергей Степановичны авыл советына сайларга ди – кулларыгызны күтәрегез* (В. Нуруллин). *Н ә р с ә әйтсәң – ышана* («Казан утлары»). *К ү п м е интеккәндер ул шунда; бер сәгатьме, бер тәүлекме – белмим* (Г.Әпсәләмов).

Икенче төр төзелештәге җөмләләрдә теркәгеч сүзләрнең янәшәсендә мөнәсәбәтле сүзләр катнаша. Мондый төзелмәләр телебездә киң кулланылыш тапкан: *Н и н д и мәсләктәге кешеләр: гонорарсыз мәкалә җибәрсәләр, ш у л басыла бирә* (Ф. Әмирхан). – *Беләм, андый нәрсәләрне язган бар,– дип, алъяпкычларын кага-кага, н и ч е к килгән булса, ш у л а й у к китеп тә барды Фатыймәттәй* (Р. Мөхәммәдиев). *Күңелләрдә к ү п м е дәрт бар, уяттың син ш у л а р н ы* (Ә. Фәйзи).

Гасырлар буена иҗат ителгән әдәби мирасның үзебезгә әйләнеп кайтуы, көнчыгыш әдәбиятының гүзәл җәүһәрләре белән кабаттан ныклап кызыксыну, һинд-европа телләрендә язылган күренекле әсәрләрнең тәэсире нәкъ менә теркәгеч сүзләрне киң куллануга этәрә.

Татар телендә теркәгеч сүзләр белән бәйләнешкә кергән төзелмәләрнең компонентлары арасындагы мәгънә мөнәсәбәтләре гаять күп төрле.

*Кем, ни, нәрсә* теркәгеч сүзләре, беренче чиратта, үзара хәбәрлекле мөнәсәбәттә торган компонентларны бәйләүдә катнаша.

1. Бу теркәгеч сүзләр белән бәйләнешкә кергән ияргүче компонент иярчен ия җөмлә функциясен үти. Алда күреп үткәнебезчә, мондый төзелмәнең ике төрдәге төзелеше дә кулланыш таба:

1) теркәгеч сүз ике компонентны бер-беренә бәйләүдә үзе генә катнаша: *Куйган самоварны ни кайната – каен агачының күмере; Өч ай гына түгел, өч ел көттем, өч ел – бер кешенең гомере* (җыр). *Кем күпме эшли, хезмәт кенәгәсенә төшә бара* (С. Рафыйков). *Кем шушы шартларга риза түгел, иртәгә үк заводтан чыгып китсен* (И. Гази);

2) теркәгеч сүз белән бергә килгән мөнәсәбәтле сүз баш җөмләнең иясе булып санала һәм ияргүче компонент та ия җөмлә вазифасын үти: *Кем күп яшәгән булса, шул күпне күргәндер* (мәкаль). *Кем күп укый, шул күп белә* (мәкаль). *Ындырыңда ни булса, келәтеңдә шул булыр* (мәкаль).

Теркәгеч сүзгә хас үзенчәлек – иярчен җөмләнең төрен билгеләүдә катнаша алмау – һәр ике төзелештә дә үзен ачык күрсәтә. Мәсәлән, иярчен ия җөмләдә теркәгеч сүзнең баш килештә генә килүе мәҗбүри түгел: *Кемнең итәгенә ут төшсә, шул яна* (мәкаль). *Кемгә ярый, кемгә юк – газетада шул язылган* (көндәлек матбугат). *Оясында ни күрсә, очканында шул булыр* (мәкаль).

2. Бу теркәгеч сүзләр *(кем, ни, нәрсә)* белән бәйләнешкә кергән төзелмәдә ияргүче компонент тәмамлык җөмлә булып килә: *Кем сынар, кем чыдар – туасы көн сынар* (С. Сөләйманова). *Кемнәр барлык мәсьәләне дә дөрес итеп чишә, бишле билгесе куячакбыз* (Идел). *Бер дә булмаса, дөньяданиләр бар, шуны белик* (Ә. Фәйзи). *Нәрсә бар, шуны сатабыз* (көндәлек матбугат). *Мәгъсум да үзгәрде; ... мәдрәсә тирәли куышып йөрер, кычкырып көләр, агзына ни килсә, шуны сөйләр* (З. Һади).

3. Бу теркәгеч сүзләр *(кем, ни, нәрсә)* белән бәйләнешкә кергән төзелмә компонентларының берсе иярчен җөмлә вазифасын үти:

1) *Кем күргәзмәгә беренче булып килә, мәгълүматларын язып алып калыгыз* (көндәлек матбугат);

2) *Кемнең эше юк, шуның ашы юк* (мәкаль). *Кем яман, аның идәнгә карасы төшеп кала* (Х. Туфан). *Кемнең белеме бар, аның кадере бар* (мәкаль). *Кемгә, җыеп, җиләк бирдең, шул кыз булсын сөйгәнең* (М. Җәлил).

*Кайсы* теркәгеч сүзе белән бәйләнешкә кергән компонент, шулай ук, иярчен аергыч җөмлә вазифасын үти:

1) *Аз шул бездә байлар, кайсысы кем фәрештәдән канат каермас* (Г. Тукай). *Ул, ул – кеше, кайсы өчен бүген бөтен җир яшь түгә, Кайсының рәсмен бүген ерак африканецлар табып, елап үбә* (Һ. Такташ);

2) *Бәхетле шул баладыр, кайсы дәрсенә күңел бирсә* (Г. Тукай). *Кайсы урыннан юл салырга кирәк, шундагы урманны кисеп, җирен тазартып бетерегез* (көндәлек матбугат). *Кайсы ыру көчле, ханны шул ыру куя; кайсы ыру үчле, канны шул ыру коя* (мәкаль).

*Кайда, кая, кайдан* теркәгеч сүзләре, беренче чиратта, эш-хәрәкәтнең урынын күрсәткән төзелмәне оештыруда катнаша:

1) *Кайда егыласымны белгән булсам, алдан ук салам түшәтеп куйган булыр идем* (мәкаль);

2) *Кайда эшләсә, шунда кала зимагурның маллары* (җыр). *Кайда куркыныч, аның йөрәге шунда ташланырга ашкына торган булды* (Г. Ибраһимов). *Ярда торгач, ач халыкка йөз дә бормый Юргалый ул шунда тиз-тиз, кайда бай сайфиясе* (Г. Тукай).

*Кайда* теркәгеч сүзе белән бәйләнешкә кергән компонент иярчен аергыч җөмлә вазифасын үти: *Утыр аулакка, кайда һич кеше юк, сабыйдай тәмле-тәмле күз яше түк* (Г. Тукай).

Бу теркәгеч сүз иярчен тәмамлык җөмләне баш җөмләгә бәйләүдә дә катнаша: *Казанга килгәч, кайда торып ята булыр – бөтенләй ишеткәнем юк* (көндәлек матбугат).

*Ничек* теркәгеч сүзен шактый тотрыклы бәйләүче чаралар рәтеннән санарга кирәк, чөнки ул иң зур күпчелектә эш-хәрәкәтнең ни рәвешле үтәлүен чагылдыра торган төзелмәләрдә кулланылып йөртелә.

1) *Нигә мин тормадым бер читтә ялгыз,* *н и ч е к* *күктә яна бер данә йолдыз?* (Г. Тукай). *Юк, шунда да дөресен әйт,* *н и ч е к* *оештырасың андый эшне?* (А. Расих). *Рәхимҗан абзый* *н и ч е к* *көйләр бит әле – белгән юк* (И.Туктар). *Алмашыну* *н и ч е к* *булган – исең китәр* (Н. Думави);

2) *Кемнең дә булса асылташны гади таштан аера алмавы геологны* *н и ч е к* *җәберләсә, телнең кадерен белмәүче, аны аңламаучы һәм бозучылар тел белгеченең һәм язучының да шулай ук кәефен кыралар* (Г. Бәширов). *Хәзер ул* *н и ч е к* *әйтсә, мәҗлеснең соңы шулай бетәчәк* (Ә. Баянов). *Ул арада җил көче белән капканы төбенә кадәр ачып җибәрүгә, бозау, кергәндә* *н и ч е к* *коерык чәнчеп кергән булса, шулай чыгып та чапты* (Ф. Хөсни).

*Ничек* теркәгеч сүзе ярдәмендә бәйләнешкә кергән һәм ияртүче компонентта *шулай, шул кадәр* сүзләре килгән төзелмә хәзер инде телебездә калыплашкан бер гыйбарә хәленә кереп бара, андый төрне язучы һәм журналистларның һәркайсы куллана, халык авыз иҗатында да еш күзәтелә: *Таһир Зөһрәне* *н и ч е к* *сөйгән, мин дә сине сөям шул кадәр* (җыр). *Ак куй баласын күрмәсә,* *н и ч е к* *түзмәйдер, бу кыз мине күрмәсә, шулай түзмәсен, минем артымдан калмасын* (М. Усманов). *Камилә карчык* *н и ч е к* *тиз керсә, ул шулай тиз чыгып та китте* (М. Мәһдиев).

*Ничек* теркәгеч сүзе вакыт нисбәтендәге компонентларны бәйләүдә дә очрый: *Йокысыннан Кояш* *н и ч е к* *уяндисә, Җил шул вакыт җилбер-җилбер итеп исә* (Г. Тукай).

*Ничә, күпме, ни кадәр, ни чаклы, ни хәтле* теркәгеч сүзләре ярдәмендә бәйләнешкә кергән җөмлә белән ияртүче компонент арасында микъдар-күләм, объектлык нисбәте урнаша:

1) *Казан шәһәренә* *н и ч ә* *миллионга төшкәндер ул көн – белмим* (М. Мәһдиев). *Н и ч ә* *кем зур әйләде, күтәрмәде, зәррә мыскал җиреннән тибрәтмәде* (Г. Тукай);

2) *Бәйләмдә чәчәкләрнең төре* *н и* *к а д ә р* *күп булса, гадәттә бәйләм шул кадәр матуррак һәм хуш исле чыга, һәр чәчәк аны үз төсе, үз хуш исе белән баета* (Г. Бәширов). *Болытның юлы бу авылларга, бу басуларга таба* *н и ч а к л ы* *якын килсә, крестьяннарның йөрәкләрендәге өмет катыш шатлык шул чаклы арта бара* (Г. Ибраһимов). *Искеләр* *к ү п м е* *кирегә китсәләр, без шул кадәр алга китәмез* (Ф. Әмирхан).

Шушы ук теркәгечләр белән бәйләнешкә кергән компонентлар арасында хәбәрлекле мөнәсәбәт тә урнаша ала: *К ү п м е булса сездә көч һәм ялкын, шул кәдәрле җирдә хаккыгыз!* (М. Җәлил). *Агачта яфрак н и ч а к л ы , бездә шатлык шул чаклы* (җыр).

*Нинди* теркәгеч сүзе белән бәйләнешкә кергән җөмләләрнең берсе шулай ук иярчен хәбәр җөмлә вазифасын үти. Бу калыптагы кушма җөмләләрне без халык авыз иҗаты үрнәкләрендә күпләп очратабыз: *Агачы н и н д и , җимеше шундый* (мәкаль). *Соравы н и н д и , җавабы шундый* (мәкаль).

Бу теркәгеч сүз иярчен аергыч җөмләне баш җөмләгә бәйли: *Н и н - д и эш уңай булса, шул эшне эшлидер* (Г. Тукай). *Бу уй н и н д и кинәтлек белән исемә төшсә, шундый ук тизлек белән югалды да* (Ф. Сәйфи-Казанлы).

*Нинди* теркәгеч сүзе белән килгән иярчен җөмлә баш җөмләдәге күләм хәлен ачыклый*: Осталыгың н и н д и зур булса, шул кадәре юлың киң булыр* (Х.Туфан).

*Кайчан (кайчан ки)* теркәгеч сүзе белән бәйләнешкә кергән төзелмәнең компонентлары үзара вакыт нисбәтендә торалар: *Мостафин к а й ч а н керсә, шунда Нажиясе канатлы кош кебек очып каршы ала иде* (Ә. Еники). *Ул к а й ч а н килергә куша, Илсөяр нәкъ шул вакытта килеп җитә* (Г. Гобәй). *К а й ч а н к и комнан аркан ишеп, күлне күккә асарлар, бу эш шунда булыр* (мәкаль). *Менә Баязит абый к а й ч а н котылса, мин шул чакта кайтырмын* (Г. Ибраһимов).

# 11. КИСӘКЧӘЛӘР

Аерым сүзләрне һәм җөмләләрне төрле мәгънәви һәм модаль төсмерләр белән бизи торган ярдәмлек сүзләр кисәкчәләр дип атала.

Мөстәкыйль сүзләрдән кисәкчәләр тулы лексик мәгънәне түгел, төрле өстәмә төсмерләрне генә белдерү һәм, шунлыктан, аерым җөмлә кисәге булып килә алмау белән аерылалар, Болардан тыш, кисәкчәләргә ясагыч һәм төрләндергеч кушымчаларны кабул итмәү һәм үзләренә аерым басым белән әйтелмәү хас.

Кисәкчәләр кайбер яклары белән кушымчаларга охшыйлар. Кушымчалар кебек үк, алар да, бердән, контексттан тыш, ялгыз кулланыла алмыйлар, ә мөстәкыйль сүзләргә ияреп кенә киләләр; икенчедән, күбесе «төрле аваз вариантлары бирәләр, ягъни аларның бердәм аваз составлары юк» [Дмитриев Н., 1950, с. 131] (*дыр-дер/тыр-тер, гына-генә/кына-кенә, ук/үк* һ.б.). Әмма кисәкчәләр, кушымчалардан аермалы буларак, «морфологик-синтаксик рольне түгел, ә фәкать синтаксик рольне генә үтиләр» [шунда ук]. Кушымчалар билгеле бер сүз төркеменә ялганып һәм аның морфологик формасын үзгәртеп, ул сүзнең башка сүзләр белән булган синтаксик бәйләнешләрен тәэмин итәләр. Ә кисәкчәләр, киресенчә, төрле сүз төркемнәре янында киләләр һәм алар сүз һәм җөмләләрне модаль һәм экспрессив-стилистик төсмерләр белән бизәп, махсус синтаксик конструкцияләрне төзүдә зарури структур элемент буларак катнашалар [Шведова Н., 1960, с. 18–19]. Кайбер кисәкчәләр исә теркәгечләргә якын функцияне башкаралар. *Әллә, әле, мы/ме* кисәкчәләре, мәсәлән, саф модаль төсмерләрне белдерү белән бергә, сүз һәм җөмләләрне бәйләү хезмәтен дә үтиләр.

Кисәкчәләр мәгънәләре буенча дүрт төркемгә бүленәләр: 1) логик-мәгънәви: *нәкъ, гына-генә/кына-кенә, бары, тик, фәкать, исә* һ.б.; 2) модаль һәм модаль-ихтыяри: *һич, ни, мы/ме, мыни/мени, әллә, дыр-дер/тыр-тер, сана/сәнә, чы/че, әле, инде* һ.б.; 3) экспрессив: *да-дә/та-*

*тә, ук/үк, хәтта; иң, чем, дөм, утә* һ.б.; 4) эмоциональ кисәкчәләр: *бит, ич, лабаса/ләбаса, ла/лә* һ.б.

*Гына-генә, кына-кенә, нәкъ, тик, бары, фәкать, исә* кисәкчәләре сүзләрне аеру-чикләү һәм аныклау-билгеләү функцияләрен үтиләр.

*Гына-генә/кына-кенә* кисәкчәсе, төрле сүз төркемнәренә ялганып, аларны аеру-чикләүне белдерә: *Күп идек без былтыр үткән к ө з г е н ә , Инде калдык барчабыз б и ш й ө з г е н ә* (Г. Тукай). *Тик телеграф аппаратының рычагы т а в ы ш ы г ы н а аның колагына керә, у л г ы н а аны уята ала* (Ш. Усманов). *Төрмә тып-тын. Моңсу караш белән Күктән карый тулган а й г ы н а* (М. Җәлил).

*Гына-генә/кына-кенә* кисәкчәсе мәгънәне көчәйтү функциясен дә үти ала: *Безнең илкәй – и л г е н ә . Җир йөзендә бер генә; Безнең илдә үскән кызлар Ч ә ч ә к к е н ә , г ө л г е н ә* (К. Әмири). *Без, бернәрсәгә карамастан, ч а б а б ы з г ы н а* (Г. Ибраһимов). *Яңгыр, к и с ә к к е н ә башланган кебек, к и с ә к к е н ә узып та китте* (М. Галәү). *Я ң а г ы н а , тик менә х ә з е р г е н ә урам капкасын куе дегет белән сылап киткәннәр* (Г. Ибраһимов).

*Гына-генә/кына-кенә* кисәкчәсе сыйфат һәм рәвешләр янында кайвакыт предметның билгесе яки микъдары нормаль дәрәҗәдән кимрәк яки артыграк булуны белдерә: *Үзе булган т а з а г ы н а бер яшь кеше. Ялыкмыйча эшли икән ул таш эше* (Г. Тукай). *Гыйбашның күзгә бәрелеп торган күркәм яклары да к ү п к е н ә* (Г. Бәширов).

*Тик, бары, фәкать* кисәкчәләре шулай ук үзләре караган сүзләрне аеру-чикләүне белдерәләр: *Вә шунда, кайда аулак. Җил дә мин т и к , йөрербез бер-бергә Син дә мин т и к* (Г. Тукай). *Авыл кырыенда бер өйдә ф ә к а т ь сүнми тора бер ут* (Г. Тукай).

*Тик, бары* кисәкчәләре бик еш *гына-генә/кына-кенә* кисәкчәсе белән бер үк сүз янында бергә кулланылалар: *Вагоннарда т и к штаблар, аерым командалар г ы н а калды* (Ш. Усманов). *Нәгыймә... шул йөрәк эчендә үзе генә, т и к ү з е г е н ә , тик Нәгыймә генә, тик ул я л г ы з ы г ы н а булганын тирән бер ышаныч белән бөтен күңеленнән сизенә* (Г. Ибраһимов). *Ул карады миңа б а р ы б е р г е н ә кат, Шуннан: Башын бөкте, бакмады* (Һ. Такташ).

*Тик* һәм *фәкать* кисәкчәләре, үз семантикаларын өлешчә саклаган хәлдә, каршы куючы теркәгеч функциясен дә үти алалар: *Көндез кояш чыкты, кар өсләре бик матур булып ялтырап яттылар. Т и к м е н ә*

*кичкә таба гына әзрәк җил кузгалды* (Г. Ибраһимов). *Безне һичкем азат италмас, ф ә к а т ь итәрбез үзебез. Безне һичкем дә шат италмас, ф ә к а т ь итәрбез үзебез* («Интернационал»). *Кәкре түгелдер моның бармаклары – бик төз-төзен. Т и к килешсез һәрбере дә ярты аршыннан озын* (Г. Тукай).

*Исә* кисәкчәсе исем сүзләрдән соң аеру-чикләү, ә фигыльләрдән соң тизлек төсмерләрен белдерә: *Йокларга уйлыйм. Б а б а й и с ә нидәндер йоклый алмый* (Г. Тукай). *Йокысыннан кояш ничек у я н д и с ә, Җил шул вакыт җилбер-җилбер итеп исә* (Г. Тукай). *Ә ай күктә һаман сүгенеп йөри, Җил й о к л а д ы и с ә төн белән* (Һ. Такташ).

*Нәкъ* кисәкчәсе, исем сүзләр алдында килеп, аныклау-билгеләү мәгънәсен белдерә: *Н ә к ъ К а з а н а р т ы н д а бардыр бер авыл – «Кырлай» диләр* (Г. Тукай). *Яшәде ул сөеп, һәм үләр бер көнне Н ә к ъ м ә г ъ р у р с а н д у г а ч һәм чишмә шикелле* (М. Җәлил). *Н ә к ъ ш у л в а к ы т ил өстендә, еракта, авылга таба кайтып килүче чаналы кеше күренде* (И. Гази).

*Һич, ни, -мы/-ме, -мыни/-мени* һәм *ә* кисәкчәләре сөйләүченең чынбарлык фактларына һәм күренешләренә модаль мөнәсәбәтен белдерәләр.

*Һич* кисәкчәсе инкяр җөмләләрдә юклык мәгънәсен көчәйтү, куәтләү өчен кулланыла: *Барча байлыкны җыячаклар имеш, һ и ч һөнәрсез бай булачаклар имеш* (Г. Тукай). *Һ и ч уенда юк кызык, дәрсем хәзерләп куймагач* (Г. Тукай).

*Ни* кисәкчәсе, *түгел* сүзе белән килеп, билгесезлек мәгънәсен белдерә: *Н и он т ү г е л, камыр т ү г е л, Булдык без пешмәгән калач* (Г. Тукай).

*Мы/ме* кисәкчәсе, хәбәргә ялганып, сорау мәгънәсен белдерә: *Нәрсә бу? К а ч к ы н м ы? Җ е н м е? Я ө р ә к м е? Нәрсә бу?* (Г. Тукай). Т*ик әйт, кошчык, Синең минем янга бу килүең соңгы к а б а т м ы?* (М. Җәлил). *Т ы ң л а д ы ң м ы син ул җырны йокы аралаш: Т о р д ы ң м ы син хисләреңә Түзә алмагач; К ү ч е р д е ң м е, без килер дип, Тәрәз гөлеңне; К ү т ә р д е ң м е, күрермен дип, Ап-ак өлгеңне?* (С. Хәким).

*Мы/ме* кисәкчәсе, категорик үткән заман фигыльләргә ялганып, шарт мәгънәсен, ә тиңдәш кисәкләргә ялганып, билгесезлекне белдерә яки бүлгәләүче теркәгеч функциясен үти: *Төш а в ы ш т ы м ы – офыкка Кышкы кояш байый* (С. Хәким). *Хәлең бетеп е г ы л д ы ң м ы –*

*шәфкать көтмә: приклад белән бәргәлиләр дә юл кырыена чыгарып атып китәләр* («Соц. Татарстан»). *И с е р е к л ә р м е, а й н ы к л а р м ы – йөгенә керә алмыйм, иллә мәгәр, котырган этләр кебек талашып баралар иде* (Г. Ибраһимов). *Ярты юл у т т е м е, ю к м ы, Котырып буран чыкты* (С. Хәким). *Йөк б у ш а т у м ы ул, урам с е б е р ү м е, тәрәзә ч и с т а р т у м ы – анысы турында уйлап та тормыйсың* («Соц. Татарстан»).

*Мыни/мени* (< *мы/ме* + *ни* алмашлыгы) кисәкчәсе гаҗәпләнү тойгысы белән сугарылган сорауны белдерә: – *Шулай тиз у т т е м е н и бу гомер?* (Г. Ибраһимов).

*Мыни/мени* кисәкчәсе катгый раслауны аңлаткан риторик сорау җөмләләрдә дә кулланыла: Б*ергә гомер иткән, яхшылыгын, яманлыгын бергә кичергән, бергә аш-су күргән кешеләр о н ы т ы л а м ы н и* (Г. Ибраһимов). *Илдә яу йөргән чагында, Ир кеше т ү з ә р м е н и. Аерылу җиңел түгел дә, кыз өмет ө з ә р м е н и* (С. Хәким).

*Ә* кисәкчәсе сорау интонациясен тагын да көчәйтү, куәтләү хезмәтен үти: *Миңа ачуланмыйсыз бит, ә?* (М. Гафури).

*Әллә* кисәкчәсе, җөмләдә ялгыз үзе генә килсә, билгесезлек мәгънәсен, ә *мы-ме* сорау кисәкчәсе белән бергә кулланылса, фараз итү, чамалау мәгънәсен белдерә: – *Син соң каян беләсең? Ә л л ә сөлге, ә л л ә тастымал! Ә л л ә уң ягы белән торган килен, ә л л ә хәтәр төшләр күреп уянган?* (Г. Бәширов). *Ә л л ә сөйли, ә л л ә җырлый, ә л л ә икесе дә бергә?* (Г. Бәширов). *Нинди эш булган соң анда, нәрсә бар? Бер сугыш чыкканмы, ә л л ә пожар?* (Г. Тукай). *Ә л л ә ул Донбасста өйрәнәме күмер базларын?* (Н. Баян).

*Әллә* кисәкчәсе, модаль мәгънәсен саклаган килеш, бүлгәләүче теркәгеч сыйфатында тиңдәш кисәкләрне һәм җөмләләрне үзара бәйләү өчен дә кулланыла: *Язгы яңгыр тамчысы бер башка тамчыдан сорый, Ә л л ә белмичә сорый, ә л л ә шаярыпмы юри?* (Г. Тукай). *Ә л л ә алар караңгы төндә, юлдан язып, тирән кар эчендә күмелеп калдылармы? Ә л л ә биш мең кеше, берсе дә калмыйча, дошман кылычы астында үлеп беттеме?* (Ш. Усманов).

*Дыр-дер/тыр-тер* кисәкчәсе, төрле сүз төркемнәренә кушылып, билгесезлек, икеләнү, чамалауны һәм «фактның дөреслегенә сөйләүченең, ничектер, ышанып җитмәвен аңлата» [Дмитриев Н., 1950, с. 132]: *Әни кемнәр б е л ә н д е р сөйләшә, ишек янында к е м н ә р-*

*д е р кыштырдый* (Г. Бәширов). *Кем белә, бәлки алар язгы җилдән дулкынланмый т о р г а н д ы р , ә таудан аккан кар суы белән с а у - б у л л а ш а л а р д ы р* (А. Шамов). *Мин унбер яшьләремдә б у л г а н - м ы н д ы р , яңа гына укудан кайткан идем* (Г. Ибраһимов).

*Әллә* һәм *дыр-дер/тыр-тер* кисәкчәләре сорау алмашлыкларыннан билгесезлек алмашлыклары ясыйлар: *әллә кем, әллә нәрсә, әллә ничек, әллә нинди, әллә кайда; кемдер, нәрсәдер, ничектер, ниндидер, кайдадыр* һ.б.

*Чы/че, сана/сәнә, әле, инде* кисәкчәләре сөйләүченең тыңлаучыга карата модаль-ихтыярый мөнәсәбәтен белдерәләр.

*Чы/че, сана/сәнә* кисәкчәләре, боерык фигыльләргә ялганып, үтенү, ялыну, ялвару яки тәкъдим һәм җиңелчә боеруны белдерәләр: – *Кил әле, син дә бераз бармакларыңны селкет и яшь егет! К и л - ч е , икәү уйныйк бераз кети-кети* (Г. Тукай). – *Син бераз кызган мине, к о т к а р ч ы , и адәм генәм* (Г. Тукай). *Күл янында утырып җырлар язам, Әй, таң җиле, тукта, и с м ә ч е !* (Һ. Такташ). *Бер йөзең к ү р - с ә т с ә н ә , Тугсын гүзәл көннәр минем* (Г. Тукай). *К у й с а н а юкны, к ө л д е р м ә с ә н ә , Юкка сүзне б ү л д е р м ә с ә н ә !* (С. Хәким).

*Әле* кисәкчәсе, боерык һәм теләк фигыльләр янында килеп, үтенү, теләк яки карар кылу төсмерләрен белдерә: – *Әйдә, кер ә л е өйгә* (Г. Ибраһимов). *Кил ә л е син дә бераз бармакларыңны селкет, и Яшь егет!* (Г. Тукай). *Шул турыдан аз гына, биш-алты сүз сөйлим ә л е , Гадәтемчә аз гына җырлыйм әле, көйлим ә л е* (Г. Тукай). *Кара сатин ситсылардан Күлмәк кистерим ә л е , Сиңа охшатып бакчаларда Гөлләр үстерим ә л е* (халык җыры). *Шуңда да мин Садрыйны җибәрим ә л е* (М. Фәйзи).

*Әле* кисәкчәсе, кабатланып килеп, бүлгәләүче теркәгеч сыйфатында вакыйгаларның яки предметларның бер-берсен алмаштырып килүен белдерә: *Яшүсмер Мифтах өй йомышларыннан бушамады, аны ә л е Фәтхия әби, ә л е Мәфтуха килен бертуктаусыз йөгертә тордылар* (Г. Ибраһимов). *Болын өстен яңгыратып ә л е уңда, ә л е сулда көйләп-көйләп чалгы яныйлар* (Г. Бәширов). *Ә л е яшь әтәч кычкырган, ә л е үрмәкүч тозагына эләккән чебеннәр безелдәгән шикелле* (Г. Бәширов).

*Инде* кисәкчәсе боерык фигыльләр янында – үтенү, ялыну, хикәя фигыльләр янында – вакыт, ә исем сүзләр янында – көчәйтү төсмерен

белдерә: *Алсу тагын ялынып чакыра. – «Кил, уйнамыйм, бетте... Кил и н д е !»* (Һ. Такташ). *Язгы сандугачлы яшьлек таңым үтте и н д е ... Онтылдылар бик күп исемнәр, И н д е яшьләр хәзер яратсыннар. И н д е яшьләр хәзер сөйсеннәр...* (Һ. Такташ). *Бу и н д е үзенең аллы-кызыллы чуклары белән бөтен бүлмәне нурлы төсләр дулкынына тутырды* (Г. Бәширов).

Экспрессив кисәкчәләр сүзләрнең мәгънәләрен көчәйтү хезмәтен үтиләр. Алар түбәндәгеләр: 1) *да-дә/та-тә, ук/үк, хәтта;* 2) *иң, чем, дөм, үтә, чалт, җете, тома, шыр;* 3) *ап, зәп, кап, кып, нәп, оп, сап, соп, тап, түм* һ.б. Болар асыл сыйфатларны бер иҗеккә кадәр кыскартып һәм аларга *п, м* тартыклары ялгап ясалалар һәм шул сыйфатлар белән генә кулланылалар да, мәсәлән: *ап-ак, зәп-зәңгәр, кап-кара, кып-кызыл, нәп-нәзек* һ.б. Күренгәнчә, бу төр кисәкчәләр, икенче төркемгә караган кисәкчәләр кебек үк, сыйфатларда артыклык дәрәҗәсен ясыйлар.

*Иң* кисәкчәсе асыл сыйфатлар, кайбер урын-вакыт һәм күләм-чама рәвешләре, сыйфат фигыльләр белән кулланыла: *Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабереӊ ташы, Шунда тамсын күз яшемнең и ң ачы һәм татлысы* (Г. Тукай). *И ң күбе бармак башы зурлыгында җир җиләкләре* (Г. Ибраһимов). *Менә хәзер инде икебез дә картайдык, чәчләребез агарды, һаман бер-беребезгә и ң сөйгән вә и ң якын кешеләр булып гомер итәбез* (Ш. Камал).

*Шыр* кисәкчәсе *тиле, ялангач* сыйфатлары һәм кайбер исемнәр белән кулланыла, мәсәлән: *Кызганыч егетләр ш ы р далада тилмереп, иңгереп үләләр* (Н. Думави). *Мин алдымда күрдем ш ы р сөяктән котылгысыз үлем шәүләсен* (М. Җәлил).

*Дөм, җете, чалт* кисәкчәләре *сукыр* һәм башка сыйфатлар *(җете кызыл, чалт аяз, дөм сукыр), үтә* кисәкчәсе *салкын* һәм *явыз* сыйфатлары, хәтта кайбер фигыльләр белән дә кулланылалар. Мәсәлән: *Мондый чакларда ул үзенең авылын ү т ә сагынып куя* (Г. Ибраһимов).

*Да-дә/та-тә* кисәкчәсе түбәндәге мәгънәләрне белдерә:

1) исемнәр янында ялгыз, үзе генә килеп, *тагын, шулай ук* сүзләренә якын мәгънәне белдерә: *Башкалар белән Җ и һ а н ш а б а б а й д а килгән иде* (Г. Ибраһимов). *Быел Ш ә м г у н С а ф а с ы д а язны мыек чыккан егет кебек каршы алды* (А. Шамов);

2) тиңдәш кисәкләрдән соң кабатланып килеп, аларны үзара бәйләү белән бергә, экспрессияне арттыра, мәгънәне көчәйтә төшә:

*Яныңда Зыя д а юк, бакча д а , нур д а , чәчәкләр д ә , теге чатыр эчендәге диңгез д ә – берсе дә юк* (Г. Ибраһимов). *Минем җаныем, бригадир, Күкрәгендә медале; Казанда д а , Мәскәүдә д ә Белмәгән юк инде аны* (халык җыры);

3) шарт фигыльләр составында кире шарт, ә хикәя һәм хәл фигыльләр составында тизлек, кинәтлек мәгънәләрен белдерә: *Сагынсам д а сине, яратсам д а сине, Кайта алмыйм әле хәзергә* (Һ. Такташ). *Күренде д ә шул ук минут бөтен Иделне, бөтен тирә-як урманнарын, яланнарын яңгыратып, корыч тавыш белән кычкыртып т а җибәрде* (Г. Ибраһимов);

4) кабатланып килгән хикәя фигыльләр арасында процессның дәвамлылыгын белдерә: *Таңнан башланган кар туктамады, яуды д а яуды* (Г. Ибраһимов). *Буран дулый д а дулый, әти һаман юк* (Г. Бәширов);

5) җөмләнең тиңдәш кисәкләре арасында *һәм* теркәгече функциясен үти: *Ичмасам, иптәш тә юк ич, тик икәү без: уй д а мин* (Г. Тукай). *Кулда мылтык т а пулемет, алда матур ал флаг* (Й. Йосфый).

*Ук/үк* кисәкчәсе көчәйтү һәм тизлек төсмерләрен белдерә: *Гыйбаш абзый... сөлгене колганың иң югары очына у к бәйләп куя* (Г. Бәширов). *Тиз барып җиткән егет, эшкә тотынган баргач у к* (Г. Тукай).

*Хәтта* кисәкчәсе үзеннән соң килгән сүзне, аеру-чикләү белән бергә, мәгънәсен дә көчәйтә төшә: *Кайчакларны аның вәгъдәсе х ә т т а әллә ничә елга сузыла, йонны чормада көя турап бетерә* (Г. Бәширов). *Бармыймын х ә т т а Микитин циркына, Шул Дию башына күңлем җилкенә* (Г. Тукай).

*Түгел* кисәкчәсе[1] түбәндәге функцияләрне үти:

1. Хәбәр составында килсә, тулы инкярны (1), ә ия һәм иярчен кисәкләр составында килсә, өлешчә инкярны (2) белдерә:

1) *Җәйге күк к ү л м ә к т ү г е л ш у л : үтми бармак тун калын* (Г. Тукай); *Һичкайсыгыз т а н ы ш т ү г е л хәсрәт берлә, утыргансыз матур гына рәт-рәт бергә* (Г. Тукай). *Аталарның йөрәкләре дә т ы н ы ч т ү г е л* (Г. Ибраһимов). *Яралы кызылармеец бер генә*

---

[1] *Түгел* кисәкчәсенең этимологиясе турында кара: Кононов А. Этимология слова *däril* «не есть», «не» // Советское востоковедение. 1949. VI. С. 52–62; Мельников Г. К этимологии отрицания *tegül* (По материалам «Древнетюркского словаря») // Советская тюркология. Баку. 1970. № 4. С. 57–66.

*минутка да ярдәмсез ятарга тиеш түгел* (Ш. Усманов). *Ерактан мылтык, пулемет ату да мөмкин түгел иде* (Ш. Усманов); *Гомер – ит кисәге түгел* (М. Мәһдиев);

2) *Өздереп нигә карадың, Ник тоттың чиләгемнән, Суларым түгел, ялкыным түгелде йөрәгемнән* (С. Хәким). *Кит инде, безнең юлны түгел, бәлки без ташлап киткән юлны кисәргә бара* (Ф. Әмирхан). *Әле күптән түгел генә аңар мөкатдәс булып күренгән бу калфаклы кызлар хәзер инде бөтен мәгънәләрен җуйдылар* (Ф. Әмирхан). *Бара болар. Туктамастан һаман бара, Күрә болар: ерак түгел бер ут яна* (Г. Тукай). *Электә бер ташчы торган бу дөньяда, Безнең җирдә түгел, ерак Япониядә* (Г. Тукай). *Үскән фәрештәдәй кыз бала, җирдә түгел, күктә, гарешләрдә Булмаган бер тиң аңа* (Һ. Такташ). *Әмма алар да (кар өемнәре) көнләп түгел, сәгатьләп эри, дымлы җир ачыла бара* (М. Галәү).

Тиңдәш кисәкләр һәм тезмә кушма җөмләләр составында күрсәтелгән кисәкчә кабатланып килергә дә мөмкин: *Безнең гомер уен түгел, бәйрәм түгел, һич кайгысыз кеше булса, адәм түгел* (Г. Тукай). *Хәсәннең ул белеш түгел, таныш түгел, Нинди икәне мәгълүм түгел кызга кәефе китә башлады* (Ф. Әмирхан). *Ай түгел, атна түгел, бер көн, бер сәгать көтәргә дә ирек бирмәделәр* (Г. Ибраһимов). *Сирәк-сирәк атылган снарядлар хәзер авыл өстендә түгел, болын өстендә дә түгел, ә Идел өстендә ярыла* (И. Гази). *Күрдем хәзер; Эшкә хәзер һичнәрсә тиң түгел, Эштән көчле нәрсә табу мөмкин түгел* (Г. Тукай). *Ул шәһәр – гади шәһәр, алтын, көмеш, гәүһәр түгел, Күл дә тик бер күл генә, әлбәттә, ул кәүсәр түгел* (Г. Тукай).

2. Ябык градацион мөнәсәбәтләрне белдерә торган җөмләләрдә (7) *түгел* кисәкчәсе *һәм* яки *-да/-дә (-та/-тә)* теркәгече функциясендә кулланыла. Андый җөмләләр, әлбәттә инде, инкярны түгел, ә раслауны белдерәләр. *Кинаяләрне егет белән кыз үзләре генә түгел, башкалар да аңладылар* мисалында, мәсәлән, *түгел* кисәкчәсе *егет* һәм *кыз* төшенчәләрен инкяр итүне түгел, ә *Кинаяләрне һәм егет белән кыз үзләре һәм башкалар* (яки *егет белән кыз үзләре дә, башкалар да*) *аңладылар* дигән мәгънәне белдерә. Әлеге кисәкчәнең шулай ук тиңдәш кисәкләрне үзара бәйләү функциясендә кулланылуы түбәндәге җөмләләрдә күренә.

*«Яз якын»ның шатлыгыннан йөзгә чыккан елмаю Инде яшьләрдә т ү г е л , хәстә вә хәлсез картта бар* (Г. Тукай). *Шәкертләр генә т ү - г е л , бертөрлерәк хәлфәләр дә аңа бераз шикләнеп карыйлар иде* (Г. Ибраһимов). *Әти миннән әллә ничә сүз сорады. Мин һәммәсенә җавап бирү генә т ү г е л , әти берлә моназара кылышып китеп, әнине дә куркыттым да* (Г. Исхакый). *Аның (Зыяның) бу сыйфатларын, башка һәркемнән бигрәк, Зөләйха абыстай белә,– юк, белә генә т ү г е л , эре вә йөрәге белән сизә* (Г. Ибраһимов). *Мин генә т ү г е л , күпләр телебез язмышы турында борчылып уйлана* (Ә. Еники). *Бер муены белән генә т ү г е л , Раиса күзләре һәм зифа буе-сыны белән дә Фәйзулланың хыялын алдамады* (Ф. Хөсни).

3. Ике инкярлы җөмләләрдә инкяр түгел, ә раслау белдерелүгә берничә мисал: *Озыкламыйча, шәһәрнең беренче ахуны булу ихтамалы да ю к т ү г е л* (Г. Ибраһимов); *Адашып, авылга кайтам дип, бөтенләй кире якка китеп баручылар, йөреп һәлак булучылар да ю к т ү г е л* (Г. Ибраһимов). *Хәер, Әминә үзе дә к а у ш а м а г а н т ү г е л иде* (Ф. Әмирхан). *Малайга өйдә дә э л ә к м ә д е т ү г е л* (Ф. Хөсни). *Байлыгы шәп булганга, дус-иш күп, түрәләр тирәсендә дә к а д е р с е з т ү г е л иде* (Г. Ибраһимов). *Мәләкәснең урамнары да, Мәләкәснең чыпчыклары һәм этләре дә – берсе дә я м ь с е з т ү г е л* (Ф. Хөсни).

4. *Юк* сүзе белән *түгел* кисәкчәсе, еш кына, янәшә килеп, алда әйтелгән фикерне катгый рәвештә инкяр итүне (кире кагуны), аның белән килешмәүне, аңа кискен каршы төшүне белдерәләр: *Җәзалау камчысын биргән ул халыкка к е м ? Т ү г е л , ю к . Бирмәгән һичкем, Ходай гадил, Ходай хаким!* (Г. Тукай). *Хәсрәтем – әллә минем нурлы кабыклы бер елан? Куркынырда елмаялар, ни бәхетледер елан! Ю к , т ү г е л , һәрхәлдә дә хәсрәт язу рәүшем шулай* (Г. Тукай). *Төсе нинди?.. Татар кызы булгач, ул инде кара туткыллырактыр. Ю к , т ү г е л . Татар кызларында да бик ак йөзле, саргылт чәчле, зәңгәр күзлеләре була* (Г. Исхакый).

5. *Түгел* кисәкчәсе тиңдәш кисәкләр ярдәмендә бирелгән раслау белән инкярны яки инкяр белән раслауны бер-берсенә капма-каршы куюны белдерә: *Кызганыч хәл, кызганыч хәл, бик кыен бит, бик кыен; Бирсәгезче бер тиен тик, тәңкә т ү г е л бит, тиен* (Г. Тукай). *Зәгыйфь кырмыскамын мин юлда яткан, Т ү г е л бал корты мин чагып елаткан* (Дәрдемәнд). *Бары бергә яңадан баягы өйгә т ү г е л , уртадагы өлкән*

*тирмәгә керделәр* (Г. Ибраһимов). *Ул (Зыя) бит мужик малае т ү - г е л – ул мәхдүм, ул шәкерт* (Г. Ибраһимов). *Кылыч белән т ү г е л, турылык һәм чынлык белән көчле кешеләр* (М. Җәлил). *Автоматы т ү г е л, аты т ү г е л, Анты белән көчле бу егет* (М. Җәлил). *Син т ү г е л, зур артистлар да репетициясез сәхнәгә чыкмыйлар* (Ф. Хөсни). *Рәхәтләнде Фатыйма: чәе дә бит карлыган яфрагы т ү г е л, чын чәй!* (И. Гази). *Сугыш булгач, сугыш инде ул, шар сугу т ү г е л* (Ф. Хөсни). *«Син т ү г е л минем сөеклем, Байтирәгем минем сөеклем, син т ү г е л минем якыным, менә кемнәр минем якыным», – дип (Солтан) бөтенебезне кочаклап ала...* (Г. Бәширов).

6. Кайбер тотрыклы сүзтезмәләрдә *түгел* кисәкчәсе билгесезлекне белдерә, ә *ни...ни* теркәгече яки *да/дә, та/тә* кисәкчәсе сүзләрне бәйләү һәм әлеге мәгънәне көчәйтү функциясен үти.

*Ләкин миндә әүвәлгесе дә юк, ахыргысы да юк. Һәрнәрсә бар, бернәрсә юк! Шуның өчен мин у л д а т ү г е л, б у д а т ү г е л! Т ә в ә д ә т ү г е л, к о ш т а т ү г е л! А т т а т ү г е л, и ш ә к т ә т ү г е л!* (Г. Исхакый). *Ләкин кыз моңа карамады, карарга җае да булмады: бу вакыт аның карынында Усман егеттән дүрт айлык баласы бар иде. Солдатка китеп барса, н и х а т ы н т ү г е л, н и к ы з т ү г е л кебек уртада калудан курыкты* (Г. Ибраһимов). *Аннары тагын косынкасы астына сыймыйча яртылаш җилкәсенә ташып чыккан чәче, к а р а д а т ү г е л, с а р ы д а т ү г е л, әллә нинди үзенә бертөрле, ялкын белән аралашып чуалган гөнҗәләне күз алдына китерә иде* (Ф. Хөсни).

7. Вакыйгалар тиз алмашынып тору очракларында «шунда ук», «ул арада» мәгънәләрендә кулланыла торган *ул да түгел* дигән штамп-клише дә әдәби әсәрләрдә шактый еш очрый.

*У л д а т ү г е л, башы болытларга барып терәлгәндәй биек булып, караңгыдан ябык ындыр үзе калкып чыкты* (Г. Бәширов). *У л д а т ү г е л, Нәфисә аның (Зиннәт) белән башын гына иеп исәнләште дә якындагы берәүгә дәште* (Г. Бәширов). *У л д а т ү г е л, кайтучылар пароходтан чыгып өскә күтәрелә башладылар* (Б. Бәширов). *У л д а т ү г е л, тиктомалга чебеш әнкәләре тәгәрәп үлде* (И. Гази). *У л д а т ү г е л, Якуп барачак өяз шәһәре дә дошман кулына эләкте* (И. Гази). *У л д а т ү г е л, ишек ачылып китте, һәм бүлмәгә ике хәрби кеше килеп керде* (И. Гази).

Исем хәбәрләр яки кайбер фигыль хәбәрләр составында килгәндә, *түгел* кисәкчәсе хәбәрлек һәм күплек кушымчалары белән кулланылырга мөмкин: *Аh! Синең газмеңдә бәхтең каршы тормый бирсә юл. «Яшь егет! күрсәт эшең, манигъ т ү г е л м е н », – дирсә ул* (Г. Тукай). *Әгәрчә дәүләтем юктыр җитәрлек, Ишәктәй һәм йөк астында т ү г е л м е н* (Дәрдемәнд). *Сүзебез бер булсын, моннан соң мин сиңа: «Рәт чыкмас бу малайдан!» – дип әйтәчәк т ү г е л м е н* (Ф. Хөсни). *Юк, син Кәбир малае т ү г е л с е ң , син Иблис-мәлгунь малаесың* (Ф. Хөсни). *(Без) шәһәр белән таныш т ү г е л б е з , урамнарны яхшы белмибез* (Ә. Еники). *Хәзер менә ничектер шәкертләр элекке кебек т ү г е л л ә р* (Г. Ибраһимов). *Урман кисәр балта сабы шулар, оят белмәс кара күңелләр... Ходай үзе биззат ясыйм дисә, Адәм була торган т ү г е л л ә р* (С. Рәмиев).

*Әй, и* ымлык кисәкчәләре дә, фигыльләр алдында кабатланып килеп, экспрессияне көчәйтүгә хезмәт итәләр: *Су анасыннан котылгачтын, тынычлангач, әни и орышты, и орышты, и орышты соң мине* (Г. Тукай). *Күрмимен алны вә артны, ә й , чабам мин, ә й чабам* (Г. Тукай). *Ә й тотына кайгыртырга, ә й кыштырдый, ә й сөйләшә башлый ана каз! Бер әкәмәт инде!* (Г. Бәширов).

*Бит, соң, ич, лабаса/ләбаса, ла/лә* кисәкчәләре сөйләмне төрле эмоциональ төсмерләргә бизиләр.

*Бит, ич* кисәкчәләре, сүз яки җөмлә азагында килеп, көчле эмоциональ раслауны белдерәләр: *«Тор шәкерт! Җиттек Казанга, алдыбызда б и т Казан!»* (Г. Тукай). *Ходаем, миңа гына түгел, сиңа да бала и ч ! Нигә әз генә дә кызгана белмисең?! Иртә-кич өзгәләнә б и т* (Г. Ибраһимов). *Бу – туган илем көе б и т , Кем шулай җырда суза?* (С. Хәким).

*Лабаса/ләбаса* һәм *ла/лә* кисәкчәләре «*бит* сүзенә караганда да көчлерәк раслауны белдерәләр» [Дмитриев Н., 1950, с. 132]: *Галимә. Соң вәгъдә билгесе итеп үзеңә чиккән яулык та бирде л ә б а с а* (М. Фәйзи). *– Оятлы була язганмын л ә б а с а ! Үзебезнең кызларыбыз икәнсез л ә б а с а !* (Г. Бәширов). *Яратам л а шундый үз иткән кешеләрне...* (А. Шамов).

*Лабаса/ләбаса, ла/лә* кисәкчәләре гаҗәпләнү, үкенү, кайгыру, әрнү, ачыну тойгыларын белдерәләр: *Кара син аны! Төзек кенә торган икән л ә б а с а !* (Г. Ибраһимов). *Икенчесе... үз җырын такмаклый: – Их,*

*товарлары л а , товарлары! – ди* (Г. Бәширов). *Бу ни хәл? Үзе дә юк! Хәбәре дә юк! Ил алдында хур булдык л ә б а с а !* (Г. Ибраһимов). *Белмисез л ә , дуслар, тоткын күңел, Күкрәктәге җәрәхәттән түгел, Канлы үчтән шулай кызара* (М. Җәлил). *Юл баткак вә лайла, Кул-аяк богауда: кыймылдап булмый л а !..* (Ш. Бабич).

*Соң* кисәкчәсе дә, җиңелчә шелтәләү, битәрләү, борчылу, кайгыру, кызгану тойгыларын белдереп, сөйләмне төрле эмоциональ төсмерләр белән бизи: *Ачуланма туры сүзем өчен, Ярыймы с о ң шулай багарга?* (С. Хәким). *Ник, Мокамай, с о ң син тормышыңны чабатаңдай матур үрмәдең!!* (Һ. Такташ). *– Бәгырем, балам, ни генә эшлим с о ң ?!* (Г. Ибраһимов).

## 12. ЫМЛЫКЛАР

Кешеләрнең хис-тойгыларын, эчке кичерешләрен һәм теләк-ихтыярын белдерә торган сүзләр ымлык дип атала.

Ымлыклар лексик һәм грамматик яктан башка сүз төркемнәреннән нык аерылалар:

1) Ымлыклар эмоцияләрне һәм ихтыярны төшенчәләр аша чагылдырмыйлар, бәлки аларның турыдан-туры тәгъбирләре булып торалар. Әйтик, соклану, гаҗәпләнү, курку, җирәнү сүзләре кешенең эмоцияләрен атап белдерсәләр, *и! әй! ах! фу!* ымлыклары саф эмоциональ сигналлар хезмәтен генә үтиләр. Димәк, ымлыклар хис-тойгы һәм ихтыярның атамалары түгелләр, ә саф субъектив сөйләм тамгалары булып кына саналалар.

«Номинатив функцияләре булмаса да, ымлыклар коллективка гомум аңлаешлы мәгънәви эчтәлеккә ияләр» [Виноградов В., 1947, с. 745], чөнки, башка сүзләр кебек, алар да билгеле бер тел коллективында гына конкрет бер мәгънә алалар.

2) Ымлыклар сирәк очракларда сүз ясагыч кушымчалар белән килсәләр дә, сүз төрләндергеч кушымчаларны кабул итмиләр; исемнәр кебек – сан, килеш, тартым белән һәм фигыльләр кебек зат, сан, заман, юнәлеш белән төрләнмиләр.

3) Ымлыклар, номинатив функция үтәмәгәнлектән, җөмлә кисәге була алмыйлар; алар я үзләре генә мөстәкыйль бер җөмлә төзиләр, я аның конструктив бер элементы сыйфатында кулланылалар. Мәсәлән: *Тфу! Күзге җилләр тиде теңкәгә* (Һ. Такташ). *Аһ, үләм бит, бу бәладән кем килеп йолкыр мине?* (Г. Тукай). *Аптырый, ботка суга, ах, дип куя, «Ах, юләр мин, ах, мин ахмак!» – дип куя* (Г. Тукай).

4) Ымлыклар экспрессив-эмоциональ төсмерләргә бай булалар, махсус интонация һәм кул-йөз хәрәкәтләре катнашлыгында әйтеләләр. «Ымлыкларның структурасында экспрессив-мәгънәви, фонетик һәм

интонацион-мелодик элементлар хакимлек итү, – ди В. Виноградов, – алар белән башка типтагы сүзләр арасына кискен чик сала» [Виноградов В., 1947, с. 745].

Төзелешләре белән ымлыклар төп һәм ясалма булалар.

Төп ымлыклар ирексез кычкырудан, рефлектор аваз һәм тавышлардан килеп чыкканнар. Алар «нинди дә булса мөстәкыйль сүз төркеме белән бәйләнмәгән һәм эчке яктан кисәкләргә бүленми торган һәм грамматик формалашмаган эмоциональ һәм ихтыярый эчтәлекле тамгалар булып торалар» [Грамматика русского..., 1953, с. 675].

Төп ымлыклар ясалышы буенча өч типта булалар:

1) Ялгызак ымлыклар*: а, ә, э, о, у, йә, йа, ай, әй, уй, ой, ах, аһ, их, эх, ох, уф, на, мә, ну, һа, һә, һе, һу, һи, фу, фи, һм, чу, мм, тсс, ссс, шш, бәй, иһи, әһә, оһо, уһу, һай, һәй, һәйт, аба, абау, әбәү* һ.б.

2) куш ымлыклар: *а-а, ә-ә, и-и, о-о, у-у, э-э, ай-ай, уй-уй, уф-уф, һәй-һәй, һай-һай, һәйт-һәйт, чү-чү, на-на, көш-көш, пес-пес, бах-бах* һ.б.

3) парлы ымлыклар: *ай-яй, ай-вай, ай-һай, аһ-һай, ах-ух, бәллү-бәү* һ.б.

Башлангыч мәгънәләрен югалтып, хис-тойгы һәм ихтыярны белдерә башлаган сүзләр, фразеологик тезмәләр һәм идиомалар ясалма ымлыклар дип атала. Мәсәлән: *тамаша! пәрәмәч! пычагым! каравыл! менәтерәк! баш өсте! кит аннан! менә сиңа мә! кара аны! муены астына килсен! йөзе кара булсын!*

Кайбер ымлыклар мифик көчләргә мөрәҗәгать итү, инану һәм сыенуны белдерә торган дини сүзләрдән ясалганнар. Мәсәлән: *ай алла! я ходай! әй раббым! ходаем, ярлыкагыл! шайтан алгыры!* һ.б.

Ымлыклар арасында башка телләрдән алынмалар да очрый. Мәсәлән: *о, ну, ой, ша* (русчадан); *афәрин, билләһи, валлаһи, бәрәкалла, машалла, иншa алла, шөкер* (гарәп һәм фарсычадан); *алло, бис, марш* (< французча *allons, bis, marche*), *браво* (< итальянча *bravo*), *ура* (< монголча *ороя*) һ.б.

Ымлыклар мәгънәләре буенча ике зур төркемгә бүленәләр: 1) эмоциональ ымлыклар, 2) императив ымлыклар.

Эмоциональ ымлыклар сөйләүченең хис-тойгыларын һәм кичерешләрен, башка бер кешенең сөйләменә һәм эш-хәрәкәтенә карата эмоциональ мөнәсәбәтен белдерәләр.

Эмоциональ ымлыклар җиде төркемчәгә бүленәләр:

1) күңел күтәренкелеге, шатлану, куану, сөенү, гаҗәпләнү, соклану, ис китү, шаккату, таң калу, көчле теләк, канәгатьләнү хисләрен белдерә торган ымлыклар: *и, о, у, ай, әй, ой, их, эх, ух, ну, һу, һуу, оһо, иһи, иһһи, бәй, аба, әһә, уһу, ура, абау, әбәү, и-и, о-о, ай-й, ай-ай, ай-яй, ай-ли, әй-й, һа-ай, ай-һай, их-ма, ихи-хи, менәтерәк, әттә генәсе, бәлеш, пәрәмәч, кара аны, кит аннан* һ.б. Мисаллар: *И х ! Кичә генә әле февраль иде, Бүген давыл кырга кар ташый, Март аенын нечкә билле җиле, Сузылып ятып җиргә кар ашый* (Һ. Такташ). *Бaрактан чыккач: – И һ и , – диде Гариф.– Менә кайда дөнья*! (Ш. Камал). *Бу минутта аның йөрәге чиксез шатлык белән тулды, һәм ул шул шатлыктан кычкырып җибәрде: – У р р а* ! (Ш. Камал). *Ә й , халык шат! Һәммәсе уйный, көлә, Каршыдан балкып Кызыл байрак килә* (М. Гафури). *Кайгысы юк ул песинең тик һаман уйнау уе; Бик шаян! А й - һ а й  наян! Уйнарга хәзер көн буе* (Г. Тукай). *Зөбәйдәнең сеңле уйнап йөри, А б а у , матур! Күзем тимәсен*... (Һ. Такташ). *У*... *Шәвәли бабай, үзеңне көрт басып бетергән бит! Чак таптым* (Г. Ибраһимов). *Тормышым, у х , нинди ямьле, Нәкъ чәчәк, Көн-төнемдә төрле ямьнәр сирпәгәч* (Ш. Фидаи). *Б ә л е ш ! Бу ниткән эш тагын* (Ф. Әмирхан). *Егетләр, берсен-берсе бүлдереп, сокланырга, телләренә салынырга тотындылар: – С ө б х а н а л л а , м а ш а л л а , күз тимәсен башала!* (Г. Бәширов). *Сәхипҗамал шаккатып авызын ачты. – Ә н е к ә й г е н ә м ! Карале син боларны! – дип башын чайкарга тотынды* (Г. Бәширов). *Телләрен чартлаткан, исләре киткән тавышлар ишетелде. – К и т  а н н а н ! Шул тиклеме?! Икегез генәме?* (Г. Бәширов);

2) ару-талу, сызлану, әрнү, газаплану, кайгыру, хәсрәтләнү, сагышлану, эч пошу, борчылу, үкенү хисләрен белдерә торган ымлыклар: *и, ай, әй, аһ, ах, их, уф, уй-й, уф алла, һай, һәй, ай-яй, ай алла, әй ходай, и-и ходаем* һ.б. Мисаллар: *И ,  и генә лә, и генә, ни булды миңа, ни генә, Эшем дә юк ла көй генә, никадәр язамын хатлар* (Г. Кандалый). *Николай аны ычкындыргачтын, ул йөдәп алҗыган хәлдә: – У х , тәмам хәлдән тайдырды, хәерсез* (Ш. Камал). – *У ф  а л л а ! Билем, аркам, – дип сыкранганы ишетелә торган булды* (Г. Ибраһимов). *А һ , үләм бит, бу бәладән кем килеп йолкыр мине?* (Г. Тукай). *А х , минем сайрар җирем урман иде, Анда һәртөрле кызык тулган иде* (Г. Тукай). *Бер заман ачсам күзем, бер төрле яп-ят кыр күрәм. А һ ,  бу нинди*

*аерылу Гомремдә бер тапкыр күрәм* (Г. Тукай). *Һ ә й , гомерләр... үтте китте. Кая китте ул заман!* (З. Рәмиев). *Озын шәкерт, кулын ычкындырып, ачы тавыш белән чинап җибәрде: – У й - й ! Бармагымны өзә язды тешләп* (К. Нәҗми). *У ф , бүгенге кебек, гомеремдә дә арыганым юк иде, башларым әйләнеп бетте, бер тамчы хәлем калмады* (Ф. Бурнаш). *Әсәрләнеп тыңлый-тыңлый да бабайлар: – Һ а й ! – дип таягын тукылдатып куя.– Бар иде бит асыл чаклар, арысландай гайрәтле, аттан таза ир чаклар, һ а й , дөнья!* (Г. Бәширов);

3) курку, кот очу, шүрләү, шомлану, шикләнү, шөбһәләнүне белдерә торган ымлыклар*: ах, аһ, ух, уф, ай, әй, һәй, абау, ай-һай, харап, и ходаем, ходаем, ярлыкагыл* һ.б. Мисаллар: *А һ , бәла! Безне казый күргән, имеш! Уйнаганны ул карап торган, имеш.* (Г. Тукай). *Аждаһа!.. У х ... нинди коточкыч нәрсә!* (Г. Ибраһимов). *А х , аяклар да калтырый!.. Хәзер көзән җыера башлый ахры... А х ! Җитеп кенә булса ярар иде* (Ш. Камал). *Әни, каушавыннан хәле бетеп, сәкегә ауды. – У ф , йөрәгем! Аллаң гына орган хайван икәнсез! Т ф ү ! Т ф ү !..* (Г. Бәширов). *Вәдига. Качкан?! Ә й , илаһым, алты балам белән шулай ук суда гарык булырмынмы икәнни*!.. (К. Тинчурин);

4) ярсу, ачулану, тиргәү, шелтәләү, битәрләү, каргау, рәнҗү, зарлану, сукрануны белдерә торган ымлыклар: *у-у, ах, эх, һа-һә, һе, һы, ай, ах, ух, абай, ай-яй, ай-һай, пычагым кергере, кара аны каһәр төшкере, ләгънәт төшкере, бәддога суксын, каһәр суксын, каһәр суккыры, йөзе кара булсын* һ.б. Мисаллар: *Ф у ... к а һ ә р т ө ш с е н , саран байның рәтле сбруе буламы соң аның* (Г. Ибраһимов). *А х , юләр маэмай! Тырыш яшьләй, зурайгач җайсыз ул; Картаеп каткач буыннар, эш белү уңайсыз ул* (Г. Тукай). *К а һ ә р с у к к ы р ы , елы тулы килде. Дәһшәтле, буталыш ел* (Э. Касыймов). *Ул шундук җиңнәрен сызганып, калын тавышы белән гадәтенчә үкереп куйды: – Һ е , килеп кенә карасыннар! Муеннарын борып, ыргытмасам, Гайнулла булып йөрмим дә!..* (Г. Бәширов). *Һилал. У х , Акбирдин картлар сүзен тыңламадың...* (К. Тинчурин). *Заһирә. Казак, собака, дурак!* (йодрыгын селкеп). *У - у - у - ! . .* (К. Тинчурин). *Рауза гаепләнгән балага шелтә биргән ана тавышы белән: – Э х син, халыкка хезмәт итү хакына көрәшкә яшь тормышны корбан кылырга әзер булган егет!* (Ш. Усманов);

5) ис китмәү, санга сукмау, күрә алмау, нәфрәтләнү, җирәнү, чиркану, кимсетү, мыскыл итү, мәсхәрәләү, сарказм, иронияне белдерә

торган ымлыклар: *э, ә, эх, һа, һә, һәй, әй, фи, фу, тфү, иһи, ай-һай.* Мисаллар: *Бервакыт Гали югары караган көе: Т ф ү ! – дип төкереп җибәрде* (Ш. Камал). – *Ә й , тавык баш! Шуны да белмисеңме?* (Г. Ибраһимов). *Туташ кинәт кашын җыерды, эченнән бераз чирканып: – «Ф и , балалык!» дип әйтеп куя язды* (Г. Ибраһимов). *Хатын иренә бетеп карады. Яңа күргән кебек кычкырып җибәрде: – Ф у - у ! Әллә моржага кереп чыктыңмы?* (Г. Ибраһимов). *Һ и , моңарчы уен гына булган, менә кайчан икән әле аның тамашасы!* (Г. Бәширов). *Һилал. Һ ә ? ... Йомыш төшкәч, үзәнмени? А й - һ а й ! . . Остарып киттегез, егетләр* (К. Тинчурин). *Хәсән маңгаена төшкән чәчләре арасыннан күзләрен тутырып аңа карады: – Э х , шпунтик! Шул башы белән мылтык тотып тора бит* (Ш. Усманов);

6) уйлану, икеләнү, чамалау, искә төшерү, ышану, раслау, хуплауны белдерә торган ымлыклар: *ә, әй, ай-һай, м-мм, ым- м-м, ә-ә, валлаһи, билләһи* һ.б. Мисаллар: *Землемер, моның күзенә караган көенчә: – Ә - ә - ә ... шулаймыни! – диде* (Ш. Камал). *Ә һ ә , су капканнар икән...* (Ш. Маннур). *Шуңа күрә теге малай балык дигән сүзне, авызына алу белән: – Ну таптың, малай! Китәбез, в а л л а һ и , китәбез! – дип кычкырып җибәрдем* (Г. Ибраһимов). *Бала-чаганың барысының да берьюлы диярлек исенә төште: – Ә - ә - ә ! – дип суздылар. – Юк, онытмадык!* (Г. Бәширов). – *М - м м . Белергә кирәк иде Бәшир* (Г. Бәширов). *Ул аның җиңеннән тартып бик борчылган кыяфәттә кибеттәге ыгы-зыгыны күрсәтте: – Гыймай энем! А й - һ а й , дөрес булырмы икән бу?* (Г. Бәширов). *Әти нидер төшенә башлаган сыман: – Ә - ә - ә ... дип сузды* (Г. Бәширов);

7) исәнләшү, саубуллашу, хушлашу, гафу үтенү һәм рәхмәтне белдерә торган ымлыклар: *нихәл, исәнме, исәнмесез, саумы, хуш, исән бул, сау бул, сау булыгыз, хәерле кич, рәхим ит(егез), рәхмәт* һ.б. Мисаллар: *С а у б у л инде, х у ш , б ә х и л б у л , и минем туган җирем; минем болай, шулай итәм, дип төрле уй корган җирем* (Г. Тукай). *Шуннан соң кардәшчә бер тавыш ишетелде: – Әссәламәгаләйкем, н и х ә л ? И с ә н м е , балам?..* (Г. Ибраһимов). *«Р ә х м ә т , балам, р ә х м ә т , күз нурым, бәгырем... тырышкансың» дигән сүзләре дә колагымда тора кеби тоям* (Г. Ибраһимов). *Гаҗи. Ә с с ә л а м е л - г а л ә й к е м ! Җәләл. В ә г а л ә й к е м ә с с ә л а м , Хаҗи әфәнде, әйдә, х у ш к и л ә с е з !* (Ш. Камал).

Эмоциональ ымлыклар (*и, их, ух, әй, ай, әбәү, абау* һ.б.), гадәттә, күп мәгънәле булалар. *Их* ымлыгы, мәсәлән, соклану, гаҗәпләнү, күңел күтәренкелеге, көчле теләк, битәрләү, шелтәләү, кызгану мәгънәләрен белдерә ала: *И х , гаҗәп могҗизаларың бар синең революция!* (Г. Ибраһимов) – гаҗәпләнү. *...Тирәкләрдә кычкыра кәккүк; Кәккүк... И х , матур, матур шул чак, Шул чак!* (Ш. Маннур) – соклану. *И х , Авыл кырын тутырып бодай үсә. Дулкынлатып аны җил исә* (Һ. Такташ) – күңел күтәренкелеге. *И х , астына граната җибәрергә – диде* берсе (Г. Бәширов) – көчле теләк. *И х , бабай, – диде, – кем арбасына утырсаң, шуның җырын җырлап гомерең үтәр ахрысы* (Г. Ибраһимов) – битәрләү, шелтәләү. *Кыз түзмәде: – И х , әбкәем, бер дә рәтең калмаган синең хәзер..., – диде* (Г. Ибраһимов) – кызгану.

*Ай* һәм *әй* ымлыклары соклану, шатлану, якын күрү, үз итү, кызгану, борчылу, ачыну, санга сукмау, ис китмәүне белдерәләр: *Эчтән уйлыйм: Ә й , матурсың! Ә й , сылу!..* (М. Гафури) – соклану. – *А й , балам... Бу җирләрдә ризыкларың бетмәгән икән әле... – диде дә кочаклап катты* (Г. Ибраһимов) – шатлану. *Кыз бик борчыулы тавыш белән җавап кайтарды: А й , әйтә күрмәгез! Миңа ни булса – шул! Анакай ишетсә, үләр инде! – диде* (Г. Ибраһимов) – борчылу, ачыну. *Ә й әни, бер көн рәхәт күрми үлеп киткән әни...* (З. Ярмәки) – кызгану һ.б.

Императив ымлыклар кешенең теләк-ихтыярын белдерәләр һәм ике төркемчәгә бүленәләр:

1) эндәшү, мөрәҗәгать итүне белдерә торган ымлыклар: *и, я, ау, әү, әй, һәй, һәйт* һ.б. Мисаллар: *Шәйхи. Я , егетләр, юл кешесенең юлда булганы яхшы, әзерләнегез!* (К. Тинчурин). *И кояш! Тизрәк җылыт җирне, терелдер дөньяны* (З. Ярмәки). *Ә й , син, илне җырларың белән юаткан яшь егет. Ә й , матурларны оялтучы батыр, уйнап, көлеп!* (Ә. Сәгыйди). *Аерылып китсәм дә синнән, гомеремнең таңында мин, И Казан арты! Сиңа кайттым сөеп тагын да мин* (Г. Тукай);

2) әмер, боеру, чакыру, әйдәү, таләп итү, тыю, кисәтүне белдерә торган ымлыклар: *чү, тс, тсс, ссс, ш-ш, ыс-с, әйдә, әйдүк* һ.б. Мисаллар: *Тукта, ч ү ! Ямьсез тавышлы әллә нәрсә кычкыра* (Г. Тукай). – *С - с - с ! Бик каты шаулама* (К. Нәҗми). *Бергәләп* (шыпырт тавыш белән). *С - с - с - с ! . .* (Картлар). *Ш - ш - ш - ш ! . . Менә шунда та-*

*вышсыз гына утырып сөйләшик* (К. Тинчурин). *Ә й д ә , иптәш, ул тавышка тот та кулга мылтыгың, Суз аңар ярдәм кулың – коткар шәрыкның юксылын!* (Х. Утюшев). *Ә й д ү к , кояш иптәш! Бергә-бергә бәйрәм итәрбез* (Х.Туфан). *Ч ү , ы с с , җилме, Кем ышкына мышнап ишеккә* (Х.Туфан).

Императив ымлыкларга шулай ук хайваннарны, кош-кортларны чакыру һәм куу сүзләре дә кертеләләр. Мәсәлән: *на, на-на, баһ-баһ, тпру, һай, һайт, тәч-тәч, бәрәч-бәрәч, чәбә, маһ-маһ, пес-пес, көш-көш* һ.б. Мисаллар: *Бу тавыш бик ачты күңелем, шатлыгымнан җан яна: Әйдә, чап, күчер, Казанга Атларны ку: н а - н а - н а !* (Г. Тукай). *Һ а й т , буразна. Ә й д ә , бахбай, тарт сабанны н а - н а - н а* (К. Әмири). *Әле уңда, әле сулда бары сабан ашлыгы чәчкәндә генә әйтелә торган үзенә бертөрле ат куу, ачулану, орышу, сызгыру тавышлары ишетелеп тора: – Әйдә, малкай! Н а - н а - н а ! – Карасана, һ ә й т ! – Ф и т , ф и т , наян, атлабрак* (Г. Бәширов). *Кайдадыр ишек ачылды һәм сукранып кычкырган карчык тавышы ишетелде: – Ч ә б ә ! Т с - с с ... Ч ә б ә , дип әйтәм түгелме мин сезгә...* (К. Нәҗми). *Кулларына ипи тотып чыккан җиңгиләрнең сарыкларын дәшеп көйләүләре ишетелә, башлады: – Б ә р ә ч , б ә р ә ч , б ә р ә ч ! – Т ә ч - т ә ч - т ә ч ! Б ә т и , б ә т и , б ә т и , б ә т и !* (Г. Бәширов).

# 13. ИЯРТЕМНӘР

Кеше һәм башка җан ияләре чыгарган авазларга, шулай ук төрле предметлар һәм табигать күренешләренең тавышларына охшатып ясалган сүзләр ияртем дип атала. Ияртемнәр күбрәк аваз ияртемнәреннән торалар.

Аваз ияртемнәре телебезнең сүзлек составында бай һәм гаять үзенчәлекле лексик бер катламны тәшкил итәләр. Алар үзләренең мәгънәләре һәм функцияләре белән башка сүз төркемнәреннән, шул ук вакытта ымлыклардан да, кискен аерылалар. Дөрес, ымлыклар белән аваз ияртемнәре арасында кайбер уртак яклар бар: тегеләре дә, болары да номинатив функциягә ия түгелләр; ымлыклар хис-тойгыларны, ә аваз ияртемнәре тавыш һәм яктылык күренешләрен атап күрсәтмиләр, бәлки аларны «турыдан-туры һәм иң кыска рәвештә белдерәләр» [Тумашева Д., 1950, б. 280–281]. «Ымлыклар һәм мимемаларның[1] уртак билгесе шул; алар эмоцияләрне, тавыш һәм хәрәкәт образларын атап белдермиләр, ә аларның турыдан-туры тәгъбирләре булып торалар» [Баскаков Н., 1952, с. 235]. Ләкин бу ике сүз төркеме атау функциясенә ия булмаулары белән генә бер-берсенә охшыйлар, ә семантик, фонетик һәм грамматик яктан алар арасында аерма зур: әгәр ымлыклар кешенең хис-тойгысын һәм ихтыярын белдерә торган эмоциональ сигналлар хезмәтен үтәсәләр, аваз ияртемнәре тавыш күренешләренең образлы чагылышлары булып торалар, аларны турыдан-туры үз авазларының яңгырашы аша чагылдыралар. Мәсәлән, *Тау астында салкын чишмә ч ы л т ы р - ч ы л т ы р агадыр* яки *Ч у т - ч у т итеп тирәкләрдә сандугач сайрый* дигән шигъри юлларда чишмә чылтыравы һәм сандугач сайравы турыдан-туры шул тавышларга охшаган сөйләм авазлары белән тасвирланганнар.

Яктылык һәм хәрәкәт күренешләре, шулай ук предметларның формасы һәм торышы да, эчке бер ассоциация нигезендә «нинди дә

[1] Мимема (< грекча *mimema* «иярү, охшау») – «аваз ияртеме».

булса үзенчәлекле бер тавышка охшатылып» [Хәзерге татар теле, 1965, б. 279], аваз ияртемнәре белән тасвирланырга мөмкин. Мәсәлән, *Җем-җем итә чыклар таңда, бизәп мул кырны* (М. Хөсәен) яки *Фыр-фыр* итеп торган чәчкәйләрең битләремә тиеп сөярләр (М. Укмаси).

Мотивлаштырылган тамгалар хезмәтен үтәү, ягъни аларның яңгырашы белән мәгънәсе арасында турыдан-туры бәйләнеш булу аркасында, аваз ияртемнәре, гадәттә, югары экспрессия белән сугарылган булалар; алар чынбарлык күренешләрен җанлы картиналарда, гаять конкрет һәм образлы итеп сурәтлиләр.

Аваз ияртемнәре тавыш һәм яктылык күренешләрен тасвирлап кына да калмыйлар, бәлки әйберләрнең тышкы кыяфәтен, хәрәкәтен, торышын да күзалларга ярдәм итәләр, аларның предметлы образын тудырып, җанлы итеп безнең күз алдына китереп бастыралар. Мәсәлән, Г. Тукай «Габделхәмит» шигырендә *гөмберррт* сүзе ярдәмендә кеше тирән базга егылып төшкәндә чыккан тавышны да, аның кинәттән төшеп китүен дә сурәтләп бирә: *Утыз ел казыган баз бик тирән шул: Менә инде Хәмитең шунда гөмберррт!*

Семантик яктан аваз ияртемнәре ике зур төркемгә бүленәләр: 1) тавыш тасвирлары; 2) образ тасвирлары.

Тавыш тасвирлары үзләре биш төркемгә аерылалар:

1) кешенең сөйләү әгъзаларында барлыкка килгән тавышларның тасвирлары: *ай-й-й-й, у-у...у-у, ии..и-и, бәү-бәү, үә-үә...үә-үә... үә-үә, мышык-мышык, пышык-пышык* (елау); *пыш-пыш, чыш-пыш, пышы-пышы* (пышылдап сөйләшү); *кых-кых. кхи-кыйх-кыйх, кәх-кәх, кәһ-кәһ* (йөткерү); *ыһым-ыһым, һемм, эһ-м-м-м* (тамак кыру); *чыр... чыр...чыр, чырый-чырый, чырык-чырык* (хатын кыз яки кыз балалар тавышы); *бытыр-бытыр, тә-тә-тә* (күп сөйләшү); *меңгер-меңгер, мегер-мегер, мыгыр-мыгыр* (аңлаешсыз итеп, авыз эченнән сөйләү, мыгырдау); *фиийт, фүйть!* (сызгыру); *лач-лоч,чапыл-чопыл* (әйбер чәйнәү); *голт-голт* (сыек нәрсә йоту); *чырт* (теш арасыннан төкерү); *гөж-гөж, гөр-гөр* (күп кешенең берьюлы сөйләшүе); *гыж-гыж* (ютәл авырулы кешенең сулавы); *мыш-мыш* (ашыгып килгән кешенең сулавы); *уфф-ф* (авыр итеп тын алу); *ың-ың-ың, өһ-өһ* (ыңгырашу); *тфү-тфү* (төкеренү); *гыр-гыр, мыр-мыр* (йоклаганда бугаздан чыккан тавыш) һ.б.;

2) кеше хәрәкәте тудырган тавышларның тасвирлары: *дөп-дөп, лап-лап, лап-лоп* (авыр гәүдәле кешенең аяк тавышы); *лачтыр-лочтыр, чыптырт-чыптырт, чыптыр-чыптыр* (пычрак ерып атлау); *тык-тык, тук-тук* (ишеккә яки стенага бәрү); *чалт-чалт* (кул белән яңакка сугу); *шап-шап, шоп* (кул белән йомшак нәрсәгә сугу); *шалт-шолт, шак-шок* (таяк белән каты әйбергә сугу); *чаж-чож* (каеш яки чыбык белән йомшак нәрсәгә сугу); *чык-чык, чак-чок* (чакма ташка металл белән сугу); *тыпыр-тыпыр* (биючеләрнең аяк тавышы); *кыштыр-кыштыр* (акрын гына кием киенү тавышы), *лык* (каты нәрсәгә сугу, егылу); *лып* (нәрсәдер өстенә кинәттән утыру яки авып төшү, аву); *доңк-доңк* (йодрык белән аркага сугу); *дөбер-шатыр, шатыр-шотыр, шалтыр-шолтыр* (авыр әйберләрне кузгату, арлы-бирле күчерү); *тәп-тәп* (кечкенә баланың тәпи йөрүе), *дөбер-дөбер* (ишек кагу), *колт-колт* (баланың имчәк имүе), *гөрс-гөрс* (домино белән өстәлгә сугу), *чыжт-чыжт* (пычак кайрау) һ.б.;

3) йорт хайваннары, ерткыч җәнлекләр, кош-корт, бөҗәк тавышларының тасвирлары: *иһи-иһи, и-и-иһа-аһай* (ат кешнәве); *э-э-э-э... мә-ә-ә-ә-мә-ә-ә* (сарык кычкыруы); *бә-ә* (сарык бәрәне бәелдәве), *микикики* (кәҗә тавышы); *вау-вау.., һау-һау-вау* (эт өрүе), *ләң-ләң* (көчекләр өрүе), *һам* (этнең тешләп алуы), *мыр-мыр* (мәче мыраулавы), *мырау-мырау, мияу* (мәче тавышы); *у-у-у-у-у* (бүре улавы); *лап-лап* (казларның аяк тавышы), *га-га-га* (ата каз тавышы), *ге-ге-ге* (ана каз тавышы), *кыйгак-кыйгак* (казлар кычкыруы); *ки-кри-күк, кикрикүк... кикрикүк* (әтәч кычкыруы); *шалт-шолт* (әтәч аягы тавышы), *прх-прх* (әтәчнең берәр җиргә очып кунуы), *ко-ко-ко* (әтәч җим эзләп йөргәндә чыгарган тавыш); *пи-пи-пи, пи-биби-бип, чип-чип, чып-чып* (чебиләр тавышы); *гөлдер-гөлдер, гөр-гөр* (күгәрченнәр гөрләве); *торыйк-торыйк* (торналар кычкыруы), *һаң* (торна тавышы), *күк-кү, кәккүк...кәккүк, кук-кук, кук-ку, ку-ку* (кәккүк тавышы); *чүт-чүт-чүт, чут-чут* (сандугач сайравы); *коңгыйк-коңгыйк* (козгын тавышы); *кар-кар, карр-карр-карррр-кар-р-р* (карга кычкыруы); *чөкерт тә мөкерт, фиют дә миют* (кошлар сайравы); *быз-быз, зәңң, зиң-зиң, зың-зың* (бал корты тавышы); *чыр-чыррр, тыррр* (сыерчык балаларының чыелдавы); *ба-ба-какка... ба-ка- ка, ка-ка-ка-ка* (бака кычкыруы); *лап-лоп* (арысланның аяк тавышы); *тар-тар* (тартар тавышы); *каң-каң* (киек казлар тавышы); *леп-леп* (күбәләкләр

очуы); *кетер-кетер* (куянның кишер кимерүе); *чепер-чепер* (песинең сөт эчүе) һ.б.;

4) машиналар, механизмнар, эш, уен һәм сугыш кораллары тавышларының тасвирлары: *тыр-тыр...тр...тр-р, зыр-р-р- ...зыр-р-р, трек-трек...тррр...тек...тек* (трактор тавышы); *эт-ч-туф...эт-ч-туф, чаж-чож...чаж-чож* (паровоз тавышы)*; лакыш-локыш...лакыш-локыш, чакылт-чокылт... чакылт-чокылт* (поезд тәгәрмәчләре тавышы); *ток...тек...тыр-тыр...тыр...тыр, тратт...та...та...та... та, тррр...тек...тек, та-та-та-та-та, траттата...та* (пулеметтан аткан тавыш); *гу-у-у-у-у* (пароход гудогы тавышы); *гу-гу-гу* (фабрика гудогы тавышы); *чакы-чокы-чак* (чүкеч белән сандалда чалгы тапау); *тук-тук, тык-тук* (агач чүкеч белән кисмәккә сугу), *келт-келт* (стена сәгате йөрүе); *зиң-зиң* (сәгать сугуы); *гөп-гөп* (движок тавышы), *тек-тек* (тегү машинасы тавышы); *а-х...у-х* (тимерче күреге тавышы); *даң-даң, даң-даң-даң, даңң, доң-доң...даң...доң, даңгыр-доңгыр* (чиркәү чаңнарының тавышы); т*или-тен... тилли-тилли-тен-н, дин-дин-дин* (кыңгырау тавышы); *келдер...келдер* (шөлдер тавышы); *тратта... тата...та...та* (быргы тавышы); *тык-тык* (металл әйбернең идәнгә бәрелүе), *чеңгел-чеңгел* (трамвай звоногы тавышы) һ.б.;

5) табигать тавышларының тасвирлары*: у-у-у, ф-ю-ю-ю, ыж-ж, выж, выж-ж* (җил сызгыруы); *гөр-р, дөбер-шатыр* (күк күкрәү), *шабыр-шобыр, шыбыр-шыбыр* (яңгыр тамчылары тавышы); *чылтыр-чылтыр, челтер-челтер* (чишмә тавышы)*; чеп-че-п...чеп-чеп* (дулкын тавышы); *шыгыр-шыгыр* (агач кәүсәләре яки кар шыгырдавы), *чебер-чебер* (су агу); *дөп-дөп, тып-тып, шып-шып, тач-точ, чулт-чулт, чалт-чолт, зың-зың, пелт-пелт* (тамчы тавышы); *шатыр-шотыр* (боз китү); *былт-былт* (суга әйбер төшү) һ.б.

Югарыда әйтелгәнчә, аваз ияртемнәренең икенче зур семантик төркемен образ тасвирлары тәшкил итә. Образ тасвирлары шулай ук охшату принцибы буенча, ләкин акустик күренешләр өлкәсеннән кешенең хисси реакцияләре (күреп сиземләү, соматик реакция) өлкәсенә күчерелгән охшату принцибы буенча ясалалар [Харитонов Л., 1954, с. 154]. Шул рәвешчә, образ тасвирлары ишетеп түгел, ә күреп яки тоеп сиземләнә торган күренешләрне белдерәләр; алар яктылык күренешләре, шулай ук җан ияләренең эчке халәте һәм хәрәкәтләре, төрле әйберләрнең тышкы күренешләре турындагы хисси күзаллауларны

тәгъбир итәләр. Мәсәлән, *җем-җем* сүзе яктылык күренешен (йолдызлар балкуын, учак күмерләренең җемелдәвен яки чәчләрнең ялтыравын), *тыз-быз* – кешенең хәрәкәт итү рәвешен, ә *чымыр-чымыр* – эчке сиземләүне образлы итеп тасвирлый. Мисаллар: *Таңга кадәр тәрәзәм каршында җ е м - җ е м итеп йолдыз балкыды* (Г. Латыйп). *Таң нурында чәчләре җ е м - җ е м итә* (И. Юзиев). *Яучылар... т ы з д а б ы з йөреп торалар* (Г. Гобәй). *Бөтен тәнем, беләкләрем, муеннарым ч ы м ы р - ч ы м ы р килә* (М. Әмир).

Шулай итеп, образ тасвирлары яктылык күренешләрен, төрле хәрәкәтләрне, предметларның тышкы күренешен, шулай ук эчке кичерешләрне һәм сиземләүләрне образлы итеп чагылдыралар, алар бернинди тавыш чыгармый торган күренешләрнең эчке ассоциация нигезендә нинди дә булса үзенчәлекле бер тавышка охшатып ясалган сүз-образлары булып торалар. Образ тасвирлары дүрт семантик төркемгә бүленәләр:

1) яктылык һәм төс тасвирлары: *гөлт* (лампа утының, ялкынның кабынып яки ай һәм ут яктысының ялтырап китүе), *келт* (электр утының кабынып китүе), *ялт-ялт-ялт* (яшеннең көчле итеп ялтырап китүе), *ялт-йолт* (яшеннең, күн итекләрнең, металл әйберләрнең ялтыравы), *елт-елт-елт* (күзләрнең яки шахтер лампасының уты елтыравы), *елк-елк* (чәчнең яки ефәкнең елкылдавы), *җем-җем* (йолдызлар яки кар балкуы, сүнми калган учак күмерләренең, еpoints ерактагы шәһәр утларының яки вак дулкыннарның кояш нурында җемелдәве, чәчләрнең ялтыравы), *ялтыр-йолтыр* (юеш җирдә яңгыр тамчыларының ялтыравы), *ялык-йолык* (кылыч ялтыравы), *елтыр-елтыр* (су өстендәге май тәңкәләренең елтыравы), *елык-елык* (атласның елкылдавы), *җылтыр-җылтыр* (йолдызлар балкуы), *әлҗе-мөлҗе* (тирә-яктагы күренешләрдән күзләрнең камашуы һ.б.;

2) хәрәкәт тасвирлары: *тыр-тыр, тырт-мырт* яки *терт-терт* (хатын-кызның кабалана-кабалана йөгереп баруы); *тыз-быз* (ашыга-ашыга ике арада йөреп тору); *җил-җил* яки *җәлт-җәлт* (ашыгып, бик тиз атлап бару); *кәз-кәз* яки *фырт-фырт* (көяз хатын-кызның атлап баруы); *кылгый-кылгый* (теләр-теләмәс, акрын гына атлап бару); *теп-теп* (кечкенә баланың атлап баруы); *лырт-лырт, тырык-тырык* (атның сикертеп чабуы); *шалт* яки *капылт, ялт* (тиз генә берәр эшне эшләп ташлау); *ялт-йолт* (як-якка карангалап алу яки машиналарның

узып торуы); *ялт-ялт* (тиз генә берәр нәрсәне боргалау); *кырт* (сүзнең яки музыканың кинәт туктап калуы, өзелүе); *кылт* (берәр нәрсәнең кинәт искә төшүе); *чыт-чыт, чет-чет* яки *челт-челт* (күзләрне тиз генә йомып-йомып алу); *шып* (шау-шудан яки сөйләүдән кинәт туктап калу); *мыж-мыж* (мыжылдау, кайнашу); *дер* яки *дер-дер* (берәр җисемнең бик каты селкенүе); *пыран-заран* (берәр нәрсәне җимереп, ватып ташлау, юкка чыгару); *мелт-мелт* (иреннәр кыймылдау, саламга капкан ут ялкыннарының кабынып-кабынып китүе) һ.б.;

3) кыяфәт һәм характер тасвирлары: *фыр-фыр* (чәчнең бөтеркәләнеп торуы); *фырт* (көяз, бизәнгән кеше турында); *тырт* яки *тырт-мырт* (үз сүзле, тиз үпкәли торган кеше турында) һ.б.

4) эчке сиземләүләрнең һәм соматик реакцияләрнең тасвирлары: *чымыр-чымыр* (гәүдәнең яки берәр әгъзаның җиңелчә туңып китүе, чымырдавы); *дер* яки *дер-дер* (туңудан яки куркудан гәүдәнең яки берәр әгъзаның калтыравы); *пылт-пылт* (нәрсәләрнең дә булса су астыннан бер-бер артлы калкып чыгуы, калтыравы); *дөрт-дөрт, тук-тук, дөп-дөп* (куркудан йөрәкнең ашкынып тибүе); *леп-леп* яки *пыт-пыт* (көчле дулкынланудан йөрәкнең каты итеп тибүе); *сулк-сулк* яки *сулык-сулык* (йөрәкнең сулкылдавы) һ.б.

Морфологик яктан аваз ияртемнәре 5 типка бүленәләр:

1) ялгызак аваз ияртемнәре: *бам, без, булт, вау, выж, выжт, гөж, гөжт, гөлт, даң, дер, дөп, дөңк, ялт, кар, лык, лып, прх, тфү, тып, чалт, чулт, чырк, чырт, шап, шарт, шыр, ыр, өф, җең, һам, һап, һем, һоп* һ.б.

Китерелгән мисалларның барысы да бер иҗекле ялгызак аваз ияртемнәренә карыйлар. Болардан тыш, сирәк булса да, ике һәм өч иҗекле ялгызак аваз ияртемнәре дә очрый: *апчхи, гөмбер, гөмберт, дөберт, капылт, коңгыйк, кәккүк, фиуть, челтер, чытырт, чәлдер, шылдырт, әптчхи, кикрикүк, һаптечү* һ.б.;

2) бердәй ике компонентлы аваз ияртемнәре: *гыж-гыж, гыр-гыр, гөж-гөж, гөрс-гөрс, каң-каң, келт-келт, кыйгак-кыйгак, кых-кых, кыштыр-кыштыр, дер-дер, доңк-доңк, дөбер-дөбер, дөп-дөп, мөгер-мөгер, мелт-мелт, мыгыр-мыгыр, мыр-мыр, мыш-мыш, зың-зың, пыш-пыш, пышык-пышык, пыр-пыр, тык-тык, тук-тук, тыр-тыр, тыпыр-тыпыр, торыйк-торыйк, фыр-фыр, фырт-фырт, чырт-чырт, челт-челт, чик-чик, чип-чип, чеп-чеп, чык-чык,*

*чылтыр-чылтыр, челтер-челтер, чымыр-чымыр, чың-чың, шып-шып, шытыр-шытыр, шар-шар, шыгыр-шыгыр, шыпыр-шыпыр, шыптыр-шыптыр, шыбыр-шыбыр, хыр-хыр, һам-һам, җем-җем, җылтыр-җылтыр, җилфер-җилфер* һ.б.;

3) бердәй өч компонентлы аваз ияртемнәре; *а-а-а, бытыр-бытыр-бытыр, га-га-га, ге-ге-ге, гу-гу-гу, гый-гый-гый, даң-даң-даң, диң-диң-диң, ко-ко-ко, пип-пип-пип, тук-тук-тук, тә-тә-тә, у-у-у, үә-үә-үә, ха-ха-ха, хе-хе-хе, хи-хи-хи, чут-чут-чут, һо-һо-һо, һу-һу-һу* һ.б;

4) парлы аваз ияртемнәре: *галдыр-голдыр, галт-голт, даң-доң, даңгыр-доңгыр, дөбер-шатыр, ялт-йолт, ялтор-йолтыр, ялык-йолык, лап-лоп, ларык-лорык, лач-лоч, лачт-лочт, лачтыр-лочтыр, лаштыр-лоштыр, пых-кых, тык-тук, тырт-мырт, чалдор-чолдыр, чалк-чолк, чалт-чолт, чап-чоп, чатыр-чотыр, чаш-пош, чаш-пож, челтер-белтер, чып-пыш, шабыр-шобыр, шак-шок, шалдыр-гөлдер, шалт-шолт, шалтыр-шолтыр, шап-шоп. шар-шор, шарт-шорт, шатыр-шотыр, ык-мык, әлҗе-мөлҗе, өф-төф һ*.б.;

5) катлаулы аваз ияртемнәре*: кә-күк...күк-кү...күк-кү; та-та-ри-ра-ри-рай-ри-ра-ри-рай; тра-трра-тррат-татата; тилли-тилли-тан... тилли-тилли-тен; трим-там-там-та-та; тук-тук-тын-тук; чакы-чокы-чак; иха-ха-ха...иха-ха... миха...ха; һа-һу-һи-һа* һ.б.

Фәнни әдәбиятта аваз ияртемнәре, ымлыклар кебек үк, морфологик категорияләр белән төрләнмиләр: аларның грамматик мәгънәләре дә, грамматик формалары да юк, дигән фикер формалашкан [Хангилдин В., 1959, б. 275; Суник О., 1966, с. 44–45]. Әмма тел фактлары, ымлыклардан үзгә буларак, аваз ияртемнәрендә дә, кушымчаларга охшаган *-т, -к, -ек // -ек, -ыр //-ер, -ыл / -ел* кебек элементларның булуы турында сөйлиләр. Тамыр аваз ияртемнәренә ялганып, бу элементлар тавыш яки яктылык күренешләрен куәтлек, тизлек, кинәтлек яки дәвамлылык ягыннан характерлауга хезмәт итәләр. Мәсәлән: *дер-т, фыр-т, доң-к, мыш-к, лыч-ык, чыр-ык, келт-ер, елт-ыр, чап-ыл, чеңг-ел.*

Тавыш яки яктылык күренешләренең төрле дәрәҗәләрен белдерергә кирәк булганда, бер үк аваз ияртемнәренә бер-бер артлы берничә «кушымча» ялганып килә ала. Мәсәлән: *дөб-ер-т, шыг-ыр-т, даң-г-ы-р-т, лач-тыр-т, ялт-ыр-т* һ.б.

Кагыйдә буларак, ымлыклардан, бик сирәк очракларны гына исәпкә алмаганда, яңа сүзләр бөтенләй ясалмый, бу аваз ияртемнәре исә исем һәм фигыльләр ясау өчен нигез булып хезмәт итәләр.

Образлы мәгънәләрен югалта һәм акрынлап лексик символларга әверелә бару уңаенда аваз ияртемнәре я исем, я фигыль, я рәвеш булып китәләр, ди проф. Н. Ашмарин [Ашмарин Н., 1928, с. 129]. Һәм, чыннан да, төрле тавышларның тасвирлары метафорик нигездә ияләренең үзләренә – җанлы һәм җансыз предметларга – күчерелеп, тора-бара аларның исемнәре хезмәтен үти башлаганнар. Мәсәлән: *кәккүк, тартар, ләкләк, бытбылдык, шөлдер, чаң, чың, чатыр-чотыр* һ.б.

Морфологик юл белән исем сүзләр аваз ияртемнәренә түбәндәге кушымчалар ялганып ясалалар; *-а, -е, -га/-кә, -ле, -на, -ма/-мә, -мак, -ман, -ыз, -ыл, -ым. -ылты/-елте, -ын, -ран* һ.б. Мисаллар: *дыңгыр-а, күк-е, кар-га, чикерт-кә, тор-на, чак-ма, шак-мак, тук-мак, чытыр-ман, йолд-ыз, шав-ыл, дав-ыл, йылдыр-ым, балк-ыш, гөр-елте, хыр-ылты, шав-ылты, ялк-ын, тук-ран* (исемнәр); *гөбер-ле, ләч-мә, елд-ам, тыңк-ыш, челдер-мәле, мышт-ым* (сыйфатлар) һ.б.

Фигыльләр аваз ияртемнәреннән түбәндәге кушымчалар ярдәмендә ясалалар: *-а/-ә, -ы/-е, -ла/-лә.-да/-дә, -на/-нә, -ра/-рә, -гыр/-гер, -кыр/-кер, -ылда/-елдә* һ.б. Мисаллар: *чылтыр-а, гөлдер-ә, шаңгыр-а, чүк-е, шак-ы, кыт-на, мыш-на, чи-на, чың- ра, шаң-ра, ың-ра, чыңла, быз-ла, шар-ла, гү-лә, гөж-лә, жу-ла, гөмбер-лә, зыр-ла, чөкер-дә, чыкыр-да, шыңгыр-да, чымыр-да, каңг-ылда, зыңг-ылда, чыңг-ылда, без-елдә, чур-ылда, чут-ылда, чутк-ылда, черк-елдә, тыр-ылда, тек-елдә, зың-ылда, җем-елдә, дер-елдә, а-кыр, ү-кер, ба-кыр, пош-кыр, ыж-гыр* һ.б.

Татар телендә аваз ияртемнәре *кил-* һәм *ит-* ярдәмче фигыльләре тагылып, тезмә фигыльләр ясауда киң таралган. Мәсәлән: г*өж килү, гөр килү, пыр килү, зыр-зыр килү; ялт итү, гөлт итү, чулт итү, лык итү* һ.б.

Синтаксик функцияләре белән дә аваз ияртемнәре ымлыклардан кискен аерылалар. Кагыйдә буларак, ымлыклар җөмлә кисәге хезмәтен үти алмыйлар, ләкин үзләре генә мөстәкыйль җөмләләр ролендә кулланылалар. *Мәсәлән: Ч у ! Тышкы ишек ачылды түгелме?* (Г. Ибраһимов); *Т ф ү ! Көзге җилләр тиде теңкәгә!* (Һ. Такташ). Шул рәвешчә,

«ымлыклар бер үк вакытта һәм сүзләрнең, һәм, аеруча, җөмләләрнең эквивалентлары булып торалар» [Виноградов В., 1947, с. 746].

Аваз иярткемнәре, җөмләдәге башка сүзләр белән синтаксик бәйләнешкә кереп, күбесенчә, рәвеш хәле булып киләләр, хәтта хәбәр һәм аергыч функцияләрендә дә кулланылалар. Мәсәлән: *Эре-эре яңгыр тамчылары... ш ы б ы р - ш ы б ы р ява* (Г. Ибраһимов). *Ч у т - ч у т сайрый сандугачлар, җәйге таң сызылып бара* (Ә. Ерикәй). *К ы й - г а к казлар – к ы й г а к казлар бармыйсызмы безнең якларга?* (халык җыры); *Шул чакта үземне-үзем белештермичә, ч а л т берне яңагына* (М. Гафури). *Неводчыларның һ а й - һ у тавышлары ишетелеп, аның күңелен әллә нишләтеп, борчып җибәрделәр* (Ш. Камал).

## БИБЛИОГРАФИЯ

### *Рус телендә*


Азилова П. Префиксация в туркменском языке. Ашхабад, 1947.

Алиев У. В. Причастие карачаево-балкарского языка // Учен. записки Кабардино-балкарского гос. ун-та. Вып. 4. Нальчик, 1958.

Аналитические конструкции в языках различных типов. М.-Л.: Наука, 1965. 343 с.

Андреев И.А. Причастие в чувашском языке. Чебоксары: Чувашгосиздат, 1961. 62 с.

Андреева И.С. К вопросу о функционировании форм повелительного наклонения в современном русском языке // Функционально-семантический анализ грамматических категорий / ЛГПИ им. А.И.Герцена. Л., 1973. С. 123–136.

Арсланов Л.Ш., Нигматуллов М.М. К вопросу о происхождении аффикса *-ман/-мән* в татарском языке // Словообразование в тюркских языках: исследования и проблемы: материалы Международной тюркологической конференции, посвященной 80-летию Фуата Ганиева. Казань, 20–21 сентября 2010 г. / [сост.: И.И. Сабитова, канд. филол. наук; науч. ред.: А.А. Тимерханов, д-р филол. наук, проф., Э.И. Сафина, канд. филол. наук]. Казань, 2011. С. 142–146.

Архангельский А. Грамматика народно-татарского языка. Оренбург: Типо-литогр. Б. Бреслина, 1894. 96 с.

Ахманова О.С. К вопросу об отличии сложных слов от фразеологических единиц // Труды Института языкознания АН СССР. М.: Изд-во АН СССР, 1954. Т. 4. С. 50–73.

Ахмеров Ш. Синтаксический разбор глагола в казанско-татарском наречии. Казань: Типо-литогр. Казанского ун-та, 1895. 43 с.

Ашмарин Н И. О морфологических категориях подражаний в чувашском языке. Казань: Издание Академического центра, 1928. 60 с.

Бархударов Л.С., Штелинг Д.А. Грамматика алтайского языка. М.: Высшая школа, 1965.

Баскаков Н.А. Каракалпакский язык. М.: Изд-во АН СССР, 1952. 544 с.

Баскаков Н А. К вопросу о происхождении условной формы на *-са-сә* в тюркских языках: академику В.А. Гордлевскому к его семидесятипятилетию. М.: Изд-во АН СССР, 1953. С. 35–63.

Баскаков Н.А. Татарский язык // Тюркские языки. М.: Изд-во вост. лит-ры, 1960. С. 158–161.
Бенвенист Э. Обшая лингвистика. М.,1973.
Бирюкович Р.М. Семантика и формы выражения способов глагольного действия в чулымско-тюркском языке //Советская тюркология. 1980. № 1.
Богородский В.А. Введение в татарское языкознание. Казань: Татгосиздат, 1953. 220 с.
Бозиев А.Ю. Словообразование имен существительных, прилагательных и наречий в карачаево-балкарском языке. Нальчик: Кабардино-балкарское кн. изд-во, 1965. 88 с.
Бондаренко В Н. Виды модальных значений и их выражения в языке// Науч. докл. высш. шк. филол. наук. М., 1979. № 2. С. 54–61.
Бондаренко В Н. Отрицание как логико-грамматическая категория. М.: Наука, 1983. С. 212.
Бондарко А.В. Вид и время русского глагола. М.: Просвещение, 1971. 234 с.
Бондарко А.В. Грамматическая категория и контекст. Л.: Наука, 1971. 114 с.
Бондарко А.В. О некоторых аспектах функционального анализа грамматических явлений // Функционально-семантический анализ грамматических категорий. Л.: Наука, 1973. С. 5–30.
Бондарко А. В. Теория морфологических категорий. Л.: Наука, 1976. 255 с.
Бондарко А. В. Прииципы и методы функциональной грамматики и аспектологии. Л.: Наука, 1983. 208 с.
Бондарко А.В. Функциональная грамматика. Л.: Наука, 1984.
Бондарко А.В., Буланин Л.Л. Русский глагол.
Будагов Р.А. Введение в науку о языке. М.: Учпедгиз, 1958. 435 с.
Будагов Р.А. Категории синтаксических отношений // Вопросы языкознания. 1973. № 1. С. 3–15.
Бурганова Н.Б. О временных формах глаголов изъявительного наклонения в казанских говорах // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 3. Казань, 1974.
Вандриес Ж. Язык. М., 1937.
Васильев Л.М. Семантика русского глагола. М.: Высшая школа, 1981.
Вещилова В.Ф. Глаголы движения в турецком языке // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. Т. IV. Лексика. М.: Изд-во АН СССР, 1962. С. 101–104.
Виноградов В.В. Русский язык (Грамматическое учение о слове). М.-Л.: Учпедгиз, 1947. 784 с.
Виноградов В.В. О категории модальности и модальных словах // Труды Ин-та рус. яз. М.-Л.: АН СССР, 1950. Т. 2. С. 38–79.

Виноградов В.В. О некоторых вопросах теории русской лексикографии // Вопросы языкознания. 1956. № 5. С. 80–94.

Володин А.П., Храковский В.С. Особенности строения императивной парадигмы в сопоставлении синдикативной // Советская тюркология. 1978. № 6. С. 3–11.

Воронин С.В. Основы фоносемантики. Л.: Изд-во Лениградского ун-та, 1982. 244 с.

Вопросы грамматики тюркских языков. Алма-Ата : Изд-во АН Каз. ССР, 1956. 252 с.

Вопросы грамматического строя. М.: Изд-во АН СССР, 1955. 482 с.

Вопросы теории частей речи на материале языков различных типов. Л.: Наука, 1968. 343 с.

Гаджиева Н.Э. Словоизменительные категории имени и глагола в кумыкском языке (сравнительно с другими тюркскими языками). Махачкала: Юпитер, 2000.

Газизов Р. Татарский язык. Казань, 1967.

Гайсина Р.М. Лексико-семантическое поле глаголов отношения в современном русском языке. Саратов: Изд-во Саратовского ун-та, 1981.

Гак В.Г. Семантическая структура слова как компонент структуры высказывания // Семантическая структура слова: психологические исследования. М., 1971.

Гак В.Г. Высказывание и ситуация // Вопросы структурной лингвистики. М., 1973.

Гак В.Г. Теоретическая грамматика французского языка. М.: Высшая школа, 1979. 304 с.

Ганиев Ф.А. Видовая характеристика татарского глагола. Казань: Таткнигоиздат, 1963. 180 с.

Ганиев Ф.А. О синтетических и аналитических падежах в татарском языке // Ученые записки Казанского пединститута. Вып. 74. Казань, 1970. С. 74–82.

Ганиев Ф.А. О семантике и аналитических падежах в татарском языке // Вопросы тюркологии. 1970. С. 74–84.

Ганиев Ф.А. К вопросу о классификации частей речи в современном татарском языке // Вопросы тюркологии. 1971. № 10. С. 274–284.

Ганиев Ф.А. Проблемы классификации частей речи в современном татарском литературном языке // Вопросы морфологии татарского языка. Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. 81 с.

Ганиев Ф.А. Актуальные вопросы морфологии современного татарского литературного языка // Актуальные вопросы грамматики и стилистики татарского языка. Казань, 1981. С. 26–32.

Ганиев Ф.А. Образование сложных слов в татарском языке. М.: Наука, 1982.

Ганиев Ф.А. Семантические разряды глаголов татарского языка // Исследования по татарскому языкознанию. Казань, 1984. С. 75–84.

Гарифуллин С.Ф. Из истории изучения послелогов (дооктябрьский период) // Исследования по лексике и грамматике татарского языка. Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. С. 38–46.

Гиганов И. Грамматика татарского языка. СПб., 1801. 188 с.

Гилязов И.М. Формы изъявительного каклонения в татарских грамматиках первой половины XIX века // Татар тел белеме мәсьәләләре. Бишенче китап. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1972. Б. 99–115.

Головин Б.Н. К вопросу о парадигматике и синтагматике на уровне морфологии и синтаксиса // Единицы разных уровней грамматического строя языка и их взаимодействие. М.: Наука, 1969. С. 73–87.

Грамматика азербайджанского языка. Баку: Элм, 1971. 413 с.

Грамматика алтайского языка, составленная членами алтайской миссии. Казань, 1869.

Грамматика русского языка : В 2-х т. М.: Изд-во АН СССР, 1960.

Грамматика современного башкирского литературного языка. М.: Наука, 1981. 495 с.

Грамматика современного русского литературного языка. М.: Наука, 1970. 755 с.

Грамматика туркменского языка. Ашхабад: Ылым, 1970. 503 с.

Грунина Э.А. К вопросу об изучении семантической структуры индикатива // Советская тюркология. 1975. № 4. С. 82–91.

Грунина Э.А. К истории семантического развития перфекта на *-min* // Советская тюркология. 1976. № 1. С. 12–26.

Гузев В.Г. Очерки по теории тюркского словоизменения: имя (на материале староанатолийско-тюркского языка). Л.: Изд-во ЛГУ, 1987.

Гухман М.М. Грамматические категории и структура парадигм // Исследования по общей теории грамматики. М.: Наука 1968. С. 117–174.

Диляра Гарифовна Тумашева / сост. Ф.М. Хисамова. Казань: Фэн, 2003. 55 с.

Дмитриев Н.К. Грамматика кумыкского языка. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1940. 206 с.

Дмитриев Н.К. Грамматика башкирского языка. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1948–276 с.

Дмитриев Н.К. Категория принадлежности // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков : Т. II. Морфология. АН СССР. М., 1956.

Дмитриев Н.К. Служебные имена в турецком языке // Строй тюркских языков. М.: Изд-во вост. лит-ры, 1962. С. 114–132.

Дмитриев Н.К. Глаголы движения // Строй тюркских языков. М.: ИВЛ, 1962.

Дмитриев Н.К. Строй тюркских языков. М.: Изд-во вост. лит., 1962. 608 с.

Дмитриев Н.К., Чистяков В.М. Характеристика русских предлогов и татарских послелогов // Очерки по методике преподавания русского и родного языков в нерусской школе. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1948. С. 54–114.

Дыренкова Н.П. Грамматика шорского языка. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1940. 206 с.

Дыренкова Н П. Грамматика ойротского языка. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1940. 302 с.

Закиев М.З. Синтаксический строй татарского языка. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1963. 464 с.

Закиев М.З. К вопросу о категории падежа в тюркских языках // Проблемы тюркологии и истории востоковедения. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1964. С. 207–219.

Закиев М.З. Влияние Казанского университета на развитие тюркологии в 1-ой половине XIX века (до 1885 г.) // Вопросы татарского языкознания. Кн. 2-я. Казань : Изд-во Казан. ун-та, 1965. С. 357–393.

Закиев М.З. Формы обладания и отсутствия в тюркских языках // Лингвистический сборник. Ташкент: Фан. 1971. С. 23–29.

Закиев М.З. Классификация частей речи и аффиксов в тюркских языках // Советская тюркология.1973. № 6. С. 3–8.

Закиев М.З. Современный татарский литературный язык: Синтаксис. М.: Наука, 1974. 336 с.

Зейналов Ф.Р. Категория модальности и способы ее выражения в тюркских языках // Советская тюркология. 1970. № 2. С. 95–101.

Зейналов Ф.Р. Сравнительная грамматика тюркских языков. Баку: Изд-во Азерб. ун-та, 1975. 131 с.

Зиннатулина К.З. Залоги глагола в современном татарском литературном языке. Казань: Татар. кн. изд-во. 1969. 231 с.

Золотова Г.А. Коммуникативные аспекты русского синтаксиса. М.: Изд-во АН СССР, 1982 –368 с.

Иванов М. Татарская грамматика. Казань: Тип. Казан. ун-та, 1842. 311 с.

Иванов С.Н. Очерки по синтаксису узбекского языка (Форма на *-гак* и ее производные). Л.: Изд-во Ленинградского ун-та, 1959. 152 с.

Иванов С.Н. Родословное древо тюрок Абу-л-Гази хана. Ташкент: Фан, 1969. 203 с.

Иванов С.Н. К истолкованию категории принадлежности // Советская тюркология. 1973. № 4. С. 26–36.

Иванов С.Н. К истолкованию многозначности грамматических форм // Вопросы языкознания. 1973. № 6. С. 101–109.

Иванов С.Н. Об изучении грамматики тюркских языков. История и современность // Советская тюркология. 1976. № 5. С. 54–66.

Иванов С.Н. Курс турецкой грамматики. Ч. 2. Л.: Изд-во Ленинградского ун-та, 1977. 87 с.

Ильминский Н. Учащательные формы татарского глагола // Учен. зап. Казанского ун-та, по отделению ист.-филол., политико-юрид. наук. Казань, 1863. С. 15–18.

Искаков А.И. О подражательных словах в казахском языке // Тюркологический сборник. 1. М.-Л., 1951. С. 103–111.

Исенгалиева В. Тюркские глаголы с основами, заимствованными из русского языка. Алма-Ата: Наука, 1966. 248 с.

Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков: В 3-х т. М.: Изд-во АН СССР, 1956. Ч. 2: Морфология. 335 с.

Исследования по татарскому языкознанию. Казань, 1984. С. 146–155.

Исхаков Ф.Г. Имя прилагательное// Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. М.: Изд-во АН СССР, 1956. Ч. II. С. 143–175.

Исхаков Ф.Г. Числительное // Исследования по сравнительной грамматике тюркских языков. Морфология. М .: Изд-во АН СССР, 1956. С. 180, 196–197.

Исхаков Ф.Г., Пальмбах А.А. Грамматика тувинского языка. М.: Изд-во вост. лит-ры, 1961. 472 с.

Казем-Бек А. Грамматика турецко-татарского языка. Казань, 1839. 528 с.

Казем-Бек А. Общая грамматика турецко-татарского языка. Казань: Тип. Казан. ун-та, 1846. 467 с.

Катанов Н.Ф. Опыт исследования урянхайского языка с указанием главнейших родственных отношений его к другим языкам тюркского корня: В 2-х т. Казань: Типо-литогр. Имп. Казанского ун-та, 1903. Т. 1. 832 с.; Т. 2. 833 с.

Кильдибекова Т.А. Глаголы действия в современном русском языке. Саратов: Изд-во Саратовского ун-та, 1985.

Ким К.Б. Образные слова нанайского языка. Л.: Наука, 1973.

Классы слов и их взаимодействие. Свердловск, 1980.

Кононов А.Н. Грамматика турецкого языка. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1941. 312 с.

Кононов А.Н. Грамматика современного турецкого литературного языка. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1956. 569 с.

Кононов А Н. Грамматика современного узбекского литературного языка. М.-Л.: Изд-во АН СССР, 1960. С. 238.

Кононов А.Н. Грамматика языка тюркских рунических памятников VII – IX вв. Л.: Наука, 1980. 255 с.

Кононов А.Н. Заметки по морфологии турецкого языка // Советская тюркология. Л., 1980. 2. С. 14–20.

Крючков С.С., Максимов Л.Ю. Синтаксис сложного предложения // Современный русский язык. М : Просвещение, 1969. С. 31–32.

Кудайбергенов С. Подражательные слова в киргизском языке. Фрунзе: Киргизучпедгиз, 1957. 106 с.

Кузнецов П И. К обоснованию теории вербальности тюркского предложения // Советская тюркология. 1980. № 3. С. 48–56 (статья первая); № 4. С. 43–54 (статья вторая).

Кузнецова Э.В. Русская лексика как система. Свердловск, 1980.

Кузнецова Э.В. Лексикология русского языка. М.: Высшая школа, 1982.

Курбатов Х.Р. Татарская лингвистическая стилистика и поэтика. М.: Наука, 1978. 218 с.

Кучкартаев И.К. Валентный анализ глаголов речи в узбекском языке. Ташкент, 1977.

Ломоносов М.В. Российская грамматика. СПб.: Иждивением Имп. Академии наук, 1755. 449 с.

Любимов К.М. Система грамматических времен в современном турецком языке // Советская тюркология. 1970. № 2. С. 44–64.

Майтинская К.Е. Служебные слова в финно-угорских языках. М.: Наука, 1982. 196 с.

Мардиева М.Б. К сравнительной характеристике перифрастических форм тюркских языков // Очерки по морфологии татарского глагола. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1978. С. 63–83.

Мардиева М.Б. Роль перифрастических форм в выражении временных и модальных значений // Структура и история татарского языка. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1982. С. 45–51.

Мартынов В В. Категория языка: семиол. аспект. М.: Наука, 1982. 192 с.

Материалы по татарской диалектологии. Казань: Татар. кн. изд-во, 1972. 132 с.

Махмудов М. Практическое руководство к изучению татарского языка. Казань: Тип. Казанского ун-та, 1857. 255 с.

Махмутова Л.Т. Опыт исследования тюркских диалектов. Мишарский диалект. М.: Наука, 1978. 268 с.

Милославский И.Г. Морфологические категории современного русского языка. М.: Просвещение, 1984. 254 с.

Мудрак О.А. Классификация тюркских языков и диалектов на данных морфологии и исторической фонетики // Словообразование в тюркских языках: исследования и проблемы: материалы Международной тюркологической конференции, посвященной 80-летию Фуата Ганиева. Казань, 20–21 сентября 2010 г. / [сост. И.И. Сабитова, канд. филол. наук; науч. ред.: А.А. Тимерханов, д-р филол. наук, проф., Э.И.Сафина, канд. филол. наук]. Казань, 2011. С. 98–101.

Мусаев К.М. О глагольно-именных формах на *-ган, -атын (а), -р, -у, -(ы)с, -кы* и конструкциях, образованных на их основе в современном казахском языке // Известия АН Каз. ССР. Серия филологии и искусствоведения. Вып. 1. Алма Ата, 1957. С. 65–79.

Наджип Э.Н. Современный уйгурский язык. М., 1960. 133 с.

Насилов В.М. К вопросу о грамматической категории вида в тюркских языках // Труды Московского института востоковедения, 1947. № 4.

Насилов Д.М. Типологические сопоставления в рамках сравнительно-исторического изучения отдельных грамматических категорий // Советская тюркология. 1971. № 2. С. 59–66.

Насилов Д.М. К истории вспомогательных глаголов в тюркских языках // Тюркологические исследования. М., 1976.

Насилов Д.М. Формы выражения способов глагольного действия в алтайских языках // Очерки сравнительной морфологии алтайских языков. Л.: Наука, 1978.

Насилов Д.М. Аспектуальные значения аналитических образований и разряды глагольной лексики в узбекском языке // Теория грамматического значения и аспектологические исследования. Л.: Наука, 1984. С. 128–165.

Насыйри К. Краткая татарская грамматика, изложенная в примерах. Казань, 1860.

Нигматов Х.Г. Соотношение категории времени и наклонения в тюркских глаголах // Советская тюркология. 1970. № 5. С. 51–57.

Нигматов Х.Г. О характере грамматического значения тюркских форм и категорий // Советская тюркология. 1980. № 6. С. 44–50.

Панфилов В.З. Гносеологические аспекты философских проблем языкознания. М.: Наука, 1982. 357 с.

Пешковский А.М. Русский синтаксис в научном освещении. М.: Учпедгиз, 1938. 451 с.

Пешковский А.М. Лингвистический энциклопедический словарь. М., 1990.

Петров Н. Е. О содержании и объеме языковой модальности. Новосибирск: Наука, 1982. 161 с.

Плунгян В.А. Общая морфология. Введение в проблематику. М., 2000.

Поцелуевский Е.А. Тюркский трехчлен. М.: Наука, 1967. 136 с.

Предикативное склонение причастий в алтайских языках. Новосибирск: Наука (Сиб. отделение), 1984. 192 с.

Проблема общности алтайских языков. Л.: Наука, 1971. 404 с,

Рамазанова Д.Б. Грамматические особенности говора пермских татар // Материалы по татарской диалектологии. Вып. 3. Казань: Татар. кн. изд-во, 1974. С. 92–112.

Розенталь Д.Э., Теленкова М.А. Справочник лингвистических терминов. М. 1972.

Розенталь Д.Э., Теленкова М.А., Голуб И.Г. Современный русский язык. М., 1990.

Русская грамматика: В 2-х т. М.: Наука, 1980. Т. 1. Фонетика. Морфология. 783 с,

Русский язык. Энциклопедия. М.: Сов. энциклопедия, 1979–431 с.

Русско-татарский словарь / под ред. д-ра филол. наук Ф.А. Ганиева. М.: Русский язык, 1984.

Салехова Н.Х. Средства выражения временной и аспектуальной характеристики действия в их отношении к категории времени татарского глагола // Очерки по морфологии татарского глагола. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1978. С. 27–44.

Сафиуллина Ф.С. Синтаксис татарской разговорной речи. Казань: Изд- во Казан. ун-та, 1978. 253 с.

Сафиуллина Ф.С. Функционально-семантическая категория утверждения и отрицания (На материале татарского языка) // Советская тюркология. № 5. 1980.

Севортян Э.В. Современное состояние и некоторые вопросы исторического изучения тюркских языков в СССР // Вопросы методов изучения истории тюркских языков. Ашхабад: Изд-во АН Туркменской ССР, 1961. С. 11–41.

Севортян Э.В. Аффиксы именного словообразования в азербайджанском языке // Опыт сравнительного исследования. М.: Наука, 1966. С. 370–377.

Севортян Э.В. Несколько замечаний к тюркологическим исследованиям по грамматике // Советская тюркология. 1970. № 3. С. 3–16.

Севортян Э.В. Этимологический словарь тюркских языков. Общетюркские и межтюркские основы на букву «Б» / АН СССР. Институт языкознания. М., 1978.

Сергеев В.И. Морфологические категориальные и некатегориальные формы в современном чувашском языке. Чебоксары, 2002.

Серебренников Б.А. К проблеме типов лексической и грамматической абстракции // Вопросы грамматического строя. М: Изд-во АН СССР, 1955. С. 54–73.

Серебренников Б.А. Проблема глагольного вида в тюркских языках // Вопросы грамматики тюркских языков. Алма-Ата, 1958.

Серебренников Б.А. Система времен татарского глагола. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1963. 75 с.

Серебренников Б.А., Гаджиева Н.З. Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Баку: Маариф, 1979. 304 с.

Сибгатов Р.Г. Модальность как структурно-семантическое единство // Советская тюркология. 1978. № 4. С. 21–30.

Сибгатов Р.Г. Модальный конституетет предложения (на материале татарского языка) // Советская тюркология. 1979. № 1. С. 3–14.

Современный русский язык. М.: Высшая школа, 1981. 560 с.

Современный татарский литературный язык. Лексикология, фонетика, морфология. М.: Наука, 1969. С. 210–294.

Современный татарский литературный язык. Синтаксис. М.: Наука, 1971. С. 10–35.

Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков: региональные реконструкции. М.: Наука, 2002.

Степанов Ю.С. Имена, Предикаты, Предложения, Семиограмматика. М.: Наука, 1981. 360 с.

Татарская грамматика: В 3-х т. Казань. Т. I. 1993. 584 с.; Т. II. 1997. 397 с.; Т. III. 1992. 488 с.

Тенишев Э.Р. Глаголы движения в тюркских языках // Историческое развитие лексики тюркских языков. М.: Изд-во АН СССР, 1961. С. 233–293.

Теория функциональной грамматики. Темпоральность. Модальность. Л., 1990.

Троянский А. Краткая татарская грамматика. Изд. исп. и доп. Казань: Изд-во дух. учебн. упр., 1860. 234 с.

Тумашева Д.Г. Перифрастические формы татарского глагола // Вопросы татарского языкознания. Кн. 2. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1965. С. 154–166.

Тумашева Д.Г. Глагол // Современный татарский литературный язык. Лексикология, фонетика, морфология. М.: Наука, 1969. С. 210–294.

Тумашева Д.Г. Диалекты сибирских татар. Опыт сравнительного исследования. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1977. 294 с.

Тумашева Д.Г. К проблеме морфологических синонимов в татарском языке (на материале глагольных форм) // Структура и история татарского языка. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1982. С. 3–17.

Тумашева Д.Г. Семантика аналитических конструкций с глаголами движения // Татарский язык: лексическая и грамматическая семантика. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1984. С. 59–71.

Тумашева Д.Г. О способе номинации пространственной характеристики глагольного действия в татарском языке // Номинативный аспект лингвистических единиц в языках различных типов. Саратов, 1986. С. 129–141.

Тумашева Д.Г. Татарский глагол (Опыт функционально-семантического исследования грамматических категорий). Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1986. 187 с.

Тумашева Д.Г. О двух типах аналитических конструкций с глаголами движения в татарском языке // Сущность, развитие и функции языка. М.: Наука, 1987. С. 202–209.

Тумашева Д.Г. Взаимодействие грамматической семантики глагольных форм и ее связей с лексическим значением глагола // Языковые уровни и их взаимодействие. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1990.

Тумашева Д.Г. Взаимодействие лексической и грамматической семантики (на материале татарского глагола) // Исследование языковых систем в синхронии и диахронии. М.: Наука, 1991. С. 137–149.

Тумашева Д.Г. Ономасиологическая структура аналитических образований с глаголами движения // Труды международного семинара по компьютерной лингвистике и ее приложениям. Казань: Диалог, 1995. С. 305–313.

Тумашева Д.Г., Лизунова Р.Д. Многозначность и омонимия аналитических конструкций с глаголами движения в тюркских языках (на базе татарского языка) // Вопросы алтайского языкознания. Горно-Алтайск, 1988. С. 128–144.

Тумашева Д.Г., Шайхайдарова Д.Ш. Грамматическая категория лица и персональность татарского глагола // Очерки по морфологии татарского глагола. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1978. С. 45–62.

Ураксин З.Т. О междометиях и их классификации // Исследования по грамматике современного башкирского языка. Уфа, 1979. С. 88–94.

Урусбиев И.Х. Спряжение глагола в карачаево-балкарском языке. Черкесск, 1963.

Хальфин И. Азбука и грамматика татарского языка с правилами арабского чтения, преподаваемые в Казанской гимназии. Казань: Тип. Казан.ун-та, 1809. 106 с. (на арабской графике).

Харитонов Л.Н. Современный якутский язык: Ч. 1. Якутск: Янгиз, 1947. 312 с.

Хисамова Ф.М. Некоторые особенности формы на *-ган* в татарском языке // Вопросы татарского языкознания. Казань: Изд-во Казанского ун-та, 1969– С. 197–209.

Хисамова Ф.М. Формы на *-асы* в татарском языке // Сборник аспирантских работ. Кн. 2. Гуманитарные науки. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1969. С. 49–54.

Хисамова Ф.М. Временные значения на *-ган* в татарском языке // Сборник аспирантских работ. Кн. 3. Гуманитарные науки. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1971. С. 97–106.

Шайхайдарова Д.Ш. Семантическая структура грамматической категории лица татарского глагола (в рамках функционально-семантической категории персональности) // Структура и история татарского языка. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1982. С. 34–44.

Шведова Н.Ю. Очерки по синтаксису русской разговорной речи. М., 1960.

Шендельс Е.И. Многозначность и синонимия в грамматике. М.: Высшая школа, 1970.

Щерба Л.В. Языковая система и речевая деятельность. Л., 1974.

Щербак А.М. Очерки по сравнительной морфологии тюркских языков (Наречия, служебные части речи, изобразительные слова) / ответ. ред. Л.А. Покровская. Л., 1987.

Юлдашев А.А. Аналитические формы глагола в тюркских языках. М.: Наука, 1965. 275 с.

Юлдашев А.А. Соотношение деепричастных и личных форм глагола в тюркских языках. М.: Наука, 1977. 270 с.

Ярцева В Н. Взаимоотношение лексики и грамматики в системе языка // Исследования по общей теории грамматики. М.: Наука, 1968. С. 5–57.

*Татар телендә*

Абдуллина Л.С. Татар телендә синтетик үткән заманнарның үзенчәлекләре һәм семантик кулланылышы // Очерки по морфологии татарского глагола. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1978. С. 84–89.

Алпаров Г. Безнең телебездә падеж бармы, юкмы? // Белем. Казан. 1925. № 3. Б. 41–43.

Алпаров Г. Шәкли нигездә татар граматикасы (Телебезне гыйльми тикшерү юлында бер тәжрибә.). Казан: Татар. кит. нәшр., 1926. 164 б. (гарәп графикасында).

Алпаров Г. Сайланма хезмәтләр (Татар грамматикасы һәм гомуми тел белеме мәсьәләләре). 1945. 180 б.

Бәширова И.Б. Татар әдәби теле тарихы. Казан, 1999.

Борһанова Н Б. Татар теленең диалектлары буенча кыскача белешмә. Морфологик үзенчәлекләр. Татар теленең диалектологик сүзлеге. Казан, 1969. 636 б.

Вәлиди Җ. Татар теленең имла һәм сарыф вә нәхү кагыйдәләре. Казан: Мәгариф, 1915. 52 б. (гарәп графикасында).

Вәлиди Җ. Татар теленең кагыйдәләре. Казан, 1918. 44 б. (гарәп графикасында).

Вәлиди Җ. Татар теленең грамматикасы. Казан, 1919. 175 б. (гарәп графикасында).

Вәлиуллина З.М., Зиннәтуллина К.З., Сәгыйтов М.А. Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе. Казан: КДПИ, 1972. 206 б.

Гамәли тел сабаклары. 3 нче китап: Гамәли сарыф-нәхү. Казан, 1923.

Гарданов Х.Ш. Татар телендә тәкъбирлек категориясе һәм аның стилистик кулланышы // Вопросы тюркологии. Казань: Татар. кн. изд-во, 1970. С. 73–282.

Гарданова Л. Татар телендәге модаль сүзләрне өйрәнү // Совет мәктәбе. 1965. № 12. Б. 22–25.

Дмитриев Н.К. Башкорт теленең грамматикаһы. Өфө: Башкорт кит. нәшр., 1950. 300 б.

Зәйнуллин М.З. Хәзерге башкорт әдәби теле. Морфология. Өфе, 2002.

Зәкиев М.З. Ике составлы җөмләләрдә баш кисәкләрнең белдерелүләре һәм аларның төп мәсьәләләре. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1959. Б. 5–67.

Зәкиев М.З. Хәзерге татар әдәби теле. Казан, 1974. 336 б.

Ибраһимов Г. Татар сарыфы. Казан, 1911. 82 б. (гарәп графикасында).

Ибраһимов Г. Татар сарыфы. Казан: Сабах, 1918. 84 б. (гарәп графикасында).

Ибраһимов Г. Әсәрләр. Том 8. Төрки һәм татар теле белеме буенча хезмәтләр (1910–1930). Казан, 1987.

Ибраһимов С.М. Татар телендә аналитик төзелмәләр. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1964. 134 б.

Ибраһимов С.М. Татар телендә синтаксик синонимнар. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1976. 168 б.

Кәбутари Х. Сарыф төрки. 1910.

Курбатов Х.Р. Татар теленең синтаксис һәм стилистика мәсьәләләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1956. 176 б.

Курбатов Х.Р. Хәзерге татар әдәби теленең стилистик системасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. 192 б.

Курбатов Х.Р. Телнең морфологик төзелешен өйрәнүгә карата // Татар теле һәм әдәбияты. 5 кит. Казан, 1976. Б. 107–115.

Максуди Һ. Төрки сарфы. Казан, 1910. 48 б. (гарәп графикасында).

Мөхәммәдиев М.Т. «Татарча-русча сүзлек»тә ярдәмлек сүзләрне бирү принциплары // Вопросы лексикологии и лексикографии татарского языка. Казань, 1976. С. 35–52.

Насыйри К. Әнмүзәҗ. Казан: Типо-литогр. Казан. ун-та, 1895. 876 б.

Нугайбәк Г. Төрлек. Казан. 1911. 80 б.

Нуриева А. Төрле наклонениеләрдәге фигыльләрнең заман белән төрләнүенә карата // Татар теле һәм диалектологиясе мәсьәләләре. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1959. Б. 166–194.

Рамазанов Ш.А. Татар теле буенча очерклар. Казан: Таткнигоиздат, 1954.

Сафиуллина Ф.С. Текст төзелеше. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1993.

Сәгъди Г. Яңа һәм җиңел тәртиптә телебезнең сарыф вә нәхү кагыйдәләре. Казан, 1915.

Сәгыйтов М.А. Аваз ияртемнәрен өйрәнүгә карата // Вопросы тюркологии. Казань: КГПИ, 1970. С. 176–186.

Татар грамматикасы. Т. I. Мәскәү-Казан, 1998. 512 б.

Татар грамматикасы. Т. III: Синтаксис. Мәскәү-Казан, 1999. 512 б.

Татар грамматикасы. Т. II: Морфология. Мәскәү-Казан, 2003. 448 б.

Тумашева Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1964. 299 б.

Тумашева Д.Г. Татар теле морфологиясен өйрәнү һәм кайбер теоретик мәсьәләләр // Очерки по морфологии татарского глагола. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1978. С. 5–26.

Тумашева Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле. Морфология: югары уку йорты студентлары өчен дәреслек-кулланма. Казань: Казан ун-ты нәшр., 1978. 221 б.

Фәезханов Г. Татар телигә кыскача гыйльми сарыф. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1887. 32 б. (гарәп графикасында).

Ханбикова Ш. С. Татар телендә синонимнар. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1961. 64 б.

Ханбикова Ш.С. Татар телеңндә синонимия һәм сүзлекләр. Казан: Татар кит. нәшр., 1980. 208 б.

Хангильдин В Н. Татар теле грамматикасы. Морфология буенча очерклар. Казан: Татар кит. нәшр., 1954. 335 б.

Хангилдин В Н. Татар теле грамматикасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. 642 с.

Харисова Ч.М. Морфология: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2010.

Хәзерге татар әдәби теле (Лексика. Фонетика. Орфоэпия. Графика һәм орфография. Морфология). Казан, 1965. 299 б.

Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе / Казан дәүләт педагогика институты. Казан, 1972.

Хисамова Ф. М.Татар теле морфологиясе: югары уку йортлары өчен д-лек. Казан: Мәгариф, 2006. 334 б.

Хисамова Ф. М.Татар теле морфологиясе: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2015. 335 б.

Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе: уку-укыту кулланмасы / төз. Ф.М. Хисамова, Г.Р. Галиуллина, М.Х. Әнвәрова, А.Ә. Гафурова. Казан: Казан ун-ты нәшр., 2010. 126 б.

**Сүзлекләр**

Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге: татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре / К.З. Хәмзин, М.И. Мәхмүтов, Г.Ш. Сәйфуллин; ред.: Р.С. Газизов, М.Г. Гыймадиев, И.Г. Гыйльфанов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. 853б.

Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге: татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре. Т. 1. / төз. М.И. Мәхмүтов, К.З. Хәмзин, Г.Ш. Сәйфуллин. Казан: Иман, 1993. 448 б.

Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге: татар әдәбиятында кулланылган гарәп һәм фарсы сүзләре. Т. 2. / төз. М.И. Мәхмүтов, К.З. Хәмзин, Г.Ш. Сәйфуллин. Казан: Иман, 1993. Б. 449–854.

Древнетюркский словарь / ред.: В.М. Наделяев и др. Л.: Наука, Ленинградское отделение, 1969. 676 с.

Персидско-русский словарь: свыше 60000 слов. С приложением грамматического очерка персидского языка: в 2-х т.. Т. 1 / АН СССР, Ин-т востоковедения; сост.: М.Н. Османов, Д.Х. Дорри, Л.Н. Киселева [и др.]; под ред. Ю.А. Рубинчика. М.: Советская энциклопедия, 1970. 782 с.

Персидско-русский словарь: свыше 60000 слов. С приложением новых слов и грамматического очерка персидского языка: в 2-х т. Т. 2 / сост. М.Н. Османов; под ред. Ю.А. Рубинчика. 2-е изд., стер. М.: Рус. язык, 1983. 864 с.

Татарско-русский словарь / под ред. проф. Ф.А. Ганиева. Казань: Таткнигоиздат, 1985.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда.Т. 1: А – Й / СССР ФА, Казан филиалы, Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты; [редкол.: Л.Т. Мәхмүтова һ.б.]. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. 475 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. Т. 2: К – С / [төз.: И.А. Абдуллин һ.б.]. Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 726 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: өч томда. Т. 3: Т – Һ / [төз.: И.А. Абдуллин һ.б.]. Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. 832 б.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / ТФА. ТӘҺСИ; баш ред. проф. Ф.Ә. Ганиев. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.

Татар теленең зур диалектологик сүзлеге: якынча 40000 берәмлек / ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты; Төз.: Ф.С. Баязитова һ.б.; җав. мөх-р: Д.Б. Рамазанова, Т.Х. Хәйретдинова. Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. 839 б.

Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге / төз. Р.Г. Әхмәтьянов; фәнни ред.: Ф.Ә. Ганиев, В.Х. Хаков. Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. 272 б.

Татар теленең фразеологик сүзлеге / төз. Н. Исәнбәт. Яр Чаллы: Идел-йорт, 2001. 235 б.

Татарча-русча тел белеме терминнары сүзлеге: 4500 гә якын термин тупланып бирелде / төз. Ф.С. Сафиуллина; фәнни мөх. М.З. Зәкиев. Казан: Хәтер, 1998. 126 б.

Татар энциклопедия сүзлеге / баш мөх-р М.Х. Хәсәнев; җав. мөх-р Г.С. Сабирҗанов; баш гыйльми мөхәрририят: М.Х. Хәсәнев һ.б. Казан: Татар энциклопедиясе институты, 2002. 829 б.

Тел белеме буенча терминнар һәм әйтелмәләр сүзлеге / СССР ФА Казан филиалы, Тел, әдәбият һәм тарих ин-ты; Р.Ф. Шакирова редакциясендә. Казан: Татгосиздат, 1953. 76 б.

Тел гыйлеме терминнары сүзлеге / Х. Сәлим; фәнни мөх-р Д.Ә. Сәлимова. Алабуга: Алабуга пед. ин-ты нәшр., 2001. 88 б.

### Диссертация һәм авторефератлар

Акберова А.Г. Структура и семантика наречий в современном татарском литературном языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1998. 19 с.

Алиев В.Л. Причастие в современном азербайджанском и узбекском языках: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Ташкент, 1965.

Аминова А.А. Внутриглагольная деривация в русском и татарском языках: (сопоставительный аспект): автореф. дис....д-ра филол. наук. М., 1995. 70 с.

Ангели Ф.А. К вопросу о категории модальности и лексических средствах ее выражения в тюркских языках (на материале турецкого, азербайджанского и гагаузкого языков): автореф. дис. ... канд. филол. наук. М.: Изд-во Московского ун-та, 1964. 14 с.

Ахмедов Дж.С. Предикативы в современном азербайджанском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Л., 1970.

Баширова И.Б. Татарский литературный язык конца XIX – начала XX века: литературная норма, вариативность нормы и функционально-стилистическая вариативность в категориях имени существительного и наклонениях глагола: автореф. дис. … д-ра филол. наук. Казань, 2000. 67 с.

Баширова Н.З. Морфонологические процессы, сопровождающие словообразование в английском и татарском языках: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1994. 17 с.

Васильева Т.Н. Глаголы движения в современном чувашском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Уфа, 1980.

Габбасова Г.З. Средства выражения экспрессивности в татарском литературном языке (на материале имен существительных и прилагательных): автореф. дис. … канд. филол. наук. Уфа, 2002. 26 с.

Габдуллина И.Ф. Переход имен собственных в имена нарицательные в английском, немецком и татарском языках: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2003. 28 с.

Гадельшин А.С. Инфинитивная форма глагола в современном татарском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1965. 14 с.

Гайнутдинова А.Ф. Субстантивные прилагательные в татарском и русском языках (сопоставительное исследование): автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2002. 21 с.

Гаряев Р.Н. Категории числа и принадлежности имени существительного и происхождение их показателей в татарском языке: автореф. дис. … канд. филол. наук. Тобольск, 2009. 26 с.

Гильфанова Р.Т. Система глагольных времен в татарском и французском языках: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1998. 18 с.

Гиниятуллина А.Ю. Татарское причастие на *-ган* и его эквиваленты в английском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2006. 19 с.

Гыйләҗева Л.Г. Хәзерге татар әдәби теле фәнни стиленең лексик-грамматик үзенчәлекләре: филол. фән. канд. ... дис. Казан, 2005. 260 б.

Закамулина М.Н. Категория темпоральности в неродственных языках (сопоставительное исследование временных форм во французском и татарском языках): автореф. дис. … д-ра филол. наук. Казань, 2001. 48 с.

Зарипов Р.Ф. Категория падежа в башкирском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Уфа, 1971. 23 с.

Зейналов Ф.Р. Служебные части речи в современных тюркских языках: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Баку, 1966. 17 с.

Ибрагимова М.Ю. Ирреальная модальность и средства её передачи в татарском языке: автореф. … канд. филол. наук. Казань, 1975.

Ирисов Н.И. Генетив в современном татарском языке (к проблеме взаимодействия морфологии и синтаксиса): автореф. дис. … канд. фил. наук. Казань, 1983.

Искаков А.И. Морфологическая структура слова и именные части речи в современном казахском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Алма-Ата, 1964. 18 с.

Иштанова Р.К. Глаголы татарского языка в семантическом аспекте: дис. … канд. филол. наук. Казань, 2002. 264 с.

Костенко В.А. Имена прилагательные в современном татарском литературном языке: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2002. 22 с.

Кулиев Г.К. Семантика глаголов в тюркских языках: автореф. дис. ... д-ра филол. наук. Баку, 1992.

Латфуллина Л.Г. Категория качественного прилагательного в современном татарском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. М., 2003.

Латыпов Р.И. Джамал Валиди и развитие татарской грамматической науки: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2007. 19 с.

Лизунова Р.Д. Семантика аналитических конструкций с глаголами движения (на материале татарского и других тюркских языков): авфтореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 1988.

Лутфуллина Г.Ф. Сопоставительный анализ средств выражения способов действия кратности во французском и татарском языках: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2004. 24 с.

Мардиева М.Б. Перифрастические формы татарского глагола и сравнение с узбекскими и турецкими формами: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 1976. 20 с.

Минниахметов Р.Г. Модальные слова и частицы как лексико-грамматическое средство выражения модальности в татарском языке: автореф. дис. … канд. филол. наук. Уфа, 2000. 22 с.

Миннуллин Ф.Г. Глаголы татарского языка и их лексикографирование: дис. канд. филол. наук. Казань, 2003. 213 с.

Мирзаев Г.И. Причастие в современном азербайджанском литературном языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Баку, 1965.

Мифтахова И.Г. Развитие грамматической теории в татарском языкознании. Самостоятельные части речи (по татарским грамматикам XIX – начала XX вв.): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1998 . 29с.

Мифтахова И.Г. Развитие грамматической теории в татарском языкознании, самостоятельные части речи (по татарским грамматикам XIX – начала XX вв.): дис. канд. филол. наук. Казань, 1998. 394 с.

Насырова Г.Г. Деятельность Каюма Насыри в области татарского языкознания: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2002. 24 с.

Нуриева А.Х. Система спряжения глагола по категории времени в татарском языке: автореф. дис. . канд. филол. наук. Казань, 1961. 21 с.

Пашковский А.А. Словообразование в современном японском языке (типы сложных и аффиксальных слов): автореф. дис. ... д-ра филол. наук. М., 1952. 29 с.

Сагдиева Р.К. Аффиксы как средства выражения конкретизирующих отношений в татарском языке: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2000. 21 с.

Садыйкова Л.Р. Шиһап Рамазановның татар тел белеме өлкәсендәге фәнни эшчәнлеге: филол. фән. канд. ... дис. Казан, 2010. 147 б.

Садыкова Р.З. Валентность татарского глагола: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2013. 27 с.

Садыкова Р.З. Валентность татарского глагола: дис. … канд. филол. наук. Казань, 2013. 199 с.

Салахова Р.Р. Омонимичные суффиксы татарского языка: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2004. 24 с.

Салехова Н.Х. Грамматическая категория времени татарского глагола и темпоральность: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1975. 20 с.

Салимова Д.А. Части речи в разноструктурных языках: системно-функциональный подход (на материале татарского и русского языков): автореф. дис. … д-ра филол. наук. Казань, 2001. 51 с.

Самирханова Г.Р. Выражение падежных отношений в татарском литературном языке : автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2004. 21 с.

Сат Ш.Ч. Причастия в тувинском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. М., 1961.

Тадыкин В.Н. Причастие в современном алтайском языке: дис. ... канд. филол. наук. М., 1967.

Фаттахова Р.Ф. Категория числа в современном татарском литературном языке: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2002 . 25 с.

Хангишиев Дж.М. Причастия в кумыкском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Баку, 1966. 24 с.

Хәкимов Б.Э. Галимҗан Ибраһимовның татар тел белеме өлкәсендәге эшчәнлеге: филол. фән. канд. ... дис. Казан, 2005. 259 б.

Хисамова Ф.М. Причастия в современном татарском литературном языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 1970. 27 с.

Шайхайдарова Д.Ш. Грамматическая категория лица татарского глагола и персональность: автореф. дис. … канд. филол. наук. Алма-Ата, 1980.

Шәрәфетдинова З.Г. Хәзерге татар әдәби телендә ияртемнәр: филол. фән. канд. ... дис. Казан, 2007. 263 б.

Якупова В.И. Сравнительно-типологическое исследование наречия и его суффиксальных производных в английском и татарском языках: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2002. 20 с.

ЭЧТӘЛЕК

КЕРЕШ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 5
1. ИСЕМ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
1.1. Исемнең семантик төркемчәләре . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
1.2. Исемнәрнең өйрәнелү тарихы . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
1.3. Исемнәрнең грамматик категорияләре . . . . . . . . . . . . . 31
1.3.1. Сан категориясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
1.3.2. Тартым категориясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
1.3.3. Килеш категориясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 43
1.3.4. Хәбәрлек категориясе . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
1.3.5. Исемдә билгелелек-билгесезлек мәсьәләсе . . . . . . . 57
1.4. Исемләшү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
1.5. Исемдә иркәләү-кечерәйтү кушымчалары . . . . . . . . . . . . 59
2. СЫЙФАТ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60
2.1. Сыйфатның лексик-грамматик төркемчәләре . . . . . . . . . 62
2.2. Сыйфат дәрәҗәләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63
3. САН . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
3.1. Саннарны өйрәнү тарихы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
3.2. Сан сүз төркеменең үзенчәлекле билгеләре . . . . . . . . . 68
3.3. Сан төркемчәләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
3.4. Саннарның исемләшүе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
3.5. Нумератив сүзләр (Сан ачыклагычлары) . . . . . . . . . . . 82
4. ФИГЫЛЬ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
4.1. Фигыльнең лексик-грамматик мәгънәсе . . . . . . . . . . . . 84
4.2. Фигыль лексикасын өйрәнү һәм төркемләү мәсьәләсе . . . . 94

4.3. Фигыльнең функциональ-семантик һәм грамматик категорияләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 109
4.3.1. Темпоральлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 115
Хикәя фигыль заманнары . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116
Хәзерге заман . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 116
Үткән заман формалары . . . . . . . . . . . . . . . . . . 119
Киләчәк заман формалары . . . . . . . . . . . . . . . . 129
Сирәк кулланыла торган (архаиклашкан) заман формалары 133
Башка фигыль формаларының темпоральлеге . . . . . . 134
4.3.2. Модальлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 141
Боеру модальлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 141
Теләк наклонениесе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 150
Шарт модальлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 153
Мөмкинлек модальлеге (мөмкинлек мәгънәсен белдерә торган формалар) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164
Кирәклек модальлеге (кирәклекне белдерә торган формалар) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 166
Тиешлек модальлеге (тиешлек мәгънәсен белдерә торган формалар) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 168
Ният модальлеге (ният мәгънәсен белдерә торган формалар) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 170
Фараз итү модальлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172
4.3.3. Персональлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 172
4.3.4. Фигыль юнәлешләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 186
Төп юнәлеш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 189
Төшем юнәлеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 189
Кайтым юнәлеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 198
Уртаклык юнәлеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 201
Йөкләтү юнәлеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 205
4.3.5. Затланышсыз фигыльләр . . . . . . . . . . . . . . . . 209
Сыйфат фигыль . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 209

Хәл фигыль . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 246
Исем фигыль . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 255
Инфинитив . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 258
4.3.6. Фигыльдә дәрәҗә-ысул категориясе . . . . . . . . . . 260
5. АЛМАШЛЫК . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 308
6. РӘВЕШ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 318
7. ХӘБӘРЛЕК СҮЗЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 322
8. МОДАЛЬ СҮЗЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 337
9. БӘЙЛЕКЛӘР ҺӘМ БӘЙЛЕК СҮЗЛӘР . . . . . . . . . . 350
10. ТЕРКӘГЕЧ ҺӘМ ТЕРКӘГЕЧ СҮЗЛӘР . . . . . . . . . 358
11. КИСӘКЧӘЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 383
12. ЫМЛЫКЛАР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 395
13. ИЯРТЕМНӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 402
БИБЛИОГРАФИЯ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 411

Научное издание

**ТАТАРСКАЯ ГРАММАТИКА**

**Том II**

(на татарском языке)

Редактор *Я.М. Абдулкадырова*
Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*
Дизайн обложки *Л.Ш. Давлетшиной*

Подписано в печать:16.12.2016.
Формат 60×84 $^{1}/_{16}$. Гарнитура «Times».
Бумага офсетная, печать офсетная.
Усл.-печ. л. 25,1. Уч.-изд. л. 21,2.
Тираж 1000. Заказ №

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, г. Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, г. Казань, ул. Баумана, 20